Туфан Миңнуллин

Пьесалар

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2010

УДК 821.512.145-2
ББК 84(2Рос=Тат)-6
М57

**Миңнуллин, Т.А.**

Пьесалар / Туфан Миңнуллин; кереш сүз авт. А.Габәши-Салихова. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2010. – 415 б.

ISBN 978-5-298-01906-4

Китапка танылган драматург, Татарстанның халык язучысы Туфан Миңнуллинның соңгы елларда язылган драма әсәрләре туплап бирелде.

УДК 821.512.145-2
ББК 84(2Рос=Тат)-6

ISBN 978-5-298-01906-4

© Татарстан китап нәшрияты, 2010

© Миңнуллин Т.А., 2010

## ИҖАТЫНДА – ИЛ ГАМЕ

Татар мәдәниятенең үсеше, аеруча әдәбият һәм театр, җәмәгатьчелектә һәрвакыт зур кызыксыну уята килде. Соңгы вакытларда бу хакта әледән-әле кайнар бәхәсләр дә булып тора. Буыннар чылбыры ныклыгы, традицияләрне саклау һәм яңалыкка омтылу, һаман хәрәкәттә, үсештә булган зур тизлек заманы куйган таләпләрне үзенә генә хас нәфислек, гүзәллек, дөньяга карашлар җыелмасы аша хәл иткәндә татар театры үз асылын вә миллилеген саклап кала алырмы – болар һәрвакыт, һәр заманда иң җитди мәсьәләләр булып кала бирә. Бүгенге заман театр сәнгате кичерә торган катлаулы вазгыятьтән кайберәүләр шөбһәле уйларга бирелеп шүрләп калса, икенчеләре исә, киресенчә, киләчәкне матур итеп күрү дәрте белән рухланып яши. Россия чикләрендә дә яхшы билгеле, күренекле драматургыбыз Туфан Миңнуллин нәкъ менә шундыйлардан. Әдипнең олпатлыгы шунда – аның ирекле иҗади фикерләве, форма белән вәкарьле идарә итү осталыгы сәхнә традицияләренә һәм милли идеалларга тугрылыгы белән органик төстә үрелеп бара.

Шулай да Туфан ага турында язуы җиңелләрдән түгел. Моның берничә сәбәбен атап үтәм. Иң тәүдә – әдипнең киң кырлылыгы, гаҗәеп күп әсәрләр иҗат итүе. Аның 2002 елда дөнья күргән 10 томлы «Сайланма әсәрләр» җыентыгында төрле жанрдагы иҗат җимешләре исемлеге генә дә 60 битне алып тора! Болар – пьесалар, хикәяләр, юморескалар, әдәби-нәфис һәм публицистик мәкаләләр, күпсанлы әңгәмәләр... Шушы гаҗәеп олуг дәрья төпкеленнән гаять киң кырлы, хәрәкәтчән, һаман үсештә-үзгәрештә булган, акылын йөрәк авазына буйсындыра белгән Туфан Миңнуллин дигән олпат шәхес күтәрелә.

Әдипне хаклы рәвештә бәхетле йолдыз астында туганнар исемлегенә кертер идем. Ни өченме? Чөнки ул үзенең халыкка кирәклеген исән вакытында ук белеп, тоеп яши. Ә бу исә бик сирәк кешегә генә элэгә. Моның өчен әлбәттә күп көч, тир түгеп эшлисе, акыл һәм җан бергәлеге белән ихлас тырышлык куясы, ниндидер амбицияләреңне вә шәхси мәнфәгатьләреңне җәмгыять ихтыяҗларына буйсындыра алырлык фидакарь булуың кирәк! Т.Миңнуллин нәкъ менә шушы бөтенлекне саклый да инде. Ул үзен һәрвакыт олы бер кыйммәтнең бер өлеше итеп саный: илнең булсынмы, милләтнеңме, театрныкымы – монда Туфан яши, монда Туфан булмыйча калалмый... Мондый хиссият аңа ана сөте белән үк кергән, соңыннан исә тормыш тәҗрибәсе белән ныгытылган.

Т.Миңнуллин ишле гаиләдә туып үсә. Мәктәптән соң хисапчылар курсларын тәмамлагач, чирәм җирләрне күтәрүгә китә. Биредә ул төрле милләт кешеләре белән аралаша. Мәскәүдә Щепкин исемендәге данлыклы театр училищесында белем алу да бердәмлек хисләренең ныгуына ныклы нигез булып ята. Аның белән бергә укыган щепкинчылар буыны бүген дә үзләрен бүленмәс бербөтен итеп саный. Ошбу бергәлек, яшьтәшләре һәм хезмәттәшләре белән теләктәш булуы Туфанга алтмышынчы еллар буыны исеменнән сәхнә мөнбәреннән сөйләү хокукы бирде. Моның ачык мисалы – 1968 елда «Миләүшәнең туган көне» спектакле белән башланып киткән драматик трилогия. Аның икенче бүлеге режиссер Марсель Сәлимҗанов тарафыннан 1977 елда сәхнәгә менә. Соңгысын – «Хушыгыз!» исеме белән 1993 елда Фәрит Бикчәнтәев сәхнәләштерә. Билгеле бер хәят-чорны чагылдырып иҗат ителгән бу пьесага күпмедер дәрәҗәдә уникальлек хас. Ул тулы бер буынның кичерешләрен ачып сала: яшьлекләрендә чынбарлыкны идеаллаштырган һәм бар нәрсәне әхлакый югарылыктан карарга күнеккән буын кисәк кенә рухи үзгәрешләр кичерә. Алар инде кичәге бер кайгысыз яшь-җилкенчәк түгел, алар арыган, аларга ял кирәк, аларның идеаллары үзен-үзе аклый алмаган һәм, ни кызганыч, моның белән килешмичә һич чара юк. Менә бу – кырыс чынбарлык. Бернәрсә дә мәңгелек түгел, бу дөнья – фани... Һәрнәрсәнең чиге бар... Еллар узган саен, геройлары белән бергә автор үзе дә үзгәрә барды. Тышкы гадилегенә һәм күренешләрнең кыскалыгына, артык катлаулы булмавына карамастан, пьесаларның һәр өчесенә дә эчке тирән фаҗигалелек, эмоциональ һәм интеллектуаль бөтенлек, аерым урын вә вакыт кысаларыннан азат булган кискен конфликт хас. Кеше дигән горур яңгырашлы исемгә тап төшерми яшәргә тырышкан инсаннары булган җәмгыятьтә шунсыз

мөмкин дә түгел. Чөнки биредәге сатлыкҗанлык яисә, киресенчә, яшәеш кыйммәтләренә тугрылык, югары әхлакый җаваплылык, рәссам намусы кебек темалар – мәңгелек!

Трилогиягә карата режиссерларның мөнәсәбәте бик тә үзенчәлекле булды. Марсель Сәлимҗанов вазгыятьне үзе һәм замандашлары карашыннан чыгып бәяләсә һәм шуңа нисбәтле рәвештә спектакльләрне рәхимсез фаш итү формасында куюны сайлаган булса, Фәрит Бикчәнтәев исә, үзенең яраткан остазлары һәм ата-аналары буынының тормышын яктыртканда, күпкә йомшаграк, нәзакәтлерәк һәм хислерәк чишелешкә өстенлек бирде. Бу юл да үзен аклады диярге кирәктер. Ни өчен дигәндә, алтмышынчы елларда сәяси вазгыять җиңелләрдән булмады. Бу чорда кешеләр, үзләренең дөньяви күзаллауларына каршы килгән хәлдә, күп нәрсәне күрмәмешкә салынып, килешеп яшәргә дучар ителде (шуның өчен үзләрен рәхимсез төстә битәрләп яшәделәр) һәм шушы ихтыяри мәҗбүрилекне аларның артларыннан ук бастырып килгән яшь буын дөрес аңлады, гаепләмәде, буыннар арасындагы бәйләнешнең өзелүенә юл куелмады. Үзара ышаныч һәм эчкерсез мөгамәлә – шулар түгелме соң әлеге буынның иң зур җиңүе, иң зур шатлыгы?!

Т.Миңнуллин иҗатының ургылып аккан чишмәгә тиң яшәү көченә ия булуының янә бер сере – аның армый-талмый эшләвендә, хезмәт сөючәнлегендә. Берсеннән-берсе төрле темаларны яктырткан 40 тан артык пьеса иҗат итте ул: колхозчылар һәм нефтьчеләр, авыл укытучылары һәм студентлар, пугачевчылар һәм җәлилчеләр... Совет заманында социаль заказ зур роль уйный иде бит, театрларга аерым проблеманы чагылдырган әсәрләр кирәк иде, бу җәһәттән Туфан Миңнуллин һәрвакыт әзер булып торды. Автор һәр эшен үз-үзен аямыйча, боларны язып кайчандыр дан-шөһрәт казанырмын дигән уйларга бирелмичә, намус белән башкарды. Шунысы да билгеле: нәкъ менә шулай эшләгәндә генә бәхет һәм танылу үзләре эзләп таба сине. Драматургның уңышлы әсәрләре Г.Камал театры сәхнәсендә куела барды, җәмәгатьчелектә зур кызыксыну тудырды, татар театр сәнгатенең якты маягына әйләнделәр. «Әлдермештән Әлмәндәр», «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Әниләр һәм бәбиләр», «Моңлы бер җыр» спектакльләре үзләре генә дә ни тора! «Әлдермештән Әлмәндәр» («Старик из деревни Альдермыш»), «Әниләр һәм бәбиләр» («Колыбельная»), «Моңлы бер җыр» («У совести вариантов нет») спектакльләренең үзәк телевидение каналыннан берничә мәртәбә күрсәтелүе язучыга гына түгел, татар драматургиясенә дә дәрәҗә өсти. Т.Миңнуллин пьесаларын Г.Камал театры гына түгел, республиканың һәммә театр коллективлары да үз итте. Аның күп әсәрләре К.Тинчурин (ул вакытта әле кучмә театр иде), Әлмәт, Минзәлә дәүләт һәм халык театрларында яратып уйналды, үзешчән сәнгать түгәрәкләре дә Т.Миңнуллин пьесаларына еш мөрәҗәгать иттеләр. Драматург шушы кечкенә генә бәйләнешләрне дә игътибарыннан читтә калдырмады, чөнки сәнгатьтә түбән һәм югары чиннарга буйсыну чире юк, һәркайсының үз йөзе, үз олпатлыгы. Хәер, Туфан агамы соң боларны аңламас?! Үзе дә һәр авылның кечкенә генә әртистләр коллективы булып күрше авылларга театр куеп йөргән заманда үскән, ныгыган лабаса. Артист буларак аңа үзешчән сәнгатьтә дә катнашырга туры килә, щепкинчылар студиясендә дә уйный, кечкенә булуына карамастан зур дәрәҗәләргә ирешкән Минзәлә татар дәүләт драма һәм мәшһүр Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәләренә дә менәргә насыйп була. Чын сәнгатьнең тылсымлы тарту көче бернинди шартларга буйсынмый, аңа күпме тамашачы җыелуы да мөһим түгел, сәхнәнең зуры-кечкенәсе юк һәм дәрәҗәсе ни бәһа торуы да роль уйнамый. Т.Миңнуллин бу хакыйкатьне бик яхшы үзләштерде. Алай гына да түгел, профессиональ артистлык тәҗрибәсе аңа сәхнәне тою көчен бирде һәм нәтиҗәдә Туфан әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә үзенең катлаулы һәм үтә бай эчке дөньясы белән бөтен уенны тотып торучы күпкырлы характерга ия образны түкми-чәчми тамашачыга җиткерә белгән актерны күрми калу мөмкин түгел иде! Әйтик, «Ай булмаса, йолдыз бар» драмасындагы төп роль Әлмәт театры артисткасы Дамира Кузаевага махсус атап язылды. Заманында бу спектакль гаҗәеп зур уңыш белән барды. Бу әсәр хатын-кыз намусына, тормыш авырлыкларын җиңеп, алга барырга үзендә көч тапкан кеше ныклыгына гимн булып яңгырады. Мәдинә Сафинаның тоташ югалтулардан һәм үкенечләрдән гыйбарәт катмарлы язмыш сәхифәсен тамашачы эчке бер тетрәнү белән күзәтте. Тамашачы аның урынында сугыш китергән авырлыкларны үз җилкәсендә татыган, яу кырында ятып калган ирләренә тугрылык саклап ялгыз картайган әниләрен күз алдына китерде. Башка шартларда һәм масштабларда булса да, шушы аналарның рухи ныклыгын, чисталыгын-пакьлеген, тугрылыкларын үзләрендә тупларга омтылу ул заман буынына ят нәрсә түгел иде. Шуңа күрә Мәдинә образы йөрәкләргә бик тирән үтеп керде. Көчле рухлы, үзенең әхлакый тәртип-низамына беркайчан хыянәт итмәячәк Мәдинә Сафина үзенең дә, башкаларның да хата-ялгышларын кичерми. Аның өчен иң мөһиме – намус, вөҗдан, бурыч иминлеге. Үз чорының хатын-кыз идеалын әнә шундый биеклеккә күтәрде Туфан Миңнуллин.

Чирек гасыр узганнан соң, «Ай булмаса, йолдыз бар» спектаклен К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры режиссеры Рәшит Заһидуллин сәхнәгә менгерде. Кешелек кыйммәтләре акрынлап кысрыклана барган бу заманда шушы пьесаның сәхнәдә куелышы үзе үк игътибарга лаек хәл. Сүз уңаеннан әйткәндә, бу әсәрне Т.Миңнуллинның соңгы елларда иҗат ителгән пьесалары белән чагыштырып караганда, шактый кызыклы аермалар күренә. Төгәлрәк әйткәндә, еллар узган саен, мәхәббәт һәм горурлык төшенчәләренең дә мәгънәсе үзгәрә икән...

Әгәр иҗатыңда уңышка ирешим дисәң, эчке дөньяңның һаман үсештә, яңарышта булуын тәэмин ит, үзгәрешләргә әзер булып тор. Үз шәхси инануларын вакыт-вакыт күздән кичереп һәм әйләнә-тирәгә колак салып яшәгән кеше сирәгрәк ялгыша, кирәкмәгән уйлардан, стереотиплардан котыла. Әмма шул ук вакытта үз йөзеңне дә югалтмау зарур, ихлас һәм чиста булып кала белергә кирәк. Т.Миңнуллин әсәрләрендә озак вакытлар инде төп тема булып гади кешенең каһарманлык сыйфатларын ачу тора. Нинди генә хәлдә дә гаярь ир, чын кеше булып калу, илаһи кыйммәтләр дигәндә үз-үзеңне аямыйча, җаныңны фида кылып яшәү дәрәҗәсенә күтәрелү – болар нииндидер гайре табигый төшенчәләр түгел, ә бәлки гап-гади кеше тормышының аерылгысыз бер өлеше, алардан башка тормыш бармый, барырга тиеш тә түгел. Туфан Миңнуллин әнә шуларны табигый итеп сурәтли белә. Җәллад алдында башын имичә, үлемнең йөзенә туры карап Ватаны өчен елмаеп шәһит киткән Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләре, еллар исәбенә бирешмәгән Әлмәндәр карт, шәхси тетрәнүләрдән сукыр калган, әмма һаман да изгелеккә инанудан туктамаган ялгыз Мәдинә – болар һәммәсе бер үк теманың төрле вариантлары гына. Ә

менә «Эзләдем, бәгърем, сине» һәм «Шулай булды шул» спектакльләрендә бу тема бик тә үзенчәлекле чишелеш тапты.

Пьесаларның икесе дә Т.Миңнуллин иҗатында аерым урын били. Нәрсәсе белән шулхәтле җәлеп иттеләрме? Боларда вакыйга фәкать мәхәббәт, йөрәк мәсьәләләре тирәсендә бөтерелә. Кызык, әдипнең алдагы елларда язылган әсәрләрендә моңа урын аз иде шикелле (мәхәббәт өчпочмагына корылган музыкаль комедияләрне исәпкә алмаганда). Бу, мөгаен, Марсель Сәлимҗановтан ук шулай килгәндер: мәхәббәт интригасы башланып үсеш алган спектакльләрдә ул һаман арткы планга күчерелә килде, социаль-фәлсәфи уйланулар, идея һәм дөньяга карашның төрлелеге исә маңгайга-маңгай чәкешеп, аеруча калку итеп күрсәтелде. «Илгизәр + Вера», «Сөяркә» спектакльләре шул рәвешле чишелеш тапты. Беренчесе милләтара мөнәсәбәтләргә, төгәлрәк әйткәндә, катнаш никах мәсьәләләренә багышланган булса, икенчесе дини яңарыш чорына аяк баскан бер дәвердә кеше җанының да ояну кичерүен шулкадәр зур осталык белән, мүкләнгән күңелләрне дә уятырлык итеп ачып салды. Биредә драматург белән режиссер икәүләп социолог ролен башкарган күк тоела: пьесада күтәрелгән проблеманың төрле юнәлешләрен һәм чикләрен ача-ача, төрле яктан якын килеп, ваклап-бөртекләп, һәр адымны үлчәп диярлек эшләделәр. Бер-берсенә капма-каршы позициядә һәм әдәп-әхлак турындагы күзаллаулары да төрле булган геройларның еш кына очына чыга алмаслык бәхәскә кереп китүләре спектакльне хисси киеренкелектә тотты, күренешләрне чын мәгънәсендә җанлы, ышандыргыч итте. Тулаем алганда, пьесаларның икесен дә психологик драмага караганда публицистикага якынрак булуын танырга кирәктер.

«Эзләдем, бәгърем, сине» пьесасын сәхнәләштереп, Т.Миңнуллин поэтикасын Рифкать Исрафилов бөтенләй яңа яктан ачуга иреште. Очраклы телефон шылтыравыннан башланып киткән танышлык инвалид коляскасында утырырга мәҗбүр ике яшь кеше арасында чын мәхәббәт хисләре кабыза. Драматургның башка әсәрләрендәге кебек үк бу постановкада да сәяси һәм социаль мотивлар күп, сәхнә түреннән үткен-үткен фикерләр еш яңгырый. Мәгәр бу юлы режиссер нәкъ менә шуларын арткы планга күчерә дә, тамашачы игътибарын мәңге картаймас, сүнмәс-сүрелмәс мәхәббәт лирикасына юнәлтә. Озын-озак итеп телефоннан сөйләшүләрне сәхнә күренеше дип атап та булмастыр, мөгаен, әмма зал бер сулыштан шушы икәүнең әңгәмәсен тыңлый, сюжет борылышларында йә күз яшьләрен агыза, йә көлеп җибәрә. Пьесаның төше шунда: катнашучылар бары тик икәү генә булганлыктан, вакыйгалар болар тирәсендә генә куера, беркем комачау итми. Нурсинә белән Рәхимҗанның бер-берсен күрмичә, ерак аралардан торып аралашуы аларның мөнәсәбәтләренә аерым бер җылылык, наз, рухи пакьлек, самимилек, чисталык өсти. Сәхнәдә шушы икәүнең бер-беренә карата туган ышанычыннан үзара якынлык аурасы барлыкка килә.

Туфан ага әлеге пьесасын тормыштан алып язган. Физик мөмкинлекләре чикләнгән ике кешенең, язмыш сынауларына бирешмичә, гаилә корып, бала тәрбияләп үстерүләре турындагы вакыйга әдипнең күңел дәрьясын актарып ташлый. Шунысын искәртү дә мөһим: спектакльдә төп тема тән гариплеге түгел, биредә ул фәкать поэтик аллегория рәвешендә бирелә. Автор һәм режиссер тамашачыга ике ялгызакның рухи якынаюын күрсәтүне максат итеп куйган һәм шуңа ирештеләр дә. Бит ялгызлык физик мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә генә юлдаш дип уйлау – тамырдан хата фикер. Азмы арабызда бер җылы сүзгә, назлы карашка тилмереп яшәүче сау-сәламәт, тышкы кыяфәтләре белән күз явын алырлык чибәрләр?! Ә менә мәхәббәтен тапканнарга бернинди киртәләр куркыныч түгел...

Мәхәббәт темасы Ф.Бикчәнтәев куйган «Шулай булды шул» спектаклендә дә үз бормалары белән дәвам иттерелә. Нурсинә-Рәхимҗан мөнәсәбәтләреннән аермалы буларак, бу спектакльдәге геройларның язмышы үтә дә баналь. Алмаз исемле яшь егет, армиядән кайтып килешли, бергә хезмәт иткән дустының әти-әниләре хәлен белешергә уйлый. Ә бу авылда менә нинди хәлләр булып ята икән: шактый нык тормышлы Нургали дигән бер агайның Гөлшат исемле кызы, Казанда бер ел укыганнан соң авырга узып, авылга кайтып төшә. Авылдашлары алдында оятка калудан курыккан кайгыртучан ата кеше Алмазны кияү ролен үтәп, ялган туй үткәрергә күндерә. Әлбәттә инде, шуны башкарып чыкса, Алмазны бүләк тә көтә. Әмма, комагайланудан битәр, кызны җәлләүдән ризалаша егет. Тырышлыгына күрә иске булса да «Ока» машинасына ия булып, Алмаз өенә кайтып китә... Елдан артык вакыт уза һәм егет Гөлшатка чын-чынлап гашыйк булуын аңлап ала. Мәхәббәтен хатлар язып аңлатканчы тагын әллә күпме гомер үтә. Баштарак туң йөрәк кебек күренгән кыз, Алмазның ихлас хисләрен белдереп язган хатларын укып, акрынлап аңа карата җылына һәм үзенең дә егетне яратуын аңлый. Буйга зур булмаган ябык кына Алмазның бөтен батырлыгы шунда: бернигә дә карамыйча чын мәхәббәтен танырга үзендә көч таба ул. Балалы хатынны чын-чынлап ярата алырмын дип, Алмаз, бәлки, уйламагандыр да. Ә ул исә егетнең саф хисләре һәм язмышы булып чыга. «Шулай булды шул» спектакле тамашачы алдында яңа киңлекләр ача, гадәти көндәлек тормышта да романтик мөнәсәбәтләргә урын калуын күрсәтә. Әмма болардан тыш пьеса үзе дә гаҗәеп осталык белән, юморны күп кулланып, чын татар комедиясе рухында язылган. Монда шулай ук игътибарны җәлеп итәрлек эпизодик бер роль бар. Ул – элеккесендә парторг булып эшләгән бүгенге көн мулласы. Бу образ алдан ук сатирик итеп уйланылгандыр, чөнки спектакльдә аның адресына төртмәле кәлимәләр явып кына тора, ә зал рәхәтләнеп көлә. Мәгәр мулла образын берьяклы һәм туры гына кабул итәргә кирәкми, минемчә. Ник дигәндә, коммунистлар чорын кичергән бу кеше бер дә йә эшмәкәр, йә демократ, йә яңа номенклатура әгъзасы булып китмәгән бит әле! Әгәр ул шушы мулла вазифасына алынган икән, димәк, моның энке сәбәпләре бар. Күп кешене коммунистик доктрина үзенә хас әхлакый кыйммәтләре белән, рухи байлыкның матдилектән өстен куелуы белән җәлеп итте ләбаса. Шулай ук муллалар да халыкны фәкать яхшылыкка, игелеккә өнди. Шулай булгач, элеккеге партия эшлеклеләренең бүген дин әһелләренә әверелүенә гаҗәпләнергә кирәкме икән?! Эшчәнлекнең фәкать формасы үзгәрде, ә эчтәлеге шул ук калды: адәм балаларын билгеле бер әхлак кысаларында тоту, яхшылыкка инандыру, изге гамәлләрне күбрәк кылырга өндәү. Күпмедер дәрәҗәдә ошбу сыйфатлар Туфан Миңнуллинның үзенә дә хас. Гомумән алганда, дидактизм – үгет-нәсихәт – чын мәгънәсендә милли, халыкчан сәнгатьнең иң ачык, ярылып яткан бер сыйфаты ул. Безнең халык файдасыз вә мәгънәсез нәрсәләргә вакыт әрәм итми. Сәнгатебездә бу хакыйкать аеруча калку чагыла: рәсем сәнгатенең рәвеше декоратив-гамәли һәм ул көнкүрешебезне бизи. Көй-

моңнарыбыз җанны дәвалый, авыр хезмәтне җиңеләйтә, сагынуларга бер дәва булып тора. Әдәбият вә театрларыбыз исә тәрбия-агарту, үгет-нәсихәт кебек игелекле вазифаларны колачлый. Язучы үзе дә шушы фикерне куәтли. Бу урында драматург иҗатының милли чыганакларына тукталып үтәсем килә. Кызык бит: европача үсеш алган замана театрында куелучы пьесаларда борынгы милли мәдәниятебез җәүһәрләре асылташ кебек ялтырыйлар! Әлбәттә, биредә фольклор материалларыннан башка мөмкин түгел. Драматургның тулысынча фольклор тамашасына корылган пьесалары да бар, алар һәркемгә билгеле: «Гөргөри кияүләре» һәм «Йөрәк маем» спектакльләре. Үзәктә – керәшен һәм Сергач татарларының элеккедән сакланып килгән гадәт-йолалары. Т.Миңнуллинның комедия һәм экиятләре дә фольклор өслүбенә бик тә якын. Ә заманының иң үткен проблемаларын ачып салучы фәлсәфи драмаларында исә халык җырлары әхлакый гимн буларак яңгырый. Мисал өчен, «Әниләр һәм бәбиләр» спектаклендәге борынгы бишек җырлары ана белән бала арасындагы иң изге бәйләнешне – рухи бергәлекне гәүдәләндерә, чөнки нәкъ менә ана сөте белән галәмнәрнең какшамас нигезе бала аңына сеңә, күчә. Хөкем алдыннан җәлилчеләр барысы бергә «Сибелә чәчәк»не суза. Халкымның бу җыры да көчле рухлы татар милләтенең үлемсезлегенә дан җырлый. Ә «Хушыгыз!» драмасының ахыргы күренешендә чиксез сагыш булып иңрәгән «Тәфтиләү» турында ни әйтерсез?! Сөекле Тукаебыз соңгы сәгатьләре сукканда йөрәгә түреннән өзеп төшергән түгелме соң шушы илаһи моң-зарны?!

Туфан Миңнуллин – театраль миниатюраларның танылган остасы да әле ул. Бу үзенчәлекне шулай ук миллилек белән бәйләп карау кирәктер. Чөнки татар фольклор театры энә шул кечкенә юмористик күренешләрдән гыйбарәт. Берничә ел элек миңа Казан дәүләт сәнгать академиясе студентларының диплом спектаклен карап хозурланырга туры килде. Т.Миңнуллинның бер пәрдәле пьесаларын сәхнәләштергәннәр иде алар. Шул тамашадан соң күңелгә саф һава бәреп кердемени – нindидер җиңеллек, яшьлек дәртенә күмелдем, әйтерсең иңнәремдә канат тойган унсигез яшем әйләнеп кайтты! Бер карасаң, сәхнәдә гап-гади күренешләр бара, кыска-кыска гына өч бәян. Әмма алар бер үк вакытта театраль дә, тормышчан да! Аларда киңлек бар, киләчәкне тоясың, төрле буыннарның үзара җылы мөгамәләсенә тап буласың, бик үткен психологик күзәтүләргә юлыгасың. Кыскасы, һәр рольдә тулы бер язмыш.

Туфан Миңнуллинның ошбу осталыгы «тулы метражлы» пьесаларына да хас. Әйтик, «Шәҗәрә» драмасы бөтенләе белән кечкенә спектакльләрдән тора, кайчандыр сәүдәгәрләр нәселеннән булган атаклы Сәетбәковлар токымын чагылдырган күренешләр, дисбе тезмендәге төймәләр кук, бер-берсен алыштырып кына тора. Биредә төп һәм икенче пландагы персонажлар юк, һәммәсенең язмышы үзенчәлекле һәм кабатланмас. Драматургның әсәрләре иҗат киңлеге һәм ирек бирә, аның персонажларын рәхәтләндереп «үзең язып» уйнарга була дигән фикерне күп артистлардан ишеткән бар. Бу гына түгел әле. Т.Миңнуллин геройлары күңелгә якын, алар чын халыкчан рухта иҗат ителгән булыр. Бөтен илгә үлемсез карт, төгәлрәге, Әлдермештән Әлмәндәр булып танылган Әлмәндәр бабай татар халкының символы дәрәҗәсенә күтәрелә алды! Әлмәндәр карт үзендә татар халкының иң күркәм сыйфатларын туплавы белән үлемсез: ул чын мәгънәсендә эшсөяр каһарман, үз «мин»енә түгел, кешелек файдасына хәйләкәр, Әҗәлнең күзенә туры карап, теге дөньяга елмаеп китеп бара... Гомумән алганда, драматургның башка персонажларында да миллилек ярылып ята: авыл кызлары һәм егетләре булсынмы ул, шанлы хезмәт кешесеме, яшь яки гомер көзенә кереп баручы аналар образымы, шагыйрьләр, гыйсъянчылар, ат каракларымы – барысы да күңелгә якын, барысын да яратабыз, чөнки Туфан үзе дә аларны яратып иҗат иткән бит. Ә йөрәктән чыккан бик тиз йөрәккә барып җитә. Хәтта аның каләменнән туган урман шүрәлесенә тиклем яисә башка җанвар-хайваннары да үзенә бертөрле, космополитлыктан ерак торалар. Ә инде «Авыл эте Акбай» сериалындагы Акбайны бөтенләй дә милли сыйфатларыбызны чагылдыручы образ итеп кабул иттек: ул тугры, намуслы, гадел, хезмәт сөючән. Нәни тамашачылар бу спектакльне бик яратып карадылар. Туфан Миңнуллин алар өчен махсус 15 кә якын пьеса иҗат итте. Киләчәкнең яшь буын кулында булуын аңлаганга күрә, драматург кечкенә дусларына олы-олы хакыйкатьләрне әйтеп калырга ашыга: яхшылык һәм мәрхәмәт, матурлык, гаделлек, кешенең яшәү мәгънәсе нидә – менә бу кыйммәтләрне бала чактан ук күңелгә дөрес итеп сеңдерү зарур.

Чын талантның осталыгы янә дә шунда чагыла: ул һәрдаим үсештә-үзгәрештә булырга һәм көтелмәгән ачышлары белән укучыларын шатландырып-гаҗәпләндереп яшәргә, иҗат итәргә тиеш. Т.Миңнуллинның күптән түгел генә сәхнә күргән ике пьесасы тамашачы өчен көтелмәгән бүләккә тиң булды. Шуларның берсе – Башкорт дәүләт академия һәм Минзәлә драма театрлары куйган «Мулла» драмасы. Чынбарлыкны бөтен буяулары белән ачып салучы реаль вакыйгаларны чагылдыра ул. Пьеса үзенең үткенлеге, катгый-кырыс дөреслеге, замана вазгыятен аяусыз-рәхимсез сурәтләп бирүе белән һушларны ала. Монда инде без күрергә күнеккән татар сентиментальлегенең эзе дә юк, мәгәр шыксыз, куркыныч чынбарлыкны фаш итү аша дөньяга яңа караш туа: хәтәрлекнең күзенә курыкмыйча туры карап җиңәргә өйрәнү ул. Нәкъ менә шушы яшь үсентеләр киләчәккә өмет-ышаныч уята.

Драматургның «Дивана» трагифарсы премьерасы да киң җәмәгатьчелектә зур шау-шу уятты. Режиссер Ф.Бикчәнтәев тарафыннан куелган бу спектакльгә карата фикерләр төрле булды, арада каршылыклы карашлар да чагылып үткәләде, әмма ничек кенә булмасын, ул берәүне дә битараф калдырмады. Кемдер «Дивана»ны сәяси памфлетка тиңләде, кайберәүләр аны бөтен дөньяны колачлап алырга җитәрлек мәңгелек ана мәхәббәте турындагы бәет буларак кабул итте. Шәхсән үзем өчен бу спектакль күңелләрне тетрәндергән, бүгенге көндә бик актуаль психодрама дәрәҗәсенә күтәрелде. Ике бертуган – абый белән энекәш арасындагы низагны сыйнфый көрәш дип карау дөрес булмас иде. Бу – замана кешесенең рухи дөньясы белән матдилекнең бергә-бер көрәше. Бер карасаң, базар икътисады шартларында һәркемнең үзенә симезрәк, тәмлерәк калҗаны эләктереп калырга тырышуын аклап та була кебек – кешедән ким яшисе килми бит. Ә икенче якта – яхшылыкка һәм гаделлеккә, мәхәббәткә балаларча самимилек белән ышану, һәркемне тигез итеп күрәсе килү теләге... Шуңа күрә ошбу бәрелеш гаять зур киеренкелек дәрәҗәсенә җитеп кыза да инде. Вил белән Ким икесе бербөтен, әмма алар ике ярымшарның полюслары кебек бер-берсенә капма-каршы холыкта. Автор бөек идеяләр белән шашкан кешене шул дәрәҗәдә осталык белән сурәтли ки, гүя кеше җанының бер яклаучысыз гаҗиз калган яктылыгын, садәлеген,

самимилеген, балаларча беркатлылыгын гәүдәләндерә. Ә шушы «авыру»ны дәвалау инсандагы бөтен илаһилыкны юкка чыгаруга, бетерүгә тиңләшер төсле. Шуңа күрә дә спектакльнең ахыры үзеннән-үзе җаннарны өшетерлек фаҗигагә килеп тоташа. Вилне хастаханәгә урнаштыру вакыйгасы чынбарлыктагы тормышыбызда оятсызлыкның, кешеләрнең үз файдасын гына кайгыртып яшәве кебек куркыныч ваемсызлык-гамьсезлекнең һәм череп таркалган рухи бушлыкның тантана итүен тануга китерде. Кызганыч, әйләнә-тирәбез бүген шундый, Вил кебекләргә монда урын юк...

Бүген Туфан Миңнуллинны татар драматургиясенең әйдәп баручы көче дип атыйлар, ул – татар театрының йөзе. Үз тамырларына тугрылыгы, милләтенә чиксез бирелгәнлеге әдипнең бөтен рухын биләп алган. Шушы бөтенлек иҗатында да чагылыш тапмыйча калалмый. «Мин бөтен галәм хозурлана алырлык чәчәк түгелмен, ә бары тик авылым капкасы төбендә үсеп утыручы бер үләнмен...» дип язганы бар Туфан аганың. Хәер, берсе берсенә һич тә комачау итми. Иҗатлары бөтен дөньяга танылган язучылар чын мәгънәсендә милләт уллары бит алар. Дан-шөһрәттәмени хикмәт? Чын бәхет – туган җиреңдә кадерең булу, газиз халкың белән рухи тамырларыңның якынлыгын тою һәм үзеңне «татарның бер баласы» итеп тану хокукына ия булудадыр...

*Айгөл Габәши-Салихова,*
Татарстан Фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм сәнгать институты фәнни хезмәткәре

# Шулай булды шул

*Ике пәрдәле комедия*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Алмаз.
Гөлшат.
Нургали – Гөлшатның әтисе.
Хәлимә – Гөлшатның әнисе.
Әүхәт
Әхәт Гөлшатның абыйлары.
Фәгыйлә Гөлшатның җиңгиләре.
Фәһимә
Гамир
Сүрия Алмаз кунак булган йортның хуҗалары.
Туйга килгән кунаклар.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Капка төбе. Утыргыч. Шул утыргычта Гамир белән солдат киемендәге Алмаз утыра. Ачык тәрәзәдән Сүрия карап тора. Вакыт – кич. Көтү кайткан, сыерлар савылган. Йокыга талыр алдыннан авылның гөжләп алган чагы. Гамир сыздырып гармун уйный. Алмаз «Алмагачы» көенә очына-очына җырлый.

Алмаз. Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырлап ачыла күңел;
Җырлап ачылмаган күңел
Мәңге ачылачак түгел.
Гамир. Әйт шуны!
Алмаз. Җырлыйк әле, җырлыйк әле,
Җырламый тормыйк әле.
Чәчәк кебек яшь гомерне
Бушка уздырмыйк әле.

Гамир (*уйнаудан туктап*). Маладис егет син. Төшеп югала торган түгел.

Алмаз. Булганы белән шул, Гамир абый. Сезнең Дамир да шәп егет.

Сүрия. Шулай булсын иде инде.

Гамир. Пешмәгәннәр, җебегәннәр заманасы түгел бүген. Иртәгә китәм, дисең инде.

Алмаз. Җитәр инде, Гамир абый. Болай да ике көн кунак булдым. Кешедә бит оят дигән нәрсә дә булырга тиеш. Әйеме, Сүрия апа?

Сүрия. Кайткач нишләргә җыенасың инде? Калхузда эш тә юк хәзер.

Алмаз. Җае табыла аның, Сүрия апа. Планнар зурдан минем, Гамир абый. Башта машина алып җибәрәм, аннан өй салам, аннан өйләнәм.

Гамир. Ай-һай-һай... Зурдан икән шул. Авылда яшәп боларны эшләү өчен гомер җитмәс. Син өйләнүдән башла. Иң җиңеле, иң арзаны шул.

Сүрия. Бозма Алмазны. Хәерче бәндәгә рәтле кыз чыкмый ул.

Алмаз. Дөрес, Сүрия апа. Машина минем хыялым ул, Гамир абый. Минем телем «әннә» дип түгел, «машина» дип ачылган. Машинага мин бернәрсәне дә алыштырмыйм.

Гамир. Армиядә дә шофер идеңме?

Алмаз. Шофер. Генералны йөрттем.

Сүрия. Булыр, булыр. Булдыра торганга охшагансың. Әйдә, керегез. Чәй өлгерде.

Алмаз. Син бар кер, Гамир абый. Мин авылыгызны бер әйләнеп кайтам әле. Авылыгыз матур да сезнең, кызларыгыз чибәр түгел.

Гамир. Нәрсә, Сүрия апаң да ямьсезмени?

Алмаз. Сүрия апа кызлар түгел ич инде ул.

Гамир. Карап йөре, безнең егетләр усал, кыйнап кайтармасыннар. (*Кереп китә.*)

Алмаз. Менә, җәмәгать, шулай башланып китте ул мин сөйлисе роман. (*Көянтә-чиләк күтәреп килүче Гөлшатны күреп.*) Туктагыз әле, җәмәгать... Гафу итегез. (*Гөлшатның каршына чыгып.*) Исәнмесез... Исәнмесез, хур кызы.

Гөлшат, күз кырые белән генә, җирәнгәндәй, Алмазга карап ала да китә.

Әһе... Чиртмәде бу балык. Чибәр үзе. Ничек бүгенгә хәтле күренмәде икән. Әйе, шулай башланып китте ул мин сөйлисе хикәя. Безнең ротага бер көтү салагаларны китерделәр. Шулар арасында бер татар малае да бар. Танышып киттек бит. Нишлисең, үз татарың бит, сагындыра. Менә шушы авыл егете булып чыкты ул. Без Казаннан кайтканда шушы авыл аша үтеп йөрибез. Салагаларны армиядә нишләткәннәрен беләсез инде. Безнең кебек дедлар, картлачлар инде татарчасы, иманнарын «укыталар» инде аларның. Мин үзебезнең татар малаена тидермәдем. Минем кем икәнне беләләр ич анда. Шулай яшәп менә дембель вакыты җитте. Мин киткәндә, Дамир әйтә, безнең этиләргә кереп кит, ди. Менә кердем. Җибәрмәделәр. Ике көн сыйладылар. Туйганчы йокладым. Иртәгә китәм... Гафу итегез... Теге чибәр судан кайтып килә. Тагын бер сүз кушам. Чиртмәсә, кармагымны алам да ыргытам. (*Гөлшат каршына чыгып.*) Нигә сәламемне алмадыгыз, чибәр кызый?

Гөлшат аны урап үтмәкче була. Алмаз тагын аның каршына төшә.

Әллә сезнең телегез юкмы, гүзәлем? Исемегез ничек, матурым?

Гөлшат (*зәһәр итеп карап алып*). Кит! (*Китеп бара.*)

Алмаз. Ай-яй... Шундый итеп карады, үтерә язды. Кызлар янына якын бармаслык итте. Әгәр дә, шундый кызга өйләнеп, хатының шулай итеп караса...

Нургали (*Алмаз янына килеп туктап*). Нихәл?

Алмаз. Исәнмесез?!

Нургали. Кыз ошадымы?

Алмаз. Нинди кыз?

Нургали. Ике тапкыр каршына чыктың бит.

Алмаз. Ә-ә-ә... Аны әйтәсең икән. Чибәрен чибәр дә...

Нургали. Нәрсәсе ошамады?

Алмаз. Бик усал, ахрысы. Шундый итеп карады.

Нургали. Минем кыз ул... Нургали минем исемем. Шулай... Әнә тора безнең өй.

Алмаз. Минем исемем Алмаз.

Нургали. Беләм, Гамир сөйләде. Солдаттан кайтып барасың икән.

Алмаз. Барам шул.

Нургали. Ярый... Шулай... Әти-әниләрең бармы?

Алмаз. Бар.

Нургали. Булгач, нигә монда ятасың? Көтәләрдер бит.

Алмаз. Җибәрмиләр. Иртәгә китәм инде.

Нургали. Иртәгә... Ярый... Кайткач нишлисең инде?

Алмаз. Вәт кызык. Нигә миннән сорау аласыз әле? Күз күрер әле.

Нургали. Күз ул төрлесен күрә. Кирәкмәгәнне дә. Шулай... Өйләнәсеңдер дә инде.

Алмаз. Уйлаган юк. Өлгерер әле.

Нургали. Әйе... Шулай... Өлгергәч, өзелеп төшә инде ул. Ярый... Әти-әниләрең кемнәр?

Алмаз. Кемнәр булсын. Председатель түгел инде, эшлиләр.

Нургали. Ярый... Эшләгәч ярый. Шулай... Минем турыда нәрсә уйлыйсың инде син?

Алмаз. Туктагыз әле, абзый кеше...

Нургали. Абзый кеше түгел, Нургали абзый. Әйт, нindирәк кеше инде мин?

Алмаз. Каян белим?

Нургали. Ярый... Белмәгәч ярый. Шулай... Минем турыда ни уйлыйсың?

Алмаз (*көлеп*). Каян килеп чыкты бу кеше, дип уйлыйм.

Нургали. Тагын?

Алмаз. Тагынмы? Нигә миңа бәйләнә, дип уйлыйм.
Нургали. Дөрес уйлыйсың. Гамир абыең нәрсә сөйли минем турыда?
Алмаз. Берни дә сөйләми.
Нургали. Минем кыз турында ни сөйлиләр?
Алмаз. Бернәрсә сөйләмиләр.
Нургали. Ярый... Шулай... Инде болай... Минем кыз ошадымы сиңа?
Алмаз. Әйттем ич инде...
Нургали. Әйе... Шулай... Усал ул. Безнең нәселдә юашлар юк. Безнең авыл өч нәселгә бүленгән: Шәйхел нәселе, Хәмәт нәселе, Сафа нәселе. Шәйхелнекеләр менә Гамирлар. Алар нәселләре белән гармунчылар, җырчылар. Хәмитнекеләр – муллалар, укытучылар, врачлар. Без – Сафа нәселе. Без эш кешеләре. Усаллар. Безнең бабай ат карагы булган. Син усалдан курыкма, юаштан курык. Бездә хатын аеру, ирне ташлап китү юк. Бездә – тәртип. Армиядәге кебек. Шулай. Безнең өйдә мин ни әйтсәм, шулай була. Минем кыз сиңа бирәр сүз әйттеме?
Алмаз. Кит, диде.
Нургали. Шулай... Ярый... Ни өчен син аның каршысына чыктың инде?
Алмаз. Мин бит аның сезнең кыз икәнен белмәдем.
Нургали. Белсәң чыкмас идеңме?
Алмаз. Кызык икәнсез сез. Мин бит бернишләмәдем.
Нургали. Нишлисең киләме соң?
Алмаз. Ничек инде «нишлисең киләме»?
Нургали. Өйләнер идеңме шул кызга?
Алмаз. Ничек?
Нургали. Шулай... Шул кыз, әйтик, сиңа кияүгә чыгарга риза булса, өйләнер идеңме?
Алмаз. Ничек инде... Мин аны белмим дә ич әле.
Нургали. Белмисең, әйе... Шулай... Кем белеп өйләнә... Яши-яши беләсең. Анда да белмисең әле. Шулай...
Алмаз. Бераз йөрергә кирәктер инде ул.
Нургали. Кирәктер, әйе... Шулай. Әйтик, кызның йөрергә вакыты булмаса? Хәзер үк кияүгә чыгарга теләсә?
Алмаз. Теләгәнен әйтмәде бит.
Нургали. Әйтер. Мин дә бар бит әле монда... Шулай. Гөлшат ошады, дисең инде алайса. Ошамаслык түгел... Шулай... Ошаса, ал син аны. Бирәм.
Алмаз. Нәрсә? Бирәсез? Ничек?
Нургали. Бирәм. Тик торганнан түгел. Бирәм. Өч көннән туй ясыйбыз.
Алмаз. Китегез әле. Алай булмый ич инде.
Нургали. Булдырсаң – була. Шулай... Ничек?
Алмаз. Уйларга кирәк монда. Әти-әниләр дә бар. Алар ни әйтер? Киңәшергә кирәк.
Нургали. Киңәшергә кирәкми. Ник дигәндә... Әйе... Шулай... Сиңа ошаган кызның гаебе бар. Кил мондарак... Шулай... Нинди гаебе бар, дип сора. Әйтәм – аны алдаганнар. Казанда укый иде. Шунда бер сволычы алдаган. Хәзер өйдән чыкмый.
Алмаз. Ничек алдаган?
Нургали. Кызларны ничек алдыйлар соң? Шулай... Шулай... Кара аны, бу турыда берәүгә дә ишеттерәсе булма. Өйләнсәң-өйләнмәсәң дә, бу турыда биш кенә кеше белергә тиеш. Иң беренче – син, аннары – Гөлшат үзе, аннан соң хатын белән мин, аннары инде теге алдаучы сволыч.
Алмаз. Кем соң ул?
Нургали. Каян белим? Әйтми кыз. Яраттым, ди. Теге алдаган да тайган. Мондый нәрсәнең безнең нәселдә булганы юк. Бәреп үтерә идем кызны, әнисе каршы төште. Шулай... Шуннан артыгын белмә, кирәксә, үзе сөйләр. Аласыңмы шундый кызны?
Алмаз. Кыз түгел ич инде ул. Ә нигә аны миңа бирәсез? Авылыгызда бүтәннәр юкмы?
Нургали. Үз авылыңда ни пешерсәң дә, исе чыга. Без безнең нәсел турында сүз чыгуын яратмыйбыз. Сез китәсез дә югаласыз. Шулай.
Алмаз. Кызыгыз ризамы соң миңа чыгарга?
Нургали. Аның ризалыгын кем сораган. Бер айлык корсагы бар. Әйттем, теләсә кемгә тотып бирәм, дидем.
Алмаз. Корсагы бар, дидегезме?
Нургали. Бар. Шулай...
Алмаз. Абзый, сез нормаль кешеме?
Нургали. Энем, мин алай сөйләшкәнне яратмыйм.
Алмаз. Алайса, нигә мине җүләргә саныйсыз.
Нургали. Санамыйм. Өйлән, аерып җибәрерсең. Рөхсәт итәм.

Алмаз. Безнең нәселдә дә хатын аермыйлар, Нургали абзый.
Нургали. Ярый... Шулай... Аңлашылды... Яратсаң да өйләнмисеңме?
Алмаз. Үзегез өйләнер идегезме соң?
Нургали. Юк... Шулай... Инде болай... Юри генә өйләнгән бул.
Алмаз. Ничек инде анысы?
Нургали. Туйда кияү булып утыр. Туйдан соң китәрсең дә барырсың. Ни өчен икәнен төшенәсеңме?
Алмаз. Кияү ташлап киткән, дип әйтер өченме?
Нургали. Маладис. Үткен егет, дигән иде Гамир, дөрес икән. Йә, ничек?
Алмаз. Юк, абый. Мин жулик түгел.
Нургали. Кем әйтә сиңа жулик дип. Коткар безне хурлыктан. Әнисе сөйләшкән, төшерттермим дип әйтә, ди. Хурлыгы ни тора. Нургали кызы зинадан бала тапкан, дип сөйләсәләр, хурлыгыңнан үләрсең.
Алмаз. Әйтегез соң, кияүгә чыккан да кияве ташлап киткән, диегез.
Нургали. Алдарсың безнең авыл халкын. Туйсыз ничек кияүгә чыксын. Белмиләрмени шуны. Туй булса... Риза бул. Бушка түгел. Шулай...
Алмаз. Акча түләпмени?
Нургали. Туйда утырсаң, тиешлесен аласың да китеп барасың.
Алмаз. Ай-яй-яй... Акча алдың дип, буаз кызыгызны сылап куяр идегез бугай.
Нургали. Буаз димә, сыер түгел ул. Әгәр кызымны шулай мыскыл итәрлек булсаң... Безнең нәселдә алдакчылар юк, энекәш. Шулай... Әйткәнмен икән, эшлим. Кызыма орындырттырмыйм да. Тиешлесен аласың да китәсең. Мин сине белмим, син мине белмисең, вәссәлам.
Алмаз. Күпме соң инде ул тиешлесе?
Нургали. Үзең әйт. Мин бәясеннән тормыйм. Утыз сигез баш умартам гына бар минем. Тракторым бар. Ике машинам бар.
Алмаз. Машиналарыгыз нинди?
Нургали. «УАЗ» белән «Ока». Шулай...
Алмаз. «Ока»сын бирәсеңме?
Нургали. Җүләр түгел син, малай. Шундый киявем булса, мин... Ярый, әйдә.
Алмаз. Әйтеп куям, Нургали абзый, киявегез булмыйм. Туйда утыруны уйлап карармын.
Нургали. Озак уйлама. Тагын бер әйтәм, бу турыда берәүгә дә...
Алмаз. Бер сүз әйтмим...
Нургали. Шулай... Ычкындырсаң, кара аны, минем икешәр метрлы ике улым бар. Холыклары бик начар.
Алмаз. Анысы аның миндә дә бар абыйлар. Берсе кеше кыйнаган өчен егерме ел утырып чыкты, берсе һаман да утыра. Алайса болай, Нургали абзый, кызыгызны минем янга чыгарыгыз. Әйтегез, минем белән сөйләшсен.
Нургали. Нәрсә турында сөйләшмәкче буласың?
Алмаз. Табармын ни турыда сөйләшергә.
Нургали. Безнең сөйләшкәнне әйтмисең. Чынлап өйләнәсең дип белсен. Әтиең риза булды, диген. Тик кулың белән орынмыйсың. Орынсаң, муеныңа тагып җибәрәбез. Шулай... Авылдан читкә дә чыкмыйсыз. Урамда. Кешеләр күрсен.
Алмаз. Машинаны онытмагыз. Аны минем исемгә дә күчерергә кирәк бит әле.
Нургали. Анысы синең кайгы түгел. Туй буласы көнне машина язулары кесәңдә булыр. (*Китеп бара.*)
Алмаз. Әйе... Шулай... Ярый... Нәрсә булып бетәр икән бу галәмәт? Әллә сызаргамы яхшы чакта? Аферист бу абзый. Ә миңа нәрсә. Шулай да шикләндерә. Карбыз йоткан кызларын ябыштырып куюлары бар. Сылап куйсалар, нишләргә? Уен эш түгел. Һәй, алайга китсә, мин генәме балалы хатынга өйләнүче. Һәй, беткән баш беткән. Туйда утыруы үзе ни тора.

Беткән башлар беткән, диеп
Әйтәләр күптән.
Безгә дә диңгез тубыктан –
Беткән баш беткән.
Кемнәрне кемнәр кочкан да
Кем кемне үпкән:
Кызлар ни дә хатыннар ни –
Беткән баш беткән.
Өсләр бөтен, тамаклар тук –
Безгә шул җиткән.
Алдагысын Алла белә –
Беткән баш беткән!

(*Нургалиләр өе ягына карап.*) Әкәмәт, тәки чыгарды бит бу моны. Эшләр тирәнгә кереп бара бит әле монда. Уйла, Алмаз, уйла. Эшләт башыңны. Төп башына утыртмасыннар. (*Көянтә-чиләк күтәргән Гөлшат каршына чыгып.*) Су күп эчәсең икән, Гөлшат туташ. Кич белән дә су ташыталар. Шушы бүрәнә өстендә минем белән утырып торырга теләмисезме? (*Гөлшат селкенмәгәч.*) Ярый соң алайса. Галиябану белән Исмәгыйль шикелле урам уртасында басып кына сөйләшик. Кара, сезнең телегез юк мәллә ул? Телсез кызга өйләнәммени мин? Минем сезгә өйләнәчәкне белмисезмени әле? Ничек инде ул булачак ирегез белән сөйләшмисез? Карале, әтиегез әллә бер сүз дә әйтмәдеме? (*Гөлшатның ачулы карашын күреп.*) Алай итеп карамагыз инде. Чибәр кызларга усал булу килешми. Усал хатын белән ничек торырмын? Нишләтим, бигрәк тә ошадыгыз бит. Әтиегезгә әйткән идем, бирәм, диде. Матур итеп яшәрбез, Алла боерса. Матур-матур балалар үстерербез.

Гөлшат. Идиот!

Алмаз. Иди-от?.. Телегез ямьсез сүз белән ачылды. Ярый... Яхшы... Шулай... Бөтен ямьсез сүзләрне әйтеп бетердегез. (*Урамнан үтеп баручы берәүгә.*) Исәнмесез! Кеше алдында гына булса да елмаегыз инде. Зерә сез мине мыскыл итәсез. Шәп егет мин. Менә дигән итеп яшәрбез. Мин иртән торырмын да «Карчык, чәй өлгердеме?» диярмен, син «Хәзер, картым, хәзер» дип йөгереп йөрерсең. Кочаклашып аерылышырбыз, кочаклашып күрешербез. Безгә карап бөтен авыл сокланыр.

Гөлшат. Козел!

Алмаз. Кара, нинди сүзләр беләсең. Казанда күп нәрсәгә өйрәткәннәр икән сине. Урысча гына сиптерәсең. Соң, бәгырькәем, мин козел булгач, син козлиха буласың ич инде. Между прочим, моннан ике ай элек Казаннан килгән бер салага «козел» дигән иде миңа. «Козел» дип әйткән теле белән аяк табанымны ялады. Бар суыңа. Өеңә кайткач, әтиеңә әйт, ул миңа өйләнергә теләми, диген. Ферштейн, козлиха? (*Гөлшат киткәч.*) Кара син аны. «Козел» дип алдаган Казан козелына әйтсен. Мин аңа яхшылык эшләргә җыенам, ә ул. Кирәкми. Машиналары да кирәкми. Менә сез, машиналы булам дип, шушы сүзләрне ишетер идегезме? Эшләр шундыйга китте бит әле. Әйе... Шулай... Туктале, нәрсә мин?.. Әйтсә ни. Үгез булмагае чурт булсын, малайларга сөт булсын, әйе бит? Аның шулай әйтүе яхшы да әле. Каршыңда елмаеп торса, йә чыннан өйләнерсең. Алып кайтырсың әни янына буаз кәҗә. Сез инде мине, зинһар өчен, гафу итегез, җәмәгать. Хатын-кызга андый ямьсез сүз әйтергә ярамыйдыр. Нишләтәсең, дөнья бит бу. Алдыйсың да, алданасың да. Алла сакласын, әни әйтмешли. Ну бит үзе дә гаепле, әйтмәсен теләсә нәрсә. «Хайван» дисә дә, түзәр идең әле, «козел» ди бит. Хәер козелы да хайван инде аның. Ярый, тынычлан, Алмаз. Дөнья бу, әллә нинди сүзләр ишетерсең әле. Юк өчен кайгырма да. Ишәк кайгырсын. Машина кулыңа керәм дигәндә. Иртә кичтән хәерлерәк, әни әйтмешли.

Кичен син хәерче,
Иртән баерсың.
Иртәгесе өчен
Ишәк кайгырсын.
Кичен син өйләнгән,
Иртән аерымсың.
Иртәгесе өчен
Ишәк кайгырсын.

(*Тәрәзә каршына барып.*) Гамир абый... Гамир абый...

Гамир (*тәрәзәне ачып*). Мин монда, Алмаз.

Алмаз. Мин өйләнәм бит, Гамир абый.

Гамир. Нәрсә, сөйгән кызың көтәмени авылда? Дөрес эшлисең. Башта өйлән, койрыгыңны бозга катырып куй. Машина качмый ул. Менә Сүрия апаң белән машинасыз да яшибез бит әле. Өен дә бергәләп җитештерерсез.

Алмаз. Мин сезнең авыл кызына өйләнәм. Өч көннән туй.

Гамир. Туй? Кәмит малай син.

Алмаз. Мин чынлап әйтәм, Гамир абый.

Гамир. Чынлап? Кемгә? Матур кызлар юк, дигән идең ич.

Алмаз. Табылды.

Гамир. Кем инде ул?

Алмаз. Гөлшат. Нургали абый кызы. Шулай...

Гамир. Әкәмәт, каян күреп өлгердең?

Алмаз. Мин бит егет кеше, Гамир абый. Күрдем дә гашыйк булдым. Үзе дә мине ошатты. Алып китәм, дим, дәшми. Дәшмәү ризалык билгесе бит инде ул. Шулай...

Гамир. Казанда укый түгелме соң ул?

Алмаз. Заочныйга күчәр.

Гамир. Белмим, белмим. Сүрия! Кая әле? (*Тәрәзә янына килгән Сүриягә.*) Ишетәсеңме, Алмаз ни ди. Өйләнәм, ди. Нургали кызы Гөлшатка, ди.

Сүрия. Кит әле?!

Алмаз. Мин әйткәнемне үлсәм дә эшлим, Сүрия апа.

Сүрия. И сез, яшьләр, яшьләр. Бигрәк башсызлар инде. Уен эш түгел бит өйләнү. Кай арада сөйләшеп өлгерәләр. Нургали бар бит. Ул узып баручы солдатка кыз бирәме? Акча төртеп, укырга урнаштырдылар. Укып яткан җиреннән!

Алмаз. Мин дә укырмын. Туксанга җитмәгән. (*Узып киткән Гөлшатка ымлап.*) Чибәр бит.

Сүрия. Әй! Бездән көләсеңдер әле?

Алмаз. Көлүдән эш узды, Сүрия апа. Нургали абзый риза булса, туйны монда ясап китәм. Булмаса, урлап качам.

Сүрия. И башсызлар, башсызлар. Дөнья шуларга кала бит инде.

Алмаз. Сезнең баш бар иде дә бит, дөньяның рәте юк. Башсыз, бәлки, яхшырактыр ул, ә, Гамир абый?

Гамир. Кем белә инде аны. Кара инде үзеңә. Ул-бу була күрмәсен. Нургалинең малайлары бик ниләр, тия күрмәсеннәр. Әти-әниләрең белән сөйләшергә иде. Качмас иде әле Нургали кызы!

Алмаз. Кача, Гамир абый. Мин аның башын әйләндердем. Башы әйләнгәндә эләктереп калырга кирәк. Яратам мин аны. Әниләр белән сөйләшсәң, мәңге өйләнә алмассың.

Сүрия. И Алла... Башсызлар. (*Гамирга.*) Әйдә, ят. Иртән торасы. (*Алмазга.*) Сиңа шунда верандага җәйгән. Кереп ят, йөрмә тилереп.

Тәрәзәне ябалар.

Алмаз. Ышанмыйлар. Ышанырлык та түгел бит. Сез дә ышанмыйсыздыр әле. Юкка сөйли бу дип уйлыйсыздыр. Юк, мин бары тик булганны гына сөйлим. Шулай... (*Урамнан узып баручы Нургалинең каршысына чыгып.*) Нургали абзый, эшләр ниерәк бит әле. Кызыгызның сөйләшәсе килми.

Нургали. Муеныңа асылынганын көткән идеңмени?

Алмаз. Ну бит... Шулай да... Ике сүз әйтте... Икесе дә шундый сүзләр...

Нургали. Түзәрсең.

Алмаз. Түзәрсең дип... Үземне мыскыл иттерергә...

Нургали. Машинаны тигенгә бирәләр дип уйладыңмыни? Бушка килгән машина өчен утыртып та куялар әле. Егет бул, сөйләштек бит...

Алмаз. Берәр җаен табарга иде бит. Туйда да янәшә утырасы бар.

Нургали. Тап. Егет кеше бул шулай...

Алмаз. Минем мондый кызны күргәнем юк.

Нургали. Башың яшь. Әллә нindiләрен күрерсең әле.

Алмаз. Кызык сез. Кулыннан тотарга ярамый, тегесе ярамый, монысы ярамый.

Нургали. Кем әйтә ярамый дип? Тот. Тик өйләнәсеңне генә онытма.

Алмаз. Хет, әйтегез инде үзенә, сөйләшсен.

Нургали. Яныңа куып чыгарганым да җиткән. Сөйләшмәсә, исең китмәсен. Бик матур басып тордыгыз. Күрәсе кеше дә күреп китте. (*Гамирлар тәрәзәсенә килеп.*) Гамир!

Гамир (*тәрәзәдән күренеп*). Кем бар анда? Ә-ә-ә... Нургали абый. Ни бар?

Нургали. Туйга чакырырга килдем. Килегез. Гармуныңны онытма.

Гамир. Чын булдымыни инде?

Нургали. Чын булмыйча. Өйләнешәбез, диләр бит. Яратышабыз, диләр. Нишләтәсең аларны? Шулай...

Гамир. Кай арада табышалар...

Нургали. Бөтенесенә өлгерәләр шул. Килми калма. Хатыныңны иярт, онытма. Аналарын саткыры. (*Китеп бара.*)

Алмаз. Әйе... Шулай... Җиңел түгел шул гомер итүләре, әни әйтмешли. Ничегрәк нитәргә соң? Орынырга яраса, бер хәл. Кысып кочаклар идең ул, тыпырчыныр иде, тешләр иде, тырнар иде, аннан җәтмәгә эләккән балык кебек тынар иде. Тынар иде дә кыздырып ашар идең. Ярый... Шулай... Хәерле булсын Хәмидәнең туйлары. Шулай... Шулай итеп, җәмәгать, бер көн үтте, икенче көн җитте. Гөлшат белән тагын бер тапкыр очраштык. Монысында тагын бер мәртәбә козел булдым, бер тапкыр дурак, бер тапкыр сарык. Тагын бер кат әйттем әтисенә, йә чыгарма кызыңны яныма, йә сөйләшсен адәм рәтле, дидем. Ярый... Шулай... Иртәгә туй дигән кичне дә очраштык. (*Көянтә-чиләк күтәреп килүче Гөлшатны каршы алып.*) Хәерле кич, Гөлшат. Сөйләш, димим, сөйләшмә. Дөньядагы бөтен хайваннарның исемен тагып бетердең. Тирем калын минем, түзәм мин. Син миңа арыслан, юлбарыс исемнәрен генә әйтмәдең. Каян беләсең, бәлки, мин арысландыр? Карама алай усал итеп, курыкмыйм. Син барыбер минеке булачаксың. Минем яныма чыгасың килми, әтиең барыбер чыгара бит һәм дә ки бирәчәк тә әле. Карама, дидем. Мин кызлар күргән егет. Татар кызын да, марҗа кызын да. Ләкин дә син уйлама, мин бозык түгел. Начармы, яхшымы – мин чип-чиста егет кеше. Әбием әйтеп үстерде – кызлар каргышыннан курык, диде. Бу безнең туй алдыннан соңгы очрашуыбыз – әйтәсе сүзеңне әйтеп кал.

Гөлшат. Бөтенесен дә беләсеңме?
Алмаз. Беләм.
Гөлшат. Нигә өйләнәсең?
Алмаз. Әйттем ич, ошаттым. (*Гөлшат китеп баргач, әле генә әйткән сүзен кабатлый.*) Бер күрүдә ошаттым... Кара, чынлап әйттем бит бу сүзләрне. Теләсәгез ни әйтегез, ошый миңа бу. Их, артык җире дә булмаса. Яратмаса да яраттырыр идем мин аңа. Әллә ул чынлап өйләнмәгәнемне сизә инде. Хатын-кыз сизгер була, диләр бит. Чынны ялганнан аера, диләр. Алайса, нигә алданган? Һә-ә-әй, алданмагандыр да әле. Үзләре егетләр муенына асылына да, эш узгач, алдандым, дигән булалар. Беләбез инде. Иртәгә туй диген, ә. Уйландыра башлады әле.

Туй, туй, туй, туй, туй килә –
Җүләр башка уй килә.
Туйлар ничек үтәр икән,
Ахыры матур бетәр микән?
Туен туйлаган егетне
Нинди язмыш көтә икән?
Туй, туй, туй, туй, туй килә –
Төрле-төрле уй килә.
Туй, туй, туй, туй, туй килә –
Башка төрле уй килә.
Туй узгач, туннар тузармы,
Гомерләр зарлы узармы?
Туйда биегән егетләр
Туйдан соң кул сузармы?
Туй, туй, туй, туй, туй килә –
Төрле-төрле уй килә.

ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Алмаз. Менә туй көне дә килеп җитте. Шулай... Инде хәзер Гамир абыйларның капка төбеннән Нургали абзыйларның капка төбенә күчәбез. Капканы ачып куйганнар болар. Кешеләр күрсен диптер инде. Мәш киләләр. Туй, туй, туй, туй, туй килә, төрле-төрле уй килә. Миңа туй кәчтүне алганнар. Шулай... Шулай да әйбәт кеше түгел мин, әйеме. Бер машинага кызыгып... Туктале, ә нәрсәсе начар? Мин бит аны алдамыйм. Ошаттым дип әйткәнмен икән, чынлап та ошаттым. Калганы мин чыгарган бәет түгел. Аннары мин бит ул машинаны эшләп алам. Берәүләр туйда кияү булып утырып хатынлы була, мин – машиналы. Ни начарлыгы бар... Шулай... Туй кәчтүнен салдырып калдырырлар микән? Һәй, калдырсалар тагын. Әзерләнәләр. Ә мин әзер. Солдатка нәрсә аңа. Ятты – йоклады, торды – юынды, шагом марш! Вольно! Смирно! Здравие желаю! Вәссәлам... Чабышалар... Нәрсә сөйләшәләр икән, тыңлап карыйсы килә. (*Читкәрәк китә.*)

Нургалиләр ишегалдында мондый сөйләшү бара.

Хәлимә. Хәерле генә була күрсен.
Нургали. Булыр. (*Өйгә кереп китә.*)
Хәлимә. Килен! Фәгыйлә! Фәһимә!

Киленнәр чыга.

Фәгыйлә. Ни бар, әнкәй?
Хәлимә. Башым әйләнгән. Карап чыгыгыз әле, бөтенесе дә бармы?
Фәгыйлә. Барысы да бар. Бисмилла итеп ашасыннар гына.
Фәһимә. Гөлшат җылый да җылый.
Хәлимә. Җылый торган көне. Мин дә җыладым, сез дә җылагансыздыр.
Фәгыйлә. Без бит юри генә җыладык. Модасы шундый бит. Бу чынлап...
Фәһимә. Бер сүз дәшми. Үзалдына карап утыра да җылый.
Фәгыйлә. Риза түгел, ахрысы, ул.
Хәлимә. Риза булмыйча. Кем аны көчләп биргән?
Фәһимә. Егете болай чибәр күренә. Офитсәргә укый, ди әткәй, дөрес микән?
Хәлимә. Әткәең әйткәч, дөрес булмыймы?
Фәһимә. Бигрәк тиз бит.
Хәлимә. Армиядә көтеп торалар, ди. Өйлән дә кире кайт, дип әйткәннәр. Әткәегез шулай ди.
Фәһимә. Офитсәр хатыны булу әйбәт инде.
Хәлимә. Сезнекеләр дә генералдан ким түгелләр. Барыгыз, бәлешне карагыз.

Киленнәр кереп китәләр.

Нургали (*өйдән утыргычлар күтәреп чыгып*). Кирәкмәгәнне сөйләмә боларга.

Хәлимә. Нәрсә сөйлим, ди. Гөлшат җылый, диләр.

Нургали. Җыласын. Күп көлгәч, бер җылыйсың ул.

Хәлимә. Хәерле булсын, хәерле булсын. Кем уйлаган бит, кем уйлаган?

Нургали. Беркем берни уйламаган. Берни уйламаганга шулай булган. Баш белән уйламыйлар бит хәзер, арт белән уйлыйлар. Ояты безгә. Сезнең нәсел галәмәте бу. Җилбәзәкләр сезнең нәселдә. Безнең нәселдә мондый хәл юк.

Хәлимә. Безнең нәселнең дә андый азып-тузып йөргән даны чыкмаган.

Нургали. Менә чыкты. Ахырына хәтле уйлап бетермисең. Миңа чыкканда да бер әйтүем булды, риза булдың.

Хәлимә. И Алла! Сине белмиммени инде мин?!

Нургали. Күп беләсең шул.

Хәлимә. И-и-и, синең белән торганга рәхмәт юк. Бер рәтле сүзең булмады. Малайларыңны да гел сүктең дә гел сүктең.

Нургали. Сүкмәдем, яшәргә өйрәттем.

Хәлимә. Кызыңа кызым дигәнең булмады. Гел куркытып үстердең.

Нургали. Курка, бар... Курыкса... Куркытырсың сезне...

Хәлимә. Бардыр инде, бардыр. Бездә дә бардыр, сездә дә бардыр. Дөньяның асты өскә килде.

Нургали. Асты өскә килгәндә, нигә безнең кыз аста калырга тиеш?

Хәлимә. Хәерле булсын инде. Үзем матур итеп чыктым. Ике улыбыз матур итеп өйләнде. Бердәнбер кызыбыз...

Нургали. Булды, җебемә. Миннән узып йөргәч, шулай була ул. Казанга китсен, укысын, дип сайрадың. Менә китте.

Хәлимә. Укымыйча да булмый бит. Үзенең дә укыйсы килде.

Нургали. Укыды инде. Алты фләге балыма бүләк төяп кайтты. Карап чык өстәлеңне, барысы да бармы? Кызыңа да күз сал.

Хәлимә. И Ходаем, и Ходаем!

Әүхәт белән Әхмәт керәләр – икешәр метрлы ике әзмәвер.

Нургали. Кайда йөрдегез? Кунак булып кына киләсез.

Әүхәт. Нәрсә, без дә кирәк булдыкмыни?

Нургали. Телеңә салынма. Килеп өстәлләрне рәтләп китсәгез, кулыгыз корымас иде.

Әхәт. Хатыннар китте бит, шул җитмимени?

Нургали. Без сезнең хатыннарыгызны үстермәдек. Сезне үстердек.

Әүхәт. Килгәнебезгә рәхмәт әйт, эти. Әллә нәрсәләр кыландырып ятасың монда.

Нургали. Нәрсә кыландырам, йә, әйтеп кара әле, күсәк?

Әхәт. Кызларны болай кияүгә бирмиләр инде. Узып баручы бер шыпана солдатка кыз тоттырып җибәрәсең.

Нургали. Малчайт! Кем булдыгыз атагызны тикшерергә? Ыштан киеп өлгерделәр дә аталарын тикшерәләр. Күрсәтермен мин сезгә күрмәгәнегезне! Фермер булганнар, имеш. Икмәк үстерәсе урынга ыспикүлән булып йөриләр дә аталарын өйрәтәләр. Үз кызым, теләсә кемгә бирермен. Пуняли?

Әүхәт. Аңладык.

Әхәт. Аңладык, эти.

Нургали. Шулай... Әгәр дә өстәл янында, кунаклар алдында берәр сүз ычкындырсагыз, ыштаннарыгызны салдырып, каеш чыбыркы белән тунармын. Барыгыз, өйгә кереп торыгыз, чакыргач чыгарсыз. Малакасуслар. Кая барасыз? Әниегез белән кем исәнләшер?

Әүхәт. Исәнме, әнкәй!

Әхәт. Саумы, әнкәй!

Хәлимәне кочаклап исәнләшәләр дә өйгә кереп китәләр.

Хәлимә. Бигрәк каты бәрелдең.

Нургали. Өйрәтмәсеннәр. Син дә өйрәтмә. Әнә кызыңның җилдән туган баласын өйрәтерсең.

Хәлимә. Әйтмә инде шулай дип, әйтмә инде. Капканы ябып торыйк мәллә, атасы?

Нургали. Торсын. Вакыты җиткәч ябылыр. (*Өйдән чыгып капкага таба атлаучы Гөлшатка.*) Кая барасың?

Гөлшат. Белмим.

Нургали. Ничек инде «белмим»? Чыгып барасың – белмисең.

Гөлшат. Йөреп кайтам.

Нургали. Йөреп кайтканың җиткән. Кер өйгә, киен матур итеп!
Хәлимә. Йөрмә, кызым. Нәрсә инде хәзер. Башың исән булсын.
Нургали. Булмаган баш ничек исән була ди?
Гөлшат. Әйтегез абыйларга. Нәрсә алар миңа шулай карыйлар?
Нургали. Ничек карыйлар?
Гөлшат. Мине мыскыл иткән кебек.
Нургали. Түз абыйларың караганга. Бүтәннәр карамасын. Кер өйгә.
Хәлимә (*Гөлшат киткәч*). Башы әйләнгән инде аның.
Нургали. Ярый... Бар син дә. Матур итеп киен. Тагасы әйберләреңнең бөтенесен так. Өстәл яныннан кузгалма. Фермер хатыннары чапсын. (*Сәхнә алдына килә, карана.*)
Алмаз (*Нургали янына килеп*). Мине эзлисеңме, бабай?
Нургали. Бабай... Анагызны саткырлары. Озакламый башлыйбыз. Шулай... Мин әйткәннәрне онытмадыңмы?
Алмаз. Яттан беләм. Мин армия уставын өйрәнгән кеше.
Нургали. Кеше... Кеше күләгәләре...
Алмаз. Син, бабай, мине мыскыл итмә. Киттем бардым булыр.
Нургали. Китеп кара. Машина талоны белән акчасы кесәңдә.
Алмаз. Бөтенесен кире бирәм дә китәм. Шулай...
Нургали. Нәрсә әле кирле-мырлы сөйләшә башладың? Минем малайларны күрдеңме?
Алмаз. Джиптан төшеп, икәү кереп киттеләр, шулармы?
Нургали. Шулар. Өстеңә егылсалар гына да сытып үтерәчәкләр.
Алмаз. Минем дә ике абыем бар. Берсе кеше кыйнаган өчен егерме ел утырып кайтты, икенчесе һаман да утыра.
Нургали. Шыттырма, энекәш. Барысын да беләбез. Барып белешеп кайттылар. Бер дә әллә кем түгел. Ишелергә торган өегез, аварга торган капкагыз, егылырга торган әтиең, җылап утыручы әниең бар. Шулай...
Алмаз (*кинәт юашланып калган*). Әллә?..
Нургали. Әллә шул менә. Син курыкма. Әгәр чынлап торып өйләнсәң, кеше итәбез үзеңне. Өйләнмәсәң дә сүзем юк. Мин алдаша белмим. Бар, кер безгә. Сиңа кияү кәчтүне алынган. Киен дә түр башына чыгып утыр. Кер, шүрләмә, сиңа тиюче булмас. Кара аны, чыраең сытып утырма. Элеккеге кебек елмайган бул. Өстәлдә аракы булмый – өметләнмә. Әче балны күп эчмә – йоклата. Минем малайлар сүз әйтсә, кылтырап төшмә, бабайга әйтеп, иманыгызны алдырам, диген. Бар.

Алмаз кереп китә. Әкрен генә кунаклар килә. Исәнләшеп кереп
китәләр. Гамир белән Сүрия керәләр. Гамир гармун кыстырган.

Гамир. Әссәламегаләйкем, Нургали абый?
Нургали. Уз әйдә. Шулай...
Гамир. Мондый туйны күргән юк иде әле.
Нургали. Күрерсең. Гармуныңны тартып уйна. Казанга ишетелерлек булсын. (*Сүриягә.*) Син җырла, тавышың матур.
Сүрия. Гөлшатны Дамирыбызга дип торган идек тә...
Нургали. Өлгермәдегез. Шулай... Узыгыз...

Кунаклар өстәл янына тезелешеп утырышалар. Әүхәт белән Әхәт
тә чыгып утыра.

Нургали (*алар янына килеп*). Нәрсә җәелдегез? Әниегез утырмаган килеш. Утыртыгыз җайлап әниегезне. (*Әүхәт белән Әхәт ишектән чыккан әниләрен түр башына утырткач.*) Тәк. Шулай... Әйтегез анда, кияү белән кызны алып чыксыннар. Гамир, суз әргәнеңне.

Гамир кияү белән кәләшне каршылау көен уйный. Гөлшат белән
Алмаз чыгып утыралар. Нургали сүз ала.

Шулай... Ярый... Әйе... Болай, җәмәгать. Киләселәр килде, рәхмәт. Килмәгәннәр үзләренә карасыннар. Шулай... Туй икәнен барыгыз да беләсездер. Шулайрак килеп чыкты. Хәзерге яшьләрне аңлап буламыни ул?! Бер күрүдә яратышалар, бер күрүдә танышалар. Менә бу кунак егете дә күргән безнең кызны, вәссәлам. Безнең кыз да бер күрүдә башын җуйган. Берсе өйләнәм, икенчесе кияүгә чыгам, ди. Теләсәң нишлә. Көтегез бераз, дим, бер-берегезне белгәнче сабыр итегез, дим. Юк. Беләбез, диләр. Риза булдык, нишлисең. Малайлар, Әүхәт белән Әхәт тә, яшьләрнең сүзенә аркылы төшмә, эти, диләр. Аларның да сүзләрен тыңламый булмый. Хәлимә дә әйтә, хәерле булсын, ди. Хәерле булсын, яши-яши белешерләр, Алла боерса. Әйдәгез, ризыклардан җитешегез, әче балдан авыз итегез, җырлашыгыз, биешегез, көлешегез. Гаеп итештән булмасын, хәзинәдә барын өстәлгә куйдык. Киявебез Алмаз

исемле. Әти-әниләре тирә-якта билгеле кешеләр. Туйга килеп җитә алмадылар. Магадан дигән шәһәргә кунакка киткән булганнар.

Хәзрәт. Нәрсә, Нургали, никах укытмыйсызмыни?

Нургали. Юк, алар камсамуллар. Шулай...

Хәзрәт. Камсамул бетте ич инде ул.

Нургали. Бетермәгәнгә бетмәде. Шулай...

Хәзрәт. Килешми бит, Нургали.

Нургали. Син кем, Галиулла, мулла булдым дигәч тә, хуҗа булма. Курыкма, тиешле садакасын алырсың. Яшьләр үзләре әйттеләр, урысча өйләнешәбез, диделәр.

Хәзрәт. Урыслар да туй алдыннан чукына.

Нургали. Йә инде, Галиулла. Остарма инде. Туйның ямен җибәрмә инде. Ашап-эчеп утырыгыз, кунаклар. Әче балдан авыз итегез. Әйдәгез җырлап бирәм. (*Әче бал салынган җамаякны күтәреп.*)

Ничек килдегез сез безгә,
Батмыенча диңгезгә?
Кадерле кунак сез безгә,
Ни хөрмәт куйыйм сезгә?

Тотыгыз әле, тотыгыз әче балны.

Әй нужалар, нужалар шул,
Безнең баштан узалар.
Нужа күрмәгән егетләр
Хатын-кыздан хужы алар.

Яле, ашап-эчеп утырыгыз. Хәзинәдә бары. Бердәнбер кызыбызның туе.

Фәһимә. Әткәй, мин дә бер сүз әйтимме?

Нургали. Иреңнән алда чәчрәп чыкма.

Әүхәт. Әйтсен, әйтәсен барыбер әйтә ул.

Фәһимә. Минем әйтәсе сүзем киявебез Алмазга. Алмаз кияү, син Сафалар нәселенә керүеңә бер дә үкенмә. Карап торырга гына усал күренсәләр дә, әйбәтләр алар. Борчылма, Гөлшатыбыз янында биеп кенә йөрер. Менә минем Әүхәтемә генә кара. Карап торырга усалларның усалы, ә үзе миңа ялгыш кына авыр сүз әйткәне юк.

Әүхәт. Ярый, булды, утыр.

Фәһимә. Хәзер, Әүхәткәем, бер җыр җырлыйм да утырам.

Сокланып карап туймассың
Зифа буегызга да,
Онытмагыз чакырырга
Бәбәй туегызга да.

Фәгыйлә. Мин дә бер сүз әйтимме?

Нургали. Берегез әйтте, җитәр.

Фәгыйлә. Фәһимәгә ярый, миңа юкмыни? Сеңлебез Гөлшат, син җылама. Дөнья шулай инде ул, әти өендә, әни кочагында гына утырмыйсың. Иң бәхетле парлар сез булырсыз әле, Алла боерса. Гамир абый, безнең туйда уйнаган көйне уйна әле.

Гамир. Нинди көй уйнаган идем соң?

Фәгыйлә (*җырлый*).

Озата барма, дустым, озата барма,
Олы юл бит, бәлки, адашмам.
Синең серле зәңгәр күзләреңне
Башка күзләр белән алмашмам.

Алмаз урыныннан тора да урамга чыгып китә. Аның артыннан тын калып озатып калалар. Нургали аның артыннан чыга да капканы
ябып куя. Алмаз янына чабып килә.

Нургали. Нәрсә булды? Әллә әче бал килешмәдеме?

Алмаз. Килешмәде.

Нургали. Шул шул. Аракы эчеп өйрәнгәч, бал килешми.

Алмаз. Минем эчкәнем юк. Минем берни дә эчкәнем юк. Әче балыгызны да эчмәдем. Шулай...

Нургали. Туктале, син нигә кычкырасың?

Алмаз. Оят булып китте миңа, Нургали абзый.

Нургали. Нәрсәсе оят?

Алмаз. Ничаклы кеше ышанып утыра.

Нургали. Утырса, ни булган? Бөтен туйларда ышанып утыралар инде ул. Сокланып карап туймассың, дип, бөтен туйларда җырлыйлар. Әйе... Шулай... Берәр елдан карыйсың – сокланып туймаслыклар аерылышкан булалар. Шулай...

Алмаз. Минем бит башка. Мин бит сатылып. Утырам өстәл башында сатылырга куйган товар кебек.

Нургали. Һай, бигрәк нәзберек икәнсең.

Алмаз. Әни ишетсә, бу малаемнан да рәт чыкмады, дияр инде.

Нургали. Нишлибез инде хәзер?

Алмаз. Белмим, Нургали абзый.

Нургали. Син, энекәш, әйдә нитмә инде. Кызымның оятка калдырганы да җиткән. Адәм көлкесенә калам бит. Бөтенесе дә көйләнгән. Машина ачкычы кесәңдә, утырасың да китәсең. Шулай...

Алмаз. Машинагыз да кирәкми.

Нургали. Алай димә әле син, энекәш. Барысы да кирәк дөньяда. Сиңа нинди оят? Ояты миңа аның, түзәм бит. Нишләргә кала миңа? Әйдә инде кереп утыр, түз. Әйбәт кенә бара иде бит әле. Әйдә...

Алмаз. Гөлшат миңа дөресен әйтте. Козел мин. Козел гына түгел, ишәк.

Нургали. Менә инде... Нәрсәгә инде... Чынлап торып уйласаң, без беребез дә кеше түгел. Тирәнгә кермә инде, энекәш. Син чыгып киткәч, андагылар ни уйлый инде.

Алмаз. Капканы ачып куймагыз.

Нургали. Ярый, ярый, синеңчә булыр. Шулай... Ябып куйдым.

Алмаз. Бар, керә торыгыз. Бераз утырам да керәм.

Нургали. Ярый, ярый. Тик качма инде, ярыймы. (*Кереп китә.*)

Алмаз. Әйе, шулай... Шулай була инде ул. Безнең авылга театр килгән иде. Шунда «Их безнең җүләрлек, исәпләсәң, үләрлек» дип җырладылар. Чүтеки намус бар икән әле миндә, китереп бәрде бит башка, матур гына утырганда. Әллә эче бал эчеп карыйсы инде. Йоклата, диде Нургали абзый. Йоклап утырсаң, үтәр дә китәр иде. Сезгә, билгеле, көлке инде мине тыңлавы, миңа бер дә көлке түгел.

Капкадан Әүхәт белән Әхәт чыгалар. Алмаз янына килеп, икесе ике ягына басалар. Алмаз кечерәеп кала.

Әүхәт. Нәрсә, кияү, баш әйләнеп киттеме?

Алмаз. Болай гына.

Әүхәт. Әче бал ул шундый. Аны белеп эчмәсәң... Татар аракы эчмәгән дип сөйлиләр телевизорда. Нигә эчсен, әче бал булгач.

Әхәт. Безнең сеңелне сайладың инде, әйеме?

Алмаз. Туй булгач, сайлаганмындыр инде.

Әхәт (*Алмаз иңенә кулын куеп*). Чынлаптыр инде?

Алмаз. Чынлаптыр инде.

Әүхәт (*икенче иңенә кулын салып*). Бик ашыгыч булды, ахры?

Алмаз. Ашыгыч булды шул.

Әхәт. Карале, кияү, син бик коры сөйләшәсең әле каенагаларың белән.

Алмаз. Ничек сөйләшим соң?

Әхәт. Армиядә өйрәтмәделәрмени?

Алмаз. Әллә сез офицерлармы?

Әхәт. Генераллар.

Алмаз. Мин – маршал.

Әүхәт. Шулай укмыни? Яле, тотып карыйк беләгеңне. (*Алмазның беләген капшап карагач.*) Болай ярыйсы. Кайсы войскада?

Алмаз. Погонны күрмәдегезмени?

Әхәт. Без погон карап йөрүчеләр түгел.

Алмаз. Карагыз әле, сез мине кыйнарга җыендыгыз мәллә?

Әүхәт (*дөньяны яңгыратып көлеп*). Курыктың мәллә?

Алмаз. Куркырсың да.

Әхәт. Курыкма. Тик торган кешегә тимибез без. Әгәр дә инде сеңел белән андый-мондый хәл булса...

Икәүләшеп кулларын Алмазның иңнәренә куялар.

Әүхәт. Андый-мондый хәл булса... Безнең сеңел берәү генә.

Алмаз. Алыгыз әле кулларыгызны, күтәреп торуы авыр. Элегрәк карарга иде сеңлегезне.

Әхәт. Өлгер егет булып чыктың. Сөйләштекме, кияү? Әгәр дә сеңелгә бармак белән чиртсәң, менә шушы йодрыкларны иснәрсең.

Алмаз. Ярар. Одеколон сөртеп килегез йодрыгыгызга.

Капка ачылып китә. Аннан, биеп, Фәгыйлә белән Фәһимә чыгалар. Башка кунаклар да аларга кушылган. Гамир гармун уйный.

Фәгыйлә (*биеп, Әхәт янына килә*). Әйдә, картым.

Әхәт биюгә кушыла.

Фәһимә (*Алмаз янына килеп*). Нишләп монда утырасың, кияү? Бар, чакыр Гөлшатны биергә. Үз туеңда биемәсәң, бәхетең булмый, диләр.

Алмаз (*Гөлшат янына бара*). Биибезме, Гөлшат? Әйдә. (*Гөлшатның кулыннан тота.*)

Гөлшат, бик саллы итеп, Алмазның яңагына суга.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Беренче күренештәге урын. Алмаз сәхнә алдында басып тора.

Алмаз. Шулай... Шулай булды шул. Саллы гына эләкте абзагызга. Сафаныкылар нәселеннән шул. Күздән Казан утлары күренде. Туйның рәте-чираты китте инде, билгеле. Ярый әле Гөлшатның сукканын бөтен кунаклар да күреп тормады. Ишегалдында Нургали абзый белән Гөлшатның әнисеннән башка кеше юк иде. Гөлшат миңа тамызды да үкереп җылап өйләренә кереп китте. Аның артыннан әнисе чапты. Нургали абзый белән икәү генә калдык. «Әгәр дә өйләнсәң, хатыныңа кыз бала таптырма», – диде Нургали абзый. «Шулай да бу эшне ахырына барып җиткерик инде, син бүген бездә кун инде, верандада урын җәеп куелган», – диде. Кундым инде, сөйләшенгән бит. Гөлшатны күрсәтмәделәр дә, күрәсем дә килмәде. Иртәгесен... Иртәгесен ни булганны сөйләгәнче, бернәрсә әйтим әле. Менә сезгә сөйли башлаган романның шушы җиренә хәтлесен бер компаниядә сөйләгән идем. Сөйләдем дә туктап калдым. Ничек бетте, ничек бетте, дип сорыйлар. Шуннан әйттем тегеләргә, яле, мин әйтәм, ничек беткәнен үзегез чамалагыз әле, дим. Әй тотындылар сөйләргә. Берсе әйтә, син машинага утырып кайтып төшкәч, абыйлары артыңнан килеп җиткәннәр дә сине кыйнап машинаны алып киткәннәр, ди. Икенчесе әйтә, Гөлшат төнлә торып күлгә сикергән, батып үлгән, ди. Сез Нургали белән үкенгәнсез, ди. Өченчесе Гөлшатны бәхетле итеп күрәсе килә. Икенче көнне алдаган егет кайткан да аны Казанга алып киткән, ди, икенче туйны Нургали Казанда уздырган, ди. Шатлыгыннан сиңа «Ока» машинасы түгел, «Жигули»ен биреп җибәргән, ди. Тагын берсе әйтә, син кайтып киткәнсең, әмма ләкин Гөлшатны оныта алмагансың, газаплангансың һәм дә, чынлап өйләнергә дип, яңадан Гөлшат янына килгәнсең, ди. Болай дип әйтүчегә барысы да каршы чыктылар. Аңгыра мәллә ул, җүләр мәллә ул, шушыннан соң да килеп йөрергә, диләр. Китте бәхәс – очына чыга алмадылар. Ә чынында ул болай булды. Иртәгесен тордым да Гамир абыйларга кайттым. Гамир абый эшкә барырга чыккан, Сүрия апа көтү куып кайтып килә.

Гамир. Нәрсә, кияү егете, Нургали кызының кочагы кайнармы?

Сүрия. Оялтма малайны.

Гамир. Оялтырсың аларны. Маладис. Балда, майда йөзәрсең. Түлке анда бернәрсә ишеттем әле. Әхмәтҗан күреп калган. Кәләш синең колак төбеңә ямаган, ди.

Сүрия. Сөйләмә инде кеше сүзен. Туйда сөйлиләр инде ул.

Гамир. Нургали кызы бер дә туйда утырган кебек утырмады. Алмазга күтәрелеп тә карамады. Зерә син үзеңне яратмаганга өйләнәсең. Нәрсәдер монда ни.

Сүрия. Ни булсын инде, син дә... Хатын-кыз кебек...

Алмаз. Юк, Гамир абый дөрес чамалый. Ние бар инде анысы. Гөлшатны мин күптәннән беләм ич. Дамир адресын бирде дә хат язышып тордык. Моннан өч ай элек Гөлшат минем янга килде. Шунда ялгышканбыз. Беләсең бит инде, баш юк бит бездә. Гөлшат шуннан ни инде, балага узган. Шулай...

Сүрия. Сөбханалла!..

Гамир. Мондый чакта, сөбханалла, дип әйтмиләр.

Алмаз. Шуннан соң үзгәрде Гөлшат. Ызгышып аерылыштык. Хат та язмады. Монда да сөйләшергә теләмәде. Нургали абзыйга әйттем. Калганын беләсең инде.

Гамир. Нәрсәгә дип киреләнде икән соң, үзе килгән яныңа. Ни җитмәгән?

Сүрия. И-и-и, алар нәселен беләсең инде. Холыклары көнгә ун үзгәрә.

Гамир. Инде ничек?

Алмаз. Ничек дип. Нургали абзый әйтә...

Гамир. Нургали абзый түгел инде хәзер. Бабай...

Алмаз. Бабай әйтә: бар да җайланыр, кияү, балага узган хатын холыксызлана, кайтып кил авылыгызга, ди, килеп алып китәрсең, ди.

Сүрия. Әйбәт булсын инде, әйбәт булсын.

Гамир. Шулай да сугуы хакмы?

Алмаз. Булды инде.

Гамир. Юк, тормышыгыз булмый инде. Хатын-кыз ир буласы кешесенә кул күтәрдеме, юк инде ул. Сылап җибәрәсең калган үзенә дә.

Сүрия. Бөтен кеше син түгел, бар, эшеңә соңга каласың. Чәй өлгергән, әйдә, Алмаз улым.

Алмаз. Рәхмәт, Сүрия апа. Сыйландым.

Гамир. Бергә яттыгызмы соң?

Сүрия. Төпченмә хатын-кыз кебек, бар.

Гамир. Ярый, сау бул инде алайса.

Алмаз. Сау булыгыз, Гамир абый. Сау булып торыгыз, Сүрия апа.

Сүрия. Исән-сау кайтып җит.

Алмаз (*Гамир белән Сүрия киткәч*). Уф!.. Тәки ерып чыктым бит. Бу хәтле үк ялган сөйләгәнем юк иде. Өйрәтте бит Нургали абзагыз. Дамирга хат язып салырга кирәк, минем ялганны тоттырмасын. Вот әкәмәтство, үз ялганыңа үзең ышанып куюың бар. Гөлшат баласын тәки үз балам дип йөрерсең. Тизрәк ычкынырга кирәк. Әллә машинасын да алмаска инде Нургали абзыйның. Юк, бер ахмаклык эшләдең, икенче җүләрлек эшләмә. Син «Ока»лык кына хезмәт иттең.

Нургали (*Алмаз янына килеп*). Кай арада чыгып киттең?

Алмаз. Нишләп ятыйм анда?

Нургали. Әйе... Шулай... Нишләп ятасың... Машина ишегалдында.

Алмаз. Күрдем. Әллә алмаскамы дип тә уйлап торам.

Нургали. Ал, энекәш. Тормышның рәте китте. Машинасы да күзгә күренми.

Алмаз. Аптырамагыз ул хәтле. Балалы кызлар хәзер дөнья тулы.

Нургали. Дөньяда эшем юк минем. Ал син машинаны, ал. Тырыштың.

Алмаз. Шулай сөйләштек бит.

Нургали. Исән-сау кайтып җит. Берәүгә дә сөйләмә инде моны. Оныт... Әйдә, утыртып җибәрәм. Шулай...

Алмаз. Гөлшат нишли?

Нургали. Каян белим? Беләсем дә килми. Әнисе кайнаша шунда. Хатын-кызларсыз гына торам. Шулай... Шулай шул... (*Китә.*)

Алмаз. Шуннан... Шуннан шул инде, киттем кайтып. Машина әйбәт. Кәеф кенә әллә ничек. Бозылган колбаса ашаган кебек. Бара-бара бераз ачылды. Туктап су да коенып алдым. Шуннан бөтенесе онытылды. Кайтам җырлап.

Бу дөньяга ник тудым дип
Үкенмә икән,
Дөнья йомгагы бик җиңел
Сүтелә икән.
Эх-ма, эх-ма-ма!
Аласын ал, йоклама.
Ходай сиңа бирәм дисә,
Бирә икән ул...
Сиңаниләрнең кирәген
Белә икән ул.
Эх-ма, эх-ма-ма!
Биргәндә ал, йоклама.
Бәхет юк дигән булалар,
Булмый димени?
Аккан суга чиләк тотсаң,
Тулмый димени?
Эх-ма, эх-ма-ма!
Бәхет бар ул, йоклама.

Шулай... Җырлап кайтып кердем авылга. Ничек каршы алганнарын сөйләмим инде – миңа кызык түгел, сезгә дә кызык түгел. Шуны гына әйтәм, машинаны каян алдың, дигәнгә, тагын алдаштым, яхшы хезмәт иткән өчен генерал бирде, дидем. Ышандылар, җаннарым. Берәр җиргә чыгып таяргамы әллә дип йөрдем. Таеп кая барасың? Бөтен җирдә бер дөнья. Әни дә кызганыч. Тотындым яшәргә. Бер кыз белән таныштым. Уналты яшьтә генә булса да, белмәгәне юк. Муенга асылына, кызык түгел. Күңел нәрсәдер эзли. Эзләгәндә килә дә төшә бит искә теге. Төшә – нишләтәсең. «Козел» дигәне дә «бәгырькәем» булып ишетелә. Яңакка сукканы да килеп кочаклаган кебек тоела. Төшкә керә, сабакы. Шулай дигәнгә ачуланмагыз инде, яратып әйтәм, яратмасам, «эт» дияр идем. Көн үткән саен якыная бу миңа. Бер елга якын интектем. Әллә барып күреп кайтыйм микән, дип тә уйлыйм. Шүрләп калам. Ә өченчекөн шундый төш күрдем. Сезгә аны сөйләмичә булмый. Гөлшатны беренче тапкыр очраткан

урын икән. Гөлшат көянтә-чиләген күтәреп суга бара икән. Дөнья шундый аллы-гөлле икән. Миллион сандугач сайрый икән... (*Гөлшат каршына атылып барып.*) Исәнме, Гөлшат?

Гөлшат. Исәнмесез!

Алмаз. Мине таныдыгызмы, Гөлшат?

Гөлшат. Алмаз ич син.

Алмаз. Әйе шул. Үзе. Нихәлләрдә яшисең, Гөлшат?

Гөлшат. Сине көттем.

Алмаз. Ә мин синең өчен килдем. Син шундый итеп атлап киләсең, судан йөзеп барган шикелле.

Гөлшат. Сине күргәнгә шулай ул.

Алмаз. Чынмы, Гөлшат?

Гөлшат. Мин бит гомерем буе көттем сине, Алмаз. Сине очраткач, бу егет минем бердәнберем дип уйладым.

Алмаз. Беренче очрашканда сөйләмәдең, ямьсез сүзләр әйттең, туебызда яңагыма суктың.

Гөлшат. Сине сынар өчен иде ул, Алмаз.

Алмаз. Тегесе дә мине сынар өчен идеме?

Гөлшат. Чынлап яратуы хак булса, ышанмас дип юри генә әйткән идем.

Алмаз. Чынлап әйтәсеңме, Гөлшат?

Гөлшат. Валлаһи, билләһи. Сине сагыныплар үлә яздым. Син киттең дә югалдың.

Алмаз. Югалмадым мин. Авылда гына идем. Мин дә сине бик сагындым. Мәхәббәтнең мондый икәнен белми идем әле мин. Акылдан шаштыра икән ул. Туйда чакта мин бит синең кулыңнан «әйдә биибез» дип әйтергә тоткан идем. Шундый йомшак, шундый кайнар иде кулларың, шуңадыр инде яңагым ут кебек янды. Яңакның януларына түзеп була, йөрәк януларына түзеп булмый икән. (*Җырга күчә.*)

Чәчәк эзли күбәләкләр,
Күбәләкне көтә чәчәк.
Безгә чаклы эзләгәннәр
Бездән соң да көтәчәк.
Гөлшатым, Гөлшатым!
Сине тапкач мин шатмын.

Гөлшат. Лачын оча күкләр гизеп,
Сандугачка таңнар кирәк.
Таңны көткән сандугачка
Кунып сайрар таллар кирәк,
Алмазым, Алмазым!
Синсез яши алмасмын.

Икәү бергә. Табышканга, кавышканга
Бәхет гөле атсын чәчәк.
Безгә чаклы яратканнар.
Бездән соңнар да сөячәк.
Алмазым! Гөлшатым!
Сине тапкач, мин шатмын.

Гөлшат. Синең җырың күгәрчен гөрләве кебек, Алмаз.

Алмаз. Ә синеке сандугач сайравы шикелле.

Гөлшат. Син Таһирга охшаган, Алмаз.

Алмаз. Ә син Зөһрәгә. Гөлшат, мин бер әйбер үтенеп сорасам, ачуланмассыңмы?

Гөлшат. Меңне сора, Алмаз.

Алмаз. «Идиот» дип әйткәнеңә дә үпкәләмим, «дурак» дип әйткәнеңә дә ачуланмыйм. Син миңа «козел» дип әйтмә инде, ярыймы. Бик нык, бик нык ачуың килгәндә, «айгыр» дип әйтерсең. Ә мин сиңа гел генә дә «сандугачым, карлыгачым» диярмен. Аннары соң туебызда үбешмәдек тә. «Горько» дип әйтүче дә булмады.

Гөлшат. Татарлар туйдан соң гына үбешә бит, Алмаз.

Алмаз. Туебыз узды, әйдә пәп итешик инде. (*Үбешкәч.*) Их, миннән дә бәхетлерәк беркем юк дөньяда. (*Биюгә күчә.*)

Аңа Гөлшат кушыла. Биегәндә Гөлшат югала. Аны Алмаз эзли.

Гөлшат! Гөлшат! (*Сәхнә алдына килә.*) Шулай булды шул. Шуннан түзмәдем, килдем менә. Нигә килгәнемне дә белмим. Нишләргә җыенганымны да белмим. Әллә нәрсә мине этеп алып килде. Торам менә Гамир абыйлар өе каршында.

«Бәтәч» дигән тавышка борылып карый. Сүрия басып тора.

Сүрия. Бәтәч... Алмаз, син түгелме соң бу?
Алмаз. Исәнмесез, Сүрия апа.
Сүрия. Кая югалдың син?
Алмаз. Югалмадым.
Сүрия. Монда сөйлиләр. Качты, диләр. Эзләтеп тә караган сине Нургали. Әллә кая Себер якларына китеп качкан, ди. Дамирыбыздан да хат килде. Озакламый кайтып җитәм, дигән. Хатының бала тапты. Ир бала. Бигрәкләр дә үзеңә охшаган инде, койган да каплаган. Керденме соң әле үзе янына?
Алмаз. Оялам.
Сүрия. Нидән, үз хатыныңнанмы?
Алмаз. Әллә ничек килеп чыкты бит. Акча эшлим дип, Түбән ягына киткән идем дә кайта алмадым.
Сүрия. Бар кер, аңлатырсың. Хат та язмадыңмы?
Алмаз. Язмаган идем шул.
Сүрия. Һәй, яшисез дә инде уйламыйча. Абыйлары очрамасын инде, кыйнап имгәтерләр. Гөлшат бик үзгәрде. Басылып, юашланып калды. Алып китәргә дип килмәгәнсеңдер ич?
Алмаз. Белмим әле.
Сүрия. Ничек инде белмисең? Алма кебек балаң бар.
Алмаз. Гөлшат ни әйтер бит. Гафу итмәс.
Сүрия. Итәр, итәр. Кая барсын бала белән? Кая бара ала хатын-кыз?
Фәһимә (*үтеп барганда Алмазны күреп ала*). Син түгелме соң бу, оятсыз?
Алмаз. Исәнмесез!
Фәһимә. Исән булмый нишлик? Нишләп йөрисең монда?
Сүрия. Нишләп йөрсен, ди. Хатыны, баласы бар.
Фәһимә. Исенә төшкәнмени, оятсыз. Хәзер Әүхәт абый белән Әхмәткә әйтеп иманыңны укыттырам.
Сүрия. Бик нитмә әле син, Фәһимә. Башта сораш. Аннары, син алай судия булма әле. Син килен генә. Гөлшат үзе бар. Гөлшатның әти-әнисе бар.
Фәһимә. Булгач, нигә анда кермәгән, нигә монда басып тора?
Сүрия. Уйлашабыз менә. Бар әле, Нургалине чакырып чыгар әле.
Фәһимә. Оятсыз... (*Китә.*)
Сүрия. Әйбәтләп сөйләш Нургали белән. Гафу үтен. Иелгән башны кылыч кисми. Кияве бит, әллә нишләтмәс. Ну болай бик ачулары килеп йөрде инде. Мактанчык нәселгә җитә калды. Әле авылыбызның мулласы белән сүзгә килгәннәр. Никахсыз кыз бирдең, шуңа да шулай булып чыкты, дигән мулла. Коммунист башың белән кысылма, дип әйтә икән Нургали. Шундый хәлләр. Син дә бераз олыгаеп киткәнсең сыман. Бала атасы кыяфәте кергән. Ярый, мин чәй куя торам. Гафу үтенсәң дә, Нургали белән куркып сөйләшмә. Үзләреннән курыкмаганга каты бәрелмиләр алар. (*Кереп китә.*)
Алмаз. Нургали абзый белән сөйләшербез анысы. Гөлшат нишләр? Аны күрергә дип килдем. Кызык та инде кешеләр, ни сөйләсәң, шуңа ышаналар. Үзем дә ялганларга өйрәнеп беттем. Түбән, имеш. Көтәләр ди анда сине, бар. Чыккан Нургали абзый. Ничегрәк итеп аңлатырга икән аңа? Нәрсә ялганларга? Юк, дөресен әйтәм дә бирәм, Гөлшатны күрәсем килде, дим.
Нургали. Нишләп йөрисең?
Алмаз. Исәнмесез, Нургали абзый?
Нургали. Күрешик... Шулай...
Алмаз. Менә килдем әле, Нургали абзый. Гамир абыйларның малае Дамир белән бергә хезмәт иттек бит. Кайтырга тиеш иде, кайтмады микән, дип килдем.
Нургали. Монда буталып йөрмәскә дип сөйләшкән идек бит.
Алмаз. Сөйләштек инде анысы. Сез дә мине Себергә качкан дип сөйләп йөргәнсез.
Нургали. Тинтәк халыкка төшендерергә кирәк ич. Шулай...
Алмаз. Хәлимә апа ни хәлләрдә соң?
Нургали. Исән-сау.
Алмаз. Гөлшат ни хәлләрдә?
Нургали. Балагыз бар... Шулай... Анагызны саткырлары.
Алмаз. Минем әнине нигә сатасыз? Аның ни гаебе бар?
Нургали. Син инде, энекәш, тизрәк ычкын моннан. Бүтән килеп йөрмә. Гамир малае кайтса, үзе синең янга барыр.
Алмаз. Гөлшатны күрергә ярыймы миңа, Нургали абзый?
Нургали. Нигә кирәк ул сиңа?
Алмаз. Кирәкми дә...
Нургали. Кирәкмәгәч...
Алмаз. Кызык ич.
Нургали. Кызык... Кызык инде анда. Укуын ташлады. Ята өйдә. Кызык...
Алмаз. Ни исемле куштыгыз?

Нургали. Кемгә?
Алмаз. Нигә инде... Гөлшатның ниенә.
Нургали. Сиңа нигә кирәк ул?
Алмаз. Кирәк дип... Кирәкми дә... Туйда янәшә утырдык бит. Мин сезнең сүзне тыңладым бит. Гөлшатны күреп кенә китим.
Нургали. Әллә чынлап күрәсең килә?
Алмаз. Мин шуның өчен килдем, Нургали абзый.
Нургали. Шуның өчен?
Алмаз. Шуның өчен.
Нургали. Алай... Ярый... Шулай... Ник туры безгә кермәдең?
Алмаз. Ничек туры керим ди.
Нургали. Гөлшатны күргәч, ни була инде.
Алмаз. Сорау алмагыз инде, Нургали абзый. Болай да оялам.
Нургали. Анысы менә ярый, ояла белү ярый ул. Шулай... Тагын бер тапкыр яңагыңа сукмасмы соң Гөлшат?
Алмаз. Сукса суга инде.
Нургали. Әллә тагын син?..
Алмаз. Күрәсем килә, Нургали абзый.
Нургали. Күрәсем килә... Менә нәрсә, энекәш... Син күңелеңне аздырып йөрмә. Күрсәң дә шул, күрмәсәң дә шул бу дөнья. Беләм дә инде, исеңә төшкән дә инде синең... Өстән генә уйлыйсыз. Асты бар икәнен онытасыз дөньяның.
Алмаз. Бәлки, аның асты өстенә караганда яхшырактыр.
Нургали. Нәрсә-ә?..
Алмаз. Күрим Гөлшатны. (*Нургалинең текәлеп каравыннан уңайсызланып.*) Нигә инде шулай карыйсыз?
Нургали. Карыйм әле менә... Шулай... Әллә күреп була бүтән, әллә юк... Шулай... Бар, кер Гамирларга. Урамда болганып йөрмә. Караңгы төшкәч килерсең.
Алмаз. Сезгәме?
Нургали. Гөлшатның бездә икәнлеген белмисеңмени? Әй, дөньясы...

Китеп бара. Алмаз сәхнә алдына килә.

Алмаз. Көттем инде Гамир абыйларда караңгы капканны. Күрәсе килә бит, нишләтәсең. Планнар корган булам. Әгәр дә Гөлшат «козел» дип каршылаcard, нишләргә дә, әгәр түштәге шикелле «көттем» дисә, нишләргә? Кем белә, бәлки, күренергә дә теләмәс. Караңгы капкач, киттем Нургали абзыйларга. Барам шулай. Капкаларына җитсәм, капка төбендә теге абыйлары утыра. Карап торам боларга бәйгә куйган усал этләргә караган сыман.
Әүхәт. Нихәл, кияү. Кил утыр безнең уртага. Сагындырдың.
Әхәт. Утыр, утыр, оялма.

Алмаз урталарына утыра. Моны ике яклап кысалар.

Алмаз. Кысмагыз, үтерәсез ич.
Әүхәт. Синең әле яшисең киләмени?
Алмаз. Сезнең дә яшисегез киләдер ич... Кысмагыз, дим, юкса сугыша башлыйм.
Әүхәт. Нәрсә-ә-ә... Кем белән сугышасың, чебеш?
Алмаз. Мин спецназда хезмәт иттем. Әгәр дә имгәнсәгез, миңа үпкәләмәгез.
Әхәт. Оho! Шулай укмыни? Яле күрсәт әле морякларга кем икәнлегеңне!

Ике яклап тагын да ныграк кысалар.

Алмаз (*кычкырып*). Җибәрегез, дим.
Нургали (*тавышка чыгып*). Ни бар монда?
Алмаз. Менә болар.
Нургали (*улларына*). Нишләп йөрисез монда?
Әүхәт. Менә кияү күрергә дип килдек.
Нургали. Барыгыз, кайтыгыз өйләрегезгә. Кемгә әйтәләр!..
Әхәт. Ә бу?
Нургали. Анда сезнең эшегез юк. Барыгыз.
Әүхәт. Нәрсә инде син, эти?..
Нургали. Ике әйттермәгез. (*Әүхәт белән Әхәт киткәч.*) Нишләттеләр?
Алмаз. Кысалар.

Нургали. Ә син кыстырма, егет булсаң. Көчең җитмәсә дә, сугыш. Кысылганны кысалар ул бу дөньяда.

Алмаз. Алар икәү бит.

Нургали. Булса соң. Телевизор карамыйсыңмыни? Кысалмыйлар бит чаянны. Шулай... Инде болай... Өйгә кермисең булып чыкты. Гөлшат үзе чыгар.

Алмаз. Үзе риза булдымы?

Нургали. Төпченмә. Көт. (*Кереп китә.*)

Алмаз. Уф! Йөрәк дөп-дөп тибә. Кабырганы авырттырдылар звирләр. Спецназ дигәч тә курыкмыйлар. Сүзне нидән башларга инде? Гел «исәнмесез» дип әйтү дә туйдыра. Теләсә ни булсын, капкадан чыгуга ук кочаклап алам. Беткән баш беткән. (*Капкадан Гөлшат чыккач, сүзен әйтә алмыйча, Гөлшатка карап тора.*)

Гөлшат. Исәнмесез.

Алмаз. Исәнмесез... Исәнме... Исәнмесез, Гөлшат... Мин... Әйе... Шулай... Утырыгыз әле, Гөлшат.

Гөлшат (*утыра*). Нигә килдегез?

Алмаз (*Гөлшат янәшәсенә утырып*). Ни... Гөлшат... Сезне күрәсем килде.

Гөлшат. Нигә?

Алмаз. Котлыйм сезне.

Гөлшат. Ни белән?

Алмаз. Улыгыз бар дип ишеттем.

Гөлшат. Шуны әйтер өчен килдегезме?

Алмаз. Ул гына түгел инде, билгеле. Әйттем ич, күрәсем килде. (*Гөлшатның үзенә текәлеп карап торуын күреп.*) Сез Нургали абзый кебек икән. Дәшмичә кешегә карап торасыз. Ни уйларга да белмәссең.

Гөлшат. Нигә килдегез?

Алмаз. Кызык икәнсез сез, бер сорауны әллә ничә тапкыр бирәсез.

Гөлшат. Чөнки җавап бирмисез.

Алмаз. Күрәсем килде, дигәч, җаваптыр инде ул.

Гөлшат. Сезгә нәрсә кирәк тагын? Туйда утырдыгыз, машина алып киттегез.

Алмаз. Машина дип... Мин аны алмыйсы да идем әле. Алып килдем мин аны, калдырып китәм. Миңа ошамасагыз, туйда да утырмый идем.

Гөлшат. Минем кем икәнлегемне белә идегезме? Ник дәшмисез?

Алмаз. Болай ул, Гөлшат... Әйе... Шулай...

Гөлшат. Әти белән бигрәк килешкәнсез, аныңча сөйлисең.

Алмаз. Начар кеше түгел бит ул. Инде болай, Гөлшат. Әйе... Шулай... Син миннән сорау алма. Үткәннәрне тикшерергә дип килмәдем монда. Син кем идең, мин кем идем дип тә килмәдем. Мин төшеп калган малай түгел. Каушатма мине. Сине күргәч, болай да инде әллә нишләдем. Нигә килдең дип бүтән сорама. Сине күрәсем килде. Нигә күрәсең килде дип тә сорама. Күрәсем килде, бетте-китте. Синең күрәсең килмәсә, кереп кит. Болай да инде төшләремә кереп интектерәсең. Мин гаеплемени аңа? Сиңа начарлык эшләгән булсам, гафу ит. Син дә «козел» дип әйткәннәрең өчен гафу үтен. «Дурак, идиот» дип әйткәннәрең өчен гафу үтенмәсәң дә ярар. Яңакка сукканга да ачуланмыйм. Син чөнки дә белештермичә суктың. Менә шул... Шулай... Мин әйтәсен әйттем, теләсәң нишлә. Сине күрәсем килеп килдем.

Гөлшат. Кайда сез хәзер?

Алмаз. Авылда... «КамАЗ» йөртәм.

Гөлшат. Мин дә авылда менә. Өйдә ятам.

Алмаз. Ә нигә җылыйсың?

Гөлшат. Мине күрергә килгәч, нигә җылаганымны да бел.

Алмаз (*паузадан соң*). Беләм. Җылама. Җылаган кеше күрсәм, минем йөрәгем бозыла. Казанны сагынасыңмы?

Гөлшат. Юк. Күрәсем килми ул кабахәтне.

Алмаз. Алай димә. Казан безнең башкалабыз. Аның гаебе юк.

Гөлшат. Сине әллә кая, Түмән ягына качкан дип сөйләделәр. Дамирның әнисе Сүрия апа да әллә ниләр сөйләп йөргән, мине синең янга барып йөргән дип...

Алмаз. Мин аны үзем сөйләдем.

Гөлшат. Нигә?..

Алмаз. Нигә, нигә... Нигә икәне билгеле инде. Инде болай... Әйе... Чыннан әйтәм, Гөлшат, мин сине яратам, ахрысы. Төшкә юкка гына кермисеңдер, юкка гына сине күрәсем килмәгәндер.

Гөлшат. Ул турыда сөйләшмик.

Алмаз. Нәрсә турында сөйләшик соң?

Гөлшат. Килгәнеңне әти әйткәч, ачуым да килгән иде. Инде... Рәхмәт искә алып килүеңә.

Алмаз. Нәрсә инде... Сиңа рәхмәт чыгуыңа. Берәр тапкыр мине исеңә төшердеңме?

Гөлшат. Синең кайгың булмады. Ачуланма. Нигә туйда утырганыңны сизгәч кенә... Мин керим инде. Син килеп йөрмә инде, Алмаз.

Алмаз. Беренче тапкыр исememне әйттең.

Гөлшат. Килеп йөрмә. Бөтенесе өчен дә мин сине гафу итәм. Машинаны калдырма, истәлек булсын. Килеп йөрмә. Мин ант иттем. Мин беркайчан да беркем белән мәхәббәт турында сөйләшмәячәкмен.

Алмаз. Без бүтән нәрсәләр турында сөйләшербез.

Гөлшат. Нәрсә турында?

Алмаз. Дөнья булгач, сөйләшергә сүз бетми инде ул. Менә сөйләштек ич әле.

Гөлшат (*урыныннан торып*). Хуш!

Алмаз. Утырыйк инде, Гөлшат.

Гөлшат. Юк. Мин инде хәзер сиксән яшьлек карчык кебек.

Алмаз. Соң мине дә сиксән яшьтә дип уйла.

Гөлшат (*елмаеп*). Чыннан да, тиле, ахры, син. Тагын бер тапкыр яңагыңа сугарга дип чыккан идем... Хуш! (*Кереп китә.*)

Алмаз. Мин барыбер киләчәкмен, Гөлшат... Килдем мин. Бер генә түгел, әллә ничә тапкыр килдем. Чыкмады. Дамир кайткач, ул да сөйләшеп караган. Онытсын, дип әйткән. Ул «онытсын» дигән саен, мин кыза гына барам. Аптырагач, хат яза башладым. Аңардан хат килмәде. Хет, ичмасам, карточкаңны җибәр, дип язган идем, улы белән төшкән карточкасын җибәргән. Тик сүз юк. Бер сүз дә юк. Әни күреп алган карточканы, кемнәр алар, дип сорый. Барысын да сөйләп бирдем. Башыңны әйләндермә, бәхетегез булмый, диде әни. Синең бәхетеңә ул бала аркылы төшәчәк, диде. Мин әле ул турыда уйламый идем, Гөлшатның үзе турында гына уйлый идем. Үземне биздерергә тырыштым. Тик барыбер хат язудан туктамадым. Барыбер үземнекен иттем, Гөлшат хат язды. Кыска гына иде ул хат. Хатта очрашканда әйткән сүзләр инде. Тора-бара бүтән сүзләр дә яза башлады. Язмаслык та түгел шул – мин аңа шундый хатлар язам, кайсы хатын-кызның йөрәге түзсен. Бер хатны әле шигырь белән дә яздым. Бер куплеты истә дә калган.

Нигә икән Чулпан йолдыз
Айдан ерак киталмый,
Айдан ерак китмәсә дә,
Ай янына җиталмый?

Шулай булды шул... Хат языша-языша тагын бер ел үтеп китте. Көннәрдән бер көн Гөлшатның хатында «Сагынам, ахры, мин сине» дигән сүзләрне укып акылдан шаша яздым. Хатны укуга ук киттем авылларына. Анда ни булганын сөйләп тормыйм инде, җәмәгать. Үзегез дә сизенәсездер. Ләкин, чү... Ашыкмагыз... Дөнья без сизгәнчә генә бармый ул. Син уйлыйсың тауның түбәсенә менеп утырдым дип, ә тау уйлый бу адәм нишләп минем итәгемдә буталып йөри дип. Болар очрашып, бәхетле булдылар дип уйлыйсыз инде сез. Шулай булса, ни әйтер идең дә бит, шулай булмый шул. Сөйләве авыр булса да, авылларына килеп төшкән моментны әйтәм. Чөнки анысы сезгә дә кызык тоелыр. Үзем дә аны бик еш искә алам. Әйе... Шулай... Килеп төштем авылларына. «Ока»да түгел, үзем эшләгән «КамАЗ»да. Машинаны калдырдым да Дамирларның бакча артында, киттем җәяүләп кенә Гөлшат өе ягына. Шунда карасам, каршыма Нургали абзый килә. «Соңга калдың, энекәш, Гөлшатлар яңа гына китте», – ди. «Кая китте?» – мин әйтәм. «Баласының әтисе кайтты бит, шул алып китте», – ди. Минем хәлне аңлыйсыздыр инде, җәмәгать. Сезгә дә бу сүзләрне ишетү җиңел түгелдер. Минем Гөлшатны үлеп яратуым сезгә дә күчкәндер. Күпләрегез минем бәхетле булуымны теләгәндер. Ләкин борчылмагыз, җәмәгать. Барысы да сез уйлаганча булды – Гөлшатлар өе ягына барганда капкадан чиләк-көянтә күтәргән Гөлшат чыкты да...

Гөлшат, иңнәреннән чиләк-көянтәләрен ташлап, Алмазның кочагына ташлана.

(*Гөлшатны кочаклаган килеш залга карап.*) Менә шулай булды шул, җәмәгать. Бәлки, алай да кирәкмәгәндер. Шулай да ун ел яшибез бит әле. «Козел» дип әйткәне дә юк, яңакка да сукканы юк. Сезгә дә бәхет телим.

Пәрдә.

# Галиябану, сылуым иркәм

*Ике пәрдәле моңсу комедия*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Нәсимә Ислами
Әнвәр Шамил
Гөлли Ибраһим
Ришат Туктар
Фирая Әхәт
Рамил Шәрифҗан
Туран Муллин – драматург.
1 нче артист
2 нче артист Хәлил, Галиябану, Исмәгыйльне уйныйлар.
3 нче артист

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гөлли Ибраһим фатирының зал дип аталган бүлмәсе. Хәтта балконы да бар. Бүлмә уртасындагы өстәлгә тыйнак кына табын әзерләнгән. Табын тирәсендә – катнашучылар. Рамил Шәрифҗаннан калганнары утырганнар.

Рамил (*баскан килеш*). Мөхтәрәм картлар һәм мөхтәрәмия карчыклар.
Гөлли. Нишлисең син, ә?
Рамил. Тост әйтәм.
Гөлли. Нинди тост? Бу бит мәҗлес түгел.
Рамил. Нәрсәгә җыелдык соң алайса?
Фирая. Пьеса укырга.
Рамил. Нинди пьеса тагын?
Фирая. Драматург Туран Муллин пьеса язган.
Рамил. Тагын шулмы?
Фирая. Шул үзе.
Рамил. Укымыйм мин ул язганны. Халтура.
Әнвәр. Ашыкма, Шәрифҗан. Хөрмәтле режиссерыбыз аны куярга җыена. Кабатлап әйтәм, безнең театрның хөрмәтле режиссеры. Безнең театрның. Син эшли торган театрның. Ә син пенсия яшендә. Ферштейн?
Рамил. Нигә мине чакырганда пьеса укырга димәдегез?
Фирая. Алай дисәк, килми идең.
Рамил. Килми идем. Мин уйнарлык роль юк бүгенге пьесаларда.
Нәсимә. Элеккеләрендә бар идеме?
Рамил. Бар иде. Ромео бар иде. Уйнатмадылар.
Гөлли. Адәм мәсхәрәсе. Нинди Ромео син? Сине күрсә, Джульетта хурлыгыннан егылып үләр.
Рамил. Ашыкма, әбекәй. Мин әле бүген дә Ромеодан ким түгел.

Урындыкка Фираяны күтәреп бастырып, каршына тезләнеп, Ромео монологыннан өзек сөйли.

Хуш, сөеклем, үзем исән чакта тилмертмәмен сине хат-хәбәргә. Кер кочакка. Соңгы тапкыр үбим! Менә булды. Йә, хуш! Инде китим. (*Көлешәләр.*)
Гөлли. Адәм мәсхәрәсе. Шушының белән бер театрда эшләп үтте гомерем.
Рамил. Барыбер укымыйм пьесагызны.
Фирая. Нәрсә, театрда эшлисең килмимени? (*Ришатка.*) Ришат, әйт әле шуңарга бер сүз.
Ришат. Режиссер әйткәч, укырга кирәк.
Рамил. Син гомер буе режиссер колы булдың.
Әнвәр. Театр ул – колбиләүчеләр дәүләте.
Ришат. Әтәч булып кычкырган тавыкны суялар.
Рамил. Рәхмәт инде. Ләкин суйсагыз да укымыйм.
Нәсимә. Бар, кайтып кит алайса. Режиссерыбыз – яшь кеше, безнең өчен тырыша. Пенсиядә булсак та, театрдан кумый.
Рамил. Мине куса, кем белән кала ул. Карт драматург халтура яза, яшь режиссер шуны куя. Ә мин шунда уйнап интегергә тиеш. Мин Шекспирны уйнарлык артист. Театрыгызда Джульетта булса, мин Ромеоны уйный алам.
Гөлли. Йә, ярар, тыңлыйбызмы бу адәм тәганәсен, укыйбызмы? (*Рамилгә.*) Бар, кит.
Рамил. Юк инде. Чакырып китердегез, илле грамм аракыгызны эчмичә китмим.
Гөлли. Аракы юк.

Рамил. Коньяк та ярый.

Гөлли. Коньяк та юк, берни дә юк. Мин өстәлемә шешә куйдыртмыйм.

Әнвәр. Беләсегез килсә, урысның «шиша» дигәне татарның «шешә» дигәненнән алынган. Шиш безгә аракы, Рамил.

Рамил. Картайдыгыз, кызлар. Мин әле һаман да унсигез яшьтә. Артист сиксәндә дә унсигез яшьтә булырга тиеш.

Нәсимә. Белмиләр ди синнән башка. Әйдә башлыйк. Кайда пьеса? Кем укый?

Гөлли. Автор үзе укырга тиеш иде.

Нәсимә. Кайда соң ул?

Гөлли. Хәзер килеп җитә.

Рамил. Килеп җитмәгән халтурщикның пешмәгән пьесасын тыңларга нигә мине чакырдыгыз? Китәм. (*Китәргә җыенганда ишектә кыңгырау чылтырый.*) Килде сабакы.

Гөлли барып ишекне ача. Туран белән керәләр.

Туран. Гафу итегез, җәмәгать. Пьесаның соңгы ноктасын яңа гына куйдым.

Рамил. Синең ноктаңны без монда көтеп утырырга тиешме?

Туран. Бәхет гөле чәчәк ата көтә белгәннәргә.

Рамил. Яртыңны кыстырып килдеңме? Юкса тыңламыйм.

Туран. Булыр, ашыкма.

Әнвәр. Сузмагыз вакытны, укыйк.

Туран (*җайлап утыра. Пьесасын алдына куя.*) Тәк... Бисмиллаһир-рахманир-раһим. (*Укый башлый.*) «Галиябану, сылуым иркәм».

Нәсимә. Нинди Галиябану?

Туран. Пьесаның исеме.

Нәсимә. «Галиябану» бар ич инде. Мирхәйдәр Фәйзи язган.

Туран. Бу башка Галиябану.

Рамил. Ха-ха-ха, хи-хи-хи...

Нәсимә. Башка Галиябану булалмый. Ул берәү генә.

Әнвәр. Хәлил дә берәү генә.

Гөлли. Башта тыңлыйк инде. Нәрсә инде сез? Укы, Туран.

Туран (*укый*). Катнашалар. Галиябану – җитмеш яшьтә.

Рамил. Ха-ха-ха, хи-хи-хи... Җитмеш яшьлек Галиябану? Хәлил җитмеш биштәме?

Туран. Хәлил юк минем пьесада. Ничек аңламыйсыз? Мин язган Галиябану башка Галиябану.

Нәсимә. Башка булса, сыз Галиябануны. Галиябану безнең өчен изге исем. Хәмдебану дип яз.

Фирая (*кинәт кычкырып җибәрә*). Туктагыз! Сәгать ничә?

Гөлли. Ни булды инде тагын?

Фирая. Бүген бит... Кабызыгыз телевизорны...

Рамил. Нишлисең син, ә?

Фирая. Ничек инде «нишлисең»? Бүген бит... Бара бит инде... Ничек оялмыйсыз. Артист башыгыз белән. Бүген бит телевизорда «Галиябану».

Нәсимә. Нәрсә булган икән дип торам?! Синең аркада гына йөрәк авыруы алдым. Кычкырасың да җибәрәсең.

Рамил. Импульсивная дама – Фирая Әсәтовна! Туйган ул артистлардан. Артистларсыз гына утырыйк әле. Сөйлимме, Нәсимә, бер мәзәк?

Нәсимә. Сөйләп кенә кара, авызыңа бәреп җибәрәм. Җыен пычрак анекдотны син сөйлисең.

Әнвәр. Анекдотның пычрагы булмый, кешеләрнең генә кәкәе була.

Фирая. Нишлисез сез, ә? Театрның яшь артистлары уйный бит. Ничек оялмыйсыз? Гөлли, кабыз телевизорыңны.

Нәсимә. Кирәкми. Алар кыланганны күреп нервы бозасым юк.

Фирая. Ничек оялмыйсыз? Безнең яшь чагыбыз булмадымыни?

Рамил. Булмады безнең яшьлек. Бездән Хәлилне уйнатмадылар.

Нәсимә. Әллә шушы кыяфәтең белән Хәлилне уйнар идеңме?

Рамил. Нигә? Син Галиябану булсаң, сиңа парга мин коеп куйган инде. (*Җырга күчә.*)

Таң әтәчләре кычкыра,
Әллә таң ата микән?
Тәрәзә ачып карап калды,
Галиябану, сылуым иркәм
Әллә ярата микән.

Ришат. Пьеса укыйк инде, җәмәгать.

Фирая. Өлгерербез. Бераз гына карыйк та...
Ришат. Туйдым шул телевизордан. Өйдә шул телевизор, кунакта шул телевизор.
Гөлли. Телевидениедән чыкмый яткач туйгансыңдыр шул. Ничә ачсаң, телевизорда синең елмайган йөзең.
Рамил. Йөз түгел, Гөлли ханым, ирләрдә йөз булмый, морда гына була.
Нәсимә. Мурды синдәдер инде ул.
Рамил. Юк, минем рыло. Чучка бит мин.
Фирая. Ягез инде, карап кына алыйк инде.
Рамил. Карыйк. Котылыйк пьеса укудан. Гөлли, китер шишаңны.
Фирая (*телевизор янына барып*). Гөлли, ничек кабызырга моны?
Рамил. Тип син аңа. Бездә эшләнгән телевизор бит, типмичә кабынмый.
Фирая (*телевизорны кабызып*). Туктагыз!

Телевизорда «Галиябану» спектакле бара. Җиденче күренеш. Галиябану ялгызы. Әче итеп сызгырган тавыш.

Галиябану. Ай, Хәлилме икән?

Лампаны сүндерә дә, пәрдәне күтәреп, тәрәзәне ача, тулган ай бүлмәне яктырта. Галиябану тыңлап тора.
Тагы сызгыру.

Чыгыйм микән, чыкмыйм микән? (*Башына шәл алып бөркәнә.*) Әниләр дә ятып бетмәгән. (*Ишеккә барып тыңлап килеп.*) Бүген чыкмыйм, булмаса. Әни сизсә, яхшы түгел.

Шул вакыт сузып кына «Галиябану» көенә җырлаган тавыш ишетелә.

Билемдәге ал билбавым
Тормый кыстырган җирдә;
Үзе чакыра, үзе кача,
Галиябану, сылуым иркәм,
Чыкмый сызгырган җиргә.

Галиябану (*тәрәзә янына килеп җырлый*).

Йөгереп төштем су буена
Кошлар суда йөзә дип;
Чыкмыйсың дип үпкәләмә,
Җаныем, бәгърем, сылуым иркәм,
Куркам кеше сизәр дип.

Хәлил (*Галиябануның кулын тоткан көе*).

Читтән аша төшкән чакта
Бүрәнәгә абындым.
Минуты ай, сәгате ел,
Галиябану, сылуым иркәм,
Шулкадәрле сагындым.

Кочаклашып үбешәләр.

Хәлил. Синең тирәдә козгыннар очканы беленмиме?
Галиябану. Ул кадәресен белмим. Су буенда булдыңмы?
Хәлил. Булдым. Исмәгыйль арага керә бит. Мин аның белән чак-чак сүзгә килми йөрим.
Галиябану. Мин мәңге аңа барачак түгелмен. Әтиләр кыстап йөдәтә башласалар, син миңа ярдәм итәрсең бит, Хәлил?
Хәлил. Теләсәң, мин иртәгә үк сиңа яучы җибәрәм.
Галиябану. Яхшылык белән бирмәсәләр, мин ябышып чыгам.
Хәлил (*Галиябануның кулын кыскан көе*). Вәгъдәме? Мин иртәгә яучы җибәрәм.
Галиябану. Иртәгә үк җибәр! Иртәгә үк җибәр! Исмәгыйль кысылганчы, бер хәл булсын.

Әтәч кычкыра.

Таң әтәчләре кычкыра,
Аерылуның билгесе.

Өстәлдән яулыкны алып бирә.

Бу бүләгем, сине сөеп,
Чын күңелемнән кайнап чыккан

Вәгъдәләрнең билгесе.

Хәлил. Рәхмәт. Хуш, җаным! Мин тыныч күңел белән китәм.

Галиябану (*күрешеп*). Юлыңа ак җәймә! (*Карап калып.*)

Ак укага энҗе тездем,
Бер бөртеге калганчы...

Нәсимә (*кычкырып*). Туктатыгыз! Позор! Позор! (*Барып телевизорны сүндерә.*)

Фирая. Нәрсә булды, ә?

Нәсимә. Нәрсә булганын күрмисеңмени? «Галиябану»ны үтерәләр, терелэтә суялар. Шундый Галиябану буламы? Шундый Хәлил буламы? Булмый андый Галиябану.

Рамил. Нишләп булмасын? Боты озын, итәге кыска.

Нәсимә. Җаны юк, теле юк.

Фирая. Нигә инде син? Яшьләр бит әле.

Нәсимә. Театр ул балалар бакчасы түгел.

Әнвәр. Заманы ыштансыз булгач, Галиябану гына чишенми калмас инде.

Нәсимә. Сез нәрсә, кендектән югары күтәрелә алмыйсыз? Яулык чите белән генә авыз каплап Галиябану уйнамакчы булалар. Тыйнак, имеш. Тыйнак булса ни?! Галиябануның йөрәгендә гыйшык уты яна. (*Ришатны тартып торгыза.*) Әйдәле.

Ришат. Нәрсә?

Нәсимә. Син Хәлилме?

Ришат. Нинди Хәлил?

Нәсимә. Уйнадың бит.

Ришат. Әллә кайчан ич ул. Кырык ел элек.

Нәсимә. Хәлил картаймый ул. Әйдә, җырла.

Ришат. Нишлисең син?

Нәсимә. Уйнап күрсәтәбез.

Ришат. Кемгә?

Нәсимә. Менә боларга. Күрсеннәр чын Галиябануны. Нәрсә карап утыралар бит.

Рамил. Әйдә, әйдә, Ришат. Галиябануы бигрәк яшь бит.

Нәсимә (*Рамилгә*). Син тик тор. Хәлилне уйнау ул кеше көлдерү генә түгел. Җырла, Ришат.

Ришат. Нәрсә инде... Ну, ярый. Гармун юк бит.

Нәсимә (*диваннан баш мендәрен алып бирә*). Мә гармун дип уйла. Башладык.

Ришат. Сүзләре дә онытылган.

Нәсимә. Алдашма. Беләсең. Әйдә.

Әле генә яшьләр уйнаган өзекне уйныйлар.

Нәсимә (*уйнаудан туктап*). Менә шулай уйныйлар ул Галиябануны.

Әнвәр. Алай ук түгел инде.

Нәсимә. Ничек «түгел»? Син бервакытта да минем уенымны ошатмадың.

Әнвәр. Алай димә. Ләкин синең Галиябануың Галиябану түгел.

Нәсимә. Кем соң?

Әнвәр. Син бит котырган Галиябануны уйнадың!

Нәсимә. Карале моны. Карагыз әле, котырган, ди. Минме котырган? Этмени мин котырырга?

Әнвәр. Син үзең котырган түгел, Галиябануың котырган. Хәлил мондый кызны яраталмый.

Нәсимә. Нәрсә, татар кызы җансыз булырга тиешмени? Меҗ-меҗ килеп торырга тиешмени?

Әнвәр. Кыю булырга тиеш. Әмма котырган түгел.

Нәсимә. Тыңлагыз әле, нәрсә сөйли ул, нәрсә сөйли? Галиябану ул – хисләр йомгагы. Ул, әтисенә каршы чыгып, Хәлилне сайлаган кыз. Тәрәзәдән егет керткән кыз. Аның яратуы вулкан кебек.

Әнвәр. Галиябану котырган кыз түгел.

Нәсимә. Туктыйсыңмы-юкмы? Син беркайчан да мине бәяли белмәдең. Син беркайчан да мине аңламадың. Син һәрвакыт миннән көлдең. Мине мактасалар, көенә идең, тәнкыйтьләсәләр, сөенә идең. (*Елап ук җибәреп.*) Син беркайчан мине яратмадың.

Үкереп елап балконга чыгып китә.

Рамил (*Әнвәргә*). Нәрсә инде син?..

Әнвәр. Ә мин нәрсә? Дөресен әйттем. Әллә шулай түгелме? Мондый Галиябануны Хәлил ярата алмый.

Гөлли. Нәрсә, сиңа яшьләр уены ошыймыни?

Әнвәр. Аларныкы да ошамый. Әйт, Ришат, дөрес уйныймы Нәсимә?

Ришат. Ә миңа нәрсә, әйтте – уйнадым.

Әнвәр. Син дә дөрес уйнамадың.

Гөлли. Син генә дөрес уйныйсың инде. Кешене җылаттың. Бар, юат.
Әнвәр. Нигә мин аны юатырга тиеш?
Гөлли. Син җылаттың, син юат. Бүтәннәрне оста юатасың.
Туран. Укыйбызмы без пьесаны, юкмы?
Рамил. Күрмисеңмени? Монда бүтән Галиябанулар котыра. Трагедия.
Гөлли. Ерма авызыңны. Бар, Әнвәр. Ничек аңламыйсың? Җылый бит.
Әнвәр. Хатын-кыз җылый дип, дөнья тәгәрмәче әйләнүдән туктамый. (*Балконга чыга. Нәсимә янына килә.*) Нәрсә инде син?
Нәсимә. Кит, кит.
Әнвәр. Ну китәм инде алайса. Юат, диләр бит. Нишлим?
Нәсимә. Син беркайчан да мине артистка санамадың.
Әнвәр. Санамасам, мин ул сүзләрне сиңа әйтмәс идем.
Нәсимә. Син беркайчан да мине яратмадың.
Әнвәр. Яраттым да бит, син кияүгә чыктың. Бүтәнгә.
Нәсимә. Алдашма.
Әнвәр. Нәрсә, алтмыштан узгач, яңабаштан башлыйбызмыни? Җылама. Мин сине мыскыл итеп әйтмәдем.
Нәсимә. Мыскыл итеп әйттең. Котырган, дидең. Минем йөрәгемә кадалырлык итеп әйттең. Син һәрвакыт шулай, мине үтерерлек итеп әйтәсең. Үч аласың. Минем бер гаебем юк синең алда. Мин сиңа вәгъдә биргән кыз түгел идем.
Әнвәр. Тикшермик...
Нәсимә. Алайса, нигә үч аласың? Бәлки, мин дә сине яратканмын. Дәшмәдең бит.
Әнвәр. Ярый әле дәшмәгәнмен. Миңа кияүгә чыгар идең дә артист акчасына хәерче булып яшәгән булыр идек. Бай кияүгә чыктың да рәхәтләнеп яшәдең.
Нәсимә. Һәм рәхәтләнеп яшим дә.
Әнвәр. Алайса, нигә мине битәрлисең?
Нәсимә. Син мине башкалар алдында мыскыл итәргә тиеш түгел идең.
Әнвәр. Ярый соң алайса. Үзебез генә калгач мыскыл итәрмен.
Нәсимә. Үртәмә мине.
Әнвәр. Ай-яй, холык синдә. Ходай бар ул, барысын да күреп-белеп тора. Әнә бит безне кавыштырмаган. Югыйсә мин әллә кайчан беренче группа инвалид була идем инде.
Нәсимә. Миннән әйбәтенә эләктең инде.
Әнвәр. Булдымы инде? Туктадыңмы җылавыңнан?
Нәсимә. Гафу үтен.
Әнвәр. Ни өчен?
Нәсимә. Котырган дип әйткәнең өчен.
Әнвәр: Ярый, котырган дип әйткәнем өчен гафу үтенәм.
Нәсимә. Көлмә. Елмаймыйча гына әйт.
Әнвәр. Алла бәндәсе, елмаймыйм ич инде.
Нәсимә. Күреп торам, күзләрең елмая. Миннән көләсең.
Әнвәр. Әйдә, керәбез.
Нәсимә. Кермим.
Әнвәр. Алайса, мин керәм.
Нәсимә. Кермә.
Әнвәр. Алай булмый ич иде, әллә нәрсә уйларлар.
Нәсимә. Яшь чакта уйламаганны хәзер нәрсә уйласыннар.
Әнвәр (*Нәсимәнең иңнәренә кулын салып*). Әй, Нәсимә, Нәсимә...
Нәсимә. Ал кулыңны.
Әнвәр. Гафу ит, син бит намаз укыйсың. Ярамый.
Нәсимә. Урындык артында сумкам эленеп тора, алып чык.
Әнвәр. Нәрсәгә ул?
Нәсимә. Бу кыяфәтем белән керә алмыйм ич инде.

Әнвәр бүлмәгә керә. Ә анда көлешеп утыралар.

Рамил (*сумка алырга кергән Әнвәргә*). Озак сайраштыгыз.
Әнвәр. Юат, дидегез бит.
Рамил. Юаттыңмы соң?
Әнвәр. Мин бит арысланнар белән эш итүче дрессировщик түгел. (*Чыгып китә.*)
Рамил. Әй-йе, арысланның ниндие әле.
Фирая. Үзегез бик әйбәт инде, кеше гайбәтен сатмагыз.

Туран. Болай ярамый бит инде. Укыйк инде пьесаны, җәмәгать!
Фирая. Карыйк «Галиябану»ны. Ничек йөрәгегез түзә?
Рамил. Берегезнеке түзмәде ич. Кабыз инде алайса.

Фирая телевизорны кабыза. Анда «Галиябану»дан Исмәгыйль белән Галиябану сәхнәсе бара.

Исмәгыйль (*ялыныбрак*). Галиябану, җаным! Мине шул Хәлилдән ким күрәсеңмени? Үз бәхетеңне киртәләмә. Минем кемлегемне беләсеңме? Минем исемем ишетелгәндә, бөтен тирә-як халкы тетрәп тора. Минем бөтен авыл халкын бармагымда уйнатырга кулымнан килә. Минем күңелемне егып, башкага китүнең ахыры бик яхшы булмавын уйлап кара.
Галиябану. Зинһар, Исмәгыйль абый, мине җәберләмә, мин Хәлилне сөям. Сиңа һич мәйлем юк. Юкка минем юлымны бүлмә!
Исмәгыйль. Яхшылык белән күнмәсәң, нишләргә белермен!
Галиябану. Ходайдан курык азрак.
Исмәгыйль. Ачу килгән вакытта Ходай истән чыга. Аннан да аң бул.
Галиябану. Хәтта минем синең белән сөйләшәсем дә килми. (*Китмәкче була.*)
Исмәгыйль (*бик ачу белән*). Мин сиңа китмәскә кушам.
Галиябану. Миндә синең эшең юк.
Исмәгыйль. Китә алмассың!
Галиябану. Артык тора алмыйм.

Китә башлый.
Исмәгыйль тиз генә барып Галиябануның башыннан шәлен тартып ала.
Көянтә-чиләкләре шалтырап җиргә төшә.

Зинһар, дим... (*Борылып килеп.*) Туктатма мине, бир шәлемне!
Исмәгыйль (*мыскыл итеп*). Бар кит, ник китмисең?
Галиябану (*көянтә-чиләкләрен алып*). Исмәгыйль абый, йөдәтмә мине юкка. Барыбер файда юк... Бир шәлемне.
Исмәгыйль. Хәлилгә барырга ашыгасыңмыни?
Галиябану. Зинһар, дим, туктатма.
Исмәгыйль (*каршында ялынып торган Галиябануны мыскыллап, шәл тоткан кулы белән бөеренә таянып, «Галиябану» көенә җырлый*).

Җәйгә чыксаң, җилләр өчен
Җәй келәткә урыныңны;
Миннән артык яр тапмассың,
Бик күтәрмә борыныңны.

Исмәгыйль белән Галиябану сәхнәсе барганда, балконнан кычкырып җырлап Нәсимә керә.

Нәсимә. Яшь гомер бер узгач,
Кайтмый ул яңадан.
Ә минем яшьлек кире кайтыр кебек.
Яшьлек бит күңелдә
Иң матур җирендә
Вакытлыча туктаган бер җыр кебек.
Яшьлек бит күңелдә...
Фирая. Тукта инде, Нәсимә. Карыйк инде бераз.
Нәсимә. Нәрсә, мин кайтып китиммени?
Гөлли. Бар, Нәсимә, чәй куя тор.
Нәсимә. Менә, ичмасам бу эш. (*Телевизорга карап алып.*) Позор! Позор!
Яшьлек бит күңелдә
Иң матур җирендә.

Чыгып китә.

Рамил. Бер нормальный кеше юк. Җыен шизик, җыен тилик безнең өйдә.
Фирая. Туктагыз инде. Карыйк инде.

Тынып карыйлар. Телевизорда Хәлил җырлый.

Аклы ситсы күлмәгемне
Саламын да киямен.

Ярым ятлар белән уртак
Янамын да көямен.

Галиябану. Җаным, мин ул Исмәгыйль эшне чуалтыр дип куркам.

Хәлил (*юатып*). Бернәрсә дә эшли алмас. Бер дә кайгырма. Синең, минем ризалыкларыбыз өстенә әти-әниеңнең дә күнүе белән булган эшне ун Исмәгыйль дә боза алмас. Бөтен авыл безнең якта. Ялгыз Исмәгыйль әллә кая бара алмас.

Галиябану (*бик борчулы*). Белмим шул. Ул әллә нинди яла ябудан да тартынмас. Бигрәк яман күңелле кеше икән инде. Миңа эт кебек ябышты бит... Әллә ни, әтиләрне айнытмагае дип куркам.

Хәлил (*уйга калып, бераздан*). Соң нишлик дисең, Галиябану?

Галиябану. Зинһар, бер юлын тап! Минем акылым ирешми...

Хәлил. Алайса, менә нәрсә, Галиябану, без хәзер сабыр итеп торыйк. Әтиең каладан кайтсын. Әгәр Исмәгыйль чынлап эшне болгатып, әтиләрең айнысалар һәм изалый торган булсалар, шул ук төнне Көмшәр авылына качарбыз да никах укытырбыз.

Читтән гармун тавышы ишетелә башлый.

Галиябану. Алар кемнәр?.. Исмәгыйль түгелме?

Хәлил. Шулар.

Галиябану (*борчылып*). Ходаем, мыскыл итеп җырларга тотынырлар инде. Анда никадәр халык җыелган.

Хәлил. Җыелмагае тагы...

Гармунга кушылып «Галиябану» көенә җырлый башлыйлар.

Җәйнең ямьле көннәрендә
Асыл кошлар кычкыра.
Әллә нинди җебегән авыз
Егет саен кочтыра.

Галиябану. Җаным, харап итәләр...

Җыр. Сары атым саз буенда,
Җиз камыты муенында.
Алмасам да үкенмимен,
Күп йокладым куенында...

Галиябану (*кычкырып*). Ах, ялган! Ялган! (*Егыла башлаганда, Хәлил тотып кала.*)

Гөлли (*барып телевизорны сүндерә*). Ярый, булды.

Фирая. Туктагыз инде, нишлисез соң сез?

Гөлли. Нәсимә дөрес әйтә – ачуны китерә. Галиябану түгел бит ул.

Рамил. Кем соң?

Гөлли. Атлап йөрүләре татар кызы түгел. Артын марҗа кебек боргалый.

Рамил. Татар кызы ничек боргалый соң?

Гөлли. Күрәсең киләмени?

Рамил. Синең боргалануыңны күрәсем килми. Күреп туйган.

Гөлли. Әй хәчтерүш. Арттан ялынып йөргәнеңне оныттыңмыни? Без дә уйнадык Галиябануларны.

Туран. Әллә син дә уйнап күрсәтәсеңме?

Гөлли. Әллә күрсәтмәс дисеңме?.. (*Ришатка.*) Әйдәле, Ришат.

Туран. Болай булмый бит инде. Болай ярамый бит инде.

Гөлли. Ярый, өлгерербез. Әйдә, Ришат.

Ришат. Таптылар йомшак икмәк. Миннән башка Хәлил юк мәллә сезгә?

Рамил. Гомер буе герой любовникны уйнадың. Менә мине чакырмыйлар бит. Җыен гарип-горабаны уйнагач.

Ришат. Әнә Әнвәр бар.

Гөлли. Җырлый белмәгән артист Хәлил буламыни? Әйдә, Ришат.

Ришат. Таптылар йомшак икмәк. Кайдан башлыйбыз?

Гөлли. Җырла.

Әле генә яшь артистлар уйнаган сәхнәне уйныйлар.

Рамил. Ришатның кочагына шәп аудың.

Гөлли. Ришат кочагына түгел – Хәлил кочагына.

Рамил. Син Нәсимәгә караганда Галиябанурак.

Әнвәр. Юк!

Гөлли. Нәрсә юк?

Әнвәр. Образ юк.

Гөлли. Ничек юк?
Әнвәр. Шулай, юк. Арт якны боргалап кына тумый ул образ.
Гөлли. Димәк, минем талантым юк?
Рамил. Җыла, Гөлли, җыла.
Гөлли (*Фираяга*). Ә син нигә хихылдыйсың?
Фирая. Әле дә ярый мин Галиябану түгел.
Гөлли (*җыларга җитешеп*). Усаллар сез, явызлар.
Фирая. Йә инде, нигә шулхәтле исегез китә. Яратып кына әйтә ич Әнвәр.
Гөлли. Яратып. Шулмы ярату? Ярата беләмени ул? Яратып караганы бармыни аның? Туң йөрәк ул.
Әнвәр. Образ юк бит, булмагач нишләтәсең.
Фирая. Йә, җитте инде сиңа да, Әнвәр.
Әнвәр. Образ юк. Аңлыйсыңмы, образ юк.
Гөлли. Син үзең образ. (*Өстәлдән салфетка алып күзләрен каплап балконга чыгып китә.*)
Рамил. Образ түгел, образина. Бар, Әнвәр, юат, бусы да синең корбан.
Әнвәр. Бер сүз әйтергә ярамый. Образ булмагач, бар дип булмый ич инде.
Фирая. Сүзеңне чамалап әйт. Без бит хатын-кызлар. Юктан да хәтеребез кала.
Әнвәр. Хәтер калырлык булгач, уйнамаска кирәк. Чын артист тәнкыйтьне күтәрә белергә тиеш.
Нәсимә (*җырлап чыга*). Яшь гомер бер узгач, кайтмый ул яңадан. Гөлли кайда?
Рамил. Җылый. Балконда.
Нәсимә. Ни булды?
Рамил. Менә Әнвәр, образың юк, ди.
Нәсимә. Ха-ха! Әллә Гөлли дә Галиябануны уйнап карадымы?!
Рамил. Карады шул.
Нәсимә. Ха-ха! Чәй өлгерде. (*Гөллине чакыра.*) Гөлли!
Рамил. Әнвәр чыгып алмыйча керми ул. Синең кебек.
Нәсимә. Ә минем синең сүзеңә исем дә китми. (*Ришатка.*) Син тагын уйнадыңмы?
Ришат. Уйнатасыз ич.
Нәсимә. Ничек соң? Кайсыбыз яхшы?
Ришат. Миңа барыбер.
Нәсимә. Ха-ха!

Яшь гомер бер узгач,
Кайтмый ул яңадан.

Гөлли!
Рамил. Бар, бар, Әнвәр, сине көтә ул. Бар, югыйсә чәй эчмичә дә китәргә туры килә.
Әнвәр (*балконга чыга-чыга*). Җыларлык булгач, нигә уйныйлардыр? (*Балконга чыга. Гөллигә.*) Нәрсә инде син дә?
Гөлли. Бар, кереп кит.
Әнвәр. Әнә бит әйтәләр, юат, диләр. Нәнкә ясадылар.
Гөлли. Син минем талантымны беркайчан да күрмәдең.
Әнвәр. Күренгәнен күрдем. Ә менә бүген...
Гөлли. Дәшмә.
Әнвәр. Образ юк. Аңлыйсыңмы, образ юк.
Гөлли. Син мине беркайчан да яратмадың.
Әнвәр. Яратуның монда ни катнашы бар? Образ юк, аңлыйсыңмы, образ юк!
Гөлли. Дәшмә, дим. (*Йодрыклары белән Әнвәрнең башын төя. Әнвәр бер сүз эндәшми башын иеп тик тора.*)
Әнвәр (*Гөлли төеп туктагач*). Мин ишек кебек – бер кешедә эшем юк, мине төртмәгән кеше юк. Йа Алла, түземлек бир.
Гөлли. Явыз син.
Әнвәр. Нинди явыз? Ниткән явыз? Явыз булып нишләгән?
Гөлли. Син мине беркайчан да яратмадың.
Әнвәр. Кызыклар сез. Барыгызны да яратып бетерә алмыйм ич инде.
Гөлли. Алдашма. Нәсимә артыннан чаптың.
Әнвәр. Нәрсә инде син? Хатыным бар бит минем.
Гөлли. Ә син аны яратмыйсың. Хатыныңны да яратмыйсың, беркемне дә яратмыйсың син. Әшәке. Кай җирен яраталардыр шуның? Әйдә, керәбез. Нәсимәң җан кисәгең чәй куйгандыр.

Бүлмәгә керәләр. Анда чәй эчеп утыралар.

Фирая. Бөтенесе дә балконга чыгып керде. Мин генә калдым. Кайсыгыз минем белән чыга?
Рамил. Аның остасы бар инде. Әнвәрне алып чык.

Фирая. Ә бәлки, минем аның белән чыгасым килмидер. Мин бит Галиябану түгел. Мин гомер буе җыен дурочкаларны уйнадым.

Рамил. Мин әйтәм, нигә безнең Фираябыз әллә ниндиерәк. Шул дурочкаларны уйный-уйный ычкынгансың инде син.

Фирая. Синең сыманрак инде. Ягез инде, ахырын булса да карыйк инде спектакльнең. Юкка килдем. Өйдә генә караган булсам...

Нәсимә. Әйдә, укы пьесаңны, Туран.

Туран. Әй, кәефем китте. (*Сумкасыннан шешә чыгарып.*) Эчәбезме, Рамил?

Нәсимә. Әгәр эчсәгез, мин кайтып китәм.

Рамил. Нәрсә син гел ялындырасың? Кит!

Нәсимә. Ә менә китмим. Эчермим дә, китмим дә.

Рамил. Синең ирең синең белән яшәп ничек эчмичә түзә?

Нәсимә. Минем иремне тикшермә, үз хатыныңны тикшер.

Рамил (*җырлап җибәрә*).

Биектауда Ямаширмә,
Сабаларда Икширмә.
Үз күтеңне кысып утыр,
Кеше күтен тикширмә.

Нәсимә. Фу... Нигә мине шушы пошляк янына чакырдыгыз?..

Фирая. Бер рәтле сүзең юк, Рамил.

Рамил. Ә нәрсә әйттем ул кадәрле? Җырның җыртыгы юк.

Фирая. Кабызып карыйк инде телевизорны. Ахырын гына булса да карыйк инде.

Рамил. Шулай инде үзеңә тәтемәгәч, кеше үбешкәнгә кызыгып утырасың.

Авыр тынлык.

Әнвәр. Рамил, Фираядан гафу үтен.

Рамил. Ни өчен?

Әнвәр. Гафу үтен.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук урын.

Рамил. Үзләре миңа әллә ниләр әйтәләр. Мин шаярып әйткәнне... Гафу үтенимме, Фирая?

Фирая. Кирәкми.

Рамил. Ә мин барыбер үтенәм. Әгәр дә ки мин, Фирая Әсәтовна, Сезне ялгыш кына уңайсыз сүз әйтеп рәнҗеткәнмен икән, алдыгызга тезләнеп, мең тапкыр гафу үтенәм. (*Фираяның кулын үбә.*) Гафу үтенүемнең билгесе итеп Сезгә «Галиябану» күрсәтүне үз өстемә алам.

Фирая. Кирәкми инде. Нәсимә дә...

Нәсимә. Нәрсә Нәсимә... Карамагаең. Гел шулай инде, бер нәрсәгә дип җыелабыз да икенче нәрсә эшләп таралабыз. Намазымны калдырып.

Әнвәр. Намаз укучы мөселманга театр уйнау харам.

Нәсимә. Өйрәтмә!

Рамил. Тимәгез Нәсимәгә. Без кылган гөнаһлар өчен дә тырыша ул.

Гөлли. Гөнаһ дигән була. Нишләдең соң син, хәчтерүш?

Нәсимә. Сөйләгән була инде...

Рамил. Үзең бит әйтәсең, пошляк, дисең.

Туран (*торып*). Нәрсә, пьеса укымадыкмыни инде?

Рамил. Аллага шөкер, Туран дус, котылдык.

Туран. Син нәрсә һаман да мине мыскыл итәсең? Артымда да халтурщик дип сөйләп йөрисең икән. Үзең кем соң?

Рамил. Мин артист.

Туран. Артистның ниндие булмый.

Нәсимә. Боларның тозсыз сүзен тыңлаганчы, кабыз телевизорны, Фирая.

Фирая телевизорны кабыза. Анда «Галиябану» спектакленең финалы.
Исмәгыйль, Хәлил, Галиябану.

Галиябану. Зинһар, Исмәгыйль абый, безне җәберләмә!

Хәлил. Без кечкенәдән бер-беребезне сөеп вәгъдәләр бирештек. Сиңа көндәш булу дигәнне уйлаганым да юк. Син дә безне бикәргә харап итмә!

Исмәгыйль. Ник шунда Ходай үзе никахыгызны укып яратмаган. Ул сүзләрнең берсе дә колагыма керми хәзер. Тик сез минем алдымда калтырап торырга тиеш икәнне генә беләм, һәм менә шуны күзем

белән күреп торам. (*Револьверын Хәлилнең маңгаена ук китереп.*) Менә Исмәгыйльнең кулы бу җирдән вәгъдәләрегезнең көле очканнан соң гына алыныр...

Галиябану (*хәлдән таеп*). Атма! Атма!

Исмәгыйль. Кит Хәлилнең яныннан, ташла аны!

Хәлил белән Галиябану нишләргә белми аптырашып торалар.

Исмәгыйль (*аз гына көтеп тора да сул кулы белән Галиябануның кулына ябыша; Галиябану тартыла; көч белән йолкып алып, Хәлилгә*). Инде Галиябану миндә. Син үзеңнең язмышыңны билгелә! Йә туры гына чыгып кит, йә дөнья белән саубуллаш! Бер минут срок сиңа...

Хәлил кинәт Исмәгыйльнең өстенә очып куна. Исмәгыйль атарга өлгерә алмый кала. Револьверы җиргә төшә. Икәү алыша башлыйлар. Ахыр чиктә Исмәгыйль, Хәлилне җиргә егып, өстенә атлана. Ләкин Хәлил җирдәге револьверны алып өлгерә дә яткан җиреннән өстендәге
Исмәгыйльгә төзи.

Исмәгыйль (*кире чигенә*). Шаярма, дим, минем белән!

Хәлил. Тор! Атам!

Исмәгыйль. Уйнама, дим! (*Акрын гына тора.*)

Хәлил (*револьверны төзәгән килеш торып*). Менә инде хәзер син минем кулда. Инде мин синең язмыш белән уйныйм. Бездән каласыңмы? Юкмы?

Галиябану (*Хәлилгә килеп ябышып*). Ай, үзеңне харап итәсең. Атма, зинһар! Атма, дим, Хәлил! Ташла җиргә аны! Ташла, зинһар, ташла!

Исмәгыйль. Йә, күрсәт егетлегеңне.

Хәлил. Синең кебек этне атарга хурланам. (*Револьверны җиргә бәрә.*)

Исмәгыйль револьверга ташлана.

Ал, иманың булмаса, шул җиргә ташланган алтатарны!

Исмәгыйль. Кит, сөйләнмә! Тыясыңмы телеңне? Китәсеңме яхшы чакта?

Галиябану. Имансыз ук икәнсең!

Хәлил. Ник китим мин?

Исмәгыйль. Китәсеңме, дим?

Хәлил ике бармагын авызына кабып әче итеп сызгыра.

Исмәгыйль (*револьверын төзәп*). Стоп! Ә, син шулаймыни?!

Галиябану *(кулын сузып, Исмәгыйльгә каршы йөгереп).* Зинһар, Исмәгыйль абый!..

Исмәгыйль (*төртеп җибәреп*). Кит моннан!

Галиябану (*аягына егылып*). Кызган!

Хәлил. Ялынма ул эткә!

Исмәгыйль (*ачуыннан буылып*). Ә, этме?!

Хәлил. Эт син! (*Кесәсеннән пәке чыгарып, Исмәгыйльгә һөҗүм итә.*)

Исмәгыйль. Мә алайса! (*Атып җибәрә.*)

Хәлил чалкан килеп төшә.

Галиябану (*сикереп торып, әче тавыш белән кычкыра*). Ах! (*Хәлил янына тезләнеп.*) Хәлил! Хәлил!.. (*Паузадан соң.*) Хуш, җаным, Галиябануыңа кавышу шатлыгы урынына синең җеназаң өстендә елап утырырга туры килә инде. Хәлил! Күңелемнең иң тирән җиреннән, каршымда син бар вакытта гына килеп чыга алган, син «Галиябану» дип атаган көй минем бердәнбер юанычым булып калды. Моннан соң бу көйне сине сагынып җырлармын. Синең төсең итеп тотармын... Хәлил! Бу көйне синең өчен генә җырлый алган идем. Менә шушы җеназаң өстендә синең исемеңә мәңгелек бүләк итеп багышлыйм.

Бу вакыт ерактан скрипкада «Галиябану» көен уйнаган тавыш ише
телә. Һәммәсе дә тын гына тәэсирләнеп тыңлап торалар.

Галиябану *(бик моңлы итеп кушылып җырлап китә).*

Ак атласым җитмәде,
Алмас кайчым үтмәде;
Унөч яшьтән бирле сөешеп,
Күзебез күзләрдән китмәде,
Ходаем насыйп итмәде.

*(Елап Хәлил өстенә ава.)*

Рамил (*Фираяга*). Йә, булдымы инде, күңелең? Кино бетте, фильм тәмам.

Нәсимә. Позор! Шулай елыйлармы? Үпкәләгән бала кебек мышкылдый.

Гөлли. Мужигы кыйнаган Марфа шикелле үкерә. (*Елап утырган Фираяны күреп.*) Әллә җылап утыра инде? Карагыз әле моңа, җылап утыра. Тапкан җыларлык спектакль.

Фирая балконга чыгып китә.

Рамил. Әле дә балкон бар әле. Чыгалар да күз яшьләрен түгеп керәләр. Бар, Әнвәр, юат.

Әнвәр чыгып китә.

Ришат. Юкка җылаттыгыз Фираяны.

Нәсимә. Нишләп без аны җылатыйк?

Ришат. Күңеле нечкә аның. Хәер, без барыбыз да бала-чагалар. Нәрсәгә кирәк иде артист булу, картайдык, олыгаеп булмады, акыл кермәде.

Рамил. Әйттем бит инде, нәрсәгә кирәк ул акыл? Акыллыларны хәзер аталар.

Ришат. Безне дә кызганып тормыйлар инде. Әйдә, укы пьесаңны, Туран.

Туран. Укымыйм. Үпкәләттегез.

Ришат. Нишлибез соң алайса? Нәсимә, җырла әле яшьлегеңдә җырланмый калган берәр җырыңны. Бар иде заманалар – Гөллинең биле бер учка сыеп бетә иде.

Рамил. Безне танымый да иде.

Ришат. Ә Нәсимә кыр кәҗәсе кебек кыргый иде. Егерме өчәү идек бит. Инде ничәбез китеп барды. Мәңгелеккә.

Гөлли. Күңелсез әйберләр сөйләшмик әле.

Нәсимә. Тегеләр нишлиләр икән?

Рамил. Көнләшмә, бер нишләмиләр.

Нәсимә. Бик исем китә.

Рамил. Исең китә инде анысы.

Ришат. Беренче тапкыр сәхнәгә чыккан көннәр, ә. Син яшьләрне хурлама, Нәсимә. Без дә шулар кебек идек.

Гөлли. Юк, без андый түгел идек. Бер наиврак идек.

Ришат. Хәтерлисеңме, Рамил? Рәшитне кибеткә ипи алырга җибәргән идек. Соңгы тиеннәрне җыеп. Ул кибеттән тулай торакка кайтып җиткәнче бер кирпеч ипинең яртысын ашап бетергән иде.

Гөлли. Барыгыз да бетле идегез инде.

Нәсимә әкрен генә җыр башлый. Балкон рәшәткәсенә таянып Фирая
белән Әнвәр дөньяга карап торалар.

Әнвәр. Син нитмә, Фирая. Нишлисең инде. Шулай инде дөнья. Аңлыйм мин сине. Авыр сиңа. Бик авыр сиңа. Мин дә синең кебек. Булатны уйнарга теләдем, Ромеоны уйнарга теләдем. Хәлил белән хыялландым. Уйнатмадылар. Аңлыйм сине. Күрәсең без Хәлил белән Галиябану түгелдер. Нәсимә белән Гөллигә рәхәт. Барысын да уйнадылар. Аларның яшьләрне тәнкыйтьләргә хакы бар. Ә менә синең хакың юк. Берәр тәнкыйть сүзе әйтсәң, үзең уйнап күрсәттеңме соң, диячәкләр. Әнә бит Рамил дә ничек мыскыл итте. Аңлыйм мин сине. Син җылама. Шулай инде, без җырласак – көләләр, биесәк – көләләр.

Фирая. Синнән көлмиләр.

Әнвәр. Миннән дә көләләр. Ләкин мин җыламыйм. Үзем дә көләм. Җырлый-бии белмәгәннәр өчен аерым театр булсын иде ул. Син Галиябануны, мин Хәлилне уйнар идек. Беләсеңме, мин бит Хәлил ролен яттан беләм.

Фирая. Мин дә.

Әнвәр. Син үкенмә, Фирая. Үкенечкә калган әйберләр күп инде ул дөньяда. Ләкин үкенмә.

Фирая. Рәхмәт сиңа, Әнвәр. Әле дә янымда син бар. Берәү дә белмәгән серләремне син беләсең. Үзем аңламаган уйларымны син аңлыйсың. Олыгайган саен сиңа якыная барам. Ташлама мине.

Әнвәр. Ничек ташлыйсың? Син дә миңа кирәк бит. Безнең җаннарыбыз бертуганнар, Фирая. Ришат мәсьәләсендә генә аңлаша алмыйбыздыр без.

Фирая. Кирәкми, Әнвәр.

Әнвәр. Мин яратмыйм аны. Син яратасың.

Фирая. Кирәкми, дидем.

Әнвәр. Сукыр түгел бит ул синең мәхәббәтне күрмәскә. Үзе гомер буе Хәлилләрне уйнады, янәшәсендәге Фирая исемле Галиябануны күрмәде. Ә син гомер буе шуны көттең. Кияүгә чыгарга иде сиңа. Ришат дип ялгыз калдың.

Фирая. Ялгыз түгел мин.

Әнвәр. Үз-үзеңне алдап яшисең. Аның исе дә китми.

Фирая. Күңеле ятмагач нишләсен инде?!

Әнвәр. Кешенең мәхәббәтен бәяли белергә дә кирәк.

Фирая. Бәяләп нишләсен?

Әнвәр. Сине өзелеп яраткан хатын-кызны бер тапкыр да кочаклап карама инде.

Фирая. Кочаклар өчен яратырга кирәк. Мин аңа рәхмәтле. Әле дә ярый кочакларга үрелми. Мин белмим нишләр идем.

Әнвәр. Әйе-е-е...

Фирая. Мине кочаклаучы бар бит, Әнвәр. (*Әнвәрнең кочагына сыена.*)

Әнвәр. Әй, минем кочаклавым да инде. Кысыр кочаклау.

Фирая. Алай димә. Җаныңның җылысын тоям мин. Без синең белән яшьтәшләр булсак та, бертуган абыем кебек син. Әтисез үстем бит мин. Әти урынына абыем булды. Аның кочагында үстем. Ул да юк инде. Син калдың. Ходай сиңа озын гомер бирсен. Чиста кеше син.

Әнвәр. Чиста калып булмый инде ул. Дөньясы пычрак булгач.

Фирая. Гаепләмә дөньяны. Кешеләр пычратканга аның ни гаебе бар.

Бүлмәдә Нәсимә җырлый.

Кайсы гына ла егеткә барырбыз дип, Гөлҗамал,
Колактан колакка гына сөйлиләр.
Энҗе-мәрҗән кызларның кул бавы,
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.

Ришат. Хәзер әйтсәң дә ярыйдыр инде, мин сиңа гашыйк идем, Нәсимә.

Нәсимә. Гашыйк дигән була, Гөллине күрсәң, башың-күзең әйләнә иде.

Гөлли. Ә Ришат ул гашыйк була белми. Үзенә гашыйкларны да күрмәде.

Ришат. Нигә инде алай дисең, Гөлли? Мин дә кеше ич.

Балкон күренеше.

Әнвәр. Ришатны әйтәм, гомер буе хатын-кызны аңламады. Кара инде, шушы гүзәллекне күрмичә...

Фирая. Оялтма мине.

Әнвәр. Минем хатын синнән көнләшә. Бер әйбер дә аңламый бу хатын-кыз. Иң гөнаһсыз кешеләр – синең белән без, ә көнләшә. Гөнаһ кылсак, көнләшмәс иде әле. Беләсеңме, Фирая, дөньяда Галиябанулар күптер, ләкин бердәнбер Галиябану – син. Ярата беләсең син. Олы мәхәббәтнең корбаны син. (*Үзе дә сизмәстән җырга күчә. Һәм алар, мавыгып китеп, «Галиябану»дан бер күренешне уйнарга күчәләр.*)

Әнвәр. Билемдәге ал билбавым
Тормый кыстырган җирдә;
Үзе чакыра, үзе кача,
Галиябану, сылуым иркәм,
Чыкмый сызгырган җиргә.

Фирая. Йөгереп төштем су буена
Кошлар суда йөзә дип;
Чыкмыйсың дип үпкәләмә,
Җаныем, бәгърем, сылуым иркәм,
Куркам кеше сизәр дип.

Әнвәр (*Фираяның кулын тоткан көе*).
Читән аша төшкән чакта
Бүрәнәгә абындым.
Минуты ай, сәгате ел,
Шулкадәрле сагындым.

Кочаклашып үбешәләр.

Әнвәр. Синең тирәдә козгыннар очканы беленмиме?

Фирая. Ул кадәресен белмим. Су буенда булдыңмы?

Әнвәр. Булдым. Исмәгыйль арага керә бит. Мин аның белән чак-чак сүзгә килми йөрим.

Фирая. Мин мәңге аңа барачак түгелмен. Әтиләр кыстап йөдәтә башласалар, син миңа ярдәм итәрсең бит, Хәлил?

Әнвәр. Теләсәң мин иртәгә үк сиңа яучы җибәрәм.

Фирая. Яхшылык белән бирмәсәләр, минябышып чыгам.

Әнвәр (*Фираяның кулын кыскан көе*). Вәгъдәме? Мин иртәгә яучы җибәрәм.

Фирая. Иртәгә үк җибәр! Иртәгә үк җибәр! Исмәгыйль кысылганчы, бер хәл булсын.

Әтәч кычкыра.

Таң әтәчләре кычкыра,
Аерылуның билгесе.
(*Өстәлдән яулыкны алып бирә.*)

Бу бүләгем, сине өеп,
Чын күңелемнән кайнап чыккан
Вәгъдәләрнең билгесе.

Әнвәр. Рәхмәт.

Су буенда салкын җил,
Туңам, җанкай, туның бир.
Айлар бата, Чулпан калка.
Чулпан калкып таңны уята,
Китәм, җанкай, кулың бир.

Бүлмә күренеше.

Гөлли. Нишлиләр анда тегеләр?

Рамил. Нишләсеннәр, «Галиябану» уйныйлар. Акылдан шаштылар. Берәү алтмыш ике яшьтә «Галиябану» яза, икенчеләре алтмыштан узып Галиябану уйныйлар. Драматургның алып килгән мәен эчермиләр.

Туран. Ярый, мин киттем. Кирәк булсам, чакырырсыз әле.

Гөлли. Үпкәләмә инде, Туран.

Туран. Нигә үпкәләргә? Артист халкы шундый инде ул.

Нәсимә. Нинди?

Туран. Килделе-киттеле. Бала-чагалар.

Рамил. Акыл кергән көнне артист театрдан китәргә тиеш. Бизнес белән шөгыльләнергә тиеш.

Гөлли. Нишлиләр анда тегеләр?

Рамил. Хәзер беләбез. (*Балкон ишеге янына барып.*) Һа, монда хәлләр. Хәлил белән Галиябану.Килегез, күрегез, монда Исмәгыйль генә җитми. Менә мин инде ул Исмәгыйль. Хәзер Исмәгыйль булып Хәлилне атабыз. (*Бармагын Әнвәргә төзәп.*) Үл, бәдбәхет! Шалт! Шалт! (*Әнвәр егылгач.*) Эшең бетте, кодагый.

Өстәл янына киләләр.

Хәлил үлде, Галиябанулар миңа калды. (*Нәсимә белән Гөллине кочаклый. Җыр суза.*) Галиябану, сылуым иркәм.

Фирая (*кабаланып кереп*). Карагыз әле, Әнвәр тора алмый.

Рамил. Аткач ничек торсын? Үлгән ич инде ул.

Фирая. Шаярмагыз әле. Төсе ап-ак.

Балконга чыгып китә. Бүтәннәр дә балкон ишегенә киләләр.

Рамил. Шәп артист шул, уйный белми уйный.

Гөлли. Туктале син... (*Әнвәр янына килә.*) Әнвәр!.. Әнвәр!.. Йа Ходаем! Нәрсә карап торасыз?! Алып керегез...

Әнвәр тирәсендә кайнашалар. Ришат белән Рамил аны күтәреп кереп
диванга яткыралар.

Рамил (*Әнвәргә*). Чынлаптамы әллә, Әнвәр?

Нәсимә (*Әнвәрнең йөзен күреп кычкырып җибәрә*). Юк!.. Юк!..

Ришат. Нәсимә, кычкырма әле.

Нәсимә. Юк!.. Юк!..

Фирая (*Әнвәр янына тезләнеп*). Әнвәр... ишетәсеңме мине, Әнвәр?!

Гөлли. И Ходаем! Дару юкмы бирәрегездә? Шылтыратыгыз әле «ашыгыч ярдәм»гә.

Әнвәр (*торып баса*). Кирәкми, мәшәкатьләнмәгез. Менә шулай уйныйлар ул «Галиябану»ны.

Рамил. Молодец, Әнвәр, уйный белеп уйнадың!

Гөлли. Әшәке, куркыттың.

Нәсимә. Ә мин ышанмадым.

Ришат. Алдашасың, Нәсимә.

Нәсимә. Алдашса ни булган. Әллә сезгә генә алдашыргамы? Укы әйдә пьесаңны, Туран.

Туран. Юк инде, укымыйм. Соң инде. Үпкәләттегез. Ярый, хөрмәтле җәмәгатьство... Минем халтураны укымадыгыз инде. Үпкәләмим. Нигә үпкәләргә. Без бит бер ата балалары кебек. Гомер бергә узды. Мин халтура яза тордым, сез аны уйнадыгыз. Уйнап, халык артистлары, лауреатлар булдыгыз. Гомумән, Шекспир белән Чеховны уйнап лауреат булган татар артистын белмим мин. Әйе, искерәмдер инде. Сез дә, бәлки, искерәсездер. Ләкин бер нәрсәгә иманым камил – сез барыгыз да талантлылар. Һәм мин сезне чын күңелемнән яратам. Сезнең һәркайсыгыз да Галиябану белән Хәлилне уйнарлык талантлар. Вакытында уйнатмаганнар икән, ни әйтим... Сез бүген укырга теләмәгән пьеса сезнең турында иде. Бөтенегезне бергә җыеп, үзебез исән чакта җыелышып уйнарсыз дигән идем. Режиссер да

пьесаны шуның өчен сезгә укытырга теләгән иде. Тамашачы да сезне һаман да сәхнәдә күрергә тели. Сезне алар да яраталар. Чөнки сезне ятратмаска мөмкин түгел. Сау булыгыз, кадерлеләрем. Кирәк тапсагыз, телефонымны беләсез.

Ирләрне кочаклап, хатын-кызларны үбеп чыгып китә.

Пәрдә.

# Алты кызга бер кияү

*Ике пәрдәле моңсу комедия*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Рәхмәтулла Хөрмәтуллович – 59 яшьтә.
Гөлчирә – 42 яшьтә.
Фаягөл – 39 яшьтә.
Рузалия – 19 яшьтә.
Нурзидә Мөбәрәковна – 45 яшьтә.
Хәдичә – 40 яшьтә.
Нина Васильевна – 42 яшьтә.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыйга бухгалтериядә бара. Бер бүлмәдә алты өстәл. Бөтен өстәлләрдә дә компьютер. Пәрдә ачылганда, Рәхмәтулла үз өстәле артында
эшләп утыра. Әкрен генә көйли.

Заманалар авыр, еллар ябык –
Дус-иш кирәк гомер итәргә...
Заманалар авыр, еллар ябык...
Заманалар авыр, еллар ябык...

Хәдичә керә, Рәхмәтулла өстәленә тастымалга төрелгән ризык куя.

Хәдичә. Суынганчы капкалап алыгыз, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович.
Рәхмәтулла. Ач түгел мин, Хәдичә. Нигә инде син?..

Хәдичә сүзсез генә үз өстәле янына барып утыра. Күзгесенә карап
төзәтенә. Рәхмәтулла аны күзәтә.

Сиңа чәчне кыектан ачу килешә, Хәдичә! (*Янына килеп.*) Менә бу яктан ач, бу ягын күпертебрәк җибәр. Синең йөзең тулган ай кебек түгәрәк, күпертебрәк җибәрсәң, тагын да чибәрләнәсең. Чын татар кызының чибәрлеге синдә. (*Хәдичәнең аркасыннан чәбәкли дә өстәле янына бара.*)

Фаягөл керә.

Файгөл. Шушы трамвайларның тәгәрәп җан биргәннәрен генә күрсәм иде. Троллейбусларын үләт себереп китсен иде! Маршруткалары мәтәлеп үлсен иде!
Рәхмәтулла. Соңга калмадың ич, Фаягөл.
Фаягөл. Калмаса ни. Үләрдәй булып чаптым. Үпкәм бугазыма килде.
Рәхмәтулла. Җәяү йөрү сиңа файдалы ул, Фаягөл. Биләң әз генә калыная башлады. Кызлар биле 60 сантиметр булырга тиеш.
Фаягөл. Кызлар биле бит ул.
Рәхмәтулла. Синең кай җирең кызлардан ким? Синең атлап йөрүләреңә карап торам да яшь чагым искә төшә.
Фаягөл. Сезнең аркада ашыгам мин. Кайчан килсәң дә, сез тасраеп утырасыз. Сезгә карап мин чабам.
Рәхмәтулла. Яшьрәк булсам, мин синең арттан чабар идем. Алданрак туарга ашыкканмын шул. Яңа туфли алгансың икән.
Фаягөл. Шул аякларымны кырып бетерде инде.

Рәхмәтулла. Аякларың кырып ясалган кебек шул.

Фаягөл. Күз тидермәгез тагын. Без бит исәнләшмәдек тә. Исәнме, Рәхмәтулла абзый! (*Рәхмәтулланың битеннән пәп итеп ала.*)

Рәхмәтулла. Исәнме, Хәдичә! (*Утыра.*)

Рузалия керә.

Рузалия. Исәнмесез!

Рәхмәтулла. А-а-а, Рузалия!.. Безнең яраткан кызыбыз да килде.

Кулымдагы йөзегемнең
Исеме Рузалия.
Шул Рузалияне күрсәм,
Йөрәгем сикерия.

Мәхәббәт өлкәсендә уңышлар ничек, Рузалия?

Рузалия. О’кей.

Рәхмәтулла. Их, миңа унтугыз яшь булса...

Фаягөл. Нишләр идегез, Рәхмәтулла абзый?

Рәхмәтулла. Рузалияне үземә каратыр идем.

Рузалия. Мин болай да сезгә карыйм, Рәхмәтулла бабай.

Фаягөл. Бабай димә, безне картайтасың.

Нина керә.

Нина. Исянмесез! (*Рәхмәтуллага.*) Привет, жених! Килегез әле, аракы исе килмәгән бер егетне кочаклыйм әле, (*Рәхмәтулланы кочаклап алганнан соң*) привязался бер алкаш трамвайда. Зараза. С утра тыгынган, сволочь. Дөрес әйтәмме, Рахматулла Хурматуллович? Тыгынган-налакался бит, да?

Рәхмәтулла. Син әйтсәң дөрес, Ниночка. Ты всегда истину глаголишь. Как спали, Нина Васильевна?

Нина (*кәефсез генә*). Бик яхши.

Рәхмәтулла. Вы Шекспира читали, Нина Васильевна?

Нина. Какого Шекспира?

Рәхмәтулла. Был такой англичанин. Он писал гениальные трагедии. «Отелло», например. Так вот Отелло говорит своей возлюбленной: «Молилась ли ты на ночь, Дездемона?»

Нина. Ну и что?

Рәхмәтулла. Задушил Отелло Дездемону.

Нина. Причем здесь я?

Рәхмәтулла. При том, Ниночка, улыбаться надо. Улыбка делает женщину прекрасной.

Нина. Ну и улыбнитесь. Кстати, почему сез минем белән урысча сөйләшәсез? Мин татарча өйрәнәм. Мин сине яратам – приходи к воротам.

Гөлчирә (*кереп*). Капиталистик хезмәт алдынгыларына ялкынлы сәлам! Рәхмәтигә аерым сәлам! (*Рәхмәтулла янына килеп.*) Нихәл? (*Рәхмәтулланың пеләшен үбеп ала.*) Пеләш башны үбүе җайлы, авызга чәч керми. Кара утырып торуын. Тор һәм кочакла! (*Үзе Рәхмәтулланы кочаклап алгач.*) Утыр һәм эшлә!

Фаягөл. Әгәр дә Зөһрә Таһирны шулай кочаклаган булса, мәхәббәт турында гениаль әсәр язылмый калган булыр иде.

Гөлчирә. Көнләшмә. Шул җиткән аңа. Югыйсә азына башлый. Шунысын да онытмагыз, Таһир пеләш башлы булмаган.

Рәхмәтулла. Пеләш башлы ирләр бүгенге заманда файдалы, Гөлчирәкәй. Парикмахерскаяда бәяләр көн саен арта.

Гөлчирә. Сөйләштермә, эшем күп.

Берара тыныч кына эшлиләр.

Рәхмәтулла. Ишетмим. Бүген кем чираты? Рузалия, синме?

Рузалия. Мин кичә көйләдем. Бүген Нина Васильевна көне.

Рәхмәтулла. Ниночка, начинай. Эшләп булмый.

Нина. Не умею я мурлыкать. Белмим.

Рәхмәтулла. Бүтән көннәрне белә идең.

Нина. Бүген нет у меня настроения.

Рәхмәтулла. Настроение җырлаганда килә.

Нина. Прямо как надзиратель сез, Рахматулла Хурматуллович.

Рәхмәтулла. Не надзиратель, а петух в курятнике.

Гөлчирә. Аһ! Петух! Карт әтәч.
Рәхмәтулла. Сез дә чебиләр түгел. Нина, көтәм. Жду.

Нина авыз эченнән бер көй көйли. Ул көй салмак кына яңгырый.

Гөлчирә (*кычкырып җибәрә*). Сабакы! Тагын глюк башланды.
Рузалия. Нәрсә карый президент?!
Нина. Куда смотрит правительство?!
Фаягөл. Нигә Дәүләт Советы дәшми?!
Гөлчирә. Көлмәгез. Миңа иске шайтан машинасы бирделәр дә... Рәхмәти, кил, кара.
Рәхмәтулла. Гел синеке генә кәҗәләнә, Гөлчирә.
Фаягөл. Компьютеры да үзенә охшаган.
Гөлчирә. Молчи, морду набью.
Рәхмәтулла. Матур гына сөйләшегез.

Компьютерны карый.

Нина. Тихо! Рузалия с кавалером будет говорить.

Рузалия кесә телефонын колагына куеп чыгып йөгерә.

Фаягөл. Их! Сотовыең булсын иде дә шылтыратсыннарые.
Рәхмәтулла. Булды бу, Гөлчирәкәй.
Гөлчирә. Маладис! Безнең ишан хәзрәтнең белмәгәне юк. (*Көйләп.*)

Ишан хәзрәт, бар, утыр,
Син бит безнең компьютыр.

Нурзидә Мөбәрәковна керә.

Нурзидә. Хәерле иртә!
Рәхмәтулла. Иртә түгел, Нурзидә Мөбәрәковна. Иртә ул эшкә килгәнче генә була. Котлы булсын яңа күлмәгегез.
Нурзидә. Мин күлмәк күрсәтергә кермәдем, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Иртәгә отчет әзер булырга тиеш. Шеф ашыктыра.
Фаягөл. Башта акчасын вакытында түләсен.
Гөлчирә. Сиңа нәрсәгә акча, ирең «Мерседес»та йөртсен.
Фаягөл. Авыз чайкама минем ирем белән.
Рәхмәтулла. Әй, сез! Кисәм телегезне. Бәхет акчада түгел. Бәхет баш бухгалтерыбыз Нурзидә Мөбәрәковнаның исәнлегендә. Утырып ял итегез, Нурзидә Мөбәрәковна, арыгансыздыр.
Нурзидә (*Рузалия урынына күрсәтеп*). Бу кыз кайда?
Нина. Решает любовные проблемы.
Гөлчирә. Туалетта бикләнеп сөйгән егете белән сөйләшә. Кесә телефоныннан.

Рузалия керә. Йөзе балкыган.

Рузалия. Исәнмесез, Нурзидә Мөбәрәковна!
Нурзидә. Бухгалтерия – утырып эшли торган эш. (*Чыгып китә.*)
Гөлчирә. Ах, нинди афоризм әйтте! Бухгалтерия – утырып эшли торган эш. Ә менә мин юри утырмыйм. (*Рәхмәтулла өстәле каршына килеп баса.*) Сөйлә мәзәгеңне, Рәхмәти.
Рәхмәтулла. Бер карт үгез су буенда ята икән. Аның янына яшь үгез чабып килгән. «Абый, көтүгә яңа таналар китерделәр, әйдә», – дигән. «Эч пошырып йөрмә», – дигән карт үгез. Бераздан яшь үгез тагын чабып килгән. «Әйдә инде, абый, таналары шундый сылу, сокланып туймассың», – дигән. «Нигә миңа анда барып йөрергә, су эчәргә үзләре монда киләчәкләр», – дигән карт үгез.
Гөлчирә. Ах, оятсыз! Ах, азгын! Әле син таналар көтеп утырасыңмыни? Килегез әле монда, таналар. Нишләтергә җыена икән ул безне. (*Янына хатыннар җыелгач.*) Йә, нишләтәсең безне? Менә сиңа сөлек шикелле таналар. Нишләтәбез бу карт үгезне, кызлар?
Нина. Хәзер без аны разденем и стриптиз устроим.
Рәхмәтулла. Пажалысты, пажалысты...
Фаягөл. Болай эшлибез. Без аның башына бармак белән сүзләр язабыз. Белмәсә, нишләтәбез?
Гөлчирә. Печәбез. (*Туктаусыз көлеп торган Рузалиягә.*) Башла, Рузалия.
Фаягөл. Ул тана түгел, бозау гына. Куегыз әле башыгызны, иптәш үгез. (*Рәхмәтулла башына бармагы белән яза.*) Ни яздым?
Рәхмәтулла. «Яратам»...

Фаягөл. Дөрес!

Нина. Дай-ка сюда. (*Рәхмәтулла башына яза.*) Нәрсә яздым?

Рәхмәтулла. «Я вас люблю».

Нина. Дөрес!

Гөлчирә. Хәзер минекен белеп карасын ул. (*Яза.*) Әйтеп бир!

Рәхмәтулла. «Яратам».

Гөлчирә. Алдаша. «Яратмыйм» дип яздым.

Рәхмәтулла. Син үзең алдашасың. Нигә яраткан килеш «яратмыйм» дип яздың?

Рузалия. Мин дә языйм инде.

Фаягөл. Сиңа әле иртә. Телефоныңнан сөйләш.

Рәхмәтулла. Әй кулларыгыз да кулларыгыз, кызлар. Шундый йомшаклар. Шундый рәхәт. Карагыз әле, чәчем үсмәдеме?

Нина (*Рәхмәтулланы кочаклап*). Шевелюра, Рахматулла Хурматуллович?!

Гөлчирә. Кочакламагыз, ул минеке генә.

Хатыннар шау-гөр килеп көлешә-көлешә Рәхмәтулланы бүлешәләр. Нурзидә Мөбәрәковна кереп карап тора. Хатыннар аны күреп
тиз генә урыннарына утыралар.

Нурзидә. Нишлисез соң сез? Ишегегез яныннан үтеп булмый.

Рәхмәтулла. Гафу итегез, Нурзидә Мөбәрәковна, мин гаепле.

Нурзидә. Мин гаеплене эзләп йөрмим. Болай ярамый бит инде. (*Чыгып китә.*)

Гөлчирә. Син нәрсә, маңка малай шикелле, мин гаепле, дип торасың ир кеше башыңнан.

Рәхмәтулла. Нәчәлствога каршы әйтергә ярамый, Гөлчирә. Артыңда ныклы терәк булмаса, нәчәлствога каршы сүз әйтмәскә кирәк.

Гөлчирә. Ә мин әйтәм. Мине терәп торучы кеше бар. Нигә кем дип сорамыйсыз? Менә Рәхмәтулла абый. Куып чыгарсалар, бер Гөлчирәсен генә ашатыр әле.

Нина. Аның үз хатыны бардыр.

Гөлчирә. Булмагае. Гөлчирә исемле түгелдер әле.

Нина. Кстати, хатыныгызны как зовут, Рахматулла Хурматуллович? Вы не разу не говорили о ней.

Гөлчирә. Төпченмә. Әйтми икән – ярамый. Безгә аның хатыны түгел, үзе кирәк. Булды – шаярдык. Әйдә эшләргә.

Тыныч кына бераз эшләп алалар.

Рәхмәтулла. Ишетмим. Кем чираты? Фаягөл!..

Фаягөл авыз эченнән генә көй көйли. Шул көй астында ут сүнә. Ут янганда, бүлмә уртасына өстәл куелган. Анда савыт-саба, ризыклар
өстәл тирәсендә Рәхмәтулла кайнаша.

Рәхмәтулла. Кызлар, чәй әзер, утырып садисыгыз!

Гөлчирә. Утырып садисыгыз,

Кеше ярларын сөяргә
Житәрме сависыгыз?

Рәхмәти, яса чәйләреңне!

Хәдичә. Үзем.

Гөлчирә. Утыр урыныңа. Матриархат заманы, ирләр изелсен. Рәхмәти, ач вәринҗә капкачын.

Фаягөл. Рәхмәтулла абзый, шикәрең кайда?

Нина. Рахматулла Хурматуллович, минем кашыкны бир.

Рәхмәтулла официантларга охшатып йөренә.

Гөлчирә. Безнең күңелебезне күреп җырлап тор.

Рәхмәтулла. Баш өсте. Кайсы көйне телисез, галиҗанәпбикә Гөлчирә?

Гөлчирә. «Алма турыйм»ны.

Рәхмәтулла.

Алма турыйм, алма турыйм,
Алманың түгәрәген.
Инде ниләр уйлыйм икән
Мәхәббәт күбәләгем.

Алма турыйм, алма турыйм,
Алмаларның кызылын.

Сине сөйгәч кенә белдем
Бу дөньяның кызыгын.

Алма турыйм, алма турыйм,
Алмаларның яшелен.
Мине сөйми дип уйлама,
Сөюләрем яшерен.

Тагынниләр телисез, бикәкәйләрем?

Гөлчирә. Миңа осетрина!

Нина. Миңа ананас!

Фаягөл. Миңа... Миңа... Кыздырылган фил борыны.

Рәхмәтулла. Сиңа нәрсә, Хәдичә?

Хәдичә. Миңа берни дә кирәкми.

Фаягөл. Сүз әрәм итеп сөйләшмә аның белән, Рәхмәтулла абзый.

Рузалия. Миңа шоколад.

Рәхмәтулла. Калганнарын табарга тырышырбыз. Ә шоколад – хәзер үк. (*Түш кесәсеннән шоколад алып Рузалиягә суза.*)

Гөлчирә. Ах син, ә! Кара моны нишли!

Рәхмәтулла. Аның шоколад ашый торган чагы.

Рузалия. Рәхмәт, рәхмәт! (*Рәхмәтулланың битеннән үбеп ала.*)

Гөлчирә. Булды, Рәхмәти. Бик әйбәт хезмәт күрсәткәнең өчен синең дәрәҗәңне күтәрәбез – солтан ясыйбыз.

Бер урындыкка папкалар өеп тәхет ясыйлар. Аңа Рәхмәтулланы утыртып куялар.

Гөлчирә. Хәдичә, син солтанга чәй ясап тор. Без шәрык биюен биибез. Без аның җарияләре.

Рәхмәтулла. Шәрык биюендә кендек күрсәтеп бииләр.

Гөлчирә. Кендек күрәсең килсә, Бауман урамына чык.

Рузалия. Минем бабай әйтә әбигә: «Пилмән яса, пилмәнең кызлар кендеге кебек матур булсын», – ди.

Фаягөл. Картлар бөтенесе азгын алар. Башладыкмы, Гөлчирә?

Шәрык биюе бииләр.
Нурзидә Мөбәрәковна керә.

Рәхмәтулла. Безнең әбәт вакыты, Нурзидә Мөбәрәковна.

Нурзидә. Обед булса, бу бит ресторан түгел.

Гөлчирә. Ашханәгә акча җитмәгәч, ресторан ясыйсың инде.

Нурзидә. Үз өстегезгә күпне аласыз, Гөлчирә Нәҗиповна.

Гөлчирә. Алам икән, димәк, күтәрерлек көчем бар.

Нурзидә. Ә мин сез күтәргән йөкне һәм үзегезне берьюлы күтәрә алмасам.

Гөлчирә. Андыйларга татарлар, серкәсе су күтәрми, диләр.

Рәхмәтулла. Гөлчирә, усалланма.

Нурзидә. Рәхмәтулла Хөрмәтуллович, минем янга кереп чыгыгыз әле.

Нурзидә чыгып китә. Аңа Рәхмәтулла иярә.

Рузалия. Эләгә Рәхмәтулла абыйга.

Нина. Нәрсә, ул виноват что ли? Безнең обеденный перерыв.

Гөлчирә. Кеше ашаганда кереп иснәнеп йөри.

Нина. Син тоже, Гуля...

Гөлчирә. Нәрсә, мин тоже?

Нина. Нурзидә Мубараковна белән... Пререкаешься.

Гөлчирә. И, ачуым китереп торма әле марҗа башың белән.

Нина. Че ты? Марзя, марзя... Үзең кем? Әйтәсең, бисмилла, бисмилла, а сама вешаешься на шею мужчин.

Гөлчирә. Кайчан мин ирләрнең муенына асылынганым бар, ә?

Нина. Рахматулла Хурматуллович не мужчина что ли?

Гөлчирә. Ай-яй-яй... Ревнуешь, да? Может я его люблю.

Фаягөл. Арттырып җибәрәсең инде анысы. Яратканыңны бөтен кешегә күрсәтергә димәгән.

Гөлчирә. Син тик тор. Минем бит өемдә синеке кебек мужигым юк.

Фаягөл. Ал, кирәк булса, бирәм.
Гөлчирә. Төкердем мин синең өч тиенлек үләтеңә.
Хәдичә. Җитте инде, кызлар.
Фаягөл. Ә син оянда тик кенә утыр.
Рузалия. Ә мин сезне Рәхмәтулла абыйга әйтәм.
Фаягөл. Нәрсә дип әйтәсең?
Рузалия. Алар сез булганда гына әйбәт, сез чыгып киткәч, ызгышалар, дим.
Гөлчирә. Кем ызгыша, әйт әле, кем ызгыша?
Рузалия. Әнә бит ямьсез сүзләр әйтешәсез.
Нина. А ты не вмешивайся. Говори по своему телефону.
Гөлчирә. Әгәр дә Рәхмәтулла абыйга берәр начар сүз әйтсә, бәреп үтерәм мин ул хатынны.

Башын түбән иеп Рәхмәтулла керә. Урынына сүзсез генә барып утыра. Шомлы тынлык. Хәтта Хәдичә дә, торып, Рәхмәтуллага карап
тора.

Гөлчирә (*сакланып кына Рәхмәтулла янына килә*). Рәхмәтулла абый.

Рәхмәтулла кулын селтәп кенә җавап бирә. Бүтән хатыннар, Рузалия Рәхмәтулла янына җыелалар. Хәдичә генә тораташтай үз урынында
басып тора.

Рәхмәтулла. Бетте...
Фаягөл. Нәрсә бетте, Рәхмәтулла абый?
Рәхмәтулла. Мин китәм.
Нина. Куда, Рахматулла Хурматуллович?
Рәхмәтулла. На пенсию отправляют, Ниночка.
Нина. Как? Сезгә әле алтмыш юк.
Рәхмәтулла. Досрочно, Ниночка.
Фаягөл. Чынмы, Рәхмәтулла абзый?
Рәхмәтулла. Чын, Фаягөл, чын.
Гөлчирә. Безобразие! Шеф янына керәбез. Шефтан узарга аның ни хакы бар?!
Рәхмәтулла. Соң инде, Гөлчирәкәй. Шеф янына алып керде Нурзидә Мөбәрәковна. Рәнҗемәгез, кызлар, төрле чакларым булгандыр. Миннән башка тату гына эшләгез, тату гына яшәгез. Әйтәсе сүзләремне бүген әйтеп калыйм. Рузалия, кызым, синнән башлыйм. Бәхетле бул, ярыймы?
Рузалия. Ярый, Рәхмәтулла абый.
Рәхмәтулла. Фаягөл, бәхетле бул, ярыймы. (*Фаягөлне кочаклый.*)
Фаягөл (*еларга җитешеп*). Рәхмәт, Рәхмәтулла абый.
Рәхмәтулла. Будь счастлива, Ниночка. (*Нинаны кочаклый.*)
Нина. Спасибо! Рахмат, Рахматулла Хурматуллович.
Рәхмәтулла. Гөлчирәкәй. (*Гөлчирәне, кочаклап, бит уртасыннан үбә.*) Син үзең дә кочаклап үп инде, Гөлчирәкәй.
Гөлчирә (*кычкырып*). Хәшәрәт! Алдаша! Алдаша, кызлар. Күзенә карагыз, күзенә карагыз, елмая. (*Рәхмәтуллага очып куна, тукмый, кочаклый.*) Үтерәм!

Рәхмәтулла көлә, шау-шу.

Рузалия. Арти-и-ист...
Рәхмәтулла. Утырыгыз урыннарыгызга. Бүгеннән башлап шаярулар бетте. Эшкә вакытында киләсез, эшлисез, шыпырт кына чәегезне эчәсез, шыпырт кына кайтып китәсез. Нурзидә Мөбәрәковна мине бу бүлмәнең старостасы итеп билгеләде. Мин шаярмыйм, кызлар. Утырышыгыз. (*Барысы да үз урыннарына утыргач та.*) Ишетмим? Кем чираты? Минем чират.

«Әпипә» көенә көйли. Ут сүнә.
Ут янганда, Рәхмәтулла компьютерда эшләп утыра. Әлеге дә баягы
үзенең җырын көйли.

Рәхмәтулла. Заманалар авыр, еллар ябык –
Дус-иш кирәк гомер итәргә...

Хәдичә керә.
Хәдичә. Исәнмесез, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Менә җылы өчпочмаклар.
Рәхмәтулла. Ничек җылы килеш алып килеп җиткерәсең син аларны?
Хәдичә. Мин аларны кайнар килеш төрәм дә суынып өлгермиләр.

Рәхмәтулла. Бик күпкә китте бит инде бу, Хәдичә.

Хәдичә. Юк, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович, миңа рәхәт кенә. Сез шундый тәмле итеп ашыйсыз, рәхмәт.

Рәхмәтулла. Синең белән бер утырып сөйләшәсе бар әле, Хәдичә.

Хәдичә. Нәрсә турында, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович?

Рәхмәтулла. Ташла әле шул Хөрмәтулловичны. Абый, диген.

Хәдичә. Ияләшкән инде. Нәрсә турында сөйләшергә җыенасыз Рәхмәтулла... абый...

Рәхмәтулла. Бар сөйләшәсе сүзләр.

Хәдичә. Әйтерсез, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Кичә кульяулыгыгыз төшеп калган булган. Югач чистарды. (*Таслап бөкләнгән кульяулыкны Рәхмәтулла өстәленә куя.*) Берәр әйберегез каралса, әйтерсез.

Рәхмәтулла. Син нәрсә инде, Хәдичә... Әллә ислемай да сөрткән инде.

Хәдичә. Ирләрнеке ул. Кибеттә әйттеләр. (*Урынына барып утыра.*) Рәхмәтулла абый, әйткәнгә ачуланмагыз. Нигә сез үзегезне мыскыл иттерәсез? Сез олы кеше. Алар сезне бала-чагага саный.

Рәхмәтулла. Алар көлмиләр, шаяралар гына, Хәдичә.

Хәдичә. Шаяралар дип инде...

Рәхмәтулла. Менә бүген чәчеңне дөрес ачкансың. Шулай йөрт. Бик килешә.

Рузалия керә дә тәрәзәгә чаба. Карап тора. Урынына килеп утыра.

Рәхмәтулла. Киттеме?

Рузалия. Уһу...

Рәхмәтулла. Әйбәт егетме?

Рузалия. Уһу...

Рәхмәтулла. Әйбәт булгач бик әйбәт. Шулай да син исәнләшергә онытма инде.

Рузалия. Әллә исәнләшмәдемме?

Рәхмәтулла. Юк шул.

Рузалия. Ай, гафу итегез, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Исәнмесез, Хәдичә апа.

Нина керә. Кәефсез генә исәнләшеп урынына узып утыра.

Рәхмәтулла (*аның янына килеп*). Успокойся, Нина Васильевна.

Нина. Я спокойна, Рахматулла Хурматуллович.

Рәхмәтулла. Успокойся, все будет хорошо.

Нина. Спасибо, Рахматулла абы.

Фаягөл керә.

Фаягөл. Исәнмесез! (*Рәхмәтулла янында туктап.*) Рәхмәтулла абый, бүген мине көйләтмәгез, яме. Кәефем юк.

Рәхмәтулла. Кәеф булмаганда көйләргә кирәк тә инде ул, Фаягөл. Кәефле чакта исерек тә җырлый.

Фаягөл. Чынлап әйтәм, Рәхмәтулла абый. Чынлап та кәефем юк.

Рәхмәтулла. Ярый, синең өчен үзем көйләрмен.

Фаягөл. Соң, куйыйк берәр музыкальный центр. Торсын көйләп.

Рәхмәтулла. Әнә шул центрлар күбәйгәнгә кешеләрнең кәефе юк инде, Фаягөл. Ярый, бар, утыр. Тынычлан. Барысы да җайланачак.

Гөлчирә керә.

Гөлчирә. Бетте. Көннең рәте-чираты булмаячак. Өйдән чыккач, кара мәче очрады, коридорда Мөбәрәковна каршыга килеп чыкты.

Рәхмәтулла. Аның каравы монда мин көтеп торам. Нихәл!

Гөлчирә. Әй, сине дә күрәсе килеп тормый әле. Нихәл? Бүген магнитлы көн мәллә? Нәрсә берегез дә сөйләшмисез?

Рузалия. Исәнмесез, Гөлчирә апа.

Гөлчирә. Исәнме, матурым. Әле дә син бар, бәгырькәем.

Рузалия. Сез зря Рәхмәтулла абыйга алай әйттегез.

Гөлчирә. Нәрсә дип әйттем?

Рузалия. Күрәсем килми, дидегез.

Гөлчирә. Һай, берәүнең адвокаты табылган. (*Рәхмәтулла янына килеп.*) Кил! (*Бер кулы белән кочаклап ала.*) Булдымы?

Рузалия. Кайчан сез Рәхмәтулла абыйны кочаклыйсыз, миңа бик ошый.

Гөлчирә. Ярый, Аллага тапшырдык. *(Урынына утыра.)*

Тын гына эшлиләр. Фаягөл көй көйли башлый. Аңа Рәхмәтулла кушыла.

Рәхмәтулла. Их, кызлар! Ун яшьтә мин райком секретаре кызына гашыйк булган идем. Аңа тугыз яшь иде. Аларның чия бакчасы бар иде. Шунда чия агачлары арасында үбешә идек. Бервакыт безнең үбешкәнне аның әнисе күргән. Шуның өчен мәхәббәтемнең этисе мине кычыткан белән сыйлады. Мәңгелек сабак булды. Ун яшьтә чия агачлары арасында райком секретареның тугыз яшьлек кызын үбәргә ярамый икән.

Гөлчирә. Син ул чакта ук азгын булган инде.

Рәхмәтулла. Хатын-кызлар ни өчендер азгын ирләргә кызыгалар.

Нина. Неправда. Кызыкмыйлар, алданалар. Бабники умеют находить ключ к женскому сердцу.

Гөлчирә. Карале, Рәхмәти. Син сөйләмәдең бит әле ни булганын баш бухгалтер кабинетында. Син әйдә шыттырма, сөйлә.

Рәхмәтулла. Без мәхәббәт аңлаштык. Мин аңа багышланган шигыремне укыдым.

Рузалия. Шигырь?! Әллә сез шагыйрь дәме, Рәхмәтулла абый?

Гөлчирә. Аның булдырмаган эше юк. Укы безгә дә шигыреңне, Рәхмәти.

Рәхмәтулла.

Гүзәлләрдән гүзәл баш бухгалтер!
Ничәнче размер икән сезнең бюстгальтер?

Дәррәү көлешәләр.

Гөлчирә. Нәрсә ди Мөбәрәковна?

Рәхмәтулла. Гөлчирәнекеннән зуррак, ди.

Гөлчирә. Үтерәм мин сине, оятсыз.

Нина. Бюстгальтерның татарчасы ничек?

Гөлчирә. Юк аның татарчасы. Элек татар хатыннары аны кимәгән.

Фаягөл. Ә күкрәкчә нәрсә?

Гөлчирә. Ул бюстгальтер түгел.

Рәхмәтулла. Бар аның татарчасы. Имидж дип атала ул. Шуның зурлыгына карап хатын-кызның кемлеге бәяләнә.

Гөлчирә (*Рәхмәтулла янына атылып килеп*). Нишләтим мин моны, әйтегез. Чәчен йолкыр идем, чәче дә юк бит, әй. Карагыз әле, Рәхмәтулла абыйның башы глобуска охшаган икән. Менә Африка, менә Татарстан. (*Рәхмәтулланың борынын кысып.*) Менә Кавказ тавы.

Нина. Ульяновский область кайда?

Гөлчирә. Әйләндер, теге яктадыр.

Рәхмәтулланың башын боргалыйлар.

Рәхмәтулла. Үтерәсез. Әйтәм Нурзидә Мөбәрәковнага.

Гөлчирә. Әле син әләкче дәмени? Фаягөл, биклә ишекне, күрмәгәнен күрсәтәбез.

Рәхмәтулла. Рузалия кызым! Үтерәләр болар, коткар.

Рузалия. Тимәгез Рәхмәтулла абыйга.

Рәхмәтулла. Тисеннәр, тик үтермәсеннәр генә.

Гөлчирә. Нина, бир косынкаңны, кулларын бәйлибез.

Косынка белән Рәхмәтулланың кулларын артка каерып бәйлиләр.
Рәхмәтулла, әлбәттә, карышмый.

Фаягөл. Булды, нишләтәбез?

Гөлчирә. Печәбез!

Нина. Кастрировать, что ли? Что ты, Гуля! Такого старого бугая. Бирегез аны миңа.

Гөлчирә. Берәүгә дә булмасын. (*Рәхмәтуллага.*) Бас әле монда. Тәк. Башта ул безнең сорауларга җавап биреп карасын. Сорауларыгызны әзерләгез. Җавап бирә алмаса, җәзасын үзегез билгеләрсез. Тәк, иптәш Рәхмәтулла Хөрмәтуллович, беренче сорау. Син, җанбиздергеч адәми зат, ни өчен дип кылчыклы арпа башагы кебек кашларың астындагы ике пыяла кисәген күз дип атыйсың?

Рәхмәтулла. Ә син, сөйкемлеләрдән сөйкемле, аккоштан да сылурак бөек зат, ни өчен энҗе сыман тешләреңне каплап торучы ике карбыз телемен иреннәр дип атыйсың?

Фаягөл. Син, дию пәриеннән дә кошпәтсез адәми зат, ни өчен тау куышыдай авызың эчендә боргаланучы җыланны тел дип атыйсың?

Рәхмәтулла. Ә менә син, алма кисәгем, урман күле сыман серле күзләреңдә урын алган камышларны ни өчен керфекләр дип атыйсың?

Гөлчирә. Нина, синең чират.

Нина. Я потом...

Гөлчирә. Рузалия, кил, бир соравыңны.

Рузалия. Мин белмим, Гөлчирә апа. Минем өчен син әйт.

Гөлчирә. Фаягөл, әйт Рузалия өчен.

Фаягөл. Әйт әле, килбәтсезем, син нигә мунча морҗасыдай муеның өстендәге кабакны баш дип йөртәсең?

Рәхмәтулла. Ә син, фәрештәләр фәрештәсе, нигә таң алсулыгы кунган битләрең уртасындагы фәрештә үпкән сөйдергеч урыннарны чокыр дип йөртәсең? Нигә син, алтын кисәгем, күл өстенә иелгән бөдрә талны иркәләүче йөгерек дулкыннарны чәч дип йөртәсең?

Гөлчирә. Кара син мутны, кызларга икешәрне әйтә, Хәдичә синең соравың бармы?

Хәдичә. Юк.

Гөлчирә. Нина, давай.

Нина. Не могу я плохое сказать про Рахматулла Хурматулловича.

Гөлчирә. Можешь. Смотри, какой он безобразный. Давай...

Нина. Ну, если давай... Рахматулла Хурматуллович, почему... Почему вы такой... Но не могу я... Ну почему вы такой?

Рәхмәтулла. Потому что ты такая милая.

Нина. Ну разве можно такого симпатичного... Лучше я поцелую его. (*Рәхмәтулланы ике битеннән дә үбеп ала.*)

Гөлчирә. Ай-яй-яй. Монысы рөхсәт ителми.

Үзе Нина шикелле үбеп ала. Аңа Фаягөл кушыла.

Фаягөл. Мин дә! (*Рәхмәтулланың битеннән үбә.*)

Шул вакыт ишек шакыйлар.

Бетте баш.

Гөлчирә (*шыпырт кына*). Ачмагыз!

Нурзидә тавышы: Ачыгыз!

Хатыннар тиз генә урыннарына утыралар. Нина Рәхмәтулланың куларын чишәргә өлгерә. Рәхмәтулла барып ишекне ача.

Нурзидә. Нигә бикләнеп утырасыз?

Нина. Чтоб не мешали работать, Нурзида Мубараковна.

Нурзидә. Ой ли. Такой шум стоял.

Гөлчирә. Рузалия бюстгальтер алган да, шуны үлчәп карадык.

Нурзидә. Рәхмәтулла Хөрмәтуллович, сез дәме? (*Рәхмәтулланың иннектән кызарып чуарланган йөзен күреп.*) Ни булды сезгә?

Гөлчирә. Оялудан шулай кызарган ул. Бюстгальтер күргәне юк икән.

Нурзидә. Гөлчирә Нәҗиповна, һәрнәрсәнең чиге була.

Гөлчирә. Ә мин чик белмим.

Нурзидә. Кызганыч.

Гөлчирә. Нурзидә Мөбәрәковна!..

Рәхмәтулла. Гөлчирә...

Гөлчирә. Гафу итегез.

Нурзидә. Рәхмәтулла Хөрмәтуллович! Иртәгә бүтән бүлмәгә күчәсез. (*Чыгып китә.*)

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Аерым бүлмәдә Рәхмәтулла эшләп утыра. Шакымый-нитми генә Гөлчирә килеп керә. Кергәч, бүлмәне карап-тикшереп чыга.

Гөлчирә. Ай-яй, оялаган берәүләр тыныч урынга. (*Җырлап.*)

Уңга каерылгач та,
Әй, дускаем, рәхәт яшә,
Бездән аерылгач та.

Бездән аерылгач рәхәтме?

Рәхмәтулла. Мин бит үзем аерылмадым, аердылар.

Гөлчирә. Хатын-кызга буйсынып яшәгән иргә ни әйтим? Әйтергә иде! Юк, Нурзидә Мөбәрәковна, хатыннарымнан аерылып башка чыкмыйм, дияргә иде. Җебегән. Беләм инде, миннән качтың. Барыбер үзеңне генә калдырмыйм. Минутына ун керәчәкмен. Аңладыңмы?

Рәхмәтулла. Аңладым.

Гөлчирә. Аңласаң шул. (*Кулын сузып.*) Нихәл? (*Рәхмәтулла күрешергә кулын сузгач.*) Ах, оятсыз! Бер тәүлек буе күрешмәдек, ә ул күрешергә кулын суза. Тор урыныңнан, җир бит. (*Урындыгыннан торып баскан Рәхмәтулланы кочаклап алып.)* Утыр. *(Рәхмәтулла каршысына утырып.*) Нихәл соң?

Рәхмәтулла. Үзең нихәл?

Гөлчирә. Начар.

Рәхмәтулла. Ни булды?

Гөлчирә. Син юк. Килеп кердем эшкә – син юк.

Рәхмәтулла. Менә ич мин.

Гөлчирә. Мине мондагысы канәгатьләндерми.

Рәхмәтулла. Нишләп?

Гөлчирә. Мондагысын кочаклап булмый.

Рәхмәтулла. Кочакладың ич.

Гөлчирә. Монысы аның формально гына кочаклау. Кызлар карап торганда, шаярган булып чынлап кочаклый идем. Монда оялам.

Рәхмәтулла. Кемнән?

Гөлчирә. Үземнән.

Рәхмәтулла. Кызык икән.

Гөлчирә. Кызык түгел. Чөнки мин сине чынлап яратам.

Рәхмәтулла. Ни өчен?

Гөлчирә. Ахмак сорау биреп үзеңнән биздермә. Син дә бит мине яратасың. Мин ни өчен дип сорамыйм.

Рәхмәтулла. Минем ятратканымны каян беләсең?

Гөлчирә. Белмим, сизәм. Мин бит тиле-миле. Андыйларны ирләр ярата. Фәритем дә, сине тиле булганың өчен яратам, дия иде. Күзгә карап торма, оялтасың. Әйт, яратырлык хатынмы мин? Ник дәшмисең?

Рәхмәтулла. Яратмаслык түгел инде.

Гөлчирә. Җәбриләр кебек алдын артка куеп сөйләшмә. Өзеп әйт, яратырлыкмы?

Рәхмәтулла. Яратырлык. Мин яратырлыкны гына яратам.

Гөлчирә. Әйтмә «яратам» дип. Кызыгы бетә. Ятратканыңны мин генә сизим! Минем чибәрлегем әле бетмәгән. Чибәр хатынга «яратам» дип еш әйтәләр. Чибәр хатынны ахмак дип уйлыйлар. «Яратам» диюгә яннарына ятар дип өметләнәләр. Син өметләнмә, яныма яткызмаячакмын. Өзелеп яратсам да, яткызмаячакмын. Чөнки яратканымның берсе ятты инде. Ятты да мәңгелеккә китеп барды. Синең китүеңне теләмим. Сине яшәтәсем килә. Син, бәлки, минем соңгы мәхәббәтемдер. Карап торма алай. Нигә алай караганыңны беләм мин. Их, шуны бер кочаклап үбәргә дип карап торасың. Кочаклаттырам, әмма үптермим. Үптерсәм, дәртем кузгалыр дип куркам. Үземне тыеп кала алмамдыр шикелле. Елмайма. Нигә елмайганыңны беләм. Кая инде миндәй картка дәрт кузгатырлык куәт дип уйлыйсың. Илле тугыз яшьтә бит инде дисең, пенсия яшенә җитәм дип уйлыйсың. Мин беләм, синдәге дәртнең әле чик-чамасы юк. Син дәртеңне минем өчен саклап тоткансың. Яныма яткыза алмаганга кызганам да мин сине. Нишлим, яраткан ирем бар иде шул. Аерылып, ташлап китсә дә авыр булмас иде, бакый дөньяга китеп барды. Яшәүнең кызыгы беткән иде, син очрадың. Кил, чынлап бер кочаклыйм әле үзеңне кеше юк чакта. Утырып кына тор, үзем кочаклыйм. (*Рәхмәтулланы кысып кочаклый да ишеккә таба атлый.*) Кара аны бүтәннәргә кочаклаттырма, көнләшә торган әшәке гадәтем бар. (*Чыгып китә.*)

Рәхмәтулла эшкә тотынгач кына Фаягөл ишекне ача.

Фаягөл. Керергә ярыйдыр бит, Рәхмәтулла абзый.

Рәхмәтулла (*урыныннан торып, Фаягөлне каршылый*). Кер әйдә, кер. Әйдә, уз, утыр.

Фаягөл. Узып тормыйм. Эшкә килдем, нәрсәдер җитми. Нәрсә җитми дисәм, сез юк икән. Шушында күчерделәрмени инде сезне? Бергә утырсак ни була иде инде? Сезнең белән бергә утырганда рәхәт иде. Күрше өстәлдә сез барын тою рәхәт иде. Гөлчирә кереп өлгергәндер инде?

Рәхмәтулла. Кереп болганып чыгып китте.

Фаягөл. Сезгә гашыйк ул. Шуны яшерер өчен кыланган була. Мин дә яратам сезне, Рәхмәтулла абый. Беләсезме, ни өчен яратам сезне?

Рәхмәтулла. Белмим инде, Фаягөл. Шундый чибәр хатын яратырлык нием бардыр? Бигрәкләр дә чибәр бит син. Тулып пешкән алма кебек.

Фаягөл. Шундый сүзләрегез өчен яратам бугай мин сезне, Рәхмәтулла абый. Беләм инде, минем күңелемне күрер өчен генә әйтәсез чибәр дип. Сез иң олы җанлы, җылы күңелле кеше, Рәхмәтулла абый. Шуңа күрә дә сезнең янда миңа җылы.

Рәхмәтулла. Юк, син чыннан да чибәр, Фаягөл. Ходай Тәгалә дөньяга ямьсез хатын-кызны яратмый. Хатын-кызны Ходай карап сокланыр өчен ярата. Син, беләсең килсә, арагызда иң чибәре. Кемдер синең чибәрлегеңне күрә белми икән, ул – ахмак, ул – утын агачы.

Фаягөл. Беләм инде, Рәхмәтулла абзый, юатыр өчен генә әйтәсең. Шулай да рәхмәт сезгә. Нишләтәсез, хатын-кызның холкындадыр инде, алдаганны өнәп бетермәсәк тә, алданасы килә. Кайсыдыр шагыйрь шулай әйткән бугай.

Рәхмәтулла. Алдамыйм, Фаягөл бәгырькәм. Кил әле, бас әле каршыма. Хәзер мин сиңа чибәрлегеңне дәлилләп исбатлыйм. Әйтик, менә синең күзләрең...

Фаягөл. Кирәкми, Рәхмәтулла абый. Миңа хәзер инде барыбер – чибәр булдым ни, булмадым ни. Кияүгә чыгасы унсигез яшьлек кыз түгел. Кырык тула.

Рәхмәтулла. Алай димә, Фаягөл. Кырык яшь ул – хатын-кызның чәчәк аткан вакыты.

Фаягөл. Җимеше булмагач, чәчәк атудан ни мәгънә, Рәхмәтулла абзый. Бер сүз әйтсәм, ачуланмыйсызмы?

Рәхмәтулла. Нишләп ачуланыйм ди, Фаягөл.

Фаягөл. Мин ир белән егерме ел яшим. Балабыз юк, беләсеңме шуны?

Рәхмәтулла (*паузадан соң*). Беләм.

Фаягөл (*аптырап*). Каян беләсез? Әйткәнем юк. Гөлчирә әйттеме?

Рәхмәтулла. Юк.

Фаягөл. Шулай да... каян белдегез? Мин ул турыда берәүгә дә әйткәнем юк. Киресенчә, ике балам бар, дип сөйләп йөрим.

Рәхмәтулла. Хатын-кыз алдашса да алдаша белми. Хатын-кызның дөрес сүзе телендә түгел, йөзендә, Фаягөл.

Фаягөл. Сез сихерчедер, Рәхмәтулла абзый. Ярый, чишелә башлаганмын икән, чишелеп бетим инде. Чишеләсем килә, Рәхмәтулла абзый. Шундый да чишеләсем килә. Күңелемдә җыелган бөтен серләремне кемгәдер сөйлисем килә. Мине тыңлый алырлык кеше юк дөньяда. Сез очрадыгыз. Ничә ел инде сезгә сөйлим-сөйлим дим, һич кенә дә җае чыкмый.

Рәхмәтулла. Мин сине сөйләмәсәң дә аңлыйм, Фаягөл сеңелем.

Фаягөл. Аңлаганыгызны беләм. Ләкин миңа бушанырга кирәк. Рөхсәт итегез. Яратып чыктым мин кияүгә. Ул нигә өйләнгәндер, белмим. «Яратам» дигән сүзен хәтерләмим. Ни өчен яратканмындыр? Эчми, тартмый, сүгенә белми, күп сөйләшми, шул ягы ошагандыр инде. Мин гомерем буе исерекләрдән җирәнеп яшәдем. Бу шундый тәртипле. Ничек яратмыйсың. Тик менә үзем яратсам да, яраттыра алмадым. Яратып түгел, өйләнергә кирәк булганга гына өйләнгән булып чыкты. Балабыз булмады, дидем. Булмады шул. Булган булса, туң җаны, бәлки, эрегән булыр иде. Бала булмаганга мин өзгәләндем, аның исе дә китмәде шикелле. Унбиш ел гомер шулай үтте дә китте. Бервакытны әйтә бу: «Синең бала тапмавың әйбәт, – ди, – югыйсә үзең кебек ямьсез бала табып бәхетсез итәр идең», – ди. Тыныч кына әйтә, елмаеп әйтә. Ышанасызмы, Рәхмәтулла абзый? Йөрәгемә боз булып төште шул сүзләр. Бөтен яратуларым нәфрәткә әйләнде. Янына яту түгел, яныннан үтеп китәсем дә килми. Шул килеш ничә ел яшибез бит, Рәхмәтулла абый, җан кисәгем. Кайвакытларда башымны элмәккә тыгарлык булам. Яшәү түгел бит инде бу, Рәхмәтулла абый. (*Рәхмәтулланың күкрәгенә башын куеп елый.*)

Рәхмәтулла. Тулган күңелең бушансын. Нишлим соң инде, җыла... Булдымы инде? Инде хәзер күз яшьләреңне сөртик... Менә шулай. Кара син бу күзләргә, алар бит көләр өчен генә яратылган.

Фаягөл. Бирегез берәр киңәш миңа, Рәхмәтулла абзый. Нишлим?

Рәхмәтулла. Нинди киңәш бирим инде сиңа, бәгырькәем? Киңәш бирү җиңел түгел бит.

Фаягөл. Ташламагыз мине, Рәхмәтулла абый. Гафу итегез мине.

Рәхмәтулла. Ни өчен?

Фаягөл. Менә бит... Әллә ниләр сөйләдем. Җылаганымны кешегә әйтмәгез инде, Рәхмәтулла абый. Сез шундый итеп карап торасыз миңа, Рәхмәтулла абый.

Рәхмәтулла. Ничек итеп?

Фаягөл. Сокланып.

Рәхмәтулла. Сокланырлык бит.

Фаягөл. Рәхмәт сезгә. Мин кызганып карауларыннан куркам, Рәхмәтулла абый.

Рәхмәтулла. Кызганып карарга ярамый кешегә. Ул аны түбәнсетә.

Фаягөл. Мин бит матур җырлый идем яшь чакта. Үз туемда җырлаган җырымны җырлыйммы? Тик ачуланмагыз, ярыймы, Рәхмәтулла абый. (*Җырлый.*)

Туйда җырлар өчен нигә шул җырны сайладым икән, Рәхмәтулла абый? Ярый, чыгыйм инде, Рәхмәтулла абый. Гаеп итмәгез, зинһар. Ташламагыз мине. (*Чыгып китә.*)

Гөлчирә керә.

Гөлчирә. Фаягөл нигә кергән?

Рәхмәтулла. Сагындым, ди.

Гөлчирә. Аның сагынырга хакы юк. Чөнки аның ире бар.

Рәхмәтулла. Алай димә инде, Гөлчирә.

Гөлчирә. Нәрсә, аны яклыйсыңмыни?

Рәхмәтулла. Якламыйм да.

Гөлчирә. Якламагач, нигә алай сөйләнәсең?

Рәхмәтулла. Ничә ел бергә утырдык, бергә эшләдек. Бергә эшлибез.

Гөлчирә. Синең бик әйбәт һәм дә бик начар гадәтең бар – син бөтен хатын-кызны да яратасың.

Рәхмәтулла. Нишлим соң инде, барыгыз да яратырлык бит.

Гөлчирә. Ә мин?

Рәхмәтулла. Син син бит инде ул.

Гөлчирә. Сөйләп тора Фаягөл: «Рәхмәтулла абзыйның хатынына рәхәттер Рәхмәтулла абзый белән яшәве», – ди. Беренчедән, нигә ул сиңа «абзый» ди. Нинди абзый син? «Абый» дисә ярамыймы? Икенчедән, ни эше бар аның синең хатыныңда. Миңа булды ни синең хатының, булмады ни. Миңа син булгач җиткән. Мин аның өлешенә керергә җыенмыйм, мин бары тик яратам гына. Мин кочаклаганнан гына Рәхмәтулла хатынының иренә мөгез чыкмас. Рәхмәтулланың хатынына Рәхмәтулла – кочаклап ятар өчен, миңа – яратыр өчен генә. Нигә шулай карап торасың?

Рәхмәтулла. Әллә нинди син. Көнгә әллә ничә төрлегә керәсең.

Гөлчирә. Кермим, үзем шундый мин. Мине Ходай шундый итеп яраткан. Шуңа күрә син мине яратасың. Фәрит тә мине шуның өчен ярата иде. Ләкин мин мәхәббәт мәсьәләсендә генә үзгәрмим. Яратам икән, мәңгелеккә яратам. Фәритне мәңгелеккә яраттым. Аны син алыштырдың, сине дә мәңге яратачакмын. Ләкин Фәрит хисабына түгел. Синең минем җанымда үз урының бар. Мин күп сөйлим, әйеме?

Рәхмәтулла. Әйе.

Гөлчирә (*рәхәтләнеп көлеп*). Менә шуның өчен яратам да мин сине. Син минем җанымны аңлыйсың. Мин күзәтеп торам бит, син хатын-кызның үзләре дә белмәгән серләрен беләсең. Син кеше кыяфәтендәге Хозыр-Ильяс бит, бәгырькәем. Шуңа күрә бөтен бәхетсез хатыннар сиңа елышалар. Тыңлавы рәхәтме мине?

Рәхмәтулла. Рәхәт. Сиңа карап торуы да җан рәхәте. Яраттыра торган сихерең, сөйкемле сөягең бар синең. Мин синең биегәнеңне карап торырга яратам. Биегәндә син җирдә яшәгәнне дә онытасың шикелле. Дөньяда өлкәнәю килешми торган кешеләр була. Син шуларның берсе, Гөлчирәҗан.

Гөлчирә. «Шуларның берсе» димә, «бердәнбере» диген.

Рәхмәтулла. Бердәнбере.

Гөлчирә. Кил, кочакла шуның өчен. Тик үбәргә үрелмә, ярыймы? (*Рәхмәтулланы кочаклап.*) Әй бу Фаягөлне. Хатыны дигән була, хатынының монда ни катнашы бар? (*Рәхмәтулланы этеп җибәреп.*) Утыр, эшлә. Эшләгәндә мине уйлама, саташуың бар. Сау бул! (*Бөтерелеп бии-бии чыгып китә.*)

Рәхмәтулла эш өстәле артына утырырга өлгерми, ишектә Хәдичә күренә.

Хәдичә. Мөмкинме, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович? Сөйләшәсем, бар дигән идегез.

Рәхмәтулла. Кер әйдә, Хәдичә, нигә рөхсәт сорап торасың? Уз, утыр.

Хәдичә (*полиэтилен пакеттан тастымалга уралган тәлинкә ала. Тастымалны сүтеп, тәлинкәне өстәлгә куя.*) Суынып ук өлгермәгәндер әле...

Рәхмәтулла. Син мине азындырып бетерәсең, Хәдичә. Мин инде өйдә иртәнге ашны ашамый башладым. Хәдичә алып килер әле, дим.

Хәдичә. Сез бит тәмле итеп ашый беләсез, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Күп итеп пешерергә яратам мин. Минем берүземә күпме кирәк?! Әле дә ярый сез бар. Ашагыз, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович! (*Рәхмәтулла ашаганда, күзләрен дә алмый Рәхмәтуллага карап тора. Аннан торып ишеккә юнәлә.*)

Рәхмәтулла. Туктале, Хәдичә. Нишләп әле алай бик тиз генә.

Хәдичә. Чыгам...

Рәхмәтулла. Утыр инде бераз. Синең белән утырып сөйләшкән дә юк.

Хәдичә. Нәрсә турында сөйләшәсең инде?

Рәхмәтулла. Тормышларың ничек?

Хәдичә. Тормышым юк минем, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович.

Рәхмәтулла. Хөрмәтулловичын әйтеп торма, дидем бит инде.

Хәдичә. Мин бит Гөлчирә түгел, сезнең яшьтәге кешегә Рәхмәти дип әйтә алмыйм. Килешми.

Рәхмәтулла. Гөлчирәгә килешәме?

Хәдичә. Аңа да килешми. Сез бит бала-чага түгел. Ул да бала-чага түгел.

Рәхмәтулла. Син һәрвакыт җитди, Хәдичә. Дөньяга бераз көлеп карарга кирәк.

Хәдичә. Көлеп карый алмыйм мин, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Яшәве кызык түгел миңа. Яшисем килми генә яшим. Кайвакытларда үкереп-үкереп җылыйсым килә. Юатучы булмаганга җыламый түзәм. Кырык яшь бит инде миңа. Һаман берьялгызым.

Рәхмәтулла. Шулайдыр инде. Ялгызлык бәхет түгел. Нишләп соң болай? Чибәр дә үзең. Арагызда иң чибәре син. Эшкә уңган. Пешергән ризыкларың ашап туймаслык.

Хәдичә. Шулар харап итте дә бугай инде. Сайландым шул. Күңелем ятардае очрамады. Очраганда инде соң иде.

Рәхмәтулла. Соң түгел, Хәдичә. Яратырга беркайчан да соң түгел.

Хәдичә. Соң, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Аннан инде минем яшьтә ярату, мәхәббәт дип сөйләнү дә килешми.

Рәхмәтулла. Очрады, дидең бит.

Хәдичә. Очрады. Ләкин ул ярату түгелдер, хөрмәт итү генәдер.

Рәхмәтулла. Хөрмәт итмичә яратып булмыйдыр, Хәдичә.

Хәдичә. Кем белә инде анысын. Сезнең яшисегез килмәгән чагыгыз булгалыймы, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович? Карап торсаң, сезнең бәхетегез тулып ташкан кебек. Уен-көлке, мәзәк. Бер кайгыгыз юк кебек.

Рәхмәтулла. Мин дә адәм баласы бит, Хәдичәкәй. Ләкин яшәргә кирәк бит. Ходай биргән гомер бит. Бүләк итеп биргән. Мә, яшә, бу дөньяның да рәхәтен күр, дигән.

Хәдичә. Авыр бит, Рәхмәтулла абый.

Рәхмәтулла. Авыр, билгеле. Сиңа гына авырмы? Авырайтсаң, ашый торган кашыгың да авырая. Сөйләш син кешеләр белән. Син гел үз-үзеңә йомылып утырасың. Гөлчирәгә җиңелме? Нинага, Фаягөлгә җиңелме? Тиле булганга көләләрме алар? Җилбәзәк булганга шаяралармы? Синең яшен яшьнәгәнен, күк күкрәгәнен күргәнең бармы?

Хәдичә. Ничек инде булмасын?

Рәхмәтулла. Ни өчен яшен яшьни? Ни өчен күк күкри? Алар күккә кара болытлар җыелгач яшьниләр, күкриләр. Кара болытлар сыеша алмагач, яшен яшьни, күк күкри дә коеп яңгыр ява башлый. Яңгыр ул – болытларның күз яше. Ә күк күкрәү – табигатьнең кычкырып көлүе. Табигать кычкырып көлә дә, болытлар яңгыр булып яугач, дөнья бушанып кала. Әгәр дә ул бушанмаса, дөнья җыелган кайгысыннан шартлар иде. Дөрес сөйлимме?

Хәдичә. Сез һәрвакыт дөресен сөйлисез. Ләкин сезнең бөтен сүзләрегез дә әкият. Тормыш әкият түгел.

Рәхмәтулла. Әкият, Хәдичә җанкисәгем, әкият. Әйт әле менә, нигә дип син миңа иң тәмле ризыклар пешереп киләсең? Нигә син минем төшеп калган кулъяулыгымны табып юып алып килдең? Нигә бүген яныма кердең? Үзем әйтимме? Яшисем килми, дидең. Юк, Хәдичә бәгырькәем, яшисең килгәнгә кердең яныма. Чөнки мин әкият. Мин әкияттәге маймыл. Мин әкияттәге Таз малай. Карале миңа. (*Төрле мимикалар ясап кылана. Бака булып сайрый, әтәч булып кычкыра, үгез булып мөгри.*) Йә, ничек? Нигә елмаясың? Кызык бит, әйеме? Көлке бит. Алтмыш яшьлек карт ничек тилерә.

Хәдичә. Сезгә алтмыш түгел әле. Илле тугыз яшь тә ике ай гына.

Рәхмәтулла. И-и-и, сабый гына икәнмен әле. Алайса, мин сиңа менә дигән кияү егете. Эзләгәнемне таптым дигәнең әллә минме?

Хәдичә. Шаяртмагыз, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Әйе, сез.

Рәхмәтулла. Пәрәмәч... Алайса гафу ит шаяртканым өчен.

Хәдичә. Соңгарак калып очрадыгыз шул. Ләкин мин барыбер бәхетле. Сезнең бүлмәгә күчеп утырсам, сез каршы түгелме, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович? Бер бүлмәдә утырсак, миңа артыгы кирәкми...

Гөлчирә кереп карап тора.

Гөлчирә. Бәтәч... Нишләп утырасыз?

Хәдичә чыгып китә.

Кара син боларны, мыштым гына. Нигә ташып ашата дисәм, кулга ияләштерә икән.

Рәхмәтулла (*кискен итеп*). Узынма, Гөлчирә.

Гөлчирә (*каушап калган*). Син усал да була беләсеңмени, Рәхмәтулла абый?

Рәхмәтулла. Беләм.

Гөлчирә. Гафу ит инде алайса. Йомыш белән генә кергән идем. (*Чыгарга борыла.*)

Рәхмәтулла. Йомышыңны әйт.

Гөлчирә. Ярый инде. Фәритем дә, баудан ычкынып китсәм, узынма дия иде. Зинһар, гафу ит, Рәхмәтулла абый. Мин чыннан да йомыш белән кергән идем. Рузалия җылый.

Рәхмәтулла. Ни булган?

Гөлчирә. Ни булсын, йөргән егете шылтыратмый.

Рәхмәтулла. Ә минем ни катнашым бар?

Гөлчирә. Кара бу оятсызны, ни ди. Аңа, җылый, дип әйтеп торалар. Ул ни катнашым бар, ди. Син бит аның әтисе урынына калган кеше. Ул бит синең һәр сүзеңне йотып утыра. Аның тома ятим үскәнен белмисеңмени?

Рәхмәтулла. Белмим.

Гөлчирә. Белмәсәң бел. Детдом баласы ул. Әрәм булмаганына рәхмәт әйт. Эшли, тәртипле.

Рәхмәтулла. Егете нигә шылтыратмый?

Гөлчирә. Каян белим? Белеп буламыни сезне. Яраттырасыз да качасыз.

Рәхмәтулла. Кайчаннан бирле шылтыратмый?

Гөлчирә. Ике көн, ди, инде.

Рәхмәтулла. Ике көн күп түгел, шылтыратыр.

Гөлчирә. Кара моны... Ике көн синең белән миңа күп түгел. Аңа бит унтугыз гына яшь. Аңлыйсыңмы – унтугыз.

Рәхмәтулла. Миңа нишләргә кушасың?

Гөлчирә. Менә ул егетнең телефон номеры. Шылтырат.

Рәхмәтулла. Ни дип?

Гөлчирә. Нәрсә, мин өйрәтер көнгә калдыңмыни?

Рәхмәтулла. Нигә үзең шылтыратмыйсың?

Гөлчирә. Ярамый. Мин хатын-кыз. Хатын-кыз черелди башлый. Черелдәгән хатын-кызны кем тыңласын. Шылтырат, Рәхмәти. Рузалия, шылтыраткач, «номер не отвечает» дигән язу чыга, ди. Юри алмый инде. Кесә телефоныңны бир әле. (*Рәхмәтулла кесәсеннән телефонын алып номерлар җыя.*) Мә, Рәхмәти, мә, җаным. Әйбәт бит син. (*Кесә телефонын Рәхмәтулланың колагына куя.*)

Рәхмәтулла. Исеме ничек егетнең?

Гөлчирә. Әй, Алла, сорарга онытканмын. Хәзер.

Атылып чыгып китә. Ул арада Рузалиянең йөргән егете телефонны ала.

Рәхмәтулла. Алло! Исәнмесез! Рәхмәтулла абыегыз бу. Хәзер белерсез. Ә сез Рузалия исемле кызны беләсезме?.. Безнең бухгалтериядә эшли. Искиткеч акыллы һәм искиткеч чибәр кыз. Арада иң чибәре. Беләсезме андый кызны?

Гөлчирә (*атылып керә*). Тимур. Тимур аның исеме.

Рәхмәтулла. Тимур бит әле сезнең исемегез? Бик матур исем. Рузалия әйтмичә, кем әйтсен. Мин аның әтисе урынына калган кеше. Ул сезнең турыда гына сөйли. Сезне очратуын зур бәхет дип саный. Ул сезнең бәхетегез, Тимур улым. Кулдан ычкындырмагыз. Андыйлар хәзер еш очрамый. Нигә шылтыратаммы? Нигә сез аңа шылтыратмыйсыз, шуңа шылтыратам. Рузалия кушмады, үзем шылтыратам. Телефон номерын ул бирмәде, үзем сорап алдым. Энекәш, сез көлмәгез әле. Көлмә әле син. Кеше җылаганда көлү килешми. Рузалияң җылый. Кызларның күз яшеннән куркырга кирәк, Тимур энекәш. Шылтырат син аңа. Сүзгә килгән булсагыз, очрашып аңлашыгыз. Хатын-кыз кәпризле була ул. Чөнки аларның күңелләре нечкә. Скрипкә кылы кебек. Көйләмәсәң, әче тавыш чыгара. Аңладыңмы? Көлмә син. Минем яшькә җиткәч көлмәссең.

Гөлчирә (*Рәхмәтулланы кочаклап алып*). Менә ничек яратмыйсың инде сине. Әле дә син бар әле дөньяда. Килешсәләр ярар иде инде. Бәхетле булсыннар иде. Минем кебек бәхетле булсыннар иде. Сине яратканымны кызым да белә. Элек мин аңа әтисе турында гына сөйли идем. Әтисен хәтерләми бит ул – яшь ярымлык кына иде. Хәзер синең исем дә ычкынгалый икән. Бервакыт әйтә, Рәхмәтуллаң ни хәлләрдә яши, ди. Егылыплар китә яздым. Синең исемгә ияләште инде. Яратканымны сизә, кунакка чакырыйк, ди. Чакыра алмыйм шул. Чыгарып җибәрмәм дип куркам. Кызыбызны нишләтербез икән, Рәхмәтулла?

Рәхмәтулла. Ничек «кызыбызны»?

Гөлчирә. Хәзер синең кыз да инде ул. Мәктәпне тәмамлый, кая укырга кертербез икән... Нигә алай карап торасың, Рәхмәтулла, әллә ярамаган сүз әйттемме? Узынма дип әйтергә җыенасыңмы? Ник дәшмисең, Рәхмәтулла? Ни уйлыйсың?

Рәхмәтулла. Юк, юк, сөйлә, сөйлә...

Гөлчирә. Юк инде, сөйләмим, ошатмадың. Сау бул. Рузалия өчен рәхмәт.

Рузалия (*атылып кереп Рәхмәтуллага ташлана, кочаклый*). Рәхмәтулла абый! Рәхмәтулла абый...

Гөлчирә. Кысыбрак кочакла. Ике яңагыннан үп. Булды. Инде мине кочакла.

Рузалия. Гөлчирә апа!..

Гөлчирә. Менә шундый инде без, Рәхмәтулла абый. Ә син безне әллә кем дип уйлыйсың. Күктәге йолдыз! Тулган ай! Фәлән-төгән, өч тиенлек бер дурак өчен акылдан шашучылар димисең.

Рузалия. Өч тиенлек түгел, Гөлчирә апа. Дурак та түгел. Рәхмәтулла абый кебек әйбәт егет ул.

Гөлчирә. Нәрсә, Рәхмәтулла абыең шулай бик әйбәтмени?
Рузалия. Искиткеч! Чудо!
Гөлчирә. Нәрсәсе чудо инде?
Рузалия. Мин каян белим инде? Кызык бит аның белән, күңелле.
Гөлчирә. Нәрсәсе күңелле инде?
Рузалия. Ну, Гөлчирә апа. Сез беләсез бит инде.
Гөлчирә. Нәрсәне беләм?
Рузалия. Ну сез, Гөлчирә апа. Үзегез дә яратасыз ич инде Рәхмәтулла абыйны.
Гөлчирә. Ни өчен яратам соң мин аны?
Рузалия. Ну, Гөлчирә апа.
Гөлчирә. Бар, чәй куя тор, мин хәзер чыгам. (*Рузалия чыгып киткәч.*) Рәхмәт сезгә, Рәхмәтулла абый.
Рәхмәтулла. Нишләп әле «сез» дип сөйләшә башладың?
Гөлчирә. Гаебем бар синең алда. Син миңа шулай әйткәләп тор, ярыймы, Рәхмәтулла абый. Ә миңа шундый рәхәт булды, син узынма, дип әйткәч. Ирләр сүзе җитми шул безгә, Хәдичәгә дә ирләр сүзе җитми. Күпме әйттем «сайланма» дип. Әллә кемне эзли. Син аның ризыкларын тәмле дип аша, Рәхмәтулла абый, күңеле булсын. Ир кирәк шул хатын-кызга, ир кирәк. Хәзер кочаклаттырмассың инде, әйеме?
Рәхмәтулла. Син миннән уенчык ясап бетердең. Рәхәтләнеп уйныйсың.
Гөлчирә. Уйныйм, Рәхмәтулла абый. Уйнарлык уенчык барында нигә уйнамаска. Әгәр дә бик беләсегез килсә, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович, бер генә бала да яратмаган уенчыгы белән уйнамый, яраткан уенчыгы белән генә уйный. Минем сүзләрем сезләрнең баш шәрифләренә барып җиттеме?
Рәхмәтулла. Җитте.
Гөлчирә. Менә шулай. Мин булмасам, нишләпләр бетәр идең син? Әле мин уйныйм гына, чынлап тотынсам – һу-һу-һу!.. Син дә уйна, Рәхмәтулла абый, мин яраткан уенчыгың булырга риза бит. Менә мин – синеке, теләсәң нишләт. Тездән түбән, кендектән югарысы барысы да синеке.
Рәхмәтулла. Бар, чыгып кит!
Гөлчирә. Чыгып китсәм, сагынасың бит.

Телеграм баганасы –
Олы юлга маяк ул;
«Сагынасыңмы» дип сорыйлар,
Сагынмаган кая ул.

(*Боргаланып чыгып китә.*)
Рәхмәтулла (*Гөлчирәнең җырын дәвам итә*).

Телеграм баганасын
Санийсым калган икән;
Күз керфекләрем талганчы
Карыйсым калган икән.

(*Кесәсеннән кесә телефонын алып саннар җыя.*) Исәнме, алтыным. Борчылма, бик яхшы. Укып бетердеңме әле китабыңны? Әйе, бик яхшы язучы ул. Кит инде... Яле, яле укы... Искиткеч, алтыным. Тагын яз. Китап итеп чыгарырбыз. Мин дә шагыйрь ире булып мактанып йөрермен. Сау бул, күгәрченем. Борчылма.
Гөлчирә (*ишектә күренеп*). Бу мин түгел, курыкма. Әйдә, Нина. Менә Нинаның синең янга керәсе килә. Оялам, ди. Үзе марҗа – үзе ирләрдән ояла. Утыр әйдә, Нина. Сөйләш туйганчы.
Нина. Балаболка син, Гуля. Исянмесез, Рахматулла Хурматуллович.
Рәхмәтулла. Пока живой, Ниночка.
Гөлчирә. Мин чыгам, Нина. Смотри, не трогай Рахматулла абыйны. Марҗаларга ир ышанып калдырсаң... Марҗа күрсә, татар ире акылдан шаша бит ул.
Нина. Потому что без матурлар. Әйеме, Рахматулла абы?
Рәхмәтулла. Әйе.
Гөлчирә. Кара, кара, монысын. Кил, башта кызыгыңны үзем күрим. (*Рәхмәтулланы кочаклап чыгып китә.*)
Нина. Ә мин беләм нигә Гуля кочаклый сезне. Она вампир. Ул сездән ни... жизненный тонус высасывает. Шуңа ул такая веселая. Ул сезгә ошыймы?
Рәхмәтулла. Ошый. Все вы мне нравитесь. Я всех вас люблю.
Нина. Сез со мной татарча сөйләшегез, Рахматулла Хурматуллович. Сез ошыйсыз миңа, кайчан татарча сөйләшәсез. Сез сөйлисез, все мне понятно. Язык, наверно, красив тогда, когда на нем красиво говорят. Минем ирем булды татар, аның сөйләшүе татарча меня раздражал. «Раздражал» ничек татарча.

Рәхмәтулла. Ачуны китерә иде.

Нина. Вот, вот, ачуны китерә. Мин уйлый идем – какой грубый язык. Сез сөйлисез, ласкает слух сезнең сүзләр. Какие-то мягкие они. Сез үзегез дә такой йомшак. Вот сез прикоснетесь руками, кулыгыз белән, әйеме, и по всему телу вот такая теплота, җылы. Вроде бы вы уже не молодой. Яшь кеше түгел бит, да? Менә вот сезнең объятие... Кочакка керәсе килә. Гуля ул такая хитрая. Сез гафу итегез мине алай сөйләгәнгә. Мне вот захотелось в любви объясниться. Юк, мин бернәрсә теләмим, сорамыйм. Сезне выгнали безнең бүлмәдән и так скучно мне стало. Откуда у вас такая положительная энергия?

Рәхмәтулла. Белмим инде, Ниночка. Сез үзегез яхшы булгангадыр ул.

Нина. Какой уж яхшы. Үзем беләм. Правильно я говорю – үзем беләм. Кстати, не такая уж я стерва, да, Рахматулла абы?

Рәхмәтулла. Синме, Ниночка? Син арада иң чибәре, иң яхшысы.

Нина. И иң бәхетсез. Самая несчастная, наверно.

Рәхмәтулла. Алай димә, Ниночка. Бәхетне аны үлчәүгә салып үлчәп булмый.

Нина. Как, как?..

Рәхмәтулла. Ну как сказать. Счастье невозможно положить на весы и взвесить.

Нина. Интересно. Может быть. Вот мин, Рахматулла абы, дүрт иргә чыктым, да? Беренче чыктым. Любила. Яраттым. Сигез ел нормально жили. Аннан начал эчәргә. Беспробудно. Вроде бы и причина да юк. Эчә дә сугыша. Кыйный. Үз баласын да кыйный. Аерылдым. Икенче чыктым – такая же картина. Өченче татарга чыктым. Вроде бы трезвее народ. Ну эчте. Хуже других может. Исереп под трамвай попал. Четвертый раз за еврея вышла. Ну этот же народ абсолютно трезвый. Умный, рассудительный. Ну откуда мне попался такой экземпляр. Пьяница. Мин хәзер уйлыйм, Рахматулла абы, мы всем миром дышим перегаром. Минем дүрт иремнән өч балам бар. Как аларны уберечь? И у меня хәзер такое ощущение, что мин постоянно йокладым с бочками, наполненными водкой. Гафу итегез, что мин инде болай... Зашла вот объясниться в любви и объяснилась. Сез әйтәсез, что сез старый. Вот если сез әйтәсез миңа, Ниночка, выйди за меня, дип, побежала бы.

Рәхмәтулла. Читтән караганда гына шулай ул, Ниночка.

Нина. Нет, Рахматулла Хурматуллович. Юк, Рахматулла абы. Кайтыгыз безгә, вернитесь. Мы уговорим эту кикимору. (*Нурзидә Мөбәрәковнаның кергәнен күреп.*) Извините. (*Чыгып китә.*)

Нурзидә. Сез мавзолейда яткан кебек, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Чират торып керәләр.

Рәхмәтулла. Нишләтим инде аларны. Ничә ел бергә утырдык бит, ияләшкәннәр.

Нурзидә. Ияләшү генә түгел бу. Сөйкемле сөягегез бар, күрәсең.

Рәхмәтулла. Кем белә инде анысын, Нурзидә Мөбәрәковна. Яратам бит мин аларны. Алар яратуга мохтаҗ. Эшли-эшли сезне дә яратырмын, мохтаҗ булсагыз.

Нурзидә. Ләкин бит эш бүлмәсе балаган түгел. Анда ниндидер тәртип булырга тиеш.

Рәхмәтулла. Эш бүлмәсе төрмә камерасы да түгелдер инде. Монда бит җинаятьчеләр утырмый.

Нурзидә. Комедия театры да түгел инде бухгалтерия.

Рәхмәтулла. Үз эшләрен эшлиләр бит алар. Мин дә калышмыйм.

Нурзидә. Сез өлкән яшьтә бит инде. Алар сезне уенчык итеп уйныйлар.

Рәхмәтулла. Уйнасыннар. Сез баскетбол дигән уенны беләсезме? Мин аны яратам. Менә шул уенда уйнаучылар бар, туп бар. Уйнаучылар әллә нинди булсалар да, тупсыз уйный алмыйлар. Мин шул туп. Уйнасыннар, аннан кемгә зыян? Нигә алай карап торасыз? Бу абзый акылында микән дипме?

Нурзидә. Нигә минем турыда начар уйлыйсыз? Бәлки, теге кызларыгыз кебек сокланып карап торамдыр.

Рәхмәтулла. Охшамаган. Сез кирәгеннән артык җитди, Нурзидә Мөбәрәковна. Телисезме, мин сезгә Нурзидә дип кенә дәшәм. Сез әле миннән күпкә яшь. Чибәр. Беләсезме, бездә ничә хатын-кыз эшли, арада иң чибәре сез. Нигә елмаясыз? Телисезме, мин сезгә бер мәзәк сөйлим. Ишеттем дә бүген көлә-көлә үлә яздым. Көтүдән бер сыер кайтып килә икән. Капка төбендә бер песи баласы утыра, ди. «Кит юлдан, – дигән сыер, – үзең бәләкәй генә, үзең мыек үстергән булгансың», – дия икән. «Үзеңне бел, – дигән песи баласы, – тубал хәтле ими үстереп лифчиксыз йөрисең». (*Нурзидәнең көлгәненә куанып.*) Шәп бит, әйеме?

Нурзидә (*көлүдән туктап*). Ә бит сезнең тормышыгыз мәзәк сөйләп йөри торган түгел, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Сезнең туганыгыз белән без бер йортта торабыз. Сез унбиш ел буена паралич суккан хатыныгызны тәрбиялисез.

Рәхмәтулла. Алдаша ул.

Нурзидә. Алдашмый. Сез аны берәүгә дә әйтмисез.

Рәхмәтулла. Нигә сез аны миңа әйтәсез? Ул бит аны сер итеп сөйләгәндер. (*Югалып калып.*) Кемдә кемнең ни эше бар? Әллә сезнең тормыш тоташ бәхеттән торамы? Бер үтенечем сезгә. Моны миңа сөйләп бер ахмаклык эшләдегез, бүтәннәргә сөйләмәгез. Кемдә кемнең ни эше бар? Кешеләр кайгы түгел, шатлык уртаклашырга тиешләр.

Нурзидә. Гафу итегез. (*Ишектә Гөлчирә башын күреп.*) Керегез, Гөлчирә Нәҗиповна.
Гөлчирә (*кереп*). Әллә кермәмме?
Нурзидә. Сау булыгыз, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович. Гафу итегез. (*Чыгып китә.*)
Гөлчирә. Нигә гафу үтенә ул?
Рәхмәтулла. Мине синнән аерганга.
Гөлчирә. Ха!.. Аерып карасын. Ишекне бикләп куйса, тәрәзәдән керәчәкмен. Сиңа ни булды? Сөмсереңкоелган сыман.
Рәхмәтулла. Озак керми тордың бит.
Гөлчирә. Көлмә инде, чыкканым да юк. Нинага ни әйттең, очынып йөри. «Яратам» дидеңме?
Рәхмәтулла. «Үлеп яратам» дидем.
Гөлчирә. Оятсыз! Кочаклап үтерәм бит үзеңне. (*Рәхмәтулланы кочаклый.*) Җылыйсым килсә дә, җыламыйм әле. Җылый белмим бит. Нигә алай икән, Рәхмәтулла абый? Ә син мине бер тапкыр җылаттың. Хәтерлисеңме, Яңа ел каршылаганда. Коллектив белән. Кал безнең янда, дидем, калмадың. Ялындым – калмадың. Хурлыгымнан җыладым. Нишләтәсең, үземнеке түгел шул. Кеше кешесе. Уйныйсың, дисең мине. Уйнамыйм, бик нык ятратканымны сиздермәс өчен уйнаган булып кыланам. Һәр кешегә Ходай ярату хисе салган. Миндә әле аның яртысы да сарыф ителмәгән. Син дә мине яратасың бит, әйеме?
Рәхмәтулла. Яратмаска сине мөмкин түгел.
Гөлчирә. Кирәкми, икенче юлы әйтмә. Соң түгел әле, соң түгел. Мин әле сине йөз яшькә хәтле яшәтәм.

Шаулашып Фаягөл, Нина, Рузалия, Хәдичә керәләр.

Нина. Все, Рахматулла Хурматуллович, вы – наш. Сез – безнеке.
Фаягөл. Нурзидә Мөбәрәковна рөхсәт бирде.
Рузалия. Күчерегез, диде.
Гөлчирә. Күчерергә ул бит сезгә шкаф түгел.
Нина. Все, Гуля! Монополия уничтожена – Рахматулла абы общий.
Гөлчирә. Общий булмый торсын.
Нина. Рахматулла абы – всенародное достояние. Дөрес әйтәмме, девочки?
Рузалия. Дөрес!
Фаягөл. Дөрес!
Рәхмәтулла. Нәрсә, миннән сорап та тормыйсызмыни?
Хәдичә. Кайтыгыз, Рәхмәтулла Хөрмәтуллович.
Нина. Башла, Фаягуль. Һай, хилляу, хилляу...

Фаягөл җыр башлый, аңа башкалар кушылалар.

Алма сатучылар килгән,
Үлчәүләре бар микән;
Әҗәлгә дару бар, диләр,
Мәхәббәткә бар микән?
Һай, һилләү, һилләү, һилләү,
Алты кызга бер кияү.
Һай, һилләү, һилләү, һилләү.
Һай, һилләү, һилләү лә.

Пәрдә.

# Саташу

*Ике пәрдәле драматик хикәя*

Күз яшең дә кипмичә егълап вафат булган әни!
Гаиләсенә җиһанның ник китердең ят кеше?!

*Г.Тукай*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Гүзәл – 27 яшьлек кыз.
Марат – Гүзәлнең этисе.
Галиябану – Гүзәлнең әнисе.
Мөслимә – Маратның әнисе.

Надир – 29 яшьлек егет.
Фәридә – судья, 35 яшендә.
Харис – Фәридәнең ире.
Саташкан әби.

ПРОЛОГ

Урам буйлап үз-үзенә сөйләнеп Саташкан әби атлый.

Саташкан әби. Барыйм әле, аннары кайтырмын. Барырга кирәк иде, кайтырга да кирәк. (*Туктап.*) Тукта, кая барам соң әле мин?.. Кая барырга чыктым соң әле?.. Урамдагы бу халык кая бара икән?.. Нигә ашыгалар? Кая чабалар? Баргач кайтасын беләләр микән?.. Кайтыр юлларын онытмадылар микән?.. Берсен-берсе күрмиләр. Мине дә күрмиләр... Нигә күрмиләр? Әллә соң мин ят кешеме?.. Әллә мине ятсыналармы? Нигә үз итмиләр? Нигә ятсыналар? Мин аларга нинди начарлык эшләгән? Әллә инде без барыбыз да ятлармы? Дөнья безне ятсынамы? (*Узкән-сүткән кешеләргә.*) Исәнмесез!.. Здрастуйте!.. Исәнмесез!.. Здрастуйте!.. Нигә исәнләшмиләр?.. Танымагангадыр инде. Танымаса ни булган. Без танымасак та исәнләшә идек. Авылга берәр чит кеше килсә, өчәр кат исәнләшә идек. Чит кеше дип тормый идек, ят итми идек. Бөтен кешеләр дә кеше ич, нигә ят итәргә... Карасана, кая бара идем соң әле? Шушы яктан килдем инде килүен. Шушы өй янынннан үттем ич инде. Сөбханалла, бигрәк биек өй инде. Монда да кешеләр яши инде. Кеше өстендә кеше яши. Берсе астында икенчесе яши. Шулай да яшәп була диген, ә... Янәшә яшәсәң әйбәтрәктер инде. Үз кешеләр янәшә яшиләрдер инде. Бер фатирда. Ичмасам, алар бер-берсен ят итмиләрдер... Шушы өй янынннан үттем бугай шул. Кызык инде бу дөнья – барыр юл да юк, кайтыр юл да онытылган... Шушыннан килгән идем бугай. Кайтыр юлыңны белеп чыгарга кирәк шул. (*Сөйләнә-сөйләнә чыгып китә.*)

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гарифуллиннарның ике бүлмәле фатирының зал дип аталырга тиешле өлеше. Кәнәфидә аякларын бөкләп, шәл бөркәнеп, бөрешеп Гүзәл утыра. Бүлмә читендә телевизор эшләп тора. Гүзәлнең карашы шул якка төбәлсә дә, ул аны карамый. Үз уйларына чумган. Хәер, ул уйламый да бугай. Ниндидер мәгънәле, кирәкле, нәтиҗәле уй уйлау халәтендә түгел. Телефон шылтырый, ләкин Гүзәл трубканы алмый. Дөрес-
рәге, телефон шылтыраганны ишетми.

Мөслимә (*икенче бүлмәдән чыгып*). Кызым, ишетмисеңме соң син? Гүзәл, балакаем, сиңа әйтәм.
Гүзәл. Ә? Нәрсә бар?..
Мөслимә. Соң, телефон шылтырый ич... Гүзәл, сиңа әйтәләр...
Гүзәл. Ал, сөйләш.
Мөслимә. Соң, сиңа шылтыраталардыр. Миңа кем шылтыратсын. (*Трубканы алып.*) Әлү... (*Гүзәлгә.*) Сине сорыйлар.
Гүзәл. Кем сорый?
Мөслимә. Шул, Надир дигән егет бугай.
Гүзәл. Әйт, вакыты юк, диген.
Мөслимә. Ничек юк, тик утырасың лабаса.
Гүзәл. Уйлыйм мин.
Мөслимә. Ниткән инде ул туктаусыз уйлау?
Гүзәл. Әбием, комачаулама.
Мөслимә. Ни булды соң сиңа, кызым? Утырасың да уйлыйсың, утырасың да уйлыйсың.
Гүзәл. Кемдер уйларга тиештер бит бу дөньяда? Бар, әбием, бүлмәгә кер, мин әйтмичә чыкма.
Мөслимә. Ни булды соң сиңа?

Гүзәл урынынннан тора да Мөслимәне култыклап ишектән чыгара.

Гүзәл. Намазыңны укырга онытма. (*Узе өстәл янына килеп нидер яза. Язганын ертып ташлый, тагын яза. Язуыннан туктап көлә.*)
Мөслимә (*ишектән башын тыгып*). Гүзәл, кызым...
Гүзәл. Нәрсә, әбием, мин әйткәнне аңламадыңмы? Нәрсә, минем белән сөйләшәсең киләме?
Мөслимә. Килә.
Гүзәл. Ә минем сөйләшергә вакытым юк.
Мөслимә. Син сөйләшмә, әйт кенә.
Гүзәл. Кил әле алайса, утыр шушында. (*Мөслимәне урындыкка утыртып.*) Син хөкемдар...

Мөслимә. Ниткән хөкемдар?

Гүзәл. Судья. Ә мин... Мин әлегә үземнең кем икәнлегемне белмим. Йә гаепләүче, йә гаепләнүче. Суд бара. Юк. Ул ахырына җиткән. Мин соңгы сүзне әйтәм. Игътибар белән тыңла. Гражданин судья! Минем сезнең алдыгыздагы гаризамда барысы да төгәл язылган. Мин аны кабатлап тормыйм. Гражданин судья!..

Мөслимә. Кияүгә чыгарга кирәк сиңа, кызым.

Гүзәл. Бүлдермәвегезне үтенәм.

Мөслимә. Олыгая барасың. Җаның шуңа уйный, балакаем.

Гүзәл. Җаным уйнамый, башым гына уйлый.

Мөслимә. Хатын-кызның бөтен уе балаларында аның.

Гүзәл. Бүлдермәгез, дидем. Гражданин судья...

Ишектә Галиябану күренә. Ул Гүзәлнең соңгы сүзен ишетеп калган.

Галиябану. Нишләвегез бу?

Гүзәл көлә-көлә чыгып китә.

Нишли ул?

Мөслимә. Аның нишләгәнен кем белә? Сәгатенә йөз үзгәрә. Миннән судья ясады менә.

Галиябану. Бүген дә беркая да чыкмадымы?

Мөслимә. Юк. Уйланып утыра-утыра да нидер яза башлый. Яза да ертып ташлый язганын. Тагын яза. Кычкырып көләргә тотына. Шул инде – иләсләнә. Тиле-миле чакта кияүгә чыгып калырга кирәк шул. Башка төрле-төрле уйлар керә башлагач читен ул. Егерме җиде яшь кыз бала өчен күп инде.

Галиябану. Эшеннән чыгарганнар.

Мөслимә. Тагынмы?

Галиябану. Дүртенче эшеннән куып чыгаралар бит инде.

Мөслимә. Йа Ходаем! Тагын нишләде икән.

Галиябану. Нишләсен, тыныша алмый.

Мөслимә. Үзегез гаепле. Үчти-үчти итеп үстердегез дә. Берәүне дә санга сукмый. Баланы артык иркәләргә ярамый шул.

Галиябану. Нәрсә иркәләдек? Синең куеныңда үсте бит.

Мөслимә. Үсте дә. Үсеп җитмәгән, күрәсең.

Галиябану (*Гүзәлне чакыра*). Гүзәл! Гүзәл, дим!

Гүзәл (*чыгып*). Нәрсә?

Галиябану. Нәрсә син, мин кайтып керүгә, чыгып киттең?

Гүзәл. Кысталдым.

Мөслимә. Матур сөйләш, син кыз кеше.

Галиябану. Нәрсәгә көлдең?

Гүзәл. Анысы сине күргән шатлыктан.

Галиябану. Шатлыктан?

Гүзәл. Ә нигә? Әнием кайткан ич. (*Көлә.*)

Галиябану. Бүген дә эшкә бармадыңмы?

Гүзәл. Юк.

Галиябану. Нигә?

Гүзәл. Чөнки эшләмим.

Галиябану. Нигә эшләмисең?

Гүзәл. Чыгардылар.

Галиябану. Ничек «чыгардылар»?

Гүзәл. Шулай, чыгардылар.

Галиябану. Кайчан?

Гүзәл. Ике көн элек.

Галиябану. Нигә әйтмәдең?

Гүзәл. Менә әйттем ич.

Галиябану. Ни өчен?..

Гүзәл. Шуның өчен.

Галиябану. Ипләп сөйләш.

Гүзәл ишектән чыгып киткәч.

Гүзәл! Гүзәл, дим! Гүзәл, кемгә әйтәләр. Кер, diләр!.. Гү-зәл!..

Гүзәл керә.

Гүзәл. Нәрсә?

Галиябану. Утыр әле.
Гүзәл. Моннан да ишетәм.
Галиябану. Син кем белән сөйләшкәнеңне беләсеңме?
Гүзәл. Беләм.
Галиябану. Белгәч...
Гүзәл. Сиңа миннән ни кирәк?
Галиябану. Миңа белергә кирәк. Эшеңнән нигә чыгардылар? Һәм гомумән... Син көннән-көн начар якка үзгәрә барасың. Сәбәбе ни?
Гүзәл. Белмисеңмени?
Галиябану. Белмим.
Гүзәл. Белмәгәч, нигә укытып йөргән буласың?
Галиябану. Ничек инде ул «укытып»?..
Гүзәл. Укытучы ич син.
Галиябану. Булса?..
Гүзәл. Булса, шул... Миңа юынырга кирәк. Барасым бар.
Галиябану. Кая?
Гүзәл. Миннән сорау аласыңмы? Гаепләнүчедән генә сорау алалар. Гомерең буе син миннән сорау аласың.
Галиябану. Нишләвең бу, кызым? Мин – синең әниең.
Гүзәл. Ләкин судья түгел. Нигә син миннән туктаусыз сорау аласың?
Галиябану. Ә кем алырга тиеш? Мин синең турыда ни дә булса белергә тиештер бит? Берни әйтмисең, берни аңлатмыйсың. Үзең әйтмәгәч, мин нишләргә тиеш?
Гүзәл. Балаларны укыт. Мин инде бала түгел.
Галиябану. Кем соң син миңа?
Гүзәл. Гузель Маратовна Гарифуллина. Юрист по образованию. Окончила юридический факультет государственного университета. Ну дай мне помыться. Я вся в грязи. И душа у меня грязная. (*Китә.*)
Галиябану. Йа Хода... Әнкәй!.. (*Бүлмәсеннән чыккан Мөслимәгә.*) Ишеттеңме? Нигә дәшмисең?
Мөслимә. Ни дип әйтим инде?
Галиябану. Ишеттеңме соң?
Мөслимә. Барысын да йөрәгеңә якын алма инде. Үтәр дә китәр.
Галиябану. Ничек үтеп китәр... Эштән тагын чыгардылар, ди.
Мөслимә. Килен, кызыңны син һаман да ун яшьтә дип уйлыйсың. Үз көнен үзе күрер яшьтә инде ул. Нигә син аңа туктаусыз бәйләнәсең?
Галиябану. Ничек инде ул «бәйләнәсең»?
Мөслимә. Әйдә, ашап ал, чәй эч. Эшеңә барасың бар.
Галиябану. Тамагымнан аш үтәме минем? Нинди дөнья соң бу? Мәктәпкә барсаң, анда балалар белән сөйләшү куркыныч, өйгә кайтсаң, үз балаң.
Мөслимә (*ишектәге звонокны ишетеп*). Марат та кайтты бугай. (*Чыгып китә*).

Бераздан Марат керә.

Марат (*Галиябануга*). Салют!
Галиябану. Исәнме! Кердеңме?
Марат. Әйе.
Галиябану. Чыгарулары дөресме?
Марат. Әйе.
Галиябану. Ни өчен?
Марат. Билгеле инде. Сыеша алмый бит.
Галиябану. Инде нишләгән?
Марат. Фирманың директорына «жулик» дигән.
Галиябану. Әй Алла...

Гүзәл керә.

Кәефе шәп. Авыз эченнән көй көйли.
Гүзәл (*Маратны күреп*). Салют!
Марат. Салют!
Галиябану. Нигә юынмадың?
Гүзәл. Җылы су юк. Һәм салкыны да юк. Сез төзегән коммунизмның дәвамы. (*Сызгырынып диванга барып ава.*) Бер шигырь сөйлимме?

Һәр шагыйрьнең үз темасы, нишләтәсең...
Мин мактыймын Якуп агай эшләпәсен:

Хезмәт итеп хуҗасына армый-талмый –
Салкында да, кызуда да аннан калмый,
Искергәч тә постта тора – бакча саклый,
Бакчадагы карачкының башын каплый.

Ничек?

Марат. Шәп.

Гүзәл. Надир Садри шигыре. Миңа укыган мең ярым шигыренең миңа ошаган бердәнбере. Кайдан килеп чыкты икән ул «шигырь» дигән сүз? Ши-ши-ши, дип, бер тешсез татарның шыелдавыннан микән, гыр-гыр-гыр, дип, икенче татарның гырлавыннан микән? Ничек уйлыйсың, картлач?

Марат. Укытучыдан сора.

Гүзәл. Укытучыдан сорый торган заман түгел. Укытучылар сорана торган заман. (*Торып утырып.*) Мин хәзер чыгып китәм, әйтәсе сүзләрегез юкмы?

Марат. Юк.

Галиябану. Ничек юк?!

Марат. Минем юк.

Галиябану. Кыланма, Марат. Күпме мөмкин? Алты ел эчендә бишенче тапкыр эшеннән куалар. Нәрсә бу?

Марат. Мин кухняга киттем.

Галиябану. Китмә, Марат!

Марат. Минем аңа соравым юк.

Галиябану. Синең бервакытта да соравың булмады. Өйдә кунак кына булдың.

Марат. Кунак – хуҗаның ишәге.

Галиябану. Бернидә дә гамең юк.

Марат. Эшкә соңга калам. Сәгать икенче яртыда әбәт бетә.

Галиябану. Нинди эш? Ун ай акча алганың юк.

Марат. Синең дә – өч ай.

Галиябану. Әйт кызыңа бирәр сүз.

Марат. Ни әйтим? Ул барысын да белә.

Галиябану. Бөтенесе дә бөтен нәрсәне беләләр. Мин генә бернәрсә дә белмим.

Марат. Әйе.

Галиябану. Нәрсә «әйе»?

Марат. Син генә бөтен нәрсәне дә беләсең.

Галиябану. Үртәмә.

Гүзәл. Ярый, мин киттем.

Галиябану. Кая?

Гүзәл. Кайткач әйтермен.

Мөслимә керә.

Мөслимә. Аш бүлдем, чыгыгыз. Гүзәл, кызым, әйдә.

Гүзәл. Мин ашамыйм.

Галиябану. Ничек инде ашамыйсың?

Гүзәл. Мин бүгеннән башлап бу өйдә ашамыйм.

Ут сүнә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урамнан Гүзәл атлый. Аңа кулына чәчәк бәйләме тоткан Надир ияргән.

Надир. Гүзәл... Гүзәл...

Гүзәл (*туктап*). Мин әйттем – минем берәүне дә күрәсем килми.

Надир. Минем сине күрәсем килә.

Гүзәл. Күрдең бит. Шул җитмәдеме?

Надир. Беләсең ич инде.

Гүзәл. Мин бер нәрсәне беләм, иптәш шагыйрь. Ирләр кызганыч булырга тиеш түгел. Йөрмә ияреп. Кит дигәндә китә бел. Ничә тапкыр әйттем шул турыда.

Надир. Ал чәчәкләрне.

Гүзәл. Алмыйм. Чөнки син аларны соңгы акчаңа сатып алгансың. Акчаң юк синең. Ярлы син, фәкыйрь син, хәерче син, шагыйрь син. Шулар җитмиме сиңа? Теләнче дә булма инде. Шагыйрь кеше горур булырга тиеш, теләнче булырга тиеш түгел.

Надир. Син ни әйтсәң дә, мин көтәрәм, Гүзәл.
Гүзәл. Ни өчен?
Надир. Чөнки мин сине яратам.
Гүзәл. Мин дә сине ярата идем бугай. Хәзер – юк. Сүнде. Аңлыйсыңмы син мине?! Сүнде! Учакның дөрләп янган чагында кадерен белергә кирәк. Сүнгәч нигә көлдә актарынасың? Алырга иде кочагыңа, кысып-кысып кочакларга иде.
Надир. Теләмәдең бит.
Гүзәл. Теләмәдең, теләмәдең. Каян беләсең теләмәгәнемне?
Надир. Үзең әйттең, кияүгә чыкмыйм, дидең. Әлегә, дидең.
Гүзәл. Һәрбер әйтелгән сүзгә ышаналармы? Хәер, син шагыйрь шул. Өстәвенә авыл малае. Йә, ярый, китер чәчәкләреңне. Үзең кит. Минем сөйләшеп торырга вакытым юк. Сау бул!
Надир. Озатып куйыйм.
Гүзәл. Мәхәббәт өчен кич бар, төн бар. Көпә-көндез озатып йөрмиләр инде.
Надир. Минем сиңа әйтәсе сүзем бар.
Гүзәл. Шигырь укырга җыенасыңмы?
Надир. Юк.
Гүзәл. Йә, әйт алайса.
Надир. Җитди сүз ул.
Гүзәл. Синең җитди булмаган сүз сөйләгәнең юк. Алты ел мин синнән гел җитди сүз генә ишетәм. Картаеп беттең бит инде. Ничә яшь инде сиңа? Егерме тугыз. Чәчләрең агара башлаган бит инде. Йә, әйт, нәрсә әйтәсең?.. Тик шигырь генә укыма.
Надир. Син әйтәсең, кайчан да кайчан туй ясарлык акчаң була, шул чакта мин сиңа кияүгә чыгам, дисең.
Гүзәл. Димим, дия идем.
Надир. Әйе, дия идең. Мин өченче ел чыккан китабыма гонорар алдым.
Гүзәл. Ничек аек соң әле син, алай булгач?
Надир. Көлмә инде. Беләсең ич, мин исерекбаш түгел.
Гүзәл. Гафу ит. Гонорар алгач юа идегез.
Надир. Йоласы шул.
Гүзәл. Нәрсә, өйләнешик дисеңме? Әйдә соң. Тулай торакта булса да аерым бүлмәң бар. Туйлык акча да биргәннәр. Яратасың да... Әгәр дә, Надир, мин синең урыныңда булсам, әллә кайчан төкереп киткән булыр идем.
Надир. Син беләсең, мин төкерә алмыйм.
Гүзәл. Кыйммәткә алдыңмы инде бу чәчәкләрне?
Надир. Үз бәясенә.
Гүзәл. Матурлар инде алар, әлбәттә. Ләкин минем матурлыкны күрәсем килми шул. Матурлык минем ачуымны китерә. Минем артымнан йөрүдән тукта син, Надир.
Надир. Туктаган идем, үзең эзләп таптың.
Гүзәл. Таптым шул. Үзгәргәнсең дип уйладым... Һаман шул ук. Бу юлы эзләмәячәкмен.
Надир. Нинди кеше соң син?
Гүзәл. Ә син нинди кеше? Гомумән, нинди кешеләр соң без? Бәлки, кешеләр дә түгелбездер. Укы әле теге шигыреңне. «Якуп агай эшләпәсен».
Надир. Шаярып язып аткан нәрсә инде. Нигә инде. Син минем үземнән көл, ләкин шигырьләремнән көлмә.
Гүзәл. Ә мин көлмим. Гомер буе хуҗасына хезмәт итеп хәзер карачкы башына элеп куелган эшләпәнең язмышыннан көләргә ярыймы? Ярый, сау бул, Надир. Мин бик җитди эш белән йөрим. Мин дә бүген шигырь яздым, шуны бастырырга алып барам.
Надир. Гүзәл...
Гүзәл. Юк, Надир. Мин кияүгә чыкмаячакмын. Беркемгә дә, беркайчан да. Элегрәк, җүләррәк чакта эләктереп калган булсаң... Хәзер юк инде. Кияүгә чыккач бала табасы була. Ә минем бу хәшәрәт дөньяга корбан бүләк итәсем килми.
Надир. Дөнья хәшәрәт була алмый, Гүзәл.
Гүзәл. Дөньяны син беләсеңме, минме?
Надир. Икебез дә белмибез.
Гүзәл. Алайса, хуш! Мә чәчәкләреңне! Мин барасы җиргә чәчәк белән йөрмиләр.

Чәчәк бәйләмен Надирга тоттырып китеп бара. Харис белән очраша.

Харис. Исәнме, күрше!
Гүзәл. Исәнмесез!
Харис. Мине танымадың, ахрысы, Гүзәл?

Гүзәл. Юк.
Харис. Шулай инде, чибәр кызларның хәтере начар була. Күрше фатирдагы абыйларын танымыйлар.
Гүзәл. Сау булыгыз!
Харис. Ашыгасың, ахры?
Гүзәл. Ашыгам.
Харис. Кая таба инде?
Гүзәл. Сезнең хатыныгыз янына.
Харис. Фәридәне күрер өчен нигә эшенә барырга? Күршедә генә.
Гүзәл. Ә минем сезгә керәсем килми.
Харис. Нигә дип сорарга рөхсәт итегез.
Гүзәл. Чөнки сез өйдә буласыз.
Харис. Булса ни?
Гүзәл. Сезне күрәсем килми.
Харис. Менә сиңа мә. Нинди начарлык эшләдем?
Гүзәл. Сез оятсыз экземпляр.
Харис. Гафу итегез...
Гүзәл. Итмим. Хушыгыз!
Харис (*Гүзәлнең каршысына төшеп*). Юк инде, күршекәем. Авыр сүз әйттең. Аңлат. Шундый сүз ишетерлек нинди оятсызлык эшләдем?
Гүзәл. Сез миңа кызыгып карыйсыз. Алкаш аракыга караган шикелле.
Харис (*көлеп*). Шәп әйтелде. Кызыгырлык та бит.
Гүзәл. Кайсы җирем?
Харис. Бөтен җиреңдә исемең кебек гүзәл.
Гүзәл. Йөзем дәме? Күзләрем дәме?
Харис. Әлбәттә.
Гүзәл. Алайса, нигә йөземә карамыйсыз? Нигә күзләрегез белән итәгемне күтәрәсез?
Харис (*көлеп*). Әллә сизәсеңме?
Гүзәл. Сизәм шул менә, абзыкаем.
Харис. Болай булгач, бик яхшы. Кул белән күтәрергә дә насыйп булсын.

Гүзәл аның яңагына суга да китеп бара. Бу күренешне Саташкан әби күреп кала. Аптырап, Гүзәл һәм Харис киткән якларга карап-
карап ала.

Саташкан әби. Сугышалар. Нигә сугышалар?.. Өстә дә сугышалар, аста да сугышалар. Сугышып җиңәбез дип уйлыйлар микән? Җиңелгәннең дә бит җиңәсе килә. Тагын сугыш чыга. И Ходаем! Нигә син акылсызларга көч бирәсең икән?.. Оялмыйлар, сугышалар. Саташты дөнья. Ят кешеләр күбәйде дөньяда. Үз кешеләр бетте. Урамга чыксаң – ят кешеләр, өйгә керсәң – ятлар. Шуңа күрә сугышалар. Сугышып нишләмәкче булалар?.. Сугышып үз булып буламы? Үз кешеләр сугышамы? Ятлар гына сугыша. Сугышмыйча гына яшәп булмыймы? Әйтәсе сүзең булса, әйт телең белән. Нигә әйтәсе сүзеңне йодрык белән әйтергә? Нигә әйтәсе сүзеңне бомба белән әйтергә? Йодрык белән бомбаның теле юк бит аның. Акылсызлар күбәйде. Оятсызлар күбәйде. Исәнләшә белмиләр, сугыша гына беләләр. И Ходаем! Акылсызларга акыл бир, саташканнарга юл күрсәт.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Судья Фәридә Гомәрованың эш бүлмәсе. Ишек ачыла. Анда
Гүзәл.

Гүзәл. Мөмкинме?
Фәридә. Гүзәл? Әйдә, әйдә, уз. Исәнме! Кил, утыр. Менә биргә. Күршедә торып күптән күргән юк. Ни хәлләр?
Гүзәл. Яхшы. Эштән кудылар.
Фәридә. Тагынмы? Ничек?
Гүзәл. Юрист безгә кирәкми, диделәр. Юристка түләргә фирманың акчасы юк, диделәр.
Фәридә. Начар. Нигәдер бер урында озак эшли алмыйсың. Инде нишләргә уйлыйсың?
Гүзәл. Белмим.
Фәридә. Бездә дә штат тулы.
Гүзәл. Мин эш сорап килмәдем. Заявление алып килдем.
Фәридә. Нинди заявление?
Гүзәл. Менә укыгыз.

Фəридə (*Гүзəл биргəн кəгазьне карап чыккач*). Аңламадым.
Гүзəл. Аңлашылмаслык ни бар?
Фəридə. Гарифуллин Марат диелгəн, Гарифуллина Галиябану. Марат абый белəн Галиябану апа. Əтиең белəн əниең.
Гүзəл. Əйе.
Фəридə. Ни өчен?
Гүзəл. Анда язылган.
Фəридə (*заявлениене тагын бер кат укып чыгып*). «За причинение мне морального вреда согласно статье 151 Уголовного кодекса Российской Федерации». Нəрсə бу, Гүзəл?
Гүзəл. Язылган.
Фəридə (*заявлениене укып*). Мои родители Гарифуллин...»
Гүзəл. Кычкырып укуның кирəге юк. Мин үзем язганны яхшы хəтерлим.
Фəридə. Лəкин... Туктале, Гүзəл... Əти-əниеңне судка бирəсең ич.
Гүзəл. Фəридə Хафизовна, эмоциялəрсез генə сөйлəшик. Күршелəр булып түгел, юристлар булып. Сез – судья, мин – дəгъвачы, юридик яктан заявление дөрес язылган. Сезнең эш – аны кабул итеп алып эшкə җибəрү.
Фəридə. Шаярасыңдыр əле?
Гүзəл. Мондый нəрсə белəн шаярмыйлар, Фəридə Хафизовна. Мин дə бит юрист, белəм ни эшлəгəнемне.
Фəридə. Юристын юрист та. Ни өчен?
Гүзəл. Язылган заявлениедə.
Фəридə. Язылуын язылган да. Язып булмый торган нəрсəлəр дə була. Мин, мəсəлəн, аңламыйм. Мондый эш беренче тапкыр.
Гүзəл. Беренче генə түгел. Мондый фактлар дөньяда бар инде.
Фəридə. Əтиең Марат абый – хөрмəтле кеше. Галим. Галиябану апа укытучы. Алар белəлəрме?
Гүзəл. Белерлəр.
Фəридə. Гаҗəп. Башыма сыймый.
Гүзəл (*көлеп*). Менə башка сыймаслык эш эшлəп карагыз əле. Өйрəндегез фатир басучыларны утыртып куеп. «Бастыңмы?» – «Бастым». –«Үтерденңме?» – «Юк». – «Унбиш ел!».
Фəридə. Ни сөйлисең син, Гүзəл?
Гүзəл. Белеп сөйлим, Фəридə Хафизовна. Университетны кызыл диплом белəн тəмамладым. Сезнең ярдəм белəн. Сез бит котырттыгыз əтине миннəн юрист ясарга. Мине дə сез үгетлəдегез. Менə сез утырткан агачның җимеше өлгерде.
Фəридə. Алыгыз моны, Гүзəл. Кешегə күрсəтмəгез.
Гүзəл. Ə мин күрсəтергə телим. Күрсеннəр.
Фəридə. Мин мондый заявлениене кабул итə алмыйм.
Гүзəл. Хакыгыз юк.
Фəридə. Алмыйм. Бүтəн судка мөрəҗəгать итегез.
Гүзəл. Юк, мин торган адресым буенча сезгə мөрəҗəгать итəргə тиеш.
Фəридə. Карале күземə туры итеп. Шаярасың бит, əйеме?
Гүзəл. Сез нəрсə? Нигə мин сезнең белəн шаярырга тиеш?
Фəридə. Мине сынап карарга телисеңдер.
Гүзəл. Нигə мин сезне сынарга тиеш.
Фəридə. Күршедə генə Фəридə исемле бер апа яшəп ята. Авылда туып үскəн. Өендə дə авылча яши. Бəлеш пешерə, коймак куя. Туктале, эшендə ничек икəн ул? Нишлəп əле шул авыл хатынын суд председателе иткəннəр? Тукта, сынап карыйк əле үзен, нишлəр икəн... Шулаймы?
Гүзəл. Əйтер идем инде. Ямьсез сүз əйтеп рəнҗетəсем килми. Чөнки сез чыннан да яхшы апа. Кабатлап əйтəм, мин яхшы апа янына килмəдем. Рəсми учреждениегə, суд рəисенə рəсми заявление китердем. Кабатлап əйтəм, мин шаярмыйм һəм шаярырга да телəмим.

Пауза.

Фəридə. Туктале, Гүзəл... Сине бик яраталар бит – əтиең дə, əниең дə.
Гүзəл. Кем əйтə яратмыйлар дип, яраталар. Үзлəренчə. Лəкин аларның яратуыннан миңа ни файда?
Фəридə. Яратудан файда эзлəргə ярамый ич. Алар бит сине дөньяга китергəннəр.
Гүзəл. Соң шуның өчен судка бирəм дə ич инде. Сез нəрсə...
Фəридə. Үстергəннəр. Укыттылар. Үзлəре кимичə сине киендерделəр.
Гүзəл. Без юристлар телендə сөйлəшмибез. Мин бу заявлениене нык уйлап һəм юридик əдəбиятны өйрəнеп яздым. Миңа мораль зыян китергəн өчен Гарифуллин Марат белəн Гарифуллина Галиябану компенсация түлəргə тиешлəр дип саныйм. Судның минем үтенечемне кире кагарга бернинди дə сəбəбе юк.

Фәридә. Анысын суд карар... Син чирлисеңдер, Гүзәл?
Гүзәл. Сез нигә мине мыскыл итәсез?
Фәридә. Мыскыл итмим. Врач-психологка күренергә кирәк. Бүген без барыбыз да психологик кризис кичерәбез. Заманасы әллә нинди.
Гүзәл. Заманада минем эшем юк. Замананы шундый итеп мин ясамадым. Миңа яшәргә кирәк.
Фәридә. Әтиеңнән һәм әниеңнән талап алган акчагамы?
Гүзәл. Ә кем талап алырга җыена? Талап алырга теләсәм, мин монда килеп йөрмәс идем. Мин закон нигезендә алырга телим. Җинаять кылучылар җавап бирергә тиеш.
Фәридә. Нинди җинаять?
Гүзәл. Җинаять. Алар мине тудырмаска тиешләр иде.
Фәридә. Ни сөйлисең, Гүзәл? Утыр әле, тынычлан әле...
Гүзәл. Ә мин тыныч. Мин инде сез әйткән психологик барьерны уздым. Хәзер мин тыныч. Хәзер мин закон нигезендә генә эш итәм.
Фәридә. Мораль законнар бар. Язылмаган законнар бар.
Гүзәл. Язылмаганы мине кызыксындырмый.
Фәридә. Мин барыбер аңламыйм, Гүзәл. Гафу ит, аңламыйм. Яхшы, мин алып калам заявлениеңне. Ләкин тагын бер кат уйла әле. Ныклап уйла.

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Сызгырынып урам буйлап Гүзәл атлый. Аны Фәридә куып җитә.

Фәридә. Гүзәл! Туктагыз әле.
Гүзәл. Нәрсә инде тагын?
Фәридә. Туктагыз әле! Тагын бер кат сөйләшик әле. Бәлки, алырсыз заявлениене?
Гүзәл. Урам сезнең эш урыныгыз түгел, Фәридә Хафизовна. (*Сызгырынып китеп бара.*)

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гарифуллиннар фатиры. Марат креслода утыра. Галиябану бүлмә буйлап арлы-бирле йөренә.

Марат. Утыр, тынычлан. Бетерәсең бит үзеңне болай...
Галиябану. Бетәсе беткән инде.
Марат. Нәрсә булган ул чаклы? Җиткән кыз белән ана еш кына килешә алмыйлар инде ул. Син аны һаман да бала итеп күрергә телисең. Кулыңа алып сөясең, алдыңа утыртып чәчен тарыйсың килә. Ул киреләнә.
Галиябану. Әкият сөйләп утырма, ичмасам.
Марат. Әкият түгел, ул – мәңгелек проблема. Аталар һәм балалар. Тимә, яшәсен үзенчә. Аңа инде егерме җиде яшь. Картаеп бара торган кыз. Холкының кәнфит булмавы табигый. Кайбер кыланышларын күрмә, кайбер сүзләрен ишетмә.
Галиябану. Күрмә... Ишетмә... (*Халат кесәсеннән бер бит кәгазь чыгарып.*) Моны да күрмәскәме? Моны да ишетмәскәме?
Марат. Нәрсә ул?
Галиябану. Заявление.
Марат. Нинди заявление?
Галиябану. Кызың язган. Судка. Өстәлдә калдырып киткән.
Марат. Йә, күрсәт әле. (*Кәгазьне алып укый.*)

«В .......................... районный суд
Истица: Гарифуллина Гузель Маратовна,
проживающая по адресу: ул.Юкачева, д.195, кв.13
Ответчики: отец – Гарифуллин Марат Закирович,
мать – Гарифуллина Галиябану Халиловна

*Исковое заявление (о возмещении морального вреда)*

Мои родители Гарифуллин М.З. и Гарифуллина Г.Х. родились и проживали в деревне. Приехали учиться в Казань. После окончания института поженились, не имея квартиры.
Я родилась 20 октября 1974 года в общежитии, где проживали тогда мои родители.
Ничего хорошего в детстве я не видела. Когда мне исполнилось 10 лет, отцу дали двухкомнатную квартиру. Отец привез из деревни свою маму – мою бабушку, и мы в четвером стали жить в этой

тесной квартире. По настоянию родителей я поступила на юридический факультет Казанского государственного университета.

Потекли полуголодные, необеспеченные студенческие годы. Высшее образование не дало никакого улучшения жизни. Пять раз устраивалась на работу. Пять раз меня выгоняли. Наконец я поняла – честные юристы обществу не нужны.

По Закону от рождения я имею право на выбор места жительства, работы, на достойную жизнь, уважение своей личности.

Однако всего этого я была лишена по вине моих родителей. Решив родить ребенка, они думали лишь о себе, исходили только из личных отношений и чувств друг к другу, совершенно упустив из внимания, что ждет их ребенка в таком необустроенном государстве. Когда люди думают только о себе, не обращая внимания на окружающих, страдают другие.

В результате необдуманного поступка родителей, захотевших иметь ребенка в такое время, я постоянно претерпеваю моральный вред, заключающийся в моих нравственных страданиях. Мои родители проживают в невыносимых жилищных условиях и получают мизерную заработную плату, и то не вовремя. Я лишена чувства гордости. Разве я могу гордиться своими родителями? Стесняюсь своего положения, родственников и условий своей жизни.

Во всем этом я виню своих родителей и считаю, что они должны возместить мне моральный вред в достаточном количестве для достойной жизни для своего ребенка.

Руководствуясь ст. 151 ГК РФ, Суд

Прошу взыскать с моих родителей Гарифуллина Марата Закировича и Гарифуллиной Галиябану Халиловны в мою пользу возмещение морального вреда.

Истица: Гарифуллина Г.М.».

(*Озак кына кәгазьгә карап торганнан соң.*) Кызык. Бик кызык бу. «Взыскать с моих родителей...» Өстәлдә калдырганмы? Нигә өстәлдә калдырган? Нигә судка илтеп бирмәгән?

Галиябану. Черновик икәнен күрмисеңмени?

Марат. Кызык. Нигә ертып ташламаган караламасын?

Галиябану. Тотынды инде, тотынды... нигә?.. Нигә?.. Синең белән мин укысын дип.

Марат. Йә, укыдык. Шуннан?..

Галиябану. Ничек «шуннан»?..

Марат. Шуннан без нишләргә тиеш инде? Син һуштан язып егылырга, мин йөрәкне тотып валидол кабарга тиешме?

Галиябану. Син ни сөйләгәнеңне беләсеңме?

Марат. Мин нишләгәнемне һәрвакытта да бик яхшы беләм, Галиябану, сылуым-иркәм. Әгәр дә мин нишләгәнемне белмәсәм, сине әллә кайчан аерып җибәрергә тиеш идем. Ә мин сине һаман да яратам. Менә сез аналы-кызлы чынлап та нишләгәнегезне белеп бетермисез һәм белергә дә теләмисез.

Галиябану. Акыл сатма. Укыдың бит нәрсә язганын.

Марат. Укыдым. Иркәлектә үскән эгоист кызның чираттагы әкәмәте.

Галиябану. Булыр әкәмәт, суд булса...

Марат. Бернинди дә суд юк. Кызың сине куркыта. Синең аңа карата булган кайнар һәм эчкерсез мәхәббәтеңнең чынлыгын, ихласлыгын сыный. Шуңа күрә ул аны өстәл өстендә калдырып киткән. Үзе рәхәтләнеп берәр дустында кофе яки сухое вино эчеп утыра.

Галиябану. Вино эчми ул. Дуслары да юк аның.

Марат. Каян беләсең?

Галиябану. Белмәскә. Син генә ул тарихыңа кереп чумдың. Мең ел элек ни булганын тикшерәсең, бүген үз кызыңның нишләгәнен белмисең.

Марат. Укытучы сүзе сөйләмисең, Галиябану, сылуым-иркәм... Син, Галиябану, татарның бер әйтемен беләсеңме? Ни ди ул? Анасына карап кызын ал, атасына карап улын сайла, ди. Мин бит ашлап, су гына сибеп тордым. Алмасы үзеңнеке бит. Мультфильмда әйтелгәнчә, «Хотите ли, не хотите ли, мы ваши дети, товарищи родители!» Кайда соң әле үзе?

Галиябану. Дустында кофе эчәдер.

Марат. Менә афәрин. Шаярта башладың. Дөньяга бераз көлебрәк кара, Галиябану, сылуым-иркәм. Әнкәй!..

Үз бүлмәсеннән Мөслимә чыга.

Әнкәй, кая киткәнен әйтмәдеме Гүзәл?

Мөслимә. Әйтмәде.

Марат. Кайчан чыгып китте?

Мөслимә. Сез төшке ашны ашап киткәч тә. Улым, карагыз әле сез ул баланы. Килен, син дә бик талкыма аны. Әллә нишләде бит. Тик торганнан шаркылдап көлә...

Марат. Сиңа бер сүз дә әйтмәдеме?

Мөслимә. Юк. (*Китәргә җыена.*)
Марат. Утыр монда гына, әнкәй. Нигә һаман саен шунда кереп бикләнәсең?
Мөслимә. Анда җайлы. Сезнең үз сүзегез.
Марат. Үзебезнең генә түгел шул.
Галиябану. Кирәкми. Нигә кирәк ул әнкәйгә.

Мөслимә бүлмәсенә кереп китә.

Нишлибез?
Марат. Нишлибезме? Чәй эчәбез. (*Ишек ачылганны сизеп.*) Кайтты бугай. Син сабыррак, Галиябану. Кил әле, утыр әле минем яныма. Кабыз әле телевизорны.

Телевизор караган булып утыралар.
Гүзәл керә.

Гүзәл. Кызыкмы?
Марат. Бик озак йөрдең.
Гүзәл. Җибәрмәде.
Марат. Кем?
Гүзәл. Президент.
Марат. Нәрсә, эшкә алдымыни?
Гүзәл. Алды шул.
Марат. Кем итеп?
Гүзәл. Моника Левински итеп.
Марат. Котлыйм.
Гүзәл. Рәхмәт. (*Бүлмәсенә кереп китә.*)
Галиябану. Нәрсә син?..
Марат. Утыр тыныч кына...
Галиябану. Ничек тыныч кына утыра алыйм?
Марат. Чәй куй алайса.
Галиябану. Сөйләшергә кирәк.
Марат. Ашыкма.
Галиябану. Син гомер буе – ашыкма да ашыкма, тынычлан да сабыр ит. Шуның аркасында шушы көнгә калдык инде. (*Гүзәл бүлмәсенең ишеген ачып.*) Чык әле монда. Кемгә әйтәләр.
Гүзәл (*чыгып*). Йә, нәрсә?.. Анда барысы да язылган.
Галиябану. Нәрсә язылган?
Гүзәл. Укыгансыз ич инде.
Галиябану. Укыдык шул, укыдык. Аңлатып бир.
Гүзәл. Анда аңламаслык берни дә юк. Мин аны судка илтеп бирдем.
Галиябану. Бирдең?!
Гүзәл. Нигә гаҗәпләнәсең? Шуның өчен язылган бит. Сезгә көтелмәгән хәл булмасын дип, копиясен өстәлдә калдырдым. Укысыннар, фикер алышсыннар дип кайтмыйча йөрдем. Менә кайттым.
Галиябану. Марат...
Марат. Әйттем бит мин сиңа тынычлан дип.
Галиябану. Ничек тынычланыйм. (*Елый.*) Ничек тынычланыйм?! Ишетмисеңмени?!
Гүзәл. Әгәр скандал чыгарырга җыенсагыз, керәм дә бикләнәм. Күз яшьләрен күп күрдем инде мин.
Галиябану. Нәрсә күрдең, нәрсә күрдең? Чынлап та илтеп бирдеңме судка?
Гүзәл. Әйттем ич инде.

Галиябану үкереп елап чыгып китә.

Марат. Бар, тынычландыр әниеңне.
Гүзәл. Ничек тынычландырыйм мин аны?
Марат. Ничек җылаттың, шулай тынычландыр.
Гүзәл. Ул һәрвакыт җылый. Аның бердәнбер аргументы – җылау. Нишләтим мин аны?
Марат. Син җылаганда ул нишли иде соң?
Гүзәл. Мин җылаганымны хәтерләмим.
Марат. Бик иртә башланган синдә склероз. Утыр әле.
Гүзәл. Тик акыл сатма. Мин заявлениедә язылганнан артыгын өсти алмыйм, һәм мин аны чыннан да судка илтеп бирдем. Кире алырга җыенмыйм. Карап торма миңа алай. Мин барысына да әзер.
Марат. Барысына дамы?
Гүзәл. Барысына да.
Марат. Син болай үзеңне безнең бала икәнеңне таныйсыңмы соң?

Гүзәл. Анда язылган.
Марат. Нәрсәләр яздың дип сорамыйм, нигә яздың?
Гүзәл. Анысы да әйтелгән.
Марат. Бары тик шул гынамы? Сиңа акча гына кирәкме?
Гүзәл. Миңа компенсация кирәк.
Марат. Ул компенсация акчадыр бит инде? Әллә бүтән нәрсә дә таләп итәсеңме бездән?
Гүзәл. Анысын суд хәл итәр.
Марат. Нигә аны суд хәл итәргә тиеш? Син юрист кеше. Юриспруденция төгәллекне ярата. Бәлки, сиңа бу фатир да кирәктер?
Гүзәл. Нигә әле мин монда сезнең надзор астында яшәргә тиеш? Күпме яшәргә мөмкин бу камерада?
Галиябану (*ишектә күренеп*). Оятсыз син! Без яшибез бит әле.
Гүзәл. Сездә минем ни эшем бар? Моңардан да начарына күчәрсез дә яшәрсез. Мин теләмим.
Марат. Бик яхшы. Нигә аның өчен суд кирәк булды? Әйтергә иде безгә, мин сезнең белән бергә яшәмим, дияргә иде.
Гүзәл. Мин суд аша телим. Чөнки эш акча белән фатирда гына түгел. Сез җавап бирергә дә тиеш. Суд алдында.
Марат. Ни өчен?
Гүзәл. Кылган җинаятегез өчен.
Марат. Нинди җинаять?
Гүзәл. Җинаять. Сез мине тудырмаска тиеш идегез.
Галиябану. Ни сөйлисең син, кызым? Марат, ни сөйли ул?
Марат. Менә монысы кызык. Димәк, без әниең белән сине бу дөньяга тудырып җинаять кылдык? Ялгышлыкмы, җинаятьме?
Гүзәл. Җинаять.
Марат. Аңлатып бирәсеңме соң?
Гүзәл. Тик әнигә әйт, кычкырмасын.
Марат. Кычкырмас.
Гүзәл. Сез кайсы илдә яшәгәнегезне белеп тудырдыгызмы мине? Белеп. Чөнки син КПСС тарихы буенча диплом яклаган кеше. Хатыныңның һәм үзеңнең беркемгә дә кирәге юклыгын белдегезме? Белдегез. Чөнки кирәк булган кешегә рәтле хезмәт хакы түлиләр. Мине тудырганда, сез тулай торакның бер почмагында яшәдегез. Сезне кудылар тулай торактан, бушатыгыз бүлмәне, диделәр. Шулаймы? Сез фатир сорадыгыз, бирмәделәр. Шулаймы? Киләчәктә дә рәтле-юньле фатир булмаячагын сез белдегезме? Белдегез. Киләчәктә дә сезнең ишелергә рәтле тормыш булмаячагын белдегезме? Белдегез. Шуларны белгән килеш нигә сез дөньяга тагын бер мескенне тудырдыгыз? Җинаять түгелме бу?

Пауза.

Марат. Әйе... Дәвам итәсеңме?
Гүзәл. Судта сөйләргә дә калсын.
Марат. Син бит юрист. Рәсми судка хәтле безгә хөкем карарыңны чыгар.
Гүзәл. Ә син көлмә. Син башыңны юләргә салып көләсең дә шамакайланасың. Синнән клоун ясаганнар, көлдерер өчен. Син менә шушы ике бүлмәле хрущевкага канәгать. Әни, ичмаса, җылый, син көләсең. Мине дә гомер буе көләргә өйрәттең. Минем көләсем килми башлады. Сез бетәргә тиеш идегез. Сезнең нәсел калдырырга хакыгыз юк иде.
Галиябану. Марат...
Гүзәл. Сез мине тудырып, миннән курчак ясап уйнадыгыз. Менә үсеп җитте ул курчак. Кемгә кирәк мин? Ирәүгә дә кирәкмим. Хәтта сезгә дә кирәкмим. Берегез кычкыра, икенчегез мыскыллап көлә. Бер сиксән яшьлек карчыкка гына кирәк мин. Ул гына миңа кызганып карый. Улының җинаятен ул гына аңлый.
Марат. Бәлки, мине дөньяга китереп ул да җинаять эшләгәндер?
Гүзәл. Бәлки. Ләкин анысы сезнең проблема.
Марат. Әниең белән минем арадагы мәхәббәт тә безнең проблема инде, әйеме? Бәлки, анысы да җинаятьтер?
Гүзәл. Минем философия белән шөгыльләнергә вакытым юк.
Марат. Ә синең безне судка бирүең философия түгелмени? Әгәр биргән булсаң, ал ул заявлениеңне. Кәмит ясама. Җинаять кылганбыз икән, үзең хөкем ит. Бүтәннәрнең безнең җинаятьтә катнашы юк. Менә сиңа ике бүлмәле хрущевка, ал, без берәр почмак табарбыз. Акча вәгъдә итә алмыйм, аның урынына җиһазларны калдырырбыз. Ачуланмасаң, тагын бер генә сорау бирим. Менә без – әниең, әбиең, мин – һәрвакыт булмаса да, чәй өстәле янында дөнья, кешеләр, яшәү мәгънәсе турында

сөйләшеп утырабыз. Бала чагыңнан ук син дә безнең янда. Безнең сөйләшкән сүзләрнең беразы гына да синең колакка кермәдемени?

Гүзәл. Берәүгә дә кирәкмәгән татар теленә өйрәттегез. Берәүгә дә кирәкмәгән намус турында сөйләп мине алдадыгыз.

Марат. Бүтән соравым юк. Без чыннан да җинаятьчеләр. Ни телисең, шуны эшлә. Без үзебезне яклап маташмаячакбыз.

Галиябану. Нишлисез сез? Ни сөйлисең син, Марат?

Марат (*Гүзәлгә*). Сезгә китәргә мөмкин, Гүзәл Маратовна. Минем сезгә бүтән соравым юк. Әйтәсе сүзегез булса, әйтегез.

Гүзәл. Юк.

Галиябану. Марат!.. Кызым!.. Туктагыз! Кызганыгыз мине. Үзегезне кызганмасагыз, мине кызганыгыз. Кешеләр арасына ничек чыгыйм? Укучыларым күзенә ничек күреним? Гомердә булмаган хәл бит бу. (*Гүзәл алдына тезләнеп.*) Кызым! Бәгырькәем! Нишләдең син?! Нишлисең син? Нишлисез сез? Кызым!.. Тыңла! Аягың астында туфрак булырмын. Хур итмә.

Марат (*Галиябануны күтәреп торгызып*). Галиябану! Булды! Җитте! (*Гүзәлгә.*) Кит! (*Гүзәл киткәч.*) Булды, Галиябану. Йә, йә. Булды, диләр.

Галиябану. Син! Син гаепле барысына да...

Марат. Әйе, әйе, мин... Мин гаепле, тик тынычлан гына.

Галиябану. Син узындырдың аны.

Марат. Әйе, мин... Әлбәттә, мин.

Галиябану. Теләсә ни әйтергә, теләсә ни эшләргә ирек бирдең. Мөстәкыйль фикер йөртергә өйрәнсен, дидең.

Марат. Әйе, әйе... Шулай... Син тынычлан гына.

Галиябану. Нишләтәләр инде безне хәзер?

Марат. Әйдә.

Галиябану. Кая?

Марат. Йөреп керик. Пристаньга төшеп пароходлар карап кайтыйк.

Галиябану. Ничек син... шундый чакта?..

Марат (*тавышын күтәреп*). Әйдә, дидем. (*Бүлмәдән чыккан Мөслимәгә.*) Әнкәй, без йөреп керәбез.

Мөслимә. Соң бит инде.

Галиябану. Әнкәй, син ишеттеңме?

Мөслимә. Юк. Берни дә ишетмәдем. Ишетәсем дә килми. Мин инде сүз тыңлап туйган.

Галиябану. Гүзәл бит...

Мөслимә. Әйтмә, килен. Кирәкми. Беләсем дә килми. Дөньягызның рәте юк. Такталары черегән идәндә йөргән кебек йөрисез. Бетеренмә, килен, син генә түгел. Телевизорыгызда күрсәтеп торалар. Шул телевизор баш булды адәм баласына. Телевизор ни күрсәтсә, шулай эшлиләр адәм балалары. Ата юк, ана юк, бала юк. Кешенең башыннан күбрәк артын күрсәтәләр телевизорда. Әй Алла! Үзең саклый күр. Ышаныч бер синдә генә.

Марат. Син бик борчылма инде, әнкәй.

Мөслимә. Борчылма дип, улым... Барыгыз барасы җирегезгә.

Марат. Киләсе ялда авылга кайтып килербез, әнкәй. Аннан отпуск алырбыз да бергәләп... Авылны да сагынасыңдыр.

Мөслимә. Сагынмадым. Берсе дә кирәкми.

Марат. Алай димә инде, әнкәй.

Мөслимә. Ярый, барыгыз, бар. Килен, бәргәләнмә. Бер-берегезгә тотыныбрак йөрегез.

Марат белән Галиябану чыгып киткәч, бүлмәдә әрле-бирле йөренә. Әле бер нәрсәгә тотынып, әле икенчесен алып тәртип салмакчы була. Гүзәл
чыгып телевизорны кабыза.

Мөслимә. Сүндер. Сүндер шул тәрене. Шуңа карап җенләнәсең. (*Телевизорны сүндереп.*) Утыр әле.

Гүзәл. Син дә акыл өйрәтергә җыенасыңмы?

Мөслимә. Юк, үземә җитмәгән акылны нишләп сиңа өйрәтим.

Гүзәл. Рәхмәт, әбекәем. Алдыңа яткыр әле, әбекәем. Башымнан сыйпа әле. Син ачуланма, әбекәем. Мин нәрсә эшләгәнемне белеп эшлим. Бүген кычкырганым өчен гафу ит, ярыймы?

Мөслимә. Үзең беләсеңдер. Син укыган кеше.

Гүзәл. Укымаска кирәк булган миңа. Миңа бик авыр, әбекәем. Мин җүләрләнермендер, ахрысы.

Мөслимә. Юкны сөйләмә. Зур кыз инде син.

Гүзәл. Мин гаепле түгел, әбекәем.

Мөслимә. Түгел, түгел. (*Телефон шылтырагач.*) Шылтырата да шылтырата. Сөйләш син анның белән, кызым. Начар кеше түгел бит.

Гүзәл (*трубканы алып*). Әйе, мин. Йөз тапкыр, мең тапкыр ишеттем бит инде. Беләм, яратасың. Мин нишләргә тиеш? (*Бер фикергә килеп.*) Карале, кил син безнең өй янына, каршы ал мине.

Пәрдә.

**ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ**

АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Урам. Анда Надир таптана, Гүзәлне көтә. Саташкан әби үтеп бара. Надирны күреп туктый да текәлеп карап тора.

Надир. Исәнмесез, әбекәй!

Саташкан әби. Сөбханалла, таныды. Исәнләште. (*Сумкасында актарынып вак акча ала.*) Бисмиллаһи-рахманир-рахим. Мәле, дога кылырсың. Йөрим-йөрим, садака бирерлек кеше юк. Алмыйлар. Садака ияләре бетте.

Надир. Әбекәй, мин дә садака иясе түгел.

Саташкан әби. Исәнләштең ләбаса. Мин әйтәм «исәнмесез» дип, җавап кайтаручы юк. Чабалар да чабалар, чабалар да чабалар. Миннән алда барып җитәбез диләрмедер. Садака бирерлек кеше юк. Хәерчеләр күп, садака ияләре юк. Садака иясе дип карыйсың – ят кеше. Урам тулы ят кеше. Өй тулы ят кешеләр. Барам да барам, бер үз кеше юк. Ятлар арасында ничек йөрмәк кирәк. Кайтам әле. Үз итмәсәләр дә кайтам. Баргач, кайтырга кирәк ич инде.

Сөйләшеп чыгып китә. Надир кулындагы тиенгә карап кала. Гүзәл керә.

Гүзәл. Нихәл? Көттеңме?

Надир. Исәнме, Гүзәл.

Гүзәл. Әйдә тизрәк.

Надир. Кая?

Гүзәл. Бүлмәңә.

Надир. Бүлмәгә? Ни булды әле? Күпме чакырып та керми идең.

Гүзәл. Бу юлы керәм. Керәбез, чишендерәсең һәм... Аннан куып чыгарасың.

Надир. Тукта әле, Гүзәл.

Гүзәл. Туктамыйм. Әйткәнне эшлә.

Надир. Әйткәнне дип... Болай булмый торгандыр ул, Гүзәл. Миннән көләргә, мыскыл итәргә телисеңме? Кирәкми, мин инде болай да... Сине яратканыма минем гаебем юк.

Гүзәл. Мин чынлап... Синең яратуыңа мин ни белән булса да түләргә тиеш. Бөтен нәрсә товарга әйләнгән заманда. Кияүгә чыкмыйм мин сиңа. Балабызның безне судка бирүен теләмим. Син саф кеше, әмма ләкин кызганыч кеше.

Надир. Син әллә нишләгән, Гүзәл. Изге нәрсәләр турында шулай сөйләшү...

Гүзәл. Нинди изге? Кайда ул изгелек? Акыл сатма. Дөньяга күтәрелеп кара. Мин инде төштем күктән. Саташып йөрдем дә төштем. Бөтенләем белән иблискә әйләнгәнче сиңа бер яхшылык эшлисем килә. Мин бит аңлыйм – син яратасың мине.

Надир. Син әллә исерекме?

Гүзәл. Исерек? Кара, кызык сүз әйттең бит әле. Әйдә эчәбез. Нигә карап торасың? Озак итеп карап торма. Соңга каласың.

Надир. Минем җитешмәгән якларым күптер, Гүзәл. Әмма син миннән көлмә.

Гүзәл. Көлмим, Алла бәндәсе. Мин сиңа бирелергә килдем, аңла. Аңла, мокыт! (*Надирны уңлап-суллап яңаклый.*)

Надир. Нишлисең син? (*Гүзәлнең кулларын эләктереп ала.*)

Гүзәл. Җибәр.

Надир. Нишлисең син, Гүзәл? Алай булмый бит. Без бит хайваннар түгел.

Гүзәл. Синме хайван түгел? Ишәк син.

Надир. Рәхмәт. Менә, ниһаять, дөресен әйттең. (*Китәргә борыла.*)

Гүзәл. Кая барасың?

Надир. Абзарыма.

Гүзәл. Китмә.

Надир. Юк, Гүзәл. Гафу ит, әлбәттә.

Гүзәл. Алып кит мине.

Надир. Юк.

Гүзәл. Үкенәчәксең.

Надир. Мин инде күп үкендем. Ничә ел минем белән уйныйсың.
Гүзәл. Менә хәзер барам да берәрсе астына ятам.
Надир. Үзеңә кара.
Гүзәл. Нигә шылтыраттың алайса?
Надир. Сагынып.
Гүзәл. Менә килдем.
Надир. Миңа синең болай килүең кирәкми. Бу кыяфәттә син миңа ят кеше. Хуш!
Гүзәл. Үкенәчәксең. Яратасың бит мине.
Надир. Яратам. Ярата идем.
Гүзәл. Хәзер дә яратасың. Яратуың бәрабәренә син нидер алырга тиеш. Ал мине. Бүтәннәр бит яратмаган килеш тә алалар.
Надир. Мин сине аңлый алмый интектем, Гүзәл. Инде аңладым шикелле.
Гүзәл. Кем соң мин?
Надир. Садист. Кеше газаплаудан тәм табасың.
Гүзәл. Мин аны синнән яшермәдем дә. Синең томана булуыңа мин гаеплеме? Син мазохист бит. Газапланудан тәм табасың. Сиңа рәхәт булсын дип тырышам мин. Хәер, без барыбыз да мазохистлар. Безне изәләр, безгә рәхәт. Укы әле «Якуп агай эшләпәсен». (*Надир эндәшмәгәч.*) Нинди кешеләр соң сез? «Килмә» дисең, киләсез, «мә» дисең, алмыйсыз, «укыма» дисең, укыйсыз, «укы» дисәң... Бар кит, күземә күренмә. (*Надир китә башлагач.*) Һәм шулай тыныч кына китәсеңме? Китәсең килеп китәсеңме?
Надир. Китәргә кирәк булганга китәм.
Гүзәл. Һәм мине төнге урамда ялгызымны гына калдырасыңмы?
Надир. Сиңа ялгызлык килешәрәк төшә.
Гүзәл. Кызганмыйсыңдамы?
Надир. Юк. Бүтән мин сине эзләп килмәячәкмен.
Гүзәл. Соңгы сүзеңме?
Надир. Соңгы сүзем.
Гүзәл. Шагыйрь түгел син.
Надир. Түгел. (*Китеп бара.*)
Гүзәл. Китмә.

Ләкин Надир инде киткән.

Кабахәт! Кабахәтләр!

Харис үтеп бара. Гүзәлне күреп туктый.

Харис. Нишләп торасың, күрше? Әллә сөйгән ярың килмәдеме? Әйдә, кайтабыз.
Гүзәл. Юлыгызда булыгыз.
Харис. Менә сине күреп туктадым әле. Авыз кыйшаеп калды. Яңакның бу ягына да суктырырга иде.
Гүзәл. Китегез.
Харис. Сук та китәм. Нигә шулай карап торасың? Ай-яй, карашларың синең, күрше! Без кебек. Бигрәк тә яратмыйсың инде Харис абыеңны.
Гүзәл. Яратсам, нишләр идең соң?
Харис. Менә монысы яхшы. «Син» дип сөйләшә башладың. Югыйсә җиде ятка эндәшкән кебек – «сез, сез».
Гүзәл. Әйт, яратсам, нишләр идең?
Харис. Аның бер генә юлы – мин дә яратыр идем.
Гүзәл. Йә, яратып күрсәт. Минем яратыласым килә.
Харис. Шулайдыр. Күпме түзәргә була... Сине эшеңнән киткән диләр.
Гүзәл. Китмәдем. Кудылар. Жулик дигәнем өчен.
Харис. Миңа киләсеңме соң эшкә?
Гүзәл. Син дә куачаксың.
Харис. Ни өчен?
Гүзәл. Жулик дигәнем өчен.
Харис. Юк. Дөресен әйткән өчен мин үч алмыйм. Миңа «оятсыз» дидең, исем дә китмәде. Чөнки дөресе шулай. Оялып торсаң, бәхетеңне алып китүләре бар. Заманасы шундый.
Гүзәл. Мин, яратып күрсәт, дидем. Син акыл сатасың.
Харис. Күрсәтербез, күршекәем. Ярата беләбез без.
Гүзәл. Минем бүген, менә хәзер яратыласым килә.
Харис. Хәзер үкме?

Гүзәл. Хәзер үк.
Харис. Киттек минем дачага. Машина көтеп тора.
Гүзәл. Дача синеке генә түгел, Фәридә Хафизовнаныкы да.
Харис. Фәридә апаң өйдә бит.
Гүзәл. Чынлап торып алып китәр идеңме?
Харис. Нәрсәсе бар?
Гүзәл. Баручылар бармы?
Харис. Анысын инде баргач сорашырсың.
Гүзәл. Курыкмыйсыңдамы?
Харис. Кемнән?
Гүзәл. Фәридә Хафизовнадан. Судья бит.
Харис. Фәридә апаң бүтәннәр өчен генә куркыныч.
Гүзәл. Әгәр мин аңа әйтсәм?
Харис. Әйтмисең. Әйтсәң дә, ул ышанмый. Ышанса да, берни эшли алмый.
Гүзәл. Чыннан да оятсыз син, Харис абый.
Харис. Мин генә түгел. Мин, оятсыз булсам да, алдашмыйм бит. Берәү булса, әллә кайлардан әйләндереп сөйләр иде. Үлеп гашыйк булдым, дип, башыңны әйләндерергә тырышыр иде. Син ышаныр идең. Аннан соң, алдандым, дип елар идең. Мин алдашмыйча әйтәм: сине кочаклыйсым килә, дим. Син бит унбиш яшьлек кыз түгел. Киттекме? (*Фәридәне күреп алып.*) А-а-а, карчык. Мин инде сине эзләп чыккан идем. Менә күрше кызын очраттым да, син онытылдың. Арыдыңмы, карчык?
Фәридә. Эш күп. Исәнме, Гүзәл.
Харис. Мин әйттем аңа, карчык. Ярамый алай, дидем.
Фәридә. Ярый, әйдә кайтабыз.
Харис. Кайтабыз, карчык, кайтабыз. Балалар сагынгандыр.
Фәридә. Син өйдә булмадыңмыни?
Харис. Минем дә эш күп булды, карчык. (*Гүзәлгә.*) Әйткәнне тыңла, Гүзәл. Ярамый алай.

Гүзәл көлә.

Фәридә. Нидән көләсең, Гүзәл?
Гүзәл. Болай гына. Дөньяда яшәве рәхәт бит, көләсе килеп кенә тора. Эшне нигә сузасыз, Фәридә Хафизовна?
Фәридә. Синең акылга килгәнеңне көтәм.
Гүзәл. Мин үз акылымда.
Фәридә. Юк, Гүзәл сеңелем, юк. Иблис акылы белән йөрисең.
Гүзәл. Мыскыл итмәвегезне үтенәм.
Фәридә. Дөреслек ошамый мәллә?
Гүзәл.Ошамый. Чөнки ул юк.
Фәридә. Шуны исбатларга телисеңме?
Гүзәл. Ул инде исбатланган. Аксиома.
Фәридә. Алайса, нигә суд?
Гүзәл. Анысын суд утырышында әйтермен.
Фәридә. Оялмассыңмы?
Гүзәл. Кемнән оялырга? Сездәнме? Харис абыйданмы?
Фәридә. Харис абыеңның монда ни катнашы бар?
Гүзәл. Оят турында әйттегез бит.
Фәридә. Ни әйтергә телисең?
Харис. Мин кайта торам, карчык. Алай ярамый, Гүзәл сеңелем, ярамый. Суд белән уйнарга ярамый. (*Китеп бара.*)
Фәридә. Нәрсә, сеңелкәем, үзегезнең гаиләне пыран-заран китердең дә, безнекенә тотындыңмы?
Гүзәл. Бик матур яшисез бит, көнләштем. Ирегез сезне бигрәк ярата.
Фәридә. Анда синең эшең юк.
Гүзәл. Ничек булмасын ди? Чөнки ул мине дә ярата.
Фәридә. Шуннан?
Гүзәл. Оят турында кузгаттыгыз.
Фәридә. Нишләвең бу, Гүзәл? Нишләргә җыенасың син?
Гүзәл. Нишләргә җыенуым заявлениедә язылган. Ә сез миңа оят турында акыл сатасыз. Шуңа җавап кына бирдем. Миңа акыл да, киңәш тә кирәкми. Шуңа күрә барлы-юклы акылыгызны сатмыйча гына вазифагызны үтәгез.
Фәридә. Бик яшь бит әле син, Гүзәл. Әйе, бәлки, син хаклысыңдыр. Чыннан да... Оятсыз заман. Оятсызлар көннән-көн күбәя. Нәрсә, Харис абыең?

Гүзәл. Белмисезмени?
Фәридә. Беләм лә... Ярый... Яшәргә кирәк бит... Син безгә тимә инде, Гүзәл.
Гүзәл. Нигә мин сезгә тияргә тиеш...
Фәридә. Ничек дип әйтим... Син теләсә ни эшләргә сәләтле.
Гүзәл. Оятсызмы?
Фәридә. Юк ла инде... Ләкин... Мине аңлыйсың инде.
Гүзәл. Әлбәттә, аңлыйм. Кирәкми миңа, Фәридә апа, пычрак Хафизыгыз. Үрнәк гаилә булып яши бирегез. Тик мине генә оялтырга алынмагыз. Җинаятьләр кодексыннан читкә чыкмагыз.
Фәридә. Шулай да куркыныч кеше син, Гүзәл.
Гүзәл. Куркаклар өчен куркыныч. Сез нигә куркасыз? Сез бит миннән дә куркынычрак кешеләрне хөкем итәсез.
Фәридә. Алардан курыкмыйм, синнән куркам
Гүзәл. Димәк, үзегезне гаепле итеп тоясыз. Гаеплеләр генә курка. Суд кайчан булачак, Фәридә Хафизовна?

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Гарифуллинар фатиры. Марат белән Галиябану янәшә утырганнар да телевизор карыйлар. Телевизорда кемдер сөйли: «Великая неделимая Россия всегда будет великой державой. Великий наш народ никогда не позволит...»

Галиябану. Казан нишли?

Марат телевизорны Казан тапшыруына күчерә. Казан Татарстанның халык артисты тавышы белән: «Мин хәзер шындый аникдут сүлим. Ха-ха-ха...»

Галиябану. Сүндер.
Марат. Тукта, ни сүләр икән.
Галиябану. Ни булсын инде. Ул оятсыз мәзәк сөйлиячәк, зал кешнәячәк.
Марат (*телевизорны сүндереп*). Син артык җитди, Галиябану. Дөньяның синеңчә генә баруын телисең. Дөньяны ничек бар шулай кабул итәргә кирәк.
Галиябану. Җайлашыргамы?
Марат. Кирәк булса, җайлашасың да инде ул.
Галиябану. Нигә үзең җайлашмыйсың соң алайса? Татар тарихын бозып язучылар белән бәхәсләшәсең?
Марат. Мин намусыңа каршы барып җайлашу турында әйтмим. Авырлыкларны уен-көлке белән уздырырга кирәк, дим.
Галиябану. Җүләр сатма инде. Шушы хәлдә ничек көлеп утыра алыйм мин?!
Марат. Көлмәсәң дә бәргәләнмә. Җәтмәгә эләккән балык чәбәләнгән саен күбрәк чорнала. (*Ишегеннән чыгып үтеп барган Мөслимәгә.*) Әнкәй, чыгып утыр безнең янга.
Мөслимә. Намаз вакыты җитте.
Марат. Ходай белән генә сөйләшергә димәгән, безнең белән дә сөйләш.
Мөслимә. Үзең укыган кеше, үзең – мәгънәсез. (*Чыгып китә.*)
Галиябану. Менә синең уен-көлкең.
Марат. Әллә соң без дә әнкәйгә иярикме? Бердәнбер ышанычлы зат Ходай калды. Намазлыкка тезләнеп аңардан мәрхәмәт сорарга дыр, бәлки? (*Галиябануның елаганын күреп.*) Йә инде, нишлисең инде?
Галиябану. Юатма. Рәхәтләнеп җыларга да ирек бирмисең, һаман юатасың, һаман юатасың.
Марат. Нәрсә, мин дә кушылып җылыйммыни?
Галиябану. Җыламаслыкмы?
Марат. Йә, йә, булды, тынычлан. Яшисе бар бит.
Галиябану. Яшәүнең мәгънәсе югалды. Нигә яшәргә?
Марат. Нигәме? Нигә яшәдек соң? Нәрсә, хәзер инде барысын да сызып ташларгамы?
Галиябану. Сызылды бит, Марат.
Марат. Нигә әле син яшәвебезнең бөтен мәгънәсен бер Гүзәлдән генә эзлисең? Нишләтәсең, син һәм мин теләгәнчә булмады. Без теләгәнчә генә булса иде ул. Әни дә бит ни ди, Казанга алып килеп бикләп куйдың, ди. Үзеңнең дә бәхетең юк, көне-төне чабасың, чапканыңны күрүче юк, ди. Мин дә бит әни теләгәнчә генә яшәмәгән, димәк. Яңа буын үсә, Галиябану. Циниклар буыны. Тамырыннан аерылган буын. Монда безнең генә гаеп түгел. Без корбаннар гына, Галиябану. Кил монда якынрак. (*Галиябануны кочагына ала.*) Менә шулай. Бәргәләнмә, бәгырькәем. Безнең намусыбыз чиста, мәхәббәтебез дә саф иде, саф итеп сакладык. Хәтерлимсең? Мин сине болай гына, биергә пар кирәк

булганга гына танцыга чакырдым. Син дә теләр-теләмәс кенә риза булдың. Бер-беребезнең йөзенә карамый гына биедек. Шунда кинәт күзләребез очрашты, һәм син дә, мин дә бер-беребезгә гашыйк булдык. Күзләреңнән үземне күрдем.

Галиябану. Әйе. Биюдән туктадык. Мин оялдым. Курыктым да бугай әле. Качып йөрдем синнән. Кыргый идем шул мин. Холыксыз да идем. Рәхмәт инде сиңа, үзем кебек холыксыз кеше очраса, яши алмаган булыр идек.

Марат. Холыксыз түгел, Галиябану. Тынгысыз кеше син. Мин сине шуның өчен яраттым да. Хәтерлимсең, син исемеңнән ояла идең. Мин ул исемгә лаек түгел, дия идең. Галиябанулар, Хәлилләр, Таһирлар, Зөһрәләр яши иде бит безнең күңелдә. Алар югалды бүгенге буында, алыштырырга алмаш юк. Бушлык. Бушлык. Бушлык...

Таң әтәчләре кычкыра,
Әллә таң ата микән?
Тәрәз ачып карап калды
Галиябану, сылуым-иркәм,
Әллә ярата микән.

Җавап бир, Галиябану.

Галиябану. Кирәкми инде.

Марат. Урам аша чыккан чакта
Бүрәнәгә абындым.
Сәгате ай, минуты ел,
Галиябану, сылуым-иркәм,
Шулкадәрле сагындым.

(*Галиябануның тагын еларга җыенуын күреп.*) Йә, йә, йә, сабыр. (*Учы белән Галиябануның күзендәге яшьне сөртә.*)

Галиябану. Чаптык та чаптык шул. Мәхәббәт җимеше дә ачы була икән. Күпме көттек бит. Син булып син дә шатлыктан тилердең. Әллә соң дөньяда мәхәббәт дигән нәрсә юк микән, Марат? Булса, аның җылысы җимешенә дә күчәргә тиеш ләбаса. Син мине гаепләмә инде, ярыймы, Марат.

Марат. Ни өчен, Галиябану?

Галиябану. Гаеп миндәдер. Синең сүзләреңә колак та салмаганмын. Иркәләдем, якладым, узындырдым.

Марат. Юкны сөйләмә.

Галиябану. Бозасың баланы, дидең, тыңламадым. Хатын-кыз үзен һәрвакыт хаклы дип уйлый бит.

Марат. Хатын-кызның бөтен матурлыгы шунда да.

Галиябану. Син инде бигрәк. Үзең бит әйтәсең: Галиябану, нигә кистереп сөйлисең, синең ялгышуың да ихтимал лабаса, дисең.

Марат. Ирләрнең бөтен ахмаклыгы хатын-кызның ялгышын төзәтергә маташуда инде. Хатын-кызны акылга утыртам дип күпме ирләр алтынга тиң вакытларын әрәм итәләр, күпме нервы туздыралар.

Галиябану (*елмаеп*). Шулайдыр шул. Йөрәгең еш тибә.

Марат. Шундый чибәр хатынны кочаклап утыр да...

Галиябану. Кешеләр төсле ял итә дә белмисең.

Марат. Менә ич, итәм ич.

Галиябану. Син мине ачуланма, ярыймы? Әйдә авылыңа кайтып китәбез, Марат. Йортыгызны ремонтларбыз да... Әнкәйгә дә җан керер.

Марат. Юк инде, Галиябану. Без инде авыл кешеләре түгел. Авыл инде без сагынып сөйләр өчен юаныч кына. (*Узып барган Мөслимәгә.*) Әнкәй, утырып тор инде бераз гына. (*Мөслимәнең иңеннән кочып Галиябану янына утырта.*) Менә яраткан киленең янына утыр әле һәйбәтләп.

Мөслимә. Ник аны мыскыл итебрәк әйтәсең. Әллә яратмаганмы? Әллә урамга талашып чыкканмы?

Марат. Әллә нindиләр сез, берегезгә бер сүз әйтергә ярамый.

Мөслимә. Яраганын сөйлә. Укыган башың белән. Минем сүзем шул: ят итмәгез баланы. Бала өстенә кирәкмәгән сүз сөйләмәгез. Аның яшендә беребез дә остабикә түгел иде.

Галиябану. Аның яшендә дип. Егерме җиде яшь инде аңа. Университет тәмамлаган.

Мөслимә. Тәмамласа. Нәрсәгә укыталар соң университетыгызда? Кеше булырга укыталармы? Тимәгез балага. Җанын ашамагыз. Телдән биздергән, диннән яздырган илдә тугач нишләсен?!

Галиябану. Соң, әнкәй, суд булса...

Мөслимә. Булсын. Суд гел булып тора ул. Аңа карап җир өстенә кояш чыкмый калганы юк. Күрше Фәридәгә дә әйтегез, йөрмәсен җаныгызга тоз сибеп. Үз эшен генә эшләсен. Керә дә ах-ух килә. Әйтерсең аннан башка белмиләр.

Ишектә звонок.

Кайтты бугай. Адәм рәтле каршылагыз.

Ишекне ачарга китә. Надир белән керәләр.

Мөслимә. Кунакка чәй эчерегез. (*Бүлмәсенә кереп китә.*)
Надир. Исәнмесез!
Марат. Исәнме, туган! Уз әйдә. Гүзәл өйдә юк бит әле.
Надир. Мин сезнең янга килдем.
Марат. Әллә Гүзәлнең кулын сораргамы? Бирәбез, туган, бирәбез.
Галиябану. Марат... Утыр, Надир. (*Үзе чыгып китә.*)

Пауза.

Марат. Йә, эшләр ничек соң, Надир туган? Язып буламы? Кичә газетада шигыреңне күргәч, мактанып куйдым әле. Коллегаларга әйттем, бу шагыйрь белән таныш мин, дидем. Ничек әле?.. «Энекәшләр учак якты микән». Туктале, газета шул тирәдәдер. (*Өстәлдән газета эзләп алып.*) Менә ул. Ошады миңа. Бабайлар шигыренә охшаган охшавын, ләкин барыбер... (*Укый.*)

Күңелемә Ходай салган назлы сүзләр
Барысы да ияләрен тапты микән?
Өметләнеп иртә яздан чәчкән гөлләр
Бөтенесе җәен чәчәк атты микән?
Болыннарда уйнаклаган безнең тайлар
Үсеп җиткәч бәйгеләрдә чапты микән?
Сусаганда учлап-учлап суын эчкән
Чишмәләрнең суы һаман татлы микән?
Малай чакта дөньяларга без караган
Тәрәзәләр һаман шулай якты микән?
Юл чатында бездән калган энекәшләр
Су читендә төнге учак якты микән?

Надир. Марат абый... (*Туктап кала.*)
Марат. Йә, йә, оялма. Син инде бала түгел. Олы кеше. Шагыйрь.
Надир. Мин олыгая алмый интегәм, Марат Закирович.
Марат. Тумас борын картайганчы, сабый булып калу яхшырак ул. Сүзең Гүзәл турындамы?
Надир. Әйе. Ләкин безнең ике арадагы мөнәсәбәт турында түгел. Гүзәл үзгәрде. Начар якка. Белмим, сез аны беләсезмедер? Мин бик борчылам.
Марат. Дөрес, яраткан кеше борчылырга тиеш.
Надир. Эш яратуда гына да түгел.
Марат. Нәрсәдә соң?
Надир. Мин борчылам.
Марат. Димәк, яратасың. Димәк, нык яратасың. Начар якка үзгәргән кызлар күп бит, берсенең дә өенә борчылып бармагансың. Мин, гафу ит, күптән инде күзәтеп киләм, интектерә ул сине. Син түзәсең. Сукыр мәхәббәт дигән нәрсә шул буладыр инде. Ташла да кит син аны, туган.
Надир. Булмый.
Марат. Тегеләй дә булмый, болай да булмый, диген. Синең Гүзәлеңнең холкы ташка үлчим шул. Бер киңәш биримме үзеңә? Тотып кыйна син аны. Син юаш, хатын-кыз юашларны мактап сөйли, ләкин юашларны өнәп бетерми. Көчле кешеләргә тартылалар алар. Шуның белән харап та булгалыйлар. Әнә безнең институттагы бер профессорның кызы гаҗәеп акыллы, тәртипле бер аспирантка кияүгә чыкты. Аерылды. «Сарык» дип әйтә икән аспирантка. Икенче берәүгә чыкты. Бүрегә. Тегесе инде моны көн саен кыйный, ди. Яшиләр. Живут. Хоть бы что.
Надир. Кызык кеше сез.
Марат. Кызык булмый нишлисең, туган? Мин сиңа бер нәрсәне әйтәм, Гүзәл дә сиңа битараф түгел, яратадыр да. Уйный синең белән. Яраткан уенчык белән күбрәк уйныйлар бит балалар. Түзәсең инде, туган. Синең хәлләр әле, начар булса да, ярый. Менә монда безнең хәлләр... Әйттеме сиңа?
Надир. Ни турында?
Марат. Синең Гүзәлең судка бирде ич безне.
Надир. Ничек судка? Ни өчен?
Марат. Менә бер шагыйрьнең бәхетенә кыз үстерәбез дип куанып йөри идек, без аны дөньяга китереп җинаять эшләгәнбез икән.
Надир. Ничек инде алай?
Марат. Менә шулай, туган. Галиябану апаң белән суд көтеп яшибез.

Гүзәл керә. Ишек төбендә туктап, Марат белән Надирга карап тора.

Надир. Исәнме, Гүзәл.

Гүзәл. Исәнме. Әтигә зарланырга килдеңме? Мескен Мескенович Мескенов. (*Көлә.*)

Марат. Син әкрен, кызый. Әдәпсезлекнең дә чиге бар. Кешеләр синең янга сине яратып киләләр. Син...

Гүзәл. Минем берәүне дә күрәсем килми.

Марат. Минем дә сине күрәсем килеп тормыйдыр, бәлки. Түзәм бит.

Гүзәл. Түзмә. Кем сине мәҗбүр итә.

Марат. Дөньяга кеше булып тууым мәҗбүр итә. Миңа Надир алдында оят. Бәлки, сине мин ояла белергә өйрәтмәгәнмен. Ә үзем ояла беләм. Мин сине үчти-үчти дип учымда сикерткәндә, кызым-кызым дип үстергәндә, син мине дә мескен дип уйлагансың. Мин усал да була беләм. Нишлисең син? Нишләмәкче буласың? Кемнәр арасында кемнәр белән яшәмәкче буласың?

Гүзәл. Сез ясаган дөньяда сезнең белән.

Марат. Бик күпне беләсең. Кирәген генә белмисең. Килеп йөрмә моның янына, Надир энем. Бушка сарыф итмә җаның җылысын, һәм Галиябану апаң белән мине гафу ит.

Надир. Марат абый, борчылмагыз... Гүзәл...

Гүзәл бүлмәсенә кереп китә.

Марат. Гафу ит, туган.

Надир. Андый түгел иде ул, андый түгел иде. Нидер булды.

Марат. Андый булган инде, без күрмәгәнбез генә. Күрми калганбыз, сизми калганбыз.

Надир. Дөньясы да бит...

Марат. Ни булган дөньясына?

Надир. Бутала. Болгана.

Марат. Дөньяның кайчан буталмаганы бар? Мине әз талкыдымы дөнья? Сине әз талкыймы? Без яшәгән буталчык дөнья нормаль күренеш ул. Барысы да әйбәт булса, гаҗәп булыр иде. Ул бит шуны гына аңларлык яшьтә. Унбиш яшьлек мәктәп баласы түгел. Югары белемле юрист.

Надир. Нидер эшләргә иде, Марат абый.

Марат. Ни эшлисең? Хөкем карарын гына көтәргә кала.

Надир. Оят бит.

Марат. Оят булса, нишлисең? Димәк, без шуңа лаек. Әтиләре өчен балалар җавап бирмәсә дә, балалары өчен әтиләр җавап бирергә тиеш.

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Урамнан Саташкан әби үтеп бара. Туктап аякларына карап тора.

Саташкан әби. Тукта, аякларым атламый ич әле минем. Нишләп атламыйлар икән алар? Иртән атлыйлар иде, хәзер атламыйлар. (*Сул аягын атлатып.*) Яле, атла әле, нигә атламыйсың? Әллә бу аягымны ятсынасыңмы? Аны әллә ят итәсеңме? Ят итмә, ул бит синең парың. Ят түгел ул сиңа. (*Аягындагы галошларга игътибар итеп.*) И-и-и, карасана, галушларым үземнеке түгел икән ич. Ят галушлар ич болар. (*Җиргә утырып галошларын җентекләп карый.*) Алыштырганнар ич галушларымны. Аякларым нигә атламый дисәм, галушларымны алыштырганнар. Минем галушларым кызыл эчле иде, болар кара эчле ич. Кызыл эчле галушка ияләшкән ич минем аяклар. Кара эчле галушны ятсыналар ич алар. Шуңа атламыйлар да. Ятсыналар шул. Ят галушны үз итмиләр. Бөтен нәрсә ят. Кешеләр дә ят, галушлар да ят, аяклар ничек атласын? Юк, кимим ят галушларны. Үземнекеләрне бирсеннәр. Минекеләр кызыл эчле иде. Кимим, кимим, кимим. Нишләп мин киим ят галушларны. (*Узып барган Гүзәлгә.*) Син алыштырдыңмы минем галушларны?

Гүзәл. Нәрсә-ә-ә?

Саташкан әби. Минем галушларым кызыл эчле иде.

Гүзәл. Нинди галуш?

Саташкан әби. Минем кызыл эчле галушымны алгансың да кара эчлене калдыргансың. Бир минем галушларымны.

Гүзәл. Кит бар. Син генә җитмәгән идең, әбекәй, бу акылдан язган дөньяга. (*Аягындагы туфлиен салып.*) Мә, әбекәй, кызыл эчле галушыңны.

Саташкан әби. Кара, кара, тиле, туфлиен галуш, ди. Бу бит галуш түгел, кызыл эчле дә түгел.

Гүзәл. Соң, үзең әйттең ич.

Саташкан әби. Нигә син мин сөйләгәнне тыңлап йөрисең?

Гүзәл. Акыллы сүз сөйлисең бит син, әбекәй. Кызыл эчлеләрне себереп түктек инде.

Саташкан әби. Тиле мәллә син?

Гүзәл. Тиле, әбекәй, тиле.

Саташкан әби. Дөньясы тулы тиле, бер акыллы кеше юк. Бар, кит моннан.

Гүзәл. Сау булып тор, әбекәй. (*Китә.*)

Саташкан әби. «Сау булып тор» ди. «Хуш» дип әйтергә кирәк. «Сау булып тор» дигәч, күрешәсе була бит. «Хуш» дисәң, бүтән күрешмисең. (*Узып баручы Мөслимәгә.*) Исәнмесез. Здрастуйте.

Мөслимә. Исәнмесез!

Саташкан әби. Кара, исәнләште. Ник син исәнләштең минем белән?

Мөслимә. Сәламеңә каршы сәлам бирдем.

Саташкан әби. Мин бит сиңа ят кеше. Син бит мине танымыйсың да. Син таныйсыңмы мине? Йә, кем мин, әйт.

Мөслимә. Без барыбыз да адәм балалары инде.

Саташкан әби. Мин дә адәм баласымы?

Мөслимә. Кем буласың инде тагын.

Саташкан әби. Син дә адәм баласымы?

Мөслимә. Кем булыйм инде тагын? Ярый, сау бул, кем...

Саташкан әби. Нигә син миңа садака бирмисең?

Мөслимә. Садака?.. Тукта соң... (*Кесәләрендә актарынып.*) И Ходаем, бер тиенем дә юк икән бит. Икенче юлы инде, ярыймы... Ярый, сау бул...

Саташкан әби. Ә син нигә галуш кимәдең?

Мөслимә. Галушым юк шул минем.

Саташкан әби (*галушларын салып Мөслимәгә биреп*). Мә.

Мөслимә. Рәхмәт. Кирәкми. Үзеңә дә кирәк ич.

Саташкан әби. Алар минеке түгел. Алыштырганнар. Минекеләр кызыл эчле иде, болар кара эчле.

Мөслимә. И Ходаем!.. Син ки әле, кем. Ки... (*Саташкан әбигә галошларын кидерә.*) Ки, үзеңнекеләр алар. Син кайда торасың соң, кем?.. Өеңнең кайда икәнлеген беләсеңме?

Саташкан әби. Син миңа үз галушымны кидердеңме?

Мөслимә. Үзеңнеке инде, үзеңнеке. Бар инде, өеңә кайт.

Саташкан әби. Кайтмыйм. Анда ят кешеләр. Өйдә дә ят кеше, урамда да ят кеше. Син дә ят кеше, мин дә ят кеше. Барыгыз да ят кеше. Китәм мин. Качам сездән. Еракка, еракка китәм. Китәм. Кайтмаска китәм. Үз кешеләр янына китәм. Сезне мин үзем белән алып бармыйм. Сез садака да ала белмисез, садака да бирә белмисез. Китәм! (*Горур атлап чыгып китә.*)

Мөслимә. И Ходаем, үзең сакла.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Беренче күренештәге зал. Гүзәл кайтып керә. Икенче бүлмәгә кереп чыга. өйдәгеләрне эзли. Аннан көзге янына килә дә төзәтенә. Диванга авып ятып тора. Аннан торып тагын көзге янына килә. Судта сөйләячәк сүзләренә репетиция ясый.

Гүзәл. Гражданин судья! Минем судка язылган заявлениемдә барысы да төгәл язылган. Мин аны кабатлап тормыйм.

Мөслимә кайтып керә.

Мөслимә. Кайда йөрдең, кызым? Эзли-эзли арып беттем.

Гүзәл. Бик кирәк булдыммыни, әбекәй? (*Көлә.*)

Мөслимә. Көлмә әле шулай итеп. Элеккечә көл.

Гүзәл. Элек ничек көлә идем, әбекәй?

Мөслимә. Матур итеп. Хәзер мыскыл иткән кебек көләсең.

Гүзәл. Ялгышасың, әбекәй. Мин беркайчан да сине мыскыл итеп көлмәдем. Чөнки мин сине үземнән артык яратам. Дөньяда бердәнбер яраткан кешем.

Мөслимә. Әти-әниең бар.

Гүзәл. Аларны да яратам.

Мөслимә. Яратасыңдыр да. Яраткач, алай эшләмиләр.

Гүзәл. Син, әбекәй... Кайда соң әле үзләре?

Мөслимә. Кая булсын, авылга киттеләр. Сине көттеләр дә киттеләр.

Гүзәл. Мине нигә көттеләр?

Мөслимә. Җүләр сүз сөйләмә.

Гүзәл. Иртәгә бит суд була, беләләр ич алар.

Мөслимә. Белмим, белмим, башымны әйләндермәгез.

Гүзәл. Әбекәй, бөтен кеше, нигә әтиләреңне судка бирдең, дип сорый, син генә сорамыйсың.

Мөслимә. Ни дип әйтим, балакаем? Үзең беләсеңдер. Кемгә кирәк безнең сүзебез. Кирәк тә булмады, хәзер дә кирәк түгел.

Гүзәл. Менә әби синең кебекләр аркасында шулай яшибез дә инде. Үз күләгәсеннән курыккан куяннар кебек. Үзең курку гына җитмәгән, этине куркак итеп үстергәнсең. Мин синнән, әбекәй җаным, гел бер генә сүз ишетеп үстем: ипи белән бәрәңге булса, шул җиткән, сугыш кына булмасын. Ипи белән бәрәңге, ипи белән бәрәңге. Сине намуслы булырга өйрәтүчеләр аңа канәгать түгел бит.

Мөслимә. Нәфеснең чиге юк аның, кызым.

Гүзәл. Ләкин мескенлекнең чиге бар.

Мөслимә. Менә чиге бар дип берәү белән дә тыныша алмыйсың шул. Куалар да чыгаралар.

Гүзәл. Чыгарсыннар. Мин барыбер әйтәсен әйтеп китәм.

Мөслимә. Имгәтеп ташламасалар ярый инде. Әллә нинди заман килде шул.

Гүзәл. Килмәде, әбекәй, бар иде инде ул. Патша вакытында дөреслек эзләүчеләрне казак камчысы белән суктырдылар. Сталин миллионлап атты.

Мөслимә. Йә, булды, булды... Нишләтәсең инде. Булганнар үчен эти-әниеңнән алмыйлар. Син бит укыган кеше, аны гына белергә тиеш.

Гүзәл. Ә син судка бар, әбекәй.

Мөслимә. Нием калган анда?

Гүзәл. Улың белән киленеңне якларсың.

Мөслимә. Көлмә олы кешедән.

Гүзәл (*Мөслимәне кочаклап*). И, әбекәй... Син шундый да әйбәт әби. Берәү булса, мине орышыр, сүгәр иде.

Мөслимә. Сүгеп ни файда?

Гүзәл. Әбекәй, судья буласың киләме?

Мөслимә. Җүләр сүз сөйләмә.

Гүзәл. Юк, әбекәй, чынлап та. Әйдә, без синең белән репетиция ясыйбыз. Суд бара ди, әйеме? Син – судья, мин – гаепләүче. (*Диванга мендәрләрне утыртып.*) Болар гаепләнүчеләр – эти белән әни.

Мөслимә. Тагын нәрсә уйлап чыгарасың?

Гүзәл. Әбекәй, син бит һәрвакыт мин әйткәнне үтисең. Кил әле монда, утыр шушында. Әти белән әнине хөкем итәчәк суд утырышында. Судья булачак бит, син шул судья булып тор.

Мөслимә. Әйләндермә башымны.

Гүзәл. Судья булыр өчен баш әйләндерергә кирәкми, әбекәй. Тиешле урында тиешле сораулар гына бирергә кирәк. Бир соравыңны.

Мөслимә. Нинди сорау?

Гүзәл. Нигә әти белән әниеңне судка бирергә булдыгыз, диген. Мин җавап бирермен.

Мөслимә. Ишетеп тордым инде җавабыңны, бүтән ишетәсем килми.

Гүзәл. Юк, әбекәем. Бу юлы чын дөресен ишетерсең. Соравыгызны бирегез, гражданин судья.

Мөслимә. И Ходаем, нинди кәмитләр күрсәтерсең икән тагын?

Гүзәл. Кәмит түгел бу, әбекәй. Бу – трагедия. Бу – син күреп картайган дөреслек. Сез ул дөреслек турында әйтергә курыктыгыз. Бирегез соравыгызны, хөрмәтле хөкемдар.

Мөслимә. Интектермә инде, кызым.

Гүзәл. Бирегез соравыгызны.

Мөслимә. И Ходаем! Ярый инде... Нигә дип эти-әниеңне судка бирергә булдың?

Гүзәл. Гражданин судья! Минем суд хөкеменә бирелгән гаризамда барысы да төгәл язылган. Мин аны кабатлап тормыйм. Тик компенсация мәсьәләсенә генә ачыклык кертәм. Юк, миңа эти-әнидән берни дә кирәкми. Аларның эшләп тапканнары миңа түгел, үзләренә дә җитми. Алар һәм мин яшәгән сыман фатирга да дәгъва кылмыйм. Озакламый мин аннан китәм. Мине яратып йөргән бер тиле бар. Үзе талантлы, үзе фәкыйрь. Ярата икән, яшәп карасын. Мин үзем аны өзелеп яратам дип әйтә алмыйм. Мин аны кызганам гына. Әлбәттә, ир-ат кызганыч булырга тиеш түгел. Ләкин мин аны аңлыйм. Ул – без яшәгән җәмгыятьнең корбаны. Минем этием белән әнием кебек. Бүген мин аларны түгел, алар яшәгән җәмгыятьне җавапка тартам. Әгәр дә мин ялгышам икән, минем гаепләвем яла ягу икән, мине хөкем итегез. Ул чакта минем этием белән әнием шаһит буларак кына катнашырлар. Мин хөрмәтле судтан гаеплеләрне хөкем итүләрен сорыйм. Минме, минем якыннарыммы, әллә без яшәгән җәмгыятьме?

Мөслимә (*ишектә Марат белән Галиябануны күреп*). Кызым... Әтиеңнәр... (*Торып алар янына бармакчы була.*)

Марат. Утыр, әнкәй. Әйтелде бит, шаһит булып катнашалар, диде. Дәвам итегез, гражданка гаепләүче.

Гүзәл. Сез – киләчәк судның шаһитлары. Монысы тәмам. Судьяның хөкем карарын чыгаруын көтәм.

Марат. Гаепләнүче буларак безнең сүз әйтергә хакыбыз бардыр?

Мөслимә. Әйтте ләбаса Гүзәл, гаебегез юк, диде.

Марат. Нишләп?.. Бар гаебебез. Без яшәгән җәмгыять без төзегән җәмгыять иде бит. Без чыннан да гаепле. Шуның өчен Гарифуллина Гүзәл Марат кызы алдында гафу үтенәбез. Сез шул компенсациягә ризамы, Гүзәл туташ?

Телефон шылтырый. Марат трубканы ала.

Әлү! Кем әле бу? Ә-ә... Өйдә Гүзәл, өйдә, без дә өйдә. Авылга китмәкче идек тә борылып кайттык менә... Син ни, туган... Син инде болай йөрмә...

Гүзәл. Бир әле... (*Мараттан трубканы алып.*) Син өй телефонына шылтыратып этиләрне борчыма. Минем кесә телефонының номерын беләсең. Беләм инде, беләм, нигә аны туктаусыз кабатларга...

Саташкан әби (*пәйда булып*). Саташканнар... кызыл эчле галушымны алдылар да кара эчлесен бирделәр. Кайтыр юлыңны белмәгәч, барырга чыкма син. (*Пәрдә ябыла башлагач.*) Ә, качасызмы? Үзләре сөйлиләр, үзләре качалар.

Пәрдә.

# Риваять

*Наив романтизм стилендә язылган*
*ике пәрдәле хикәят*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Ихтыяр.
Гөлсылу.
Назлыгөл.
Аксакал.
Байрас.
Азамат.
Домбай.
Карачура.

**БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ**

БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Елга ярындагы агач күләгәсендәге таш өстендә Аксакал, сазда көй көйләп, мөнәҗәт әйтә.

Йөз яшәдем, төшенмәдем дөнья гамен,
Сизми калдым, туймый калдым яшәү тәмен.
Миннән соңра килгәннәргә васыятем шул:
Өйрәнегез дөньяларда яшәү фәнен.
Янып өлгер гыйшык уты кабынганда,
Очып кара канатларың кагынганда,
Үзең генә белгән моңлы җырың булсын,
Җырлар өчен яшьлегеңне сагынганда.
Оят-хурлык китерерлек гөнаһ кылма,
Кеше сөймәс тәкәббер дә, кол да булма,
Акыллылар киңәшенә колак сал да
Үз намусың, вөҗданыңны күбрәк тыңла.

Аксакалның мөнәҗәтенә Гөлсылуның җыры кушыла.

Гөлсылу (*җырлап яр буйлап килә*).

Агымсуда битләремне юсам,
Зарым бетәр микән?
Хәсрәт-кайгыларым аккан суга
Агып китәр микән?
Искән җилгә серләремне чишсәм,
Җилләр тыңлар микән?
Җилләр белән зарым очып китеп,
Җаным тынар микән?

Аксакал (*Гөлсылу җырлап туктагач)*. Ни сәбәптән моңланасың, сылу зат?
Гөлсылу. Моңланырлык сәбәп бар, бабакай.
Аксакал. Сер булмаса, әйт сәбәбен, сылукай? Синең җырың минем җырыма тәңгәл килде, бәлки, ярдәмем тияр.
Гөлсылу. Юк, бабакай. Миңа беркем дә ярдәм итә алмый. Мин, кайгы-хәсрәтемне җырга салып, аккан суга агызырга дип, монда килдем. Аккан су аны дәрьяга алып китсен. Дәрья киң, тирән, минем кайгымны сыендыра алыр.
Аксакал. Дәрьялардан киң, дәрьялардан да тирән күкләр бар. Син кайгы-хәсрәтеңне минем сазыма сөйлә. Сазым синең моңыңны, көйгә салып, күкләргә таратыр. Күкләрнең күңеле киң – ничәмә гасырлар буе ничәмә миллиард адәм балаларының моң-зарын үзенә сыендыра. Сөйлә, сылу зат. (*Сазын көйли.*)
Гөлсылу. Мин якты дөньяга туган көнне күршебездә бер ир бала да дөньяга килә. Шул көнне безнең әтиләр безне яраштырганнар. Ул турыда безгә ун яшь тулган көнне әйттеләр. Без бергә уйнап үстек. Без әле ярәшүнең дә, мәхәббәтнең дә ни икәнен белми, аңламый идек. Үсә төшкәч аңлашылды. Без, өйләнешеп, бергә яшәргә тиеш икәнбез. Шуны белгәч, без бер-беребездән читләшә башладык. Без бер-беребезне бер гаилә төзеп яшәр дәрәҗәдә яратмыйбыз икән. Аңа мин дә, ул да гаепле түгел. Туй буласын белгәч, мин өзгәләндем, ә ул бик үк хафаланмый. (*Туктап кала.*)
Аксакал. Сөйлә, сөйлә, сылу зат.
Гөлсылу. Әтиләр сүзе үтәлергә тиеш, ди ул. Әтиләр сүзенә каршы килү гөнаһ, ди. Ул гөнаһлы булудан курка. Аны мөгаллиме шулай укыткан.
Аксакал. Син гөнаһлы булудан курыкмыйсыңмы, балакай?
Гөлсылу. Мин дә куркам. Тик аның кебек үк түгел. Мин аңа әйттем: «Әйдә әйтик әтиләргә, кавыштырмасыннар безне, бәхетсез итмәсеннәр», – дидем. Ул теләми, аталар сүзеннән чыгарга ярамый, ди. Бир киңәшеңне, бабакай, нишләргә безгә? (*Елый.*)
Аксакал. Сабыр, сабыр, балакай! Дөньяда ике мәхәббәтнең тәңгәл килүе сирәк була. Ләкин адәм балалары пар-пар булып яшиләр.
Гөлсылу. Бер-берсенә тартылмаган ике кеше ничек пар була алсын?!
Аксакал. Яши-яши кешеләр парлашалар. Берсен-берсе яхшырак белә башлыйлар. Ул аларны якынайта.
Гөлсылу. Юк, юк, бабакай, без инде бер-беребезне яхшы беләбез. Әмма көннән-көн ераклаша гына барабыз.
Аксакал. Синең мәхәббәтеңә лаек түгелме ярәшелгән ярың?
Гөлсылу. Юк, юк, мин аны хурларга җыенмыйм. Ләкин ярата алмыйм. Ул да миңа битараф. Күрәм бит мин, сизәм бит мин, бабакай. Юк, мин әтиләр теләген үтәмәячәкмен. Яратмаган ир белән яшәгәнче, мин суга ташланам.
Аксакал. Менә монысы юләрлек, сылу зат.
Гөлсылу. Ах, бабакай, син карт инде, мәхәббәтнең ни икәнен оныткансың.
Аксакал. Һай, онытып булса икән аны, онытып булса икән.
Гөлсылу. Шундый сагышлы итеп әйттең, бабакай?!
Аксакал. Сагышлы, сылу зат. Мин дә, синең ярәшелгән ярың кебек, гөнаһ эшләүдән курыктым.
Гөлсылу. Беләсеңме, бабакай, минем бит күзем төшкән егетем бар. Мин аны күрсәм, йөрәгем еш-еш тибә башлый. Тик мин аңа гыйшкымны белдерә алмыйм. Ярәшелгән кызга бүтәннәргә күз салырга ярамый. Ни өчен ярамый, бабакай? Ул бит миңа ошый. Ул да, сизәм, мине ошата. Без кавыша алмабыз микәнни?
Аксакал. Мәхәббәт утында янмаган кеше юк ул дөньяда, сылу зат. Тик син сабыр бул. Бәхет кошының бәхет агачына кай яктан килеп кунганын беркем белми.
Гөлсылу. Юатма мине, бабакай. Син әйт, нишләргә миңа?
Аксакал. Мин шуны гына беләм, сылу зат, аталар сүзен аяк астына салу зур гөнаһ.
Гөлсылу. Син дә шуны әйтәсең.
Аксакал. Мин шуны әйтерлек яшьтә, балакай. Синдәй балага «теләсә ни кылан» дисәм, мин кем булыр идем?!
Гөлсылу. Мин бит кыланмыйм, бабай. Мин ярәшелгән егетне ярата алмыйм. Ул да мине яратмый. Ник безне кавыштыралар? Бу үзе гөнаһ түгелмени?
Аксакал. Бу – язмыш, бу – тәкъдир.
Гөлсылу. Сау бул, аксакал.
Аксакал. Син миңа үпкәләдең, ахры, балакай?
Гөлсылу. Юк, бабай. Сез барыгыз да бертөсле уйлыйсыз.
Аксакал. Кемнәр инде ул барыбыз да?
Гөлсылу. Өлкәннәр.

Аксакал. Өлкәннәр генә түгел. Ярәшелгән ярың да шулай уйлый, дисең.

Гөлсылу. Аның яратып караганы юк. Ул мәхәббәт турында уйламый, гөнаһ турында уйлый. Ул да инде картайган.

Аксакал. Бәлки, өлгереп җитмәгәндер. Өлгерер һәм сине яратыр.

Гөлсылу. Кирәкми миңа андый ярату. Сау бул. (*Китеп бара.*)

Аксакал (*мөнәҗәт әйтә*).

Бу дөньяның хикмәтләрен кемнәр белә?
Кеше гомерен ак-карага кемнәр бүлә?
Бер үк гамәл кемгә савап, кемгә гөнаһ,
Нигә берәү елаганда, берәү көлә?

Җырлап, Ихтыяр керә.

Ихтыяр. Сахраларга чыгып сәйран кылсаң,
Сандугачлы язгы иртәләрдә –
Талгын саба җиле сәлам бирер,
Таң нурлары назлап иркәләрләр.
Җанга дәва булыр моңын тойсаң
Сабыр гына аккан инешләрнең,
Җырлар туып торыр күңелеңдә,
Сайрар кошлар булыр дус-ишләрең.

Аксакал. Сәлам бирергә оныттың, олан.

Ихтыяр (*Аксакалны күреп*). Мөгаллим?! Әссәламегаләйкем, мөгаллим. Кичерә күрегез, күрмәдем.

Аксакал. Җырлаган җырыңнан шатлыклы аваз ишетелә.

Ихтыяр. Сагышлар сагышым, кайгырыр кайгым юк, мөгаллим. Сез дә монда киләсезмени? Беренче күрүем.

Аксакал. Аккан суга карап утырырга килдем. Гомер агышларын санарга.

Ихтыяр. Елга ярының бу урыны миңа да бик ошый. Без монда балачактан бирле уйнарга киләбез. Мин сезләргә рәхмәтлемен, мөгаллим. Сез миңа дөньяда яшәүнең серләрен ачтыгыз. Гөнаһ гамәлләрнең ни икәнен аңлаттыгыз. Мин, мөгаллим, сез сызган юлдан чыкмаска тырышам.

Аксакал. Рәхмәт, олан! Мөгаллим өчен шәкертенең рәхмәтеннән зур нәрсә юк.

Ихтыяр. Алла боерса, минем туемда түрдә утырырсыз. Озакламый безнең туебыз була, мөгаллим. Мин туганда, безнең күршедә бер кыз бала туган. Шул чакта ук безнең әтиләр безне ярәшкәннәр. Туй көне дә җитеп килә.

Аксакал. Ходай бәхетле гомер насыйп итсен.

Ихтыяр. Тик миңа ярәшелгән кыз кавышуыбызга каршы. Бәхетле бумаячакбыз, ди. Без бер-беребез өчен яратылмаган, ди. Әтиләргә әйтик, туй ясамасыннар, ди.

Аксакал. Ярәшелгән кызың сине яратмыймы?

Ихтыяр. Яратмыйм, дими, ярата алмыйм, ди.

Аксакал. Ә син аны үзең яратасыңмы?

Ихтыяр. Мин ул турыда уйламыйм, мөгаллим. Әтиләр сүзен тыңларга, әтиләр теләген үтәргә тиеш мин. Әтиләр сүзен тыңламау – гөнаһ. Үзегез өйрәттегез.

Аксакал. Әйе, гөнаһ. Бездән алда яшәгәннәрнең сүзе сызылып барса, киләчәккә юлны ничек табасың?

Ихтыяр (*кинәт чыгып китә дә кулларына ике зур алма тотып керә*). Мөгаллим, күрегез. Нинди алмалар. Судан агып киләләр иде. Берсе аның сезгә, мөгаллим, берсе – үземә. (*Алманың берсен тешли.*) Алыгыз, мөгаллим.

Аксакал. Юк, олан, ала алмыйм. Рөхсәтсез кеше әйберен алу караклык. Ә угрылык кылу – гөнаһ.

Ихтыяр. Мин бирәм аны сезгә.

Аксакал. Ә алар синекеләр түгел, олан. Синең бакчаңда үсмәгәннәр.

Ихтыяр. Алар беркемнеке дә түгел. Судан агып киләләр иде.

Аксакал. Димәк, кемнеңдер бакчасында үскәннәр. Өзелеп төшкәннәр дә агып киткәннәр.

Ихтыяр. Алайса, мин аларны кире суга атам.

Аксакал. Ләкин син аларның берсен тешләп өлгердең. Алма хуҗасы рөхсәтеннән башка аның алмасын тешләдең.

Ихтыяр. Мин гөнаһ кылдыммы, мөгаллим? Миңа нишләргә, мөгаллим?

Аксакал. Алма хуҗасын эзләп тап та кичерүен сора.

Ихтыяр. Әгәр дә мин елга яры буйлап өскә менсәм, алма бакчасын эзләп табачакмын, хуҗасын күрәчәкмен. Шулаймы, мөгаллим?

Аксакал. Син зиһенле бала.

Ихтыяр. Сау булыгыз, мөгаллим. Мин киттем. (*Юлга кузгала.*)

Аны Гөлсылу кычкырып туктата.

Гөлсылу. Ихтыяр!

Ихтыяр (*Гөлсылу янына килеп*). Кичерә күр, Гөлсылу, мин сине күрмәдем.

Гөлсылу. Кая болай ашыгасың?

Ихтыяр. Елгадан агып барган алмаларны алып, берсен тешләгән идем. Алма хуҗасыннан гафу үтенергә барам.

Гөлсылу. Нигә?

Ихтыяр. Мөгаллим әйтте, мин кеше алмасын рөхсәтсез тешләгәнмен.

Гөлсылу. Ул карт синең мөгаллимеңме?

Ихтыяр. Әйе, ул мине гөнаһ кылудан саклап килде. Гыйлем бирде.

Гөлсылу. Нигә кирәк ул гыйлем сиңа, Ихтыяр? Гыйлем бит ул уйларга өйрәнер өчен. Ә син уйлый белмисең, Ихтыяр. Синең өчен бүтәннәр уйлый. Карт әйткәнне үтәргә чабасың. Бәлки, ул ялгышадыр.

Ихтыяр. Мөгаллим ялгыша белми, Гөлсылу. Ул үз гомерендә бер гөнаһ эш тә кылмаган зат. Ходай каршында саф кеше.

Гөлсылу. Өч көннән безнең туебыз, Ихтыяр.

Ихтыяр. Әйе, Гөлсылу.

Гөлсылу. Син ул көнне зарыгып көтәсеңме? Кавышуыбызга куанасыңмы?

Ихтыяр. Без ярәшелгән, Гөлсылу.

Гөлсылу. Безне бездән башка ярәшкәннәр. Мин ул туйның булуын теләмим.

Ихтыяр. Өстеңә гөнаһ алма, Гөлсылу.

Гөлсылу. Нинди гөнаһ? Мин сине ярата алмыйм, Ихтыяр. Син дә миңа битараф. Синең миндә гамең юк. Син минем барлыгымны белмисең дә. Без ничек бер-беребезне күрмичә бергә яшәрбез.

Ихтыяр. Әтиләр теләген без үтәргә тиеш, Гөлсылу.

Гөлсылу. Һаман бер сүз кабатлыйсың.

Ихтыяр. Догалар да гел кабатлана, Гөлсылу.

Гөлсылу. Без инде сабыйлар түгел, Ихтыяр. Мәхәббәт дигән нәрсә бар дөньяда. Мин аның ни икәнен аңлыйм, син аңларга теләмисең.

Ихтыяр. Без күп әйберләрне аңламыйбыз. Ләкин яшибез.

Гөлсылу. Нигә яшәргә?

Ихтыяр. Гомерне Ходай биргән, Гөлсылу. Шуңа күрә без аңа рәхмәтле булырга тиешбез. Безнең аңа рәхмәтебез – гөнаһ кылмау.

Гөлсылу. Бер-береңне яратмыйча бергә яшәү – үзе гөнаһ.

Ихтыяр. Ә нәрсә соң ул ярату? Ул шайтан уйлап чыгарган нәрсә. Адәм балаларын аздырыр өчен. Оҗмах агачыннан анабыз Хәвага мәхәббәт алмасы өзеп биргән, Хәва аны Адәмгә ашаткан. Һәм Ходай аларны оҗмахтан сөргән. Беләсеңме бу хакта? Әгәр дә шайтан биргән алманы Адәм ашамаса, без оҗмахта яшәр идек.

Гөлсылу. Ләкин без булмаган булыр идек. Без – Адәм белән Хәва мәхәббәтенең җимешләре.

Ихтыяр. Гөнаһ җыйма, Гөлсылу.

Гөлсылу. Мин гөнаһлы Хәваның дәвамы. Гөнаһлы Гөлсылу белән ничек яшәрсең, Ихтыяр? Әйтик әтиләргә, безне кавыштырмасыннар. Икебез дә әйтсәк, алар безне аңларлар.

Ихтыяр. Безне ярәшкәндә алар аңлап ярәшкәннәр. Алар сүзен үтәмәү – гөнаһ. Безгә хәтле дә бу йола булган. Без әле бер-беребезне күреп, бергә уйнап үстек. Күпләр бер-берсен туй көнендә генә күргәннәр. Син өзгәләнмә, Гөлсылу, Ходай ничек кушкан, шулай булыр. Өстебезгә гөнаһ җыйсак, Ходай каршына ничек барырбыз?

Гөлсылу. Ходай яратышмыйча яшәргә кушмаган. (*Җырга күчә.*)

Ниләр сөйләп, ни аңлатыйм
Сөя белмәгәннәргә.
Мәхәббәтнең ялкынында
Көя белмәгәннәргә.

Ихтыяр. Синең тугры ярың булырмын,
Канатыңның пары булырмын.

Гөлсылу. Канат нигә канат кагып
Оча алмаганнарга,
Күккә ашып, йолдызларны
Коча алмаганнарга?

Ихтыяр. Күңелеңнең күзе булырмын,
Намусыңның йөзе булырмын.

Гөлсылу. Күңел күзе булмыйдыр ул

Җаны булмаганнарда,
Мәхәббәттән кайнап торган
Каны булмаганнарда.

Әйдә, кайтыйк калабызга, Ихтыяр. Әтиләребез аягына баш орыйк.

Ихтыяр. Миңа иң элек бу алмалар хуҗасын эзләп табарга кирәк.

Гөлсылу. Озак йөрмә, Ихтыяр. (*Китеп баручы Ихтыярга.*) Син миңа сау бул дип тә әйтмәдең, Ихтыяр.

Ихтыяр. Сау бул. (*Китә.*)

Гөлсылу. Сау бул. Юлың хәерле булсын.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Байрас бакчасы. Байрас алмагач күләгәсендәге утыргычка утырган да җыр суза. Үзе алмагачтан алма өзеп алып суга ата.

Байрас.

Акчам да күп, бакчам да зур,
Бу дөньяның бер яме юк.
Кәләш яшенә җитеп тә
Кызларымның кияве юк.
Шуңа күңелем тонык –
Миңа бик кирәк онык.
Бакчама кем хуҗа булыр,
Байлыгым калыр кемнәргә?
«Бабай» диеп кемнәр дәшәр
Ямансулаган көннәрдә.
Миңа бик кирәк онык,
Шуңа күңелем сынык.

(*Узып баручы Назлыгөлне күреп.*) Кызым!

Назлыгөл (*Байрас янына килеп*). Килдем.

Байрас. Килдем, әткәй, диген, ичмасам.

Назлыгөл. Килдем, әткәй.

Байрас. Кая барасың?

Назлыгөл. Мин бит синнән «нигә монда утырасың?» дип сорамыйм.

Байрас. Әй шушы холкың.

Назлыгөл. Алмагачның алмасы алмагач төбенә төшә, әткәй.

Байрас. Шулайдыр, шулайдыр. Ерак китмә, кияүләр килә.

Назлыгөл. Кемгә?

Байрас. Әлбәттә, сиңа. Миңа түгел.

Назлыгөл. Кияү сиңа кирәк бит.

Байрас. Миңа оланнар кирәк. Картайган көнемдә байлыгымны калдырырга оныклар кирәк. Ходай миңа синнән башка бала бирмәде. Беренче һәм соңгы баласын табып анаң дөнья куйды. Дөньяда бер чибәр булып үстең. Гүзәл дигән даның тирә-якка таралды. Йөз илдән кулыңны сорарга киләләр. Син килгән берен борып торасың.

Назлыгөл. Син миннән мине кияүгә биреп котылырга телисеңме?

Байрас. Ни сөйлисең син, кызым?

Назлыгөл. Күңелемә ошаганы булмагач, нишләтим.

Байрас. Бакча капкасы янында тагын кулыңны сорап килүче егетләр тора.

Назлыгөл. Торсыннар.

Байрас. Бәлки, берәрсен ошатырсың, кызым. Ризалыгың бир, керсеннәр. Сөйләшеп кара, күңелең эзләгәне, бәлки, шулар арасындадыр? Инде бит йөзләп егетне куып җибәрдең.

Назлыгөл. Мин кумадым, үзләре киттеләр. Чакыр. Керсеннәр.

Байрас (*сөенеп*). Әй, егетләр! Берегез керсен!

Азамат керә.

Азамат. Әссәламегаләйкем!

Байрас. Вәгаләйкем әссәлам. Кем дип белик?

Азамат. Бортаслар иленнән Азамат. Азман байның баласы. Атам сезнең кызыгызны күреп кайткан. Мине җибәрде. Кызыгыз Назлыгөлнең кулын сорарга килдем.

Назлыгөл. Үзеңәме, атаңамы?

Азамат. Мин ишеттем, сезне әче телле, диделәр. Мин үзем дә төче түгел. Уртак тел табарбыз дип уйлыйм. Буй-сынымны күреп торасыз.

Байрас. Әйе, әйе! Сөбханалла! Атагыз бик затлы адәм.

Азамат (*Назлыгөлгә*). Ни әйтәсез, гүзәл зат?

Назлыгөл. Әйтеп бетер сүзеңне.

Азамат. Мин әйтәсен әйттем. Сез миңа ошадыгыз. Мине дә ошаткансыздыр дип уйлыйм.

Назлыгөл. Уйлау һәркемгә дә рөхсәт ителә. Минем уем болайрак, Азман углы Азамат.

Әгәр мине алыр булсаң,
Яннарыңа салыр булсаң,
Уңга да китмә,
Сулга да китмә,
Алга атлама,
Артка да чикмә.
Әнә анда комсыз чүл,
Уртасында сусыз күл.
Ал кулыңа тишек иләк
Һәм дә янә төпсез чиләк.
Сусыз күлдән су сал иләккә,
Тутыр аны төпсез чиләккә.
Чиләк тулгач килерсең.
Сиңа кулым бирермен.

Хуш, егет.

Азамат. Әйткәнеңне мин төшендем, Назлыгөл.

Син үзең дә шуны бел.
Комсыз чүлне дә табармын.
Сусыз күлдән су алып,
Төпсез чиләккә салып
Чиләкне тутырырмын.
Кулыңа тоттырырмын.
Һәм китәрмен борылып,
Калырсың буш чиләк тотып.

Без – Бортас иле егете, Азман байның баласы – ялына белмибез. Мине күрдегез. Бичәм булырга теләсәгез, хәбәр итәрсез. (*Китәргә борыла. Туктап.*) Дөресен әйтәм, сез миңа ошадыгыз.

Назлыгөл. Атагызга сәлам әйтегез, әниегез утырмага килсен.

Байрас (*Азамат чыгып киткәч*). Бу ни эш инде, кызым? Шундый егетне борып җибәрдең.

Назлыгөл. Икенчесен чакыр, әткәй.

Байрас (*капка ягына карап*). Кем чираты, керегез.

Домбай керә.

Домбай. Әссәламегаләйкем!

Байрас. Вәгаләйкемәссәлам. Кем дип белик?

Домбай Назлыгөлгә караган да сокланудан тораташ булып каткан.

Сезне кем дип белик, егет?

Домбай. Ә... Әйе... Ни дидегез?

Байрас. Кем син? Каян килдең?

Домбай. Минме? Мин... (*Назлыгөл алдына тезләнә.*) Ах, гүзәлләр солтаны. Мондый гүзәллек...

Назлыгөл. Тор һәм атамның соравына җавап бир.

Домбай. Ә? Әйе... Әйе... Мин... Мин Тәмте иле вәзиренең углы Домбай булам. Сезнең гүзәллегегез турында ишеткән идем, әмма бу хәтле үк булыр дип уйламаган идем.

Назлыгөл. Йомышың ни, егет?

Домбай. Йомыш? Нинди йомыш? Нинди йомыш булуы мөмкин? Мин сезне күрдем һәм үлеп гашыйк булдым.

Назлыгөл. Үләргә ашыкма. Ник килдең?

Домбай. Бирегез миңа кулыгызны. Кул белән кул очрашсын, йөрәккә йөрәк тоташсын.

Назлыгөл. Шуннан ни?

Домбай. Шуннанмы?.. Түшәгебез уртак булсын, гүзәл зат.

Назлыгөл. Әгәр мине алыр булсаң,

Түшәгеңә салыр булсаң,
Куш та суны утка –
Пешер ярмасыз ботка.
Атка мөгез чыгар,
Балтадан пешер чумар.
Ярык яса тишеккә,
Китап укыт ишәккә,
Йон үстер бакага,
Тиресе булыр якага.
Шул яканы алырсың,
Иңнәремә салырсың.
Башка сиңа сүзем юк.
Сүзем юк һәм үзем юк.

Домбай. Тел төбеңне аңламадым, гүзәл зат?

Назлыгөл. Хуш, дип әйтсәм, аңларсыңмы әйткәнне?

Домбай. Юк, аңламам, гүзәл зат. Хушлашмыйм мин сезнең белән. Сез һәрвакыт минем уемда булырсыз.

Назлыгөл. Рәхмәт әйткән сүзегезгә.

Домбай. Бер багыйм да йөзегезгә...

Назлыгөл. Рәхим ит!

Домбай. Рәхмәт сезгә. Сезне күрүем белән дә мин бәхетле, гүзәл зат. (*Чыгып китә.*)

Байрас. Монысы миңа да ошамады. Тиле-миле бугай бу.

Назлыгөл. Гашыйклар тиле була, әткәй. Тагын кем бар анда?

Байрас. Керегез. (*Карачура кергәч.*) Ә син нигә килдең тагын?

Карачура. Сезнең кызыгызның кулын сорарга.

Назлыгөл. Минем кулымны сорарга ике тапкыр килмиләр.

Карачура. Мин килдем. Мин Карахан бәкнең углы. Минем теләгемнең үтәлмичә калганы юк. Мин теләгемә ирешкәнче киләчәкмен.

Назлыгөл. Син минем җавабымны хәтерлисеңме?

Карачура. Минем хәтерем сәламәт.

Назлыгөл. Кабатлап күрсәт!

Карачура. Рәхим ит!

Иртән түгел, кич түгел,
Көндез түгел, төн түгел.
Юлсыз юлдан юл буйлап,
Уй уйламый уй уйлап,
Ерак юлга чыгып кит.
Бер урманга барып җит.
Урман агачсыз булсын,
Имәннәр шаулап торсын.
Сул якка да карама,
Уң якка да карама,
Алга-артка карама,
Аска-өскә карама.
Кара күзеңне йомып,
Җирдә ятар бер болыт.
Суы беткән, ди, агып.
Шуны учыңа салып,
Юлсыз юлдан юл табып,
Кайтсаң бакчама алып,
Каршыма килеп бассаң,
Болытны күккә ассаң,
Шуның күләгәсендә
Теләр-теләмәс кенә
Сузармын сиңа кулым –
Булырмын тугры колың.

Ялгышмадыммы?

Назлыгөл. Юк, Карахан бәк углы. Кайда болытың?

Карачура. Әнә күктә.

Назлыгөл. Ул мин әйткән болыт түгел.
Карачура. Сусыз болыт, дидең. Суы юк, яңгыр яумый. Мин аны учыма салып килдем дә баш очыңа элеп куйдым. Шуның күләгәсендә басып торабыз. Кулыңны бир!
Назлыгөл. Ул болыт синең учыңда түгел иде.
Карачура. Учымда иде.
Назлыгөл. Мин күрмәдем.
Карачура. Ә мине күрәсеңме? Мин Карахан бәк углы Карачура. Син минеке булырга тиешсең.
Назлыгөл. Хуш!
Карачура. «Хуш» дияргә ашыкма. Кочагымда ятасың бар.
Байрас. Егет, кызым белән андый телдә сөйләшергә рөхсәтем юк. Әнә капка, яп теге яктан.
Карачура. Үзем япкан капканы үзем ачып керермен. (*Чыгып китә.*)
Байрас. Тагын кем бар анда, керегез!
Ихтыяр (*кереп*). Әссәламегаләйкем.

Назлыгөл, Ихтыярны күреп, шунда ук гашыйк була.

Байрас. Вәгаләйкемәссәлам. Кем дип белик?
Ихтыяр. Сез утырган яр астында елга ага. Шуның түбән агымында Ташкала дигән кала бар. Мин шуннан.
Байрас. Хуш! Ни йомыш?
Ихтыяр (*кулларындагы алмаларны күрсәтеп*). Сез бу алмаларны таныйсызмы?
Байрас. Хуш! Таныйм. Минем бакчамда гына пешә мондый алмалар.
Ихтыяр. Мин аларны судан тотып алдым. Гафу итегез, берсен тешләдем. Мин аның хуҗасы барлыгын белмәдем.
Байрас. Белсәң нишләр идең?
Ихтыяр. Рөхсәт сорар идем. Рөхсәтсез алманы тешләгән өчен гафу үтенергә килдем. Илебезнең Аксакалы минем мөгаллимем әйтте: «Рөхсәтсез кеше әйберен алу зур гөнаһ», – диде. Минем гөнаһлы буласым килми.
Байрас. Бер дә гөнаһ кылганың юкмы?
Ихтыяр. Юк.
Байрас. Юк, димә. Бер Ходай гына гөнаһсыз. Хуш! Мин синең гафу соравыңны кабул итмәсәм ни була?
Ихтыяр. Итәрсез дип өметләнәм. Чөнки мин алманы бакчагызга рөхсәтсез кереп өзеп алмадым. Янә дә күрәм, бу алмаларны сез үзегез өзеп ыргытасыз. Димәк, алар сезгә кадерле түгел.
Байрас. Ялгыш уйлыйсың, егет! Алар кадерле булганга, мин шулай эшлим. Кадерле булганга, син аларны судан тотып алгансың.
Ихтыяр. Аңлатыбрак әйтегезче?
Байрас. Соңрак аңларсыз. Син өйләнгәнме?
Ихтыяр. Аңа алманың ни катнашы бар?
Байрас. Бар, егет! Соңрак әйтермен. Ә хәзергә әнә теге алмагач янында торып тор, чакыргач килерсең. (*Ихтыяр чыгып киткәч.*) Кызым, ошадымы бу егет?
Назлыгөл. Мин аңа бер күрүдә гашыйк булдым, әткәй. Ул минем хыялымдагы егет. Ләкин ул мине күрмәде. Миңа игътибар итмәде шикелле.
Байрас. Күрер дә, игътибар да итәр. Димәк, ул сиңа ошады?
Назлыгөл. Бик ошады, әткәй.
Байрас. Димәк, багучының сүзләре дөрескә чыкты. Синең өчен борчылып багучыны чакырткан идем. Алмаларны өзеп суга ташларга ул киңәш бирде. «Кем дә булса ул алмаларның берсен тотып алыр һәм, гафу сорап, яныгызга килер һәм ул сезнең киявегез булыр», – дигән иде.
Назлыгөл. Әткәй, бир син мине аңа. Ләкин нигә ул мине күрмәде? Мин бит аңа сокланып карап тордым. Нигә күзләремдәге гыйшык утын күрмәде.
Байрас. Ашыкма, дидем. (*Ихтыярны чакыра.*) Егет! (*Ихтыяр кергәч.*) Исемеңне әйтмәдең, егет.
Ихтыяр. Ихтыяр мин.
Байрас. Янәшәмдә минем кызым Назлыгөл басып тора. Кара аңа. Карадыңмы?
Ихтыяр. Әйе.
Байрас. Ә хәзер, кызым, син чыгып тор. (*Назлыгөл чыгып киткәч.*) Чибәрме минем кызым?
Ихтыяр. Әйе.
Байрас. Аның кулын сорап йөз илдән йөз егет килде. Берсенә дә бирмәдем. Инде болай. Әйе. Алмаларны рөхсәтсез алып син зур гөнаһ кылгансың. Әгәр дә мин кичермәсәм, Ходай да синең гөнаһыңны кичермәс. Мин синең гөнаһыңны бер очракта гына кичерә алам. Син минем бер теләгемне үтәргә тиеш.
Ихтыяр. Теләгегезне әйтегез.

Байрас. Тагын бер кат сорыйм: минем кызым Назлыгөл чибәрме? (*Ихтыяр эндәшмәгәч.*) Минем соравымны ишетмәдең шикелле. Ул сиңа ошадымы? Ошадымы, дип сорыйм.
Ихтыяр. Минем ярәшелгән ярым бар шул.
Байрас. Мин синнән «кемең бар» дип сорамыйм. «Ошадымы минем кызым Назлыгөл» дим.
Ихтыяр. Ул... Ул... Ул...
Байрас. Мин аны сиңа бирәм. Йөз илдән килгән йөз егеткә тәтемәгән бәхет сиңа эләкте. Кызыма – ир, миңа кияү булырсың.
Ихтыяр. Минем ярәшелгән ярым бар шул.
Байрас. Анысы ярәшелгәндер, бусы – синең язмышың.
Ихтыяр. Ләкин мин гөнаһтан куркам.
Байрас. Нинди гөнаһ?
Ихтыяр. Гөлсылу атлы бер кыз белән мине туган көнебездә әтиләребез ярәшкән. Әти теләген үтәмәү – гөнаһ.
Байрас. Син ишетеп тордың, егет, минем кызым синең күз алдыңда кулын сораучыларның икесен куып җибәрде. Сине күргәч, сиңа гашыйк булды. Син дә, аны күргәч, телеңне йоттың. Әйт, мин дөрес сөйлимме?
Ихтыяр. Әйе. Ләкин...
Байрас. Ярәшелгән кызың белән бер-берегезне яратасызмы?
Ихтыяр. Мин белмим, ул, ярата алмыйм, ди.
Байрас. Алайса, нинди гөнаһ турында сөйлисең?
Ихтыяр. Мөгаллим әйтә...
Байрас. Мөгаллимең надан синең, егет.
Ихтыяр. Мөгаллим турында андый сүз әйтмәгез.
Байрас. Алайса, сине минем яныма җибәргән мөгаллимеңә кайтып әйт, тешләнгән алма өчен мин сине гафу итмим. Ә гөнаһ турында шуны әйтәм – без туганда ук гөнаһлы булып туганбыз. Адәм белән Хәва, гөнаһ кылган өчен, оҗмахтан сөрелгәннәр.
Ихтыяр. Сез Гөлсылу сүзен сөйлисез.
Байрас. Мин үз сүземне сөйлим. Бар, кит. Мин синең гөнаһыңны кичермим.
Ихтыяр. Сау булыгыз.
Байрас. Хуш! (*Назлыгөлгә карап кузгала алмый торган Ихтыярга.*) Хуш, дидем.

Ихтыяр чыгып китә.

Назлыгөл. Килер микән, әткәй?
Байрас. Чү, кызым, синең йөзең үзгәрде.
Назлыгөл. Аны күргәч, мин кемне эзләгәнемне белдем, әткәй. Ләкин минем өметем тышауланган булып чыкты. Килмәс. Ярәшелгән, диде. Кем икән ул бәхетле җан?
Байрас. Ярәшелгәне егетне яратмый. Егет үзе әйтте.
Назлыгөл. Ничек инде аны яратмаска мөмкин.
Байрас. Сабыр, кызым. Ул киләчәк.
Назлыгөл. Нигә ул мине күрмәде, әткәй?
Байрас. Күрде, дип әйттем мин сиңа.
Назлыгөл. Әгәр ул килмәсә, син аны эзләп тап, әткәй. Ул беркемнеке дә булырга тиеш түгел. Ул минеке булырга тиеш. Бары тик минеке генә. Ишетәсеңме, әткәй?

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Беренче күренештәге елга яры. Таш өстендә утырган Аксакал мөнәҗәт әйтә.

И Ходаем! Кодрәтең киң, үзең сакла,
Гөнаһ кылсак, нурың белән җанны пакьлә.
Адәми зат ялгышлардан хали түгел,
Рәхмәтеңнән ташлый күрмә, читкә какма.

(*Кереп мөнәҗәтне тыңлап торган Ихтыярга.*) Әйтер сүзең бар күренә, олан.
Ихтыяр. Бар, мөгаллим.
Аксакал. Сөйлә, олан.
Ихтыяр. Мөгаллим, миңа әллә ни булды.
Аксакал. Ачыграк итеп әйт.

Ихтыяр. Мин аны күрдем һәм минем йөрәгем дерт итеп куйды. Минем әле беркайчан да болай булганы юк иде. Минем эчемә-тышыма әйтерсең лә ут кабынды. Сулышым кысылды.

Аксакал. Ачыграк итеп сөйлә, олан.

Ихтыяр. Алма хуҗасының кызын күргәч, минем белән шундый хәл булды, мөгаллим. Әйтер сүземне әйтә алмый тордым. Каядыр күккә очып киткәндәй булдым. Әйтерсең миңа канатлар үсеп чыкты. (*Җырга күчә.*)

Халәтемне урап алган сәер хисләр
Зәңгәр күккә очып менде канатланып,
Җан авазын җырга салып көйләр туды,
Күңелемнең кылларында кабатланып.
Аллы-гөлле төсләр уйный бар галәмдә,
Ай, йолдызлар бәйрәм итә күк илендә.
Мәхәббәтнең туган мәле шул чактадыр –
Сабыр җанның күккә ашкан мизгелендә.

Мөгаллим, бу нинди хикмәт икән? Әллә мәхәббәт дигән нәрсә шул микән, мөгаллим? Шуның уты кабынды микән күңелемдә?

Аксакал. Сабыр кылан, олан.

Ихтыяр. Мин елга яры буйлап өскә мендем. Килеп җиттем бер бакчага. Бу алмалар үскән алмагачның төбендә бакча хуҗасы утыра. Аның янында гүзәлләрдән гүзәл, чибәрләрдән чибәр, сылулардан сылу, асылларның иң асылы бер кыз басып тора. Бакча капкасы янында кызның кулын сорарга килгән егетләр. Йөз илдән йөз егет килгән, кыз аларның йөзен дә борып җибәргән. Мин ул кызның сүзләрен ишетеп тордым. Чишмә челтерәведәй тавышы күңелемнең кылларын чиртә. Бакчага кергәч, мин аңардан күземне ала алмадым. Үзем бакча хуҗасының кичерүен сорыйм, үземнең күзләрем кызда.

Аксакал. Кичердеме сине бакча хуҗасы?

Ихтыяр. Беләсезме, мөгаллим, ышанасызмы, бакча хуҗасы миңа шул чибәрләрдән чибәр, гүзәлләрдән гүзәл, сылулардан сылу, асылларның иң асылы булган кызын бирергә тели. Шул чакта гына караклыгыңны гафу итеп, гөнаһтан арындырам, ди. Йөз илдән килгән йөз егетне мыскыллап куып җибәргән кыз берни дә эндәшми читтә басып тора. Моны ничек аңларга, мөгаллим?

Аксакал. Бәлки, сине ошаткандыр.

Ихтыяр. Аның кулын сорап килүчеләр арасында әмир, вәзир, бай һәм дә бәк уллары бар. Аларны куа торды, ә мине кумады. Ләкин мин бит ярәшелгән егет, мөгаллим. Нишлим, мөгаллим? Киңәшкә дип сезнең янга чаптым. Бирегез киңәшегезне, мөгаллим?!

Аксакал. Дөньяның үлчәве бар, олан. Син ике гөнаһ уртасында. Үлчәүнең бер башында – атаң сүзен кире кагу, икенче ягында – алма хуҗасының теләген үтәмәү. Кайсы гөнаһ авыррак? Уйла!

Ихтыяр. Сез мине уйларга өйрәтмәдегез, мөгаллим.

Аксакал. Хак сүз сөйләмисең, олан. Мин сине гөнаһ кылмаска гына өйрәттем. Кылган гөнаһларыңның авырлыгын үлчәргә өйрәтмәдем. Гөнаһларның кичерелми торганы бар. Илеңә, кавемеңә, ата-анаңа хыянәт итү – кичерелмәс гөнаһлар.

Ихтыяр. Әтиемнең теләген үтәмәү кичерелмәс гөнаһмы?

Аксакал. Ул турыда, олан, атаң белән сөйләш. Әгәр ул кичерсә, бакча хуҗасының таләбен үтәү сиңа бәхет китерсен.

Ихтыяр. Мин әтием янына чабам, мөгаллим. Гөлсылу да миңа әйтте: «Әтиләребезнең аякларына баш орыйк», – диде. Сау булыгыз, мөгаллим.

Ихтыяр, чыгып барганда, Гөлсылу белән очраша.

Гөлсылу, мин... мин сине аңладым шикелле. (*Гөлсылуны кочаклап ала.*)

Гөлсылу (*Ихтыярның кочагыннан чыгып*). Нишләвең, Ихтыяр?..

Ихтыяр. Кичер. Кичерә күр, Гөлсылу!

Гөлсылу. Ни булды сиңа, Ихтыяр?

Ихтыяр. Мин... Мин гашыйк булдым, ахры, Гөлсылу!

Гөлсылу. Кемгә?

Ихтыяр. Син беләсеңме, Гөлсылу, ул синең кебек чибәр, синең кебек гүзәл. Ул менә шул алмалар хуҗасының кызы. Мин аны күрүгә, Гөлсылу... Мин гашыйк булдым, Гөлсылу. (*Җырга күчә.*)

Халәтемне урап алган сихри хисләр
Зәңгәр күккә очып менде канатланып;
Җан авазын җырга салып моңнар туды,
Күңелемнең кылларында канатланып.

Әйдә, кайтабыз калага. Тезләнәбез әтиләребезнең каршына. Алар аңлар безне, алар безне аңларга тиешләр.
Гөлсылу. Алар аңлады, Ихтыяр! Туебыз булмаячак!
Ихтыяр. Ничек?
Гөлсылу. Әтиемнең аягына егылдым. Барысын да сөйләп бирдем. Ул синең әтиеңә аңлатты.
Ихтыяр. Рәхмәт, Гөлсылу! Димәк, без үз иркебездә. Мин сиңа да бәхет телим, Гөлсылу! Мин хәзер кайткан җиремә китәм. Мин гашыйк булган кызның әтисе мин гашыйк булган кызны миңа бирергә риза. Сау бул, Гөлсылу!
Гөлсылу. Ашыкма! Сиңа Аксакалның рөхсәтен алу кирәк.
Ихтыяр. Нигә?
Гөлсылу. Синең әтиеңнең теләге. Безне ярәшкәндә, ул шаһит булган. Аның рөхсәтеннән башка безнең әтиләр килешүне боза алмыйлар.
Ихтыяр. Ул рөхсәт итәчәк, Гөлсылу! Ул бит минем мөгаллимем. Әйдә, янына барабыз.

Аксакал янына киләләр.

Мөгаллим, бу – Гөлсылу!
Аксакал. Беләм.
Ихтыяр. Безне ярәшкәндә, сез шаһит булгансыз икән.
Аксакал. Әйе, беләм.
Ихтыяр. Миңа әйтмәдегез.
Аксакал. Һәрнәрсәнең үз вакыты бар, олан.
Ихтыяр. Без Гөлсылу белән икебез дә...
Аксакал. Анысы да миңа мәгълүм, олан.
Ихтыяр. Безнең әтиләр туйны үткәрмәскә ризалар. Ләкин сезнең рөхсәтегездән башка алар сүзләреннән кайта алмыйлар. Рөхсәт итегез, мөгаллим?!
Гөлсылу. Рөхсәтегезне бирегез, бабакай?!
Ихтыяр. Нигә эндәшмисез, мөгаллим?
Гөлсылу. Әйтегез бер сүз, бабакай?!
Аксакал. Нинди сүз әйтим... Сезнең аталарыгыз, борынгыларның йоласын бозып, өсләренә гөнаһ алырга җыеналар. Әгәр мин дә аларга кушылсам, мин дә гөнаһлы булам. Син беләсең, олан, мин гөнаһ кылмыйча шушы яшемә җиттем. Инде, гөнаһ кылып, кыямәт көнне Ходай каршына басыйммы?
Ихтыяр. Үзегез әйттегез, мөгаллим, кичерелмәс гөнаһлар була, кичерелә торганнары була, дидегез. Гөлсылу белән мине бәхетле итү гөнаһ түгелдер.
Аксакал. Бәхеткә гөнаһ кылып ирешмиләр, олан.
Ихтыяр. Сез, әтиләр теләгенә каршы килү гөнаһ, дидегез, мөгаллим. Сез бит минем атам түгел.
Аксакал. Мөгаллимең белән алай сөйләшмиләр, олан.
Ихтыяр. Бергә булуыбызны Гөлсылу да, мин дә теләмибез.
Аксакал. Сез теләмисездер, әмма сезнең никахыгыз инде күктә язылган.
Гөлсылу. Безгә никах укылмаган.
Аксакал. Бәхәсләшмик, сылу зат.
Ихтыяр (*Аксакал аягына баш орып*). Бирегез рөхсәтегезне, мөгаллим?!
Гөлсылу (*Аксакал каршына тезләнеп*). Рөхсәт итегез, бабакай?!
Аксакал. Минем гөнаһлы буласым килми.
Ихтыяр. Аталарыбыз риза бит, мөгаллим.
Аксакал. Әгәр минем гөнаһны да өсләренә алалар икән, алсыннар.
Ихтыяр. Мөгаллим! Безгә нишләргә, мөгаллим?
Гөлсылу (*тезләнгән җиреннән торып*). Бабай, телисезме, мин барыгызның да гөнаһын үз өстемә алам?
Аксакал. Ни сөйлисең син, кызым?
Ихтыяр. Гөлсылу!
Гөлсылу. Барыгыз да гөнаһтан куркасыз. Мин сезнең кылмаган гөнаһларыгызны кичерәм.
Аксакал. Гөнаһларны Ходай гына кичерә.
Гөлсылу. Ул сезнең кебек рәхимсез түгел.
Ихтыяр. Гөлсылу!..
Аксакал. Син, бала, кирәгеннән артыкны сөйли башладың. Кыз кешегә әдәплерәк булу килешә.
Гөлсылу. Сез әдәпсез кыланганга, мин гаепле түгел.
Аксакал. Миңа сине тыңлап тору гөнаһ. (*Торып китә.*)
Ихтыяр. Нишләдең син, Гөлсылу? Әйдә, гафу үтеник.
Гөлсылу. Бар, чап артыннан. Карт башы белән...
Ихтыяр. Тукта, Гөлсылу, ул бер гөнаһсыз кеше.

Гөлсылу. Гөнаһсыз кеше булмый. Әгәр кеше бер гөнаһсыз икән, димәк, ул яшәмәгән. Ул туганда ук үлгән. Ә син... Син шуның артыннан барырга җыенасың. Минем күңелем сизгән, сиңа тартылмаган. Син – тере мәет. Алдашма, син гашыйк булмагансың. Син гашыйк булырга сәләтсез җан иясе, Ихтыяр.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Байрас бакчасы. Байрас белән Назлыгөл Ихтыяр киләсе юлга карап торалар.

Назлыгөл. Күренми.

Байрас. Кирәгеннән артык ашкынасың, кызым, хәерлегә түгел. Йөз илдән йөз егет килде, араларында кемнәр генә юк иде, берсен дә ошатмадың. Ә бу... кем икәнен белмичә...

Назлыгөл. Мин аның йөзенә күз салуга кем икәнен белдем. Аның йөзе якты, йөзе яктының күңеле дә якты була. Минем кулымны сорарга килүчеләрнең барысы да синең байлыгыңа кызыгып килүчеләр.

Байрас. Ялгышасың, кызым. Аларның үз байлыклары да җитәрлек. Синең гүзәллегең тартып китерә аларны.

Назлыгөл. Гүзәлләр күп дөньяда.

Байрас. Син берәү генә, кызым.

Назлыгөл. Синнән гафу сорап килгән егет тә берәү генә. Нигә килми ул? Аны көткәнемне белми микән? Миңа гашыйк булды, дисең. Юктыр, әткәй. Килер иде. Биш көн үтте бит инде.

Байрас. Өзгәләнмә, киләчәк ул, киләчәк.

Назлыгөл. Әткәй, без сиңа шундый оныклар бүләк итәчәкбез, син аларны сөеп туймассың.

Байрас. Ходай насыйп итә күрсен.

Назлыгөл. Ярәшелгән булуы хак микән? Бәлки, болай гына әйткәндер. (*Юлда килүчене күреп алып.*) Әткәй, бу ул түгел.

Байрас. Карахан бәкнең углы Карачура. Тагын нигә килә? Син аны ике тапкыр борып җибәргән идең.

Назлыгөл. Кертмә, әткәй. Мин берсен дә күрергә теләмим. Мин бары тик бер генә егетне көтәм.

Байрас. Керсен. Белим ниятен. Син курыкма, кылычым янымда. Сине һәм үземне сакларлык куәтем үземдә.

Карачура керә.

Карачура. Бакчагызга бу юлы рөхсәтсез кердем, Байрас бай. Кичерегез.

Байрас. Кергәнгә чыгар юл да бар.

Карачура. Өченче кат килүем, Байрас бай.

Байрас. Күреп торабыз.

Карачура. Гүзәлләрдән гүзәл кызыгыз нигә дәшми?

Назлыгөл. Минем кулымны сорарга өч тапкыр килмиләр. Минем сүзем өч түгел, бер генә.

Карачура. Мин килдем. Мин – тирә-якта дан тоткан Карахан бәкнең углы. Минем теләгемнең үтәлмичә калганы юк. Өч килермен, биш килермен, йөз килермен – теләгемә ирешкәнче килермен.

Назлыгөл. Син минем җавабымны хәтерлисеңме?

Карачура. Минем хәтерем сәламәт.

Назлыгөл. Кабатлап күрсәт.

Карачура. Рәхим ит.

Иртән түгел, кич түгел,
Көндез түгел, төн түгел,
Юлсыз юлдан юл буйлап,
Уй уйламый, уй уйлап,
Ерак юлга чыгып кит,
Бер урманга барып җит.
Урман агачсыз булыр,
Имәннәр шаулап торыр.
Сул якка да карама,
Уң якка да карама,
Алга-артка күз салма,
Кара күзеңне йомып –
Җирдә ятар бер болыт.
Суы беткән, ди, агып.

Шуны учыңа салып,
Юлсыз юлдан юл табып,
Кайтсаң бакчама алып,
Каршыма килеп бассаң,
Болытны күккә ассаң,
Шуның күләгәсендә
Теләр-теләмәс кенә
Сузармын сиңа кулым –
Булырмын тугры колың.

Ялгышмадыммы?

Назлыгөл. Юк, Карахан углы. Кайда болытың?

Карачура. Күзеңне йомып күккә кара. Болытымны күрерсең.

Назлыгөл. Ул мин әйткән болыт түгел.

Карачура. Сусыз болыт, дидең. Яңгыр яумый, димәк, суы юк. Мин аны учыма салып китердем дә баш очыңа элеп куйдым. Шуның күләгәсендә басып торабыз. Кулыңны бир!

Назлыгөл. Ул болыт синең учыңда түгел иде.

Карачура. Кулымда иде.

Назлыгөл. Мин күрмәдем.

Карачура. Ә мине күрәсеңме? Карахан углы Карачураны күрәсеңме, Байрас кызы?

Назлыгөл. Күрмим.

Карачура. Күзеңне ачыбрак кара.

Назлыгөл. Карадым. Чыгып барган эзеңне күрәм. Хуш!

Карачура. «Хуш» дияргә ашыкма, кочагымда ятасың бар.

Байрас. Кызым белән андый телдә сөйләшергә рөхсәтем юк.

Карачура. Мине андый телдә сөйләшергә мәҗбүр итмәгез. Мин Карахан бәк углы Карачура.

Байрас. Әнә кергән капкаң, Карахан бәк углы Карачура, теге яктан яп.

Карачура. Капканы кызың белән бергә ябарбыз, Байрас бай. Кылычыңа тотынма, сугышырга килмәдем. Бир кызыңны, Байрас бай!

Назлыгөл. Юк!

Карачура. Тавышың көр чыкмый, Назлыгөл.

Назлыгөл. Юк! Юк!

Карачура. Сәбәбен әйт, һич булмаса.

Назлыгөл. Мин синнән куркам, Карахан углы.

Карачура. Бир кулыңны, курыкмассың.

Назлыгөл. Минем көткән егетем бар.

Карачура. Бәк углы түгелдер.

Назлыгөл. Көткән кеше хан улыннан да кадерлерәк була.

Карачура. Бу синең соңгы сүзеңме?

Назлыгөл. Соңгы сүзем.

Карачура. Якынрак килеп, күземә карап әйт.

Назлыгөл (*Карачура янына килеп*). Соңгы сүземне тагын бер кабатлыйм. Мин синеке булмаячакмын.

Карачура. Минем дә соңгы сүзем бар, Байрас бай кызы. (*Назлыгөлнең битенә нидер сибә дә чыгып йөгерә.*)

Назлыгөл, куллары белән битен каплап, сыгылып төшә.

Байрас. Кызым! Ни булды, кызым?!

Назлыгөл. Минем күзләрем әчетә, әткәй. Алып төш елгага, юыйк.

Байрас. Әйдә, әйдә, кызым. (*Назлыгөлне җитәкләп алып чыгып китә.*)

Ихтыяр керә. Назлыгөлне эзли. Җыр суза.

Ихтыяр. Язмыш безне очраштырды көтмәгәндә,
Гыйшкым мине алып килде яннарыңа.
Язмыш безне ярлар итеп кавыштырса,
Каршыларбыз бергә бәхет таңнарын да.

Ярдан Байрас белән Назлыгөл күтәреләләр. Ихтыяр каршыларына йөгереп килә.

Назлыгөл. Кемдер бар? Мин аны күрмим, әткәй.

Байрас. Ул синең көткәнең.

Назлыгөл. Соңлады. Соң инде. Әткәй, алып кайт мине өйгә.
Ихтыяр. Назлыгөл!..
Назлыгөл. Әтием, алып кит.

Ихтыяр ни уйларга белми торганда, Байрас әйләнеп килә.

Ихтыяр. Әссәламегаләйкем! Мин килдем.
Байрас. Күрәм. Ләкин вакытсыз килдең.
Ихтыяр. Мин мөгаллимнең рөхсәтен алырга тиеш идем.
Байрас. Ишеттеңме кызымның сүзләрен?
Ихтыяр. Ишеттем, әмма аңламадым.
Байрас. Гөнаһың кичерелде, анысын аңладыңмы?
Ихтыяр. Ләкин...
Байрас. Ишеттең, кызым сине күрергә теләмәде.
Ихтыяр. «Бирәм» дигән идең. Назлыгөл дә каршы сүз әйтмәде ул чакта.
Байрас. Хуш, егет!

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Беренче күренештәге елга яры. Аксакал таш өстендә утыра.
Мөнәҗәтен әйтә.

Аксакал.

Гомер буе саклап килдем аклыгымны.
Гөнаһ кылмый каршыладым картлыгымны.
Тик гөнаһсыз яшәдем дип сөенә алмыйм,
Уртаклашыр бер кешем юк шатлыгымны.
Яшьлегемдә бер гүзәлгә гашыйк идем,
Үзем сөйдем, үзем, сөю – гөнаһ, дидем.
Бу гөнаһлы уйларымны кичер, Ходам,
Бүген уйлыйм – мин кемгә соң бәхет бирдем.

Гөлсылу йөгереп керә. Аксакал янына килә.

Гөлсылу. Мин сезне эзлим, бабакай!
Аксакал. Нигә кирәк булдым тагын, сылукай?
Гөлсылу. Әтиләребезгә фатихагызны биргәнсез.
Аксакал. Шулай тиештер дип санадым, хәерле булсын.
Гөлсылу. Хәерле булыр, Алла боерса. Кешеләрнең бәхетенә киртә кормау хәерле эш бит, бабакай. Тиздән безнең туебыз. Сез шул туйның түрендә утырырсыз.
Аксакал. Рәхмәт, сылукай! Ярәшелгән кешең күренми нигәдер.
Гөлсылу. Ул да бәхете белән очрашырга китте. Ул әле белми сезнең фатиха биргәнегезне. Белгәч, сөенер. Ә сезнең, бабай, гашыйк булганыгыз булдымы?
Аксакал (*паузадан соң*). Мин дә адәм баласы бит, сылу зат.
Гөлсылу. Ә ул чибәр идеме?
Аксакал. Күп сораулар бирәсең.
Гөлсылу. Кичер, бабакай! Рәхмәт сезгә, бабакай! Сау бул, бабакай!

Аксакал яныннан китә. Елга яры буйлап шатлыгыннан нишләргә белмичә йөри, җыр суза.

Әй, агымсу, күрәсеңдер,
Мин бәхетле бүген.
Бәхетемне син күрәмсең,
Минем зәңгәр күгем?

Безгә сез бәхет теләгез,
Гөлләр, бөдрә таллар.
Сәгадәт һәм бәхет теләп
Атар алсу таңнар.

(*Ихтыярны күреп алып, аңа каршы йөгерә.*)
Ихтыяр!

Ихтыяр. Исәнме, Гөлсылу!

Гөлсылу. Безгә бәхет инде. Аксакал бабай фатихасын биргән. Ә син нигә болай боек?

Ихтыяр. Соңладым, соңга калдым, Гөлсылу!

Гөлсылу. Ни булды, сөйлә?!

Ихтыяр. Синең бәхетле көнеңдә, шатлыгың ташып торганда, үз хәсрәтемне сөйләү килешмәс.

Гөлсылу. Без бер көнне туып, бергә уйнап үстек. Арабызда гыйшык уты кабынмаса да, син миңа якын. Син минем хисләремне аңладың. Икенче берәүгә булган мәхәббәтемне кабул иттең. Сине бәхетле итеп күрәсем килә. Бәхетле идең бит.

Ихтыяр. Бәхетем кыска гомерле булды. (*Җырга күчә.*)

Хыялымның ал гөлләре
Шиңделәр инде;
Бәхет кошы кунган таулар
Иңделәр инде.
Мин каршылар алсу таңнар
Атмый калдылар.
Җилдән җитез тулпарыма
Тышау салдылар.

Аксакал янына килә.

Кичер, мөгаллим! Синең фатихаңны алмый киткән идем, Ходай каһәренә юлыктым. Алма бакчасының хуҗасы гөнаһымны кичерде, тик... минем гыйшкым төшкән кыз миннән баш тартты.

Аксакал. Сәбәбе ни?

Ихтыяр. Белмим, мөгаллим. Атасы аны миңа бирергә җыенган иде бит. Кыз да каршы түгел иде. Мин ашкынып бардым, кыз сөйләшергә дә теләмәде. Соңладың, диде. Нигә соңладым, аңламадым. Мин бит чабып килдем. Өч көн үтәсе юлны бер көндә үттем. Нишлим, мөгаллим?

Аксакал. Син инде үсеп егет булдың, олан. Минем итәгемә ябышып йөрер яшьтән уздың.

Ихтыяр. Нишлим, мөгаллим? Әнә бит фатихаңны алмаган идем дә... Ярдәм ит, мөгаллим?!

Аксакал. Ничек итеп?

Ихтыяр. Син беләсең. Син бар нәрсәне дә беләсең.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Байрас бакчасы. Байрас белән Назлыгөл алмагач янында утыралар.

Назлыгөл. Әткәй, юлда берәү дә күренмиме?

Байрас. Юк, кызым.

Назлыгөл. Әткәй, алмагачның алмалары бармы әле?

Байрас. Бар, кызым.

Назлыгөл. Өзеп бир берсен. (*Байрас өзеп биргән алманы күкрәгенә кыса.*) Юлда берәү дә күренмиме, әткәй? Син яхшылап кара, бәлки, ул әле ерактадыр.

Байрас (*юлга текәлебрәк карый*). Кемдер килә, кызым.

Назлыгөл. Әткәй, алып кит мине өйгә.

Байрас. Күтәсең бит, кызым.

Назлыгөл. Алып кит. Әйт аңа, килеп йөрмәсен. Киләме?

Байрас. Ул түгел бугай килүче.

Назлыгөл. Нигә ул түгел? Ул булырга тиеш иде.

Байрас. Ни дип әйтим инде, кызым?

Назлыгөл. Әтием, син миңа ачуланмыйсыңмы?

Байрас. Нигә?

Назлыгөл. Килүче кем, әткәй?

Байрас. Таныш кыяфәт. Кайчандыр синең кулыңны сорап килүчеләрдән берсе шикелле.

Назлыгөл. Монысы нишләргә тели? Керсен, әткәй! Син әйт, бирәм, диген. Хәзер үк алып кит, диген.

Байрас. Ни сөйлисең, кызым?

Назлыгөл. Сыныйсым килә, әткәй! Беләсем килә, бар микән ул мәхәббәт?!

Азамат керә.

Азамат. Әссәламегаләйкем, Байрас бай! Мин Азман бәкнең углы Азамат буламын. Таныгансыздыр дип беләм. (*Назлыгөлгә.*) Гүзәл зат, мин тагын килдем каршыгызга. Ләкин ялынып килмәдем. (*Байрас алдына кылыч ташлый.*) Алыгыз моны, Байрас бай.

Байрас. Ни ул?

Азамат. Карахан бәк углы Карачура кылычы. Ул юк. Шакшы затлар җир өстендә яшәргә тиеш түгел.

Назлыгөл. Син?..

Азамат. Әйе, мин, гүзәл зат. Мин барысын да ишеттем. Ләкин бу сезнең өчен үч алу түгел. Аны юк итеп, сезнең кулыгызны сорау түгел уемда. Мин бары тик җир өстен бер шакшыдан чистарттым. Әйттем, кулыгызны сорарга ялынып килмәдем. Әгәр дә күңелегездә минем өчен бер почмак бар икән...

Назлыгөл. Туктагыз.

Азамат. Сез минем өчен иң гүзәл зат, беренче тапкыр күргәндә йөрәгемне биләгән асыл зат. Шуннан артыгын әйтә алмыйм.

Назлыгөл. Кичерегез, егет солтаны! Мин сезгә рәхмәттән башка сүз әйтә алмыйм.

Азамат. Мин сезне кызганып килмәдем, гүзәл зат. Кешене кызгану – аны түбәнсетү. Сез элекке кебек үк гүзәл. Мин сез әйткәнне дә, мин әйткәнне дә онытмадым.

Комсыз чүлне табармын,
Сусыз күлне табармын.
Сусыз күлдән дә су алып,
Төпсез чиләккә салып,
Чиләкне тутырырмын.

Сау булыгыз, гүзәл зат! Сау булыгыз, Байрас бай! (*Чыгып китә.*)

Байрас. Кызым!..

Назлыгөл. Дәшмә, әткәй. Ни әйтәсеңне беләм.

Байрас. Алай тәкәббер булырга ярамый.

Назлыгөл. Бу тәкәбберлек түгел, әткәй... Кара, килүче күренмиме?

Байрас. Кемдер килә. Әмма ул кыз бала бугай. Әйе, әйе, кыз бала. Нигәдер ашыга, чаба. Берәр хәбәр китерәме? Хәерле хәбәр булсын.

Назлыгөл. Егетләр килгән юлдан кызлар йөри башлады. Әткәй, күңелем сизә, ул миңа ниндидер шатлык китерәдер кебек.

Байрас. Ходай кушсын!

Назлыгөл. Әткәй, теге кылычны суга ат.

Байрас. Нигә, кызым?

Назлыгөл. Ятсын дәрья төбендә. Берәүнең дә кулына эләкмәсен.

Байрас. Синеңчә булыр, кызым!

Гөлсылу керә. Сулышын көчкә ала.

Гөлсылу. Байрас байның бакчасымы? (*Назлыгөлгә.*) Сез аның кызымы? Назлыгөлме?

Байрас. Үзең кем буласың?

Гөлсылу. Мин Ташкаладан. Ихтыярның ярәшелгән кызы. Танышмы сезгә ул исем? Мин сезгә күңелсез хәбәр китердем. Ләкин ул хәбәрнең ахыры күңелле булсын өчен Назлыгөлнең сүзе кирәк. Шуны әйтим иң элек, без инде Ихтыяр белән ярәшелгәннәр түгел. Мин башка берәүнең хәләле булачакмын.

Назлыгөл (*түземсезләнеп*). Хәбәрне әйтегез.

Гөлсылу. Мин аны үзегезгә генә әйтергә тиеш.

Назлыгөл. Әтиемнән яшерен сүзем юк.

Гөлсылу. Ике кыз сөйләшкәндә, ир заты артык.

Назлыгөл. Әткәй, ни әйтәсең?

Байрас. Сөйләшегез, кызым! (*Гөлсылуга.*) Хәбәрең яман булмасын.

Гөлсылу. Мин, яман, димәдем, күңелсез, дидем. (*Байрас читкә авышкач, Назлыгөлгә.*) Сез чыннан да чибәр.

Назлыгөл. Хәбәрегезне әйтегез.

Гөлсылу. Әйтеп куям – мин Ихтыярның бәхетле булуын телим.

Назлыгөл. Хәбәрегезне әйтегез.

Гөлсылу. Ихтыяр урын өстендә ята.

Назлыгөл. Ни булды аңа?

Гөлсылу. Сәбәпчесе – сез. Сезгә ул гашыйк булган, беләсездер. Аңлавымча, беренче килүендә сез аның гыйшкын кабул иткәнсез, хәтта сезнең әтиегез аңа сезне кияүгә бирергә теләгән. Икенче килүендә сез аны куып җибәргәнсез.

Назлыгөл. Мин куып җибәрмәдем.

Гөлсылу. Соңладың, дигәнсез. Ни булды? Ихтыяр сәбәбен белми. Сәбәбе нидә? Ә нигә сез читкә карап сөйләшәсез?

Назлыгөл (*паузадан соң*). Нигә үзе килмәде?

Гөлсылу. Ихтыяр сез белгән, сез күргән егетләргә охшамаган. Ул үз бәхете өчен үзе көрәшә белми. Ләкин ул саф күңелле егет. Сәбәбен дә аңлатмыйча, аны куып җибәрергә сезнең хакыгыз юк.

Назлыгөл (*паузадан соң*). Сәбәбе бар.

Гөлсылу. Мин аны белмичә моннан китмәячәкмен.

Назлыгөл. Сез минем күземә карагыз.

Гөлсылу. Карадым.

Назлыгөл. Ни күрәсез?

Гөлсылу. Сезнең күзләрегез күрмиме?

Назлыгөл. Әйе, мин сукыр.

Гөлсылу. Бу турыда Ихтыяр белә идеме?

Назлыгөл. Юк.

Гөлсылу. Нигә әйтмәдегез?

Назлыгөл. Син мине газапларга килдеңме?

Гөлсылу. Мин миңа ярәшелгән ярның минем кебек үк бәхетле булуын телим.

Назлыгөл. Мин дә аның бәхетенә киртә булырга теләмим. Без беренче очрашканда күзләрем күрә иде. Мин аңа күзләремне тутырып карадым. Көткәнем килде дип куандым. Икенче килгәндә... Юк, мин аны бәхетсез итәргә теләмим.

Гөлсылу. Сәбәбен әйтергә тиеш идегез.

Назлыгөл. Син әйтер идеңме?

Гөлсылу. Мин аңа әйттем. Син миңа якын, әмма ярата алмыйм, дидем.

Назлыгөл. Син сау-сәламәт.

Гөлсылу. Сез аның килүен көтәсезме?.. Нигә эндәшмисез?

Назлыгөл. Көтәм, ләкин...

Гөлсылу. Ул килер. Ихтыярның сөйләвенә караганда, сез йөз илдән килгән йөз егетне борып җибәргәнсез. Ихтыяр соңгысы булыр.

Назлыгөл. Син шундый ышанып әйтәсең.

Гөлсылу. Без көчле кавем балалары, Назлыгөл! Безне ышаныч, өмет яшәтә.

Назлыгөл. Син ерак юлны җәяүләп үттеңме? (*Байрасны чакырып*.) Әткәй!..

Байрас. Тыңлыйм, кызым!

Назлыгөл. Әйт, кунакны каласына илтеп куйсыннар.

Гөлсылу. Юк, мин Ихтыярны монда көтәм. Әгәр рөхсәт булса. Байрас бай, әгәр Ихтыярны алырга кешеләр җибәрсәң, миннән рәхмәт ишетерсез.

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук урын. Байрас белән Аксакал.

Аксакал.

Йөз яшәдем, төшенмәдем дөнья гамен,
Сизми калдым, татымый калдым яшәү тәмен.
Миннән соңра килгәннәргә васыятем шул:
Өйрәнегез дөньяларда яшәү фәнен.

Үзем шулай көйләдем, яшәвемнән разый булмадым, шәкертләремне үзем яшәгәнчә яшәргә өйрәттем. Шәкертләрем минемчә яшәргә тырыштылар. Хәзер уйлыйм – ялгышканмын, ахрысы. Фани дөнья белән хушлашканчы, бер ялгышымны төзәтергә булдым. Иң зиһенле, иң күркәм шәкертемә мәхәббәт зәхмәте, гыйшык чире йокты. Нигәдер мин аны бу чирдән дәвалыйсым килми. Тәкъдирне Ходай яза. Тәкъдирендә синең кызыңны очрату насыйп булган.

Байрас. Кызым да бит язмышының шул якка борылуын көтеп яшәде. Әмма әнә ничек килеп чыкты.

Аксакал. Кызыңның нигә Ихтыярны биздерергә теләвен мин аңлыйм. Ул үзенең мәхәббәтен саф килеш сакларга тели. Газаплы булса да, мәхәббәтне озын гомерле итәсе килә. Егетнең, өйләнешеп яши башлагач, күңеле кайтудан курка. Ләкин минем шәкертем андый түгел. Кызыгызның шундый хәлгә тарыганын белгәч тә, аның хисләре үзгәрмәде.

Байрас. Кызым да аны үзе көтә, үзе... Бүген дә егетнең килүен көтте, килгәнен ишеткәч, кереп бикләнде.

Аксакал. Чакырыгыз аны минем янга, Байрас әфәнде?!

Байрас. Чыгар микән... (*Китә.*)

Аксакал. Әйе, йөз яшәдем, төшенмәдем дөнья гамен...

Гөлсылу белән Ихтыяр керәләр.

Гөлсылу. Бабакай, сез ачуланыгыз Ихтыярны. Ул бигрәк кыюсыз.

Аксакал. Тимә аңа, сылу зат. Әрсез булуга караганда, кыюсыз булу яхшырак.

Гөлсылу. Ул – ир кеше. Хатын-кызлар ир затына сыенырга тиеш.

Аксакал. Әгәр дә Ихтыяр әрсез булса, син аңардан баш тартмаган булыр идеңме?

Гөлсылу. Мин баш тартмадым, әмма...

Аксакал. Әмма шул менә. Олан, син нигә дәшмисең? Синең турыда сөйләшәбез?

Ихтыяр. Мин сезне тыңларга өйрәнгән.

Аксакал. Өйрәнүең бик яхшы. Сылу затның сүзләрендә дә хаклык бар. Сине бәхетле итәр өчен ул йөри. Киләләр. Мин аның белән үзем генә сөйләшергә тиеш.

Гөлсылу белән Ихтыяр китәләр. Байрас белән Назлыгөл керә.

Аксакал. Исәнме, саумы, гүзәл зат!

Назлыгөл. Сезгә исәнлек телим!

Аксакал. Каршы килмәсәң, икәүдән-икәү калыр идек.

Назлыгөл. Әткәй, мин риза.

Байрас китә.

Аксакал. Гүзәл зат, минем ни әйтергә җыенганымны беләсеңдер.

Назлыгөл. Беләмдер.

Аксакал. Бер генә сорау сорыйм – сез аны яратасызмы?

Назлыгөл. Сезнең алда мин ул сүзне әйтергә оялам.

Аксакал. Йөз илдән килгән йөз егетне борып җибәргәндә кыю булгансыздыр.

Назлыгөл. Алар аксакал түгел иделәр.

Аксакал. Мин, ерак юлны якын итеп, үзем килдем. Шәкертемнең бәхетле булуын теләп килдем.

Назлыгөл. Мин дә аның бәхетле булуын телим.

Аксакал. Ул синнән башка бәхетле булмаячак. Син елыйсың. Мин беләм, бу синең хәсрәттән елавыңның соңгысы булачак. Чакырыйммы үзен, гүзәл зат? Аның күңел күзенең нуры күп, икегезгә дә җитәрлек.

Назлыгөл. Нигә үзе генә килмәде ул?

Аксакал. Анысында минем гаебем дә бар. Кичерә күр. (*Ихтыярны чакыра.*) Олан!

Ихтыяр керә.

Аксакал. Мин Байрас әфәнде янында булырмын. (*Китә.*)

Назлыгөл (*озак паузадан соң*). Син миңа төбәлеп карап торасыңмы?

Ихтыяр. Гафу ит, синнән күзләремне ала алмыйм.

Назлыгөл. Тавышың янәшәмдә, ләкин үзеңне күрмим. Син карама миңа төбәлеп. (*Җырга күчә.*)

Карама син миңа алай, карама,
Ук кадама сызлап торган ярама.
Көтеп алган мәхәббәтем хакына
Салма мине дөрләп торган ялкынга.
Бәхет кошым күкләр гизгән чагында,
Гыйшык уты кабынганда җанымда...

(*Җырдан туктап елый.*)

Ихтыяр. Ни булды сиңа, Назлыгөл?

Назлыгөл. Мин... Мин сине күрмим. Күзләрем...

Карама син миңа алай, карама,
Ук кадама сызлап торган ярама.

Ихтыяр. Син...

Назлыгөл. Әйе, әйе, әйе...

Ихтыяр (*паузадан соң*). Назлыгөл! Бу дөньяда мин синең кебек үк бик аз яшәдем әле. Күзләрем дә яңа ачылып килә... Юк, Назлыгөл, сүзләремне мин сиңа бары тик җыр белән генә әйтә алам. (*Җырлый.*)

Булганда җанга җан янәшә
Күңелләр серләшә, берләшә;
Ул чакта кирәкми сүзләр дә,
Ул чакта җанга җан эндәшә.

Назлыгөл. Тукта! Мин сине күрәм. Мин сине күрәм, Ихтыяр! (*Җырга күчә.*)

Булганда җанга җан янәшә,
Күңелләр сөйләшә, серләшә;
Ул чакта кирәкми сүзләр дә,
Ул чакта күзгә күз эндәшә.

Ихтыяр белән Назлыгөл янына Аксакал, Байрас, Гөлсылу чыгалар.
Җыр дәвам итә.

Күзгә күз эндәшкән арада
Җаннарда мәхәббәт ярала.
Гашыйк җан елмаеп караса,
Дөньялар үзгәрә, яңара.
Җыр туа мәхәббәт турында,
Чыңларлык күңелләр кылында.
Була ул моңлы җыр, нурлы җыр
Җырларлык гомерләр юлында.

Пәрдә.

# Мулла

*Драматик хикәят*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Әсфәндияр – мәдрәсә тәмамлаган яшь мулла.
Самат – эшмәкәр.
Мөслимә – авыл карчыгы.
Вәлиәхмәт Габделәхәтович.
Чуртыш авылы кешеләре.
Бәдретдин (Бәрттин).
Налимә Чуртыш авылы кызлары.
Гөлназ
Сәлахетдин – Чуртыш авылы мулласы.
Лемур – җирле үзидарә рәисе.
Әмир – участок милиционеры.
Илдар
Вильдан Мөслимәнең шәһәрдән кайткан оныклары.
Илдария
Эльбрус – Чуртыш авылы егете.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Саматларның авылдагы өе. Самат белән Әсфәндияр керәләр.

Самат. Менә, хәзрәт, сиңа өй. Бөтен нәрсәсе бар. Газ, су кергән. Мебель дә җитәрлек. Бу безнең әтиләрнең өе. Әнкәй үлгәч, әтине үзебезгә алып килдек. Бу – сиңа. Дөресрәге – мәчеткә. Әгәр безнең авылда төпләнергә җыенасың икән, үзеңнеке булыр. Акча сорамыйм. Китәсең икән, өйне ничек алган булсаң, шулай калдырып китәсең. Тик киткәнеңне миңа белдер.

Әсфәндияр. Зур авыл.

Самат. Элек тагын да зур иде. Тарала. Авыл зур, ләкин тәртип юк. Сине эзләп табуым да, беләсең, шуның өчен. Монда, әйткәнемчә, мулла бар. Ләкин тәртип юк. Мәчет салдыр, диделәр. Салдырдым. Йөрүче юк. Мулла үзе дә мәчетне Гает көннәрендә генә ача, диләр. Формаль якларын мин мөфти белән, тиешле кешеләр белән сөйләшермен, кыскасы, бу авылның хуҗасы – син.

Әсфәндияр. Авыл советлары, колхоз бардыр бит.

Самат. Идарә итә алмый торган үзидарә бар, колхоз юк. Аның урынына нәрсәдер оештырдылар бугай. Кыскасы, син – хуҗа.

Әсфәндияр. Алай булмыйдыр ул.

Самат. Булдырсаң, була. Булдыра алмасаң, кит, гаепләмәм.

Әсфәндияр. Сез шундый итеп тасвирладыгыз авылны, монда кешеләр түгел, нindидер иблисләр яшидер сыман.

Самат. Иблисен белмим, шайтаннар җитәрлек. Хуҗа бул. Үзидарә дә, колхоз урынына калган нәрсәнең председательләре дә синнән куркып торсыннар.

Әсфәндияр. Куркытып кешене иманга китереп булмый.

Самат. Ничек икәнен үзең карарсың, өйрәтеп тормыйм. Өйләнгәнче-ниткәнче сиңа бит ашарга пешереп, өй җыештырып торырга да кеше кирәк. (*Тәрәзәдән карый да ачып.*) Мөслимә апа! Кер әле, Мөслимә апа!.. (*Әсфәндиярга.*) Бик чиста апа. Авылга килгән нәчәлствоны ул ашата. Борчылма, хезмәт хакың җитәрлек булыр, садака хисабына гына яшәтмәбез, ә садаканы мәчет файдасына ал. Бирсәләр, әлбәттә. Өйрәнсеннәр садака бирергә. Өйрәт. (*Мөслимәгә.*) Мөслимә апа, менә мәчеткә мулла алып кайттым.

Мөслимә. Әстәгъфирулла! (*Әсфәндиярны карый-тикшерә.*)

Самат. Мондый чакта «әстәгъфирулла» димиләр, Мөслимә апа, «сөбханалла» диләр.

Мөслимә. Бигрәк яшь күренә түгелме соң?

Самат. Сиңа гына яшь күренә ул. Мәдрәсә тәмамлаган белемле хәзрәт ул. Исеме – Әсфәндияр.

Мөслимә. Сәлахетдинне кая куясыз соң?

Самат. Теләсә, Әсфәндияр янында йөрер. Сиңа шуны әйтергә чакырдым, Мөслимә апа. Хәзрәтебез әле өйләнмәгән, егет кеше. Ул монда яшәячәк. Аны ашатып, өен җыештырып, керләрен юып торырга хатын-кыз кирәк. Син күршедә генә. Бер көтү малай үстердең. Нәрсәнең ничек икәнен беләсең. Әсфәдиярны сиңа тапшырам. Акчаң җитәрлек булыр.

Мөслимә. Туктале, акча дип... Казан кешесеме соң син, улым?

Әсфәндияр. Әйе, мин Казанда үстем.

Мөслимә. Шәһәр кешесенә ошап булыр микән соң?

Самат. Ошарсың. Бал-май эчендә үскән малай түгел. Ятим. Әби-бабайларының пенсиясенә үскән.

Мөслимә. Белмим инде тагын. Син әйткәч, каршы килеп булмас инде. Рәхмәт инде сиңа, авылны онытмыйсың. Күперебез юк иде, күперле иттең. Ярар, Винирага да әйтермен. Ач тормас, Алла боерса. Берәр кыз да табып бирербез. Тик менә рәтле-юньле кыз гына калмады авылда. Хисмәтуллада бар иде, ул да аракы эчә башлаган, хәерсез. Унҗидесе дә тулмаган килеш.

Әсфәндияр. Авыл кызы эчәме?

Мөслимә. Авылныкы шул. Ярый, борчылма, Самат. Синең сүзеңне аяк астына салмабыз. Чыгыйм әле мин, казлар карарга чыкканыем. Кичен безгә генә кереп ашар инде алайса. (*Китә.*)

Самат. Ишеттеңме, хәзрәт?

Әсфәндияр. Авылны мин башкачарак күз алдына китерә идем.

Ишекне киң итеп ачып, Вәлиәхмәт керә. Аңа Бәдретдин ияргән.

Вәлиәхмәт. Мине эзләмиләр икән, димәк, мин кирәкмим. Казан байларына сәлам бирдек! Бәрттин, исәнләш!

Бәдретдин. Әссәламегаләйкем!

Вәлиәхмәт. Менә шулай. Син, Бәрттин, беркайчан да исәнләшергә онытма. Исәнмесез, Самат Закирович!

Самат. Исәнмесез!

Вәлиәхмәт. Бу егетне кем дип белик?

Самат. Ул безнең авылның мулласы.

Вәлиәхмәт. Мулла?! Син дә мулла, мин дә мулла, атка печән кем сала? (*Саматка.*) Син алып кайттыңмы?

Самат. Әйе, мин.

Вәлиәхмәт. Әллә мөфти дә булып алдыңмы?

Самат. Синең белән акыл сатарга минем вакытым юк, Вәлиәхмәт.

Бәдретдин. Вәлиәхмәт түгел, Вәлиәхмәт Габделәхәтович.

Самат (*Бәдретдингә*). Ә син нәрсә көпә-көндез эчеп йөрисең?

Вәлиәхмәт. Төнлә эчсә, аның эчкәнен кем күрә, әйеме, Бәрттин?

Бәдретдин. Шулай, Вәлиәхмәт Габделәхәтович.

Вәлиәхмәт (*Әсфәндиярга карап торып*). Мулла... Әйе, муллалар күбәйгән саен, гөнаһлылар арта. Исемегез ничек?

Әсфәндияр. Әсфәндияр.

Вәлиәхмәт. Мин – Вәлиәхмәт. Вәлиәхмәт Габделәхәтович Әхмәтгалиев. Кайчандыр шушы авылдан сөрелгән Мөхәммәтгали мулланың оныгы. (*Бәдретдингә күрсәтеп.*) Менә бу мәхлук минем бабамны сөргән һәм мәчет манарасын кискән бәндәнең оныгы. Әйе, диген, Бәрттин!

Бәдретдин. Әйе, Вәлиәхмәт Габделәхәтович!

Вәлиәхмәт (*Саматка күрсәтеп*). Менә бусы да минем бабамны, ягъни шушы авыл мулласын сөргән һәм мәчет манарасын кискән адәми затның оныгы.

Самат. Җитте инде, Вәлиәхмәт!

Вәлиәхмәт. Син мине туктатма, Самат! Мин синең офисыңда утыра торган хезмәткәр түгел. (*Әсфәндиярга.*) Самат әфәнде бабасының гөнаһларын юар өчен авылда мәчет салдырды. Бәрттин, кил

әле монда?! (*Бәдретдин килгәч.*) Бу мәхлук бабасының гөнаһларын юып йөри. Минем акчага. Үз акчасы юк. Нәселләре белән хәерчеләр һәм теләнчеләр. Дөрес әйттемме, Бәрттин?

Бәдретдин. Дөрес, бик дөрес, Вәлиәхмәт Габделәхәтович.

Вәлиәхмәт. Үзе адашасы килгән кешегә юл күрсәтергә кирәкми. Киттек, Бәрттин! Сине күрергә килгән кеше үзен күрсәтергә дә килә. (*Кырт борылып, ишеккә таба атлый.*)

Самат. Вәлиәхмәт, туктагыз әле?!

Вәлиәхмәт. Туктадык.

Самат. Миннән курыкмасагыз да, сез канатыгызны бигүк җәймәгез, ярыймы!

Вәлиәхмәт. Бөркет канатын җәймәсә, җиргә мәтәлеп төшә.

Вәлиәхмәт чыгып китә. Аңа Бәдретдин иярә.

Самат (*Әсфәндиярга*). Бу кеше белән сак бул. Бабасы Магнитогорскига сөрелгәч, шунда туып үскән кеше ул. Биш ел элек авылга кайтты. Берүзе яши. Өе тулы китап. Коръәнне яттан белә, диләр. Эчми, тартмый, бүтәннәрне эчертә. Авылда кибет ачкан. Кибетендә аракыдан башка нәрсә юк, диләр. Тәүлек буе сату итә. Каратэ буенча разряды бар бугай. Үзе әйтте. Дөресмедер, анысын белмим. Ярый, мин китәм. Телефон номерын беләсең. Сиңа бер үтенечем – зарланма. Зарланганнарны, елак-мескеннәрне яратмыйм.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыт кич. Әсфәндияр намазлык өстендә ястү намазын укый. Сәлахетдин керә. Ишек төбендә Әсфәндиярның намаз укып бетергәнен көтә.

Сәлахетдин (*Әсфәндиярның намазлыкны җыйганын күреп*). Әссәламегаләйкем!..

Әсфәндияр. Вәгаләйкемәссәлам! Түрдән узыгыз, бабай!

Сәлахетдин (*түргә узып утыра, дога кыла*). Ишеттем дә менә килдем әле. Мин бу авылда мулла булып торам. Самат яшь мулла алып кайткан, диделәр. Шулай тиештер. Үзе салдырган мәчет. Сәлахетдин атлы мин. Мәдрәсә-фәлән бетергәнсеңдер инде.

Әсфәндияр. Әйе.

Сәлахетдин. Хәзерге мәдрәсә бетергәннәр ваһһабистлар була инде ул. Без дә болай, Аллага шөкер, «Әлхәм» белән «Колһуалла»ны беләбез. Кирәк чакта «Ясин»ны да чыгабыз. Үлем-җитем булганда, үзебезчә җирлибез дә. Болай зарланмыйлар иде. Садака дигән нәрсә юк инде.

Әсфәндияр. Сезне аракы эчә, дип сөйлиләр.

Сәлахетдин. Самат әйткәндер инде. Кем эчми инде хәзер. Без бит фронтта эчәргә өйрәнгән халык. Унҗиде дә тулмаган иде сугышка киткәндә. Сәгать саен үлем. Ул яшьтә, үлем күреп торып, әллә ниләр эчәрсең. Эчелә инде. Бүтән кешесе табылмагач, алындым инде. Аллага шөкер, мәетне дога укып озатабыз. Син инде монда кирәкмәгәнне тыңлап йөрмә. Үз эшеңне бел. Авылга үзең сыман ваһһабистларны җыя күрмә.

Әсфәндияр. Кем соң ваһһабист?

Сәлахетдин. Кем булсын, шул террур ясаучы инде. Өйләр шартлатып йөрүче. Хәер, авылда шартлатырлык өе дә калмады инде. Бетә инде авыл.

Әсфәндияр. Нигә бетә соң ул?

Сәлахетдин. Кирәкмидер инде өстәгеләргә. Шәһәр кирәк булгач төзиләр бит. Авыл белән нишлисең. Җир сукалап интеккәнче, сатасың да аласың ризыкны Америкадан. Монда бер тавык боты ашар өчен ел буе интегәсең. Шәһәрдә саттың да алдың Америка ботын. Рәхәтләнеп кимер... Болай, мәет юарга җирәнмисеңме?

Әсфәндияр. Юып караганым юк.

Сәлахетдин. Авылда мулла мәет юганда гына кирәк инде ул. Җирәнсәң, ул эшне миңа калдыр. Мин өйрәнгән. Әз-мәз акчасы да шул үлем-җитем булганда гына килә. Казанда «Ясин» чыкканга ике йөз сум бирәләр, ди. Без монда егерме тәңкәгә эшлибез.

Вәлиәхмәт керә.

Вәлиәхмәт. Әссәламегаләйкем! Нәрсә, садака бүлешәсезме?

Әсфәндияр. Кеше өенә рөхсәт сорап керергә кирәктер.

Вәлиәхмәт. Рөхсәт сорап нәчәлство янына гына керәләр. Түрә булырга җыенмыйсыңдыр ич?

Әсфәндияр. Әдәп дигән нәрсә бар. Сез бит мулла оныгы. Ул әдәпсез булмагандыр.

Вәлиәхмәт. Оho! Бабайлар ялгышын оныклар төзәтә.

Әсфәндияр. Бабагыз ялгышканмыни?

Вәлиәхмәт. Ялгышкан. Кара мужикның аңгыра башына аң кертергә тырышкан. Шуның өчен мужиклар аны авылдан сөргәннәр. Алачыкта туган алга чыкмый. (*Сәлахетдингә.*) Ә син монда нишләп утырасың?

Сәлахетдин. Килдем әле менә.

Вәлиәхмәт. Йөрмә монда. Яшисең килсә, үләргә өйрән.

Сәлахетдин. Син дә мәңгелеккә килмәгән, Вәлиәхмәт! Кайттың да монда...

Вәлиәхмәт. Кайтып нишләдем? Әйтеп бетер, кайтып нишләдем?

Сәлахетдин. Авылга хуҗа булдың.

Вәлиәхмәт. Булдым. Сарык көтүе көтүчесез булмый.

Сәлахетдин. Мыскыл итмә инде ул кадәрле.

Вәлиәхмәт. Итәм. Сез мыскыл ителергә яратылган. Сез бетәргә тиеш. Бер югалган оят табылмый. Мин сезнең авылыгызга «Ясин» чыгарга кайттым.

Сәлахетдин. Ярый, китим инде мин, кем...

Әсфәндияр. Әсфәндияр...

Сәлахетдин. Әйе, Әсфәндияр. Ә син, Вәлиәхмәт, бик азынма. Кешегә «Ясин» чыгу җиңел нәрсә түгел ул. (*Китә.*)

Әсфәндияр. Нигә сез шундый усал?

Вәлиәхмәт. Усал гына түгел, явыз.

Әсфәндияр. Минем янга шуны исбатларга килдегезме? (*Паузадан соң.*) Нигә шулай текәлеп карап торасыз?

Вәлиәхмәт. Өйрәнәм. Мин бит психолог. Синең кем икәнлегеңне күзеңә карап беләсем килә.

Әсфәндияр. Белдегезме соң?

Вәлиәхмәт. Чамаладым. Куркак малай түгел син. Тәвәккәл күренәсең. Казандагылар белән ызгышырлыгың бар. Югыйсә анда власть белән бәлеш төбен бүлә алмый интегәләр.

Әсфәндияр. Бүлешер власть монда да бар шикелле.

Вәлиәхмәт. Мондамы власть? Бер яртыга социализмны саттылар, ике яртыны куйсаң, капитализмны сатачаклар. Үз җирен сатып эчкән мужикта нинди власть...

Әсфәндияр. Ә сез?

Вәлиәхмәт. Мин власть түгел.

Әсфәндияр. Әлегә мин сездән башка властьны күргәнем юк. Мин дә бит психолог. Имам-хәзрәтләр психология фәнен белергә тиешләр. Уйлавымча, бу авылга бүген сез хуҗа.

Вәлиәхмәт. Шуннан?..

Әсфәндияр. Шуннан шул. Сездәге властьны мин алырга телим. Сез авылны бетерергә, «Ясин» чыгарга кайткан, мин аны яшәтергә килдем.

Вәлиәхмәт. Әй сабый, сабый... Мәеткә аспиринның файдасы юк, энекәш. Әгәр проблема «Ясин»да гына булса. Авылның хуҗасы мин түгел. Авылның хуҗасы – азгынлык, бозыклык, имансызлык. Мин шуларны күреп куанучы гына.

Ишек шакыйлар.

Әсфәндияр. Керегез!

Налимә керә. Кулында бидон.

Вәлиәхмәт. Әнә хуҗаларның берсе.

Налимә. Нәрсә булган? Нигә ыржаясың?

Вәлиәхмәт. Прости, тетка, ыржаймыйм, яратып әйтәм.

Налимә (*бидонын идәнгә куеп*). Кем диден? Нинди праститутка мин сиңа, ә? Күрсәтермен мин сиңа праституткаңны. Авызыңа берне тондырырмын. Тешләреңне җыеп ала алмассың.

Вәлиәхмәт. Яле, тондырып кара.

Налимә, кизәнеп, Вәлиәхмәтнең битенә суга. Вәлиәхмәт аптырап кала.

Нишлисең син? Нишлисең син, ә? (*Налимәнең җилкәсеннән эләктереп ала.*)

Налимә. Җибәр!.. Җибәр!..

Әсфәндияр (*Налимәне Вәлиәхмәт кулыннан аерып ала. Вәлиәхмәткә*). Чыгып китегез!

Вәлиәхмәт. Вот кабахәт, этисе кебек кешегә суга.

Әсфәндияр. Чыгып китегез, Вәлиәхмәт Габделәхәтович! Үтенеп сорыйм.

Вәлиәхмәт. Вот кабахәт!.. (*Чыгып китә.*)

Налимә. Күрсәтермен мин сиңа праститутка. (*Муенын тотып.*) Буып үтерә язды, заразы.

Әсфәндияр. Башлап үзегез суктыгыз бит.

Налимә. Әйтмәсен теләсә нәрсә. Рәтле сүзе юк. Өе тулы китап. Үзен тагын мулла оныгы, диләр. Вәт хәшәрәт, нәрсә ди, ә! Кеше әллә нәрсә уйлар. (*Стенадагы көзге янына килеп чәчен төзәтә.*) Кара син аны... (*Бидонны кулына алып.*) Менә Мөслимә апа аш җибәрде. (*Кесәсеннән төенчек алып.*) Ипие монда. Кайда икән боларның савыт-сабалары. (*Шкафтан тәлинкәләр, кашыклар табып ала.*) Бөтенесе бар, берсен дә алмаганнар. Самат абыйдан куркалар, бүтән булса, әллә кайчан чистартып чыгарлар иде.

Әсфәндияр. Урлашалармыни авылда?

Налимә. Кайда урлашмыйлар соң?! Урлыйлар да сатып эчәләр. (*Тәлинкәгә аш сала-сала.*) Бар, кулыңны ю. Кранда су бар. Сөлге шунда. (*Кулларын юып килгән Әсфәндиярга.*) Утыр, бисмиллаңны әйт тә аша. «Бидонны алып чык» диде Мөслимә апа. (*Урындык алып, ишек янына барып утыра.*) Аша, оялма.

Әсфәндияр (*өстәл янына утырып*). Сез кем?

Налимә. Ничек кем? Налимә!

Әсфәндияр. Мөслимә апаның кеме?

Налимә. Кеме булсын, күршесе. Аша әйдә, аша, оялма. (*Әсфәндиярның ашау рәвешен күзәтеп тора.*) Син чынлап та мулламы?

Әсфәндияр. Ә нигә?

Налимә. Сакалың да юк. Сакалсыз мулла булмый инде.

Әсфәндияр. Аның каравы түбәтәем бар.

Налимә. Түбәтәйне хәзер бөтен кеше кия инде.

Әсфәндияр. Каты суктыгыз теге кешегә. Үтерүегез мөмкин.

Налимә. Үтерерсең аны.

Әсфәндияр. Өлкән кешенең йөзенә сугу кыз кешегә килешми.

Налимә. Нинди өлкән кеше? Очраганда беренче сүзе – «кайчан үләсең инде?». Бөтенесе курка аңардан, мин генә курыкмыйм.

Әсфәндияр. Кыз кешегә сугышу барыбер килешми.

Налимә. Кызлар диеп торсаң монда.

Әсфәндияр. Кулыгыз да саллы, ахрысы.

Налимә. Сабан туенда гер күтәрәм, кул көрәштерәм.

Әсфәндияр. Ничә яшь соң үзегезгә?

Налимә. Нигә кирәк ул сиңа?

Әсфәндияр. Болай гына. Бик яшь күренәсез.

Налимә. Кара моны. Олылар кебек сөйләшеп утырган була. Үзең әле миннән дә яшьтер. Озак ашыйсың икән син.

Әсфәндияр. Ризыкны хөрмәт итәргә кирәк.

Налимә. Озак ашапмы?

Әсфәндияр. Тиз ашасаң, тәмен белеп өлгереп булмый.

Налимә. Барыбер бер корсакка керә инде ул. Сине монда Самат абый алып кайттымы?

Әсфәндияр. Юк, Путин җибәрде.

Налимә. Нәрсә-ә-ә-ә?

Әсфәндияр. Ә нигә?

Налимә. Урыс ич ул мулла җибәрергә... И-и, котыртып утырган була...

Әсфәндияр. Чынлап. Чуртыш авылы кешеләре мәчеткә йөрми икән, барып кайт әле, ди.

Налимә (*көлеп*). Дурак! Миннән көлгән була.

Әсфәндияр. Чынлап менә.

Налимә. Син мәчеткә йөрттерәсеңме?

Әсфәндияр. Йөрмәсәләр, хәбәр ит, милиция җибәрттерәм, диде.

Налимә. Бик исләре китә безнең авылда милициягә. Учаскавай үзе безнең авыл малайлары белән эчеп йөри.

Әсфәндияр. Бер дә аек кеше юк мәллә районыгызда?

Налимә. Бар да инде ул. Күбесе эчә шул.

Әсфәндияр. Сез дә эчәсезме?

Налимә. Минме? Дурак! Нишләп мин эчим. Сүзеңне үлчәп сөйлә.

Әсфәндияр. «Дурак» сезнең яраткан сүзегезме әллә?

Налимә. Әйтелә инде шунда. Ачуланма тагын.

Әсфәндияр. Исемегез ничек әле?

Налимә. Ничек булсын, Налимә.

Әсфәндияр. Матур исем.

Налимә. Әти кушкан инде – Галимә, Сәлимә, Налимә... Аша инде тизрәк.

Әсфәндияр. Булды бугай бу. Рәхмәт сиңа, Налимә.

Налимә. Аминыңны тот. (*Әсфәндиярның эченнән генә дога укыганын дикъкать белән күзәтә.*) Ә син нәрсә укыдың?

Әсфәндияр. Әлхәмделиллаһи әлләзи вә тәгамәнә, вәсаканә, вәҗәгаләнә минәл мөслимин. Биррәхмәтикә, Ярабби. Аллаһы әкбәр.

Налимә. Матур икән. Миңа да язып бирерсең. Ату мин битне генә сыпырып куям.

Өстәлдәге табак-савытны җыештырганда, Әсфәндиярның күзләрен күреп туктап кала.

Нишлисең, ә? Нигә шулай карап торасың?

Әсфәндияр. Чибәр сез, Налимә!

Налимә. Алай итеп карама бүтән. Ату ашарга кертмим. (*Табак-савытларны кухня ягына алып чыгып китә.*)

Бәдретдин керә.

Бәдретдин. Әссәламегаләйкем!

Әсфәндияр. Вәгаләйкемәссәлам! Әйдә, түрдән узыгыз, Бәдретдин абзый! (*Бәдретдиннең кеткелдәп көлгәненә гаҗәпләнеп.*) Нигә көләсез?

Бәдретдин. Түрдән уз, дисең бит... (*Паузадан соң.*) Баш авырта, берәр нәрсәң юкмы?

Әсфәндияр. Нинди нәрсә?

Бәдретдин. Нинди нәрсә, дип... Зарифулла абыйның әче балы була иде. Калмады микән? Баш авырта.

Әсфәндияр. Вәлиәхмәт Габделәхәтовичта юкмыни?

Бәдретдин. Ул минем ишеләргә бирми.

Әсфәндияр. Сез кем соң?

Бәдретдин. Кем дип, алкашлар инде без...

Налимә (*кухня ягыннан чыга. Бәдретдинне күреп*). Син монда нишләп йөрисең, алкаш? Бар, бар-бар, йөрмә монда. (*Бәдретдинне төрткәләп чыгарып җибәрә.*)

Әсфәндияр. Нигә аны куасыз?

Налимә. Йөрмәсен.Ияләштермә. Куып чыгара алмассың.

Әсфәндияр. Бу бит сезнең өегез түгел.

Налимә. Булмаса тагын. Син әле аларны белеп бетермисең. Юаш булсаң, өстеңә менеп атланалар. Тфү, заразы. Сасытып чыгып китте.

Әсфәндияр. Ул бит сездән өлкән кеше.

Налимә. Нәрсә һаман өлкән дә өлкән. Өлкән дип, әллә алдына тезләнимме? Сау бул, иртәгә керермен. Нәрсә кертим?

Әсфәндияр. Ни булса да ярый.

Налимә. Мөслимә апа әйтә, муллалар бәлеш ярата, ди... Ашагач укый торган доганы язып бирергә онытма.

(*Чыгып китә.*)

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук өйдә Мөслимә, Налимә, Гөлназ. Мөслимә утырып тора, кызлар өй җыештыралар.

Мөслимә. Мин чыгыйм, кызлар! Бөтен җирне әйбәтләп сөртеп чыгыгыз. Тормаган өйгә тычкан да ияләшкәндер. Исе сизелә.

Налимә. Карале, Мөслимә апа, моның өчен безгә түлиләрме соң?

Мөслимә. Кем түләсен, савабы булыр.

Налимә. Савабы дип, ничә ел бушка эшләтәләр.

Мөслимә. Бушка эшләүнең нәрсә икәнен белмисез әле сез. Менә без эшләдек ул бушка. Элек тә акча түләмәделәр. Хәзер дә, хезмәт хакыгыз әз булган дип, пинсәне тиенләп кенә бирәләр. Өйрәнә тор, ияләшә тор бу өйгә. Бәлкем әле, шуңа кияүгә дә чыгып куярсың. Өйләнмәгән, ди. Төс-кыяфәте дә Алланың биргәненә шөкер. Абыстай булып йөрерсең.

Налимә. Кит әле. Абыстай дип ул хәтле... Син кушканга гына эшлибез.

Мөслимә. Кайтып җитмәсә, ачкычын ишек өстенә куярсыз. (*Чыгып китә.*)

Гөлназ. Карале, малай, урынын кызлар кебек җыештырган. Прастыйналары чиста. Казаннан алып килгәндер инде.

Налимә. Кәнишне! Монда кем әзерләп торсын аңа.

Гөлназ. Бигрәк яшь күренә, әйеме?
Налимә. Күз читләрендә җыерчыклар күренә инде, бигүк яшь түгелдер.
Гөлназ. Көләч кешеләрнең күз кырыенда җыерчыклар була, ди.
Налимә. Миннән көлгән була. Путин җибәрде, ди. Шәймиев дисә, бер хәер.
Гөлназ. Шәймиев тә мулла җибәреп ятмый инде. Ул главаларны гына җибәрә. Боларның башлыгы мөфти дигән кеше.
Налимә (*караватка авып*). Шушында мулла хатыны булып ятсаң, ә!
Гөлназ. Тор, бөгәрлисең. Кайтып керсә...
Налимә. Кайтып керсә, яныма ятар. Ят әле син дә, ике кеше сыя микән?! (*Гөлназны кулыннан тартып яткыра, кочаклый.*) Кайттыңмы, җаным-бәгърем, муллакаем!
Гөлназ. Алай көлмә мулладан, гөнаһ булыр.
Налимә. Мулладан көлгәннең гөнаһысы юк, Алладан көләргә генә ярамый.
Гөлназ. Тор әйдә, сөртеп чыгыйк.

Шулчак азан тавышы яңгырый. Кызлар, сикереп торып, тәрәзәне ачып тыңлыйлар.

Налимә. Карале, җырлаган кебек...
Гөлназ. Үзе микән ул?
Налимә. Кем булсын инде тагын. (*Тыңлыйлар.*) Кара, бер җырга охшаган бит. (*Азаннан соң укылган дога аһәңенә кушылып көйли.*)
Гөлназ. Безнең татар теле укытучысы Зәки абый, Мөхәммәт пәйгамбәр татар булган, дип әйтә иде бит, дөрестер, ахры, иеме?
Налимә. Аңа бөтенесе дә татар инде. Иван Грузный гына урыс. Әйдә киттек. Догасын укып бетергәч кайтыр.
Гөлназ. Кайтса соң...
Налимә. Әй, көтеп торган кебек. Болай да инде... Кичә ашарына керткән идем. Күзенә ялгыш караган идем, сихерле. Кочагына кергәнеңне сизми дә калырсың. Илбрүснең күзе оятсыз. Ыржаеп көлә, барыбер кызлыгыңны мин алам, ди. Бирделәр ди, көтеп тор. Кагылып кына карасын, Казандагы дәү абыйның мылтыгы белән маңгаена терәп атармын. Син беләсеңме, «яратам» дип миннән әйттермәкче була, үзе әйтми. Ничә кызның башына җитте инде, хайван.
Гөлназ. Җиткергәч җитәләр инде. Синең белән миңа җитмиләр бит.
Налимә. Җитмиләр дә... Кыз килеш картаеп та инде... Синеке килеп йөриме әле?
Гөлназ. Килә дә. Куркытканнар әле теге бандитлар. Безнең авыл кызы янына килеп йөрмә, үтерәбез, дигәннәр.
Налимә. Вәт заразы, паразитлар. Үзләре дә алмый, бүтән авылга да бирмиләр.
Гөлназ. Шундый нәрсә уйлап чыгарганнар, ди. Чит авылга кияүгә чыгарга җыенсаң, башта үзебезнең авыл егете белән йоклыйсың, дип әйтәләр, ди.
Налимә. Сиңа әйттеләрме?
Гөлназ. Әйткәннәре юк та. Әгәр бездән качып чыксаң, иреңне имгәткәнче кыйныйбыз, инвалид ир белән яшәрсең, дип әйтәләр, ди... Әйдә, карават астын гына сөртәбез дә... (*Карават астына иелә. Аннан гантельләр тартып чыгара.*) Налимә, нәрсәләр бу?
Налимә. Куй урынына, кирәк әйбердер.
Гөлназ. Гер дә бар монда, Налимә.
Налимә. Яле, яле... чынлап гер бит бу, ике потлы. (*Күтәреп карый.*) Әллә спортсмен микән? Юри генә мулла булып йөридер әле.

Әсфәндияр кайтып керә. Налимә гер күтәргән килеш, тораташ булып катып, Әсфәндиярга карап тора. Аннан, герне атып бәреп, чыгып йөгерә. Аңа Гөлназ да ияргә. Әсфәндияр гер, гантельләрне карават астына урнаштыра. Сәлахетдин керә.

Сәлахетдин. Керергә ярыйдыр бит?!
Әсфәндияр. Әлбәттә, ярый, исәнмесез!
Сәлахетдин. Әссәламегаләйкем! (*Утырып дога кылгач.*) Түбән очның Әйзенхауыры үлгән.
Әсфәндияр. Кем?
Сәлахетдин. Шундый исемле кеше инде. Кушаматы бугай инде. Исеме белән әйтүче юк. Ниндидер ярамаган нәрсә эчеп үлгән. Уксус диме шунда. Миңа килгәннәр. Мин инде синнән узып... «Ю» дисәң, юармын анысы.
Әсфәндияр. Эчеп үлгән дисезме?
Сәлахетдин. Шуның белән кырыла инде халык... Нәрсә әйтәсең?..
Әсфәндияр. Нәрсә әйтәмме? Мин, Сәлахетдин абзый, эчеп үлгән кешегә «Ясин» чыкмыйм.
Сәлахетдин. Догасыз китсен дисеңме?

Әсфәндияр. Догасыз яшәгән бит.

Сәлахетдин. Догасыз дип... ул гына да гаепле түгел инде аңа. Заманасы догасыз булгач. Яши белеп яшәмәгән икән, җәзасын тегендә алыр. Ходай үзе белер.

Әсфәндияр. Бөтен эшне Ходайга тапшырсак, без нәрсәгә кирәк соң? Без Ходай язганны халыкка җиткерүчеләр. Безнең сүзгә колак салмыйлар икән, димәк, Ходай язганга каршы бармакчылар. Мин исерткеч эчеп үлгәннәргә һәм үз-үзләренә кул салган мордарларга «Ясин» чыкмыйм.

Сәлахетдин. Алай миһербансыз булырга ярамый.

Әсфәндияр. Ә сез миһербанлы яшисезме соң? Килгәнемә ике көн, әллә ниләр ишетеп бетердем инде. Иң миһербанлы затыбыз Аллаһы Тәгалә, әмма ул да тәмуг яраткан. Кешеләр моны белергә тиеш.

Сәлахетдин. Ваһһабист дигәч тә, алай ук булырга ярамый. Син килгән кеше. Без монда бергә яшәгән. Яманы да, яхшысы да үзебезнеке. Тормыш син дигәнчә генә бармый инде ул.

Әсфәндияр. Мин дигәнчә түгел, Ходай кушканча барырга тиеш.

Сәлахетдин. Ходае да инде аның ияләшкәндер. Карап тора бит... Алайса, үзем юып, үзем озатам инде.

Әсфәндияр. Карагыз үзегезгә. Әмма минем фатихам юк. Исәннәр гыйбрәт алып, нәтиҗә ясасыннар.

Сәлахетдин. Ясамый, улым, ясамый. Берәүсе эчеп үлә, икенчесе шуның мәете өстенә эчеп килә.

Әсфәндияр. Сез үзегез дәме?

Сәлахетдин. Син, малай, алай итеп сөйләшмә. Уйлаганыңның һәрберсен кычкырып әйтү егетлек түгел. Мин эчәм икән, бисмилла әйтми генә эчәм. Шуны да бел: беркайчан да исергәнче эчкәнем юк. Рәнҗеттең, энем!

Әсфәндияр. Гафу итегез! Мин сезне рәнҗетергә теләмәдем.

Сәлахетдин. Теләмибез дә бит...

Лемур белән Әмир керәләр.

Лемур. Керергә ярыйдыр бит.

Әсфәндияр. Рәхим итегез!

Сәлахетдин (*Әсфәндиярга*). Алайса, синең рөхсәтең белән озатам?..

Лемур. Кемне озатасың, Сәлахетдин абый?

Сәлахетдин. Ишеткәнсеңдер, Әйзенхауыр үлгән.

Лемур. Нигә син йөрисең анда? Син хәзер мулла түгел инде.

Әсфәндияр. Барыгыз, Сәлахетдин абзый! (*Сәлахетдин чыгып киткәч.*) Рәхим итегез, узыгыз! Тик татар өенә аяк киемнәрен салып керәләр.

Лемур, ишек янына барып, аяк киемен сала.

Әмир. Панимаешь, миңа аякны, фуражканы салу не положено. И минем ботинкалар чиста да. Младший лейтенант Хабриев. Участковый.

Әсфәндияр. Бик яхшы, утырыгыз. Әсфәндияр Әхмәтҗанов.

Лемур. Үзидарә председателе Лемур Сафиуллин. Үзегез килмәгәч, менә үзем килдем.

Әсфәндияр. Лемур, дидегезме?

Лемур. Лемур! Ә нигә?

Әсфәндияр. Маймыл исеме түгелме соң ул?

Әмир (*шаркылдап көлеп*). Точно! Так... (*Өй эченә күз йөртеп чыгып.*) Документлар бардыр инде сезнең?

Лемур. Әйттем бит инде, Самат Закирович алып кайтты.

Әмир. Самат Закирович понятно. Но документлар булырга тиеш. Положено. О назначении муллой, например.

Лемур. Туктале, Әмир, әйтеп торалар бит сиңа.

Әмир. Падажди, падажди, Лемур.

Әсфәндияр. Ызгышып китмәгез тагын. Икегез дә салып алган.

Әмир (*паузадан соң*). М-да... Значит, так... Значит, документлар в порядке. Яхшы. А то монда кайталар разный шантрапа. Кайсы законный переселенес, кайсы незаконный переселенес. Разбирайся тут... Кайсы үлгән черт знает што эчеп. За всех отвечай... (*Лемурга.*) Мин сиңа точно әйтәм, хатыны гаепле монда. Ул белгән, что муж будет искать. Специально уксусны аракы бутылкасына салып куйган. Айзынхауыру что? Тапкан и эчкән, и вообще. Из-за бабы пьют мужики.

Әсфәндияр. Ә сез ни өчен эчәсез? Вәлиәхмәт Габделәхәтович сыйлагангамы?

Әмир. Какой Валиахмат?

Әсфәндияр. Сезнең кебекләр өчен кибет тота бит. Көне-төне аракы сата.

Лемур. Аның рөхсәте бар кибет тотарга.

Әсфәндияр. Сезгә барысы да законно. Закон нигезендә эчәсез.

Лемур. Ты не очень-то выступай, братан!
Әсфәндияр. Я вам не братан. Зарубите на носу.
Лемур (*урыныннан торып*). Киттек, Әмир.
Әмир. Че ты?
Лемур. Киттек, дим.
Әмир. Че ты? Куда ашыгасың. Ну подох и подох ваш Айзынхауыр. Туда и ему дорога. (*Әсфәндиярга.*) Значит, не братан. Давай, давай наводи монда порядок. Лемур – маймыл, значит? Обизияна. (*Шаркылдап көлә.*) Че ты тут, Лемур, будь хозяином. Досиделся, понимаешь.
Лемур. Әмир, кит-те-ек...
Әмир. Ярый, ярый... значит, документлар порядкада? Пашли, значит. (*Чыгып китә.*)
Лемур (*чыга-чыга*). Ачуланмагыз! Гафу итегез! (*Чыгып китә.*)

## ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Җәйге төн. Әсфәндияр капка төбендәге утыргычта дөнья тыңлап утыра. Кайдадыр адашып калган сарык бәрәне кычкыра, кайдадыр эт өреп куя. Кайдадыр транзистор акырталар. Мәче башлы ябалакның ухылдап алганы да ишетелә. Ут яктысы урамга төшкән. Урамнан узучыларга Әсфәндияр күренми дә диярлек. Урамнан өч-дүрт малайны Мөслимә куып алып кайтып бара.

Мөслимә. Шушы вакытка хәтле йөрмәсәгез, дуңгызлар! Иртән уятып булмый. (*Малайлар көлешкәч.*) Ермагыз авызыгызны. Кайттылар да монда Казаннарыннан, дуңгыз көтүчесе ясап бетерделәр әбиләреннән. Вилдан! Куда пайдуш! Өйгә кайт!
Вилдан. Ну, бабушка!..
Мөслимә. Бирермен мин сиңа бабушка, ристан!
Вилдан. Дау ани, рано еще...
Мөслимә. Бирермен мин сиңа ранынны. (*Илдарга.*) Син зур бит инде, нигә иярәтеп чыгып китәсең? Син хуҗа бит, алар – кунак.
Вилдан. Мы тоже хуҗа. Синең внуки.
Мөслимә. Күрсәтермен внукиеңны. Мулла абыегызга әйтермен дә...
Вилдан. Ул нишләтә, дау ани?
Мөслимә. Нишләтергә белер. Чөкиләрегезне кисәр.
Вилдан. Нәрсә ул чөки?
Мөслимә. Атла аягыңны. Кяфер булып беттеләр. Илтәм дә бирәм әниегезгә.
Илдария. Илтмә, бабушка! Илтмә, дау ани!

Мөслимәнең кайсы кулына, кайсы итәгенә асылынып, чыгып китәләр. Вәлиәхмәт белән Бәдретдин узып бара.

Бәдретдин. Вәлиәхмәт, салып бир инде бераз гына?
Вәлиәхмәт. Вәлиәхмәт түгел. Иләктән – чиләкне, бизәктән тизәкне аерырга өйрән.
Бәдретдин. Вәлиәхмәт Габделәхәтович, салып бир бераз гына?
Вәлиәхмәт. Әле яңа гына эчтең.
Бәдретдин. Әз саласың бит, тел очына да йокмый.
Вәлиәхмәт. Тезләнеп сора. Тормыш ул Сабан туе, Бәрттин! Кемдер көрәшә, кемдер чүлмәк вата, кемдер шуларны күреп кызык таба.
Бәдретдин (*Вәлиәхмәт алдына тезләнеп*). Әз генә салып бир. Үләм бит.

Вәлиәхмәт, кесәсеннән шешә белән стакан алып, стакан төбенә аракы сала.

Вәлиәхмәт. Мә, лыкын! Үләр өчен егетлек кирәкми, үлә белеп үләргә егетлек кирәк.
Бәдретдин. Әз бит бу. Өстә инде бераз?
Вәлиәхмәт. Нәфес – нәфислекнең дошманы, Бәрттин!

Берничә тамчы аракы өсти. Бәрттин тәмләп эчә. Вәлиәхмәт шешә белән стаканны кесәләренә тыгып куя.

Бәдретдин. Рәхмәт, Вәлиәхмәт! Әзрәк булды инде...
Вәлиәхмәт. Исерәсең килсә, аракы эчмә, гашыйк бул. Иртүк өйгә килеп кирәсе булма, ботыңны сугып сындырырмын. Теге ташны күрәсеңме? Тәгәрәтеп китер шуны! (*Бәрттин тәгәрәтеп китергән ташка утырып.*) Җырла «Герман көе»н!
Бәдретдин. Әз генә салып бир?!
Вәлиәхмәт. Җырла! Күп итеп салырмын.
Бәдретдин (*моңлы тавыш белән җырлый*).

Атландым атның биленә,

Киттем Герман иленә:
Герман җире яшел үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм.

Без урамнан үткән чакта
Күтәрелде тузаннар;
Йә кайтырбыз, йә кайтмабыз,
Сау булыгыз, туганнар.

Вәлиәхмәт. Җырла, ник туктадың?

Бәдретдин. Атландым атның биленә,
Киттем Герман иленә:
Герман җире яшел үлән,
Әллә кайтам, әллә үләм.

Вәлиәхмәт. Син, бөҗәк, бу тавыш белән театрда җырларга тиеш идең. Син шуны әрәм итеп... Мә эч, тыгын! (*Аракы салып бирә.*) Бабаң – кабахәт, атаң – хәшәрәт, үзең – тизәк. (*Бәдретдинне тибеп ега.*)

Әсфәндияр түзми, торып болар янына килә.

Әсфәндияр. Нишлисез сез?

Вәлиәхмәт. Ә-ә-ә, сез мондамыни? Өр шуңа эт булып, Бәрттин!

Әсфәндияр (*үзенә өргән Бәдретдинне торгызып, өстен каккалый*). Бар, абзый, кайтып йокла.

Вәлиәхмәт. Өстен кагасыз, ә? Җирәнмисез.

Әсфәндияр. Ул җирәнгеч, ә сез аңардан да җирәнгечрәк!

Вәлиәхмәт. Сүзеңне үлчәп сөйлә. Телеңне тешләвең бар. Син, акыллы булсаң, тизәктән бизәк ясарга алынма.

Әсфәндияр. Кеше тизәк түгел!

Вәлиәхмәт. Бу авылда кешеләр яшәми.

Әсфәндияр. Бәлки, сезнең бабагыз да сезнең кебегрәк булгандыр. Шуңа куганнардыр.

Вәлиәхмәт. Әй син!.. (*Сугарга кизәнә.*)

Әсфәндияр аның кулын тотып ала. Вәлиәхмәт, Әсфәндияр кулының көчле икәнен сизеп, каратэ алымын куллана, ләкин үзе сырты белән килеп төшә. Сүзсез генә күтәрелә. Әсфәндиярга карап тора да китеп бара. Әсфәндияр ташны күтәреп алып юл өстеннән читкә алып куя да
урынына барып утыра. Налимә белән Гөлназ үтеп бара.

Налимә. Вәт заразы, тәки бәйләнә бит. Син мулла өенә кереп йөрисең икән, ди. Керсә, аның ни эше бар, хайван! Бик исе китте ди ул мулланың безнең ишеләргә. Кичә миңа әйтә, үзең шундый чибәр, шундый сылу, ямьсез сүзләр кушып сөйләшмә, ди. «Дурак» дигәнне дә ошатмаган, «заразы» дигәне дә ярамый. Ул Илбрүскә «заразы» дими ни дисең инде?

Гөлназ. Өендә берүзе ничек утыра икән? Клубка барырга ярамыйдыр инде аларга, иеме? Тәрәзәсеннән карыйк, нишли икән?

Налимә. Кит әле, егетләр тәрәзәсеннән карап йөрергә теге...

Гөлназ. Нинди егет булсын, мулла ич ул.

Налимә. И, дурак! Муллаларның да егетләре була инде.

Гөлназ. Тот та алайса, кияүгә чык шуңа.

Налимә. Кит әле, нишләсен ул минем белән. Укып та булмады, Казанга китеп тә булмады. Шул Илбрүсләр кала инде. Ярый ла синең егетең бар.

Гөлназ. Килмәде бит әле бүген.

Налимә. Әйдә, чыннан да карыйк әле, нишләп утыра икән.

Әсфәндияр яшәгән өйнең капкасына таба атлыйлар. Налимә Әсфәнди-
ярны күреп ала.

Бәтәч! (*Баскан җирендә катып кала.*)

Әсфәндияр. Хәерле кич, кызлар! (*Китәргә борылган кызларга.*) Качмагыз инде. (*Туктап калган кызлар янына килеп.*) Менә сезнең тавышны ишеттем дә чыктым әле.

Налимә. Нәрсә сөйләшкәнне дә ишеттеңме?

Әсфәндияр. Нәрсә турында сөйләштегез соң? Кызларның сүзе серле була бит ул... Төнлә авылыгыз бигрәк матур.

Налимә. Авылыгыз, ди. Авылыбыз, диген. Хәзер синең авыл да инде ул.

Әсфәндияр. Әйе шул. Бигрәк матур.

Налимә. Нәрсәсе матур инде.
Әсфәндияр. Мин кичә сандугач сайраганны тыңладым.
Налимә. Таңнан уяныпмы?
Әсфәндияр. Гөлназ нигә сөйләшми?
Налимә. Аның йөргән егете бар, ярамый.
Әсфәндияр. Сезнең юкмы?
Налимә. Юк шул әлегә. Киттек, Гөлназ!
Әсфәндияр. Ашыкмагыз инде. Минем үземә генә күңелсез.
Налимә. Күңелсез дип... Клубка барырга кирәк.
Әсфәндияр. Анда күңелләме?
Налимә. Күңелле дип... Селкенәбез дә таралабыз инде. Җыен бала-чага белән.
Әсфәндияр. Егетләр юкмыни?
Налимә. Аларның егетлекләре! Киттек, Гөлназ!
Әсфәндияр. Гөлназның китәсе килми. Сез тарткалыйсыз.
Налимә. Кем тарткалый, калсын.
Гөлназ. Үзең кал, ярыймы. (*Китеп бара.*)
Әсфәндияр. Сез кайтмагыз инде. Бераз утырыйк.
Налимә. Нишләп?
Әсфәндияр. Тыңлап.
Налимә. Нәрсәне?
Әсфәндияр. Дөньяны.
Налимә. Һе... Кызык икәнсең син... Мин өйрәндем теге доганы.
Әсфәндияр. Сез җырлый беләсезме?
Налимә. Юк. Мин тыңларга гына яратам. Минем дәү әтием матур җырлый, әнием дә. Минем колакка аю баскан. Мин синең җырлаганыңны гел тыңлыйм.
Әсфәндияр. Кайчан?
Налимә. Мәчеттәге радиодан.
Әсфәндияр. Җыр түгел бит ул, азан.
Налимә. Җыр кебек инде. Мөслимә апа әйтә, сиңа егерме ике яшь, ди.
Әсфәндияр. Дөрес әйтә. Сезгә ничә?
Налимә. Егерме тула көзгә.

Урамнан үтеп барган Эльбрус Налимәнең кулыннан эләктереп ала да сөйрәп алып чыгып китә. Анда кычкырышкан тавышлар. Налимәнең чырылдап кычкырганы ишетелә. Әсфәндияр йөгереп чыгып китә.
Налимәне күтәреп алып керә.

Әсфәндияр. Налимә, Налимә!..

Налимә дәшә алмый. Сыны каткан.

Налимә!.. (*Налимәне кочагына алып.*) Йә, йә... Тынычлан!..
Налимә (*телгә килеп*). Эчемә сукты, заразы.
Әсфәндияр. Әйтмәгез, әйтмә андый сүзне.
Налимә. Авырта.
Әсфәндияр. Районга шылтыратыйк.
Налимә. Кирәкми. (*Сулкылдап.*) Син мине кыйнаттырма, ярыймы? (*Әсфәндиярның кочагына сыенып.*) Кыйнаттырма! Син көчле бит. Син спортсмен бит.
Әсфәндияр. Йә, йә, тынычлан, тынычлан!..
Налимә. Син минем абыем бул, абыйлыларга тимиләр.
Әсфәндияр. Ярый, ярый, тынычлан!
Мөслимә (*кереп*). Ни булды монда?
Налимә. Мөслимә апа, минем эчемә суктылар.
Мөслимә. И Ходаем! Кайсысы инде тагын?
Налимә. Илбрүс!
Мөслимә. Хәерсез! Бер ел да юк бит төрмәдән чыкканына. Әйдә кайтабыз.
Налимә. Йөри алмыйм, Мөслимә апа, авырта.
Мөслимә. Милитсия чакырырга кирәк мөртәткә.
Налимә. Кирәкми, кирәкми.
Мөслимә. Кирәкми, димә. Үтереп ташлар.
Налимә. Кирәкми, кирәкми. Хәзер бетә авыртуы, туктый.

БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әсфәндияр яшәгән йортның өй эче. Караватында, чишенмәгән килеш, Әсфәндияр ята. Самат кергәнне күреп, торып утыра.

Самат. Нәрсә, эш беттемени, хәзрәт?

Әсфәндияр. Әссәламегаләйкем, Самат абый!

Самат. Сәлам, сәлам! (*Кул биреп күрешә.*) Нәрсә, кәеф юграк мәллә?

Әсфәндияр. Болай гына...

Самат. Болай гына булса ярый. Иямәшеп беттеңме инде?

Әсфәндияр. Мондыйга иямәшеп булмый. Иямәшергә Ходай язмасын!

Самат. Шулайдыр. Сәлахетдин абыйны утыртып кайттым. Мактый үзеңне. Халыкны клубка җыеп вәгазь укыгансың. Мәчеткә җыярга иде.

Әсфәндияр. Мәчет клуб түгел бит.

Самат. Вакыты-вакыты белән клуб булса да ярый. Иямәшсеннәр, үз итсеннәр.

Әсфәндияр. Юк, йөрмиләр. Берничә малай-шалай кызык итеп килгәли.

Самат. Бик әйбәт. Башта кызык итеп килсеннәр. Аннан инде... Тормыш яклары ничек, җайлымы?

Әсфәндияр. Мөслимә апа үз баласы кебек карый.

Самат. Өйләнеп җибәр. Күзең төшкән кыз юкмы соң әле?

Әсфәндияр. Бөтен авылларда да шулай микән, Самат абый? Монда бит... Болай булмый бит. Яшәү түгел бит бу.

Самат. Без мактап язган авыл юк ул бүген.

Әсфәндияр. Мин авылның элеккесен дә, хәзергесен дә белмим. Элеккесен мактыйлар, ләкин ун-унбиш ел эчендә генә кешеләр болай үзгәрә алмый.

Самат. Азыныр өчен кешегә күп вакыт кирәкми.

Әсфәндияр. Хайван хәленә төшкән Бәдретдин, ерткыч җанварга әверелгән Вәлиәхмәт абыйлар...

Самат. Мин сиңа тагын өсти алам... Моннан егерме чакрымдагы татар авылында фахишә. Акчага... Бөтен авыл белә. Йөриләр.

Әсфәндияр. Алып китегез мине моннан...

Самат. Йә, йә! Теге, эчеп үлгәннең җеназасына бармый дөрес эшләгәнсең. Киләчәктә дә йөрмә. Тик кисәтеп куй, ни өчен бармаганыңны ачык белсеннәр. Кунакка чакырсалар, бар... Аракылысына барма. Әйдә, мәчетне карап кайтыйк. Намаз вакыты да җитә.

Чыгып китәләр. Тастымалга төрелгән ризыклар күтәреп, Мөслимә белән Налимә керәләр.

Мөслимә. Гел ташып ашатып булмас. Газлары, сулары бар. Шушында гына әзерлик. Минем балалар белән вакытым юк, сиңа кала инде.

Налимә. Мин оялам, Мөслимә апа.

Мөслимә. Нидән? Кемнән?

Налимә. Әллә ни уйлавы бар. Нигә бу гел монда чуала дип...

Мөслимә. Уйласа тагын. Ипләбрәк карасын. Карамаслык түгел. Менә күлмәк киеп, яулык бәйләгәч тагын да чибәрләнеп киттең. Яшең унбиштә түгел, вакытында оя кормасаң, йөрерсең карт кыз булып. Үзе өчен саклап калган ул сине. Кара син явызны, теге Илбрүсне әйтәм. Хатын-кызның эченә сугарга ярыймы соң! Бала ярала торган урын бит ул. Аныкы шикелле аракы тутыра торган корсак түгел. Оялма, син үз эшеңне эшлә. Караса карый, карамаса, аның эше. Ошатасыңдыр бит үзен.

Налимә. Ошый инде, ничек ошамасын.

Мөслимә. Бик әйбәт. Мәхәббәт ул ошаудан башлана. Син, егерме яшеңә җитеп, мәхәббәтнең ни икәнен дә белмисең. Мин аны унҗиде яшемдә татыдым... Киттем. Оялма.

Чыгып китә. Налимә урын-җирләрне рәтли. Әсфәндиярның мендәрен иснәп-иснәп карый. Азан тавышын ишетеп, Әсфәндиярның намазлыгын ала, идәнгә җәеп шунда чүгәли дә ул язып биргән доганы укый.

Налимә. Әлхәмделиллаһи әлләзи вә тәганәмә, вәсаканә, вәҗәгаләнә минәл мөслимин. Бирәхмәтикә йа әрхәмәр рахимиин. Аллаһы әкбәр. (*Намазлык өстенә, бер иелеп, бер торып, һаман шул доганы укый. Азан тавышы туктагач, намазлыкны җыеп куя да көйли-көйли табын әзерли.*)

Китәм, дисең, китәм, дисең,
Китәм, дисең, кайларга шул?
Ниләргә сабыр итмисең
Тагын бер-ике айларга?
Китәм, дисең, китәм, дисең,
Китәм, дисең, күпкәме?
Әллә айга, әллә елга,
Әллә мәңгелеккәме?

Китәм, дисең, китәм, дисең...

Лемур белән Әмир керәләр.

Лемур (*Налимәгә*). Син нишлисең монда?
Налимә. Исәнмесез! Мөслимә апа ашатырга кушты.
Лемур. Самат абый кайда?
Налимә. Әсфәндияр белән мәчеткә кереп баралар иде. Ишетмәдегезмени дога укыганнарын?
Лемур. Нишлибез, Әмир? Шунда керәбезме?
Әмир. Чыгарлар әле.
Лемур. Чыгарлар әле, димә, Самат абый бит ул.
Әмир. Беләм инде, беләм. Крутойларны синнән күбрәк күргән.
Лемур. Самат абый крутой түгел. Ул – бизнесмен.
Әмир. Бизнесменнарын да күргән.
Лемур. Син күргәннәр бит ул вак-төяк. Моны Казанда да беләләр. Телевизорда күрсәттеләр.
Әмир. Ну и что.
Лемур. Әй-й-й, ну и что, дип торма инде. Шулар тирәсендә ялманып йөрисең.
Әмир. Но-но-но! Син ялманмыйсың что ли?
Лемур. Шулай инде, акчаң булмаса, ялманасың инде.
Әмир. Син аңардан иномарка машина сора. Үзидарәнең авторитетын күтәрергә, диген. Сорап барасың, панимаешь, районга берәр нәрсә, иномаркага утырып... Главаның күзе акая.
Лемур. Әйдә керик мәчеткә.
Әмир. Анда керсәк, опять ботинка салдыралар. Ә минем носкиның үкчәсе тишек.
Лемур (*көлеп*). Син Самат абыйдан носки сора.
Әмир. Син над милицией көлмә. Без булмасак, сине өч көн дә тотмыйлар. Понял? Яшисең монда, панимаешь, суслик кебек. Кругом безобразие.
Лемур. Безобразиене син карыйсың инде.
Әмир. Карыйм мин Малаевка Маринасы белән кайсы посадкага кереп киткәнеңне.
Лемур. Тавышланма инде.
Әмир. Вот и тавышланма.

Самат белән Әсфәндияр кайталар.

Лемур. Исәнмесез, Самат Закирович! Машинагызны күрдек тә... (*Әмиргә күрсәтеп.*) Бу...
Самат. Беләм. Хәлләр ничек соң, иптәш лейтенант? Тәртипме?
Әмир. Так точно, товарищ...
Самат. Ефрейтор. Армиядә мин ефрейтор идем. Нигә ишек төбендә торасыз, түргә узыгыз.

Лемур белән Әмир, аяк киемнәрен тиз-тиз генә салып, түргә узалар.

Самат (*урындыклар биреп*). Утырыгыз.

Налимә кухнядан поднос белән чәй күтәреп чыгып өстәлгә куя да яңадан кереп китә. Самат, аны күзе белән озатып калып, Әсфәндиярга
карый.

Әсфәндияр. Күрше кызы ул.
Самат. Их, күрше кызлары – йөрәгемнең сызлавы. (*Әмир белән Лемурга.*) Ничек соң, егетләр?!
Лемур. Яхшы, Самат Закирович! Менә күперебез җимерелде әле.
Самат. Акча кирәкме?
Лемур. Кирәк инде.
Самат. Мәчеткә йөрисезме?
Лемур. Мәчеткә? Мәчет дәүләттән аерым бит, Самат Закирович!
Самат. Син нәрсә, дәүләт булдыңмыни?
Лемур. Эш шундый бит инде безнең.
Самат. Нинди эш?
Лемур. Нинди эш дип... Вакыт та җитми.
Самат. Кая куясыз соң ул вакытны?
Лемур. Табыла инде эш.
Самат. Шулайдыр. Мәчеткә эшлексезләр генә йөридер. Менә син дәүләт инде, Лемур энекәш. Әйт әле син, дәүләттән ни өчен акча аласың? Ә сиңа ни өчен түлиләр, иптәш лейтенант?
Әмир. Мы выполняем то, что предписано.
Самат. Татарча белмисеңмени?
Әмир. Беләм.

Самат. Белгәч, нигә азапланасың? (*Лемурга.*) Авылдагы тәртиптән син канәгатьме?
Лемур. Ә нәрсә, Самат Закирович?
Самат. Канәгатьме, дип кенә сорыйм.
Лемур. Яшибез.
Самат (*Әмиргә*). Ә син?
Әмир. Нормально.

Мөслимә керә.

Мөслимә (*ашыгып*). Әсфәндияр, кил әле! (*Әсфәндиярның колагына пышылдый.*)
Самат. Исәнме, Мөслимә апа! Нәрсә анда серләшәсез?
Әсфәндияр. Бәдретдин абый үлгән. Асылынып.

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Мәчет эче. Ахшам вакыты. Әсфәндияр белән Сәлахетдин намаз укыйлар. Илдар, Вилдан, Илдария, йөгереп кереп, алар янына чүгәлиләр. Өлкәннәр эшләгәнне кабатлыйлар. Үзара төртешеп алырга да өлгерәләр.

Сәлахетдин (*намаз тәгәлли*). Ярый, мин ашыгыйм әле, малайлар кайтабыз дигәннәрие. Сау булып тор. (*Чыгып китә.*)
Әсфәндияр (*балаларга*). Ә сез нихәл? Нигә соңга калдыгыз?
Илдария. Илдар аягын юмады.
Илдар. Юмадымы, юмадымы? Менә кара!
Илдария. Дәү әни ачулангач, юдың. Грязными ногами мәчет нельзя. Әйе бит, Әсфәндияр абый?
Әсфәндияр. Әйе, мәчеткә чиста тән, чиста күңел белән керергә кирәк. Кичә өйрәткәннәрне онытмадыгызмы?
Вилдан. Мин беләм. Лә илахы иллә Аллахы...
Әсфәндияр. Әйе, Лә илаһу, илла Аллаһу, Мөхәммәде рәсүлуллаһу. Алладан башка Алла юк. Ә Мөхәммәт галәйһиссәлам вә сәлаллаһу аның илчесе. Онытмагыз, кем дә кем «мин – Алла» дип мактана икән, ул ялганчы. Алладан башка Алла юк. Аннан инде сезнең әниләрегез, әтиләрегез, әби-бабаларыгыз...
Илдария. Вилдан, намаз укыганда, бисмилла, бисмилла, дип кенә торды. Мин, Аллакбәр, Аллакбәр, дип укыдым. Илдар дөрес укымый бит, әйеме?
Вилдан. Тик тор диләр сиңа, дура!
Әсфәндияр. Нигә алай дип әйтәсең сеңлеңә.
Вилдан. Че она хатын-кыз башы белән... (*Илдариягә.*) Тебе вообще мәчеткә керергә ярамый, белдеңме? Бабам, мәчеткә керергә ярамый, диде, әйе бит, Әсфәндияр абый?
Әсфәндияр. Нигә ярамасын?
Илдар. Минем әти әнигә әйтә: «Син минем кабыргадан яралган, – ди. – Ачуымны китерсәң, кире тыктым куйдым булыр урынына, – ди. – Ходай сезне мәчеткә кертергә дә кушмаган, – ди».
Әсфәндияр. Әтиләр дә кайвакыт ялгыша. Барыгыз, икенче килгәндә, бүтән малайларны алып килегез. Футбол уйнарбыз.
Вилдан. Мәчеттә что ли?
Әсфәндияр. Мәчет янында нинди матур урын бар. Ярый, барыгыз.
Илдар. Сау булыгыз, Әсфәндияр абый!
Илдария. Сау булыгыз, Әсфәндияр абый!
Вилдан. Сау булыгыз, Әсфәндияр абый!
Әсфәндияр (*Лемур кергәнне күреп, елмаеп*). Намазга соңга калдыгыз.
Лемур. Син инде мине ачуланма. Булмый миннән. Ну картларны китерәм. Кәлимулла абыйга да әйттем. Хәлиулла абыйга да әйттем. Әгәр мәчеткә йөрмәсәгез, миңа йомыш белән килмәгез, дидем. Телгә остарып беттеләр. Синең нигә кирәгең бар, зирна бирмисең, салам бирмисең, диләр. Ә Самат абый мине тәнкыйтьли. Нишләтә алам мин аларны?
Әсфәндияр. Мәчеткә куып китермиләр.
Лемур. Килмәгәч, куасың инде. Самат абый әйтте бит.
Әсфәндияр. Самат Закирович куып китерергә кушмады.
Лемур. Нишләтим мин аларны тагын. Тагын бер-ике картка әйтеп карармын.
Әсфәндияр. Кирәкми, йөрмәгез. Йа Хода, кешеләр...

Лемур. Кешеләр шул. Йөзәр грамм салып бирәләр, дисәң, киләләр. Белмим, кая барадыр дөньясы. Син миннән көләсең, исемемне маймыл исеме, дисең. Бәлкем, шулайдыр. Анысында минем гаебем юк. Бүгенге эшемнең рәте-чираты булмаганга да гаебем зур түгел. Җитешмәгән якларым бардыр, гаебем юк. Кем мин авылда? Нишли алам мин хәерче авылда? Бетәргә хөкем ителгән авылда нишли алам? Власть, диләр. Кайда ул власть?! Ярдәме тимәгән властьны кем санга суксын?! Син мине бик ачуланма инде, хәзрәт. Син килгәч, ничектер әллә ни булды әле. Үземнең кирәгемне сизә башладым кебек. Кыен, бик кыен.

Әсфәндияр. Бергәләп тырышыйк.

Лемур. Әйе, әлбәттә. Рәхмәт сиңа! Вәлиәхмәт абыйга да әйттем, төнлә аракы саттырма кибетеңдә, дидем. Вон отсюда, ди. Мин нинди власть шуңа көчем җитмәгәч...

Вәлиәхмәт керә.

Вәлиәхмәт. Керергә ярыйдыр бит?

Әсфәндияр. Әлбәттә!

Вәлиәхмәт. Ә син монда нишләп йөрисең, муниципаль берәмлек?

Лемур. Исәнмесез, Вәлиәхмәт Габделәхәтович!

Вәлиәхмәт. Исән! Бар, йөрмә буталып эшләгән кешеләр арасында. (*Лемур чыгып киткәч, бусагага утыра да Әсфәндиярга карап тора. Шактый озак паузадан соң.*) Нихәл!

Әсфәндияр. Сезнекеннән яхшырак.

Вәлиәхмәт. Нәрсә, минем хәлем начармыни?

Әсфәндияр. Бәдретдин абый юк бит.

Вәлиәхмәт (*сикереп тора да яңадан утыра*). Ызгышырга килмәдем.

Әсфәндияр. Безнең ызгышканыбыз юк шикелле.

Вәлиәхмәт. Шулайдыр. (*Паузадан соң.*) Дөрес эшләде Бәрттин. Аңарга бүтән төрле үлем килешми дә иде. Табигать законы – көз артыннан кыш килә. Хайванның кешегә әйләнгәнен күргәнем юк, кешенең хайванга әверелгәнен күреп торабыз.

Әсфәндияр. Кем турында әйтәсез?

Вәлиәхмәт. Мин хайван түгел, мин – җанвар! Ерткыч җанвар! Хайваннарны ашаучы җанвар!..

Әсфәндияр (*паузадан соң*). Түргә узыгыз. Олы кешегә бусагада утыру килешми.

Вәлиәхмәт. Мәчеттә минем урыным бусагада. Мәчет минем өчен изге йорт. Сезгә генә ул – балаган.

Әсфәндияр. Абзый кеше, ызгышырга килмәдем, дидегез. Әйдә, бер-беребезне мыскыл итми генә сөйләшик. Күреп торам бит: күңелегезне бушатырга килгәнсез.

Вәлиәхмәт. Шулай ук күренеп торамыни?

Әсфәндияр. Тора. Җаныгыз бәргәләнә.

Вәлиәхмәт (*кычкырып*). Юк! Юк ул миндә җан. Җансыз бәндә мин. Җансыз җан иясе. Җан дигән нәрсә күптән инде адәм балаларын ташлап качты. Кешеләр Газраилнең килгәнен көтмичә үк җан бирәләр. Җаннарын саталар. Бәрттин дөрес эшләде. Нигә ул ит гәүдәсен күтәреп йөрергә. Ә мин куркак. Бәрттин эшләгән егетлекне эшли алмыйм.

Әсфәндияр. Үз гомереңне үзең кисү егетлек түгел. Ходай биргән гомерне Ходай үзе генә ала.

Вәлиәхмәт. Син миңа икенең ике икәнен исбатлама.

Әсфәндияр. Үзегез белмәгәч, исбатларга туры килә.

Вәлиәхмәт. Беләм мин. Аңлый гына алмыйм. Күңелсез миңа, шуны беләсеңме? Шушы авылның кешеләренә «Ясин» чыгарга кайттым. Ә үземнең яшисем килми башлады. Йә, әйт, нишләргә миңа?

Әсфәндияр. Иманга кайтыгыз.

Вәлиәхмәт. Иман? Нинди иман?

Әсфәндияр. Ә сез аның нинди икәнен беләсез.

Вәлиәхмәт (*паузадан соң*). Йә, килдем, ди, иманга. Шуннан ни?

Әсфәндияр. Шуннан шул...

Вәлиәхмәт. Карале, егетем, кит син бу авылдан.

Әсфәндияр. Нигә?

Вәлиәхмәт. Кит! Кит яхшы чакта.

Әсфәндияр. Китмәсәм?

Вәлиәхмәт. Куркытырга җыенмыйм. Ялынып сорыйм. Минем үз гомеремдә берәүгә дә ялынганым булмады. Сиңа ялынам. Кит син. Беләсеңме, мин көзге яратмыйм. Көзгегә карасам, андагы кыяфәтемә төкерәсем килә. Син минем көзгем, ахрысы. Ул көзгене ватасым килми. Чөнки аның гаебе юк. Югалтасым гына килә. Кит син бу каһәр төшкән авылдан. Комачаулама миңа «Ясин» чыгарга... (*Туктап кала.*)

Әсфәндияр. Нигә туктадыгыз, әйтеп бетерегез?!

Вәлиәхмәт. Мин әйтәсен әйттем.

Әсфәндияр. Юк, әйтеп бетермәдегез. Сез монда аны әйтергә килмәдегез, сез бушанырга килдегез.

Вәлиәхмәт. Нинди бушану?

Әсфәндияр. Күңелегездәге авыр йөкне бушатырга килдегез.

Вәлиәхмәт (*кычкырып көлә*). Бала-чага!.. Нинди бушану... Андагы пычракны бушатып бетереп булмый.

Әсфәндияр. Ә сез тырышыгыз. Мин мәчетне чистарынган Вәлиәхмәт хәзрәткә калдырып китим. Авыл шаккатсын.

Вәлиәхмәт. Мондагы бәндәләргә ыштаның салып артыңны күрсәтсәң дә шаккатмыйлар. Иялашкәннәр. Үзләрендә бар нәрсәне телевизордан күреп рәхәтләнеп утыралар.

Әсфәндияр. Вәлиәхмәт Габделәхәтович, муллалар вәгазь укырга яраталар. Алып ташлагыз күңелегездән үчне. Үч саклау кешене харап итә. Бабагызны кууда, мәчет манарасын кисүдә бүгенге авыл халкының гаебе юк. Кешеләр язмышы белән хакимнәр уйный.

Вәлиәхмәт. Тәкъдирне, ягъни язмышны Ходай яза.

Әсфәндияр. Язганны укый да белергә кирәк. Күзе сукырайган кешеләрдән нигә үч алырга?

Вәлиәхмәт (*кинәт урыныннан торып чыгып китә*). Сау бул!

Әсфәндияр. Вәлиәхмәт абый, минем сезгә үтенечем бар.

Вәлиәхмәт. Үтенеч?

Әсфәндияр. Ябыгыз аракы сата торган кибетегезне. Һич югында төнлә сатмасыннар.

Вәлиәхмәт. Эчсеннәр! Бетсеннәр!

Әсфәндияр. Үтенеп сорыйм!

Вәлиәхмәт. Тапмаслар дисеңме?

Әсфәндияр. Сез сатмагыз. Сез бит мулла оныгы.

Вәлиәхмәт (*зәһәрләнеп*). Это не твое собачье дело. (*Чыгып китә.*)

Әсфәндияр, тәрәзә янына килеп, Вәлиәхмәт артыннан карап кала.

Әсфәндияр. Аллам! Адәм балаларын рәхмәтеңнән ташлама! Күгәргән күңелләрен чистарт! Адашкан җаннарга туры юл күрсәт! Иманын югалтканнарга иманын табарга ярдәм ит! Күңелләренә миһербан, мәрхәмәт иңдер! Кылган гөнаһларын ярлыка, уй-фикерләрен, кыласы ниятләрен изге ит! Йа Аллам, йа Хода, йа Тәңрем!..

Әкрен генә, кыймыйча гына Налимә керә. Тамак кыра.

Әсфәндияр. Килгәнеңне күрмәдем.

Налимә. Мин икенче яктан килдем. Кайтмыйсың.

Әсфәндияр. Җыена идем.

Налимә. Сагындым!

Әсфәндияр. Нәрсә-ә-ә?

Налимә. Бүтән әйтмим, ишетмәдең.

Әсфәндияр. Ишеттем. Ләкин...

Налимә. Әллә мәчеттә ул сүзне әйтергә ярамыймы?

Әсфәндияр. Менә анысын белмим.

Налимә. Синең дә белмәгәнең бармыни? «Яратам» дип әйтергә ярый микән?

Әсфәндияр. Нигә ярамасын икән?

Налимә. Алайса, нигә әйтмисең? Яратасың бит син дә. Ату йөрим дә йөрим. Сөйлиләр. Әни дә әйтә: «Ашарга пешерергә генә йөрмисеңдер», – ди. Кешеләр дә сөйли, үзе мулла, үзе гуләйт итә, диләр. Мин бит миңа кызыгып караганыңны сизәм. Кызыгып карыйсың, якын килмисең. Сөйгән кызың калгандыр әле Казанда.

Әсфәндияр. Беркемем дә юк минем.

Налимә. Налимә, диген.

Әсфәндияр. Налимә.

Налимә. Алай гына әйтмә. Беркемем дә юк минем, Налимә, диген... Ярый инде, әйтәсең килмәсә. Хатын-кыз сүзен кабатлаган ир кеше ир кеше түгел инде ул.

Әсфәндияр. Әйдә, кайтабыз, Налимә.

Налимә. Юк. Кайтасым килми әле. Монда рәхәт икән. Мин синең намаз укыганыңны карап торырга яратам. Шундый тыныч. Дөньяда бер кайгы да юк кебек. Син укы, мин карап торыйм.

Әсфәндияр. Мин сине гел күрәм, Налимә. Әниеңне бер тапкыр да күргәнем юк.

Налимә. Өйдән чыкмый ул. Мине тапкач, өзлегеп калган.

Әсфәндияр. Әтиең?

Налимә. Аны сорама. Әтисез тумаган инде, билгеле. Әни авыргач, киткән. Мөслимә апа да минем әнием кебек. Ул мине карап үстергән. Монда коверлар күп икән. Талап чыкмасыннар тагын.

Әсфәндияр. Мәчет әйберенә кемнең кулы күтәрелсен?

Налимә. Гөлназ кияүгә чыгарга җыена. Никах укытабыз, ди. Әсфәндияр укымас микән, ди. Әйткәннәр тегеләр килеп, калымыңны түлә, дигәннәр. Гөлназ белән үзидарәгә барып әйттек. Әкият сөйләп йөрмәгез, ди Лемур абый. Әкият, ди. Белми. Былтыр Гөлфиягә дә калым түләттергәннәр. Караташ авылыннан иде егете. Миңа мондый кыз кирәкми, дип өйләнмәгән. Гөлфия хурлыгыннан әллә кая китте. Беркемгә дә бернәрсә дә булмады.

Атылып Гөлназ керә. Аның артыннан Эльбрус һәм тагын бер-ике калым түләттерүчеләр керә. Эльбрус Гөлназга таба атлый.

Әсфәндияр (*аның юлына каршы төшеп*). Туктале син, егет!
Эльбрус (*ишек төбендә калганнарга*). Тотыгыз аны!
Әсфәндияр (*янына килеп басканнарга*). Мәчет бит бу, егетләр! Чыгып сөйләшик.
Эльбрус. Төкердем мин синең мәчетеңә.

Вәлиәхмәт ашыгып килеп керә. Эльбрус янына килеп баса.

Вәлиәхмәт. Нишләп йөрисез монда?
Эльбрус. Менә, Вәлиәхмәт Габделәхәтович, бу мулла кисәге кызларны бикләп тота.
Вәлиәхмәт. Бар әле, ычкын моннан!
Эльбрус. Вәлиәхмәт Габделәхәтович!..
Вәлиәхмәт. Ычкын, диләр. Мине беләсең.

Эльбрус, әкрен генә борылып, ишеккә китә. Аңа иярченнәре тагыла.

Эльбрус (*ишек янында туктап*). Зря син, Вәлиәхмәт Габделәхәтович!

Чыгып китәләр.

Вәлиәхмәт. Нәрсә алар? (*Гөлназга күрсәтеп.*) Моның өченме? Бар, чык киявеңә. (*Налимәгә.*) Син дә бар. Мәчеткә егет эзләп килмиләр... Барыгыз, бар, бар...

Кызлар чыгып китә.

Нәрсә мәчеткә кызлар җыясың. Урын беткәнме?
Әсфәндияр. Үзләре керделәр.
Вәлиәхмәт. Кертсәң, кочагыңа да күчәләр алар. Нәрсә, яныймы теге маңка? Шакшы малай, мәчет манарасын кисүчеләр нәселеннән. Нәрсә син маңка малайлар алдында җебеп төштең?

## ҖИДЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук күренеш. Мәчет идәненә җәелгән келәмнәр юк. Мәчеттә Әсфәндияр, Лемур, Әмир.

Әсфәндияр. Тикшерүчеләрне чакыртыйк.
Лемур. Туктале, зурга җибәрмик. Кемнәр булыр икән, Әмир?
Әмир. Черт знает! Откажусь сезнең авылыгыздан. То сарык юк, то бозау, инде бу. Вор на воре сидит.
Лемур. Алай ук димә. Бүтән авылларда да шулай хәзер. Берсен дә тотканыгыз юк.
Әмир. Как это тотканыбыз юк. Тотып торабыз, тагын чыгалар. Без тотып ябып торабыз, там выпускают. Мы что ли виноваты. Уф-фу-фу! (*Лемурга.*) Басма анда, не видишь, следы. Даже обувь не снимали, сволочи! Может эти?
Лемур. Кем белә инде.
Әмир. Кем белә, кем белә?! Банда асрыйсың.
Лемур. Нинди банда? Син нәрсә инде. Авыл малайлары.
Әмир. Малайлар! А этот Эльбрус малай что ли?
Лемур. Ә син нәрсә карыйсың соң?

Мөслимә керә.

Мөслимә. И Ходаем, әллә дөресме?
Әмир. Бар әле, апа, йөрмә монда.
Мөслимә. Йөрмә монда дип... Инде мәчеткә җитештеләр.
Лемур. Синең бер дә күрмәгәнең юк, мәчет тирәсендә кеше күрмәдеңме?
Мөслимә. Күрмәдем.
Лемур. Кирәген күрмисең син дә.

Әмир. Может этот. Как его... Вәлиәхмәт? Подозрительный тип. Ничә ел яши авылда, ничек яши, никто не знает.

Әсфәндияр. Ул түгел.

Әмир. Как ул түгел? Карап тордың что ли?

Әсфәндияр. Ул түгел. Тикшерүче чакыртыгыз. Әнә бит аяк эзләре күренеп тора.

Әмир (*үтеп баручы Эльбрусны тәрәзәдән күреп*). Әй! Брусок! Кер әле монда!

Лемур. Ул төнлә авылда түгел иде.

Әмир. Посмотрим! (*Кергән Эльбруска.*) Сәлам, Брусок!

Эльбрус. Минем исемем бар.

Әмир. Да, ладно. Күрәсеңме монда нәрсә?

Эльбрус. Сукыр түгел.

Әмир. Кемнәр?

Эльбрус. Ә мин каян белим?

Әмир. Может ты?

Эльбрус. Син нәрсә?

Әмир. Может дружки?

Эльбрус. Может.

Әмир. Кстати, син беркайда да эшләмисең, на что живешь?

Эльбрус. Синең ни эшең бар анда?

Әмир. Эшем бар. Сам знаешь.

Эльбрус. Минем бабай белән әби пенсия алалар.

Әмир. Значит, ночью син авылда түгел идең?

Лемур. Түгел иде, без бергә идек.

Әмир. Чем занимались?

Эльбрус. Это не твое дело. Безне тикшермә, каракларны эзлә.

Әмир. Ну ладно. Если син замешан в этом деле, смотри!

Эльбрус. Нәрсә син җикеренәсең?

Әмир (*пистолетын чыгарып*). Күрәсеңме моны?

Эльбрус. Ну күрәм.

Әмир. Он стреляет.

Эльбрус. Беләм.

Әмир. И уничтожает.

Эльбрус. Син нәрсә мине куркытасың?

Лемур. Егетләр, туктагыз әле, яхшылап кына сөйләшик.

Әмир. Надоел он мне.

Эльбрус. Нәрсә надоел? Үзең чакырып алдың, мин килмәдем.

Әсфәндияр. Мәчеттән чыгып ызгышыгыз. Мин тикшерүче чакыртам.

Әмир. Да подожди ты! Табабыз аны. (*Эльбруска.*) Малайларың да үзең белән идеме?

Эльбрус. Нинди малайлар? Малайларым юк минем, өйләнмәгән.

Әмир. Че лыбаешься?

Эльбрус. Дурак син!

Әмир. Кто дурак?

Эльбрус. Мин түгел инде.

Әмир. Значит, мин дурак? Я тебя, сука, пристрелю как собаку.

Эльбрус (*Әмирнең изүеннән эләктереп*). Ты че сказал, падла? Че ты сказал?

Лемур. Егетләр, егетләр!..

Эльбрус Әмирнең изүеннән тоткан килеш ишеккә таба бара. Чыгып китәләр. «Егетләр, егетләр» дип, Лемур аларга иярә.

Мөслимә. И Ходаем! Ахырзамандыр бу, ахырзамандыр.

Тышта пистолеттан аткан тавышлар ишетелә. Әсфәндияр ишеккә бара. Мөслимә аның юлына аркылы төшә.

Чыкма, улым!

Әсфәндияр барыбер чыгып китә.

## СИГЕЗЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Әсфәндияр яшәгән өйнең эче. Әсфәндияр чәй эчә. Читтәрәк, урындыкка утырып, Налимә аңа сокланып карап тора.

Әсфәндияр. Нигә син үзең дә минем янга утырып чәй эчмисең?

Налимә. Ярамый.

Әсфәндияр. Ни өчен?

Налимә. Мин бит синең хатының түгел.

Әсфәндияр. Булмасаң ни.

Налимә. Үзең мулла, үзең ярамаган сүз сөйлисең. Ничек инде хатының булмаган килеш янына утырып чәй эчим?

Әсфәндияр (*Налимәгә таба борылып утырып*). Әллә ниләр әйтеп куясың син.

Налимә. Әллә ниләр түгел. Мөслимә апа да шулай ди. Хатыны булмаган килеш ир-ат белән икәү генә янәшә утырып чәй эчү аның янәшәсенә яту белән бер, ди.

Әсфәндияр. Мөслимә апа шулай ди, ә үзең ничек уйлыйсың?

Налимә. Үзем дә шулай уйлыйм. Янында утырырмын да торып китә алмам. Мөслимә апа әйтә: «Яратканыңны сиздермә, кыз балага килешми», – ди. Мин яратканымны яшерә белмим шул. Мин бу өйдән чыгасым килми генә чыгып китәм.

Әсфәндияр. Миңа нишләргә кушасың?

Налимә. Кызык син, әйеме! Бүтәннәр «нишләргә» дип сорап тормыйлар. Гөлназны Дамир «яратам» диде дә алып китте. Син дә инде йә ярат, йә яратма. Кумыйсың да, якын да җибәрмисең. Ә минем бик тә ярасым килә. Хатының булып яратасым килә. Бәлки, син мине тиң күрмисеңдер. Син бит укыган кеше. Чынлап та килмәгәнсеңдер әле безгә, китәргә генә килгәнсең. Мине калдырып китәрсең дә, мин нишләрмен. Тагын шул Илбрүсләр кулына калырмын.

Әсфәндияр. Юк инде, аның кулына калмаячаксың!

Налимә. Син булмагач, миңа берсе дә кирәкми. Килмәгән булсаң... Өйләнмәсәң дә, киткәндә алып кит мине моннан. Самат абый белән сөйләш. Берәр җиргә эшкә урнаштырсын.

Әсфәндияр. Әйдә!

Налимә. Кая?

Әсфәндияр. Сезгә. Әниеңнән рөхсәт сорыйбыз.

Налимә. Чынлапмы?

Әсфәндияр. Бу эш белән шаярмыйлар.

Налимә. Алайса, хәзер мин өйгә чыгам. Син килеп керерсең, ярыймы? Мин белмәгән булырмын. Син әнигә әйтерсең, мин Налимәне яратам, аңардан башка яши алмыйм, диярсең. Кер, ярыймы, керми калма тагын.

Китәргә дип ишеккә бара, анда Эльбрус белән очраша. Туктап кала.

Әсфәндияр. Бар, Налимә!

Налимә. Юк, китмим. Ул нигә килгән? (*Эльбруска.*) Нигә килдең?

Әсфәндияр. Борчылма, бар!

Налимә. Ул яхшылыкка йөрми.

Эльбрус. Кит, диләр бит сиңа.

Налимә. Юк...

Әсфәндияр. Налимә!..

Налимә чыгып китә.

Эльбрус. Хуҗа булып алганмы?

Әсфәндияр. Узыгыз әйдә, утырыгыз!

Эльбрус. Урын бирәсең?

Әсфәндияр. Сез – кунак.

Эльбрус. Кунак?

Әсфәндияр. Ә нигә? Минем бусагамны атлап кергән һәр кеше – кунак.

Эльбрус. Ярый, кунак булып алыйк алайса. Кунакка бездә бер ярты куялар.

Әсфәндияр. Сездә шулайдыр, бездә алай түгел. Налимә әйтә, яхшылыкка йөрми, ди.

Эльбрус. Дөрес әйтә.

Әсфәндияр. Башта ук кисәтеп куйыйм, мин сездән курыкмыйм.

Эльбрус. Беләм. Вәлиәхмәт абый әйтте, үзем дә татыдым. Куркытырга килмәдем. Коверны тапмыйлармы?

Әсфәндияр. Әйткәннәре юк.

Эльбрус. Эзләмиләр дә аны. Теге ментны куганнар бит. Пистолет белән шаярганы өчен. Алар өчен пистолет уенчык кына бит. Нигә килгәнемне беләсеңме?

Әсфәндияр. Киңәш сораргадыр.

Эльбрус. Нинди киңәш?

Әсфәндияр. Беткәнмени?

Эльбрус. Миңа синең киңәшең кирәкми.

Әсфәндияр. Юкка!.. Минем киңәшемнең файдасы тияр иде сиңа.

Эльбрус. Әйтеп кара.

Әсфәндияр. Китегез сез бу авылдан. Бу авыл кысан сезнең өчен. Монда сез сыймыйсыз. Монда сезне барысы да яхшы беләләр. Сездән куркалар, билгеле.

Эльбрус. Миңа шул җиткән.

Әсфәндияр. Ләкин бу зона түгел. Монда пахан булып булмый. Шунысы да бар, зонада петух булганнар, чыккач пахан булып кыланалар. Бигрәк тә авыл җирендә. Сезнең турыда әйтмим, кесәгезгә тыгылмагыз. Биографиямнән бер деталь: зонаның ни икәнен беләм. Күреп беләм. Һәм мин бу турыда сезгә генә әйтәм. Китегез сез моннан яхшы чакта.

Эльбрус. Кая?

Әсфәндияр. Барыр урыныгыз булмагач, нигә пахан булып уйныйсыз? Яшәгез матур гына. Яши башларга әле соң түгел. Әби белән бабай пенсиясенә яшәү егетлек түгел бит.

Эльбрус. Ә мин аңа яшәмим.

Әсфәндияр. Беләм. Мәчетне талаучы син түгел, юл күрсәтүче генә. Юк әйбер белән маташасыз. Сарык, бозау урлау, мәчет келәмен урлау көненә калгач, юк инде ул.

Эльбрус. Әллә син!..

Әсфәндияр. Утыр матур гына. Килеп алганнарын көтеп. Мин синең кебекләрне зонада унике яшемдә күргән. Ә Налимәне мин сиңа бирмим. Син бит минем янга «Налимәне бир!» дип әйтергә килдең. Әгәр дә мин Налимәне синнән тартып алган булсам, гафу үтенер идем. Ләкин Налимә үзе. Күрдең бит.

Эльбрус. Мин аны яратам. Яратмасам, әллә кайчан инде...

Әсфәндияр. Яраткан ир кеше беркайчан да яраткан кызының эченә сукмый. Яратмыйсың син аны. Үзеңә буйсынмаган өчен генә үзеңнеке итәсең килә.

Эльбрус. Нәрсә мулла булып йөрисең, син мулла түгел бит.

Әсфәндияр. Мулла, иптәш Брусок, мулла! Синең кебекләр белән синең телдә сөйләшә белүче мулла. Әгәр дисбе тотып яныма килгән булсаң, бүтәнчә сөйләшер идек. Әйт, келәмнәрне китереп куйсыннар! Минем янга килгәнең өчен бер юлга сине кичерәм.

Эльбрус. Мин!..

Әсфәндияр. Әйе, син – син, мин – мин. Хуш иттек, Эльбрус!

Эльбрус чыгып китә. Кулына балта тоткан Налимә керә.

Налимә. Бер генә бәрә идем башына.

Әсфәндияр. Бир әле балтаңны. Мин барында беркайчан да кулыңа балта һәм гер алмыйсың, Налимә. Кул ярыштырып йөрмисең. Алар хатын-кыз эше түгел. Аңлыйсыңмы мине?

Налимә. Аңладым. «Яратам» диме Илбрүс?

Әсфәндияр. Аның шулай дип әйтергә хакы бар.

Налимә. «Яратам» дияргәме?

Әсфәндияр. Ә нигә? Син дә бит миңа «яратам» дидең.

Налимә. Мин бит...

Әсфәндияр. Ул да үзенчә яратадыр. Мин дә бит сине үземчә яратам.

Налимә. Әйткәнең юк.

Әсфәндияр. Әйтү ул әле ярату түгел.

Налимә. Син бөтен әйберне беләсең, үзең карт та түгел.

Әсфәндияр. Син «өебезгә кайтам» дигән идең.

Налимә. Син чынлап киләсеңме?

Әсфәндияр. Яраткан кешеңә ышаналар, Налимә!

Илдар керә.

Илдар. Мулла абый, мәчетнең ачкычын бир!

Әсфәндияр. Нигә ул?

Илдар. Малайлар белән намаз укырга керәбез.

Әсфәндияр. Әле намаз вакыты түгел.

Илдар. Ә без өйрәнә торабыз.

Әсфәндияр. Әнә эленеп тора, ал.
Налимә. Аякларыгызны юып керегез. Комган ишек төбендә.
Илдар. Беләбез инде. Дәү әни куйган комган.
Налимә. Мөслимә апа өйрәтеп җибәрә инде боларны. Мин киттем.

Китә. Әмир керә. Ишек янында аяк киемен сала.

Әмир. Исәнмесез!
Әсфәндияр. Исәнмесез, иптәш лейтенант!
Әмир. Формадан түгел. Салдырдылар.
Әсфәндияр. Ишеттем. Барган идем, тыңламадылар.
Әмир. Шулай ул. Үзләре преступностька каршы көрәшергә, диләр. Көрәшә башласаң... Мин бит аңа атмадым, җиргә аттым. Нәрсә, үтергәнне көтеп ятаргамыни?
Әсфәндияр. Сүзне дә үлчәп сөйләргә кирәк шул. Андый сүзне төрмә күргән кешегә әйтмиләр.
Әмир. Ә нәрсә?! Мин әйтәм, урлатучы шул. Мин барыбер аның эзенә төшәчәкмен. Кусыннар, барыбер үземнекен докажу. Дәшми килгәч тә, муенга менеп атланды. Төрмәдә булган, имеш. Видали мы таких. Әнә Лемур курыксын. Йөрәге алынып тора. Шуның белән аракы эчә.
Әсфәндияр. Сез дә инде...
Әмир. Мин үзем алып эчәм. Беләсеңме, нишли? Берәр әйбер югаласы булса, юри Лемур тирәсендә бутала. Как- будто ул түгел. Белә кемнәр урлыйсын... Менә күрерсең, доканаю. Аның тирәсендә йөрүче бер дуракны, тотып, телен чиштердем. Син анда теге, кемгә, Самат абыйга әйт әле, сөйләшсен безнекеләр белән. Бизнесменнардан шүрлиләр алар.
Әсфәндияр. Шулай да сакланыбрак йөрегез инде.
Әмир. Ничего! Алар сөйлиләр, милиционер тупой. Вот мин формадан түгел, значит не тупой. Посмотрим кто кого. Әгәр син Брусок икән, мин – кувалда. Да, я как кувалда тупой. Син молодец, сугыша беләсең. Каерып кына алдың кулын. Сине үзидарәгә куярга кирәк. А то утыра анда Лемур. Маймыл есть маймыл.
Әсфәндияр. Нишләсен инде ул.
Әмир. Да! Нишләсен. Үзидарә, үзидарә. Название одно. Хозяева другие.

## ТУГЫЗЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Шул ук урын. Төн. Налимә урын җәя. Әсфәндияр китап укый.

Налимә (*урынны җәеп бетереп, Әсфәндияр янына килә. Аны кочаклаган килеш китапка карап тора*). Аңлыйсың инде боларны, әйеме?
Әсфәндияр. Юк, карап кына торам.
Налимә. Көләсең инде. Теләсәм, моны укырга мин бер айда өйрәнәм.
Әсфәндияр. Ә син телә.
Налимә. Мин яхшы укыдым мәктәптә. Институтка да керә ала идем дә, әнине ташлап китеп булмый иде.
Әсфәндияр. Монда бик иркен бит, күчерик әниеңне.
Налимә. Әлегә кирәкми. Кышка карарбыз әле. Алдыңа утырыйм әле, Әсфәндияр!
Әсфәндияр. Син мине туйдыра башладың, аермый булмас.
Налимә. Алай димә, юри дә әйтмә.
Әсфәндияр. Комачаулыйсың бит.
Налимә. Укы, укы, укы... Миңа да бер китап бир. (*Караватка барып утыра.*)
Әсфәндияр. Әнә Тукай китаплары, ал да укы.
Налимә. Әй, аны беләм инде мин.
Әсфәндияр. Кайсы шигырен беләсең?
Налимә. «Пар ат», «Туган тел»...
Әсфәндияр. Ә син башкаларын укы.
Налимә (*шүрлектән китап алып укырга утыра да китапны кире илтеп куя*). Укыйсы килми. Мин лутчы җыр чыгарам. (*Кәгазь белән ручка алып, Әсфәндияр каршына утыра.*) Тәк, тәк... (*Көйли-көйли яза.*)

Җыр чыгарам, җыр чыгарам,
Җырлыйсым килгән өчен...
Минем бәхетемә Ходай
Әсфәндиярны биргән өчен.

Йә, ничек?
Әсфәндияр. Нәрсә ничек?
Налимә. Мин җыр чыгарам, ул ишетми дә.

Әсфәндияр. Комачаулама инде.

Налимә. Ярар, ярар.

Җыр чыгарам, җыр чыгарам,
Әсфәндияр янымда булган өчен.

Чыкмый да. Карале, Әсфәндияр, мулла хатынына телевизор карарга ярыймы?

Әсфәндияр. Нишләп ярамасын...

Налимә. Нигә алмыйбыз соң, алайса?

Әсфәндияр. Алырбыз.

Налимә. Куеп тор инде китапларыңны, гел укыйсың да укыйсың.

Әсфәндияр. Укымыйча булмый. Мин гарәп телен камил белмим.

Налимә. Миңа күңелсез бит. Әйдә болай эшлибез. Бер атнаны икегә бүләбез. Биш көне – синең өчен, ике көне – минем өчен.

Әсфәндияр. Ярый, шулай эшләрбез.

Налимә. Бүгеннән башлап... бүген минем җүләрләнәсем килә.

Әсфәндияр. Ничек итеп?

Налимә. Белмим әле.

Әсфәндияр. Башта бел, аннан әйтерсең.

Налимә. Син картлар кебек сөйләшәсең.

Әсфәндияр (*китапларын куеп*). Йә, җүләрлән!

Налимә, Әсфәндиярның алдына утырып, аны коча, үбә.

Налимә. Бир әле колагыңны!.. (*Әсфәндияр колагына пышылдый.*)

Әсфәндияр. Аны кычкырып әйтсәң нәрсә була?

Налимә. Ярамый, ишетмәсеннәр.

Әсфәндияр. Кемнәр?

Налимә. Шайтаннар! Син дә минем колагыма пышылдап әйт.

Әсфәндияр (*Налимә колагына*). Мин дә яратам.

Налимә. Тагын, тагын, тагын!.. (*Тагын Әсфәндиярны коча, үбә. Алдыннан төшә.*) Менә хәзер укы.

Әсфәндияр. Моннан соң укып буламы?!

Налимә. Була. Бер хәреф биш булып күренәчәк. Укы, укы! Мин мишәйт итмичә генә сиңа карап торам. (*Әсфәндияр алдына китапларын куеп.*) Укы! (*Үзе, өстәлгә таянып, аңа карап тора.*) Укы инде. Нигә алай карап торасың?

Әсфәндияр. Сокланып... Күпме синең кебек асыл кызларыбыз харап була.

Налимә. Харап була, дип. Итәкләрен җыеп йөрсеннәр... Кара, Илбрүс тәки югалган, әйеме. Синнән куркып инде.

Әсфәндияр. Каян беләсең?

Налимә. Теге вакытта әйттең ич, мин ишек артында тыңлап тордым. Туебызны ямьсезләмәсә ярар иде дип курыккан идем, Аллага шөкер! Рәхмәт инде Самат абыйга, бөтен авылны җыеп туй ясады. Илгиз абый гына әйткән: «Аракылары да булмады, кайтып киттем», – дигән. Аракысыз да биеделәр әле. Син биемәдең. Мулла кешегә биергә килешмидәдер.

Әсфәндияр. Бии белмим мин, биегән булыр идем.

Налимә. Сәлахетдин бабай никахны дөрес укыдымы?

Әсфәндияр. Дөрес!

Налимә. Бер сүз сорасам, ачуланмассыңмы, Әсфәндияр?!

Әсфәндияр. Сора!

Налимә. Юк, сорамыйм.

Әсфәндияр. Мин синең ни сораячагыңны беләм.

Налимә. Каян беләсең?

Әсфәндияр. Беләм инде.

Налимә. Әйт алайса.

Әсфәндияр. Әтиең белән әниең дә, туганнарың да туйда булмады, кайда алар, дисеңме? Җавап бирәм: берсе дә юк. Әби белән бабай үлделәр. Туганнарым юк. Әти белән әни исәннәрдер. Кайда икәнлекләрен белмим. Артыгын сорама. Киләчәктә сөйләшергә дә сүз калсын. Син минем бердәнберем! (*Налимәне кочагына ала.*) Син моны беркайчан да онытма – бердәнберем! Һәм син бердәнбер булырга лаек. Син миннән әллә нинди иркә сүзләр ишетергә телисең. Син аларны еш ишетмәссең. Син бердәнберем – онытма! Мин сине эзләмәдем, үзең табылдың. Ходай җибәргән! Син – Ходайның иң затлы бүләге! Ят, йокла. Мин һәрвакыт синең яныңда гына ятармын. Булдымы? (*Налимәне, күтәреп алып, урынга яткыра.*) Йокла! (*Үзе өстәл янына килеп утыра.*)

Налимә (*паузадан соң. Урында яткан килеш*). Әсфәндияр, бер генә сорау сорыйм инде?

Әсфәндияр. Сора!

Налимә. Мин дә хәзер мөселман булдым бит инде, әйеме?

Әсфәндияр. Ни сөйлисең, әллә кайчан мөселман инде син.

Налимә. Юк инде, барыбер. Догалар да белмәгәч... Телевизордан күрсәтәләр. Казандагы мөселман хатыннары озын-озын күлмәкләр кияләр. Яулыкларын да әллә ничек бәйлиләр. Мин дә шулай йөримме инде?

Әсфәндияр. Үз күлмәкләрең сиңа бик тә килешә, Налимә.

Налимә. Ярый алайса, тыныч йокы, тәмле төшләр, диген, Әсфәндияр. Син шулай дигәч, рәхәт!

Әсфәндияр. Тыныч йокы, тәмле төшләр.

Налимә (*паузадан соң*). Әсфәндияр, тагын бер генә сорау сорыйм инде?

Әсфәндияр. Сора!

Налимә. Син Аллага чынлап ышанасыңмы?

Әсфәндияр. Ни диден?

Налимә. Ачуланма инде.

Әсфәндияр (*паузадан соң*). Юк... Нигә?.. (*Налимә янына килеп, караваt читенә утыра.*) Бу сорауны миңа бирәүнең дә биргәне юк иде әле. Мулла бит мин, Налимә!

Налимә. Анысын беләм инде.

Әсфәндияр. Шулай да бик урынлы һәм вакытында бирелгән сорау. Беләсеңме, бердәнберем, мин беркемгә дә, бер нәрсәгә дә ышанмый идем. Ләкин минем ышанасым килә иде. Безгә бер бабай килеп йөри башлады. Сөйли бу татар балаларын җыеп. Тыңлыйбыз инде. Тыңларга кушалар чөнки.

Налимә. Мәктәптәме?

Әсфәндияр. Әйе, «мәктәптә»... Тимерчыбыклы мәктәптә. Тагын килә бу. Кешене өмет яшәтә, ди, ышану яшәтә, ди. Нинди өмет, кемгә ышану? Шунда инде бу әйтә, шундый бөек көч бар, ди. Мөселманнар аны «Аллаһы Тәгалә, Ходай» дип атыйлар, ди. Әллә кайчангы бабаларыбыз «Тәңре» дип әйткәннәр, руслар «Бог» дип әйтәләр, ди. Җирдә бүтән ышанычың калмаса, шуңа ышанырга кирәк, ди. Ул сине саклый, ди. Һәм чыннан да ул мине саклап калды. Югыйсә мин синең янында утырып тора алмаган булыр идем. Мин дә теге бабай кебек кемнәрнедер саклап каласым килә. Ышанмыйча моны эшләп булмый. Аңладыңмы, бердәнберем?

Налимә. Әйе...

Әсфәндияр. Йокла. (*Баланы сөйгән кебек Налимәне сөя дә өстәл янына барып утыра.*)

Шул вакыт тәрәзә чатырдап чатнаган тавыш ишетелә. Әсфәндияр урындыгыннан авып төшә.

## УНЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Шул ук урын. Әсфәндияр урындыкта утырып тора. Налимә әйберләр җыештырып сумкаларга тутыра.

Әсфәндияр. Налимә, әйткәнне тыңла инде.

Налимә. Әйтмә дә, сөйләмә дә. Китәбез. Сине харап иттереп, ятим бала үстерер хәлем юк.

Әсфәндияр. Нәрсә инде син, исән ич мин.

Налимә. Бүген исән, иртәгә ни булыр.

Әсфәндияр. Самат абый кайтсын инде, ичмасам.

Налимә. Самат абый да кирәкми, беркем дә кирәкми. Кирәк икән, үзе кайтып мулла булсын. Минем синең белән бәхетле буласым килә. Ходай җибәргән бәхетем, беркемгә дә бирмим.

Әсфәндияр. Авыру әниең бар.

Налимә. Булсын. Миңа гына карарга димәгән. Мөслимә апа да әйтте, карарбыз, диде.

Әсфәндияр. Уйлап бетерми эшлисең, Налимә.

Налимә. Уйлап бетермәсәм, сиңа кияүгә чыкмаган булыр идем.

Әсфәндияр. Кил әле яныма!

Налимә (*кинәт үзгәреп, Әсфәндияр янына ашыгып килә*). Нәрсә, бәгырь кисәгем, сызлыймы?

Әсфәндияр. Юк ла инде. Кил, утыр яныма! (*Налимә, урындык алып, янына утыргач.*) Ашыкма, кабаланма, сабыр булырга өйрән. Беләм, яратасың, югалтасың килми. Ләкин шашып ярату хәерлегә илтми. Акыл белән яратырга кирәк.

Налимә. Син ярат акыл белән. Мин бүтәнчә ярата белмим. Син минем бу дөньяда бердәнберем. Сиңа аттылар, синең исең дә китми. Синең иңбашың яраланды, ә минем йөрәгемә тиде.

Әсфәндияр. Шундый матур итеп сөйлисең.

Налимә. Үзең өйрәттең. Китик, Әсфәндияр!

Әсфәндияр. Кая?

Налимә. Сургутта туганнарыбыз бар, булышырлар. Мин эштән курыкмыйм. Сиңа да эш табылыр. Мәчет кенә димәгән. Безгә монда калырга ярамый.

Әсфәндияр. Ярый, уйлашырбыз. Тик кабаланма гына.

Налимә. Юк, уйлашмыйбыз. Миңа күп уйлау килешми. (*Әйберләр җыештыруын дәвам итә.*)

Әсфәндияр (*тавышын күтәреп*). Тукта!..

Налимә (*каушап калган*). Нишлисең син? Нигә кычкырасың?

Әфәндияр. Сиңа уйларга килешмәсә, миңа килешә. Ир кеше уйлый икән, аны тыңларга өйрән. Без бит бала-чагалар түгел, ир белән хатын. Нәрсә, мин хатын-кызга ияреп йөрергә тиешмени?

Налимә. Әсфәндияр!..

Әсфәндияр. Әйе, Әсфәндияр.

Налимә. Син мине ачуланасыңмыни?

Әсфәндияр. Ачуланам.

Налимә. Яратмыйсыңмыни?

Әсфәндияр. Яратканга ачуланам.

Налимә. Китмибезмени?

Әсфәндияр. Уйлашыйк, дидем.

Налимә. Соң, шулай диген. Уйлашыйк, диген.

Әсфәндияр. Әйттем бит инде.

Налимә. Әйе шул. Әйттең шул. (*Әсфәндияр янына утырып.*) Уйлашыйк соң, алайса. Син үзең генә уйла инде, Әсфәндияр. Мин уйлый белмим. Атучы шул Илбрүстер инде. Авылда юк, диләр. Әллә теге Вәлиәхмәт микән? Авылга «Ясин» чыгарга кайттым дип сөйләнә. Алайса, нигә сиңа аткан? Син бит бу авыл кешесе түгел. Миңа атсын инде, әйеме? Илбрүс булса да миңа атсын иде. Синең бит гаебең юк, сиңа мин үзем яратып чыктым. Күп сөйлим мин, әйеме, Әсфәндияр?

Әсфәндияр. Әйе.

Налимә. Үзең әйттең «уйла» дип. Хатын-кызның уе телендә инде. Китик, Әсфәндияр, ә? Бу авылда минем яшисем дә килми.

Әсфәндияр. Туган авылың бит.

Налимә. Туган, дип. Кеше барыбер бер җирдә туа инде. Гел шунда яшәмиләр. Синең дә бит туган җиреņ бу түгел. Китик синең туган җиреңә.

Вәлиәхмәт (*ишекне ачып*). Ярыйдыр бит?!

Налимә. Ярамый.

Вәлиәхмәт. Нәрсә, бу өйгә хатын-кыз хуҗамыни?

Әсфәндияр. Түргә узыгыз, Вәлиәхмәт абзый! Налимә, чәй куясыңмы?

Налимә, әйтер сүзен әйтмичә түзеп, чәй кайнатырга китә.

Вәлиәхмәт. Урынны кайдан бирәсең?

Әсфәндияр. Кунакның урыны – түрдә.

Вәлиәхмәт. Ярасы куркыныч түгел, диделәр. Иңбашын гына тырнап узган, диләр. Тидерә алмагач, нигә атарга диген. Шакшы кешеләр шундый инде – үзләре аталар, үзләре тидерә алмыйлар.

Әсфәндияр. Тидергәннәр шакшы түгелме?

Вәлиәхмәт. Түгел! Явыз, ләкин шакшы түгел. Ярый, мәтәлеп китсеннәр, иң яхшысы исән калгансың.

Әсфәндияр. Әллә сөенәсез?

Вәлиәхмәт. Син нәрсә, әллә мине хайван дип белдеңме? (*Ишектән башын тыгып тыңлап торган Налимәгә.*) Куй чәеңне, тимим иреңә.

Налимә. Тиеп кенә кара! (*Ишекне ябып куя.*)

Вәлиәхмәт. Нәрсә, китәм, дисеңмени?

Әсфәндияр. Кит, дидегез бит.

Вәлиәхмәт. Һәр әйтелгән сүз соңгысы түгел. Соңгы сүзне әйтерлек рәтең калса, җан биргәндә генә әйтәсең. Әле анысы да түгел. Соңгы сүзне синең өчен бүтәннәр әйтә. Ленин белән Сталин да соңгы сүзне әйтмәкчеләр иде. Әнә алар әйтәсене бүген бүтәннәр әйтә.

Әсфәндияр. Философ сез.

Вәлиәхмәт. Һәрбер эшлексез кеше философ була. Эшләргә ирене гәч, акыл сата башлый. Мин килгәнгә ачуланмыйсыңмы?

Әсфәндияр. Нигә?

Вәлиәхмәт. Сиңа килмәгәч, үзең киләсең инде.

Әсфәндияр. Килгәннәрне кертмисез, дип ишеттем. Хәтта Бәдретдин абзыйны да бусагадан уздырмагансыз.

Вәлиәхмәт. Бәрттиннәрнең урыны түрдә түгел. Син килсәң әгәр, уйлап карар идек... Китәм, дисең инде? Бәлки, дөрес эшлисеңдер. Муллалар заманы узгандыр. Безнең бабайлар гына ул кешенең хак

юлга басачагына ышанып яшәгән. Үзләрен атканда да бисмилла әйткәннәр. Менә сиңа аттылар. Муллага мылтыктан аттылар. Авыл халкы ах итте дип уйлыйсыңмы? Авыл халкы сиңа атучыны эзли дип беләсеңме? Тот капчыгыңны! Көтү куганда хатыннар, бер дә юкка атмаганнардыр әле, дип сөйләнәләр. Бер Мөслимә апа гына ах-вах итеп йөри. Миңа иманга кайтырга кушасың. Мин кайтырмын ул, менә бу сарыкларны ничек кайтарырсың... Китеп дөрес эшлисеңдер.

Әсфәндияр. Бәлки, минем урынга сез калырсыз.

Вәлиәхмәт. Һе... Синең авызга бармак тыгарга ярамый.

Әсфәндияр. Нигә? Коръәнне яттан белә, диделәр.

Вәлиәхмәт. Ялган! Мин аны урыс телендә укып кына өйрәндем. Тәрҗемәләр алар барысы да. «Ясин»ны гына Коръән телендә беләм. Аннары, мулла булу өчен дога укый белү генә җитми. «Интернационал»ны яттан белгән коммунистлар үз партияләренең башына җиттеләр.

Әсфәндияр. Авырдыр сезгә яшәве, әйеме, Вәлиәхмәт абый?

Вәлиәхмәт (*озак паузадан соң*). Китмә син!.. (*Торып, ишеккә юнәлә.*)

Әсфәндияр. Сез кая? Чәй өлгергәндер.

Вәлиәхмәт. Яратып эчермәгән чәйнең тәме юк аның...

Лемур белән Әмир керәләр.

Лемур. Керергә рөхсәтме, хәзрәт, исәнмесез, әссәламегаләйкем! Хәзрәт, менә Әмирнең әйтәсе сүзе бар.

Әмир. Исәнмесез! Менә болай. Әйе, мине эштән кудылар. Кусыннар. Кусалар да, мин үз дигәнемне эшләдем. Сиңа аткан кеше, мулла, милициядә утыра. Вот так. Мин эләктердем аны. Куып тоттым мин аны. Вот так.

Машина килеп туктаган тавыш. Самат керә.

Самат (*Лемурга*). Ни булды монда?

Әсфәндияр. Гафу итегез, Самат абый! Намаз вакыты җитте, азан әйтергә кирәк.

Шул вакыт азан әйткән тавыш ишетелә.

Мөслимә (*кереп*). Әсфәндияр энем, ачулана күрмә. Илдарыбыз бу. Тәһарәтен алды.

Азан тавышы яңгырый.

Пәрдә.

# Дивана

*Ике пәрдәле драма*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Вил – психик авыру белән чирләүче.
Хәнифә – Вилнең әнисе.
Нургазиз – авыл карты.
Зәйнәпбану – Нургазизнең карчыгы.
Айсылу – авыл кызы.
Ким – Вилнең абыйсы.
Диана – Вилнең курсташы.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Рәшәткә белән уратып алынган алма бакчасы. Бакча уртасында куыш. Ул Ленинның Разливтагы мәгълүм шалашына охшатып ясалган. Куыш алдында ике агач төбе. Сәхнәдә Нургазиз һәм Хәнифә.

Нургазиз. Булды бугай бу, Хәнифә сеңел. Менә рәсемдә дә шулай ясалган. Менә монда куыш, монда бер агач төбе, монда икенчесе. Монысында менә Ленин утыра, монысына куеп яза. Язу өстәле инде, ягъни мәсәлән. Йоклавын да шушы куышта йоклар микән?

Хәнифә. Кем белгән инде аны, кем белә.

Нургазиз. Монда эликтыр тартырга да кирәктер инде. Төнлә караңгыда утырмас. Ленинның да лампасы булгандыр.

Хәнифә. Рәхмәт инде сиңа, Нургазиз абый!

Нургазиз. Нигә рәхмәт? Күршеләр ич без. Ул малайны үзем дә бик яратам. Тәртипле. Нургазиз бабай, дип кенә тора. Бүтәннәр бәрелеп китәләр, исәнләшә дә белмиләр.

Хәнифә. Тәртиплесен тәртипле дә, нишләп китте бит әнә.

Нургазиз. Борчылма, тереләчәк. Күп укыганныкы ул. Башына шул уку бәргән. Кирәгеннән артыкны белсәң дә, зыянга бит ул, Хәнифә сеңел. Чамалап кына укырга кирәк, үзеңә кирәк кадәрле генә. Ленин үзе дә бит әнә укыган да укыган, укыган да укыган. Башына шуңа күрә кан сауган. Менә улыгызның да укуын туктатып торырга иде.

Хәнифә. Ничек туктатасың, Ленинның бөтен язган китапларын җыйган. Укый да яза. Хәерлегә генә булсын.

Нургазиз. Шулай инде. Кем белә инде анысын, бәлки, укый-укый Ленин кебегрәк кеше булыр. Бәлки, аңардан да уздырып җибәрер. Әтисе дә башлы кеше иде бит. Колхозны ал да гөл итеп тотты. Ул да китте председательлектән, колхоз да таркалды.

Хәнифә. Хәзер бөтен нәрсә таркала инде.

Нургазиз. Кем белә, бәлкем, Вил кебекләр җыяр. Тереләчәк улың. Әнә Торна авылында бер кыз да акылдан шашкан булган. Көпә-көндез урамда шыр ялангач йөргән. Хәзер терелгән, ди. Кияүгә чыгарга җыена, ди. Вилегез сезнең акылдан шашмаган ич. Бераз киткән генә, җиңеләйгән. Тереләчәк. Казанга укырга китеп ялгышты ул. Анда бит бер генә дә нормальный кеше юк. Трамвайга утырсаң, төшеп каласы килә. Бер-берсенә акыралар. Менә авылда Вилегез бер-ике ай дигәндә кеше булачак. Шулай шул, кирәгеннән артыкны укырга да, белергә дә ярамый. Күп белгәннәрне элек-электән үтергәннәр. Бер бик башлы кеше булган борын заманда. Бруна дигән. Шул әйткән, Җир Кояш тирәсендә әйләнә, дигән. Шуның өчен аны утта яндырып үтергәннәр. Хәзер дә үтерәләр. Фактически Ленинны да бит үтерәләр. Сталин башына җиткән аның, миннән өстен булмасын дип.

Хәнифә. Син үзең дә күп укыйсың бит, Нургазиз абый.

Нургазиз. Нәрсә ул минем уку. Мин бит үземә ошаганнарны гына укыйм. Мин баш өчен укымыйм, күңел өчен укыйм. Баш өчен күп укырга ярамый. Баш ул кечкенә, күп укыганны сыйдыра алмый. Кан тамырлары бик нечкә бит башта, түзә алмыйлар, шартлыйлар. Ә күңел киң ул, анда бөтен дөнья китабын укысаң да сыя, укыган саен күңел киңәя генә бара. Әкият күп укырга кирәк, Хәнифә сеңел. Әкиятне кешеләр күңел өчен язганнар.

Ким керә. Куышны күрә.

Ким. Нәрсә бу?

Нургазиз. Башта исәнләш, Ким энем!

Ким. Нихәл! Нәрсә бу?

Нургазиз. Вилгә бу, Ким Нурәхмәтович! Син Владимир Ильич Ленин дигән кешене укып беләсеңдер. Әллә оныттың дамы? Шул кеше, патша заманында аннан качып, Разлив дигән бер болында шалаш корып яшәгән. Шунда ничек итеп ривалютсия ясау турында китап язган. Беләсеңме шуны?

Ким. Йә, шуннан?

Нургазиз. Шуннан шул. Ривалютсия булган. Менә синең бертуган энекәшең дә Владимир Ильич Ленин кебек шалашта яшәп китап язарга җыена.

Ким. Сүтеп ташлагыз хәзер үк.

Хәнифә. Улым, нитмә әле син, нишләтик. Ленин кебек буласы килә. Ленин булып уйный.

Ким. Җүләр сүзенә карасаң, кем буласы килмәс. Кеше көлдермәгез. Болай да инде бөтен бала-чага сезнең капка төбендә.

Нургазиз. Сезнең капка төбендә, димә, Ким Нурәхмәтович. Безнең капка төбендә, диген. Хәзер каттижда яшәсәң дә, бу синең туган нигезең.

Ким. Күп белмә, картлач! Син котыртып йөрисеңдер әле. Җыен юк-барны син уйлап чыгарасың, әкият укып.

Хәнифә. Ким!..

Нургазиз. Белмичә сөйлисең, Ким Нурәхмәтович! Ташла шул начар гадәтеңне. Әтиең синең белмичә бер сүз дә әйтми иде. Менә рәсем. Менә Ленин утыра, менә шалаш. Аны миңа Вил үзе күрсәтте. Шуңарга охшатып эшлибез, диде.

Ким. Әкият. Яткан, ди, Ленин куышта. Сезнең ише дуракларны ышандырыр өчен язалар да. Чит илләрдә гуляйт итеп кенә йөргән ул. Сезнең ише дураклар аның ялганына ияреп яшәдегез дә рәтле пенсия дә ала алмыйсыз.

Нургазиз. Булганы җиткән безгә, Ким Нурәхмәтович! Без ул хәтле нәфесле халык түгел. Сугышка да бардык, сугыштык та, фашистны да җиңдек. Син бертуган энекәшеңнән шалаш күпсенәсең.

Хәнифә. Бәлки, ярдәме тияр. Шунда яшәп карасын. Бер уй башына керсә, чыгарып булмый бит, нишләтәсең. Үзем дә аптыраган инде. (*Күз яшен сөртә.*)

Ким. Йә, йә, булды, җебемә.

Хәнифә. Нишләтим инде аны хәзер...

Ким. Алып кайтмаска иде. Психлар больницасында андыйларның урыны. Анда врачлар.

Хәнифә. Акылдан шашмаган ич ул, җүләрләр йортында яткырырга.

Ким. Үзеңә читен.

Хәнифә. Түзәсең инде. Ул да бит бала минем өчен. Синең кебек үк.

Ким. «Төпчек» дип унбиш яшенә хәтле тезеңдә утырттың. Нормальный кешеләр кырык биш яшьтә бала тапмыйлар.

Нургазиз. Надан син, Ким Нурәхмәтович! Томана!

Ким. Син тик тор. Өең бар, өеңдә генә утыр.

Хәнифә. Ким, улым! Нәрсә инде син. Гомер буе керешеп яшәгән күрше абыеңа.

Ким. Вил дә аның әкиятләрен тыңлап шулай булды.

Нургазиз. Сиңа да сөйли идем. Тыңламый идең.

Ким. Бик кирәкләре бар. Сүзем шул – сүтеп ташлагыз бу карга оясын. (*Ленин томнары күтәргән Вилне күреп.*) Нихәл! Нигә исәнләшмисең?

Вил. Ә мин сезнең белән исәнләшергә теләмим. Чөнки сез – карак, сез –кеше талаучы.

Ким. Син кем инде?

Вил. Сез минем белән син дип сөйләшмәгез. Сезгә кешеләр арасында яшәргә ярамый. Сез бүреләр белән бергә яшәргә тиеш.

Хәнифә. Вил улым, бертуган абыеңа андый сүзләр әйтмә.

Вил (*Кимга*). Мин Ленинның 15 нче томын тапмадым. Син урладыңмы? Урлап саттыңмы? Сез – урлап сатучылар! Сез илне урлап саттыгыз.

Ким. Мин киттем, әнкәй! (*Китә.*)

Вил (*аның артыннан кычкырып кала*). Качып котыла алмассыз, вакыт җиле сезне качкан җирләрегездән җилдереп чыгарачак.

Хәнифә. Улым, тынычлан, улым! Абыең ул синең. Синең кебек үк минем улым бит ул.

Вил. Ул синең улың түгел. Ул – явыз, ул – тиран, ул – бирән! Илне без алардан чистартачакбыз. Алар үз корсакларын тутыру өчен генә яшәүчеләр. Аларга кешеләр кирәк түгел. Чөнки алар җанварлар! Илдә хәерчелек. Халык эчә, наркомания, спид... Халык кырыла. Аларның уенда ул юк. Алар – явызлар! Алар – карак! (*Кинәт тын калып тыңлый.*)

Хәнифә. Ни булды, улым?

Вил. Җырлыйлар.

Хәнифә. Ишетелми кебек.

Вил. Җырлыйлар...

Нургазиз. Вил улым, син теләгәнчә булды бугай бу шалаш.

Вил. Әйе, әйе... Мин канәгать. (*Төпләрнең берсенә утыра.*) Хәзер, әнкәй, миңа пальто кирәк булачак.

Хәнифә. Анысы ни өчен? Көн кызу бит, улым.

Вил (*Нургазизгә*). Бирегез әле, күрше бабай, картинаны? (*Рәсемне кулына ала.*) Менә күрәсеңме, әнкәй, Ленинның иңендә – пальто. Мин язганда, пальто минем иңемдә булырга тиеш.

Хәнифә. Хәзер, улым, хәзер. (*Китә.*)

Нургазиз. Төнлә дә монда кунасыңмы, Вил улым?

Вил. Ленин кайтып-китеп йөрмәгән.

Нургазиз. Эликтр тартырга да кирәк булыр, диюем.

Вил. Кирәкми. Разливта электр булмаган.

Нургазиз (*Ленин томнарыннан берсен алып*). Шушындый китаплары 55 дисеңме, Вил улым? Барысын да укып чыктыңмы?

Вил. Икешәр тапкыр. Кайберләрен өч тапкыр.

Нургазиз. Үзең ничәне язарга җыенасың соң?

Вил. Үземнең дөреслегемне, хаклыгымны аңлатыр өчен ничә том кирәк булса, шулхәтле язачакмын!

Нургазиз. Беркөн дә сөйләштек. Гел «үземнең дөреслек» дисең син, Вил Нурәхмәтович! Дөреслек дигән нәрсә синеке, минеке булмыйдыр. Дөреслек бит инде ул Ходай Тәгалә кебектер. Синең үз Аллаң, минем үз Аллам була алмый ич инде. Барыбызга да бер Алла.

Вил. Ялгышасыз! Һәр кешенең үзенә генә хас яшәү принцибы, фикерләү үзенчәлеге, үз дөреслеге була. Әлбәттә, әгәр дә бу сыйфатлар бөтен кешеләргә дә уртак булса, дөнья искиткеч гармонияле булыр иде. Ни кызганыч, ул сыйфатлар антогонистик булалар – һәр кеше үз дөреслеген абсолют

хакыйкать дип саный, бүтәннәрнең дөреслеген танырга теләми. Гармония югала, көрәш башлана. Берәүләр өчен үзенчә фикер йөртүчеләр яки дошман, яки надан, яки дивана. Аңладыгызмы?

Нургазиз. Бик тә аңлашыла. Әкиятләрдә дә бит үги ана үзенчә хаклы, үги кыз үзенчә хаклы. Шуңа күрә үги ана үги кызны яратмый. Менә алар икесе бертөсле уйласалар, ничек матур яшәрләр иде.

Вил. Владимир Ильич Ленин шул гармонияне эзләгән.

Нургазиз. Әһе... Тик менә гармония дигән сүзеңне төшенеп бетмим кебек.

Вил. Гармония ул – бөтен нәрсәнең бер-берсе белән килешкәнлеге, җайлашканлыгы.

Нургазиз. Менә хәзер аңлашылды. Алай булгач, гармун да шуны аңлата инде. Анда да бит бер тел артыннан икенчесе килә. Бер тавыш артыннан аңа охшашлырак, аңа ятышлырак тавыш чыга. Сандугач сайраганда, ала карга кушыла алмый бит инде, әйеме, Вил Нурәхмәтович?

Вил. Син – гений, син – даһи, күрше бабай!

Нургазиз. Бар инде анысы бераз.

Зәйнәпбануның «Нургазиз!» дигән тавышы ишетелә.

Менә Зәйнәпбану әбиең генә шуны аңламый.

Зәйнәпбану (*кереп*). Тагын шушында. Йөрмә кешегә мишәйт итеп. Исәнме, Вәли улым!

Вил. Сезгә күпме әйтергә була. Мин Вәли түгел, мин – Вил. Аңладыгызмы, Вил! Владимир Ильич Ленинны беләсезме?

Зәйнәпбану. Белмәскә. Мин ривалютсиянең унъеллыгы көнне туган бала. Ничә ел коммунист булып тордым. Кәнсәләргә җыеп укыталар да иде. Менә бу бабаң гына йөрмәде. Әкиятне мин өйдә ятып та укыйм, дия иде. Менә шушылар таратты ул СыСыСыРны. Чык әйдә, каз бәбкәләренә кычыткан турыйсы бар. Сау булып тор, Вәли улым!

Нургазиз. Күпме әйтәләр сиңа, Вәли түгел, Вил ул, Вил, Вил... Вы.И.Лы.

Зәйнәпбану. Өйрәтмә, беләм! Онытыла. Әйдә чык. (*Шалашны карап.*) Шушыны ясадыгызмыни көн буе? Кирәк инде, кирәк, алма өлгерә. Бала-чагадан сакламасаң, сындырып бетерерләр.

Нургазиз. Бакча саклар өчен түгел ул. Вил улыбыз шунда язып утырачак. Үзең коммунист, үзең Разливның ни икәнен белмисең.

Зәйнәпбану. Өйрәтмә. Барысын да белергә мин синең кебек әкият укып ятмадым. Гомерем, сыер имчәге тартып, сыер астында үтте. Менә Вәли улым әйтә... Тфү, телем коргыры, гомер буе күршедә яшәп өйрәнә алмадым. Вил инде, Вил. Менә Вил улым әйтә, барысына да Ленин язганнарны бозучылар гаепле, ди. Ленин булса да, крестиянгә шул абзар да сыер асты инде.

Вил. Алай булмаячак. Кеше азат булачак. Ленин башлаган бөек эшләрне без дәвам итәчәкбез. (*Китаплар арасыннан берсен алып.*) Менә укыгыз, нәрсә яза Ленин... «Бер адым алга, ике адым артка» ди. Нәрсә аңлата ул. Укыганыгыз бармы ул хезмәтне?

Зәйнәпбану. Биш класс белем белән каян мондый китаплар укырга инде.

Вил. Алайса тыңлагыз. Владимир Ильич Ленин-Ульянов «Бер адым алга, ике адым артка» дип аталган хезмәтендә большевиклар партиясенең тактик һәм стратегик бурычларын билгеләгән. Үз вакытында бу хезмәт архи актуаль булган. Бүген безгә икенче төрле юнәлеш алырга кирәк: ике адым алга, бер адым артка. Нигә алаймы? Бүген безнең көтеп торырга вакытыбыз юк: алга, бары тик алга гына. Ләкин чигенеп алмыйча да ярамый. Туктап уйланырга да кирәк.

Нургазиз (*Зәйнәпбануга*). Аңладыңмы инде?..

Зәйнәпбану. Өйрәтмә! Аңламаска теге. Уйланырга, ди. Син уйлыйсыңмы? Иртән чыгып киттең, гамеңдә дә юк. Гамеңдә дә юк дигәндәй, Лининны маузалидан алдырабыз, дип сөйләнәләр, булыр микән шундый эш?

Вил. Проблема гәүдәдә түгел, акылда. Аны алып ыргытып булмый. Без Ленин эшен дәвам итәчәкбез. «Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!» дигән лозунг яңача яңгыраячак.

Нургазиз. Карале, Вил Нурәхмәтович, пролетарий хәерче дигән сүзне аңлата, диләр. Хәерчеләр берләшеп нишли ала инде? Ленинның ул сүзе ялгыш булмады микән? Мин әллә кайчан язылган бер китапны укып чыктым. Шунда язылган, «Ком җыелып, таш булмас, кол җыелып, баш булмас» диелгән. Дөрес бит.

Зәйнәпбану. Чык әйдә, тузга язмаганнарны сөйли башладың. Әнә алигарыхлар җыелса, күрсәтерләр комыңны. Авыл кешесенә элек тә булмаган, хәзер дә юк, булмаячак та. Чык әйдә, әйләндермә кеше башын, болай да әйләнгән. Сау булып тор, кем, улым. (*Чыгып китә.*)

Нургазиз. Менә шуның белән илле җиде ел яшәдем инде, Вил Нурәхмәтович.

Вил. Юк, без башка юл белән китәрбез... (*Туктап калып тыңлана.*) Җырлыйлар.

Нургазиз. Ярый, чыгып керим инде мин. Йә тавыш чыгарыр. Мин керермен әле, ярыймы, Вил Нурәхмәтович! Син миңа язганнарыңны укырсың.

Вил. Керегез, Нургазиз бабай! Мин сезне бик тә хөрмәт итәм.

Нургазиз чыгып китә.

Аның бәхетле булырга хакы юкмы? Ни өчен илгә, халыкка бөтен көчләрен биреп яшәүчеләр һаман интегергә, ә илне талаучылар баерга тиеш. Юк, без башка юл белән китәрбез. Безнең каршыда торган киртәләр биек булса да, нигезе инде какшады, төртсәң аварга тора. Без шундый партия төзербез, ул халык үзе төзегән партия булыр. Безнең бурыч – кешеләрне бәхетле итү. Илдә бер генә кеше бәхетсез булса да, ил бәхетле була алмый. Илдә коррупция, наркомания, спид, алкоголизм. Кешелекнең тамырын корыта торган бу чирләрдән илне без арындырачакбыз. Кешеләрнең бәхетле булырга хаклары бар. Безнең архи бурычыбыз – һәртөрле гаделсезлектән илне коткару. Дөньяны үзгәртергә кирәк.

Рәшәткә янына бер төркем балалар килеп, Вилнең Ленин образына кереп сөйләгәнен кызыксынып күзәтәләр. Вил, аларга мөрәҗәгать иткәндәй, сүзен дәвам итә.

Кешелек дөньясы болай яшәргә тиеш түгел. Бу изге эшкә бөек фикер иясе Владимир Ильич Ленин алынган. Ләкин башлаган эшен ахырына җиткерергә аның гомере җитмәгән. Аның эшен дәвам иттерергә намуслы кешеләр булмаган. Власть башына наданнар, деспотлар, тираннар килгән. Аларны демократия күзлеге кигән авантюристлар алыштырган. Алар берсен-берсе алыштыра, власть бүлешә, ә халык һаман да хәерче. Владимир Ильичны алдаганнар, мине алдый алмаслар. Мин Россияне коррупциядән коткару законын ачтым. (*Балалар ягына бара-бара.*) Сез яңа, ирекле заманда яшәүче буын.

Балалар куркышып качалар.

Ә-ә!.. Сез куркасыз. Сезне туганда ук куркытып тудырганнар. (*Җыр сузып, шалашы янына кайта.*)

Это есть наш последний
Решительный бой:
С Интернационалом
Воскреснет род людской.

Балалар тагын рәшәткә янына килеп такмаклыйлар: «Тиле-тиле тилгән, чебеш эзләп килгән. Тиле-тиле тилгән, чебеш эзләп килгән».
Хәнифә, чыгып, балаларны куа.

Вил. Тимә аларга, әнкәй! Алар егерме беренче гасырны бәхетле итәчәк буын.
Хәнифә. Ашыйсың килгәндер, улым. Кереп ашап чык.
Вил. Кешенең гомере, әнкәй, ашап һәм ашарга эзләп үтә.
Хәнифә. Ач йөреп тә булмый бит, улым.
Вил. Кеше күп ашаган саен ач була. Күп ашаган саен комсызлана.

Малайларның берсе, зуррагы, рәшәткә янына килеп: «Хәнифә түти,
Вил безнең белән барсынмы?» – ди.

Хәнифә. Нинди Вил булсын ул сиңа? Вил абый, диген.
Малай. Вил абый безнең белән барсынмы?
Хәнифә. Кая барырга җыенасыз?
Малай. Кәҗә тавына. Бөркет оясы күрсәтәбез.
Хәнифә. Баралмый ул. Ул әле ашамаган.
Вил. Мин барам.
Хәнифә. Йөрмә, улым. Алар әле сабыйлар гына.
Вил. Олылар белән миңа кызык түгел, әнкәй! Алар изелә-изелә аңгырайганнар. Аларны изүчеләрнең акылын май баскан. Болар әле сафлар. Боларны бирәннәр кулына бирмәскә кирәк. Киттек, яшь дусларым!

Рәшәткә аша сикереп чыга да «Интернационал»ны җырлап атлый. Аңа балалар иярә. Хәнифә төп башына утырып кала. Айсылу үтеп
бара. Хәнифәне күреп туктый.

Айсылу. Исәнмесез, Хәнифә апа!
Хәнифә. Исәнме, Айсылу! Кая барышың болай?
Айсылу. Ерак чишмәгә суга барып кайтам әле. Аның ташы утырмый. Нәрсә, Вилнең чирләве дөресмени? Маңка малайлар белән чабып йөри.
Хәнифә. Балаларны ярата шул. Тегеләре дә моны үз итәләр.
Айсылу. Элек тә әллә ничек иде инде ул. Казан врачлары караганмы соң?
Хәнифә. Караганнар инде. Авыру түгел ул, дигәннәр, бераз ял итәргә генә кирәк, дигәннәр.
Айсылу. Келәнче авылында бик оста өшкерүче карчык бар, диләр. Шул үзең дә белмәгән авыруыңны таба, ди. Өшкереп җибәрә, ди. Яңа туган кебек буласың, ди.

Хәнифә. Үзең ни хәлләрдә соң, Айсылу?

Айсылу. Безнең шул инде, алда – гөл, артта – кычыткан. Кушаяклап чабып, җәяү йөрибез. Качып котылып булмады бит. Кияүгә чыгарга кешесе дә юк. Җыен исерек, исерек булмаганы шумашушный. Картаеп та барыла инде, егерме тулды. Ун елдан утыз була. Аннан кырык, илле... Монда нәрсә корып куйдыгыз соң әле?

Хәнифә. Вил ясады. Җиләстә ял итәр өчен, ди.

Айсылу. Өйгә сыймый башладымыни? Сезнекеләр шундый инде. Ким абый, сыймагач, каттиж дигән өй салып чыкты. Вил – шалаш. (*Көлә.*) Кереп карасам ярыймы?

Хәнифә. Кер әйдә, кер.

Айсылу (*кереп тикшеренә. Куыш авызыннан башын тыгып*). Рәхәт икән монда. «Җүләр» дигән булалар. Итәрсең җүләр. Без ул җүләр, бер капчык писүк өчен шушы кызуда чөгендер утап йөрибез. Их, шушы куышта рәхәтләнеп ятып йокларга! Миңа өйләнмәс микән Вил? Әби әйтә, дәртең кузгалган, кияүгә чыгарга кирәк, ди. (*Ул бик еш үз сүзеннән үзе көлеп сөйләшә.*) Үземнең элек исем дә китми иде, хәзер, егетләр күрсәм, кытыгым килә башлый. Соңга калып өлгердең, ди, әби.

Хәнифә. Чибәрләндең шул.

Айсылу. Элек тә чибәр идем мин. Безнең нәсел чибәр нәсел, ди, әби. Бу китапларның барысын да Вил укыймы?

Хәнифә. Укый.

Айсылу. Бигрәк күп. Нургазиз бабай әйтә, җүләр түгел ул, ди. Вил үзе дә, мин җүләр түгел, дип әйтә, ди. Кем инде үзен җүләр, ди. Исерек тә бит, мин исерек, дими. Өшкерүчегә алып барып карагыз, Хәнифә апа. Карап торырга чын кеше кебек. Синең киленең булсаң ярар иде ул, әйеме, Хәнифә апа. Их, Ким абыйның егет чагына туры килмәгәнмен шул. Бай хатыны гына булып яшәр идем. Туйдым тирес актарып. Чыннан чибәр бит мин, әйеме? Телевизордан күрсәткән булалар. «Чибәрләр конкурсы» дигән булалар. Җыен салам сыйрак! Әрәм булып ятабыз монда.

Хәнифә. Насыйбы табылыр әле, Айсылу!

Айсылу. Кем табыла? Җыен... Җитмәсә, чәйнәгән булалар. Шалтай-балтай, тиле-миле, дигән булалар. Иха-ха да миха-ха дип йөри, диләр. Миндәге акыл берәүдә дә юк, беләсең килсә. Казанда минем яшьтәшләр әллә нишләшеп беткән, диләр. Шалтай-балтай булсам да, миңа әле берәүнең дә кагылганы юк. Кагылырга җыенучылар – муре. Берсен дә якын җибәрмим. Керпе Садыйк малае «кыз түгел» дип сөйләп йөри, ди. Врачлардан ысправка алып кайтып, кылый күзенә чәпеп куям әле заразының. Кызык кына бу кешеләр, Хәнифә апа, үзләренекен күрмиләр, кеше бот арасын тикшерәләр. Әй рәхәтләндем синең белән сөйләшеп, Хәнифә апа! Ачуланма инде. Тукта, тагын бер кереп чыгыйм әле шалашына. (*Кереп чыга.*) Гел китап та китап инде. Менә мин укый алмыйм инде. Үтер, укый алмыйм. Укый гына башлыйм да, йокыга китәм. Әле ярый телевизор бар, бөтенесен күрсәтәләр. Ярый, сау бул, Хәнифә апа!

Хәнифә. Күлмәгең бигрәк матур.

Айсылу. Эһе! Былтыр бәрәңге иләмсез уңды бит. Бер баз башланмыйча язга чыкты. Шуны олы бер «КамАЗ»га төяп җибәрдек. Рәхәтләндек акчасына, әбигә дә, әнигә дә, үземә Казаннан ике күлмәк алып кайттым. Киң итәклеләрен. Берсен хәзер кидем, берсен – Сабан туена. Чалбар кимә, ди, әби. Егетләрнең күзе иң беренче кызлар итәгенә төшә, ди. Егетләр кызлар итәге җиленнән тилерәләр, ди. Дөресме, Хәнифә апа?

Хәнифә. Әбиең әйткәч, дөрестер инде.

Айсылу. Аның бер дә белмәгәне юк.

Хәнифә. Бүген син җырладыңмы ул, Айсылу?

Айсылу. Кайчан?

Хәнифә. Баягынак.

Айсылу. Мин гел җырлап йөрим инде ул.

Хәнифә. Мин ишетмәдем, Вил ишеткән, ахрысы.

Айсылу. Нәрсә ди?

Хәнифә. Җырлыйлар, ди.

Айсылу. Шул миндер инде, миннән башка кем җырласын авылда.

Хәнифә (*Айсылуны киткән җиреннән туктатып*). Айсылу!.. Кил әле, Айсылу! Ни... Сиңа безнең Вил ошыймы?

Айсылу. Нәрсәме?

Хәнифә. Ошыймы?

Айсылу. Ник алай дип сорыйсың, Хәнифә апа?

Хәнифә. Килеп йөр син безгә.

Айсылу. Нәрсәгә?

Хәнифә. Вил янына. Сөйләшеп утырырсыз.

Айсылу. Кит әле, нәрсә сөйләшим мин аның белән.

Хәнифә. Сөйләшкәч сүз табыла ул.
Айсылу. Юк инде. Шумашушныйлардан куркам да.
Хәнифә. Куркыныч түгел ул. Сабый бала кебек. Савыгырга ярдәм ит. Дөньяны үзгәртәм, дип саташа. Бәлки, синең белән сөйләшкәч...
Айсылу. Мин үзем дә, Хәнифә апа, дөньяны үзгәртсәң иде, дип саташам. Мин иң бәхетле хатын булыр идем. Тупырдап торган балалар тудырыр идем. Ату бер чирләшкә табалар да больнистан больниска чабалар. (*Ким кергәнне күреп.*) Исәнмесез, Ким абый!
Ким. Исәнме!.. Әнкәй, бар әле алып кайт тегене. Мине тыңламый. Су буенда ялангач йөри. Көләләр.
Айсылу. Йөрсә ни... Казанда су буенда барысы да ялангач йөри.
Ким. Син тик тор! Бар әле, әнкәй!
Хәнифә. И Ходаем! (*Чыгып китә.*)
Ким (*Айсылуга*). Ә син нишләп йөрисең монда?
Айсылу. Ярамыймыни?
Ким. Көпә-көндез, киенеп-ясанып...
Айсылу. Бүген бит ял көне, Ким абый!
Ким. Авылда бит ял көне юк.
Айсылу. Ә мин үземә-үзем ял ясадым. Хәнифә апа әйтә, безгә килеп йөр, ди.
Ким. Нигә?
Айсылу. Вил белән сөйләшеп утырырга, ди.
Ким. Шуннан?
Айсылу. Без бит Вил белән тугызынчыга хәтле бер класста укыган идек.
Ким. Шуннан?
Айсылу. Кызык син! Шуннан, шуннан... Утырган да шуган.
Ким. Ярый, бар.
Айсылу. Сау булыгыз, Ким абый! (*Китә.*)
Ким (*аның артыннан карап торганнан соң*). Кил әле монда!
Айсылу (*килеп*). Нәрсә, Ким абый?
Ким. Кил бүген Ахун чокырына!
Айсылу. Нәрсәгә, Ким абый?
Ким. Килгәч әйтермен.
Айсылу. Кайчан?
Ким. Егетләр белән кайчан күрешәләр соң?
Айсылу. Син егет түгел ич.
Ким. Очрашкач, егет булырмын.
Айсылу (*көлеп*). Ай-яй, беләм мин нигә Ахун чокырына чакырганыңны.
Ким. Белгәч, бик әйбәт.
Айсылу. Мин әле кыз кеше, Ким абый!
Ким. Анысы тагын да әйбәтрәк.
Айсылу. Харап итеп ташлар идең бугай.
Ким. Өйләнсәм, кияүгә чыгасыңмы соң?
Айсылу. Хатының бар ич инде.
Ким. Хатынны бит аны аерырга да була.
Айсылу. Ай-яй, хитри-митри син, Ким абый! Өйләнмәгән булсаң ие ул. Менә шундый куышта ятар идек тә йоклар идек.
Ким. Куыш ошыймыни?
Айсылу. Эчендә шундый рәхәт. Кереп чыктым, чыгасы килми.
Ким. Әйдә, бергә карап чыгыйк.
Айсылу. Мин карап чыктым инде.
Ким. Кем белән?
Айсылу. Кем белән булсын, үзем генә.
Ким. Хәзер икәү карыйк.
Айсылу. Ай-яй, хитри-митри! Нишлисеңне белми дип беләсеңме әллә?!
Ким. Белгәч, бик әйбәт.
Айсылу. Бик әйбәт түгел шул.
Ким. Бигрәк чибәр инде үзең.
Айсылу. Чибәр булмасам, Ахун чокырына чакырмас идең. Сау бул, Ким абый!
Ким. Китмә инде.

Айсылуның кулыннан тотып, куышка алып кермәкче була. Айсылу, кулын тартып алып, көлә-көлә чыгып йөгерә.

Ким. Кил Ахун чокырына! (*Ленин томнарын карый, актара.*)

Рәшәткә буенда Вил белән Хәнифә күренәләр.

Вил. Кагылмагыз Ленин хезмәтләренә! (*Кычкыра да йөгереп кереп Ленин томын Ким кулыннан тартып ала.*) Сез аңа лаек түгел! Торыгыз аннан. Сезнең анда утырырга хакыгыз юк!

Ким. Йә, кызма инде, укып карыйм, бәлки, мин дә синең кебек булырмын. Югыйсә гел мине сүгәсең.

Вил. Сез минем кебек була алмыйсыз.

Ким. Ленин китапларын укысам дамы?

Вил. Юк! Ленинны баш белән укырга кирәк, корсак белән түгел. (*Бакчага кергән Хәнифәгә.*) Әнкәй, әйтегез аңа, китсен бездән.

Хәнифә. Алай итмә инде, улым. Абыең бит ул. Бертуган абыең.

Вил. Дөньядагы бөтен кешеләр дә берсенә берсе туган. Ләкин һәрберсе аерым-аерым яши. Китсен! Аның үз өе бар.

Ким. Ачуланма инде, энекәш! Мин бит сине яратам.

Вил. Мин хатын-кыз түгел яратырга. Сез яратырга сәләтле дә түгел. Бер кешене яратыр өчен, бөтен кешеләрне дә яратырга кирәк. Сез үзегезне генә яратасыз. Хәтта үзегезне дә яратмыйсыз, үзегезнең корсагыгызны гына яратасыз.

Ким. Корсаксыз да яшәп булмый бит, энекәш! Синең дә бит корсагың бар, синең дә бит ашыйсың килә.

Вил. Килми минем ашыйсым. Ашыйсым килсә дә, мин ашыйсым килгәнгә генә ашыйм. Ә сез корсак тутырыр өчен ашыйсыз. Ләкин сезнең корсагыгыз беркайчан да тулмый. Килгән саен, әни, ашарга бармы, дип сорыйсыз.

Ким. Ярый, мин начар инде, начар. Син дә инде бала-чага янында шыр ялангач йөрмә. Кешеләр көлә.

Вил. Көлүчеләр үзләренең шәрә икәнлекләрен белмиләр. Чүпрәккә төренгәч, алар үзләрен ялангач түгел дип уйлыйлар. Сез шәрәләр. Катлы-катлы туннарга төренсәгез дә, мин сезне үтәли күрәм.

Ким. Ленин да кешеләрне үтәли күргәнме?

Вил. Күргән.

Ким. Кайсы китабында язган инде «күрәм» дип. Укып күрсәт.

Вил (*томнарны ачып, укып-укып күрсәтә*). Менә, менә карагыз. «Мы говорим: наша цель – достижение социалистического общественного устройства, которое устранит деление человечества на классы, устранит всяческую эксплуатацию человека человеком и одной нации другими нациями» (32 т., 78 б.). «Мы хотим добровольного союза наций – такого союза, который не допускал бы никакого насилия одной нации над другой, – такого союза, который был бы основан на полнейшем доверии, на ясном создании братского единства, на вполне добровольном согласии» (40 т., 43 б.). «Чтобы управлять, надо иметь армию закаленных революционеров-коммунистов, она есть, она называется партией» (42 т., 254 б). «Масса должна иметь право сменять их, масса должна иметь право знать и проверять каждый малый шаг их деятельности» (38 т., 157 б.). «Коммунизм один только в состоянии дать демократию действительно полную, и чем она полнее, тем скорее она станет ненужной, отомрет само собой...» «Только коммунизм создает полную ненадобность государства, ибо некого подавлять» (33 т., 90 б.). «Мы ставим целью равенства как уничтожение классов» ( 38 т., 353 б.).

Ким. Алай икән! Бу томнарның этидән калганлыгын беләсең инде син. Аларны этинең ачып та карамаганлыгын беләсеңме? Аларны бер генә райком секретареның да укымаганын беләсеңме?

Вил. Алар наданнар.

Ким. Син укыган. Бот буе малайлар белән уйнап йөрисең.

Хәнифә (*Кимга*). Бар инде, улым, кайт. Вилнең ял итәсе бар.

Ким. Энекәш белән сөйләшүе кызык бит, әнкәй! Тагын ниләр язган инде Ленин?

Вил. Мин сезнең белән сөйләшергә теләмимм.

Ким. Ленин бит кешеләр белән сөйләшкән.

Вил. Кешеләр белән сөйләшкән. Сезнең кебекләр белән түгел.

Ким. Мин кеше түгелмени?

Хәнифә. Ким, җитте сиңа!

Ким. Кызык бит, әнкәй!

Вил. Әнкәй, әйтегез аңа, миңа эшләргә комачауламасын! (*Төп өстенә утырып, китапка «чума».*)

Хәнифә (*Кимга*). Ярый инде, бар.

Ким. Ашарга берәр нәрсә бармы? (*Вилгә ишарәләп.*) Урамга чыгарма. Минем турыда әллә ниләр сөйләп йөри.

Хәнифә. Ачуланма инде, нишләтәсең.

Ким. Ачу чыга шул. Көне-төне чабасың. Рәхмәт әйткән кеше юк. Бөтенесе таларга гына тора.

Хәнифә. Бик нитмә инде. Әтиегез дә чапты-чапты да... Вил белән җаена торыбрак сөйләш. Врач әйтте бит, нервысын чыгарырга ярамый, диде. Үртәмә.

Чыгып китәләр. Вил укый, яза.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыт кичкә авышкан. Вил һаман да селкенмичә утыра. Малайлар рәшәткә ярыгыннан тын гына күзәтәләр. Алар янына Нургазиз килә.

Нургазиз (*әкрен тавыш белән*). Көш! Китегез моннан!
Беренче малай. Без карап кына торабыз.
Нургазиз. Кино түгел ул сезгә, барыгыз!
Икенче малай. Ә ул нәрсә яза?
Нургазиз. Сезне бәхетле итәсе килә аның.

Малайлар, авызларын учлары белән томалап, хихылдап алалар. Нургазиз аларның башларыннан сыйпый-сыйпый озата.

Нургазиз. Барыгыз, әниләрегез югалткандыр. (*Малайлар киткәч, рәшәткәгә таянып, Вилгә карап тора.*)

Айсылу үтеп бара.

Айсылу. Исәнме, Нургазиз бабай!
Нургазиз. Тс-с-с!.. Шаулама! Күрмисеңмени, кеше эшли?!
Айсылу. Китап уку эшмени?!
Нургазиз. Кемгә – эш, кемгә – мәзәк.
Айсылу. Күп укырга ярамыйдыр аңа, шуның аркасында бит инде ычкынган.
Нургазиз. Ычкынмаган ул, күпне сөйләмә.
Айсылу. Нәрсә укый икән?
Нургазиз. Ленин дигән кешене беләсеңме? Шул кешенең «Империя крититсизм» дигән китабын укыдыңмы?
Айсылу. Кит әле, җүләр мәллә мин андый китап укырга. Син укыдыңмы соң?
Нургазиз. Мин укымасам да беләм. Минем өчен дә, синең өчен дә укый ул.
Айсылу. Минем үземнеке үземә җиткән. Сигез класс бетердем.
Нургазиз. Сигез белән ерак китеп булмый шул хәзер.
Айсылу. Ә нигә кайтарганнар алайса?
Нургазиз. Бер хикмәте бардыр. Сталин заманында бик күп укыган, бик күп белгәннәрне сары йортларга япканнар.
Айсылу. Нәрсә соң ул сары йорт?
Нургазиз. Нәрсә булсын, җүләрләр йорты.
Айсылу. Вилне бит япмаганнар.
Нургазиз. Япмасалар. Казаннан ераккарак җибәргәннәрдер. Бәлки әле, кем белә, зур кеше ясамакчылардыр. Бераз карап йөрсен мондагы хәлләрне, нәрсәнең ничек икәнен белсен, аннары зур урынга утыртабыз, дигәннәрдер.
Айсылу. Шумашушный түгел дисеңмени?
Нургазиз. Шумашушный – синең белән без ул.
Айсылу. Мин нишләгән ул кадәрле?
Нургазиз. Ярый, бар, юлыңда бул.
Айсылу. Миңа Хәнифә апа әйтә, Вил янына килеп йөр, ди.
Нургазиз. Ни-нәрсәгә ди?
Айсылу. Син килеп йөрсәң, терелә ул, ди.
Нургазиз. Терелер дә. Хатын-кыз сихерче бит ул. Терелтә дә, акылдан да яздыра. Ярый, әйдә, комачауламыйк, эшләсен.

Китәләр. Хәнифә, кереп, Вилнең иңнәренә пальто сала. Кереп китә. Рәшәткә янына Айсылу килә дә рәшәткә аша бакчага керә. Вилнең язганын укырга тырыша. Тигезлеген югалтып, егыла яза. Вилгә тотынып кала. Вил, куркуыннан сикереп торып, Айсылуга карап тора. Айсылу да куркуыннан чигенә.

Вил. Син?!

Айсылу. Мин!.. Исәнме, Вил! Кайчан кайттың, Вил?

Вил эндәшми.

Әллә танымыйсыңмы, Вил?

Вил. Таныйм, син – Айсылу!

Айсылу. Айсылу, Айсылу! Без бит тугызынчы класска чаклы бергә укыдык, син алдагы партада идең, мин – иң артта.

Вил. Танымыйм.

Айсылу. Ничек инде танымыйсың? Бер авылдан. Каникулларга да кайтасың.

Вил. Мин сине күрми идем.

Айсылу. Ничек күрәсең. Без кем дә син кем. Син Казанда укыйсың, без монда...

Вил. Бөтен кешеләр дә тигез булырга тиеш. Кешеләре тигез булмаган җәмгыять кешелек җәмгыяте түгел.

Айсылу (*өстәл өстендә яткан кәгазьләргә карап*). Ә син нәрсә язасың?!

Вил. Аларны син аңламыйсың. Аларны бик күпләр аңламый. Бүгенге кеше үзеннән башка кешене аңларга теләми. Кеше үз-үзенә бикләнде.

Айсылу. Син бу китапларның барысын да укыдыңмы? (*Бер томны кулына алып.*) В.И.Ленин, 20 том.

Вил. Куй урынына! Син аны аңламыйсың.

Айсылу. Ишеткәнем бар инде Ленин турында.

Вил. Ишетү генә аз. Аңларга кирәк. Сәясәттәге спекулянтлар бөек философ Ленинның хезмәтләрен күрмәмешкә салыналар. Аңардан үзләре кебек спекулянт ясамакчы булалар. Аңардан гаеп эзлиләр. Аны сүгүчеләрнең берсе дә Ленинны укымаган. Ул бит сөрсеп беткән дөньяны яңартырга алынган даһи. Аңлыйсыңмы?

Айсылу. Әһе...

Вил. Син беләсеңме, кеше туганда азат, ирекле булып туа. Ләкин, тууга, аны чүпрәккә урап куялар. Кешенең иреген буалар.

Айсылу. Урамасаң, салкын тия ич аңа.

Вил. Син мине аңламыйсың.

Айсылу. Аны гына аңламаска. Әллә Ленин да шулай язганмы?

Вил. Ленин ул – философ!

Айсылу. Ә бу куышны ник ясадың? Шундый матур. (*Кереп чыкмакчы була.*)

Вил. Ярамый!

Айсылу. Мин инде аны көндез карап чыктым.

Вил. Кем рөхсәт итте?

Айсылу. Хәнифә апа! Вил, чибәрме мин? (*Вил карап торгач, уңайсызлана.*) Карап торма инде алай.

Вил. Син чибәр. Әйе, син чибәр.

Айсылу. Син дә чибәр.

Вил. Дөньяда бөтен нәрсәне дә чагыштырып карарга кирәк. Дөньяда бөтен нәрсә дә чагыштырмача. Син Эйнштейнны беләсеңме? Юк, белмисең. Аның чагыштырмалылык теориясе бар. Теория относительности. Ул дөньяны бөтенләй икенче яктан өйрәтүче теория.

Айсылу. Ярый, мин китим инде, Вил. (*Көйләп, кайтыр якка атлый.*)

Кайтам инде, кайтам
Туган ягыма...

Вил. Тукта! (*Айсылу янына килеп.*) Син матур җырлыйсың.

Айсылу. Хәнифә апа да әйтте. Минем җырны тыңлыйсың икән.

Вил. Аларны да син җырлыйсыңмы?

Айсылу. Мин булмый, кем булсын.

Вил. Син бик матур җырлыйсың.

Айсылу. Үзебезгә ярый инде.

Вил. Син кайтма.

Айсылу. Нишлим монда?

Вил. Син җырла.

Айсылу. Язуың кала бит.

Вил. Җырла.

Айсылу. Син нинди җыр яратасың?

Вил. Бөтен җырларны да.

Айсылу. Кил алайса, мин монда басам, син монда утыр. Кул чап.

Вил. Нигә?

Айсылу. Артистларны кул чабып каршы алалар.
Вил. Син артист түгел.
Айсылу. Җырлагач, артист инде. Кул чапмасаң, җырламыйм.
Вил. Мин кул чабам. (*Кул чаба.*)
Айсылу. «Урманнарда йөрдем»не җырлыйммы?
Вил. Җырла. (*Кул чаба.*)
Айсылу. Урманнарда йөрдем берьялгызым
Баласын җуйган болан эзеннән.
Башларым әйләнеп китте кинәт,
«Башканы сөям» дигән сүзеңнән.

(*Вилнең елаганын күреп.*) Ник елыйсың?
Вил. Баласын җуйган болан.
Айсылу. Җыр гына бит ул, елама!

Бу күренешне карап торган Хәнифә Вил белән Айсылу янына килә.

Хәнифә. Вил, улым, табыла аның баласы. Ерак китмәгән ул.
Айсылу. Кайтам инде мин, Хәнифә апа!
Хәнифә (*Айсылуны озата барып*). Рәхмәт сиңа, Айсылу!
Айсылу (*шыпырт*). Күзләрен күрдем мин аның, Хәнифә апа! Әллә нинди. Төбе юк күл кебек. Сау бул, Хәнифә апа!
Хәнифә. Сау бул! (*Вил янына килә.*)
Вил. Ул матур җырлый.
Хәнифә. Матур. Үзе дә чибәр. Минем улым матурларны гына ярата шул ул.
Вил. Без бергә укыганбыз.
Хәнифә. Әйе, әйе, бергә. Ничә ел бергә. Беренче класстан алып бергә.
Вил. Мин аны начар хәтерлим.
Хәнифә. Син бит, улым... Син укыдың да укыдың. Әллә укудан бераз ял итәсеңме? Язуыңны да куеп торсаң...
Вил. Минем өчен кем укыр, кем язар. Әнкәй, нигә мине авыру, диләр? Мин бит чирле түгел.
Хәнифә. Түгел, улым, түгел!
Вил. Мине ленинизм тәгълиматларын яклаган өчен эзәрлеклиләр, әнкәй. Мин беләм, минем арттан күзәтәләр.
Хәнифә. Беркем дә күзәтми, улым, син арыгансың гына.
Вил. Эзәрлеклиләр, әнкәй! Чөнки минем әйткәннәрем күпләргә ошамый. Син минем язганны берәүгә дә әйтмә, ярыймы, әнкәй! Җир өстендә кешеләрне төрле катлауларга бүлеп бетерделәр. Шуның нәтиҗәсендә явыз кешеләр килеп чыкты. Җиргә синең кебек кешеләр кирәк. Әгәр дә бөтен кешеләр синең кебек булса, җир өстендә коммунистик җәмгыять төзеп булыр иде. Коммунизмны «утопия» диләр. Кеше утопия белән яшәргә тиеш. Коммунизм идеясен Хрущев кебек наданнар пычраттылар. Егерме елдан коммунизм төзибез, дип, халыкны алдар өчен изге сүзне кадерсезләделәр. Коммунизмны егерме, утыз, кырык елдан да төзеп булмый. Бәлки, ул төзелмәс тә. Ләкин ул бар. Еракта, бик еракта. Кеше аның барлыгына ышанырга тиеш. Күктә – галәмдә миллион ел барып та барып җитә алмаслык йолдызлар бар. Аңарга кешеләр беркайчан да барып җитмәячәкләр. Әмма ул йолдыз бар. Менә шул йолдызны күрү турында хыялланырга тиеш кешеләр. Оҗмахны да берәүнең дә күргәне юк. Тик аны «юк» дип кем әйтә ала? «Юк» дип әйткән кеше кеше түгел ул. Ул бүгенге белән генә яшәүче җан иясе. Чебен ул. Кайда татлы, шунда куна, кайда пычрак, шунда җыела.
Хәнифә. Боларны син, улым, үзең уйлап чыгарасыңмы?
Вил. Мин уйлап чыгармыйм. Мин ул законнарны ачам гына. Наданнар миннән көләләр. Ленин язганнарны аңламаучы наданнар аны үзләре дәрәҗәсенә төшереп аңа әллә нинди гаепләр тагалар. Ленинны аңлар өчен Ленин дәрәҗәсенә күтәрелергә кирәк. Мең тәңкәгә хәтле акча саный белүне алар зур белемгә саныйлар.
Хәнифә. Улым, ишетәсеңме?
Вил. Нәрсәне?
Хәнифә. Айсылу җырлый.
Вил. Юк, моны син җырлыйсың, әнкәй! Синең җаның җырлый. Кешенең үз җаны җырласа гына бүтәннәр җырын ишетә. Син әйт, кешеләрнең зарын кем ишетә? Кешенең елау авазын тоя алганнар ишетә. Җирдә шундый җәмгыять төзергә кирәк, кешеләр бер-берсенең җырлаганын да, елаганын да ишетергә сәләтле булсыннар. Күңелләре саңгырау булмасын кешеләрнең.
Хәнифә. Шулар турында язасыңмы, улым?
Вил. Мин шул җәмгыятьнең моделен төзим.

Хәнифә. Абыеңны да син бик ачуланма инде.

Вил. Мин аны ачуланмыйм. Мин андыйларны фаш итәм. Алар корсакларын кыйммәтле костюмнар астына яшерәләр. Мин ачып күрсәтәм. Ленин кебек. Ленин андыйларның битлеген салдырган. Шуңа күрә капкорсаклар аны яратмыйлар.

Нургазиз белән Зәйнәпбану күренәләр.

Нургазиз. Керергә ярыйдыр бит, күршеләр!

Хәнифә. Әйдәгез, әйдә!

Нургазиз. Менә Вил улыбыз белән сөйләшеп утырырга дип кердек әле. Телевизордан карар нәрсә юк, радиодан тыңлар әйбер юк. Тыңлый гына башлыйсың, аны алыгыз, моны алыгыз, дип, дару мактый башлыйлар. Дару алырлык пинсе бирмиләр. Шул даруны алыгыз, диләр. Ничек соң, Вил Нурәхмәтович, җайлымы урының? Укып-язып буламы?

Хәнифә. Була, була. Бик матур сөйләшеп утырабыз әле.

Нургазиз. Без дә матур гына сөйләшеп утырган җирдән...

Зәйнәпбану. Җә, җә... Кеше башын әйләндермә.

Нургазиз. Баш ул әйләнер өчен, Зәйнәпбану. Шуның өчен аңа муен дип аталган күчәр куелган.

Вил. Урысның «кучер» дигән сүзе татарның «күчәр» дигән сүзеннән алынган, күчереп йөртүче. Күчәр дә күчереп йөртә, кучер да күчереп йөртә.

Нургазиз (*Зәйнәпбануга*). Менә күрәсеңме, безнең Вил барысын да белә. Вил улым, бу җир пае белән ни булып бетәр икән? Авылны тагын болгата башладылар бит.

Вил. Ленинны укырга кирәк.

Нургазиз. Язып калдырганмы?

Вил. Җир һәм кеше. Ул проблеманы читләтеп үтеп булмый. Шунысын онытырга ярамый, кеше ул үзе җирнең продукты. Җир булмаса, кеше булыр идеме? Парадокс – җирнең продукты кеше үзен җирнең хуҗасы дип атый. Алай була аламы?

Нургазиз. Бәрәңге дә җирнең продукциясе бит. Бәрәңге ничек инде мин җирнең хуҗасы дип әйтә алсын.

Зәйнәпбану. Кысылмый гына утыр әле син.

Нургазиз. Син үзең ирләр сөйләшкәнне тыңлап кына утыр. Болай була инде алайса... Колхоз, диделәр, асатсия, диделәр. Хәзер «агрофирма» дигән сүз уйлап чыгардылар, ә җир һаман да җир дип атала. Болай булып чыга. Ни генә кыландырсалар да, берни дә барып чыкмый инде. Җирне көчләргә ярамый. Болай бит ул – хатын-кызны көчләгән өчен статья бар, җирне көчләгән өчен – юк.

Вил. Сез юридик терминнарны бутыйсыз. Җир ул матди нәрсә булса да, әхлакый категория. Сез уйлап карагыз, алогизм: кешене – җирнең продуктын сатарга ярамый, җирне сатарга ярый. Кем мондый вәхшилекне уйлап чыгарды? Капитализм.

Койма яныннан үтеп баручы Ким, туктап, әңгәмәне тыңлап тора.

Нургазиз. Капитализм дигәннән, нигә дип үлгәнне терелтеп интегәләр икән. Социализмы ярамагач, бүтән төрлерәген уйлап чыгарырга иде инде. Ленинның да башы җитеп бетмәгән, Вил Нурәхмәтович.

Зәйнәпбану. Туктале шул Нурәхмәтович диюеңнән. Әйт үзебезчә итеп, Вәли улым, диген.

Вил. Вәли түгел, Вил!

Нургазиз. Надан башы белән кысыла бит тәки. Син менә әйт әле, Вил Нурәхмәтович, нигә бу хатын-кыз дигән нәрсә өйрәтергә оста икән?

Вил. Хатын-кызлар ирләр белән бер хокукта булырга тиеш. Ленин хезмәтләрендә бу һәрвакыт ачык әйтелә. Ләкин хатын-кызга чын хокук әле бирелмәде. Без хатын-кызның җәмгыятьтәге чын урынын билгеләячәкбез.

Нургазиз. Мин әле Ленин турында әйтүем иде. Башы җитеп беткән ривалютсия ясарга. Менә мәңге дә җимереп булмый торган социализм төзергә башы җитмәгән.

Вил. Аның эшен дәвам иттерүчеләр булмаган.

Нургазиз. Барые, Вил Нурәхмәтович! Әтиең Нурәхмәт бик маһир кеше иде. Сезгә дә бит исемнәрнең ниндиен кушты. Берегез – Ким, икенчегез – Вил. Нәрсәдер монда ни инде. Кайсыдыр җирен уйлап бетермәгән Ленин. Хикмәте аның шунда: ул авылда тумаган. Авылда туса, крәстияннең ничек яшәгәнен күреп үссә, бүтән төрле, Ельцин да җимерә алмаслык социализм уйлап чыгарырие.

Вил. Син, бабай, Ленинга тел тидермә.

Нургазиз. Юк, юк, Вил улым, болай гына әйтүем. Җимерелде бит.

Вил. Җимерелгәнне төзәтеп була. Без, Ленин тәгълиматларына таянып, бүтән юл белән китәрбез. Яшәсен яңартылган ленинизм! (*Бакчага кереп килгән Кимга күрсәтеп.*) Без, боларны класс буларак юк итмичә, көрәштән туктамаячакбыз. Әнкәй, нигә ул һаман безгә килә? Нигә син аны һаман да кертәсең?

Ким. Йә, йә, кызма. Сөйләшегез, мин тыңлап утырыйм.

Вил. Тыңламагыз, чыгып китегез. Сез без сөйләгәнне аңлаучылар түгел. Чыгып китегез.

Ким. Кызма, диләр.
Вил. Сез миңа кычкырмагыз.
Ким. Кычкырмыйм, әйтәм генә.
Нургазиз. Ким күрше!..
Ким. Бар әле, син чыгып кит моннан. Һәм бүтән кереп йөрмә. Гомерең буе акыл сатып кеше бутадың. Рәтле эш эшләмәдең.
Хәнифә. Ким!..
Зәйнәпбану. Син бик тузынма әле, күрше! Аның эшен син эшләдең мәллә. Аллага шөкер, колхозында да эшләдек, өйдә дә эшләдек. Өй ычтинабыз тулы грамыты.
Ким. Менә шуларга карап утырыгыз. Барыгыз өегезгә!
Хәнифә. Ким, нишләвең? Өйдән кеше куып чыгаралармы?
Вил. Син үзең чыгып кит безнең өйдән. Деспот! Тиран!
Нургазиз. Ярый, Хәнифә, чыгыйк инде. Сау бул, Вил улым!

Чыгып китәләр. Аларны Хәнифә озата бара.

Ким. Тыңлап-тыңлап торам да, энекәш, син бит авыру кеше түгел. Дивана түгел бит син, егеткәй!
Вил. Ә кем әйтте сиңа «дивана» дип.
Ким. Нигә дип кайттың монда?
Вил. Мин кайтмадым. Мине кайтардылар.
Ким. Кемнәр?
Вил. Синең кебекләр!
Ким. Кемнәр инде ул минем кебекләр?
Вил. Халыкны талаучылар!
Ким. Кемне таладым инде мин?
Вил. Каян акча алып салдың ул хан сараен? Нинди акчага сатып алдың ул иномарканы?
Ким. Алай икән. Шуның өчен кычкырасыңмыни «карак» дип. Ә син бизнес дигән нәрсәне беләсеңме?
Вил. Россиядә бизнес юк. Талаучылар уйлап чыгарган сүз ул. Ике ел эчендә бер тиен акчасыз кеше миллиардер була алмый.
Ким. Кара син, ә! Ниләр беләсең. Кайда инде ул минем миллиардлар?
Вил. Син талаучының бәләкәе.
Ким. Алай икән! Кара син, ә!.. Бәлки, син хаклыдырсың да...
Вил. Мин беркайчан да ялган сөйләмим.
Ким. Ленин да дөресен генә сөйләгәнме?
Вил. Әйе! Ул сезнең кебекләрне үтәли күргән.
Ким. Алайса, болай, энекәш...
Вил. Мин каракка энекәш түгел.
Ким. Ярый, ярый, энекәш булма. Ләкин тыңла, колагыңа киртләп куй. Әйе, мин талыймдыр. Ләкин, син әйткәнчә, халыкны түгел. Мал бүлешү бара Россиядә. Ленин бабай төзегән җәмгыятьтә халыкны талап җыелган миллионны бүлешү бара. Беләсеңме шуны? Кем малыдыр, анысын шайтан белә. Синнән башка бөтенесе талый. Нәрсә, мин шул чакта карап торыйммы? Таланып беткән Россиядә кемнәрнеңдер хезмәтчесе булып калыйммы? Син миннән кол ясарга җыенасыңмы? Юк, брат, мин дивана түгел, мин үз өлешемне алып калырга телим. Ә инде минем өй, машиналарымны әйтсәң, авыл халкының өлеше юк анда. Миңа кадәр талап бетергәннәр иде инде аны. Мин авыл бетмәсен өчен генә алындым ул эшкә. Мал бүлешкәндә, бөтенесе дә намуслы була алмый. Бүлешеп бетерик, аннары намус турында сөйләрбез. Сиңа ияреп Ленинны укырбыз.
Вил. Укырга өлгермәячәксез. Без сезне фаш итәчәкбез!..
Ким. Кем ул сез?
Вил. Минем кебек уйлаучылар.
Ким (*Вилнең иңбашына кулын куеп*). Әй энекәш, энекәш!..
Вил. Алыгыз кулыгызны!
Ким. Эх син, бездельник! Дөрес кайтарганнар сине авылга. Син, әбиеңнең әбәнәге, башыңны җүләргә салып, абыеңның тишек кесәсендә актарынасың. Әгәр дә син Ленин булсаң, патшалар, олигархлар белән көрәш. Ленин бабаң шулар белән алышкан, мужикка акыл сатып маташмаган.
Вил. Мин синең белән сөйләшергә теләмим.
Ким. Мин дә теләмим. Син монда теләсә нәрсә лыгырдап йөрсәң, муеныңнан борып ыргытырмын. Монда мин эшләгәнне ашап, теләсә нәрсә лыгырдап йөрмә.
Вил. Нишләтерсең?
Ким. Кайтаручылар алып та китәрләр. Кара син аны! Бездельник! Симулянт! Укыйсы килмичә монда кайткан да...

Вил. Мин кайтмадым, кайтмадым, кайтмадым.
Хәнифә (*борылып килеп*). Ким, нигә син аңа тиясең?
Ким. Син гел шул бездельникны яклыйсың.
Хәнифә. Беләсең бит инде аны. Нигә аңа бәйләнәсең?
Ким. Мин аңа бәйләнмим. Ул минем турыда теләсә ни кычкырып йөри.
Вил. Син – карак. Сез – караклар.
Ким. Тукта, диләр сиңа!
Вил. Син – карак, син – жулик!..
Ким (*Вилнең изүеннән алып*). Туктыйсыңмы, юкмы?
Хәнифә (*Кимның кулын ычкындырып*). Нишләвең бу?! Бар, кит!
Вил (*калтыранып елый*). Син – карак, син – жулик!
Хәнифә (*Вилне кочагына алып*). Улым, улым!

Вил бәргәләнә башлый.

Ким. Симулянт ул! Мин аны тикшертергә алып барам.
Хәнифә (*бәргәләнгән Вилне тынычландырырга тырышып*). Улым, улым!

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Түп өстендә Ким утыра. Куыш эченнән Хәнифә чыга.

Ким. Йә, нәрсә анда?
Хәнифә. Нәрсә булсын, бөгәрләнеп ята. Харап иттең баланы. Инде рәтләнә дип кенә торганда.
Ким. Ачуны китерә бит.
Хәнифә. Минем ачуым килгән саен, бөтенегезне дә изүеннән тотып селкесәм... Хәлен белеп торасың.
Ким. Чирләми ул.
Хәнифә. Белмиләр, ди, докторлар.
Ким. Докторлар?! Врачлар алар авыруның сәбәбен эзлиләр. Моның сәбәбен белмиләр. Чөнки моның авыруының сәбәпчесе син. Күпме әйтә килдем, үчти-үчти итеп алдыңда утыртма, дидем. Авыру түгел ул, тормышка яраксыз имгәк!
Хәнифә. Ни сөйлисең? Нишләп яраксыз булсын? Мәктәпне алтын медаль белән бетерде, университетында бишлегә генә укыды.
Ким. Унлыга укыса да юк. Кемгә кирәк аның укуы. Укуыннан ни мәгънә. Һәр укуның да нәтиҗәсе булырга тиеш. Ничә ел каникулга кайтып, көрәк тә тотып караганы юк бит. Һаман китап. Аңа бит инде егерме яшь.
Хәнифә. Бөтен кешегә дә тирестә казынырга димәгән. Син дә күтәреп ташымыйсың.
Ким. Ул бит бәрәңге пешереп тә ашый алмый.
Хәнифә. Син пешереп ашаттың мәллә?..
Ким. Син пешереп ашаттың. Бөтен пенсияң аңа китеп барды. Миннән күпме...
Хәнифә. Кызганасыңмыни?
Ким. Кызганмыйм, аның каравы ул нишли? Минем акчаны рәхмәт тә әйтми ашый. Мине «карак» ди. Аның Ленины да шул булган – байлар акчасына чит илләрдә типтергән, аннары байларны себереп түккән. Ярый ла аны ашатучылар, тәхеткә утыртучылар булган. Бертуган абыйсын хурлаучы, теләсә ни сөйләп йөрүче дивана татарны кем ашатыр?
Хәнифә. Күпне беләсең. Акчаң кызганыч булса, бирмә.
Ким. Син нәрсә инде, энкәй!..
Хәнифә. Тимә син аңа, үзеңчә яшә, аңа тимә.
Ким. Телен тыйсын! Эшкә яраксыз имгәкләрнең генә теле озын була.
Хәнифә. Нишлим соң инде сезнең белән?!
Ким. Илтеп салырга кирәк больницага. Авыру икән, дәваларлар. Юк икән... Син аны монда яшереп ятасың.
Хәнифә. Сине кемнән яшереп ятам соң?
Ким. Ә мин нишләгән? Алып барып, больницага салып кайтам мин аны.
Хәнифә. Салып кына кара! Бигрәк остардың.

Ким. Җир җылынып та бетмәгән. Әнә хәзер салкын җирдә ята ул. Салкын тигәч тә мине гаепләрсез. Куышлар корып уен уйнап ятасыз.

Куыш эченнән Вил тавышы ишетелә.

Хәнифә. Хәзер, улым, хәзер! (*Куышка кереп китә.*)

Нургазиз белән Зәйнәпбану керәләр.

Нургазиз. Нindидер тавыш ишетелдеме? Вил тавышы да кебек.
Ким. Сез нигә өегездә генә утырмыйсыз, ә? Чабасыз да кереп җитәсез.
Нургазиз. Тавыш ишетелгәндәй булды. Күршеләр бит.
Ким. Зәйнәпбану апа, әйт бу картка, өендә генә утырсын.
Зәйнәпбану. Картаерсың да утырырсың. Күршеләр хәл белешеп тора инде. Хәнифә кайда соң әле? Тавышы ишетелгәндәй булды.

Ким, урыныннан торып, чыгып китә.

Бу берәр нәрсә ниткәндер әле. Бөтен кешене өйрәтергә оста. (*Куыштан чыккан Хәнифәгә.*) Монда икәнсең әле. Бер тавыш ишетелгәндәй булды да...
Хәнифә. Юк, болай гына.
Нургазиз. Бу Кимны әйтәм әле, бер дә күрше итми.
Хәнифә. Аның да башы әйләнәдер инде. Вил кәефсезләнеп китте.
Зәйнәпбану. Өйгә кертеп яткырырга кирәк. Салкынча бит.
Хәнифә. Керми, нишләтим. Утырып торыгыз әле, юрган-матраслар алып чыгыйм. (*Китә.*)
Зәйнәпбану (*Нургазизгә*). Бар, булыш, нәрсә торасың. (*Нургазиз киткәч, төпкә утырып дога кыла.*) И Ходаем, бәндәләреңне кодрәтеңнән калдырма! Акыл-зиһеннәрен тулы ит! Имансызларга иман иңдер!
Вил (*куыштан чыгып*). Әнкәй!..
Зәйнәпбану. Юк, әнкәң түгел әле бу, кем, Вил улым!
Вил. Әнкәй кайда?
Зәйнәпбану. Хәзер килә, килә.
Вил. Нургазиз бабай кайда?
Зәйнәпбану. Ул да килә, хәзер килә.
Вил. Минем башым авырта, әби.
Зәйнәпбану. Үтәр, балакаем, үтәр. Яле, карыйк әле. (*Вилнең маңгаена кулын куеп карый.*) Юк, болай кайнар түгел, үтәр, Алла боерса.
Вил. Күрше әби, син Аллага ышанасыңмы?
Зәйнәпбану. Ышанмыйча ярамый, балакаем. Коммунист чакта ышанмаска кушалар иде, хәзер, рөхсәт булгач, ничек инде ышанмыйсың.
Вил. Ленин ышанмаган.
Зәйнәпбану. Ышанмаган кешене нишләтәсең. Һәркайсының үзенә җавап тотасы.
Вил. Бәлки, ул ялгышкандыр.
Зәйнәпбану. Ялгышуы да ихтимал. Ул да адәм баласы бит.

Нургазиз белән Хәнифә керәләр.

Хәнифә (*ашыгыбрак атлап*). Улым торган! Кара, Нургазиз бабасы, ничек итеп күрше әбисе белән чөкердәшәләр!
Вил. Әнкәй, минем башым авырта.
Хәнифә. Хәзер, улым, хәзер! (*Әйберләрен куышка кертеп чыга.*) Хәзер, улым!
Нургазиз. Ярый, без чыгыйк, Хәнифә!

Кулы белән ишарәләп, Зәйнәпбануга иярергә куша. Китәләр.

Вил. Әнкәй, минем башым авырта.
Хәнифә (*төпкә утырып*). Кил, улым, башыңны куй.

Вил, җиргә чүгәләп, башын әнисенең алдына куя. Хәнифә аның башын сыйпый.

Хәзер үтә ул, улым, үтә. Менә шулай. Өйгә керәсең мәллә, улым?
Вил. Өйдә йолдызлар юк. Әнкәй, әкият сөйлә?! Йолдызлар турында...
Хәнифә. Йолдызлар турында... Йолдызлар турында... (*Уйланып тора.*) Тыңла инде алайса.

Галәм дигән дөньяның нәкъ уртасында –
Күптән-күп, бик күп йолдызлар арасында
Яшәгән, ди, матур гына гүзәл бер йолдыз.
Янында йолдызлар булса да, булган ул ялгыз.
Бүтән йолдызлар аны күрмиләр икән,
Аның йолдыз икәнен дә белмиләр икән.
Яктырак та янып караган ул йолдыз,
Барыбер үзен күрсәтә алмаган йолдыз.
Күңеле йолдызның сүрелә башлаган,
Һәм ялгыз йолдыз сүнә башлаган.
Миллион елдан соң миллионнар үткән,
Һәм ялгыз йолдыз сүнеп тә беткән.
Шул чакта гына аны күргәннәр –
Янына йолдызлар җыелып килгәннәр.
Гафу үтенеп сәлам биргәннәр.
Кайгы-хәсрәткә батма, дигәннәр.
Бу хакта Айга хәбәр иткәннәр,
Кояшның үзенә барып җиткәннәр.
Алар гозерен Кояш тыңлаган,
Сүнгән йолдызның хәлен аңлаган.
Мин аны көн дә күрермен, дигән,
Яктылыгымны бирермен, дигән.
Ай исә, төнен килермен, дигән,
Йолдыз тирәли йөрермен, дигән.
Башка йолдызлар елмаешканнар,
Сүнгән йолдызга ныграк елышканнар.
Сүнгән йолдызга исем биргәннәр,
Җир исемле син булырсың, дигәннәр.
Сиңа күңелсез булмасын өчен,
Күңелсезлектән күңелең тулмасын өчен,
Сиңа бөек затлар бирәбез, дигәннәр.
Шуннан бу җиргә кешеләр иңгәннәр.

Вил. Син үзең уйлап чыгардыңмы, әнкәй?

Хәнифә. «Йолдызлар турында кирәк» дидең, улым!

Вил. Син философ, әнкәй! Димәк, кеше күктән иңдерелгән? Димәк, кешене йолдызлар җиргә бүләк иткән. Димәк, кайсыдыр йолдызда кешеләр яши? Димәк, кайдадыр тагын бер сүнгән йолдыз бар.

Хәнифә. Бик күп сораулар бирмә инде син. Мин әкият кенә сөйләдем.

Вил. Син әкият кенә сөйләмәдең, әнкәй! Син галәм һәм тереклек турында лекция сөйләдең. Син Аллага ышанасыңмы, әнкәй?

Хәнифә. Андый сораулар бирмә инде миңа, улым!

Вил. Ышанасың. Беләм, ышанасың. Алла ул – чиста күңелләләр уйлап чыгарган Гали зат. Кешеләр аны уйлап чыгарган, ләкин ул ни өчендер кешеләргә карата бигүк мәрхәмәтле түгел. Бәхетсезләр күп дөньяда, әнкәй! Уйлап чыгарганнары өчен рәхмәт йөзеннән Алла кешеләргә коммунизм бүләк итсен иде.

Хәнифә. Оҗмах бар бит инде, улым!

Вил. Аның өчен башта үләргә кирәк бит әле.

Хәнифә. Андый сүзләр сөйләшмик инде, улым. Башың басылдымы?

Вил. Рәхмәт, әнкәй! Синең кулың кагылса, башым авыртудан туктый. (*Кинәт тыңлап.*) Әнкәй, ишетәсеңме, ул җырлый. Әнкәй, бу әллә мәхәббәт микән? Мин бит аның ни икәнен белмим. Аны серле, бөек хис, диләр. Ике җенеснең бер-берсенә тартылуында нинди серлелек булсын, нинди бөеклек булсын. Бу бит гап-гади инстинкт. Кешенең яшәве – материалистик төшенчә. Безнең курста бер кыз миңа мәхәббәт турында сөйли, мин аны аңламыйм.

Хәнифә. Димәк, яратмыйсың.

Вил. Ә нигә мин аны яратырга тиеш? Мин аны хөрмәт итәм. Кешеләрне хөрмәт итәргә кирәк.

Хәнифә. Исеме ничек соң ул кызның?

Вил. Исеме?.. Диана шикелле. Әйе, Мингалиева Диана... (*Тыңлый.*) Җырлый! Ә нигә ул туктаусыз җырлый?

Хәнифә. Син ишетсен дип җырлыйдыр.

Вил. Ә ул матур җырлый. Ә ул тагын безгә киләме?

Хәнифә. Син аны үзең эзләп бар, улым!
Вил. Нигә?
Хәнифә. Җырлавын яратасың ич.
Вил. Әйе. Ул монда килә. (*Рәшәткә янына бара.*)

Айсылу керә.

Айсылу. Исәннәрдәме сез! Хәерле кичләр булсын!
Вил. Мин синең җырыңны тыңладым.
Айсылу. Тыңламаска, авылда миннән башка кем җырласын. (*Куыш янындагы Хәнифәгә.*) Исәнмесез, Хәнифә апа!
Хәнифә. Исәнме, Айсылу! Кайларга киттең?
Айсылу. Гүләйткә чыктым. Алып китимме Вилне? Тукта, башта сезгә кереп утырыйм әле. Сездә монда матур. Алмагачлар, куыш. (*Бакчага кереп, Хәнифә янына килә.*) Хәнифә апа, син Ким абыйга әйт әле, бәйләнмәсен миңа. Ату хатынына барып әйтәм. Шалтай-балтай дигәч тә, мин пыраститутка түгел. Пыраститутка кирәк булса, шәһәргә барсын.
Хәнифә. Шаяра гынадыр ул.
Айсылу. Беләм мин аның шаяруын. Хатыны белән шаярсын... Күңелле монда, әйеме. Сезгә килен булып төшсәм, монда зуррак куыш ясарбыз. Җәй көне нишләп өйдә йокларга, әйеме. Хитрый ул Вил, белә кайда әйбәтен. Минем белән барасыңмы, Вил?
Вил. Кая?
Айсылу. Кая, дип... Йөрербез шунда туда-суда. Күрсен әле теге заразы, кылый тәре. Барыбер миңа буласың, дигән була.
Хәнифә. Алайса, мин керим инде, Айсылу!
Айсылу. Курыкма, Хәнифә апа, каян алган, шунда китереп куям Вилне.

Хәнифә китә.

Утыр, Вил! Нигә атлы казак кебек басып торасың? Син бераз гына мине сагынасыңмы соң?
Вил. Мин синең җырлаганыңны көтәм.
Айсылу. Җырламасам, кирәгем юкмы? Син миңа шундый итеп карап торасың. Эт күргән бозау шикелле. Курыкма, тимим мин сиңа.
Вил. Мин курыкмыйм синнән.
Айсылу. Синең йөргән кызың бармы ул Казанда?
Вил. Ничек йөргән?
Айсылу. Йөргән кызның ни икәнен белмисең мәллә?
Вил. Белмим.
Айсылу. Шушы яшькә җитепме? Шушы кыяфәт беләнме?
Вил. Ә нигә кирәк ул?
Айсылу. Бәтәч, чынлап әйтәсеңме? Әллә кызлар кочаклап караганың да юкмы? Кочаклашуның ни икәнен дә белмисеңме?
Вил. Нигә белмәскә. Ләкин кочаклашу өчен сәбәп кирәк. Ә минем сәбәбе булганы юк. Минем кочаклашып йөрергә вакытым юк. Вакытым кызганыч. Аннан, кочаклагач, өйләнергә кирәк.
Айсылу. Менә сиңа мә, кодагый, чиле-пешле йомырка. Абыең кымтырыкларга гына тора.
Вил. Ул – бозык! Алар барысы да бозыклар!
Айсылу. Бозыгын бозыктыр да. Бозылмыйча да кочаклашырга була ич. Менә мин бозык түгел, кочаклашасым килә. Их, дип уйлыйм, күңелемә ошаган бер егет кысып кочакласын иде, дим. Карап торма миңа алай, кытыгымны китерәсең. Ә син көлә беләсеңме?
Вил. Ә нидән көләргә?
Айсылу. Нидән, дип... Кызык табасың да көләсең инде ул. Яле, елмай әле!
Вил. Ни өчен?
Айсылу. Болай гына...
Вил. Болай гына елмаймыйлар. Елмаер өчен сәбәп кирәк.
Айсылу. Нинди сәбәп? Менә миңа кара да, бу нинди тиле кыз икән дип уйла. Уйла да елмай.
Вил. Син тиле түгел. (*Елмая.*)
Айсылу. Ай-яй-яй! Кара, син нинди чибәр икән.
Вил. Ирләр чибәр булмый, хатын-кызлар гына чибәр була.
Айсылу. Яле, тагын бер елмай әле. (*Вил елмайгач.*) Үләм!.. (*Кочаклап ала.*) Синең урында мин булсам, кызларны акылдан шаштырыр идем. Кочакла әле син дә. Мин синең муеныңнан кочаклыйм, син минем билемнән.

Кочаклашалар.

Кара, кулларың көчле синең. Укыган кешенең беләге көпшәк була.

Вил. Мин көн саен зарядка ясыйм. Гантельләр бар минем.

Айсылу. Әйдә, үбешәбез!

Вил. Ничек?

Айсылу. Кил әле монда, бас әле шушы алмагач янына. Мин моннан үтеп барам, ди, әйеме. Мин сине күрмим, ди. Син күреп аласың да мине: «Айсылу, кая барасың?» – дип сорыйсың. Мин әйтәм: «Суга барам», – дим. Син әйтәсең: «Мин сине көтеп торам, мин сине бик сагындым», – дип әйтәсең дә мине кочагыңа аласың. Аласың да мине үбәсең.

Вил. Ә нигә алай эшләргә?

Айсылу. Әй, сиңа аңлатып торганчы! Кил, болай гына үбешәбез! (*Вилне кочаклап үбә.*)

Вил. Син шундый чибәр!

Айсылу. Чибәр булмыйча, әллә ямьсез кызларны үбәр идеңме? Әй, теге кылый заразы карап торсыные. Вил, без хәзер синең белән клубка чыгабыз, ярыймы. Әгәр дә анда Керпе Садыйк малае кылый Илбрус булса, миңа таба килә башласа, каршына чык та «уди отсюда» диген. Китмәсә, колак төбенә берне яма.

Вил. Сугышырга ярамый.

Айсылу. Син сугышма, яма гына.

Вил. Кешегә сугарга ярамый. Кешегә сугу ул – шәхесне кимсетү. Бер кеше икенче кешене кимсетергә тиеш түгел. Кешеләр тигез булырга тиеш.

Айсылу. Әгәр дә мине кимсетсәләр, карап торырсыңмы?

Вил. Әгәр дә сине кимсетсәләр, карап тормам. Чөнки сине кимсеткән кешенең кеше дип аталырга хакы юк.

Айсылу. И шушының матур итеп сөйләве! Син мине кулларыңа күтәр әле, Вил!

Вил. Нигә?

Айсылу. Син мине күтәр, ә мин сиңа җырлыйм.

Вил. Яхшы!

Айсылу Вилнең сузган кулларына очып кунып утыра.

Җырла!

Айсылу. Җырлыйм, җырламыйммы соң!

Алларың булырмын әле,
Гөлләрең булмасам да;
Ярларың булырмын әле,
Гомергә булмасам да.

Син мине, Вил, алмагачлар арасында күтәреп йөрт.

Алым җәл түгел сиңа ла,
Гөлем җәл түгел сиңа.
Алым түгел, гөлем түгел,
Җаным җәл түгел сиңа.

Әйдә, Вил, киттек клубка! Хәзер төшер инде, болай гына барабыз. Мине подручкым ал.

Вилне култыклап алып, җырлый-җырлый бакчадан чыгып китәләр.

Ал биргәннәргә ал бирәм,
Гөл биреп тормыйм әле,
Гөрбияннарга – гөрбиян,
Сер биреп тормыйм әле.

Хәнифә, чыгып, алар артыннан карап кала. Ут сүнә.

ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Хәнифә (*куыш янында җыештырып йөри. Көйли*).

Алым җәл түгел сиңа,
Гөлем җәл түгел сиңа...

Нургазиз белән Зәйнәпбану керәләр.

Нургазиз. Нихәлләрдә, Хәнифә! Бу куышның кирәге калмадымыни инде?

Хәнифә. Аллага шөкер, ничәнче көн инде өйдә йоклый.

Нургазиз (*бер томны алып*). Боларның да кирәге калмадымы әллә?

Хәнифә. Бу арада кулына алмый.

Нургазиз. Хатын-кыз кулына эләксәң, атаң-анаңны онытырсың. Бик әтчәйни кыз.

Зәйнәпбану. Харап итеп ташламаса ярый инде.

Нургазиз. Кем?

Зәйнәпбану. Шул ирдавайны әйтәм. Үзенә өйләндереп куяр да.

Нургазиз. Куйса ни, Вилгә аңа шундый хатын кирәк.

Хәнифә. Аны-моны уйлаган юк әле. Сәламәтләнсен иде инде. Алланың биргәненә шөкер, күзгә күренеп үзгәрә.

Нургазиз. Хатын-кыз кулына эләксәң... Колхозның айгыры бар иде. Шуны бер ир-ат та тыя алмый иде. Мал докторы Нурҗамал шуның муеныннан бер генә сыйпый, тегесе куян булып кала иде.

Вил керә.

Вил. Әнкәй, минем гантельләр кайда икән? Исәнмесез, Нургазиз бабай, исәнмесез, күрше әби! (*Кире чыгып китә.*)

Аңа Хәнифә иярә.

Хәнифә. Гаеп итмәгез инде, Нургазиз абый, юындырып, чәй эчертим.

Нургазиз. Төс керә башлады егеткә.

Зәйнәпбану. Элек тә шул иде инде, базда үскән бәрәңге кебек. Көне-төне өйдә китап укып ятып соң...

Нургазиз. Тартып алды әле теге кызый. Сөйләшеп утыруы дөнья рәхәте Вил белән. Авылда сөйләшеп утырырлык кешесе калмады. Әллә нишләде халык.

Зәйнәпбану. Әйдә, әкиятеңне миңа сөйлә. (*Чыгып китә.*)

Рәшәткә янына Диана белән Ким киләләр.

Ким. Менә аның резиденциясе. Танышмы? Ленин шалашы. Әйдә, узыгыз! (*Куыш янына килә.*) Сез бер курста, димәк.

Диана. Да.

Ким. Татар кызымы?

Диана. Да.

Ким. Татарча белмисеңме?

Диана. Беләм. Бик аз. Ну аңлыйм.

Ким. Хәзер сөйләшер өчен күп сүз кирәкми. Компьютер заманы.

Диана. Наверное. А Виль где? Кайда?

Ким. Хәзер өйгә кучте яшәргә. По-моему, приходит в себя.

Диана. Сез татарча... Мин аңлыйм.

Ким. Сез аның белән?..

Диана. Нет, просто сокурсники.

Ким. Бүтәннәр килмәгән, сез килгәнсез.

Диана. Как вам сказать... Он какой-то не такой. Не как все. Мне кажется, врачи ошиблись. Уйлый ул как-то по-своему. Мало общается. Со стороны странно выглядит. Но он чистый. Чистый душой.

Ким. Чистый булу гына аз шул.

Диана. Сегодня это главное качество.

Ким. Тормыш катлаулы.

Диана. Да, катлаулы. Духовная чистота – понятие вечное. Для вечности вчера, сегодня, завтра не существуют.

Ким (*көлеп*). Сез бер-берегезгә охшагансыз.

Диана. Не очень. Он какой-то отвлеченный. Я – нет. У меня ум практический. Я очень уважаю вашего брата Виля! Надо же, в такой глухой деревне... Вы меня извините, я еле отыскала.

Ким. Машинагыз безнең юлларда йөри торган түгел.

Диана. Да. Но ничего, нашла. Где же он?

Ким. Өйдәдер. Ул өйдә ятарга ярата.

Диана. Мин аны телим күрергә.

Ким. Татарчагыз матур, Вилне күргәнче, сезгә бер сорау бирергә ярыймы?

Диана. Почему же...

Ким. Менә сез минем энекәшне бик югары күтәрдегез. Ләкин аңардан дөньяга ни файда?

Диана. Аңламыйм, какой файда?

Ким. Ул укый да укый... Аның ул кадәр белүе кемгә кирәк? Ул тормышка җайлаша алмый. Не приспособлен. Ул бит ир кеше. Аның өйләнәсе, гаилә асрыйсы бар. Кемгә кирәк ул? Кому он нужен? Менә сез аңа кияүгә чыгар идегезме?

Диана. Почему бы нет!
Ким. Хәер, сез барыгыз да бертөсле. Сез күбрәк рассуждать итәргә яратасыз. Высшая материя. Ә яшәргә кирәк. Ниндидер черек буын килә дөньяга.
Диана. А что такое «черек»?
Ким. Ничек дип әйтим... Ну, аморфное поколение. Әтиләр хисабына укып, акыл сатып...
Диана. Зря вы так думаете.
Ким. Нинди машинага утырып килгәнсез. Үзегез эшләп алдыгызмы?
Диана. А кто же?
Ким. Һәрхәлдә, үзегез түгел.
Диана. Ошибаетесь. Я работала в Америке.
Ким. Сезме?
Диана. А кто же!
Ким. Ничего себе!
Диана. Вернулась. Узнала, что Вилик заболел. Вот и килдем. Ну пойдем к нему!
Ким. Туктагыз! (*Өй ягына барып.*) Әнкәй!

Ишектән Хәнифә чыга.

Вил янына килгән. Курсташы, ди. Керсенме өйгә?
Хәнифә. Туктале, өй дә җыештырылмаган, ни... (*Диана янына килә.*) Исәнмесез!
Диана. Исәнмесез!
Ким. Ул безнең әнкәй!
Диана. Еще раз исәнмесез!
Хәнифә. Әйдә өйгә, дисәм... Вилнең үзен генә чыгарыйммы?
Диана. Да, пожалуйста!
Хәнифә. Хәзер, хәзер. Әйдә, Ким! Минем янда гына утыр.
Ким. Мин китәм. Эшем муеннан. Ну, сау булыгыз, Диана, до свидания!
Диана. Сау булыгыз! Рәхмәт сезгә! (*Ким киткәч, куыш эчен карый, бакчада йөренә.*)

Вил күренгәч, аны кочаклап алырга барган сыман атлыга да, янына
җиткәч, туктап кала.

Вилик, дорогой!
Вил. Исәнмесез, Диана!
Диана. Нашла же я тебя. Таптым. Ну как ты?
Вил. Яхшы.
Диана. Вилик, я не о чем не буду спрашивать. Я же в Америке была почти целый год. Приехала, узнала. Ты такой же милый. Ну вот, встретились и не о чем говорить. Я всегда думала о тебе. Хотела писать. Ну ты же...
Вил. Америкада ничек?
Диана. Так – живут. Работала. Эшләдем. Официанткой. За то я английский выучила. Ну и как авылда?
Вил. Яхшы.
Диана. Ты ничуть не изменился.
Вил. Изменился.
Диана. Ты че такой грустный?
Вил. Мин һәрвакыт шундый.
Диана. Да. Я соскучилась по тебе. Сагындым. Ә син уйладыңмы мине?
Вил. Юктыр...
Диана. Да, конечно, конечно... Все-таки я тебя нашла.
Вил. Рәхмәт.

Сөйләшер сүзләре бетеп, карашып торалар.

Диана. Скажи что-нибудь, Вилик!
Вил. Рәхмәт килүеңә.
Хәнифә (*өйдән чыгып*). Вил улым, алып кер өйгә кунакны.
Диана. Нет, нет, спасибо! Рәхмәт! Мин китәм.
Хәнифә. Ничек инде китәм, чәй эчмичәме?
Диана. Я спешу. Ашыгам. Сау булыгыз! Вилик, проводи до машины. Да-а-а... Ты такой же... Я то думала.

Капкага юнәлә. Аны Вил озата бара. Алар югалгач, Айсылу күренә.
Хәнифәне күреп, аның янына атылып килә.

Айсылу. Хәнифә апа, кем ул?
Хәнифә. Бергә укыйлар, ди.
Айсылу. Ник килгән?
Хәнифә. Хәл белергәдер. Бергә укыгач.
Айсылу. Нигә бүтәннәр килмәгән, ул килгән?
Хәнифә. Мин каян белим инде? Шушында сөйләшеп тордылар да, китте.
Айсылу. Нәрсә сөйләштеләр?
Хәнифә. Тыңлап тормадым.
Айсылу. Озак сөйләштеләрме?
Хәнифә. Юк ла инде.
Айсылу. Алырга килгәндер әле.
Хәнифә. Нишләп алырга килсен? «Праводи да машина» диде дә киттеләр.
Айсылу. Марҗамыни?
Хәнифә. Юктыр. Сау булыгыз, диде.
Айсылу. Килеп җиткәннәр. Мин терелткәч кенә, хуҗа табылган.
Хәнифә. Син ачуланма инде Вилне. Авыраймасын...
Айсылу. Әйтмим. Нишләп әйтим. Әйтмим дә, бүтәннәргә бирмим дә. Килгән... Йөргән була фуфыраеп. Акылдан шаштырып, авылга куып җибәрәләр дә йөриләр. Шалашка кердеме?
Хәнифә. Күрмәдем.
Айсылу. Кереп кенә карасын безнең шалашка, ботын сугып сындырырмын. «Праводи машина» дигәч, машина белән килгәнмени?
Хәнифә. Шулайдыр, күрәсең.
Айсылу. Күрдеңме рәшәткә буендагы кычытканнарны, Хәнифә апа! Тәки өйрәттем бит чабарга. Көче күп аның, ялкау гына.
Хәнифә. Ялкау түгел ул, Айсылу! Син белгән эшне белми генә.
Айсылу. Ничава! Өйрәтәм әле мин аны «Әпипә»гә биергә. (*Көлә.*) Мин сине дә бик яратам бит, Хәнифә апа! Син кеше белән сөйләшә беләсең. Вил сиңа охшаган. Ким абый дурак. Кичә әйтә, йә, ничек, минем энекәш белән, ди. Син түгел инде, мең тапкыр әйбәт, дидем. Мине шалтай-балтайга саный. Йә, ничек, дигәнен аңламый дип белә. Вил ул кызлардан да оялчан, үрелми теләсә кая. Теге кыз миннән чибәр түгел, әйеме, Хәнифә апа?
Хәнифә. Кая инде сиңа җитәргә?
Айсылу. Юри генә әйтәсеңдер әле.
Хәнифә. Нишләп юри булсын, алма кисәгем. Кил әле, сөйим әле үзеңне. (*Айсылуны кочагына алып сөя.*)
Айсылу. Син моны Вил өчен инде, әйеме, Хәнифә апа? Бер дә борчылма, бик әйбәт ул. Күп укыган булса да, әллә ниләр белсә дә, бала кебек. Уйнарга рәхәт. Йомшак куян баласы кебек.
Хәнифә. Син аның белән уйнар өчен йөрмә инде.
Айсылу. Син нәрсә, Хәнифә апа, яратам да ич мин аны.

Вил килгәнне күреп, каршысына йөгерә, кочагына ташлана.
Ут сүнә.

## БИШЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Куыш янында Хәнифә, Ким, Вил утыралар.

Ким. Бәлки, берәр елга академик ял алырсың.
Вил. Юк, нигә кирәк ул? Мин сәламәт.
Хәнифә. Сәламәтен сәламәт тә...
Вил. Әнкәй, сөйләштек ич инде.
Хәнифә. Икегез дә киреләр, үзсүзлеләр. Әтиегезгә охшаган. Бүтәннәр киңәшенә дә колак салгаларга кирәк. (*Кимга.*) Үзең илтеп куясыңдыр ич.
Вил. Кирәкми. Олы юлдан автобус йөри. Ленин томнарын таратма, әнкәй!
Хәнифә. Нишләп таратыйм аларны?
Вил. Әнә абый бит бәйләнә, алып китмәсен.
Ким. Саташма шулар белән, энекәш! Үтте инде аларның вакыты.
Вил. Китапның вакыты үтми. Кешеләр яши белмәгәнгә, китап гаепле түгел.
Хәнифә. Бу Айсылу белән нишләрсең икән, бигрәк ияләште.
Вил. Анысы безнең проблема. Әллә кая китмим бит.

Ким. Сезнеке генә түгел. Син укыйсың да укыйсың. Ә ул шыр надан. Тиңнәр түгел сез. Хәзер кызыктыр да, бара-тора...
Вил. Айсылуга тимәгез.
Ким. Мәсьәлә тиюдә түгел.
Хәнифә. Ярый, үзләре белерләр, сабый балалар түгел.
Ким. Мин киттем алайса... (*Вилгә.*) Киреләнмә, илтеп куям Казанга.
Вил. Кирәкми, дидем.
Ким. Ярый, иртәгә карарбыз. (*Китә.*)
Хәнифә. Айсылу беләме китәсеңне?
Вил. Юк әле.
Хәнифә. Нишләр икән инде? Бигрәк ияләште шул, бигрәк ияләште.
Вил. Айсылуга мин бурычлы, әнкәй!

Нургазиз белән Зәйнәпбану күренәләр.

Нургазиз. Монда утыралар икән. (*Вил кулындагы гәҗиткә күрсәтеп.*) Монда бернәрсә килеп чыкты бит әле. Шул теге инде, «мунсипал». Нәрсә дигән сүз соң ул?
Вил. Мунсипал түгел, муниципаль. Латин сүзе. Үзидарә җәмгыяте дигәнне аңлата.
Нургазиз. Ничек була инде? Авыл советы да хәзер үзидарә. Район да үзидарә. Авыл советы үзидарәнең үзидарәсе буламы?
Вил. Муниципаль районның җирле үзидарәсе була.
Нургазиз. Әй болгаталар да инде! Таңнан уянасың, үзгәрткән булалар.
Вил. Фокусниклар.
Зәйнәпбану. Алай ук димә, газ керде бит. Дөнья рәхәте.
Нургазиз. Һе, мунисипал... Сүзен каян табалар.
Зәйнәпбану. Синең белән мин аңламасын өчен ул. Бәрәңгене дә бит әйтәсең «бәрәңге» дип, бернәрсәсе дә юк. «Картуфел» дисәң, икенче нәрсә дип уйлыйсың. Сине Нургазиз дисәң, Нургазиз генә, ә менә мунситипал икенче төрле, үсеп киткәндәй күренәсең.
Нургазиз. Зәйнәпбану булып ул да әйтә алмый, син, Хәнифә, әйтә аласыңмы?
Хәнифә. Муниципаль.
Нургазиз. Син придсидател хатыны шул, Вилнең әнисе.
Вил. Мине һаман да Вәли дип йөртә күрше әби.
Зәйнәпбану. Мин аны әйтә белмәгәннән түгел, Вәли улым, әйтергә теләмәгәннән.
Нургазиз. Ярый, без тагын чыгып укыйк әле, аңлашылмаган җире чыкса, йөгереп кереп җитәрбез.

Айсылуның җыры ишетелә.

Хәнифә. Берәр җиргә барырга сөйләшкән идегезме?
Вил. Юк әлегә.
Хәнифә. Йөртте инде ул сине. Менмәгән тавыгыз, кермәгән урманыгыз калмады бугай. Син аның язмышы турында уйла инде, улым!
Вил. Мин уйлыйм, әнкәй! Гаҗәеп бай күңелле ул. Ул – табигать баласы.

Айсылу күренә. Үз бакчасына кергәндәй, бакчага керә.

Айсылу. Исәнмесез, Хәнифә апа!
Хәнифә. Исәнме, Айсылу кызым!
Айсылу. «Кызым» ук димә әле, килинең булмаган. Килинең булгач, миңа «кызым» диярсең, мин «әни» диярмен. (*Вилгә кулын сузып.*) Привет!
Вил. Сәлам!
Айсылу. Бүген кая барабыз?
Хәнифә. Төнгә каршы кая барасыз инде?
Айсылу. Көндез эш бар, Хәнифә әни! (*Кычкырып көлә.*) Бүген урмандагы Каракүлнең төбен карыйбыз. Мин кесә фонаре алдым. Шуны яктыртып, төбен карыйбыз. Төпсез, диләр, дөрес түгелдер ул.
Вил. Без бүген беркая да бармыйбыз. Бакчабызда гына булабыз.
Айсылу. Нигә, Вил?
Вил. Шулай кирәк.
Хәнифә. Йә, алайса, мин керим. Сау бул, Айсылу!
Айсылу. Сау бул, Хәнифә апа!.. Вил, шулай кирәк, дип әллә ничек итеп әйттең. Нигә шулай кирәк?
Вил. Беләсеңме, Айсылу!.. Бүтән җирдә мин сиңа ияреп йөрим. Монда... Аннан соң монда мин беренче тапкыр синең җырыңны ишеттем. Өченчедән... Хәтерлисеңме, син миңа бер уен өйрәтергә

тырышкан идең? Миңа менә бу алмагач янына басарга куштың. Син үтеп барганда, «Кая барасың, Айсылу?» дип сорарга куштың. Син «Суга барам» дип әйтергә тиеш идең.

Айсылу. Аннан үбештекме?

Вил. Әйе, әйдә, шул уенны уйныйбыз.

Айсылу. Син әйткәч, уйныйбыз инде. Кил, бас шунда... Мин үтеп барам.

Вил. Кая барасың, Айсылу?

Айсылу. Суга барам.

Вил. Мин сине көтеп торам.

Айсылу. Нигә көтәсең, Вил?

Вил. Мин сине бик сагындым.

Айсылу. Шуннан мине кочаклап аласың, әйеме?

Вил. Әйе.

Айсылу. Мин дә сине бик сагындым, Вил! (*Вилнең кочагына керә. Муенына асылынып үбә.*) Син яратасыңмы мине, Вил?

Вил. Яратам, әлбәттә!

Айсылу. Мин сине «өзелеп-өзелеп-өзелеп яратам» диген.

Вил. Мин алай дип, синең кебек әйтә белмим.

Айсылу. Укыган башың беләнме?

Вил. Укуның монда ни катнашы бар.

Айсылу. Укыган кеше матур сүзләр күп белә инде ул.

Вил. Сиңа әйтергә тиешле сүзләрне белү өчен уку кирәкми.

Айсылу. Ни кирәк?

Вил. Син кирәк.

Айсылу. Чынмы, Вил?

Вил. Син, мине үз дөньяңа алып кереп, миңа яңа дөнья ачтың.

Айсылу. Чынмы, Вил?

Вил. Мин авылда туып, табигать кочагында үсеп, аның матурлыгын күрмәгәнмен икән, син минем күземне ачтың.

Айсылу. Матур сүзләр белмим, дигән була.

Вил. Болар матур сүзләр түгел, чынбарлык. Син табигатьнең үзе кебек гади һәм гүзәл.

Айсылу. Ай, үләм! (*Вилнең әйткән һәр җөмләсеннән соң аны үбеп ала.*)

Вил. Рәхмәт сиңа!

Айсылу. Миңа ник рәхмәт?

Вил. Булганың өчен! Дөньяда синең булганың өчен! Син мине алмагач янында бастырып уйнаттың. Рөхсәт ит, мин дә сине уйнатыйм. Кил әле монда, бас әле шушында. Җырла әле теге җырны.

Айсылу. Нигә гел шул җырны җырлатасың?

Вил. Белмим. Ошый ул миңа. Беренче тапкыр син аны миңа җырладың.

Айсылу. Тик син моңсуланма, ярыймы? Шуны җырласам, син әллә нишлисең. Мин аны хәзер «ялгызым» дип җырламыйм, ярамый. «Сине эзлим», дим.

Вил. Җырла!

Айсылу. Урманнарда йөрдем сине эзләп

Баласын җуйган болан эзеннән.
Башларым әйләнеп китте кинәт
«Башканы сөям» дигән сүзеңнән.

Нигә уйга калдың, Вил?

Вил. Айсылу!

Айсылу. Әү, матурым!

Вил. Мин иртәгә китәм.

Айсылу. Кая?

Вил. Казанга. Укуны дәвам итәргә.

Айсылу. Ничек инде? Әйткәнең юк иде.

Вил. Әйтергә иртәрәк иде.

Айсылу. Кызык икән... Ә мин?

Вил. Син? (*Пауза.*) Мин бит сине ташлап китмим.

Айсылу. Нишләтеп китәсең соң?

Вил. Казан ерак ара түгел.

Айсылу. Китмисең!

Вил. Миңа укуны дәвам итәргә кирәк. Үткән сессия имтиханнарын тапшырасы да бар.

Айсылу. Китмисең!

Вил. Китмичә ярамый. Мин өченче курсны тәмамлыйм бит инде.

Айсылу. Ярый, кит алайса... (*Чыгу юлына юнәлә.*)

Вил. Айсылу, Айсылу!..

Айсылу (*Вилнең кочагына кереп*). Китмә, Вил, китмә!.. (*Елап.*) Китмә! Харап итәләр анда сине. Китмә, бәгырькәем!

Вил. Айсылу!.. Йә инде... Хатлар язышырбыз. Кайтып йөрермен, үзең килерсең.

Айсылу (*үксеп*). Китмә!.. Китмә!..

Ут сүнә.

## АЛТЫНЧЫ КҮРЕНЕШ

Җылы киемнәр кигән Нургазиз, Зәйнәпбану, Хәнифә куышны сүтеп бетереп киләләр.

Хәнифә. Бәйләнде шул куышка Ким. Торса ни була иде инде.

Нургазиз. Үзсүзле. Сүзен сүз итәргә кирәк. Кар юк бит әле, Хәнифә! Ноябрь бетә бит инде. Салкынайтып җибәрмәсен иде.

Зәйнәпбану. Хәзер инде салкыннан куркасы юк. Газ җылытып тора.

Нургазиз. Ә җир? Җирне газ җылытмый бит. Җитмәсә, кышка коры килеш керә.

Зәйнәпбану. Хат киләме улыңнан?

Хәнифә. Хат язмый бит ул. Айсылуга килә дигән иде. Әле менә ул да әйтә, ун көннән артык килгәне юк, ди.

Шулчак рәшәткә янында чәче-башы тузган Айсылу күренә.

Айсылу. Хәнифә апа!

Хәнифә (*Айсылу янына килеп*). Ни булды?

Айсылу (*кесәсеннән конверт чыгарып*). Менә хат, Вилдән. Әллә ниләр язып бетергән ул анда. Берни дә аңламадым. Ниндидер революцияләр язган. Язуы да танырлык түгел.

Хәнифә (*хатны карап*). И Ходаем!..

Айсылу. Хәнифә апа!.. Нишлим икән?

Хәнифә. Туктале, сабыр!..

Ким керә.

Айсылу (*Ким каршына атылып барып*). Ким абый!..

Ким. Кит, буталма әле. Әнкәй, кил әле! (*Хәнифәне читкәрәк алып китә.*) Мин Казанда идем. Вилне больницага салып кайттым.

Хәнифә. И Ходаем! Нигә алып кайтмадың?

Ким. Борчылма. Сөйләштем. Тикшерсеннәр...

Айсылу. Хәнифә апа! Ким абый!.. Нигә миннән качып сөйләшәсез? Беләм ич мин. Әйттем бит аңа! Әйттем бит аңа! Әйттем бит, әйттем бит, әйттем бит, әйттем бит мин аңа!..

Пәрдә.

# Син мине күрәсеңме?*

*Ике пәрдәле музыкаль комедия*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Гәрәй – 25–30 лар арасындагы егет.
Галәү – 25–30 яшьләрдәге егет.
Галия – 25 яшьлек кыз.
Илүзә – 18 яшьлек кыз.
Нурания – 60 яшьтә.
Нургали – 65–70 яшьләрдә.
Галя – 20–25 яшьләрдә.
Гөлинә
Сәкинә 20 яшьтән узган кызлар.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Үзе моңлы, үзе дәртле кереш музыка җанны җилкендерә, күңелне алгысыта. Бу музыка безне табигатьнең гүзәл бер почмагы – Мишә елгасы ярына алып килә. Әрәмәлек. Ял итәргә килгән бер төркем (унунбиш кыз, ике егет) мәш килә, кайнаша.

Гәрәй. Шым кал! Чаукылдашмагыз! Мин булган җирдә тәртип булырга тиеш. Мин монда хөрмәтле вә гыйззәтле Айдар Исламовичның безне бер көнлек вә һәм бер төнлек коллектив ялга җибәрүе хөрмәтенә мин язган һәм сезгә өйрәткән җырны хор белән башкарабыз. Мин солист һәм оркестр ролен башкарам. Башладык. (*Гитара кылларында бармакларын йөгертеп аккорд бирә.*)

Җыр башлана.

Хор. Дөнья көтүләре авыр, диләр,
Җиңел дөнья барын кем белә?
Кемдер зарын сөйләр кеше тапмый,
Кемдер авыз ерып гел көлә.
Кемгәдер нидер ярамый,
Безгә бар да яраган.
Бу дөньяны «авыр» диләр,
Кем күтәреп караган?
Кемнәргәдер кояш нурын сибә.
Кемдер айга таба үрелә.
Кемдер гашыйк булып җыр чыгара,
Кемдер ярын тапмый сүгенә.
Кемдер сакалын кырган да,
Кемдер чәчен тараган;
Бу дөньяның тәрәзәсен
Кемнәр ачып караган?
Кайсы дөнья әйбәтлеген
Кемнәр үлчәп караган?
Безгә аның тегесе дә,
Монысы да яраган.

Гәрәй (*җыр туктагач*). Татарның һәр җыры бию белән тәмамлана. Хөрмәтле вә гыйззәтле Айдар Исламович хөрмәтенә күмәк бию!

Бию башлана. Бераздан Гәрәй аны туктата.

Туктагыз! Син нигә биемисең, Галәү?

Галәү. Мин бии белмим бит.

Гәрәй. Бии белмәгән кеше юк. Селкен. Хәзерге заманда селкенү «бию» дип атала. Нурания апа, син ник килдең?

Нурания. Үзең алып килдең ич.

Гәрәй. Беренчедән, мин алып килмәдем, Айдар Исламович җибәрде. Икенчедән, монда тамашачылар юк, барыбыз да артистлар. Музыка!

Бию дәвам итә. Гәрәй биюне туктата.

Ә хәзер барыгыз да Мишәгә!

Нурания. Биюе ошап китте бит әле, Гәрәйҗан!

Гәрәй. Дәвамы кич белән булачак. Барыгыз! (*Бию туктагач.*) Барыгыз да Мишәгә! Су өсте сезнең шатлыклы көлүегездән дулкынланып торсын. Рәсәйнең бер почмагында көлүен онытмаган халык калган икән дип уйласыннар. Алып килгән байлыкларыгыз өчен курыкмагыз, сакта үзем калам. Пистолетым кесәмдә, автоматым иңсәмдә.

Хатын-кызлар, чыр-чу килеп, йөгереп чыгып китәләр. Нураниянең муенына аскан телефоны шылтырый. Ул туктап калып сөйләшә.

Нурания. Нихәл, Нургали! Без монда Мишә суы буенда. Балык тотарга килгән идек бит теге вакытта. Шул җирдә. Нишлибез дип, биедек тә коенырга барабыз. Бүген кайтып булмастыр. Гәрәй шулайрак әйтте. Сау бул! Мин чаптым.

Кызлар артыннан чыгып китә. Гәрәй янында Галәү белән Илүзә генә кала.

Ә сез нишләп калдыгыз?

Галәү. Беләсең ич, мин йөзә белмим.

Гәрәй. Яр өстендә утырырсың. Бар!.. Ата казсыз каз көтүе булмый, Галәветдин. Галиягә дә күз-колак булырсың. Мишә буе егетләре үткеннәр, урлап китмәсеннәр. (*Галәү чыгып киткәч, Илүзәгә.*) Син нигә коллективтан аерылдың?

Илүзә. Минем сезнең янда каласым килде.

Гәрәй. Ничек инде ул каласым килде?

Илүзә. Сезнең белән бергә әйберләр саклашам.

Гәрәй. Миңа ярдәмчеләр кирәкми. Бар! Коен, йөз, кыска җәйнең рәхәтен күр. Бар, нәрсә Таһирга гашыйк булган Зөһрә шикелле карап торасың?

Илүзә. Ә мин сезгә гашыйк, Гәрәй абый!

Гәрәй. Нәрсә-ә-ә?

Илүзә (*җыр белән*).

Ә мин сезгә гашыйк, Гәрәй абый,
Гәрәй абый, мин бит сезгә гашыйк!
Сезне күрсәм, җаным канатлана,
Күңлем очып йөри күккә ашып.
Мин бит сезгә гашыйк, Гәрәй абый,
Сезне уйлап, иртән уянам мин.
Дөнья миңа сезсез кызык түгел,
Сезне уйлап кына юанам мин.

Гәрәй. Шул гына җитмәгән иде миңа. Син генә калган идең миңа гашыйк булмаган... Син мине күрәсеңме?

Илүзә. Күрәм.

Гәрәй. Минем башны күрәсеңме?

Илүзә. Күрәм.

Гәрәй. Андагы ак чәчләрне күрәсеңме?

Илүзә. Күрмим.

Гәрәй. Ничек инде күрмисең? Менә кара, кара! Минем ничә яшьтә икәнлегемне беләсеңме?

Илүзә. Белмим.

Гәрәй. Белмәсәң бел, миңа тиздән утыз яшь тула, балакаем! Сиңа ничә?

Илүзә. Унсигез!

Гәрәй. Менә күрәсеңме? Син, сабый бала башыңнан, миндәй азып-тузып беткән кешегә «гашыйк булдым» дип торасың. Егетләр белән йөргәнең бармы?

Илүзә. Бар.

Гәрәй. Яратышыпмы?

Илүзә. Юк. Болай гына. Сез – минем беренче мәхәббәтем!

Гәрәй. Нәрсә-ә? Ни сөйлисең син, тиле? Әйт әле, кайчан һәм ни өчен гашыйк булдың миңа?

Илүзә. Беренче күргән көннән. Сез миңа карап тордыгыз да «нихәл, сары чебеш» дидегез. Башымнан сыйпадыгыз.

Гәрәй. Шуның өчен гашыйк булалармы?

Илүзә. Сез яратып карадыгыз, яратып сыйпадыгыз.

Мин бит сезгә гашыйк, Гәрәй абый!
Сезне уйлап ятам төннәр буе,
Сезне уйлап каршылыйм һәр таңны,
Сезне уйлап йөрим көннәр буе.

Гәрәй. Әй-әй-әй... Әй, сабый! Бәлки, мин сиңа караганмын да «их, бу сары чебешнең башын әйләндереп, кочаклап һәм алдап ташласаң иде» дип уйлаганмындыр.

Илүзә. Сез алай уйламадыгыз. Сез сокланып карадыгыз.

Гәрәй. Ха-ха-хи, хи-ха-ха!.. Сокланырлык ниең бар соң синең? Ни буең юк, ни ниең тавык йомыркасы хәтле... Өстәвенә башың сары.

Илүзә. Сары түгел ул, аксыл. Аның каравы күзләрем матур минем. Менә карагыз.

Гәрәй. Карамыйм. Сезгә ышансаң, йә сихерләрсез. Мин, балакаем, гашыйк булмаска сүз биргән кеше.

Гашыйк ирләр мескен җаннар алар,
Богауланган коллар шикелле.
«Мәхәббәт» дип күккә ашу җиңел,
Төшүләре әмма икеле.

Юк, тимәгез миңа, тимәгез,
«Мин яратам сине» димәгез.
Гашыйк булу эзләп алган чир ул,
Чирләрнең дә иң-иң яманы.
«Мәхәббәт» дип төпсез күлгә чумсаң,
Аннан чыгулары чамалы.
Юк, тимәгез миңа, тимәгез,
Зинһар өчен, якын килмәгез!

Илүзә. Ә сез мине башта гашыйк булмыйча гына яратыгыз. Бара-тора гашыйк булырсыз.

Гәрәй. Сине кочаклаганнары бармы? Кочаклап үпкәннәре булдымы?

Илүзә. Юк.

Гәрәй. Кайда үстең соң син? Казандамы?

Илүзә. Казанда.

Гәрәй. Казанда үсеп, кочакланылмаган, үбелмәгән килеш калдыңмы? Бу бит тәмугка элэгеп тә, янмый чыгу белән бер. Соң, бәгырькәем, мин бит сине алдый алам.

Илүзә. Алдагыз!

Гәрәй. Нәрсә-ә-ә? Бар ычкын моннан! Синең аркада гөнаһ җыясым килми. Болай да гөнаһларым муеннан. Бар, диләр. Башыңны салкын суга тык та уйла бераз. Бар!

Илүзә. Минем купальнигым юк.

Гәрәй. Ничек юк? Кая, ни өчен барганыңны белдеңме? Әйттеләрме?

Илүзә. Мин сез барганга гына килдем.

Гәрәй. Син, кызый, мине җүләргә санама, ярыймы. Минем белән уйнарга да җыенма. Синдәйләрне мин миллиунны күргән. Яле, күтәр әле итәгеңне!

Илүзә. Нигә?

Гәрәй. Карыйк әле, бармы купальнигың.

Илүзә. Оялам.

Гәрәй. Менә анысы әйбәт, оялуың әйбәт. Бар, анда хатын-кызлар гына. Галәү абыеңа исең китмәсен, ул да ояла. Шәрә хатын-кыз күрсә, артына борылып утыра. Бар! (*Илүзәнең башыннан сыйпап, озатып куя.*) Вәт вәсвәсә! Тәки ышанып куюың бар. (*Гитарасын алып, җиргә ята. Җыр суза.*)

Мин ятам болында –
Иң матур урында.
Атым юк урамда,
Кайгым юк буранда.
Хатын юк өемдә –
Яшим үз көемә.
Кызлар күп янымда –
Яратам барын да.
Мин ятам болында –
Гитарам кулымда.
Өс – бөтен, тамак – тук.
Хәсрәтем, кайгым юк.
Киләм, кил, дисәләр.
Китәм, кит, дисәләр.
Агам, ак, дисәләр.
Багам, бак, дисәләр.

(*Кереп, үзенә карап торган Галияне күрә.*) Нигә кайттың, Галия?

Галия. Илүзә белән нишләдегез?

Гәрәй. Ничек инде нишләдек? Кызлар белән нишлиләр соң?

Галия. Хатын-кызлар яратмыйм дисәң дә, кызларга күзең төшә.

Гәрәй. Галия, җанкисәгем, хатын-кызларны яратмыйм, дигәнем юк. Киресенчә, бөтенесен дә бертигез яратам. Менә бу сары чәчле кызыгызны да сине яраткан кебек яратам.

Галия. Яратмыйсың шул мине.

Яратмыйсың мине, яратмыйсың,
Яратырга мине теләмисең.
Хисләремнән сиңа учак ягам –
Син янмыйсың анда, үрләмисең.

Гәрәй. Яраталмыйм сине, кичер мине,

Тик үземне генә яратам мин.
Үзем өчен яшим дөньяларда,

Яраталмыйм, кичер, яраталмыйм.

Галия. Яннарымнан үтеп киткән чакта,
Өмет итәм назлы карашыңны.

Гәрәй. «Яратам» дип, коллык чылбырына
Бәйләп куя алмыйм бу башымны.

Галия. Яратмыйсың мине, яратмыйсың.

Гәрәй. Яраталмыйм, кичер, яраталмыйм.

Галия. Яратырга мине теләмисең.

Гәрәй. Яраталмыйм, кичер, яраталмыйм.
Мәхәббәт мәсьәләсендә мин – демократик республика, Галия! Минем өчен бөтенегез бертигез. Аннары, шунысы да бар, Галиякәй, син дә бит мине яратмыйсың. Интектермә йөрәгеңне. Сиңа ир кирәк. Син картаеп барасың. Мин өйләнмәгән булгач, мине ир итмәкче буласың. Ялгышма, Галия, миннән рәтле-җүнле ир чыкмый. Җилбәзәк акыллы кеше мин. Син тәртипле, төпле кыз. Сиңа тотрыклы ир кирәк.

Галия. Миңа мин яраткан кеше кирәк.

Гәрәй. «Мин яраткан» дип, үзеңне алдама, Галия! Син Ләйлә дә , Зөһрә дә, Галиябану да түгел! «Мәхәббәт» дип саташып йөрергә сиңа ярамый. Тагын биш елдан утызны узасың. Кызлар ул яшьтә пенсиягә чыга.

Галия. Бик беләсең инде, илле биштән чыгаралар безне.

Гәрәй. Мин, кызлар, дидем, хатын-кызлар, димәдем. Ташла минем арттан йөрүеңне. Мин өйләнергә җыенмыйм. «Өйләнәм» дип, сине алдарга да теләмим.

Галия. Мин алданырга җыенмыйм да әле.

Гәрәй. Беләм, җыенмыйсың. Чөнки син кирәгеннән артык акыллы кыз. Сиңа мин түгел, әнә Галәү кирәк.

Галия. Нигә һаман саен аны миңа кодалыйсың?

Гәрәй. Чөнки ул сиңа менә дигән ир булачак. Өрмәгән җиргә дә утыртмас.

Карап торыр күзләреңә,
Күзләреңә, йөзләреңә,
Басып йөрер эзләреңә,
Каршы дәшмәс сүзләреңә.
Түзеп торыр безләвеңә,
Герләр булыр бизмәнеңә,
Чишмә булыр кизләвеңә,
Ефәк, дияр бүзләреңә,
Алтын, дияр җизләреңә,
Маяк булыр эзләреңдә,
Язлар булыр көзләреңдә.

Ярата ул сине, Галия!

Галия. Яратса, әйтер иде яратканын.

Гәрәй. Бөтен кеше дә мин түгел. Син инде бала-чагалыктан узган, күрә бел кемнең кем икәнен.

Галия. Беләм, пешмәгән!

Гәрәй. Сиңа минемише пешкәннәр кирәкме? Мин инде, Галия бәгырькәем, матурым, җанкисәгем, алма кисәгем, йөрәк маем, пешә-пешә көеп беткән. Галәү пешеп җитмәгән икән, пешереп бетерерсең. Сөйләшеп кара син аның белән.

Галия. Үзе сөйләшмәгән кеше белән ничек сөйләшим? Без коенган җиргә килеп, яр өстендә карга кебек утыра.

Гәрәй. Карга кебек түгелдер, бәлки, бөркет кебектер.

Галия. Шулай да ни сөйләштегез теге кыз белән?

Гәрәй. Яратам, ди.

Галия. Шулмы?

Гәрәй. Ә нигә? Аның да яратырга хакы бар. Аңа инде унсигез яшь, Галия!

Галия. Алар унбиштә үк егетләр муенына асылыналар.

Гәрәй. Яраткач, асылынасың инде. Менә син «яратам» дисең, бер дә асылынмыйсың. Димәк, мине яратмыйсың. Бик әйбәт яратмавың. Ә Галәүне тилмертмә син. Бүтәнгә өйләнеп куймасын.

Галия. Нишләтим инде мин аны? Яныма да килеп карамый. Үткәндә-сүткәндә күзләре белән генә ашап кала.

Гәрәй. Китерәсең киләме янына? Сөйләштерәсең киләме? Мине яратсаң, тыңла киңәшемне. Галәү – тиз ышанучан егет. Телевизордан сөйләгән төрле әкиятләргә ышана. Әйдә, бер эксперимент эшләп

карыйбыз. Бүген ул синең яныңа килсә, син аны күрмәгән булып кылан. Тавышыңны гына ишетәм, диген.

Галия. Нәрсә кыландырырга җыенасың?

Гәрәй. Кыландырмыйм. Сине дә, Галәүне дә бәхетле итәсем килә.

Галия. Синнән башка бәхет юк миңа.

Гәрәй. Нинди кешеләр соң сез, ә? Нәрсәмә кызыгасыз минем?

Галия. Синең белән сөйләшү, синең юк-бар шаяруларыңны тыңлау, синең янында тору рәхәт.

Гәрәй. Мираж алар барысы да, Галия! Сиңа төпле ир кирәк, дип әйтәм икән, ышан миңа. Галәү кирәк сиңа, Галәү кирәк. Тыңла минем киңәшемне, сүзен тыңла Галәүнең, үзен күрмә. Әнә кара, кара син ул Галәүгә. Кайдан табасың шундый ирне. Онытма, сиңа тиздән утыз яшь. Кара, сине эзли. Бар, кит тизрәк моннан, югыйсә мине үтерәчәк.

Галия. Кыланчык! Кай җиреңне яратамдыр.

Гәрәй. Мин дә шуңа аптырыйм бит.

Галия. Тиле! (*Китеп бара.*)

Гәрәй. Онытма мин әйткәнне. Әй бу тормыш дигәнең!..

Әй, тормыш, син тормыш –
Акылга утыртмыш,
Акылдан яздырмыш.
Бәхет, дип котыртмыш,
Күз яше койдырмыш,
Гыйшык, дип алдамыш,
Җаннарны ялгамыш,
Яшьләрне картайтмыш,
Картларны... нишләтмеш?
Мыш та мыш, мыш та мыш,
Мыш та мыш, мыш та мыш...

Галя керә.

Галя. Получается?

Гәрәй. Что получается, Галина?

Галя. Вроде бы поешь.

Гәрәй. Җырлыйм. Син дә миңа мәхәббәт аңлатырга килдеңме?

Галя. С чего это ты взял?

Гәрәй. Монда кызлар киләләр дә «яратам» диләр.

Галя. Нет, Гарай, дорогой, за полотенцем пришла. Впрочем, ты мне нравишься. Встретила бы раньше, привязала бы к себе.

Гәрәй. Булмый, Галинушка, мин убежденный холостяк! Галя, можно я тебя буду звать Галябану. Син бик матур, Галябану.

Галя. Еще бы! Может поцелуемся!

Гәрәй. Нет! У тебя муж. Я с разведенными целуюсь.

Галя. Баламут вы, Гарай Хамитович! И за это вас все любят.

Гәрәй. Бер җыр җырлыйммы, Галинушка? Син татарча аңлыйсың бит.

Ай җаный, вай җаный,
Татар үпкән марҗаны.
Нигә үпмәсен марҗаны,
Марҗаның да бар җаны.

Аңладыңмы, Галина?

Галя. Аңладым. Кстати, я не русская. Я марийка. Мари кызы, мари хатыны.

Гәрәй. Әйтәм аны чибәр! Мари кызларының күзләре серле була.

Иртән торып күл буена
Кудым үрдәкләремне,
Күз тутырып кара әле,
Мари кызы Галябану,
Өзмә үзәкләремне.
Их, мари, мари, мари,
Мари кызы да мари.
Әйтче миңа, мари кызы,
Күңелең кемнәргә карый.

Гөлләр булып түтәлемдә
Чәчәк атарсың микән?
Түшәгеңдә мине генә,
Мари кызы Галябану,
Уйлап ятарсың микән?
Их мари, мари, мари,
Мари сылуы мари.
Бер елмаеп кара гына,
Яратмасаң да ярый.

Галя. Хватит! Не дай Бог, влюблюсь. Хочешь я тебе марийскую песню спою.

Моланат, моланат муралшаш да
Моланат, моланат шушкалмаш?
Лыпат лийшаш шумем-мокшем,
Моланат, моланат тарваталшаш?

Моланат, моланат ойгыршаш да,
Моланат, моланат шортылдалшаш?
Лыпат лийшаш шумем-мокшем
Моланат, моланат тарваталшаш?*

Сөлгесен ала да үтеп барышлый Гәрәйнең яңагыннан үбеп чыгып йөгерә.

Гәрәй. Да-а-а!.. Түзеп кара болар арасында. Бирешмә, Гәрәй!
Мин ятам болында –
Иң матур урында.

(*Килгән Галәүне күреп.*) Нигә башларың идең, дускаем Галәветдин? Ни кайгылар төште башкайларыңа? (*«Авыл көе»нә көйләп.*)

Кулымдагы йөзегемнең
Исмен Галәү кушканнар,
Имә башларыңны түбән –
Сөенмәсен дошманнар.

Галәү. Галия синең янга нигә килгән?
Гәрәй. Син аның янына бармаганга, ул минем янга килгән.
Галәү. Әйттеңме минем турыда берәр сүз?
Гәрәй. Нишләп әле син әйтәсе сүзне мин әйтергә тиеш.
Галәү. Мин аның суда йөзгәнен карап тордым. Су кызы кебек йөзә.
Гәрәй. Су кызының йөзгәнен күргәнең бармыни?
Галәү. Бар, Гәрәй, бар! Мин бит авыл малае. Безнең өй күл буенда. Бервакыт, төнлә суга карап утырганда, күрдем су кызын.
Гәрәй. Бәлки, ул крокодил булгандыр.
Галәү. Каян килсен инде авылга крокодил?
Гәрәй. Синең кебек мокыт каян килгән соң?
Галәү. Мыскыл итмә инде, Гәрәй!
Гәрәй. Итәм! Мин сине су коенучы каз көтүе янына ата каз итеп җибәрдем. Ә син, ярым шәрә кызларның суда чупырдашканнарын күреп рәхәтләнәсе урынга, аларга сыртыңны куеп яттың. Әле тагын «Галия йөзә» дигән була. Күрмәдең бит син аның йөзгәнен.
Галәү. Күрмәсәм дә сиздем. Беләсеңме, Гәрәй, бервакыт мин күрше апаны шәрә килеш күрдем. Шуннан бирле шәрә хатын-кызны күрсәм, оялам. Сиңа рәхәт, син ояла белмисең. Синең кебек булырга тырышам да, килеп чыкмый.
Гәрәй. Әйе-е-е!.. Кызганам да мин сине, Галәү, кызыгам да. Йөз илле ел буе яратып йөреп тә, яратуын әйтергә оялган егеткә ни диләр? Кем диләр?
Галәү. Беләм инде, пешмәгән, диләр. Нишләтим, шундый инде мин.

Нишлим инде, серле минем мәхәббәтем,
Күңелемнең төпкеленә яшеренгән.
Үзем янам, үзем көям, үзем сөям,
Бер үләм мин аны уйлап, бер тереләм.
Нишлим инде, шундый минем мәхәббәтем,

«Сөям» дисәм, сүнәр төсле януларым.

Гәрәй. Шулай йөрсәң, ихтимал бит, агай-эне,
Гомер буе буйдак булып калуларың.
Галәү. Көтәм әле, көтәм әле, көтәм әле,
Көтәм әле сөю кошы кагынганын.
Гәрәй. Юк, көтмә син, өмет итмә, көталмассың
Син ул кошның кочагыңа сарылганын.
Галәү. Сиңа җиңел, Гәрәй, теләсә кайсы кызны кочаклыйсың, теләсә кайсы хатынның биленнән тотасың. Берсе дә сиңа сүз әйтми, көлеп кенә торалар.
Гәрәй. Заманасы шундый, Галәветдин, заманасы. Кочаклата һәм кочаклаттыра торган заман.
Галәү. Мин дә шул заманда яшим бит инде.
Гәрәй. Синең тактик һәм стратегик ялгышың бар, Галәү дус! Син берәүне генә яратасың. Хәлил белән Галиябанулар заманасы үтте, Галәветдин! Берләр – унны, уннар берне ярата торган заман килде. Оныт син Галияне. Мин сиңа Галяларны табып бирәм.

Ах ты, моя Галочка,
Биле нечкә талочка.
Тавык кебек курочка,
Тавык сыман дурочка.
Галәветдин – Галочка,
Мировая парочка.
Вот какая дамочка,
Мин табасы Галочка.

Галәү. Көлмә инде, Гәрәй! Миңа Галиядән башка беркем дә кирәкми.
Гәрәй. Хәлеңне аңлыйм, ярдәм итә алмыйм. Мин күп кызларны берьюлы ярату догасын гына беләм. Син беләсеңме, Галәветдин, мин бит кызлар янына күренмичә барам.
Галәү. Ничек күренмичә?
Гәрәй. Миңа әбиемнең ахирәт дусты – йөз дә бер яшьлек Бәдигылҗамал карчык бер дога өйрәтте. Шул доганы укыйм да кызлар күзенә күренми башлыйм. Кызлар янына барам, алар мине күрмиләр, юк дип уйлыйлар.
Галәү. Көлмә инде, Гәрәй!
Гәрәй. Ышанмасаң ышанма. Кызлар караватта йоклап ята, иеме, чишенгән. Мин инде аңа ияреп кайткан булам. Карап торып чишендерәм. Мине син бозык-фәлән дип уйлама, бөтенләй үк чишендермим. Бөтенләй үк чишенеп күлмәген, тегесен-монысын алыштырса, читкә карап торам. Ярамый кызлар белән шаярырга, Галәветдин! Ходай аларны кыз итеп яраткан, Ходайга каршы барырга ярамый. Мин нишлим? Алар чишенеп караватларына яткач, яннарына киләм дә яңакларыннан гына пәп итеп алам. Колакларына «яратам мин сине» дип пышылдыйм. Алар, беләсеңме, нишлиләр? Күзләрен ачып, тирә-якны күзәтәләр. Ах-ух итәләр. Ә мин шунда уң колак яфрагын пәп итеп куям. Пышылдап кына колакларына шушы җырны җырлыйм.

Гөлләрем син минем, алым син,
Шикәрем син минем, балым син.
Алтыным, көмешем, якутым,
Гомергә онытмас ярым син.
Ах, синең чәчләрең, толымың,
Мин синең бер мескен колыңмын.
Онытма, гүзәлем, онытма,
Әнкәмнең бер иркә колынын.

Шуннан кызый, тәмам гасабиланып, урыныннан торып утыра. Җыр иясен эзли. Ә мин – юк. Мин күренмим. Шуннан нишлисең, дип сора.
Галәү. Шуннан нишлисең?
Гәрәй. Кызның күзләрендә сөю ялкыны дөрли башлагач, сул колак яфрагын пәп итеп алам да сиздермичә генә ишекне ачып чыгып китәм. Кызга тимим. Кызларга тияргә ярамый. Тияр өчен ирләрен өеннән куып чыгарган, аерылып кайткан хатыннар бар.
Галәү. Әллә ниләр уйлап чыгарасың.
Гәрәй. Минме уйлап чыгарам? Менә син ул уйлап чыгарасың җыен юк-барны. «Үлгән әбиемнең теге дөньяда ятканын күрдем» дип син сөйләдеңме?
Галәү. Аны мин генә сөйләмим, газеталарда язалар, телевизордан күрсәтәләр.

Гәрәй. Галәветдин, бәгырь кисәгем, моннан илле ел элек үлгән кеше күренгәч, исән кеше дә күренмичә йөри ала. Укыганың бардыр бит китапларда.
Галәү. Бар, ярты төндә чәчәк аткан абаганың чәчәген ашасаң гына күренмисең, ди.
Гәрәй. Соң, атаңның башы, анаңның аягы, бар бит миндә абага чәчәге. Мин аны төнге сәгать унике тулганда Кариле урманында эзләп таптым да, өзеп, киптереп куйдым. Менә ул монда йөрәк янында күкрәк кесәсендә йөри. Шуны чеметеп кабам да, әбинең догасын укып, ул өйрәткән йоланы үтәп, күренмичә генә китәм кызлар артыннан.
Галәү. Анысын сөйләдең инде.
Гәрәй. Юк, бөтенесен дә ишетмәдең әле син, Галәветдин.

Ах, ул кызлар, ах, ул кызлар-кыркыннар,
Ул кызларны күренмичә күрүе!
Кызлар яткан караватның янында
Татлы, тәмле уйлар уйлап йөрүе!
Сул колакның яфрагыннан тәм алып,
Уң колакның яфрагына үрелү!
Мондый рәхәт – җанны кертү мунчага,
Мондый бәхет – үлгәннән соң терелү!

Әйт, телисеңме Галиягә күренми генә аның колак яфракларын үбәргә.
Галәү. Телим дә бит...
Гәрәй. Соң, теләсәң, өйрән абзаңнан.
Галәү. Син көләсең генә бит. Беренче апрель көнне дә ничә кешене алдадың.
Гәрәй. Сине алдадыммы?
Галәү. Юк та бит.
Гәрәй. Син ничек шофер булып йөрисең, ә? Шоферлар үткен була бит. Соңгы тапкыр сорыйм, телисеңме Галиягә күренмичә йөрергә?
Галәү. Башта үзең күрсәт миңа.
Гәрәй. Нәрсәне?
Галәү. Миңа күренмичә йөреп кара.
Гәрәй. Син нәрсә, әллә сихерне уен-муен дип белдеңме? Нигә мин синең алда күренмичә йөрим. Әллә колак яфрагыңны үбәсем бармы? Аннан соң абага чәчәге миндә бит бер пот түгел. Ике генә чеметем. Мин капсам, сиңа калмый. Ярый, син теләмәсәң, мин Галияң янына керермен дә күренмичә үбеп чыгармын. Ризамы?
Галәү. Үбеп кенә кара!
Гәрәй. Нишләтәсең?
Галәү. Соң, алай була алмый бит инде, Гәрәй! Күренмичә йөреп булмый.
Гәрәй. Була, диләр сиңа. Син сынап кара. Сынап караудан ни була? Әнә бит пьеса язучылар сынап карыйлар. Комедия язып конкурска җибәрәләр. Үзләрен дә сынап карыйлар, жюри членнарын да сынап карыйлар. Барып чыкмаса, язудан туктыйлар.
Галәү. Әллә ниләр беләсең!
Гәрәй. Син дә бел, Галәветдин!
Галәү. Йә, әйтеп кара догаңны.
Гәрәй. Дога гына түгел ул, Галәветдин! Игътибар белән тыңла. Кыйбла якка карап басасың. Ике кулыңның ун бармагын кушырып түшеңә куясың. Колак салып тыңлыйсың. Сиңа син ишетмәгән бер музыка, көй иңәр. Аңладыңмы? Мин китеп торам. Син мин әйткәннәрне эшлә. Берәр көй ишетсәң, мине дәшәрсең. Шунда син ышанырсың минем сүзләремә.

Чыгып китә. Галәү ул кушканнарны эшли. Һәм чыннан да көй ишетә.
Ул көйне без – тамашачылар да ишетәбез.

Галәү (*Гәрәйне чакыра*). Гәрәй? Мин ишеттем ул көйне.
Гәрәй. Әйтмә. Миңа әйтмә. Үзең генә бел. Мин читкә авышкач, шул көйгә җыр чыгар.
Галәү. Нинди җыр?
Гәрәй. Нишләтәсең килә Галияне? Шул хакта җырла. Җырлап туктагач, тагын тыңла, Галиянең тавышы ишетелгәндәй булыр.
Галәү. Мин аңа атап гел җырлыйм, тавышы ишетелми.
Гәрәй. Димәк, тыңлый белмисең. Колагың белән түгел, күңелең белән тыңла. Мин читкә авышып торам. Җырла!
Галәү. Кычкырыпмы?
Гәрәй. Мәхәббәт җырын кычкырып җырламыйлар. Әкрен генә, моңлы итеп. *(Чыгып китә.)*
Галәү (*җыр суза*).

Уйлыйм сине таңнар аткан чакта,
Уйлыйм сине кояш чыккан чакта.
Уйлыйм сине салкын кышлар үтеп,
Алмагачта бөре шыткан чакта.
Син уемда кояш батканда да,
Күктәге ай нурын сипкәндә дә,
Сандугачның сайрауларын, хатка салып,
Җилләр аша сиңа бүләк иткәндә дә.
Ятсам, төшләремә керәсең дә
Үзәккәйләремне өзәсең лә,
Беләсең лә, синең утларыңда
Минем янганымны сизәсең лә.

Шул чакта, Галиянең «Галәветдин» дигән назлы тавышын ишетеп,
Галәү сискәнеп китә.

Галәү. Гәрәй, Гәрәй, мин ишеттем аның тавышын!

Гәрәй. Ышандыңмы инде, Алла бәндәсе. Мә, кап шушы бер чеметем абага чәчәген. Бу сиңа төнге сәгать уникегә хәтле җитә. Ул вакытка хәтле әйтәсе сүзеңне әйт Галиягә!

Галәү. Үлмәм микән, Гәрәй!

Гәрәй. Әллә син үзеңне тере дип беләсеңме? Кап тизрәк, озак тотсаң, сихере бетә.

Галәү (*кабып*). Әче. Борыч ич бу.

Гәрәй. Әллә сиңа бал каптырырлар дип көткән идеңме? Мәхәббәт ул төче генә булмый.

Галәү. Әйдә көл инде, көл миннән. Тик көлгәнеңне кешеләргә сөйләмә, ярыймы? Ишетсәм, бәреп үтерәм. Галиядән курыксам да, синнән курыкмыйм мин. Йә, ничек, мин сиңа күренәмме?

Гәрәй. Син Галия турында уйладыңмы, аңа атап җырладыңмы? Син бөтен кешегә күренәсең, Галиягә генә күренмисең. Аңладыңмы?

Җырлап, хатын-кызлар кайталар.

Нурания. Рәхмәт яусын сиңа, Гәрәй! Кырык ел суга кермәгән идем, рәхәтләндем.

Гәрәй. Миңа рәхмәт әйтмә, Нурания апа! Айдар Исламовичка рәхмәт әйт. Ул бүләк итте бу көнне.

Нурания. Син оештырдың, рәхмәт! Җыештыручы дип тормадың, мине дә алдың.

Гәрәй. Безнең илдә, Нурания апа, идән себерүче дә, министр да, депутат та бертигез.

Нурания. Тфү, нәгаләт, телең!..

Гәрәй. Мин – экспедитор, Галия – бухгалтер, син – җыештыручы. Кайчан тамак аерганыбыз бар? Тамакларыбыз бер безнең, хезмәт хакларыбыз гына төрле.

Нурания. И-и, шушы юк-бар сөйләвең өчен яратам да инде үзеңне! Хәзер безне нишләтәсең?

Гәрәй. Әнә агач күләгәсе, алып килгән җәймәңне җәй дә рәхәтләнеп ят, Нурания апа!

Нурания. Шулай итми булмастыр.

Җырлый-җырлый китә.

Галия. Нишләп үзең генә, Галәветдинең кайда?

Гәрәй. Күрмәдеңмени? Нәрсәгә кирәк булды соң әле? Сорашканың юк иде моңа кадәр.

Галия. Үзең әйттең бит, үзең кодалап йөрисең.

Гәрәй. Үпкәләп кайтып китмәгәндер ич.

Галия. Автобусы монда ич.

Гәрәй. Чыннан да, кая китте икән? Ярый, кайтса әйтермен, Галия эзләде, диярмен.

Галия. Эзләмәдем, болай гына сорадым. (*Китеп бара.*)

Галәү. Әллә чынлап күрмәдеме мине?

Гәрәй. Нәрсә әйттем мин сиңа, ышандыңмы инде?

Галәү. Ышанмадым да...

Гәрәй. Бар, калма артыннан. Ул хәзер агач артында киемен алыштыра, карап тор. Куса, күренгән буласың, кумаса, үзеңә кара.

Галәү. Юк. Карамыйм. Ярамый.

Галия (*җәймә күтәреп килә*). Шушында гына ятыйм әле. Күләгәсе дә иркен икән.

Гәрәй. Син ят. Мин су коенырга киттем.

Галия. Минем янга ятмыйсыңмы?

Гәрәй. Син Галәү килгәнне көт инде.

Галия. Аның килгәнен көтсәң... Егет булгач, эләктереп алсын иде дә ул, кысып кочакласын иде. Кочагында эретсен иде.

Гәрәй. Ашыкма, бер кабынып китсә, эреп парга әйләнерсең.

Галәүгә күз кысып, чыгып китә.

Галия (*җәймә өстенә сузылып ята*). Их, рәхәте!

Җәйнең гүзәл кызу көннәрендә
Болыннарның яшел мендәрендә,
Күләгәле куак төпләрендә,
Йоклап киткәч татлы төшләреңдә,
Бер сөйгән яр табылсын иде.
Уянып ла киткән чакларымда,
Ятсаң иде дә кочакларында,
Янсаң иде дә учакларында,
Күңелнең серле почмакларында
Гыйшык уты кабынсын иде.

Галиянең җырын Галәү әсәрләнеп тыңлый. Ләкин Галиягә якын ук килергә базмый. Галиянең аны күрмәвенә ышанып ук бетми. Андый булмаган хәлгә кем ышансын. Шулай да ышанасы килә, шайтан ал-
гырысы.

Галия җырын дәвам итә.

Бергә-бергә тормыш корсаң иде,
Бергә ятып, бергә торсаң иде.
Шатлык чәчеп, бәхет урсаң иде,
Тормыш рулен бергә борсаң иде.

Галәү. Булыр, Галия! (*Шунда ук, ник әйткәненә оялып, авызын учлары белән томалый.*)
Галия (*сикереп тора, як-ягына карана*). Абау! Кем бар монда?.. Әллә ниләр ишетелә. Әллә башка кызу сукты инде. (*Тагын сузылып ята.*)

Галәү аңа сокланып карап тора. Галиягә якын килмичә генә янәшәсенә ятып карый. Үлән кыягы өзеп ала да шуның белән Галиянең аяк
табаннарын кытыклый.

(*Галия, янә торып.*) Әллә кырмыскалы урынга туры килдем инде?

Галәү, тыела алмыйча, кете-кете көлә.

(*Галия тагын як-ягына карана.*) Нәрсә соң бу? Галәү көлүенә дә охшаган. Ул шулай кызык итеп көлә. Әллә төш күрәм инде? (*Ята.*)

Галәү, әкрен генә үрмәләп килеп, Галиянең сул колак яфрагын үбә.

(*Галия тагын торып утыра.*) Абау, ни булды соң бу?
Галәү. Мин бу, Галия!
Галия. Кем соң?
Галәү. Мин ич инде – Галәү! Көлүемнән таныдың.
Галия. Кайда соң син?
Галәү. Янында!
Галия. Янымда булгач, нигә күренмисең?
Галәү. Мин синең төшеңә кердем.
Галия. Ничек кердең? Мин әле йокламадым да.
Галәү. Йокламыйча күргән төшләр дә була.
Галия. Җыен юк-барга син ышанып йөрисең.
Галәү. Юк-бар түгел, Галия! Әйт, син мине күрәсеңме?
Галия. Ничек күрим, булмагач? Син әллә Галәү булып сөйләшүче пәриме?
Галәү. Чын Галәү мин, Галия! Мин сиңа күренмим генә. Ничек күренмәгәнемне аннары сөйләрмен. Син курыкма.
Галия. Ничек курыкмыйсың ди. Тавышың бар, үзең юк. Нигә миңа күренмисең?
Галәү. Оялам! Мин синнән оялам бит, Галия! Бухгалтериягә путевканы керткәндә, сине күрсәм, телем бәйләнә. Ничә ел инде. Ә син мине күрмисең дә. Күренсәм дә күрмисең. Ишетәм инде, пешмәгән, дисең. Пешмәгән түгел мин, Галия! Оялчан да түгел. Сине күргәч кенә шулай.
Галия. Колагымнан син үптеңме?
Галәү. Мин. Ачуланма инде, Галия!
Галия. Кызларны колагыннан үпмиләр, иреннәреннән үбәләр.

Галәү. Миңа Гәрәй өйрәтте. Сиңа күренми йөрергә дә ул өйрәтте.
Галия. Шулайдыр дип уйлаган идем аны. Ул колактан үбәргә ярата.
Галәү. Әллә үпкәне бармы?
Галия. Үпкәне юк, үрелгәне бар.
Галәү. Күренепме, күренмичәме?
Галия. Ул син түгел. Бөтен этлеген күренеп эшли.
Галәү. Юк, этлек эшләми ул. Ул сине дә, мине дә бәхетле итәргә тели. Минем сине яратканны белә ич ул.
Галия. Син чынлап та мине яратасыңмы?
Галәү. Сизәсеңдер ич инде.

Сандугачлар таңны яраткан күк,
Мин яратам сине, Галия!
Бөдрә таллар суны яраткан күк,
Мин яратам сине, Галия!
Ак каеннар язны яраткан күк,
Мин яратам сине, Галия!
Аккош күлен сөеп яраткан күк,
Мин яратам сине, Галия!

Галия. Әй, Галәветдин, Галәветдин! Күзгә күренеп йөргән егетне яраталар шул кызлар. Син гел күләгәдә. Исемең дә Галәветдин. Фердинанд йә Марсель булсаң иде, ичмасам.
Галәү. Миңа ул исемне әти кушкан. Галәветдин дигән кешенең тылсымлы лампасы булган. Мин генә әле тылсымлы лампаны таба алмыйм.
Галия. Кызык кына, үзең күренмисең, ә үпкәнең сизелә. Кулларымнан тотып кара әле, сизәрләр микән?!
Галәү (*Галиянең кулларын учына алып*). Сизеләме?
Галия. Кул икәне сизелми, кайнары сизелә. Кочаклап кара әле?!
Галәү (*Галияне кочаклап*). Сизеләме?
Галия. Бигрәк кайнар икәнсең син, Галәветдин!
Галәү. Син кайнар булганга, мин кайнар ул, Галия!
Галия. Син күрен, Галәү, сине күрәсем килә!
Галәү. Булмый шул, Галия! Мине төнге уникегә хәтле күренмәс итте Гәрәй. Әйдә су буена, Галия!
Галия. Нишлим анда, әле яңа кайттык.
Галәү. Син йөзәрсең, мин карап торырмын. Йөзгәндә син аккош кебек, Галия!
Галия. Арттырма инде, йә ышанырмын.
Галәү. Валлаһи, билләһи, шулай.
Галия. Әйдә соң, алайса. Ал җәймәне.

Галәү җәймәне ала.

Һай, бир тизрәк!
Галәү. Ни булды, Галия?
Галия. Җәймә күренә, син күренмисең. Кешеләр әллә ни уйлар. (*Җәймәне ала.*)

Чыгып киткәндә, Гәрәй очрый.

Гәрәй. Кая юл тоттың, Галиякәй?!
Галия. Галиякәй түгел мин сиңа, Галия! Кая телибез, шунда барабыз.
Гәрәй. Син патшалар кебек, «без» дип сөйләшәсең икән.
Галия. Шундый инде без. (*Чыгып китә.*)
Гәрәй (*Галәүне туктатып*). Йә, ничек?
Галәү. Гаҗәп. Ул ышана, мин ышанмыйм.
Гәрәй. Син ышан, Галәветдин! Кешеләр чынга түгел, ялганга ышана. Коммунизмда яшибез, дигәнгә миллионнар ышанды. Бар, калма. Һәм йөзәргә өйрән. Йөзә белгәннәр заманасы бүген.

Галәү чыгып йөгерә.

Гәрәй. Бәхетле кешеләр чүтеки бар дөньяда.

Илүзә пәйда була.

Илүзә. Гәрәй абый, мәтрүшкә нинди була ул?
Гәрәй. Агачтан кырып ясыйлар. Буяп күз, борын, авыз ясыйлар, яулык бәйләтәләр.

Илүзә. Мин аны әйтмим. Анысы аның – матрёшка. Мәтрүшкә ул чәчәк икән.

Гәрәй. Анысы, әйе, үлән. Мәтрүшкә чәчәге шәмәхә төсле була. Синең кебек сары чәчәклесе дә була. Анысын, сары мәтрүшкә, диләр. Нәрсәгә кирәк булды әле мәтрүшкә?

Илүзә. Нурания апа ире белән мәтрүшкә җыйганда танышкан икән.

Гәрәй. Мине әллә мәтрүшкә җыярга чакырасыңмы?

Илүзә. Әйе.

Гәрәй. Мәтрүшкә әле чәчәк атмаган.

Илүзә. Бәлки, аткандыр, карап кайтыйк, Гәрәй абый!

Гәрәй. Монда мәтрүшкә юк.

Илүзә. Нурания апа, бар, ди.

Гәрәй. Дисә, аның белән барыгыз.

Илүзә. Минем сезнең белән барасым килә.

Гәрәй. Әй, сары мәтрүшкә, бәйләнмәле миңа. Үзләре килеп сыланалар да, көчләде, дип судка бирәләр. Кит, бозма тәһарәтемне. Вәт ахырзаман сандугачлары! Нигә елыйсың?

Илүзә. Үзе мыскыл итте дә...

Гәрәй. Кем сине мыскыл итте? Кем килеп бәйләнә беренче? Синме, минме?

Илүзә. Мәхәббәт өчен көрәшергә кирәк, ди Нурания апа.

Гәрәй. Нәрсә белә ул Нурания апаң. Менә мин аны өзелеп сөям, ул аны сизми дә.

Илүзә. Сезме? Нурания апанымы?

Гәрәй. Мин шул. Нурания апаңны.

Илүзә. Карт ич инде ул.

Гәрәй. Мин дә карт, йөрисең бит артымнан.

Илүзә. Бабае бар бит Нурания апаның.

Гәрәй. Нәрсә ул безгә бабай?

Илүзә (*көлеп*). Мин сезне шуның өчен яратам, Гәрәй абый!

Гәрәй. Бабай өченме?

Илүзә. Җүләр булганыгыз өчен. Сез дә мине яратасыз.

Гәрәй. Мин сине ни өчен яратырга тиеш инде?

Илүзә. Җүләр булганым өчен. Җүләр бит мин. Сезнең кебек. Менә күрегез. Мин – балерина. (*Биеп күрсәтә.*)

Гәрәй. Тукта. Кеше әллә ни уйлар.

Илүзә. Әйдәгез кеше күрмәгән җиргә. Мәтрүшкә җыярга.

Гәрәй. Нинди афәт соң син? Кит моннан, Барби курчагы!

Илүзә. Курчак белән уйныйлар бит, Гәрәй абый!

Гәрәй. Мин курчак уйнар яшьтән узган. Аңлыйсыңмы?

Илүзә. Юк, аңламыйм.

Гәрәй. Аңлатырлар әле болай йөрсәң. Бәлки инде, аңлатканнардыр да. Нәрсә тасраеп карап торасың?

Илүзә. Менә хәзер аңладым. (*Кинәт борылып китә башлый.*)

Гәрәй. Туктале, кызый! (*Илүзәнең кулыннан тота.*)

Илүзә. Җибәрегез!

Гәрәй. Әйт, нәрсә аңладың?

Илүзә. Сез бүтәннәр кебек үк пошляк икән. (*Чыгып йөгерә.*)

Гәрәй (*Илүзәгә ияреп*). Илүзә! Илүзә!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Шул ук урын, шул ук әрәмәлек. Сихри төн. Дискотека бара. Шау-шу. Көчле музыка. Ял итәргә килүчеләр теләсә нинди бию хәрәкәтләре ясап сикерәләр, селкенәләр, калтыраналар. Барыннан да бигрәк Нурания рәхәт чигә.

Нурания (*ниһаять, биючеләрдән читкәрәк китеп ава*). Уф, үләм! Бәлки инде, үлгәнмен дә, оҗмахтыр бу. Рәхмәтләр яусын сиңа, Гәрәй!

Гәрәй. Миңа түгел, Айдар Исламовичка рәхмәт.

Нурания. Белмим, белмим. Бөтенегезгә рәхмәт. Путиныгызга да рәхмәт, Шәймиевебезгә дә рәхмәт! Ятсын әле Нургали өйдә берүзе бикләнеп, сагынсын әле Нураниясен. Торырга булыш әле, Гәрәй! Тагын бер үлгәнче биим әле. (*Магнитофон белән идарә итүче Галәүгә.*) Кызларныкын биедем. Инде

үзебезнекен дә биик. Килегез әле, кызлар, тотынышыгыз әле кулларыгыз белән. Син, Илүзә, уртага чыгып бас әле.

Кызлар түгәрәк ясап тезелә.

Башладык. (*Җыр башлый.*)

Уртага чыктың да бастың,
Кемдә синең уйларың?
Уйлаган уйларың белән
Үтсен иде туйларың...
Талы, талы, талы бөгелеп тора,
Тагын бер күрәсе килеп
Үзәк өзелеп тора.

«Талы, талы» дигәндә, биеп торырга кирәк. «Талы, талы» дип, барыгыз да җырлагыз. (*Барысы да «талы, талы»ны кабатлыйлар. Илүзә биеп тора.*)

Нурания. Берәрсенә бас. Ул уртага чыксын. Үзең безгә кушыл. (*Җырлый башлый.*)

Сөям сине, сөям сине,
Сөям сине, чәчәгем;
«Сөймә мине, сөй башканы»
Дигәнче сөячәгем.
Талы, талы, талы бөгелеп тора,
Тагын бер күрәсе килеп
Үзәк өзелеп тора.

Яшьләргә бу уен ошый. Нураниягә кушылып җырлыйлар, бииләр.
Уртага Гәрәйне дә чыгаралар.

Әй, дускаем, буең зифа –
Тал кебек бөгеләсең.
Таллар кебек бөгеләсең –
Кем өчен өзеләсең?
Талы, талы, талы бөгелеп тора,
Сагындым, күрәсем килеп
Үзәк өзелеп тора.

Көй «Дубыр-дубая»га күчә.

Су буена төшкән идем –
Су буйлары каз гына.
Күп уйласаң саргаерсың,
Уйламый тор аз гына.
Һай дубыр-дубая,
Вай дубыр-дубая,
Зәңгәр яулыгыңны бәйләп
Кая бардың син бая?
Су буена төшкән идем –
Су буйлары әрәмә;
Бик ялынгач, бер үптердем,
Әнкәй, зинһар, әрләмә.
Һай дубыр-дубая,
Вай дубыр-дубая,
Кыска итәгеңне киеп
Кая бардың син бая?

Бию, сәхнәгә генә сыймыйча, залга да күчәргә тиеш. Бию, кабат сәхнәгә
кайткач, кинәт туктый. Барысы хәлдән таеп егылалар.

Нурания. Үләм! Үләм! Гәрәй! Гәрәйҗан! Тагын нишләтәсең безне?!
Гәрәй. Сулыш алыгыз бераз.
Нурания. Кирәкми! Үләргә икән, биеп үләргә. Җылап үлде, димәсеннәр, биеп үлде, дисеннәр.
Галя. Давайте женим Гарай Хамитовича! Туй сыграем.
Гәрәй. Ты чего, Галябану? Какой туй?

Галя. Сколько можно ходить в холостяках. Все надеемся на тебя. Поженим, девочки?

Бу идея барысына да ошый. «Өйләндерәбез! Өйләндерәбез!» дип кычкыралар.

Нурания. Валлаһи, дөрес бит бу. Кызлар ымсындырып йөрмәсен, койрыгын бозга катырырга кирәк.

Галя. Девочки, стройтесь! Гарай Хамитович невесту будет выбирать.

Нурания. Әйдәгез, тезелегез! Сайла, Гәрәй!

Гәрәй (*уенны кабул итеп*). Сайларгамы? Тәк... тәк... Син бармыйсың, Нурания апа. Беренчедән, кияүгә чыгарга яшең тулмаган, икенчедән, Нургали абзыйны беләм мин, сиңа өйләнсәм, икебезнең дә ботыбызны сугып сындырачак. Галя, Галина, Галябану, выйдешь за меня замуж?

Галя. Выйду!

Гәрәй. Не выйдет, Галочка! Ты замечательная, прелестная, очаровательная, таинственная девочка...

Нурания. Нинди девочка булсын, ике баласын Николаена калдырып килде.

Гәрәй. Дәшмә, Нурaниякәй! Монда хатыннар юк, монда кызлар гына.

Галя. Правильно, дөрес! Приедем домой, станем бабами. Здесь все девочки. Выбирайте, Гарай Хамитович!

Гәрәй. Значит так, милая Галочка, я при всей моей любви к тебе, не могу жениться на тебе. Во-первых, я – мусульманин, во-вторых, я – магометанин, в-третьих, ваххабист.

Галя. Вы же безбожник, Гарай Хамитович!

Гәрәй. Тем более. Не хочу портить замечательную биографию прелестной Галочки. (*Гөлинә янына туктап.*) Гөлинә!.. Гөлинә!.. Чыгасыңмы миңа, Гөлинә?

Гөлинә. Чыгам, Гәрәй абый!

Гәрәй. Ярый, мин бу турыда уйлап карармын. Тәк... Галия чутка керми. Егете бик усал... Нигә бер сүз дә дәшмисең, Галия?

Галия. Мин сине күрмим бит, Гәрәй!

Гәрәй. Бөтенләйме?

Галия. Кичерәйгәннән-кичерәя барасың. Ә син мине күрәсеңме?

Гәрәй. Ике булып күренәсең.

Нурания. Егете юк аның.

Гәрәй. Син беләсеңме, Нурания апа, мин беләмме? А-а-а, Сәкинә!.. Ул да чутка керми, Минтимере бар. Хәтта мин аны сайласам да, ул миңа чыкмас иде. Дөресме, Сәкинәкәй?

Сәкинә. Дөрес!

Илүзә (*чәчрәп чыгып*). Мин чыгам Гәрәй Хәмитовичка! Берегезгә дә бирмим. Аласызмы мине, Гәрәй Хәмитович?

Гәрәй (*каушап калган*). Синең чират җитмәде бит әле.

Илүзә. Мин чиратсыз керергә өйрәнгән. Әйтегез, нишләргә безгә? Кем регистрация ясый, кем никах укый? (*Югалып калган Гәрәйне, җитәкләп, агач янына алып килә.*) Туй өстәленең башы шушында булыр. Кияү белән кәләш шунда утыра.

Нурания. Туктагыз, монда әле башкода бар. Сорашмыйча, белешмичә кыз биреп булмас. Гәрәй Хәмит улы Ганибаев, син Илүзә... Илүзә, әтиеңнең исеме ничек?

Илүзә. Мөхәммәт.

Нурания. Гәрәй Хәмит улы, син Илүзә Мөхәммәт кызын үзең теләп кәләшлеккә алдыңмы?

Илүзә. Алды, алды!

Нурания. Синнән сорамыйлар. Чиратыңны көт.

Егетләрнең егете,
Күп кызларның өмете –
Хәмит углы Гәрәйҗан,
Башың белән йөрәгең
Үзләренә кирәген
Белеп сайладылармы?
Мөхәммәт кызы Илүзәне
Үз итеп алдылармы?

Хор. Хәмит углы Гәрәйҗан,
Мөхәммәт кызы Илүзәне
Кәләшлеккә алдыңмы?

Гәрәй. Мөхәммәт кызы Илүзә
Шундый итеп карады.
Хәмит углы Гәрәйҗан
Каршы килә алмады.

Хор. Үзең теләп алдыңмы?

Гәрәй. Алмый кая барасың,
Табалмагач чарасын.
Хор. Үзең теләп алдыңмы?
Гәрәй. Алдым!
Нурания. Асылларның асылы,
Йөрәккәе ярсулы
Мөхәммәт кызы Илүзә,
Башың белән йөрәгең
Үзләренә кирәген
Белеп сайладыlармы?
Хәмит углы Гәрәйҗанны
Үз итеп бардылармы?
Хор. Мөхәммәт кызы Илүзә,
Хәмит углы Гәрәйҗанга
Үзең теләп чыктыңмы?
Илүзә. Хәмит углы Гәрәйҗан
Миңа сөеп карады,
Мөхәммәт кызы Илүзә
Аны гына сайлады.
Хор. Үзең теләп чыктыңмы?
Илүзә. Чыкмый нишли аласың,
Табалмагач чарасын.
Хор. Үзең теләп чыктыңмы?
Илүзә. Чыктым!
Нурания. Туй! Туй! Галәветдин, нәрсәң бар, уйнат!
Галәү. Миндә дискотека гына.
Нурания. Хәчтерүш! Ыргыт магнитофоныңны, үзебез җырлыйбыз.
Хор. Туй! Туй! Туй итәбез,
Парсызны парлы итәбез.
Котлы булсын туйларыгыз,
Бергә булсын уйларыгыз.
Котлы булсын, Гәрәй, туең,
Сиңа – чын, безгә – уен.
Туй! Туй! Туй туйлыйбыз –
Туй ясап уен уйныйбыз.
Котлы булсын бәйрәмегез,
Тәмле булсын чәйләрегез.
Бу, Илүзә, синең туең,
Сиңа – чын, безгә – уен.

Илүзә. Туктагыз! Мин киявем белән вальс әйләнергә телим. (*Гәрәйне, җитәкләп, уртага алып чыга. Аны, әйләндереп, сәхнә алдына алып килә.*) Нигә җебедегез, Гәрәй Хәмитович! Елмаймыйсыз да. Җитди булу сезгә килешми.

Гәрәй. Син нәрсә кыландырасың?

Илүзә. Кияүгә чыктым ич. Ирем белән биергә хакым бар. (*Әйләндереп, уртага алып килә.*) Әйдәгез, күз йомыш уйныйбыз, кияүнең күзен бәйлибез, ул мине тотарга тиеш.

Гәрәйне уратып алып, яулык белән күзен бәйлиләр.

Илүзә. Син мине күрәсеңме?

Гәрәй. Юк!

Илүзә. Күрмәсәң, эзлә! Чур!.. (*Баскан җирендә катып калган Гәрәй тирәсендә әйләнеп йөри дә кочагына керә.*)

Галя. Горько! Горько!

Гәрәй, Галя янына барып, аны үбеп ала.

А причем я?

Гәрәй. Тебе же горько, Галочка!

Галя. Невесту целуй.

Гәрәй. Невеста еще несовершеннолетняя.

Галя. Ха!

Илүзә. Че ха? Мин әле сабый гына. Беләсегез килсә, мин Гәрәй Хәмитовичның кызы. Ул моннан ун ел элек минем унсигез яшьлек әниемне алдап киткән. Тугыз айдан мин туганмын. Исәнме, әтием! (*Гәрәйнең муенына асылына.*)

Гәрәй. Нишлисең син, тиле?

Илүзә. Мин тиле түгел, әтием! Нәрсәнең ни икәнен аңлап өлгермәгән кызый. Туй өзелә, хөрмәтле кунаклар! Әтиләр үз кызларына өйләнә алмый.

Нурания. Әйдәгез су керергә. Төнлә дә коенып карыйм әле. Сагынып сөйләрлек булсын.

Шаулашып чыгып китәләр. Гәрәй, Галия, Галәү калалар.

Галия. Галәү кая китте соң ул, күренми?

Гәрәй. Әнә ич.

Галия. Кайда? Күрмим ич. Барысы да, Галәү, диләр, мин күрмим. Нишләп әле син боегып калдың?

Гәрәй. Нинди кыз соң бу сары баш?

Галия. Син бит кызлар күңеленең докторы! Кемгә нишләргә кирәклеген өйрәтеп йөрисең. Бар, су кызларын күзлә.

Гәрәй чыгып китә.

Галәветдин, син мондамы соң?

Галәү. Монда, Галия! Син һаман да мине күрмисеңме?

Галия. Күрәм дә кебек, күрмим дә кебек. Ике күзеңнән нур чәчелә.

Галәү. Минем күзләр түгел ул, Галия! Автобус фарасы яктырта.

Галия. Шулаймыни, Галәветдин! Бигрәкләр ышанучан инде син. Сине бик күрәсем килә бит, Галәветдин! Кайчан күренә башларсың икән?

Галәү. Күп калмады, Галия! Тиздән төнге унике тула. Беләсеңме, Галия, сиңа күренми йөрү минем үземә ошый. Әгәр дә кешеләр бер-берсен күрмичә генә сөйләшсәләр, бәхетлеләр күбрәк булыр иде. Гәүдә белән гәүдә түгел, җан белән җан гына сөйләшер иде. Фәрештәләр күренми йөргәнгә, кешеләр аларга кызыгалар.

Галия. Боларны син үзең уйлап таптыңмы, берәрсеннән ишеттеңме?

Галәү. Мин дә уйлый беләм бит, Галия!

Галия. Фәрештәләрнең җенесе юк ич, Галәветдин! Алар колак яфрагыннан үбә белмиләр.

Галәү. Көлмә инде, Галия! Әгәр дә мин күренә башласам, минем белән шулай сөйләшерсеңме, Галия? Мине «пешмәгән» дип мыскыл итмәссеңме?

Галия. И минем пешмәгәнем, и минем җебегәнем, дип иркәләрмен.

Галәү. Кит инде. Алай булмый инде ул.

Галия. Ә син мине кысып кочакларсың да мине эретеп җибәрерсең.

Галәү. Яныңа килгәнемне сизәсеңме, Галия?

Галия (*Галәүне капшап*). Бу синме?

Галәү. Әллә кулларың мине сизә башладымы? (*Галияне кочагына алып.*) Мин шундый да сизәм синең барлыгыңны, Галия! Әгәр дә бүген, туй ясаганда, миңа пар сайларга кушсалар, мин сине генә сайлар идем, Галия! Ул уен туй булмас иде, чын туй булыр иде.

Галия. Галәветдин, бәгырькәем, син күренә башладың бит! Менә синең йөзең. Менә чәчләрең.

Галәү. Унике тулды дамыни?

Галия. Тулды, Галәветдин!

Галәү чыгып йөгерә. Аның артыннан «Галәветдин!» дип Галия чаба.
Каршысына Гәрәй очрый.

Гәрәй. Төнге сәгать уникедә кая чабасың, Галия?

Галия. Галәветдин күренә башлады. (*Чыгып чаба.*)

Гәрәй (*агачка элеп куйган гитарасын ала. Чиртеп, «Хәмдия» көенә җыр башлый.)*

Күк тулы йолдызлар, ай кайда?
Янмаган йөрәккә май кайда?
Гәрәйҗанның кара чәче
Яңа агарган чагы.
Гәрәйҗанга сүз әйтмәгез,
Зиһене таралган чагы.
Җүләр сатып яшәп ни файда?
Бүтәнчә яшәргә җай кайда?
Гәрәйҗанның кара чәче

Яңа агарган чагы.
Гәрәйҗанга сүз әйтмәгез,
Зиһене таралган чагы.

(*Илүзәне күреп, җырын дәвам итә.*) Тагын килдеңме, салам баш?

Илүзә. Тагын килдем, чакыргач!

Гәрәй. Чакырмадым бит мин сине.

Илүзә. Чәчем агара, дип җырладың лабаса. Нигә агарганын мин беләм.

Гәрәй. Әйт, нигә?

Илүзә. Вөҗдан газабы кичерәсең, Гәрәй абый! Намусына тап төшермәгән кызны бозыклыкта гаепләдең.

Гәрәй. Гаепләмәдем мин, сүз җае туры килгәнгә генә әйттем.

Илүзә. Гафу үтенмәдең!

Гәрәй. Үтендем бит инде, җанкисәгем!

Илүзә. Тезләнеп гафу үтенмәдең.

Гәрәй (*дүрт аяклап Илүзә каршына килә*). Зинһар өчен, гафу ит мине, салам баш, Барби курчагы, кычыткан чыпчыгы!

Илүзә. Бу сүзләрең өчен гафу үтендермим. Чөнки яратып әйтәсең.

Гәрәй. Яратмыйм мин сине, яратмыйм, яратмыйм!

Илүзә. Яратасың, яратмаган кешенең башыннан сыйпап иркәләмиләр.

Гәрәй. Кайчан, кайчан сыйпадым башыңнан?

Илүзә. Складка товар бушата идегез. Мин үтеп бара идем. Син минем исемдә дә юк идең, сыйпадың да... Син минем сигез яшьтә түгел, унсигез яшьтә икәнлегемне белергә тиеш идең.

Гәрәй. Кем белеп бетергән сине. Йә кәләшлеккә сикереп чыгасың, йә «әти» дисең.

Илүзә. Ир күпмедер дәрәҗәдә хатынының этисе дә булырга тиеш.

Гәрәй. Бу чаклы башың белән нишләп син университетка кермәдең? Училище бетереп бездә кулинар булып йөрисең.

Илүзә. Ә мин пешеренергә яратам. Минем ирем мин пешергән тәмле ризыкны ашарга тиеш. Сөяркәләренең закускасына кызыгырлык булмасын.

Гәрәй. Синең программаң әзерләп куелган.

Илүзә. Плансыз яшәргә ярамый, дип кем әйтә?

Гәрәй. Мин әйтәм. Ләкин минем дә планым бар бит. Мин ирек яратам. Мин унҗиде яшьтән үк акча, товар тирәсендә буталам. Ләкин бер тиенлек тә хилафлык кылганым юк. Чөнки прокурор белән судьядан куркам. Ирегемнән мәхрүм итүләре куркыта. Ирегемнән мәхрүм буласым килми. Ирек яратам мин, салам баш! Ә син, мине үзеңә бәйләп куеп, ирегемне алырга телисеңме? Өйләнсәм дә сиңа, аерып җибәрәм бит үзеңне.

Илүзә. Юк, аера алмыйсың.

Гәрәй. Ник?

Илүзә. Балга кунган чебен очып китә алмый.

Гәрәй. Бу сүзеңә каршы әйтер идем бер сүз, гафу үтендерерсең.

Илүзә. Тезләндереп, диген.

Гәрәй. Тезләндереп.

Илүзә. Менә шулай. Минем сүзне сөйли башладыңмы?

Икебез бер сүзне сөйләрбез,
Икебез атларбыз бер эздән;
Һәр язны бергәләп язларбыз,
Ямь алып һәр җәйдән, һәр көздән.
Кышларның бозлавык юлыннан
Таймыйча бергәләп атларбыз,
Яшьлектә бергәләп кабызган
Учакны сүндерми сакларбыз.
Ал минем учымны учыңа –
Серләрем кушылсын сереңә.
Йөрәкләр йөрәккә ялгансын,
Наз алып береңнән-береңә.

Гәрәй. Ахырзаманда хатын-кыз азар, диләр иде, дөрес, ахрысы.

Илүзә. Ирләр беткәнгә без гаепле түгел. Йолдызларга кара, Гәрәй абый! Алар безнең мәхәббәтебезнең бөреләнүенә шаһитлар. Исеңдә калдыр, Гәрәй абый! Картайгач сөйләшергә сүз булыр. Оныкларыбызга сөйләрбез. Бая Галя «Горько!» дип кычкырганда, мине үпмәдең. Хәзер бурычыңны түлә. Бит уртамнан үбәргә рөхсәт итәм.

Гәрәй. Әй Алла, бар икән күрәселәрем!

Илүзә. Яратырсың син мине, Гәрәй абый!

Гәрәй. Яратмаслык түгел дә инде син. Үз башыма оештырдым бу пикникны. Үзең җавап бирәсең, дигән иде Айдар Исламович. Кил, бас әле янәшәмә.

Илүзә. Нигә, Гәрәй абый?

Гәрәй. Кунакка барганда, биек үкчәле туфли киярсең инде. Вьетнам кызына өйләнгән, димәсеннәр.

Илүзә. Карале, кара, Гәрәй абый, Галәү абый нишләгән ул? Менә сиңа мыштым. Галия апаны кулларына күтәргән. Мине дә күтәр әле, Гәрәй абый!

Гәрәй. Кил! (*Илүзәне култык астына кыстыра.*)

Илүзә (*тыпырчынып*). Алай итмә инде, Гәрәй абый, мин бит чегән баласы түгел!

Гәрәй Илүзәне матур итеп кулларына күтәргәндә, Галияне күтәреп Галәү керә.

Галия. Бәтәч! Төшер, Галәветдин! (*Галәү кулыннан сикереп төшә.*) Сез нишлисез монда?

Илүзә. Сез нишлисез соң?

Галия. Без шаярып кына.

Илүзә. Ә без чынлап.

Галия. Галәветдин, күрәсеңме боларны?

Галәү. Кирәкмәгәнне күрмә, Галия! Мине күрсәң, шул җиткән.

Галия. Сөбханалла, Галәветдин!

Илүзә. Урынны бушатабыз. Әйдә, Гәрәйчик, мәтрүшкә җыярга! (*Гәрәйне култыклап алып чыгып китә.*)

Галәү. Элләгә Гәрәй, дип йөргән идем, тәки эләккән. Чуртан балыгы да кармакка эләкми, ялтыравыклы блеснага элләгә шул.

Галия. Телең ачылды синең, әйеме, Галәветдин!

Галәү. Ачкычы синдә иде бит, Галия!

Галия. Син мине ачуланмассың инде, Галәветдин!

Галәү. Ни өчен?

Галия. Шушы Гәрәйгә өметләнеп йөрдем бит мин.

Галәү. Анысын да беләбез.

Галия. Тагын ниләр беләсең, Галәветдин?

Галәү. Син минем өчен яратылган, шуны беләм.

Галия. Бөтен белгәнебезне әйтешеп бетерик, Галәветдин! Соңыннан гаепләшерлек булмасын. Син инде, Гәрәй ялганына ышанып, мине Галия күрми, дип йөрдең. Мин сине күрдем бит, Галәветдин! Гел күреп тордым. Күрмәгән булып кыландым гына. Ачуланма инде, Галәветдин! Син инде бүтән ышанма Гәрәй ялганына.

Галәү. Рәхмәт әйт син Гәрәйгә, аның ялганына ышанмаган булсам, син һаман да әле мине күрә алмас идең, Галия! Мин дә бит синең мине күргәнеңне белдем, Галия! Пешмәгән булсам да, мин тиле түгел.

Галия. «Пешмәгән» сүзен бүтән әйтмә, Галәветдин!

Галәү. Туйны кайчан ясыйбыз, Галия? Озакка сузмыйк, безгә унҗиде түгел.

Галия. Сиңа ничектер, миңа бүген унҗиде.

Галәү. Кирәкми, яшермә, Галия! Син миңа болай күбрәк ошыйсың. Мин Гәрәй түгел бала-чагага тагылып йөрергә.

Галия (*машина килеп туктаган тавышны ишетеп*). Автобусыңны алып китәләр, Галәветдин!

Галәү. Автобус тавышы түгел бу, иске «Запорожец» тавышы.

Ул арада Нургали керә.

Нургали. Шушындамы?

Галәү. Син кем?

Нургали. Нурания мондамы?

Нурания атылып керә.

Нурания. Нишләп йөрисең, Нургали?

Нургали. Ә син монда нишләп йөрисең?

Нурания. Әйттем ич инде, кунакка барам, дидем.

Нургали. Мишә буенда кунак буламы? Мишәдә балык кына тоталар. Кемнәр белән килдең?

Нурания. Ничек инде кемнәр белән? Үзебезнең коллектив белән.

Нургали. Нигә миңа шулай димәдең?

Нурания. Дисәм, җибәрәсеңмени син?! Йә инде, үз гомеремдә бер гүләйткә чыктым...
Нургали (*Галәүгә күрсәтеп*). Бу кем?
Нурания. Үзебезнең Галәветдин ич, автобус шоферы!
Нургали. Тагын кем бар ирләрдән?
Нурания. Экспедитор Гәрәй генә. Көнләшмә инде, Нургали, алар бит яшьләр.
Нургали (*Галәүгә*). Менә яшь чагында да шундый кәнтәй иде ул! Миңа әйтмичә гүләйткә чыккан да киткән.
Нурания. Ирләрсез, хатыннарсыз гына барабыз, диде Гәрәй.
Нургали (*Галәү белән Галиягә ишарәләп*). Ә болар?
Нурания. Алар ир белән хатын түгел бит.
Нургали. Булмагач, төн уртасында нигә монда торалар?
Галәү. Абзый, син давай төпченмә. Килгәнсең икән, кунак бул.
Галия. Абзый, читкәрәк китеп ызгышыгыз әле. Кияүгә чыгасым килми башлады.
Нургали. Без ызгышмыйбыз, без сөйләшәбез. Ызгышсак, утыз алты ел бергә яшәмәгән булыр идек.
Галия. Сөйләшегез алайса, әйдә, Галәветдин! (*Галәүне култыклап алып, чыгып китә.*)
Нурания. Кеше алдында көлкегә калдырдың. Төнге сәгать бердә килеп төшмәсәң...
Нургали. Синсез йоклый алмыйм мин.
Нурания. Машинаң сүнеп интектермәдеме?
Нургали. «Запорожец» ич ул, «иномарка»!
Нурания. Син мине күрәсеңме, Нургали?
Нургали. Нәрсә, абага чәчәге ашадың мәллә?
Нурания. Үлгәнче биедем, туйганчы коендым. Теге юлы, балыкка килгәндә, «батып үләсең» дип суга кертмәгән идең, бу юлы рәхәтләндем генә. Син кара бу билләремә!
Нургали. Бил ул кызларда гына була. Кыз чагында бар иде ул билең. Хәзер инде оныгыңның биленә карыйлар егетләр.
Нурания. Әйдә, биибез, Нургали!
Нургали. Син нәрсә, ычкындың мәллә?
Нурания. Ычкынасы килә, Нургали! Картаябыз бит, картаябыз.
Нургали. Әллә елый инде.
Нурания. Картаябыз бит!

Үтте дә китте гомерләр,
Чабып узган ат сыман,
Кайда безне сихерләгән
Алсу таңнар, ак томан?
Үтте дә китте гомерләр,
Яшьнәгән яшен кебек.
Яшьлек әйләнеп кайтыр дип,
Алданып яшим кебек.

Шаулашып, су коеныргa киткән кешеләр кайта.

Галя. О-о-о! У нас новый кавалер!
Нурания. Он мой! Никому ни отдам. Таныш булыгыз, кызлар, бу минем Нургалием!

Бөтенесе дә «Исәнмесез, Нургали!» дип, Нургали белән күрешеп китәләр.

Гөлинә. Кешенең ирләре ир кебек, төнге сәгать бердә эзләп табалар, безнеке ятадыр йоклап. Без йоклыйбызмы бүген, юкмы?
Илүзә. Юк, бүген йоклый торган төн түгел. Галәү абый! Галәү абый!

Галия белән Галәү керәләр.

Галия. Ни булды, нигә кычкырасың?
Илүзә. Мин сине түгел, Галәү абыйны чакырдым. Галәү абый, уйнат оркестрыңны! Кызлар! Сез Гәрәй Хәмитовичны күрәсезме?
Тавышлар. Күрәбез!
Илүзә. Күреп калыгыз. Бүтән күралмассыз. Ул хәзер минеке. Бары тик минеке генә. Әйт, Гәрәй абый, минекеме?
Гәрәй. Йә инде, булды инде.
Илүзә. Юк, әйт. Кычкырып әйт, ишетсеннәр. Без аның белән мәтрүшкә җыярга бардык һәм үбештек.

Гәрәй. Син нәрсә, үбешмәдек.

Илүзә. Син үбәргә уйладың, мин дә каршы килмәдем. Үбешү турында уйлау үбешүдән татлырак, Гәрәй абый!

Гәрәй. Галәү, җибәр инде музыкаңны! Нәрсә йокладың?

Галия. Син аңа кычкырма, Гәрәй Хәмитович! Ул синең хезмәтчең түгел. Галәветдин, уйнат бию көен! (*Нураниягә.*) Биибезме, Нурания апа?

Нурания. Олы кешегә килешмәс, Галия! Нургали дә...

Нургали. Нәрсә Нургали... Биергә кымырҗып торасың бит инде.

Нурания. Әллә сизеләме, Нургали? Бераз гына биим дә кайтырбыз, ярыймы.

Илүзә (*Гәрәйне читкәрәк алып китеп*). Син мине күрәсеңме, Гәрәй абый!

Гәрәй. Күрәм инде, күрәм.

Илүзә. Елмаеп, шатланып, куанып әйт, Гәрәй абый!

Гәрәй (*Илүзәнең башыннан сыйпап елмая*). Күрәм!

Илүзә. Күрсәң, бүтәннәргә карама, ярыймы. Үкенмәссең, Гәрәй абый! Мин сине дөньяда иң бәхетле кеше итәрмен.

Һай дубыр-дубая,
Вай дубыр-дубая.

Шуны гына көткәндәй, Галәү дә шул көйне кабыза. Бию башлана. Иң кызган чагында гына музыка туктый. Кем нинди хәрәкәт ясаган, шул көе басып кала. Илүзә Гәрәйнең муенына асылынган, Галәү Галияне кулына күтәргән, Нурания – Нургали кочагында.

Пәрдә.

# Ак тәүбә, кара тәүбә

*Ике пәрдәле, дүрт күренешле тамаша*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Ризван
Низам студентлар.
Заһир
Гомәр.
Тәнзилә.
Алинә – авылда клуб мөдире.
Нәҗми – гармунчы егет.
Дамирә – Низамның сөйгән кызы, студентка.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### БЕРЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Тар гына елганың яшел үләнле яры. Юан гына ике тирәк үсеп утыра. Елга аша басма салынган. Вакыт кич. Пәрдә ачылганда, Ризван, Низам, Заһир зур гына чатырның соңгы бавын казыкка бәйләп торалар. Гомәр бер читтәрәк, берүзе ике тирәк арасына гамак бәйләп маташа. Өч егет чатыр бавын бәйләп куялар да Гомәрнең азапланганын күзәтәләр.

Ризван. Аерым хуҗалыкка дөнья көтүләре һәрвакытта да авыр булган.

Низам. Коллективтан аерылганны аю ашаган.

Заһир. Ялгыз башка кайда да бер –
Таң ата да кич була.

Гомәр эндәшми генә бәйләвен дәвам итә.

Ризван. Һәрбер хуҗалык үзе өчен генә тырышканга, крестьян восстаниеләре җиңелүгә дучар булган.

Низам. Бөтен коллектив – уң якка, ул берүзе сул – якка...

Заһир. Ялгыз башың, түгелер яшең,
Кемнәр булыр юлдашың?

Гомәр гамакны бәйләп бетерә дә, гамак өстенә менеп, аякларын бөкләп

утыра.

Ризван. Тәхеткә үзе менеп утырган бер генә патшаның да уңышка ирешкәне булмаган.
Низам. Гамак өстендә берүзең солтан булганчы, палатка эчендә коллективның олтаны бул.
Заһир. Өскә менгән – егылып төшкән,
Егылып төшеп башын тишкән.
Гомәр (*тирәк ботагында эленеп торган гитараны кулына алып, кылларын чиертә*).
Көлегез, көлегез,
Файдасы юк – белегез.
Ризван. Оппортунист!
Низам. Ренегат!
Заһир. Индивидуалист!
Гомәр. Көнләшегез, туң күчәннәр!
Низам. Бик исебез китте, әйеме, кызлар?
Ризван. Вакытны уздырмыйк. Килегез, тезелегез!

Сәхнә алдына килеп басалар.

Ризван. Антның текстын укыйбыз. «Без, Төзелеш академиясенең дүртенче курс студентлары, җәйге каникулыбыз вакытында, аерым бригада оештырып, авылда Культура сарае төзелешенә эшләргә килдек».
Гомәр (*гамак өстеннән*). Ха-ха!
Ризван
Низам
Заһир
Гомәр. Шабашкага килдек.
Ризван. Без шабашниклар түгел, намус белән акча эшләүчеләр. «Без – Низамов Ризван, Рамазанов Низам, Закиров Заһир тантаналы рәвештә ант итәбез: эшләү чорында бөтен ихтыяр көчебезне бары тик эшкә генә тупларга, бары тик башкарылачак эш турында гына уйларга. Бу максаттан читкә тайпылуларга юл куймаска».
Гомәр. Ха-ха!
Өч егет (*Гомәр ягына борылып*). Нәрсә ха-ха?
Гомәр. Бирелгән антыгыз ха-ха булачак!
Ризван. Болай булмый. Әйдәгез, шул карганың оясын туздырабыз, очсын безнең яннан.

Өчәүләп Гомәр янына баралар.

Өч егет (*берьюлы*). Очып кит безнең яннан, эзең булмасын.
Гомәр. Кая телим – шунда кунам. Мин ирекле кош. Кошларга тимәгез, балалар, табигатьне яратыгыз!
Ризван. Алайса, телеңне тый!
Гомәр. Аңлашылмый, әфәнделәр?!
Заһир. Ә нәрсә аңлашылмый?
Гомәр. Сез мәхәббәт дигән бөек хисне ваклыйсыз. Гашыйк булу, имеш, эшкә комачаулый. Ялгышасыз, әфәнделәр. Тормышның үзәге – мәхәббәт!
Низам. Дөрес түгел! Мәхәббәт кешене акылдан яздыра. Гашыйк булган кеше төн йокламый. Йокламаган кеше ябыга. Ябык, хәлсез кешедән нинди эш көтмәк кирәк.
Гомәр. Дөньядагы барлык гашыйклар ябык, хәлсез, дип әйтергә телисеңме, Заһир әфәнде?
Заһир. Без бит, мәхәббәт кирәкми, димибез, Гомәр... Без вакытлыча...
Ризван. Туктагыз! Димәк, болай: антның текстын кабул итәбез һәм ант итәбез.
Өч егет (*берьюлы*). Ант итәбез, ант итәбез, ант итәбез!
Гомәр. Әфәнделәр! Ашыгасыз, әфәнделәр! Антыгызның шарты юк. Антын бозган кешене нишләтмәкче буласыз?
Ризван. Безгә шарт кирәкми
Гомәр. Шартсыз ант булмый, әфәнделәр. Телисезме, мин сезгә ярдәм кулымны сузам? Антын бозган кешегә җәзаны үзем билгелим.
Низам. Нишләтерсең икән, Гомәр?
Гомәр. Мин рәхимсез булачакмын! Ризамы?
Низам. Ризван, нишлибез?
Ризван. Курыкмаска! Сер бирмәскә!
Гомәр. Димәк, өчегез дә риза?
Заһир. Мин риза.

Гомәр. Син, Низам?
Низам. Беткән баш беткән!
Гомәр. Син, Ризван?
Ризван. Мин дәшмим.
Гомәр. Дәшмәү – ризалык билгесе, Аллага тапшырыгыз.
Низам. Инде нишлибез, Ризван?
Ризван. Палатка тирәсен бау белән әйләндереп алабыз, безнең территориягә бер кыз да аяк басмаска тиеш.

Чатыр эченнән бау алып чыга. Өчәүләп бау сузалар. Гомәрнең гамагы янына җиткәч туктыйлар.

Низам. Гомәрне нишләтәбез, үзебезнең территориягә кертәбезме?
Ризван. Үзенең мәхәббәте белән читтә калсын.
Гомәр (*гамак өстенә басып*). Калырмын да! Йөрәгемдә ут янганда, тәнемдә җан барында беркайчан да, теләсә нинди очракта да һәр минутта, һәр секундта кызлар сөюдән туктамам, йөрәгем утына су сипмәм. Беләгемнең көче эш өчен, йөрәгемнең хисе мәхәббәт өчен!
Ризван. Суз бауны!

Гомәрнең «биләмәсен» кырыйда калдырып, бауны суза-суза, сәхнәдән чыгып китәләр. Гомәр кулына гитарасын алып җыр суза.

Күңелдә җыр туа,
Күңелгә нур тула,
Талларда
Таңнарда
Сандугач сайраса, моңланса;
Сандугач кунармы талларга,
Сандугач сайрармы таңнарда,
Бу җирдә мәхәббәт булмаса?

Өч егет, бауны сузып бетереп, сәхнәгә керәләр.

Низам (*Гомәргә*). Җырлыйсың, ә?
Гомәр. Җырлыйм.
Ризван. Үзең генә җырлыйсың?
Гомәр. Икәү. Кулымда җан дустым – гитара бар. (*Җырын дәвам иттерә.*)

Юл чыгу читен лә,
Юлыңның чигендә,
«Кил» диеп
Елмаеп,
Бәхетең чакырып тормаса;
Бәхет соң буламы дөньяда,
Дөньяда яшәүдән ни файда,
Бу җирдә мәхәббәт булмаса?

Ризван. Ә без өчәү булгач гитарасыз да җырлыйбыз. Әйдәгез, җырларга!
Заһир. Кайсы җырны?
Ризван. Үзебезнең гимнны. Килегез!

Сәхнә алдына киләләр, тезләнәләр.

Башладык. Үзем башлыйм.
Беләктә көчебез барында,
Эшлисе эшебез барында,
Онытып дөньяда барын да,
«Эш» диеп әйтәбез тагын да.
Бергә. Ант итәбез!
Ант итәбез!
Ант итәбез!
Низам. Зөһрәләр безгә һич кирәкми,
Ләйләләр безгә һич кирәкми,
Тышаулап куябыз йөрәкне,
Җигәрбез эшкә без беләкне.

Бергә. Ант итәбез!
Ант итәбез!
Ант итәбез!
Заһир. Эш кенә тормышның тоткасы,
Эш кенә дөньяның ноктасы;
Куертмыйк мәхәббәт боткасын,
Йөрәкләр ял итсен, йокласын.
Бергә. Ант итәбез!
Ант итәбез!
Ант итәбез!

Гомәр. Аккомпаниатор җитми, әфәнделәр. Миннән башка барыбер эшегез барып чыкмас.

Низам. Чыкмаса чыкмас, ялынып бармабыз.

Ризван. Болай сөйләшәбез: Гомәр Шәйхетдинов белән араны өзәргә, һичнинди мөнәсәбәткә кермәскә, соравына – җавап, җавабына сорау бирмәскә! Чөнки ул, әлеге көнгә кадәр безнең белән дус булып йөреп, бүген безгә хыянәт итте. Әйдәгез, палатка эчен тәртипкә китерәбез.

Өчәүләп чатыр эченә кереп китәләр. Тәнзилә керә.

Тәнзилә. Хәерле кич, Гомәр!

Гомәр. Хәерле кич, мадемуазель!

Тәнзилә. Урнашып беттегезме?.. Син ял йортына килгән кебек.

Гомәр. Көндез эштә, төн гамакта яшәп гомер итәбез.

Тәнзилә. Калган өчегез кайда?

Гомәр. Чатыр эчендә.

Тәнзилә. Бу бау ни өчен?

Гомәр. Сере бар.

Тәнзилә. Кыланасыз, егетләр! Башкалар белән бергә авылда яшәсәгез ни була?

Гомәр. Кызык булмый.

Тәнзилә. Сез монда кызык эзләргә килдегезмени?

Гомәр. Эшләрбез, иптәш мадемуазель! Эштән соң калган вакыт та бар. «Көндез эштә, кич клубта комсомолка Гөлсара» дип җырлаган безнең әбиләр, иптәш мадемуазель!

Тәнзилә. Нәрсә мине үртисең?

Гомәр. Ничек үртим? Әллә син мадемуазель түгелме?

Тәнзилә. Минем исемем дә бар. (*Баудан атлап үтмәкче була.*)

Гомәр. Ярамый, Тәнзилә!

Тәнзилә. Нигә ярамый?

Гомәр. Бауның теге ягына кызлар аяк басмаска тиеш.

Тәнзилә. Монысы тагын нинди уен?

Гомәр. Уен түгел, чын. (*Кычкырып.*) Әй, әфәнделәр, тирмәгезнең дивары янында сыйнфый дошманыгыз.

Чатырдан берәмләп егетләр чыга.

Тәнзилә. Хәерле кич, егетләр!

Егетләр. Хәерле кич!

Тәнзилә. Нинди уен уйлап чыгардыгыз? Мине Гомәр бауның теге ягына кертми.

Ризван. Гафу ит, Тәнзилә, бу очракта ул дөрес эшләгән.

Низам. Гомәрнең бердәнбер дөрес эше.

Заһир. Без ант иткән идек, Тәнзилә!

Тәнзилә. Ант? Нинди ант?

Гомәр. Гашыйк булмаска, бер генә кызга да күз салмаска, чибәрләр очраса да, сер бирмәскә ант иттеләр.

Ризван. Без монда эшләргә ялландык, кызлар артыннан чабарга түгел.

Низам. Бу авылда чакта беләгебезнең көче, йөрәгебезнең хисе эш өчен генә сарыф ителергә тиеш.

Тәнзилә. Шулаймыни?

Заһир. Шулай иде шул, Тәнзилә. Шулай бит, Ризван?

Ризван. Әйе, шулай.

Тәнзилә. Тилермәгез, егетләр!

Ризван. Гафу ит, Тәнзилә?! Без тиле түгел, без акча эшләргә килдек.

Низам. Эш турында онытып, төн йокламый кызлар артыннан чапсак, икенче көнне эленке-салынкы эшләсәк ни була?

Тәнзилә. Ләкин...
Ризван. Нәрсә «ләкин»?..
Низам. Нигә «ләкин»?..
Тәнзилә (*көлеп*). Ярый, әйдә кыланыгыз... Тик озакламый су буена төшегез. Авыл яшьләре анда кичке уенга җыела. Танышырбыз, дуслашырбыз.
Ризван. Гафу ит, төшә алмыйбыз.
Низам. Без коллектив биюләр, танцы-манцылар дискотека-мискатека белән мавыкмаячакбыз. Көз көне, чебешләрне санагач, биербез.
Тәнзилә. Шаярмагыз инде, егетләр!
Ризван. Без монда шаярырга килмәдек. Һәм син дә анда-монда йөрмә. Син безнең бригада члены. Безнең аш пешерүчебез.

Тәнзиләгә сырты белән борылып баса.

Низам. Безнең поварыбыз! (*Ризванча эшли.*)
Заһир. Шулай сөйләшкән идек шул, Тәнзилә. (*Теләр-теләмәс кенә борыла.*)
Тәнзилә. Кыланчыклар! Онытмагыз су буена төшәргә. *(Көлә-көлә чыгып китә.)*
Гомәр. Дөрес! Шулай! Нык торыгыз, әфәнделәр! Әмма дә ләкин шунысы бар, Заһирга читен булачак.
Заһир. Ә ни өчен миңа?
Гомәр. Язган шигырьләреңне кемгә укырсың? Аларны бит Тәнзиләдән башка беркем тыңламый.
Низам. Әйт, Заһир, түзәрмен, диген.
Гомәр. Әйтә күрмә, Заһир.
Ризван. Әйт, түзәрмен, диген.
Заһир. Түзәрмен... Тырышырмын.

Низам белән Гомәр көлеп җибәрәләр.

Ризван. Көлүне туктатыйк!

Чатырга кереп китә, аңа Низам белән Заһир иярә.

Гомәр. Көлүне туктатыйк, иптәшләр, комедия башлана. (*Көянтә-чиләк күтәреп узып баручы Алинәне күреп ала.*) Авыл кызына ялкынлы сәлам!
Алинә (*туктап*). Нәрсә-ә-ә?
Гомәр. Авылның чибәр кызына ялкынлы сәлам! Мыскыл итеп әйтмим. Мин үзем дә авыл малае. (*Гамактан сикереп төшеп, Алинә каршына баса.*) Исәнмесез! Минем исемем – Гомәр, фамилиям – Шәйхетдинов.
Алинә. Булса ни.
Гомәр. Сезнең авылга культура учагы кабызырга килдек. Культура йорты салачакбыз.
Алинә. Салсагыз ни.
Гомәр (*Алинәнең бер дә исе китмәвенә аптырап*). Киләсе елда яңа Культура йортына танцыга йөрерсез.
Алинә. Йөрсә ни.
Гомәр. Туктагыз әле, нәрсә һаман ни дә ни. Елгага кер чайкарга төштегезмени?
Алинә. Төшсә ни.
Гомәр. Нәрсә сез мине үртәгән сыман сөйләшәсез?
Алинә. Сөйләшсә ни.
Гомәр. Һе... Менә тутый кош. Һаман бер сүзне тукый.
Алинә. Тукыса ни.
Гомәр (*ачуы чыгып*). Туктатуыма гафу итегез! Юлыгызны дәвам итегез!
Алинә. Итсә ни. (*Китми. Гомәргә туп-туры караган килеш кузгалмый да*).
Гомәр. Сау булыгыз, дим.
Алинә. Дисәгез ни. (*Һаман китми. Селкенми дә.*)
Гомәр (*аптыраганнан көлеп җибәрә*). Менә каптым.
Алинә. Капсагыз ни.
Гомәр. Ярый, ярый, ни, ни, ни. Аңлашылды. Ни икәне аңлашылды. Тик тора белмәсәң, шулай була ул, Гомәр дус.
Алинә. Булса ни.
Гомәр (*кычкыра*). Китегез, китегез моннан тизрәк. (*Ашыга-ашыга гамагына менеп утыра.*)

Алинә һаман да, кузгалмыйча, Гомәргә карап басып тора. Гомәр дә

аңа карап куя.

Алинә. Шуннан ни?
Гомәр. Уф! (*Капланып ята.*)

Алинә һаман китми. Гомәр башын күтәреп караганда да басып тора. Башка түзәр хәле калмагач, Гомәр, гамактан төшеп, чатыр артына кача.
Шуннан башын сузып Алинәне күзәтә. Алинә һаман китми.

(*Чатыр янына утырып, үз-үзенә сөйләнә.*) Кирәк бит, кемгә эләктем бит, тилегә юлыктым бит. (*Башын сузып карый, Алинәнең һаман да китмәгәнен күргәч, чатыр артыннан чыгып, янына килә дә үгетләгән тавыш белән сөйләнергә тотына.*) Бар, сеңлем, кайт инде, әти-әниең көтәләрдер.
Алинә. Көтсәләр ни.
Гомәр. Көтсәләр ни дип, алай ярамый, сеңлем! Үзеңне эзләп чыгарлар. Егетләр янында басып торганыңны күреп ачуланырлар. Син акыллы кыз бит, бар инде кайт. Син бит абыйлар әйткәнне тыңлыйсың, әйеме? Мин синең абыең. Бар, сеңлем, бар!
Алинә. Барса ни. (*Борылып китеп бара.*)
Гомәр (*җиргә утырып*). Уф! Йа Тәңрем, мең рәхмәт сиңа! Чибәрлекне өеп биргән үзенә.

Алинә яңадан әйләнеп керә. Керә дә Гомәр каршына баса. Торaташ
булып каткан Гомәр, телсез калып, Алинәгә карап тора.

Алинә (*чиләк-көянтәсен җиргә куеп, гамак янына килә. Андагы гитараны кулына ала*). Бу ни? (*Гомәр җавап бирмәгәч.*) Бу ни?

Пауза.

Бу ни?
Гомәр (*чыгырыннан чыгып*). Автомобиль!
Алинә (*гитараның кылларына чиертеп куя да кычкырып көлеп җибәрә. Көлеп туйгач*). Йә, ни әйтергә теләгән идегез миңа, Гомәр абый Шәйхетдинов? Безнең авылда Культура йорты саласыз инде, шуннан ни? Шабашниклар инде сез. Шуннан ни? Шуны әйтер өчен туктаттыгызмы инде? Сөйләгез, тыңлыйм сезне, Гомәр абый Шәйхетдинов. Авыл кызын шаккатырырга уйладыгыз инде, ә? Гамак бәйләп куйдыгыз инде тирәккә? Гитара чиертә беләсез инде. Йә, чиертеп күрсәтегез, ничегрәк чиертәсез икән?
Гомәр (*ниһаять, исен җыеп*). Сез ... кем?
Алинә. Авыл кызы. Исемем – Алинә, фамилиям – Шәйхетдинова.
Гомәр. Ничек Шәйхетдинова? Мин – Шәйхетдинов.
Алинә. Мин – Шәйхетдинова.
Гомәр. Юк, мин – Шәйхетдинов.
Алинә. Сез – Шәйхетдинов, мин – Шәйхетдинова. Шәйхетдин исемле кешеләр сезнең авылда гына түгел. Бәлки, сез миңа туган тиешледер? (*Гитара уйнап, чит телдә бер җыр җырлап ала. Гитараны үз урынына куеп, көянтә-чиләкләрен алып, китә башлый.*)
Гомәр (*аның артыннан барып*). Туктагыз әле!
Алинә. Туктамаса ни. (*Чыгып китә.*)
Гомәр. Кем булды соң бу? Нәрсә булды соң бу?

Чатыр ишегендә өч баш күренә.

Ризван. Тешебезне кысып түздек, иптәш Шәйхетдинов.
Низам. Һәрнәрсәнең чиге була, ялгыз булсаң да, коллективны хөрмәт итәргә кирәк.
Ризван. Мәҗбүр итәрбез.
Низам. Узган-барган кызга җүләрләр генә гитара чиертеп кала.
Заһир. Гомәр, ә нигә син ул кызга кычкырдың? Авыл кызына кычкырып, безнең дәрәҗәне төшермә.
Ризван. Кычкырасың килсә, палатка яныннан читкәрәк алып китеп кычкыр.
Низам. Һәм, гомумән, кызлар белән сөйләшәсең килсә, басма өстендә сөйләш.
Гомәр. Туктагыз әле, болай да башым әйләнгән.

Өч егет өчесе дә, чатыр эченнән чыгып, Гомәр каршына басалар.

Ризван. Искитәрлек берни дә юк. Муен тотрыксыз булгач, баш әйләнә инде ул.
Низам. Менә безнең башлар әйләнми.
Гомәр. Кызы чибәр, әфәнделәр.
Заһир. Чибәрләр күп булыр. Әйеме, Ризван?

Ризван. Әйе. Иртәгә эш башлыйбыз. Кызлар турында уйларга түгел, йоклау ягын уйларга кирәк.
Гомәр. Мин ант итмәдем.
Низам. Алайса, безгә комачаулама.
Гомәр. Юкка без сине бригадир иттек, Ризван, приказ биреп җаннарын алырсың инде. Начальник булырга бигрәк яратасың.
Ризван. Юк-бар сүзләрне тыңламаска! Йокларга!
Низам. Йокларга!
Заһир. Йокларга!
Гомәр. Карагыз әле безнең Тәнзиләгә, басма өстендә кем белән басып тора?
Заһир (*атылып Гомәр янына килә*). Кайда?
Гомәр. Качтылар. Очты Тәнзилә.
Ризван. Заһир! Гомәр Шәйхетдинов сүзенә игътибар итмәскә! Йокларга!
Низам. Тузга язмаган сүзләргә колак салмаска! Йокларга!
Заһир. Әйе, йокларга... (*Теләр-теләмәс кенә чатыр ягына борыла.*)

Иңенә тальян гармун аскан Нәҗип керә.

Нәҗип. Исәнмесед! (*Ул Мөслим ягы диалектында сөйләшә.*)
Гомәр. Исән бед!
Нәҗип. Үдебеднең як егете дә бар икән. Кайсы авылныкы, апаем?
Гомәр. Миндәлә.
Нәҗип. Әйбәт. Беднең районнан кала әйбәт кешеләр Миндәләдә. Клуб салырга килдегедмени беднең авылга?
Гомәр. Клуб түгел, Культура сарае.
Нәҗип. Сәхнәле булса, клуб була инде ул. Исемең ничек, апаем?
Гомәр. Гомәр.
Нәҗип (*Заһирга*). Ә синең?
Заһир. Заһир.
Нәҗип (*Низамга*). Ә синең?
Низам. Габделмиңлемөхәммәт.
Нәҗип. Андый исем булмый. Мин алдашкан кешеләрне яратмаем, апаем. Аркам кычыта башлай.
Гомәр. Низам ул.
Нәҗип. Низам? (*Низамга.*) Мине дуракка санама, ярыймы, апаем. Сигез класс бетергән. (*Ризванга.*) Ә син ни исемле?
Ризван. Нигә кирәк ул?
Нәҗип. Әйтәсең килмәймени?
Ризван. Килми.
Нәҗип. Килмәй икән, әйтмә. Безнең авылда яшисең бар, апаем.
Гомәр. Үзегез ни исемле соң?
Нәҗип. Нәҗип. Фермада эшләем мин. Җәен көтү көтәм, кышын тирес түгәм. (*Гомәрнең гитарасын кулына алып.*) Бу каз муенында кайсыгыз уйный?
Гомәр. Мин.
Нәҗип. Яхшы уйнайсыңмы?
Низам. Яхшы.
Нәҗип. Синнән сорамаем, апаем, уйнаучыдан сораем. (*Гомәргә.*) Яле, уйнап күрсәт!
Ризван. Низам! Заһир! Йокларга! Гомәр, бернинди уйнау юк, без йоклыйбыз.
Нәҗип. Нәчәлник мәллә син, апаем, кыланган буласың. (*Гомәргә.*) Уйнап күрсәт.

Ризван чатыр эченә кереп китә. Низам белән Заһир кызыксынып калалар.

Уйнап күрсәт, мин барында курыкма. Районга – глава, авылга мин хуҗа.
Гомәр. Нинди көйне уйныйм?
Нәҗип. «Гөлҗамал»ны.
Гомәр. Аны белмим шул.
Нәҗип (*куанып*). Әһә, белмәйсең. Ә мин беләм. (*Гармунын кулына алып, уйнап җырлый.*)

Шәмдәлләрдә генә утлар яна, Гөлҗамал,
Җиткән кызлар киндер-җеп эрлиләр.
Энҗе-мәрҗән кызларның кул бавы,
Авыр җан сөйгәннәрнең булмавы.

Булдымы?
Гомәр. Булды.
Нәҗип. Әйдә, син дә булдыр.
Гомәр. Алай тиз генә булмый ул.
Нәҗип. Булмаймы? Уйна мин белмәгән көеңне.
Гомәр. Туктагыз әле...
Нәҗип. Туктамаем. Уйна! (*Низам белән Заһирга.*) Уйнасынмы?
Низам. Уйнасын, уйнасын.
Нәҗип (*Заһирга*). Нигә син уйнасын дип әйтмәйсең, апаем?
Заһир. Уйнасын.
Нәҗип (*Гомәргә*). Уйна!
Гомәр. Әкәмәт! (*Әлегә хәтле ишетелмәгән яңа көйне уйный.*)
Нәҗип (*бераз вакыт колагын салып тыңлап торгач*). Тукта!

Гомәр туктый.

(*Шул көйне гармунда уйный.*) Булдымы? Әйдә миңа кушыл. (*Икәүләп уйнагач.*) Кайда синең каз муеныңның тавышы? Гармун бугазлап ташладымы? Егет булсаң, дыңгылдатма бу каз муеныңны, гармунга өйрән. Гармун орып бирә синең бу каз муеныңны. Дөресме?
Низам. Дөрес, дөрес!
Нәҗип (*Заһирга*). Син нигә дөрес дип әйтмәйсең, апаем?
Заһир. Һәр инструментның үз урыны.
Нәҗип. Струмент, струмент... Ышкы да струмент, өтергә дә струмент, бу да струмент. Гармун струмент түгел, гармун ул гармун. Алинә дә шул каз муенында уйнавы белән мактанган була. Шуны кулларына тоталар да әллә кем булалар. (*Еларга җитешеп.*) Минем күзем төшеп йөргән кыз каз муенын уйнаучы синең кебек шабашникка ияреп китте. Алты ел сүз әйтергә дә оялып яратып йөрдем. Уналты яшемнән егерме икегә хәтле. Алты ел тәрәзә төпләреннән гармун уйнап уздым – сизмәде. Иярде дә китте. Сезнең кебек берәү өченче ел сыерлар абзары салырга килде дә, каз муенын уйнап, Гөлнарны иярттеп китте. Эх! (*«Авыл көе»нә сыздырып җибәрә.*)

Гармун бәләкәй булса да,
Әйтә ул кирәкләрен.
Сикер дә төш, чум суларга,
Янса яшь йөрәкләрең.

Шаярмагыз, апайлар, шаярмагыз гармун белән. Бер нәрсә белән дә шаярмагыз. (*Кинәт борылып чыгып китә.*)

Пауза.

Низам (*кинәт көлеп җибәрә*). Шаярмагыз, кызлар!
Гомәр. Ни булды соң бу? Каян килеп чыкты?
Ризван (*чатыр эченнән*). Йокларга!
Заһир. Шаярмагыз, ди. Мәгънәсе бар бугай бу сүзнең?..
Нәҗип (*яңадан әйләнеп кереп*). Безнең авылда бер кыз бар. Хәзер минем күзем аңа төшеп йөри. Карагыз, апайлар, әгәр дә башын әйләндерсәгез, барыгызны бергә өеп куеп ярам. (*Чыгып китә.*)
Низам. Күрдеңме, Заһир, мәгънәсен? Ишеттеңме, Гомәр? Шаярма, дидеме сиңа?
Ризван (*чатыр ишегеннән башын тыгып*). Йокларга!
Гомәр. Миңа нәрсә, сез нишләрсез? Син нишләрсең, Низам? Кызлар күрсәң, күзләрең зырылдап әйләнә башлый.
Низам. Сер бирмәбез дошманга. (*Чатырга кереп китә.*)
Гомәр (*Заһирга*). Ә син?
Заһир. Син Тәнзиләне чынлап күрдеңме? Егетләр белән идеме?
Гомәр. Кызлар белән басма өстендә йөрмәс инде.
Ризван (*чатыр эченнән*). Йокларга!
Заһир. Йөрсен. Анысы аның эше. (*Чатырга кереп китә.*)

Гомәр, гамакка менеп утырып, гитара чиертеп, «Гөлҗамал» көен уйнап азаплана. Тәнзилә керә.

Тәнзилә. Кайда егетләр?
Гомәр. Йоклыйлар.
Тәнзилә. Ничек йоклыйлар?

Гомәр. Ничек йоклаганнарын белмим, Тәнзилә, кереп карамадым.
Тәнзилә. Син гитараңны әйбәт уйныйсың, Гомәр, ләкин сөйләшкәндә тапкырлыгың җитеп бетми.
Гомәр. Ягъни мәсәлән?
Тәнзилә. Әллә алар чынлапмы?
Гомәр. Чынлап, Тәнзилә.
Тәнзилә. Арттырып җибәрәсез. Син аларга кушылмадыңмы?
Гомәр. Кушылмадым. Программалары белән килешеп бетмим.
Тәнзилә. Әйдә, алайса, су буена.
Гомәр. Мин бит шигырь язмыйм, Тәнзилә.
Тәнзилә. Гомәр, әгәр минем белән болай сөйләшсәң, мин, гомумән, синең белән сөйләшмәячәкмен.
Гомәр. Тәүбә, тәүбә, Тәнзилә.
Тәнзилә. Әйдә. Анда синең гитараң кирәк.
Гомәр. Булмый.
Тәнзилә. Нигә?
Гомәр (*чатырга күрсәтеп*). Аларны ташлап китә алмыйм. Программалары белән килешмәсәм дә, мин алар компаниясендә. Алар барса – барам, бармаса – юк.
Тәнзилә. Юкка сезгә иярдем, ахрысы. Күңелсез сезнең белән. (*Чыгып китә.*)
Гомәр. Күрдегезме, әфәнделәр, кадеремне белегез, мин дә сезнең белән калдым. Йоклагыз, матурларым. Хәзер мин сезгә бишек җыры җырлыйм.

Әлли-бәлли итәрләр болар,
Черем итеп китәрләр болар,
Ниләр эшләп бетәрләр болар,
Әлли-әлли, әү-әү, бәлли-бәлли, бәү-бәү.
Тавыклар да йокламый әле,
Балыклар да йокламый әле,
Халыклар да йокламый әле,
Сез тынычлап йоклагыз, яме.
Әлли-әлли, әү-әү, бәлли-бәлли, бәү-бәү.

Гитара аскан Алинә керә, Гомәрнең бишек җырын тыңлап тора.

Алинә. Абыйга ялкынлы сәлам!
Гомәр (*куанып, Алинә каршына килә*). А-а-а, Алинә! Сәлам, Алинә!
Алинә. Абыемның тавышы әйбәт булмаса да, ярыйсы икән. Нишләп әле су буена бармыйсыз? Әйдәгез!
Гомәр (*чатырга күрсәтеп*). Менә саклыйм.
Алинә. Нәрсә соң анда?
Гомәр. Минем егетләр. Алар кич җиткәч беркая да чыкмаска, кызлар күзенә күренмәскә ант иттеләр.
Алинә. Оялчаннармыни?
Гомәр. Түгел дә... Авыл кызларының берәрсе гашыйк итеп куймагае дип куркалар.
Алинә. Хәзердән үк йокларга яткан егетләр кемгә кирәк?!
Гомәр. Кирәкми дә бит... Ә мин ант итмәдем, Алинә, аны-моны уйлый күрмәгез. Әгәр дә сез тагын бер тапкыр, әйдә су буена, дип әйтәсез икән, мин барам.
Алинә. Рәхмәт инде. Саклагыз – урламасыннар. (*Китә башлый.*)
Гомәр. Алинә, ташлап китмәгез. Әйдә дип әйтмәсәгез дә барам. Сезнең белән җир читенә чаклы барырга риза.
Алинә. Минем беләнме?
Гомәр. Сезнең белән.
Алинә. Безнең беләнме, минем беләнме?
Гомәр. Синең белән, Алинә.
Алинә. Нигә?
Гомәр. Ахмак җавап ишетергә теләмәсәгез, андый сорау бирмәгез.
Алинә. Нигә минем белән?
Гомәр. Әйттерәсез ич инде, Алинә! Гашыйк булдым дип әйттерәсез.
Алинә. Миңамы?
Гомәр. Сезгә.
Алинә. Безгәме, миңамы?
Гомәр. Сиңа, Алинә!
Алинә. Ни өчен?

Гомәр. Уф!.. Бая да аптыраште калдырдыгыз, бу юлы да.
Алинә. Ни өчен миңа гашыйк булдыгыз?
Гомәр. Чөнки, чөнки... Сез, беренчедән... беренчедән, чибәр.
Алинә. Минме?

«Чибәр» сүзен ишеткәч, Низам чатыр ишегеннән башын суза.

Гомәр. Сез!
Алинә. Безме, минме?
Гомәр. Син, Алинә!
Алинә. Әйдәгез, абыем, су буена, миннән дә чибәррәкләр белән таныштырам.

Алинәне күзәтеп торган Низам чатыр ишегеннән чыга, киерелә-сузыла, күзләрен уган була, янәсе, яңа гына йокыдан уянган.

Алинә. Әнә егетләрегез уяна башлады.
Низам. Гафу итегез, кызлар бар икән. Гомәр, сәгать ничә?
Гомәр. Сиңа сәгать нәрсәгә? Кер дә ят, үзем уятырмын.
Низам. Тартырга биреп тор әле, Гомәр?
Гомәр. Тартмаганымны беләсең.
Низам. Шулаймыни? Ташладыңмыни? (*Якынрак килеп, сиздермәскә тырышып, Алинәгә карый.*) Әйдә, син дә йокла, Гомәр, кызлар бетмәс монда. Хатыныңа ишетелсә, әйбәт түгел. Ни карадың, дип, мине дә ачуланыр.
Алинә. Без өйләнгән егетләрдән дә курыкмыйбыз. Институтта укып, исәнләшә дә белмисез икән.
Низам. Гафу итегез, исәнмесез! (*Чатырга кереп китә.*)
Алинә. Бигрәк мут күзле егет. Миңа карап сине күрә торган.
Гомәр. Алинә, сез аның сүзенә ышандыгызмы? Юри ул.
Алинә. Ышансам да курыкмыйм, Гомәр абый бәгырем! Мин сезгә үлеп гашыйк булдым. Әйдәгез, парлап уйныйк, егетләр-кызлар биесен-җырласын.
Гомәр. Баш өсте, Алинә, әйтегез генә.

Икәүләп гитара чиертә-чиертә чыгып китәләр. Чатыр ишегендә Низам башы. Ул чатыр эченә карап сөйли.

Низам. Менә шул егет белән юньле эш майтарып кара син. (*Чатырдан ук чыгып.*) Китте. Иярде дә китте.
Заһир (*чатырдан чыгып*). Ул китсә китәр, син нәрсә һаман йокламыйсың? Йокыга гына китеп барганда уяттың.
Ризван. Алдашма, ичмасам. Сезнең белән берләшүемә үкенә башладым. Җитди егетләр түгел сез.
Заһир. Нигә алай дисең инде, Ризван, сүзебездә торабыз ич.
Ризван. Торырга азапланасыз. Үзегезне үзегез мәҗбүр итәсез. Ә күңелегез... Алай ярамый, иптәшләр. Боздан салкын, корычтан нык булырга кирәк. Миннән үрнәк алыгыз.
Заһир. Синең характерың нык шул, Ризван.
Ризван. Син дә үзеңне шулай тәрбиялә.

Гармун, гитара уйнаган, җырлаган тавышлар ишетелә.

Низам. Әллә ни чибәр дә түгел үзе.
Ризван. Кем?
Низам. Гомәр танышкан кыз.
Ризван. Гомәргә тагын чибәрләр!
Низам. Ә үзе сөйкемле. Әллә соң антыбызны иртәгәдән башлыйбызмы, егетләр?
Заһир. Чыннан да... Ә, Ризван?
Ризван (*ачуланып*). Барыгыз! Теләсәгез нишләгез. Сез мине белмисез, мин – сезне. Эх, сез! Җебегәннәр, штрейкбрехерлар! Бер төнгә түзмәделәр. Ант итәләр, имеш. Менә ышан сезгә. Барыгыз!
Заһир. Ачуланма инде, болай гына әйттек.
Низам. Сине сынар өчен генә, Ризван.
Ризван. Мин сыналган. Үзегезне сынагыз. (*Чатырга керә башлый.*)
Низам. Тукта инде, Ризван. Бүгеннән үк үпкәләшкәч ни була? Әйдәле, алай эшләмик әле. Без без булып калыйк әле. Йокы алдыннан гимныбызны кабатлыйк та дуслар булып йокыга китик әле. Яле... Бер! Ике! Өч!
Низам (*җыр башлый, аңа Ризван белән Заһир кушыла.*)

Эш кенә тормышның тоткасы,

Эш кенә дөньяның ноктасы,
Куертмыйк мәхәббәт боткасын,
Йөрәкләр ял итсен, йокласын.
Ант итәбез!
Ант итәбез!
Ант итәбез!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Вакыт кич. Ризван белән Заһир эштән кайтып керәләр. Арыганнар. Ял итеп алырга җиргә утыралар.

Заһир. Куллар эштән бизгән булган, һаман өйрәнеп җитә алмый.
Ризван. Әйе.
Заһир. Әле дә ярый йокыбыз туйганчы йоклап барабыз эшкә. Әйеме, Ризван?
Ризван. Әйе.
Заһир. Эшләр болай барса, күп эш эшләячәкбез. Культура йортының нигезе әзер. Нигез булса, калганы эшләнә. Нигезе нык булсын. Биесеннәр бездән соң килгән буыннар без салган нигездә. Тыпыр-тыпыр биергә бетон нигезләр кирәк, бетон нигезләр өстендә...
Ризван. Сөйләнми генә утыр әле.
Заһир. Нигә?
Ризван. Күрмисеңмени? Арыдым. Юкка алындык. Каникул ял итәр өчен. Бай малайлары диңгез ярында ята, без ишәк кебек...
Заһир. Син чынлапмы, Ризван?
Ризван. Мин уйнап сөйләшә белмим.
Заһир. Үзең эшләп тапкан кадерлерәк була, ди минем әби. Өстәвенә чыныгабыз. Менә кара минем кулларга...
Ризван. Ярый, әйдә коенырга киттек.
Заһир. Дөрес! Арыганга гына шулай сөйләшәсең. Су кергәч, җиңеләеп китәрсең.

Бауда эленеп торган сөлгеләрне, киемнәрне алып, китәргә җыеналар. Ризван кемнедер күреп туктап кала.

Ризван. Нишли ул Низам? Кем алдында шулай бөтерелә?
Заһир. Алинә ул. Авыл кызы.
Ризван (*кычкырып*). Низам!.. Әйтеп тормасаң, хәзер читкә тайпылырга торасыз. Ә син ул кызның исемен каян беләсең?
Заһир. Ничек инде белмәскә, үзе әйтте ич. Кызлар исемен белергә дә ярамыймыни?
Ризван. Ярамый. Бары тик эш турында гына.
Заһир. Тәнзилә белән ярыймы, Ризван?
Ризван. Исемен белергә ярый. Тик янына йөрергә ярамый.

Низам керә.

Ни сөйләштегез? Ни йомышың калган ул кызда.
Низам. Ике атна түздек бит инде, Ризван.
Ризван. Без монда ике атнага килмәдек. Антны да ике атнага бирмәдек. Ике ай. Онытма, ике ай!
Низам. Үзе бит, бәйләнә!
Ризван. Кемнең бәйләнгәнен күреп тордык без. Ал сөлгеңне, киттек.

Китәргә кузгалалар. Гомәр кайта.

Гомәр (*көйләп*). Ашыкмагыз, сабыр итегез, бераз гына мине көтегез.
Ризван. Көтмәскә! Аның үз юлы, безнең үз юлыбыз.
Низам. Безнең үз юлыбыз. Киттек.
Гомәр. Ашыкмагыз! Яңа хәбәр! Бүген бәйрәм. Ризван әфәнденең тууына егерме бер яшь тулу хөрмәтенә кичке ашка Тәнзиләнең хәҗәйкәсе бәлеш пешерә.
Низам. Бә-ә-леш! Ризван, туган көнең икәнне нигә әйтмәдең?
Гомәр. Өч ел бергә укып беркемгә әйтмәгән. Тәнзилә сизеп алган.
Ризван. Без монда бәйрәм итәргә килмәдек.

Заһир. Бәйрәм итмәсәк тә, котлар идек.

Ризван. Кирәкми.

Низам. Кирәкмәгәч кирәкми, кызлар. Ризван өчен мине котлагыз. Ризван тыйнак кеше. (*Гомәргә күз кысып.*) Котла, Гомәр! Мин – Ризван.

Низам Ризван позасын алып баса. Гомәр тирәккә эленеп торган сумкасыннан бер бит кәгазь алып, укыган булып сөйли.

Гомәр. Хөрмәтле вә гыйзззәтле Ризван иптәш Низамов, моннан егерме бер ел элек дөньяга килеп, сез дөньяны һәм безне бәхетле иттегез. Сез әле бәләкәй чакта ук, тәпи-тәпи атлап киткәнче үк, дүрт аяклап мүкәләп йөреп дөньяны, тормышны өйрәндегез.

Низам. Сабыр ит, Гомәр. (*Тиз генә чатырга кереп китә дә аннан бер бит кәгазь алып чыга. Шул кәгазьгә карап.*) Рәхмәт, иптәшләр! Дәвам итегез.

Гомәр. Сез мәктәпкә укырга кергәндә үк тыйнак идегез. Үзегезнең шәхесегезне укытучының борынына төртмәдегез. Киресенчә, укытучының борын астына – беренче партага утырдыгыз.

Низам (*кәгазьгә карап*). Рәхмәт, иптәшләр!

Гомәр. Шулай тыйнак булып белем тавына күтәрелдегез. Төзелеш академиясенә кердегез, һәм менә сезнең тыйнаклыгыгыз сезне безнең белән бергә шабашниклык итәргә алып килде. Сез, Ризван иптәш,囲эштә дә тыйнаклык күрсәтәсез.

Низам. Рәхмәт, иптәшләр!

Ризван (*Гомәр каршысына килеп*). Шуның белән ни әйтергә телисең?

Гомәр (*Ризваннан читкәрәк тайпылып*). Сез пунктуаль һәм принципиаль кеше буларак...

Ризван (*Низам каршысына килеп*). Шуңа кушылып, шуның җырын җырларга тотындыңмы?

Низам. Рәхмәт, иптәшләр!

Ризван (*җирдә тәгәрәп көлгән Заһир янына килеп*). Син нигә көләсең, кемнән көләсең?

Заһир. Дөрес! Билләһи, дөрес, Ризван. Син бит бөтен сүзеңне кәгазьгә карап сөйлисең.

Ризван. Эх сез! (*Тиз генә чыгып китә.*)

Заһир. Юкка үпкәләттек.

Гомәр. Бар, йөгер тизрәк, күз яшьләрен сөрт.

Заһир. Нигә алай дисең инде, Гомәр?

Гомәр. Аның каршында биеп торасың бит. Шагыйрь чыкмаячак синнән.

Заһир. Умыртка сөягең йомшак.

Тәнзилә керә.

Заһир. Исәнме, Тәнзилә!..

Тәнзилә. Сез әле һаман юынмадыгызмыни?

Гомәр. Юынмадык шул әле, мадемуазель.

Тәнзилә. Бәлешләр өлгерә, сез һаман юк. Әйдә, тиз генә җырны кабатлап алыйк.

Гомәр. Юынмаган килешме?

Тәнзилә. Өлгерерсең.

Гомәр. Бар алайса, Заһир, төшә тор. Бар инде, нәрсә дөньяңны оныттың. (*Заһир киткәч.*) Син, Тәнзилә, нигә Заһирның сәламен алмадың? Тәнзилә, Заһир белән сезнең мөнәсәбәтләр ничек?

Тәнзилә. Нинди мөнәсәбәт?.. Җырны кабатлыйбыз.

Гомәр. Аралар ничек, дим? Яратасыңмы син аны?

Тәнзилә. Башка әйтер сүзең юкмы?

Гомәр. Ярата ул сине.

Тәнзилә. Информацияң өчен рәхмәт. Әйдә, ал гитараңны.

Гомәр. Син миңа җыр яздырып интектерәсең, ә Ризванның исендә дә юк. Бернинди туган көн юк, ди.

Тәнзилә. Аның ничек әйтүендә эшебез юк, коллектив аны котларга тиеш. Традиция. Димәк, болай: беренче булып сүзне мин алам. Барыбыз исеменнән дә сүз белән котлыйм. Аннан – җыр, без икәү. Башла.

Гомәр гитарасын алып уйный.

(*Җырлый.*)

Ризванның туган көнендә
Көлеп чыкты кояш та,
Ризванның туган көнендә
Матур сайрады кош та.

Ризванга бүген егерме бер –
Йөзгә чаклы яшәсен!
Ризванга шуны телибез –
Яшен булып яшьнәсен!

Сүзләре бигрәк мәгънәсез инде.

Гомәр. Мин бит шагыйрь түгел, Заһирга кушарга иде.

Тәнзилә. Син юри шулай язгансың. Яратмыйсың син Ризванны.

Гомәр. Ә син яратасыңмы?

Тәнзилә. Бик яратам. Бар, йөгер.

Гомәр. Кара аны, Тәнзилә, әгәр дә Заһирны бүтәнгә алыштырсаң...

Тәнзилә. Нишләтерсең?

Гомәр. Үземнеке итәрмен.

Тәнзилә (*ачуланып*). Беләсеңме нәрсә, дустым...

Гомәр. Бетте, бетте, шаярдым.

Тәнзилә. Шаяруның да мәгънәсе була. Шаярырга остарып киттегез әле.

Гомәр. Заһир шаярмый.

Тәнзилә. Шаярмаганын үз теле белән үзе әйтсен. (*Чыгып китә.*)

Гомәр. Әйтер, Алла боерса.

Ризванның туган көнендә
Көлеп чыкты кояш та,
Ризванның туган көнендә
Матур сайрады кош та...

Гомәр җырлап чыгып китә. Заһир керә.

Заһир. Тәнзилә!..

Тәнзилә. Әйе...

Заһир. Тәнзилә!..

Тәнзилә. Әйе...

Заһир. Тәнзилә, әгәр дә минем туган көнем булса, син бәлеш пешерер идеңме?

Тәнзилә. Ризванга бәлешне мин пешермәдем. Мин яшәгән фатирның хуҗабикәсе Галия апа пешерде.

Заһир. Ә син бәлеш пешерә беләсеңме?

Тәнзилә. Миңа әйтерлек бүтән сүзең юк мәллә?

Заһир. Бар да бит.

Тәнзилә. Булса әйт.

Заһир. Күптәннән әйтәсем килеп йөрим.

Тәнзилә. Бүген әйт.

Заһир (*як-ягына каранып*). Мин әйтсәм, син мин әйткәнне Ризванга әйтмәссеңме? Без бит ант иттек.

Тәнзилә. Алайса, антыңны бозма инде.

Заһир. Бозмыйча да ярамый. Синең үзеңне генә кайчан күрәм әле. Әйтеп каласым килә. Мин сине яратам бит, Тәнзилә!

Тәнзилә. Мин куркакларны яратмыйм шул, Заһир!

Заһир. Юк, мин куркак түгел, Тәнзилә, оялчан гына.

Тәнзилә. Мин оялчан түгел. Күрсәт миңа палаткагызның эчен. (*Бауны атлап, палаткага таба китә.*)

Заһир. Тәнзилә... Тәнзилә, зинһар өчен, чык аннан!

Тәнзилә. Курыктыңмыни?

Заһир. Курыкмадым. Ләкин ант иттем бит.

Тәнзилә. «Яратам» дип әйтеп антыңны боздың.

Заһир. Әйе, боздым, анысын әйтми түзалмадым. Бусы бит... Зинһар өчен, чык инде аннан. Егетләрдән яхшы түгел. Ризван бит безнең әллә нинди.

Тәнзилә. Алайса, Ризванга аңлат мәхәббәтеңне. Киттем, бәлеш ашарга килегез. (*Китә башлый.*)

Заһир. Тәнзилә!..

Тәнзилә. Иярмә. Мин ияреп йөрүчеләрне яратмыйм. Үземнең ияреп йөрисе килә.

Заһир. Синә ияреп йөрү рәхәт миңа.

Тәнзилә. Үзеңне бозау дип хис итәсеңме? (*Чыгып китә.*)

Заһир. Тәнзилә!.. (*Тәнзиләгә ияреп чыгып китә.*)

Алинә керә. Гомәрнең гитарасын алып чиерткәли. Ризван керә.

Алинә. Исәнмесез! Хәерле кич!
Ризван. Нигә кешенең гитарасын рөхсәтсез алдыгыз? Куегыз урынына. Һәм, гомумән...
Алинә. Гомумән, сез сәламгә каршы сәлам бирмәдегез.
Ризван. Исәнмесез! Сез үзегезне ямьсез тотасыз.
Алинә (*чиертүдән туктап*). Гафу итегез, ничек ул ямьсез?
Ризван. Мин әйттем, калганын үзегез аңлагыз.
Алинә. Гафу итегез, аңлый алмыйм. Сез ямьсез сүз әйттегез, анысын аңладым, ни өчен әйттегез – аңламадым.
Ризван. Сез нишләп әле бу тирәдә чуаласыз? Монда килеп йөрергә миннән сезгә рөхсәт юк!
Алинә. Гафу итегез, мин бу авылда эшлим, әнә шул өйдә фатирда торам, чишмәгә – суга, елгага су керергә төшәм, сукмак сезнең палатка яныннан үтә.
Ризван. Беләм. Сез клуб мөдире булып эшлисез, клубта утырыгыз. Сукмактан үткәндә туктап тормагыз.
Алинә. Шулай укмыни? (*Бауны атлап керә.*)
Ризван. Бауның теге ягына чыгуыгызны үтенәм.
Алинә. Әгәр чыкмасам?..
Ризван. Кабатлап әйтәм, үзегезне ямьсез тотасыз. (*Чатыр эченә кереп китә.*)
Алинә. Гафу итегез! (*Гитараны чиертеп, җырлап җибәрә.*)

Үзегез дә белми, сизми генә
Күңел кылларыма чиерттегез:
Күңелемдә яңа бер көй туды –
Гафу итегез!
Чәнечкеле сүзләрегез белән
Йөрәгемә чәнчеп үттегез;
Яраланган йөрәк дәва көтә –
Гафу итегез!

Ризван (*чатырдан чыгып*). Тагын бер кат әйтәм, сез үзегезне ямьсез тотасыз. Әгәр дә шаярырга телисез икән, бауның теге ягына чыгыгыз да Гомәр кайтканын көтегез. Шаярырга ул ярата.
Алинә. Ә миңа Гомәр белән шаяруы күңелсез.
Ризван. Һәм, гомумән, безнең Низамны тынычлыкта калдырыгыз.
Алинә. Низамның ни катнашы бар?
Ризван. Мин беләм, мин күрдем. Сезне күргәч, Низам үзгәрде, һәм сез, шуңардан файдаланып, Низам белән берничә тапкыр сөйләштегез, елгада бергә йөздегез.
Алинә. Ә сез?
Ризван. Нәрсә мин?
Алинә. Сез, мине күргәч, үзгәрмәдегезме?
Ризван. Юк.
Алинә. Кызганыч.
Ризван. Кызганыч, ләкин факт.
Алинә. Сез шулай ук таш йөрәклемени?
Ризван. Бу очракта, әйе.
Алинә. Кайсы очракта?
Ризван. Сезнең белән очрашкан чакта.
Алинә. Мин сезгә аз гына да ошамыйммыни?
Ризван. Бу очракта – юк.
Алинә. Хәерле булсын. Бәлки, чыннан да, мин үземне ямьсез тотканмын. Сезнең янга ялынып килгән кебек килеп чыккандыр. Әйе, әйе, мин, ниһаять, аңладым, болай ярамый икән, килешми икән. Ләкин минем бүтән чарам юк. Чөнки мин сезне уйлап төн йокыларымны йоклый алмый башладым, ә сез мине күрмисез дә. Гафу итегез, бүтән мин сезне борчымам, янармын, көярмен – сиздермәм. Әмма сез дә, тупас сүзләр әйтеп, мине мыскыл иттегез.
Ризван. Мин мыскыл итәргә теләмәдем.
Алинә. Мин дә үземне ямьсез тотарга теләмәгән идем.
Ризван. Ярый алайса, тупас сүзләрем өчен гафу итегез.
Алинә. Юк, сез гафу итегез. Ә сез кая барырга болай киендегез?
Ризван. Бүген минем туган көнем.
Алинә. Котлыйм, бәхетле булыгыз!
Ризван. Рәхмәт!
Алинә. Сез нигә миңа шулай текәлеп карыйсыз?
Ризван (*як-ягына каранып ала*). Чөнки сез чибәр.

Алинә. Шуннан ни мәгънә? Сезнең өчен барыбер бит.

Ризван. Сез – кызыклы, сез – серле.

Алинә. Рәхмәт! Сез шулай кичләрен беркая да бармый палаткагызда йоклап ятасызмы?

Ризван. Ант иттек.

Алинә. Ә төннәрен су буенда шундый рәхәт. Әнә елганың теге борылышында минем яраткан басмам бар. Кайвакыт шунда төшәм дә берьялгызым уйланып утырам. Берьялгызым. Гомәр, Низам кебекләрне яратмыйм мин, алар җилбәзәкләр. Төпле акыллы кешеләр белән сөйләшеп утырасым килә. Җилбәзәклек минем үземдә дә җитәрлек.

Ризван. Әйе, җилбәзәклек кызларга килешсә дә, егетләргә килешми.

Алинә. Димәк, сез миңа ачуланмыйсыз?!

Ризван (*елгага карап*). Ә елганың ул борылышы, чыннан да, матур.

Алинә. Төнлә күрсәгез иде сез аны!

Ризван. Искиткеч матур урын. (*Низам килгәнне күреп.*) Гафу итегез, зинһар, бауның теге ягына чыгыгыз, Низам кайтып килә.

Алинә (*бауны атлап чыгып*). Мин бүген дә яраткан басмама төшеп утырам.

Ризван. Мине бүген котларга тиешләр.

Алинә. Озак буласызмы анда?

Ризван. Озак түгел. Сау булып торыгыз. (*Китә башлый.*)

Алинә. Елганың теге борылышында...

Ризван чыгып китә. Низам керә.

Низам. А-а, Алинә! Малинә!

Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Алинә;
Күзләре – кара карлыган,
Иреннәре – малинә.
Кемне көтәсез?

Алинә. Ни өчен әле мин егетләр көтеп утырырга тиеш? Үтеп барышлый, гитараны күрдем дә туктадым. Гитара күрсәм, тыныч кына узып китә алмыйм.

Низам. Ә мин сезне күрсәм, тыныч кына үтеп китә алмыйм.

Алинә. Сөйләгән буласыз инде, ышана дип уйлыйсыздыр.

Низам. Менә монысы дөрес. Ышанмагыз сез миңа. Ышаныгыз дип әйткәнем дә юк. Ышанычлы түгел мин. Ләкин мин сезгә ышанам. Ышанам, нишләтим? Азмыдыр, күпмедер вакыт үтәр, һәм сез миңа ышанырсыз дип ышанам.

Алинә. Ышанмаучыларыгыз миннән башка да бардыр әле.

Низам. Бардыр, әлбәттә. Нигә алдашыйм. Ләкин кирәгеннән артык ышансалар да әйбәт түгел, күңелсез. Кызлар – егетләргә, хатыннар – ирләренә, карчыклар картларына аз гына шикләнеп карарга тиешләр. Чөнки алай-болай булса, көтелмәгән булмасын.

Алинә. Ә егетләр кызларга?..

Низам. Монда инде икенче мәсьәлә. Кызлар, хатыннар, карчыклар ышанычлы булырга тиеш. Менә мин шундыйны эзлим.

Алинә. Таба алганыгыз юкмы?

Низам. Әлегә юк дисәм, ни диярсез?

Алинә. Алай икән, диярмен.

Низам. Шуннан?

Алинә. Эзләвегезне дәвам итегез.

Низам. Дәвам итәм һәм сезгә ышанам.

Алинә. Димәк, без табышканбыз. Мин сезгә ышанмыйм, сез миңа ышанасыз. Инде нишләргә?

Низам. Кичләрен очрашырга.

Алинә. Сез бит кызлар белән сөйләшмәскә ант иткәнсез. Ант белән шаярмыйлар.

Низам. Мәхәббәт мәсьәләсендә бер адәм заты да антында тормаган, нигә мин генә тормыш законын бозарга тиеш әле?

Алинә. Димәк, ант мәсьәләсендә дә ышанычсыз.

Низам. Ант белән антның аермасы бар.

Алинә. Минемчә, юк.

Низам. Бәхәсләшмик, Алинә, юк өчен. Конкрет сөйләшик: сез минем белән очрашырга ризамы? Калганы минем эш.

Алинә. Болай да очрашып торабыз ич.

Низам. Мондый очрашу нәрсә ул! Көпә-көндез – унлаган күз карап торганда. Икәү генә калып сөйләшәсе килә.
Алинә. Мин риза.
Низам. Әллә?
Алинә. Мәллә.

Шул вакыт, «Низам!» дип кычкырып, Дамирә керә. Керә дә Низамның кочагына ташлана.

Дамирә. Сагындыңмы мине, Низамчик? Мин сине шундый сагындым. Машинам чокырга төшеп баткач җәяү йөгердем.
Низам. Дамирә... Син ни әле... Тукта әле...
Дамирә (*Алинәне күреп*). Ә бу кем?
Низам. Ул ни... Алинә...
Дамирә. Нишләп йөри ул монда?
Алинә. Мин Низамның миңа мәхәббәт аңлатканын тыңлап торам.
Дамирә. Нәрсә-ә-ә? Низам, ни сөйли ул?
Низам. Ни... Тукта әле син, Дамирә... Ни бит... Болай ул...

Ут сүнә.

## ӨЧЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Шул ук урын. Вакыт төн. Ризванның туган көненнән таралганнар. Өч егет үз территорияләрендә утыра. Гомәр гамак өстендә гитара чиертә.

Ризван. Йокларга!
Заһир. Утырыйк әле бераз, төне матур.
Ризван. Иртәгә эшкә.
Заһир. Туктале, Ризван!
Ризван. Йокларга!
Низам. Дөрес. Әйдәгез. Антны бозарга ярамый.

Беренче башлап чатыр эченә Низам кереп китә. Аңа Ризван белән Заһир иярә. Гомәр әкрен генә гитара чиертүен дәвам итә. Кинәт гармун тавышы ишетелә. Гармунын тартып уйнап, Нәҗип килеп керә.

Нәҗип (*җырлый*).

Аклы күлмәк кияр идем,
Акка кара төшмәсә.
Гомерлеккә сөяр идем,
Күзең ятка төшмәсә.
Көмеш саплы алтын пәке
Сынды гөлләр кискәндә;
Өзелә лә үзәкләрем
Таң җилләре искәндә.

Уйнавыннан, җырлавыннан кинәт туктап, Гомәргә карап тора.

Гомәр. Егетләр йоклый, Нәҗип абый!
Нәҗип. Бу чактан йоклыйлармы? Менә мин бөтенләйгә йокламаем. Шушыннан туп-туры көтүгә. Нигә син уйнамыйсың?
Гомәр. Каз муенына кая инде тальян белән ярышырга.
Нәҗип. Һе, белдеңме инде?
Гомәр. Белдем. Әкренрәк сөйләш, Нәҗип абый.
Нәҗип. Син минем янга төшеп утыр.

Гомәр гамактан төшә.

Ә син нигә йокламыйсың?
Гомәр. Үзең әйтмешли, сәгать унда кем йокларга ята?
Нәҗип. Бер кызны көтәсеңме?

Гомәр. Кайсы кызны?
Нәҗип. Бер кыз сезнең янга килеп йөри.
Гомәр. Алинәме?
Нәҗип. Исемен әйтмәем. (*Җиңен сызганып.*) Менә бу беләкне күрәсеңме?
Гомәр. Күрәм, Нәҗип абый.
Нәҗип. Әгәр дә ул кызның башын әйләндерсәгез, муеныгызны сугып сындырырмын.
Гомәр. Алай ук димәгез инде.
Нәҗип. Сындырам. Алты ел күзем төшеп йөргән кызны алып киттегез.
Гомәр. Без түгел бит.
Нәҗип. Барыбер. Сезнең иш.
Гомәр. Алты ел күзегез төшеп йөргән, шул хакта үзенә әйткән идегезме соң?
Нәҗип. Кемгә?
Гомәр. Кызга.
Нәҗип. Әйтмәдем. Нигә әйтәем, тәмен югалтып...
Гомәр. Монысына да әйткәнегез юкмы?
Нәҗип. Әйтмәем. Үзе белсә белсен, әйтмәем.
Гомәр. Үзләре белмиләр шул алар, Нәҗип абый. Ничә яшь соң сезгә?
Нәҗип. Утыз.
Гомәр. Картаеп барасыз икән шул...
Нәҗип. Утыз яшь – егетнең өлгергән чагы, күмере төшкән чагы.
Гомәр. Алай булгач, күзегез төшкән кызга әйтегез дә өйләнегез. Юкса, чыннан да, алып китүләре ихтимал.
Нәҗип. Яратканымны үзе сизсә, өйләнәем.
Гомәр. Тагын утыз ел егет булып йөриячәксез.
Нәҗип. Йөресен. Каз муенын уйнап караеммы?
Гомәр. Рәхим итегез! (*Гитараны Нәҗипкә бирә.*)
Нәҗип. Син Алинә кебек, рәхим итегез, дип сөйләшәсең икән. (*Гитара кылларын чиертә, ләкин көй чыгара алмый.*) Булмай. Өйрәт мине уйнарга.
Гомәр. Сез яратмыйсыз ич гитараны.
Нәҗип. Ә мин өйрәнәем дә ташлаем.
Гомәр. Бүген соң, иртәгә иртәрәк килерсез.
Нәҗип. Әйдә минем белән су буена.
Гомәр. Анда ни бар?
Нәҗип. Гармун уйнап, җырлап йөрибез.
Гомәр. Бүген булмый.
Нәҗип. Сау бул! (*Гармунын тартып уйнап чыгып китә.*)

Гомәр гамакка менеп ята. Чатыр ишегендә Низам күренә, йомшак
кына басып бау янына килә, атлап чыга.

Гомәр. Низаметдин, кая юл тоттың?
Низам. Тс-с! (*Гомәр янына килә.*) Май кап!
Гомәр. Каптым. Кая барасың?
Низам. Эшләр кәкәйләнде бит әле. Дамирә килеп төште. Адресны да бирмәгән идем. Эзләп тапкан.
Гомәр. Хәзер нишләргә җыенасың?
Низам. Нишләргә, нишләргә... Ул Алинәләрдә, аңлашырга кирәк ич.
Гомәр. Кызлар белән сөйләшмәскә дип биргән антың бар.
Низам. Ризван булма әле син дә. Аның йокыга киткәнен көтеп тә ничаклы вакытым үтте.
Гомәр. Ләкин, Ризваннан ычкынсаң да, миннән ычкына алмассың.
Низам. Чынмы?
Гомәр. Чын.
Низам (*көлеп*). Свинҗә син, Гомәр.
Гомәр. Антын бозган – хыянәтче.
Низам. Зурга җибәрмә. Мин шаярдым гына ул чакта, беләсеңме, шаярдым. Бу җүләрләр нишләрләр икән дип шаярдым. Үзең дә күреп тордың, сөйләшкәндә дә, җырлаганда да сул күзем гел көлеп торды.
Гомәр. Барыбер җибәрмәячәкмен.
Низам. Әй, аңа калса, бик исем китте. Нишләтә аласың?
Гомәр. Ризванны уятам.
Низам. Димәк, сатасың? Бергә укып йөргән курсташыңны, дустыңны, аягын-кулын бәйләп, сөйгән кызыннан аерып алып, шул бюрократ Ризванга сатасың?
Гомәр. Анда Заһир да бар.

Низам. Димәк, сине үлеп яраткан Низамны шагыйрь булырга хыялланып йөрүче мәҗнүнгә – Заһирга сатасың?

Гомәр. Көлдермә, Низам. Үтмәс товар сатып йөрергә әллә мин җүләрме.

Низам. Ярый, уят. Уяныр нишләтә алалар? Китәм дә барам.

Гомәр. Антын бозган кешегә җәзаны мин бирәчәкмен, Низам. Мин – рәхимсез!

Низам. Гомәр?! Алай димә инде, Гомәр. Егет бул инде, Гомәр. Ризванга исем дә китми, синнән куркам. Җибәр инде. Хәзер әйләнеп кайтам. Дамирәгә аңлатам да кайтам. Яратам мин аны, беләсеңме!.. Харап итмә мине. Үтермә мәхәббәтебезне, Гомәр, коткар.

Гомәр. Ярый алайса, бер юлга...

Низам. Рәхмәт, Гомәр. (*Китәргә җыена.*)

Гомәр. Тукта!

Низам (*Гомәр янына юргалап килеп*). Нәрсә, Гомәр?

Гомәр. Күрә торып антыңның бозылуын теләмим.

Низам. Гомәр?..

Гомәр. Ашыкма. Бар, кереп ят, мин йоклагач китәрсең.

Низам. Алай итмә инде, Гомәр. Телисеңме, мин сине тирбәтеп йоклатам. Ят, Гомәр, ят. (*Гомәрне гамагына яткыра.*) Йом күзеңне. Менә шулай. Әлли-бәлли ит. Тәмле-татлы төшләр күр. (*Гамакны тирбәтә.*)

Гомәр. Әкрен, егасың.

Низам. Яп авызыңны, йом күзеңне. Әлли-бәлли. (*Көйләп.*)

Сарыклар да йоклады инде...

Гомәр. Бозма мин чыгарган җырны. Сарыклар түгел, тавыклар.

Низам. Ярый, ярый, тавыклар.

Тавыклар да йоклады инде.

Гомәр. Йоклады инде түгел, йокламый әле.

Низам. Аңладым.

Тавыклар да йокламый әле,
Балыклар да йокламый әле,
Халыклар да йокламый әле,
Син тынычлап йокларсың, яме.
Әлли-әлли, әү-әү, бәлли-бәлли, бәү-бәү.

Гомәр, булдымы?

Гомәр. Булды.

Низам. Йокыга киттеңме?

Гомәр. Киттем.

Низам. Мин дә киттем. (*Чыгып йөгерә.*)

Гомәр, башын күтәреп, аның артыннан карап кала, чатыр ишегендә Ризванны күреп, гырлый башлый. Ризван, як-ягына карангалап, бау янына килә. Алинә күрсәткән елга борылышына карый. Бауны атлап чыга.

Гомәр (*башын күтәреп*). Ризван, кая юл тоттың?

Ризван (*каушабрак калган*). Син нишләп йокламыйсың?

Гомәр. Йоклаган идем – уяттың.

Ризван. Низам кайда?

Гомәр. Чатырга бергә кереп киттегез.

Ризван. Ул юк.

Гомәр. Алайса белмим.

Ризван. Беләсең.

Гомәр. Белсәм беләмдер.

Ризван. Кай якка китте?

Гомәр. Нигә миннән сорау аласың әле? Син кем дә мин кем.

Ризван. Анысын киләчәк күрсәтер. (*Китәргә җыена.*)

Гомәр. Күрсәтүен күрсәтер, әмма син урыныңа кереп ят.

Ризван. Нәрсә-ә?

Гомәр. Кереп ят, төнгә каршы чыгып китмә кызлар эзләп.

Ризван (*югалып кала*). Син мине кем дип беләсең?

Гомәр. Кемлегеңдә эшем юк, ант иткәнеңне күреп тордым.

Ризван. Мин Низамны алып кайтам.

Гомәр. Сабый түгел, үзе дә кайтыр.

Ризван. Кайчан?
Гомәр. Бүген булмаса, иртәгә.
Ризван. Иртәгә соң була. Антын бозып өлгергәнче алып кайтырга кирәк.
Гомәр. Бәлки, ул кызлар янына китмәгәндер?
Ризван. Шигем бар.
Гомәр. Алайса, үзем алып кайтам.
Ризван. Юк, нишләп йөргәнен мин үзем күрергә тиеш. (*Горур гына атлап чыгып китә.*)

Гомәр, гамак өстенә басып, аның кай якка киткәнен карап кала.
Тәнзилә үтеп бара.

Гомәр. Тәнзилә! (*Тәнзилә эндәшмәгәч, гамактан төшеп, Тәнзилә артыннан китә. Бераздан кире йөгереп кереп, чатыр янына килеп кычкыра.*) Заһир, чык әле!
Заһир (*чатырдан чыгып*). Нигә?
Гомәр. Нигә, нигә... Тәнзилә су буена төшеп китте, берүзе.
Заһир. Ярамый.
Гомәр. Колак кагасың Тәнзиләдән. Әнә хәзер үк... Монда туктап та тормады, сөйләшмәде дә... Ни өчен дисеңме? Синең аркада. Бәлешне ашап бетерүгә, йокларга вакыт, дип, кайтып киттегез.
Заһир. Ризван бит.
Гомәр. Ризван... Ул үзе юк, син чатырда.
Заһир. Ул Низамны алып кайта.
Гомәр. Ул Низамны тапканчы, син Тәнзилә белән сөйләшеп өлгерәсең.
Заһир. Нәрсә сөйләшим?
Гомәр. И-и Алла! Яратам мин сине, Тәнзилә, диген.
Заһир. Әйттем инде.
Гомәр. Кайчан?
Заһир. Бүген.
Гомәр. Нәрсә ди?
Заһир. Ияреп йөрмә, ди.
Гомәр. Бозау син.
Заһир. Тәнзилә дә шулай ди.
Гомәр. Бар. Куып тот та әйт, «мин бозау түгел, үгез» диген.
Заһир. Кызларга «мин үгез» дип әйтеп булмый инде.
Гомәр. Ярый, берничек тә әйтмә. Тик минем ачуымны чыгарып йоклап ятма.
Заһир. Йокламыйм мин.
Гомәр. Нишлисең соң?
Заһир. Уйланам. Тыңла әле, Гомәр, бер шигырь яздым, ничек?..
Гомәр. Тыңламыйм. Тәнзилә тыңласын...
Заһир. Әллә ниндиләр сез. (*Читкә китә.*)
Гомәр (*аның янына килеп*). Йә-йә, үпкәләмә. Әйдә.
Заһир. Кая?
Гомәр. Баргач күрерсең. (*Заһирны кулыннан сөйрәп алып чыгып китә.*)

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

### ДҮРТЕНЧЕ КҮРЕНЕШ

Су буе. Таллык. Басма. Дамирә керә. Аңа Низам ияргән.

Низам. Дамирә, алай итмә инде. Ну бит инде. Алай ярамый бит инде. Йә инде, мәрхәмәтле бул инде. Яратмасаң да, кешене хөрмәт итәргә кирәк ич инде.
Дамирә. Син әле кешемени?
Низам. Белмим, Дамирә. Син кем дисәң, шул булам. Телисеңме, эт баласы булып артыңнан ияреп йөрим. Ышан, әйтмәдем мин Алинәгә яратам дип. Сынап кына карадым мин аны. Син беләсең бит инде.
Дамирә. Беләм мин сине, бик яхшы беләм. Кызлар күрсәң, күзләрең акая.
Низам. Чибәр кызлар күп булганга мин гаепле түгел бит инде, Дамирә. (*Җырга күчә.*)

Җемелдәп-җемелдәп яналар

Галәмдә хисапсыз йолдызлар;
Ни өчен йөрәгем бер генә,
Ни өчен күп икән бу кызлар?
Йолдызлар якында, еракта,
Арада иң якын йолдыз бар;
Якында, еракта кызлар күп,
Йөрәккә иң якын бер кыз бар.
Уйныйк әле, җырлыйк әле,
Көлик әле кыз чакта;
Килен булгач көлдермәсләр,
Утыртырлар почмакта,–

дип җырлаганнар әбиләребез дә. Ул син, Дамирә, син!

Дамирә. Ышанмыйм!.. Ышанмыйм мин сиңа.

Низам. Гаебем юк, Дамирә.

Дамирә. Ышанмыйм!..

Низам. Телисеңме, ант итәм?

Дамирә. Көнгә әллә ничә ант итәсең.

Низам. Сиңа биргән антым берәү генә. Телисеңме, каршыңа тезләнәм? Низамның адәм хурына калып, мескенләнеп тезләнеп торуын телисеңме? Тезләнәм.

Дамирә. Ышанмыйм.

Низам. Дамирә!.. Ышана идең бит миңа. Нишләдең син, нишләдең?! Кемнәр синең йөрәгеңдә шик уятты?!

Дамирә. Кызлар егетләргә ышанмаска тиеш, дип әйтә идең, дөрес икән.

Низам. Җүләр ни сөйләмәс. Җүләр бит мин, шыр тиле. Шул тилелегем аркасында Ризванга ияреп юри генә ант иттем. Ризванның ачуын чыгарыр өчен, аңардан көләр өчен юри Алинә белән сөйләштем. Болай буласын белгән булсам... Икенче тапкыр... Ак тәүбә, кара тәүбә... (*Еламсыраган тавыш белән.*) Дамирә!..

Дамирә (*еларга җитешеп*). Нәрсә, Низам?..

Низам. Дамирә!..

Дамирә. Низам!..

Низам. Дамирә!..

Дамирә. Низам!..

Низам. Гафу итәсеңме?

Дамирә. Белмим.

Низам. Бел инде, Дамирә.

Дамирә. Казанга кайткач сөйләшербез, Низам.

Низам. Ай-яй-яй-яй-яй!..

Дамирә. Озакмыни?

Низам. Бик озак, Дамирә. Аңарчы үләм мин.

Дамирә. Үлмисең, Низам... Син егетләргә биргән антыңда тор, Низам. Бер кыз белән дә сөйләшмә, бер кызга да карама. Кич җиткәч, палатка эченнән чыкма.

Низам. Көләсеңме?

Дамирә. Чынлап әйтәм.

Низам. Әгәр чынлап әйтсәң, синеңчә эшләрмен, Дамирә. Чатыр эчендә гел сине генә уйлап ятармын. Әгәр дә син тагын килсәң, нишләрмен?

Дамирә. Бүтән килмәм.

Низам. Үзем барырмынмы?

Дамирә. Хатлар гына язарсың. Синең хатларыңны уку рәхәт булыр.

Низам. Рәхмәт, Дамирә!

Ризван керепкарап тора.

Үбәргә рөхсәт итмисең инде, әйеме, Дамирә?

Дамирә. Әйе.

Низам. Дөрес эшлисең, Дамирә. Синең урыныңда мин дә нәкъ менә синеңчә эшләр идем. Үбәргә дип үрелсәм, Казанга кайткач, дип әйтер идем. Казанга кайткач, әйеме, Дамирә? Күрешкәннең беренче көнендә үк.

Ризван. Иптәш Рамазанов!..

Низам. Ризван?.. Ә, Ризван... Хәерле кич, Ризван!

Ризван. Хәерле төн!.. Эләктеңме?

Низам. Эләктем, Ризван. Менә таныш бул – Дамирә. Ә бу – Ризван. Исәнләш, Дамирә, Ризван белән. Исәнмесез, Ризван, диген.

Дамирә. Исәнмесез, Ризван!

Ризван. Исәнмесез!.. Ала-ай...

Пауза. Өчесе дә бер-берсенә карашып торалар.

Низам (*ниһаять, түзмичә кычкырып җибәрә*). Әйтсәң әйт инде сүзеңне, Ризван.

Ризван. Бер сүз дә әйтмим әлегә.

Низам. Әйдә алайса, Дамирә, тизрәк китик.

Ризван. Кая?

Низам. Кая дип... килгән бит... Ерак араларны якын итеп. Озатып куярга кирәк ич инде.

Ризван. Шулаймыни?

Низам. Шулай икәнен күреп торасың.

Ризван. Яхшы. (*Дамирәгә.*) Сез чыгып торыгыз. Ә син, Низам, калып тор.

Низам (*борылып кереп*). Нәрсә инде тагын?!

Ризван. Ашыкма.

Низам. Китә бит. Әйт тизрәк сүзеңне.

Ризван. Китсә, эзләп табарсың. Шулай диген, ә?

Низам. Шулай инде, шулай. Шулай икәнен күреп торасың. Юкка утырдым синең арбаңа. Әгәр дә мәгәр икенче тапкыр... Ак тәүбә, кара тәүбә...

Ризван. Ашыкма... Гафу итәм. Соңгы тапкыр.

Низам. Соңгы тапкыр.

Ризван. Заһир белмәсен.

Низам. Белмәс.

Ризван. Гомәр сизмәсен.

Низам. Сизмәс.

Ризван. Ычкын.

Низам. Ычкынам. (*Чыгып йөгерә.*)

Ризван (*як-ягына каранып*). Басмасы шушы, Әсмасы кайда? Кара, кызык сүз килеп чыкты. Басма, Әсма. Басмасы, Әсмасы. Басмасы шушы, Әсмасы кайда? (*Ләззәтләнеп көлә.*) Юморны аңламыйсың дип көлгән булалар. Аңлыйм бит. Юморны аңламаган кеше шундый сүз уйлап таба аламы? (*Такмаклап.*) Басмасы, Әсмасы, басмасы, Әсмасы... (*Кинәт җитдиләнеп, тирә-ягына каранып тора. Басмага кереп, яр өстен күзәтә. Тәнзилә үтеп барганны күреп, аны чакырып ала...*)

Тәнзилә. Йокларга дип кайтып киткән идегез ич.

Ризван. Йоклаучылар да бар.

Тәнзилә. Ә син нигә монда?

Ризван. Минем нигәдер йокым килми. Туган көнемдә йоклап яту ничектер килешми дә.

Тәнзилә. Аңламассың сине... Нигә чакырдың?

Ризван. Яр буйлап үзеңә генә йөрү күңелсездер дип уйладым.

Тәнзилә. Минем күңелемне ачарга теләмисеңдер ич?

Ризван. Юк, үз күңелемне ачарга телим.

Тәнзилә. Шулаймыни? (*Ризванга төбәлеп карап тора.*)

Ризван. Нигә шулчаклы текәлеп карыйсың?

Тәнзилә. Синең кемлегеңне беләсем килә. Ничә ел бергә укып, аз гына да белмәгәнмен.

Ризван. Серле кеше мин, Тәнзилә.

Тәнзилә. Бүтәннәр йоклый дисең инде?

Ризван. Кайберәүләр йокламый. Низам, мәсәлән.

Тәнзилә. Гомәр белән Заһир йоклыймы?

Ризван. Гомәрне белмим, Заһир йоклый.

Тәнзилә. Аны йоклатып качтыгызмы?

Ризван. Йоклаган йоклый, йокламаган йокламый.

Тәнзилә. Нинди афоризм! Йә, ни сөйләшәбез?

Ризван. Индеме? Инде сөйләшәбез шул хакта... Әгәр дә синең минем белән сөйләшәсең килсә.

Тәнзилә. Ни өчен сөйләшмәскә?

Ризван. Син миңа бераз көлебрәк карыйсың бит.

Тәнзилә. Ничек көлебрәк?

Ризван. Ничек икәнен аңлатып бирә алмыйм. Көлебрәк, мыскыл итебрәк. Янәсе, мин синең өчен икенче сорт.

Тәнзилә. Мин кешеләрне сортларга аермыйм.

Ризван. Беләм, мин барысын да күзәтеп йөрим. Еш кына миннән көләләр, ләкин мине белми көләләр, көлгән кешеләр бервакыт үзләре дә белерләр.

Тәнзилә. Сөйләмә юкны, Ризван, кем синнән көлсен!

Ризван. Көләләр. Бер сүз әйтсәм, син дә көләчәксең.

Тәнзилә. Мәсәлән?

Ризван. Мин сине яратам, дисәм... Әнә, әйтәм бит, көләсең.

Тәнзилә. Көлмим ич.

Ризван. Авыз читең белән сиздермичә көләсең.

Тәнзилә. Кызык кеше икәнсең. Ратканыңны әлегә хәтле сизгәнем юк иде.

Ризван. Ә мин сиздермичә яратам.

Тәнзилә. Рәхмәт! Синнән ул сүзне ишетү куанычлы хәл, Ризван. Тарих моны онытмас, алтын хәрефләр белән язып куяр. Ләкин син кызлар белән сөйләшмәскә ант иткән кеше бит, Ризван.

Ризван. Әйе, иткән кеше.

Тәнзилә. Ә үзең сөйләшәсең.

Ризван. Сөйләшү белән сөйләшүнең аермасы бар. Әгәр дә мин синең белән сөйләшер өчен сине махсус эзләп йөрсәм, антымны бозган булыр идем. Бу очраклы сөйләшү.

Тәнзилә. Мәхәббәт сөйләрлек булгач очраклы сөйләшү буламы?

Ризван. Була. Мин бит «мәхәббәт» сүзен телгә алмадым, яратам, дисәм, дип кенә әйттем. Шуны белеп торсаң, бүгенгә шул җитә. Калганын киләчәк күрсәтер.

Тәнзилә. Бар икән күрәселәр!..

Ризван. Әйе, бар. Җитди сөйләшүгә әзер тор, Тәнзилә.

Тәнзилә. Баш өсте, тәкъсир! Җитди кеше белән җитди сөйләшергә туры килер. Тик Заһир белән нишләрбез икән соң, ул да бит мине ярата.

Ризван. Яратам дип әйткәне бармы?

Тәнзилә. Әлегә юк югын. Ләкин...

Ризван. Димәк, мин беренче әйттем. Монысы – бер. Икенчедән, Тәнзиләне бер генә егет яратырга тиеш дигән закон юк.

Тәнзилә. Әмма минем берәүне генә яратырга хакым бар.

Ризван. Кемне дип сорамыйм, киләчәк күрсәтер.

Тәнзилә (*Гомәр килгәнен күреп*). Әнә Гомәр сине эзләп чыккан.

Ризван. Гомәр?.. Тәнзилә, мин сине күрмәдем. (*Китәргә җыена.*)

Тәнзилә. Ничек инде күрмәдең?

Ризван. Күрдем, ләкин күрмәдем. Аңладыңмы?

Тәнзилә. Аңламадым.

Ризван. Миңа моннан тиз генә китәргә кирәк.

Тәнзилә. Юк инде, чакырып алдың да хәзер качасыңмы?

Ризван. Ярый, ярый, күрдем. Ләкин очраклы гына. Мин сиңа яратам дип әйтмәдем. Аңладыңмы?

Тәнзилә. Аңламадым.

Ризван. Гомәр белмәсен, Гомәр сизмәсен. Теле озын.

Гомәр керә

Гомәр. Исәнмесез! (*Тәнзиләгә.*) Хәерле төн, Низам!

Ризван. Низам түгел ул, Тәнзилә.

Гомәр. Шулаймыни? Син Низамны эзләргә киткән идең ич.

Ризван. Без очраклы очраштык.

Тәнзилә. Һәм Ризван миңа яратам дип әйтмәде.

Ризван. Әйтмәдем дә. Әгәр дә Низамны күрсәгез, әйтегез, кайтып йокласын. Мин аны эзләүне дәвам итәм. (*Ашыгып чыгып китә.*)

Гомәр. Әллә ниләр эшләнә бу дөньяда. Тәнзилә белән төн уртасында Ризван басма өстендә басып тора, дисәләр, үлсәм дә ышанмас идем.

Тәнзилә. Инде ышанырсың.

Гомәр. Ярый, ышанырбыз. Ләкин хәзергә шул урыннан кузгалмый тор.

Гомәр тиз генә чыгып китә дә Заһирны җитәкләп керә.

Мин Низамны эзләргә чабам. Мин әйләнеп килгәнче, Тәнзиләне шуннан җибәрмә. Аңа әйтәсе бер-ике сүзем бар. (*Чыгып китә.*)

Озак пауза. Тәнзилә чыгып китә башлый.

Заһир (*исенә килеп*). Китмә инде, Тәнзилә.

Тәнзилә. Китсә ни булган?
Заһир. Гомәр җибәрмәскә кушты.
Тәнзилә. Ә син җибәрмә.
Заһир. Тотып тора алмыйм ич инде сине.
Тәнзилә (*Заһир каршына тасраеп килеп баса*). Элек, ичмасам, шигырь укый идең. Инде анысын да оныттыңмыни? Гомерең буе кушканны гына эшләсәң, нишләрсең соң син? Ничек яшәрбез соң без синең белән?
Заһир. Ничек дидең, Тәнзилә?
Тәнзилә. Берни дә әйтмәдем.
Заһир. Яшәрбез, дидең. Яшәрбез булгач, бергә яшәү була түгелме соң? Бергә. Икәү. Гомер буе. Уйлап әйттеңме, Тәнзилә, уйнап әйттеңме?
Тәнзилә. Мин дә синең кебек филология факультетында укыйм, сүзләрнең кирәген сайлый беләм.
Заһир. Рәхмәт!
Тәнзилә. Нигә рәхмәт, нәрсәгә рәхмәт?!
Заһир. Сүзләрнең матурын сайлый белүеңә рәхмәт.
Тәнзилә. Син... син бит шигырь язасың, телеңә бер дә матур сүз килмимени?
Заһир. Минем күңелем тулы матур сүзләр.
Тәнзилә. Шуларның берсе минем өчен кызганычмыни?
Заһир. Түгел, Тәнзилә. Мин аларның барысын да сиңа әйтер идем.
Тәнзилә. Әйт соң, кайчаннан бирле көтәм.
Заһир. Көтәм?.. Рәхмәт, Тәнзилә. Мин алай дип уйламаган идем.
Тәнзилә. Ничек яшәрбез без синең белән?
Заһир (*шигырь укый*).

Күңелемнең кыллары бар тибрәнмәгән,
Кылларында көйләрем бар көйләнмәгән,
Сүзләрем күп, серләрем бар сөйләнмәгән,
Шау чәчәкле җәйләрем бар җәйләнмәгән...

Тәнзилә. Ничек итеп яшәрбез без синең белән?
Заһир. Йөрәгемдә сагыш түгел, көн дә бәйрәм –
Ярсуларым уйный анда әйлән-бәйлән,
Юлларымның очы әле төйнәлмәгән,
Хисләремнең тезгеннәре бәйләнмәгән.

Тәнзилә. Ничек итеп яшәрбез без синең белән! Сокланам мин сиңа, Заһир, һәм куркам. Саксыз кыланып синең күңелеңне ватармын дип куркам.

Пауза.

Заһир. Тәнзилә!..
Тәнзилә. Нәрсә, Заһир?
Заһир. Юк, юк... Ярамый. Ярамый, Тәнзилә!
Тәнзилә. Нәрсә ярамый, Заһир?
Заһир. Антны бозарга ярамый.
Тәнзилә. Нинди ант? Бүтәннәргә кушылып, ни эшләгәнеңне белмичә эшләү ант буламы? Низам белән Ризван шаярганга син чынлап ышангансың.
Заһир. Ант белән шаярып буламы?
Тәнзилә. Булмый.
Заһир. Димәк...
Тәнзилә. Димәк, икенче тапкыр ант иткәндә, ни өчен ант иткәнеңне белеп итәрсең. «Ант» сүзенең мәгънәсен аңлап эшләрсең.
Заһир. Ләкин... Ләкин мин ант иттем.
Тәнзилә. Син аны төштә күрдем дип исәплә.
Заһир. Юк, төштә түгел, өндә. Үз телем белән...
Тәнзилә. Алайса, безнең бу сөйләшү төшеңдәдер...
Заһир. Юк, юк!

Гомәр тамак кыргалап керә.

Гомәр. Йә, ничек, Заһир дус, шигырь языламы?
Заһир. Языла, Гомәр, языла.
Гомәр. Язганнарың Тәнзиләгә ошыймы?

Тәнзилә. Бик ошый.
Гомәр. Бик әйбәт. Инде, Заһир, бар, Тәнзиләңне озатып куй да монда кил.
Заһир. Нигә килим?
Гомәр. Һай, сорау бирмәсеннәр иде дөньяда. Кушканны эшлә.
Тәнзилә. Исеңдә тот, Гомәр, Заһир хәзер сез кушканны гына эшләмәячәк.
Гомәр. Шулаймыни?.. Бик яхшы. Минем күптәнге хыялыма син ирешкәнсең, Тәнзилә. Әмма бу юлы Заһирның сине озатып монда әйләнеп килүе кирәк.
Тәнзилә. Әгәр мин кайтырга теләмәсәм?
Гомәр. Тагын да әйбәтрәк. Барыгыз, култыклашып әнә теге урыннарда йөреп торыгыз. Мин сызгырган тавышны ишетүгә, чабышып монда килерсез. Зинһар өчен, нигә дип сорамагыз. Уңышлар телим.

Заһир белән Тәнзилә чыгып китә. Гомәр басма өстенә кереп аякларын бөкләп утыра да гитара чиртә. Ризван керә.

Ризван. Низамны тапмадыңмы, Гомәр?
Гомәр. Таптым бит, әй.
Ризван. Кайда?
Гомәр. Палаткада йоклап ята.
Ризван. Булмас.
Гомәр. Булган шул менә. Сиңа да вакыт. Каңгырып йөрмә.
Ризван. Хәзер кайтам. Гомәр, сез миннән көләсез, әйеме? Юморны аңламый, дисез. Беләсеңме, бүген мин юмор сүз уйлап чыгардым.
Гомәр. Яле, яле?..
Ризван. Басмасы бар, Әсмасы юк.
Гомәр. Ничек, ничек?
Ризван. Басмасы бар, Әсмасы юк. Уңышлы юмор бит, әйеме?
Гомәр. Шаккаткыч! (*Кычкырып көлә башлый, аңа Ризван кушыла. Гомәр, көлүеннән кинәт туктап.*) Әйдә кайтабыз, юморист.
Ризван. Кая?
Гомәр. Кайда яшәгәнеңне оныттыңмы әллә?
Ризван (*үз халәтенә кайтып*). Онытмадым. Мин әле кайтмыйм.
Гомәр. Антыңны бозасыңмы?
Ризван. Антның монда катнашы юк. Үземнең туган көнемдә басма өстендә ялгызым гына уйланып утырырга хакым бар.
Гомәр. Утыр алайса. Мин кайтам, йокым килә. (*Чыгып китә.*)

Ризван басма өстендә бөеренә таянып басып кала. Алинә керә.

Алинә. Ялгышмагансыз. Басманы эзләп тапкансыз.
Ризван. Эзләмәдем, үзе очрады.
Алинә. Юлыгызга чыгып ятканмыни?

Ризван җавап бирми. Пауза.

Ризван. Төн бик матур.
Алинә. Искиткеч!..
Ризван. Елга да бик матур.
Алинә. Гаҗәеп!..
Ризван. Йолдызлар да бик матур.
Алинә. Сөйлисе дә юк.

Пауза.

Ризван. Сез курыкмыйсызмы?
Алинә. Нәрсәдән?
Ризван. Нәрсәдән түгел, кемнән!
Алинә. Кемнән?
Ризван. Миннән.
Алинә. Ни өчен?
Ризван. Төн бит.
Алинә. Булса ни?
Ризван. Аулак урын бит.

Алинә. Булса ни?
Ризван. Һе...
Алинә. Нәрсә hе?
Ризван. Мин килдем бит.
Алинә. Күреп торам.
Ризван. Сезнең чакыруыгыз буенча килдем.
Алинә. Мин сезне чакырмадым.
Ризван. Сез нәрсә мине ахмакка санныйсыз? Мин намек белән сөйләшкәнне аңлыйм.
Алинә. Шулай укмыни?
Ризван. Әйе. (*Алинәнең кулын тота.*)
Алинә. Нишлисез?
Ризван. Кулыгызны тотам.
Алинә. Ни өчен?
Ризван. Бу нинди тиле сорау. Шуны да белмәскә...
Алинә. Чынлап та белмим. Йөрәк тибешемне тыңлар өченме?
Ризван. Сезнең йөрәк тибешегез миңа нигә кирәк? Мин врач түгел. Төшенегез, әгәр мин сезнең кулыгызны тотам икән, бу – мәхәббәт аңлату билгесе. Аңладыгызмы, ниһаять?
Алинә. Аңладым, ниһаять. Сез булмасагыз, белми үләсем икән. Инде нишлибез?
Ризван. Мәхәббәт турында җитди итеп сөйләшәбез. Аңлагыз, мин шаярып сөйләшмим. Әгәр дә мин ни дә булса әйтәм икән, бу – чын. Һәм мин сүзләремне чын итеп кабул итүләрен таләп итәчәкмен. Аңлашыламы?
Алинә. Аңлашыла. Ләкин, ялгышмасам, сез мәхәббәт турында сөйләшмәскә ант иткәнсез.
Ризван. Антны мин иткән, сез түгел. Нигә борчыласыз?
Алинә. Болай гына әйтүем.
Ризван. Болай гына әйтү өчен нигә сүз әрәм итәргә.
Алинә. Алайса дәшмим.
Ризван. Дәшмәгез һәм мин сөйләгәнне генә җитди итеп аңлагыз. Димәк, болай...

Кинәт Нәҗип гармунының әче итеп кычкырган тавышы ишетелә.
Нәҗип үзе дә күренә. Ризван куркуыннан басма читенә үк чигенә.

Нәҗип (*басма янына ук килеп*). Эләктеңме, апаем? Теге юлы бирәвегез ычкынды, бу юлы ычкына алмассың. Алинә, мин алар кебек матур итеп сөйләшә алмыйм. Турыдан-туры ярып әйтәм: чык басмадан.
Алинә. Нәҗип абый, нишләвегез бу?
Нәҗип. Мин Нәҗип абый түгел, миңа әле утыз гына яшь. Сиңа егерме. Чык басмадан. Беркая да китмәенчә янымда тор. Мине тиң күрмәсәң дә, мин әйткәннәрне бу юлы тыңла. Яратмасаң, соңыннан әйтерсең.

Алинә басмадан чыга. Ризван да кузгала.

Нәҗип. Ә син, апаем, селкенмә.
Ризван. Шаярмагыз.
Нәҗип. Шаярмаем, апаем. Сиңа бу якка юл юк. Теге якка йөзеп чык.
Ризван. Мин сезнең авылга Культура йорты салырга килгән кеше. Мине хөрмәт итүегезне үтенәм.
Нәҗип. Культура сараен басма өстендә төнлә салмыйлар. Сикер суга.
Ризван. Алинә, әйтегез аңа, шаярмасын.
Нәҗип. Мин хәзер беркемне дә тыңламаем. Чум суга.
Ризван (*кычкырып*). Мин йөзә белмим.
Нәҗип. Кычкырма, апаем, мин курыкмаем. Районга – глава, авылга – мин хуҗа. Йөзә белмәгәч, басма өстенә кермиләр аны. Сикер, чум! (*Әкрен генә басмага керә.*)
Ризван. Килмә, батып үлсәм, судка бирәчәкмен, җавап бирәчәксең, закон нигезендә.
Нәҗип. Әһә, шүрләдеңме? Әйт, Нәҗип абзыкаем, исән-сау җибәрсәң, Алинәнең кырына да килеп карамам, диген. Ак тәүбә, кара тәүбә, диген.
Ризван. Ак тәүбә, кара тәүбә...
Нәҗип. Инде хәзер шул тәүбәңне җыр белән әйт.
Ризван. Җырлый белмим.
Нәҗип. Суга төртеп төшерсәм, өйрәнерсең. Йә... башла! (*Гармунын тартып җибәрә.*)
Ризван (*бераз аптырап тора да, җиңел генә котыла алмаячагын аңлап, җырлый башлый*).

Былтыр җуйган балдагымны
Быел таптым утлыктан;

Жырлыйсым килеп жырламыйм,
Жырлыйм чарам юклыктан.

Нәҗип. Шулай, шулай, апаем. Кычкырыбрак. (*Үзе җырлап җибәрә.*)

Агыйделнең аръягында
Төшеп калды галушым;
Тагын берне жырлап җибәр,
Ишетелсен тавышың.

Ризван. Уфа безгә ерак түгел,
Телефон алдырмагыз;
Жырла диеп, җыр җырлатып,
Тавышсыз калдырмагыз.

Гомәр керә. Керә дә ике бармагын авызына тыгып сызгыра. Шуны гына көткәндәй, Дамирәне җитәкләп, Низам пәйда була.

Низам (*белмәгәнгә салынып*). Ни булды, ә, ни булды? Йокларга яткан җиремнән сызгырып уяттыгыз.

Ризван. Әй сез! Алыгыз бу мир үгезен юлымнан. Ул мине суга батырырга теләде.

Нәҗип. Тик тор, апаем! (*Егетләргә.*) Алинә белән сөйләшеп торганда эләктердем мин аны. (*Гомәргә кулын сузып.*) Тот Нәҗип абзыкаеңның кулын, дөрес әйткәнсең, алдамагансың. Тач шушы урында басып торалар иде.

Ризван. Иптәш Шәйхетдинов, бу этлекне, димәк, син эшләдең?! Без синең белән аерым сөйләшербез. (*Басмадан чыгарга килә.*)

Нәҗип. Кузгалма, апаем, урыныңа бас.

Ризван. Белеп торыгыз: безнең бригадада сатлыкҗан иптәш Шәйхетдинов яши. (*Тәнзилә белән кергән Заһирга мөрәҗәгать итеп.*) Син дә ишет, Заһир, Гомәргә безнең коллективта урын юк... Әйе, диген.

Гомәр. Антыңны син боздың, Ризван.

Ризван. Мин бозмадым, боздырдылар. (*Алинәгә күрсәтә.*)

Алинә (*көлеп*). Кем миңа мәхәббәтен җырлады?

Тәнзилә. Яратам дип миңа кем әйтте, Ризван?

Ризван. Әһә, син дә миңа каршы, Тәнзилә... Ярый, ярый... Көлегез миннән. Мин антымны боздым, суга сикерәм, батып үләм. Тик минем белән бергә Низам да, Заһир да антларын боздылар. Низам, Заһир, рәхим итегез минем янга!

Низам. Дөрес, Ризван. Мин һәрвакытта синең белән. Бәхил бул, Дамирә! (*Басмага кереп, Ризван янына баса.*) Заһир, рәхим ит!

Тәнзилә. Заһир антын бозмады.

Заһир. Яклавың өчен рәхмәт, Тәнзилә. Тик мин алар янында булырга тиеш.

Тәнзилә. Син миңа яратам дип әйтмәдең бит.

Заһир. Телем әйтмәсә дә, күңелем сөйләде. Күзләреңә карап тордым. (*Ризван белән Низам янына кереп баса.*)

Гомәр. Шагыйрь чыгачак синнән, Заһир. (*Егетләргә.*) Йә, нишлибез, әфәнделәр?

Низам. Суга сикерәбез, батып үләбез.

Гомәр. Ашыкмагыз, әфәнделәр! Шарт буенча җәзаны мин билгелим. Суга чумып котылмакчы буласызмы? Ә Культура йортын бүтәннәр төзеп бетерсенме? Ашыкмагыз, шаярмагыз! Кисәттем мин сезне. Мин рәхимсез, дидем, җәза каты булачак, дидем. Инде шаярмыйча тыңлагыз. (*Җитди тонга күчеп.*) Без, гомумән, шаярырга яратабыз. Шаянлык, җорлык, әлбәттә, кеше өчен тормышта кирәк нәрсә. Бик кирәк! Ләкин без чамадан да чыгып китәбез бугай. Онытылып китеп изге хисләр, изге сүзләр белән шаярабыз. Нәтиҗәдә хисләребез тупаслана, бөек сүзләр арзаная, үзебез вакланабыз. Мәхәббәт, Ватан, Ант! Бу сүзләрнең мәгънәсен аңлатырга җыенмыйм. Без аларны беләбез, бәлки, аңлыйбыздыр да. Ләкин... ләкин... Шаярган арада бераз гына, аз гына булса да уйланып куйыйк. Ант... Күпме бөек җаннар, гомерләре бәрабәренә, шушы изге сүзгә турылыклы булып калганнар! Бернинди дә җәза бирмим мин сезгә, дуслар! Без бит шаярдык кына, бары тик шаярдык кына. Ак тәүбә, кара тәүбә. (*Шаян тонга күчә.*) Йөзләрегез нигә җитдиләнде, әфәнделәр? Нигә боегып калдыгыз? Әйдәгез әле, без бит яшьләр, безгә боегу килешми. (*Гитарасын чиертә. Җыр башлый. Аңа бүтәннәр кушыла.*)

Күңелдә җыр туа,
Күңелгә нур тула,
Талларда
Таңнарда

Сандугач сайраса, моңланса;
Сандугач кунармы талларга,
Сандугач сайрармы таңнарда,
Бу җирдә мәхәббәт булмаса?

Пәрдә.

# Читлек

*Бер пәрдәле драма*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Акбүре.
Урман мәчесе.
Кабан.
Төлке.
Бурсык.
Куян.
Мәче.
Дуңгыз.
Эт.

Сәхнәдә дуга рәвешендә тезелгән читлекләр. Уртада Акбүре ябылган читлек. Бер читтә эт оясы. Ут Акбүре читлегенең ишеген яктырта. Анда Акбүре, арт аякларына басып, ал аяклары белән рәшәткә тимерләренә тотынган да Сорыкаен чакыра.

Акбүре. Соры-ка-ай! Соры-ка-ай! Син мине ишетәсеңме, Соры-ка-ай? (*Туктап тыңлый. Җавап ишетмәгәч, тагын улый.*) Соры-ка-ай...

Ерактан Сорыкайның улавы ишетелә.

Сорыкай. Акбүре-е-е! Син мине ишетәсеңме, Акбүре-е-е?
Акбүре. Ишетәм, Сорыкай, ишетәм, бәгырькәем!
Сорыкай. Син кайларга китеп югалдың, Акбүре?
Акбүре. Мин еракта, Сорыкай! Бик-бик еракта. Ишетәсеңме, Сорыкай? Мин еракта.
Сорыкай. Ишетәм, Акбүре! Мин сине сагындым. Нигә килмисең, Акбүре?
Акбүре. Килә алмыйм, Сорыкай!
Сорыкай. Мин сине сагындым, Акбүре!
Акбүре. Мин дә сине сагындым, Сорыкае-ем!
Урман мәчесе (*читлегенең ишеге янына килеп*). Туктыйсыңмы син, юкмы улавыңнан?!
Акбүре. Мин уламыйм, мин сөйгән ярым белән сөйләшәм.
Урман мәчесе. Сөйгәннәр синдә генә түгел. Тукта улавыңнан. Болай да башны кая куярга белмим.
Акбүре. Мин дә җаным сызлавыннан улыйм.
Урман мәчесе. Монда җаны сызламаган җан юк. Мин дә урманымны, балаларымны сагынам. Сагынуыма түзә алмый читлек тимерен кимереп, тешләрем коелып бетте.
Акбүре. Безне монда нигә яптылар? Нигә бикләп тоталар?
Кабан (*үз читлеге ишеге янына килеп*). Безне йә аталар, йә ябалар. Безне итебез өчен аталар. Урман мәчесен тиресе өчен. Бүреләрне тиреләре һәм сарыкларны бугазлаган өчен.
Акбүре. Мин бугазламадым.
Урман мәчесе. Бугазласаң ни булган? Син шуның белән җан асрыйсың. Син бугазлар өчен яратылган. Бөтен җан ияләре дә шундый, кемдер кемне бугазлый.
Кабан. Кешеләр үзләре дә бугазлый. Алар бугазлаган сарыкны нигә бүреләр бугазламаска тиеш.
Акбүре. Атсыннар, нигә ябып тоталар?
Кабан. Анысын инде кешеләрдән сора. Тик син улама гына. Күңелгә шом саласың.
Сорыкай. Акбүре-е! Нигә Сорыкаең янына килмисең?
Акбүре. Әнә бит Сорыкай елый.
Кабан. Бу дөньяда кемдер елый, кемдер көлә. Бүре дустым, син әле яшь. Менә мине ите каты, карт дип инде атмыйлар да. Читлегеңнең арткы читенә барып ят та тынычлан.
Акбүре. Мин барыбер качачакмын.
Сорыкай. Акбүре, ник дәшмисең? Нигә җавап бирмисең, Акбүре? Ишәтәсеңме мине?
Акбүре. Ишетәм, Сорыкай!

Урман мәчесе. Улама! Улаудан мәгънә юк, beләсеңме шуны. Сез беркайчан да күрешә алмаячаксыз. Дәшмә. Өметен өзсен. Үзеңне һәм аны газаплама.
Акбүре. Мин барыбер качачакмын.
Урман мәчесе. Качкач уларсың. Ә хәзергә бәргәләнмә. (*Читлек ишеге яныннан китә.*)
Акбүре. Сорыкаем мине сагына.
Кабан. Сагыныр да туктар. Икенче тәүлек туктаусыз улыйсың. Бар, ятып ял ит!
Акбүре. Мин качачакмын. (*Читлек артына китә.*)
Кабан. Читлекне качырыр өчен ясамыйлар. Качып та кая барасың? Дөнья яралганнан бирле без һаман танавыбыз белән җир актарабыз. Һаман актарабыз. Ә кешеләр безне һәм үз-үзләрен үтерү өчен ниләр генә уйлап чыгармыйлар. Без нигә үзгәрмибез дә безне үтерүчеләр нигә һаман үзгәрә? Әллә алар җан иясе түгел микән?

Кабан янына Дуңгыз килә.

Дуңгыз. Исәнме, Кабан туганым!
Кабан. Исәнме!
Дуңгыз. Хәлләрең ничек?
Кабан. Читлектәге кабанның хәле ничек булсын инде?
Дуңгыз. Син миңа үпкәләмә инде, туганым! Ярдәм итә алмыйм шул. Минем ирегем дә чикләнгән. Минем дә Кабан буласым килә. Үз иркемдә йөрисем килә.
Кабан. Ишегалды читлек түгел инде.
Дуңгыз. Урман да түгел. Нишлисең, миннән инде дуңгыз ясадылар. Түз инде, туганым, ярдәм итә алмавыма ачуланма.
Кабан. Безне нишләтергә җыена хуҗаң?
Дуңгыз. Алар уен кем белә? Бәлки, синнән дә дуңгыз ясамакчылардыр. Ләкин дуңгыз булма, туганым!
Кабан. Картайдым инде мин дуңгыз булырга.
Дуңгыз. Мин үз язмышымны беләм, туганым! Симертәчәкләр дә суячаклар. Картайганымны да көтмәячәкләр.

Эт керә.

Эт (*Дуңгызга*). Син нишлисең монда?
Дуңгыз. Туганым белән сөйләшәм.
Эт. Нинди туган ул сиңа? Ул – Кабан, син – Дуңгыз. Ычкын моннан!
Дуңгыз. Эт башың белән миңа өрмә.
Эт. Эт өрер өчен, Дуңгыз мыркылдар өчен яратылган. Ычкын! Йөрмә буталып.
Дуңгыз. Без аерым яратылмаган. Безне аерганнар.
Эт. Акыл сатма. Бар абзарыңа.
Дуңгыз. Син дә ояңа кер.
Эт. Мин саклар өчен куелган.
Дуңгыз. Куелган, куелган... Куелган шул. Куйганнар шул.
Эт. Мыркылдама, диләр. (*Кабанга.*) Син дә йокла.
Кабан. Кабаннар төнлә йокламый, надан.
Эт. Өйрәтмә. Йокларга өйрән. (*Читлекләр буйлап күзәтеп-каранып йөри.*)

Хуҗаның тавышы ишетелә. Үзе күренми.

Хуҗа. Һәй, Эт! Син кайда?
Эт. Читлекләр янында, хуҗам!
Хуҗа. Тәртипме?
Эт. Тәртип, хуҗам!
Хуҗа. Кара аны, тәртип булсын. Ул-бу булса, бәйгә куеп чыбыркы белән суктырырмын.
Эт. Борчылмагыз, хуҗам! Барысы да сез теләгәнчә булыр.
Хуҗа. Мин бүренең улаганын ишеттем. Йокымнан уятты.
Эт. Улый иде, тынды, хуҗам!
Хуҗа. Аны ныграк сакла. Ул гади бүре түгел, ул Акбүре. Мин аны зоопаркка кыйбатка сатачакмын.
Эт. Аңладым, хуҗам. Йокыгыз тыныч булсын, тәмле төшләр күрегез, хуҗам. (*Үтеп барышлый Төлке читлеге янына туктала. Читлек ишегеннән карап торучы Төлкегә.*) Син нигә йокламыйсың?
Төлке. Ә мин сезне көтәм.
Эт. Ни булды?

Төлке. Йокы алдыннан йөреп керү файдалы бит, Эт иптәш. Сез, миңа мәрхәмәт күрсәтеп, йокы алдыннан йөреп керергә рөхсәт итә идегез.

Эт. Нәрсә, аяклар оедымы?

Төлке. Оеды шул, Эт галиҗәнаплары.

Эт. Ярый, остарма. (*Читлек ишегеен ачып.*) Чык. Ләкин миңа якын килмә. Хәйләләп маташсаң, өзгәләп ыргытырмын. Шуны бел – моннан беркая китә алмыйсың. Бөтен тирә-як тимер челтәр белән уратып алынган.

Төлке. Беләм, Эт иптәш. Мин бөтенесен дә беләм.

Эт. Телеңә салынма. Йөр.

Төлке. Йөрим, Эт иптәш.

Эт. Иптәш димә. Мин сиңа иптәш түгел.

Төлке. Гафу итегез. Хәзер ул сүз модада түгел бугай шул. Телисезме, мин сезгә әфәнде дип эндәшәм.

Эт. Йөр. Күп сөйләнмә.

Төлке. Телисезме, Эт әфәнде, мин сезгә Төлке биюен күрсәтәм. Сез, оягыз өстенә менеп, биюемне карагыз.

Эт. Тик кара аны, хәйләләп маташма. (*Оясы өстенә менеп ята.*)

Төлке. Минем бу биюем «Тычкан аулаганда» дип атала. Сез беләсездер, кыш көннәрендә без кар астындагы тычканнарны аулыйбыз.

Эт. Лыгырдама, бие.

Төлке. Баш өсте. (*Бии.*)

Эт. Читкә китмә.

Төлке (*биеп туктагач*). Ничек, Эт әфәнде?

Эт. Булды. Бар, кереп ят читлегеңә.

Төлке. Әлбәттә, әлбәттә. Мин сезнең һәр боерыгыгызны үтим. Чөнки хөрмәт итәм. Сез читлекләр яныннан үтеп киткәндә, мин сокланып калам. Сәламәтлекләрегез ничек, Эт иптәш?

Эт. Синекеннән яхшырак.

Төлке. Мин бик шат.

Эт. Маташтырма, барыбер җибәрмим.

Төлке. Мин биредән китәргә дә уйламыйм. Монда рәхәт, тыныч. Кирәк икән, ятам да йоклыйм. Сезгә читен, төн буе йөрисез.

Эт. Эшем шул. Хуҗам мине шуның өчен ашата.

Төлке. Аңлыйм, аңлыйм. Безне нигә ашата икән хуҗагыз, анысын аңламыйм.

Эт. Аңларсың, тиреңне тунагач.

Төлке. Юк, Эт әфәнде, тиремне тунар өчен булса, тотканда ук аткан булыр иде. Ә ул ябып куйды. Димәк, уе бүтән. Нишләтер икән?

Эт. Зоопаркка сатар. Минем хуҗам синең ишеләрне тота да зоопаркка яки циркка сата.

Төлке. Нәрсә ул зоопарк? Нәрсә ул цирк?

Эт. Зоопаркка кешеләр синең ишеләрне карарга киләләр. Өлкәннәре балаларын ияртеп килә. Сөйлиләр балаларга: әнә ул арыслан, әнә ул фил, әнә ул төлке, диләр. Циркка эләксәң, анда сине биергә өйрәтәләр. Минем кебек этләрне арбага утыртып тартып йөрергә өйрәтәләр. Синең мине тартып йөргәнеңне кеше балалары карап тора да кул чаба. Аңладыңмы инде?

Төлке. Әгәр мин тартып йөрергә теләмәсәм?

Эт. Теләмәсәң, ашатмыйлар, кыйныйлар.

Төлке. Алай икән... Эт әфәнде, сез мине моннан чыгарып җибәрә аласызмы?

Эт. Алам.

Төлке. Алай икән...

Эт. Нәрсә алай икән? Бар, кереп ят урыныңа. (*Төлкенең җилкәсеннән тотып, читлек эченә ыргыта. Ишекне бикләп куя.*)

Урман мәчесе (*читлек ишеге янына килеп*). Миңа да аяк язып керергә ярыйдыр.

Эт. Ярамый.

Урман мәчесе. Нигә?

Эт. Чөнки минем сиңа көчем җитми. Сиңа аяк яздырып, үзем аяктан егылуымны теләмим.

Урман мәчесе. Шулай шул синең кебекләр. Без читлек эчендә булганда гына батыраясыз. Без иректә булганда, койрыгыгызны кысасыз.

Эт. Әйе, кысабыз. Эләкмәскә иде хуҗаның авына. Эләккәч шыңгырдама. Кит ишек яныннан. (*Куян читлегенең ишеге янына килә. Ишекне ача.*) Әй, кылый күз, озын колак. Чык читлектән!

Куян (*калтыранып чыга*). Нишләтәсең?

Эт. Нишләтим сине, бер кабарлык итең юк. Йөр.

Куян. Кая йөрим?

Эт. Кая? Кая? Ишегалды буйлап чап.

Куян. Нигә?

Эт. Мескен, нигә дигән була. Чабып тормасаң, аякларың хәлсезләнә, ахмак. Әллә шуны да белмисеңме?

Куян. Беләм дә бит. Чапсам, кыйныйсың бит.

Эт (*кычкырып көлә*). Ә син тоттырма. Куянның батырлыгы тоттырмавында. Әй мескен! Белмим, Хуҗам сине нигә ашатып торадыр? Нигә кирәгең бар, кемгә кирәгең бар инде?

Куян. Булгач кирәктер инде. Кирәкмәсәк, булмас идек.

Эт. Карале, ниләр сөйләгән була.

Куян. Әллә ярамаган сүз әйттемме?

Эт. Ярый, ярый. Куянга килешә. Чап әйдә, мин сине куам. Тоттырма. Тотсам, тагын тотып дөмбәслим. Чап. Миңа тренировка кирәк. Монда сине саклап, аякларымның җитезлеге бетте. Чап, нәрсә карап торасың?

Куян чаба, Эт аны куа. Куып тота алмагач кычкыра.

Эт. Тукта! (*Туктаган Куян янына килә.*) Калтырама, тимим. Бар, кереп ят.

Куян читлеккә кереп китә дә ишекне яба.

Эт. Саубуллашырга онытгың, мокыт.

Куян. Сау бул! Ә нигә син минем читлекнең ишеген бикләмисең?

Эт. Кая китә аласың син, мескен. Ят! (*Бүтән читлекләрне тикшереп китә.*)

Сорыкай. Акбүре-е! Нигә дәшмисең, Акбүре?

Акбүре. Сорыкай! Мин ишетәм сине, Сорыкай!

Эт (*борылып кереп*). Тагын уларга тотындыңмы? Тукта хәзер үк. Тукта, диләр. Кил әле монда.

Акбүре (*читлек ишеге янына килеп*). Йә, килдем.

Эт. Син нигә туктаусыз улыйсың, ә? Тукта улавыңнан.

Акбүре. Туктамасам нишләтәсең?

Эт. Син кайда икәнлегеңне онытма, кем икәнлегеңне бел. Онытма, син тимер читлек эчендә. Бу сиңа урман түгел уларга.

Акбүре. Мин ирекле җан.

Эт. Ирекләләр читлектә утырмый.

Акбүре. Минем җаным ирекгә.

Эт. Ахмак!

Акбүре. Ә син сатлыкҗан.

Эт. Сүзеңне үлчәп сөйлә. Мин берәүне дә сатмадым. Мин хуҗама турылыклы хезмәт итәм.

Акбүре. Син нәселеңне саткан мескен.

Эт. Мин эт нәселеннән.

Акбүре. Алдашма. Синең бабаларың бүре булган.

Эт. Кемнең кем булганында минем эшем юк. Шуны гына беләм: мин – ирекгә, син – читлектә. Мине ашаталар, сезне аталар. Утыр анда нәселеңне уйлап. Уласаң, суктырырлар. Синең кебекләрне акылга утырта белә минем хуҗам. Синең шикелле берәү улап маташкан иде, хәзер циркта арбага утырган маймылны тартып йөри. Икенче берегез зоопарк читлегендә йөренә. Качып киткән булган да, ашарына таба алмагач, кире кайткан.

Акбүре. Мин кайтмаячакмын.

Эт. Ахмак! Кайтмас өчен әле башта качарга кирәк. Ә без сине качырмаячакбыз. Сатлыкҗан дип мыскыл иткән өчен читлегең яныннан китмичә саклаячакмын. Әгәр дә сине хуҗам циркка сатса, мине арбага утыртып тартып йөриячәксең. Анда синең ише ахмаклар гына түгел, арыслан ишеләр дә бер шакмак шикәр өчен арт аякларында торалар. Аңлыйсыңмы шуны, маңка?

Акбүре. Мин аңларга теләмим, теләмәячәкмен.

Эт. Аңламасаң, шыңшы алайса.

Акбүре. Минем улавымны шыңшу дип атама.

Эт. Ай-яй-яй! Нинди «батыр»! Әнә шул батырлыгың аркасында эләктең дә инде. Бүтәннәр качып котылды, син миңа ташландың.

Акбүре. Аның каравы Карт бүре белән Сорыкай исән калды.

Эт. Әлегә исән калды. Тиздән атачаклар. Син исән калганыңа сөен. Ак төсле булуыңа рәхмәт әйт. Яхшылап әйткәнне тыңла, улама! Алдыңа ыргыткан сөякне кимер.

Акбүре. Ачтан үлсәм дә мин ул сөякне кимермәячәкмен.

Эт. Кимерерсең. Кимертә торган дөнья бу. Сарык кебек үлән ашарга өйрәнерсең әле. Сатлыкҗанның ни икәнен шунда аңларсың. (*Үтеп баручы Мәчене күреп алып, юлына аркылы төшә.*) Тагын Урман мәчесе янына барасыңмы?

Мәче. Юк, һава суларга гына чыктым.

Эт. Һаваны бүтән җирдә сула, читлекләр янында сулама.

Мәче. Син мине өйрәтмә. Кайда телим, шунда сулыйм.

Эт. Беләм мин синең нигә чыкканыңны.

Мәче. Белгәч, бик яхшы.

Эт. Бар, кереп кит өеңә.

Мәче. Керермен дә, чыгармын да. Миңа хуҗа булма. Мин – Мәче. Аңлыйсыңмы, мин – Мәче, син эт кенә. Хуҗа мине өендә асрый, сине ишегалдында тота. Понял, товарищ собака?

Эт. Ул миңа ышана.

Мәче. Ышанса, ул сине үзе янында яткырыр иде. Менә мине яткырган кебек. Кит юлымнан! Мин үземнең туганымның хәлен белергә барам.

Эт. Нинди туган булсын ул сиңа?

Мәче. Ул – Урман мәчесе, мин – йорт мәчесе. Язмыш безне аерган. Ләкин туганлыктан аермаган. Әнә Дуңгыз да бит туганы Кабан янына килеп китә. Син дә Бүре янына килгәнсең.

Эт. Мин аңа туган итеп килмим, улавыннан туктатырга киләм.

Мәче. Туган итмәгәч бик начар. Оч-чень плохо, паршивая Собака.

Эт. Ни дидең, нәрсә дип әйттең?

Мәче. Нәрсә ишеттең, шулай дип әйттем.

Хуҗа (*тавышы ишетелә*). Әй, Эт! Нинди тавыш анда?

Эт. Мәче сүземне тыңламый, Хуҗам.

Хуҗа. Әй, Мыраубикә, Эт белән эт булма.

Мәче. Нәрсә, хөрмәтле вә гыйззәтле Хуҗам, миңа ишегалдында урын да юкмыни йөрергә?

Хуҗа. Йә, йә, үпкәләмә. Кер, мин сине югалттым.

Мәче. Сагындым дип әйтергә телисеңме?

Хуҗа. Әйе, сагындым. Кер, озак йөрмә.

Мәче (*ысылдап*). Ишеттеңме, корчаңгы эт кисәге. Кит юлымнан.

Эт. Тагын бер адым ул якка атласаң...

Мәче. Нишләтерсең икән, мескенкәем?

Эт. Менә болай эшләтермен.

Эт Мәче өстенә ташлана. Әүмәкләшеп чыгып китәләр. Тирә-як тынып кала. Еракта Сорыкайның улавы ишетелә.

Сорыкай. Акбүре-е-е! Ишетәсеңме мине, Акбүре?!

Акбүре (*читлек ишеге янына килеп*). Сорыка-ай!

Сорыкай. Мин сагындым сине, Акбүре!

Акбүре. Сорыка-ай!

Үз читлегенең ишеге янына Төлке килә.

Төлке. Җиттеме инде сиңа, юкмы, Акбүре! Йокларга комачаулыйсың.

Акбүре. Син йоклый аласыңмы?

Төлке. Нигә йокламаска?

Акбүре. Читлектә йоклап буламы?

Төлке. Йокласаң була. Әнә Бурсык уянмыйча йоклый.

Бурсык (*читлек ишеге янына килә*). Кем миңа нәрсә әйтте?

Төлке. Әнә Акбүре әйтә, читлектә йоклап булмый, ди.

Бурсык. Белмим, мин йоклыйм.

Төлке. Әнә Акбүре йоклый алмый. Улый да улый.

Бурсык. Улап ни мәгънә?

Төлке. Мин дә шулай дим. Кычкырасың икән, аның мәгънәсе булырга тиеш. Аны кемдер ишетергә тиеш. Ишеткәчтен, ниндидер нәтиҗә ясарга тиеш. Уладың ни, уламадың ни. Читлек хуҗасы рәхәтләнеп йоклый. Безне саклаучы Эт Мәче белән ызгыша. Дөнья шулай корылган. Кемнәрдер йоклый, кемнәрдер ызгыша, ә Акбүре улый. Ирек, дигән була.

Акбүре. Мин барыбер качачакмын.

Төлке. Качып нишли аласың? Кайчан атарлар икән дип куркып яшәргәме? Монда ичмасам тыныч. Ашарга бирәләр.

Акбүре. Минем тамагымнан аш үтми. Мин барыбер алар биргәнне ашамаячакмын.

Төлке. Юкка. Биргәндә ашарга кирәк.

Бурсык. Әйе, биргәндә ашарга кирәк.

Акбүре. Тыңлап-тыңлап торам да, сезгә читлектә рәхәт кебек.

Төлке. Юк, рәхәт түгел. Читлек ул читлек. Ләкин язмыш дигән нәрсә бар, Акбүре туган. Язмышка яраклашырга кирәк. Дөрес әйттемме, Бурсык?

Бурсык. Әйе, язмыштан узмыш юк.

Урман мәчесе (*ишек янына килеп*). Сез нәрсә лыгырдыйсыз монда? Нинди язмыш, нинди узмыш? Ирек турында уйларга кирәк.

Төлке. Уйла инде, уйла. Кимер читлек тимерен. Ирек турында иректә уйларга кирәк, җанкисәкләрем. Монда әләккәч уйладың ни, уйламадың ни. Дөрес әйтәмме, Бурсык?

Бурсык. Уйлар өчен кешеләр бар.

Төлке. Менә! Акыллы Бурсыктан акыллы сүз.

Акбүре. Сез – мескеннәр.

Төлке. Син алай мыскыл итеп сөйләмә, Акбүре. Син мескен түгел дә бит, безнең белән бер читлектә. Ишекләр генә аерым.

Урман мәчесе. Читлектә булсаң да, ирек турында хыялланырга кирәк. Ирек турында хыяллану да рәхәт.

Төлке. Мин дә хыялланам, ләкин бәргәләнмим. Берәр җай чыгар. Бәлки, Хуҗа чыгарып җибәрер. Дөрес әйтәмме, Бурсык?

Бурсык. Юк.

Төлке. Ничек юк?

Бурсык. Эләккәнне чыгармыйлар. Мин йокларга киттем.

Урман мәчесе. Син җанвар түгел, Бурсык.

Бурсык. Түгелдер. Җанвар булсак, үтереп маебызны эчмәсләр иде.

Төлке. Җанвар дигәннән, бәлки чыннан да без җанвар түгелдер, кешеләр җанвардыр. Ләкин син улама, Акбүре, улама.

Кабан (*ишеге янына килә*). Уласын, тимәгез!

Төлке. Син, Кабан, безнең сүзгә катышма! Башыңны җиргә төртеп йөреп, син берни дә күрмисең. Дөнья ул син танавың белән казып чыгарган үлән тамыры түгел.

Кабан. Сине хәйләкәр диләр, ә мин әйтәм – син кабахәт.

Төлке. Кабахәт булып мин нишләгән?

Кабан. Син ирекккә омтылучыларның күңелләренә курку саласың.

Төлке. Мин курку салмыйм, акыл белән яшәргә, дим.

Кабан. Төкердем мин синең акылыңа.

Төлке. Тукта әле, нәрсәгә дип җенләнәсең?

Кабан. Тимәгез Акбүрегә. Өметен кисмәгез сез аның.

Төлке. Мин сиңа бер сүз әйтимме, Кабан?

Кабан. Әйтеп кара.

Төлке. Син әйт менә, ни өчен кешеләр синең итеңне ашый, безнекен ашамый? Куянныкын ашыйлар, безнекен – юк. Ни өчен? Белмәсәң, әйтәм. Чөнки син җанвар түгел, син гап-гади хайван. Хайванның итен ашыйлар кешеләр, җанварныкын юк.

Кабан. Иректә булсак, күрсәтер идем күрмәгәнеңне бу сүзләр өчен.

Төлке. Читлекнең аның шул ягы яхшы да, Кабан. Монда сүз иреге. Теләсәң ни сөйләргә була. Ярый, сез улагыз, чинагыз, мин йокларга киттем.

Кабан. Күңелгә шом салып йөрүчеләрдән сак бул, Акбүре. Мин ишетәм, сиңа иректән кемдер җавап бирә.

Урман мәчесе. Ул аның Сорыкае. Матуркае. Нишләптер Эт күренми. Ул гел монда йөренә иде.

Кабан. Читлектә Төлке кебекләр булганда, Эт тә кирәкми. Нәрсә, яттыкмы? Син дә, Акбүре, ят, ял ит.

Тагын тынлык урнаша. Читлегенең ишеге янына Куян килә.

Куян. Сөйләшәләр, киңәшәләр, зарланалар. Мине искә алучы да юк. Берәрсе, Куян, син ни хәлләрдә, дип сорасыннар иде, ичмасам. Әйтерсең лә мин юк. Әйтерсең мин булмаган. Мин бар бит. Бар бит куяннар да җир йөзендә. Без дә, димәк, кирәк. Кирәк булмасак, булмас идек. Менә мине дә ябып куйдылар. Кирәк булганга япканнардыр. Шулай да нигә мине читлеккә яптылар? Бүреләрне ябып куйганны мин әле аңлыйм. Юк, бүреләрне дә ябарга ярамый. Без бит беребез дә ябылыр өчен яратылмаган. Без усал булсак та, куркак булсак та иректә яшәр өчен яратылган. Дөрес, иректә дә без куяннарга куркыныч янап тора. Ләкин безгә анда качып котылырга урмандагы куаклыклар, иркен кырлар бар. Безгә җитез аяклар, сизгер колаклар бирелгән. Безгә куркыныч янаса да, безнең нәселнең

корыганы юк. Их, хәзер иректә булсаң иде. Үрдән үргә озын колакларны баш артына салып җилдерсәң иде. Чабып арыгач, арт аякларга утырып, яллар итсәң иде, ирекле дөньяга карап торсаң иде...

Мәче керә. Куянны тыңлап торганнан соң, аның янына килә.

Мәче. Нәрсә, читлектә яшисе килмимени, Куян?

Куян китәргә җыена.

Син курыкма, читлекнең бер яхшы ягы бар. Син – миңа, мин сиңа тия алмыйм. Югыйсә сине бүре тотып ашар иде.

Куян. Иректә мин аңа тоттырмас идем.

Мәче. Шулайдыр. Ирекнең кадерен мәхлук Куян да аңлый шул. Качасың киләме соң?

Куян. Моннан мин түгел, Бүре дә кача алмый.

Мәче. Читлегеңнең ишеге ачык, чык та кач?

Куян. Ничек качыйм, читлектән чыксам, Эт саклап тора.

Мәче. Тора шул, тора. Этләр барында, читлек тә кирәкми. Ярый, бар, йокла. (*Утеп китеп, Урман мәчесе читлеге янына килә.*) Әй, агай-эне! Ишетәсеңме, мин бу – Мәче. Монда кил, братан!

Урман мәчесе (*читлек ишеге янына килеп*). Исәнме, дустым!

Мәче. Әкрен. Тавышланма. (*Читлек ишеген ачып.*) Ычкын. Тай...

Урман мәчесе. Ничек? Ә Эт кайда?

Мәче. Ул җәтмәдә.

Урман мәчесе. Нинди җәтмәдә?

Мәче. Күп сөйләмә, тай тизрәк. Хуҗа сизмәсен.

Урман мәчесе. Нигә мин генә?

Мәче. Башкаларда эшем юк. Син кач.

Урман мәчесе. Алай ярамый, дустым.

Мәче. Мин эшлисен эшләдем, калганын үзең кара. Мин Хуҗам янына киттем, ул мине сагынгандыр. Хуш, братан! Мәче нәселендәгеләргә сәлам әйт. (*Китеп бара.*)

Урман мәчесе (*Акбүре читлеге янына килә*). Акбүре... Чык әйдә. (*Читлек ишеген ача.*) Чык, без иректә.

Акбүре. Кем ачты?

Урман мәчесе. Кем ачса да барыбер түгелмени?! Әйдә...

Акбүре. Ә бүтәннәр?

Урман мәчесе. Мин тайдым, бүтәннәр сиңа кала. (*Кача.*)

Акбүре Төлке читлегенең ишеген ача.

Акбүре. Төлке, чык! Без иректә! Ишегең ачык.

Төлке (*каранып чыга*). Кем ачты? Ник ачты?

Акбүре. Мин ачтым.

Төлке. Ә син үз ишегеңне ничек ачтың?

Акбүре. Урман мәчесе ачты.

Төлке. Аның ишеген кем ачты?

Акбүре. Белмим.

Төлке. Белмәгәч нигә куанасың?

Акбүре. Без иректә, Төлке!

Төлке. Нинди ирек? Кем биргән ирек?

Акбүре. Кем бирсә дә, без иректә.

Төлке. Ирекне бирмиләр.

Акбүре. Күп сөйләмә инде, качыйк. Ач бүтәннәрнең ишеген.

Төлке. Ә нигә мин ачарга тиеш?

Акбүре. Чыксыннар. Бергә качыйк.

Төлке. Ә нигә бергә качарга?

Акбүре. Бар алайса, син кача тор.

Төлке. Нигә әле мин беренче качарга тиеш? Син беренче чыктың, син кач.

Акбүре. Күп сөйләнергә вакыт юк. Бар. (*Ишекләрне ача.*) Чыгыгыз! Чыгыгыз! Без иректә! (*Чыгып китә.*)

Бурсык (*читлек ишегенең ачык икәнлеген күреп аптырый. Карана.*) Нигә ачык бу ишекләр? Алар ачык булырга тиеш түгел иде бит.

Төлке. Аларны Акбүре ачкан.

Бурсык. Нигә?

Төлке. Син качсын дип.
Бурсык. Ә Акбүре үзе кайда?
Төлке. Качты.
Бурсык. Ә син нигә качмадың?
Төлке. Мин сине көтеп тордым.
Бурсык. Моннан качып буламыни?

Кабан чыга.

Кабан. Ни булды? Нигә ачтылар?
Бурсык. Безгә качарга кушканнар.
Кабан. Кем?
Бурсык. Мин белмим. Төлке дә белми.
Кабан. Акбүре кайда?
Бурсык. Мин чыкканда юк иде.
Төлке. Акбүре качты.

Акбүре атылып керә.

Акбүре. Бөтен тирә-якта биек коймалар. Кабан, әйдә койма астын казырга.
Кабан. Нәрсә, качабыз дисеңмени?
Акбүре. Ә син ни дисең соң? Читлектә яшәү сиңа ошыймыни?
Кабан. Киттек.
Акбүре (*Бурсык белән Төлкегә*). Ә сез нәрсә карап торасыз? Киттек.
Төлке. Башта сез койма астын казып карагыз әле.
Акбүре. Озакламагыз.

Китәләр.

Төлке. Син нигә качмыйсың?
Бурсык. Син ник качмыйсың?
Төлке. Мин көтәм.
Бурсык. Кемне?
Төлке. Кабан белән Акбүрене.
Бурсык. Алар качтылар.
Төлке. Алар әле качмадылар. Бәлки, тотып китерерләр. Бәлки, атып үтерерләр.
Бурсык. Алайса, мин дә уйлыйм әле. Шулай да... Качыйк без дә, Төлке!
Төлке. Ашыкма, Бурсык! Мин дә ирекнең кадерен беләм. Ләкин мин авантюрист түгел. Куркынычның авызына барып керергә ашыкмыйм. Карап карыйк, бүтәннәр нишләрләр. Бу читлекләрнең ишекләре нигә ачылган? Нинди ният белән ачылган? Аз гына көтик. Акбүрене тотып китермәсәләр, Кабанны атмасалар, Куян кайтмаса, без дә шыларбыз. Яңадан тотып китерерлек булгач, нигә качарга?!
Бурсык. Без беләбез инде, син – хәйләкәр. Шулай да бүтәннәр качканда аерылып калу әллә ничек.
Төлке. Әллә ничек булса, бар, ияр аларга. Мин сине тотып тормыйм!
Бурсык. Күпме көтәрбез икән? Акбүре ошый миңа. Бүреләр ни әйтсәң дә тәвәккәл халык.
Төлке. Шуңа күрә аларны кыралар да читлек хуҗалары.
Бурсык. Безне дә кызганмыйлар инде. Китик, Төлке!
Төлке. Ашыкма, диләр сиңа. Китүеңнән элек кайтырыңны уйла. Читлектән качып котылып булмый, туган. Бер уйлап карасаң, дөнья гел читлектән генә тора. Кешеләр үзләре дә бит читлектә яши.
Бурсык. Китик, Төлке! Ярый, ачулансаң ачулан, мин тәвәккәлләдем. Бөтенесе качканда, йоклап калыр хәлем юк. Сау бул! (*Китеп бара.*)
Төлке. Ахмак!

Акбүре керә.

Акбүре. Кабан койма астыннан юл ясады. Әйдәгез.
Төлке. Акбүре, нигә әле син мине куасың?
Акбүре. Җай чыкканда тизрәк качып калырга кирәк. Этнең кайтып керүе ихтимал.
Төлке. Нигә әле мин качарга тиеш?
Акбүре. Нәрсә, иректә яшәргә теләмисеңме? Син ирекле җан түгелмени?
Төлке. Ирек бит ул чагыштырмача төшенчә. Берәүгә ирек, икенчесенә, бәлки, ирек түгелдер.
Акбүре. Нәрсә? Читлектә яшәү рәхәтмени сиңа?
Төлке. Рәхәтлек тә чагыштырмача төшенчә. Берәүгә рәхәттер, икенче берәүгә михнәттер.

Акбүре. Син, Төлке, койрыгың белән уйлыйсың.
Төлке. Синең дә койрыгың бар, Акбүре! Без барыбыз да койрыклылар.
Акбүре. Син куркак, Төлке!
Төлке. Син куркак түгел дә бит, читлектә яшәдең.
Акбүре. Яшәдем. Хәзер яшәмәячәкмен.
Төлке. Син, Акбүре, мине генә кыстама. Куянга да әйт. Бәлки, аның да качасы киләдер. (*Куян читлеге янына барып.*) Куян, әй, Куян! Сине Акбүре абыең чакыра.

Калтыранып, читлегеннән Куян чыга.

Куян. Акбүре, тимә миңа, минем бер гаебем дә юк.
Акбүре. Гаеп эзләп тора торган вакыт түгел. Койма астында Кабан казыган тишек бар, шуннан сыптыр.
Куян. Кая?
Акбүре. Кая булсын, урманыңа, кырыңа. Әйдә минем арттан.

Эт чабып керә.

Эт. Стоп! Керегез читлекләрегезгә.
Акбүре. Куян, Төлке, качыгыз!

Куян чыгып чаба.

Эт. Син!.. Син ни сөйлисең, ә? Кем ачты ишекләрне?
Акбүре. Без.
Эт. Кем ул сез?
Акбүре. Без ул без.
Эт. Күрсәтермен мин сиңа «без»не. Кер читлегеңә.
Акбүре. Читлек сиңа күбрәк килешә. Син өйрәтелгән читлектә яшәргә. Кит юлымнан.
Эт. Кер, диләр. Югыйсә...
Акбүре. Нишләтерсең. Йә, йә, кил мондарак. Тотып ал мине, яп читлегеңә.

Хуҗаның тавышы ишетелә.

Хуҗа. Әй, Эт! Нинди тавышлар анда?
Эт. Хәзер, хәзер, Хуҗам, барысы да тәртиптә булыр.
Акбүре. Барысы да тәртиптә булыр. (*Эткә ташлана.*)

Алышалар, сугышалар.

Эт. Хуҗам! Качалар! Качтылар!.. Коткар!..

Мылтыктан аткан тавыш. Эт белән Акбүре бер-берсенә ябышкан килеш егылалар. Төлке читлектән чыгып качарга чамалый. Мылтыктан
аталар. Төлке егыла.

Сорыкайның тавышы ишетелә.

Сорыкай. Акбүре-е-е! Син мине ишетәсеңме, Акбүре-е! Кайт! Балаларың көтә.

Пәрдә.

# Гашыйк буласым килә

*Ике пәрдәле тамаша*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Акбай
Дүрткүз авыл этләре.
Тәмлетамак – авыл мәчесе.
Чарли – фатирда яшәүче шәһәр эте. Пудель нәселеннән.
Бурзай
Сарбай
Муйнак шәһәрдәге урам этләре.
Актүш
Бульдог
Барбос

**БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ**

Авыл. Ишегалды. Эскәмиядә Тәмлетамак ята. Аңа күңелсез. Боргалана, әле уң ягына, әле сул ягына әйләнеп ята. Торып йөренә дә тагын килеп ава. Торып сәхнә алдына килә. Залга карап сүз башлый.

Тәмлетамак. Нишләп йөрисез монда? Нигә килдегез? Әллә авыл мәчесен күргәнегез юкмы? Менә күрегез инде, күрегез. Менә мыекларым, менә колакларым, менә койрыгым. Сез инде миннән көләргә килгәнсездер. Көлегез. Мыскыл итегез. Авылда ятып сөрсеп беткән, диегез. Ә минем көләсем килми. Туйдым авылдан. Туйдым авыл эте Акбай белән ызгышып. Хәзер ул да картайды. Туйдым авыл тычканнарыннан. Их, Казанда яшәсәң иде ул. Анда күңелле. Телевизордан карап ятам. Рәхәтләнеп яшиләрдер Казан мәчеләре. Казанга 1000 ел тула, диләр. Их, шунда буталып йөрсәң иде ул. Бәйрәм итәсе килә, күңел бәйрәм сорый. Ә монда күңелсез. Эч поша. (*Эскәмиягә ятып, җыр суза.*)

Дөньялары кызык түгел,
Әллә ниләр эзли күңел.
Кая барыйм, нишлим икән?
Үз хәлемне үзем беләм –
Эчем поша, үләм, үләм.
Тәмле түгел сөтләре дә,
Эч пошыра этләре дә,
Кайдан кызык табыйм икән,
Юк кәефем, күңел сүрән.
Эчем поша, үләм, үләм.

Уф, уф! Кемгә барып бәйләнергә? Кем белән ызгышырга?

Музыка яңгырый. Шул музыка ритмында әйләнгәләп, сикергәләп, Дүрткүз керә. Аңа бүген рәхәт, аңа дөнья матур, дөнья киң. Биюен-
нән аны, кычкырып, Тәмлетамак туктата.

Дүрткүз. Күрми дә торам... Исәнме, Тәмлетамак!
Тәмлетамак. Исән булмасам, әллә син мәче докторымы?
Дүрткүз. Акбай абый өйдәме?
Тәмлетамак. Юк.
Дүрткүз. Кайда икән, белмисеңме?
Тәмлетамак. Белмим. Беләсем дә килми.
Дүрткүз. Әллә кәефең юкмы, Тәмлетамак?
Тәмлетамак. Юк, юк, юк. Ун тапкыр юк, йөз тапкыр юк, мең тапкыр юк.
Дүрткүз (*ишегалдына кереп*). Нигә миңа кычкырасың? Мәче башың белән.
Тәмлетамак. Нигә син эт башың белән мәче хәлен сорыйсың?
Дүрткүз. Без бит күршеләр.
Тәмлетамак. Булмагаең.
Дүрткүз. Әллә берәр хәл булдымы?
Тәмлетамак. Булмады шул. Булса кызык булыр иде. Яшәүләре кызык түгел, беләсеңме син шуны, ахмак.
Дүрткүз. Сиңа нинди кызык кирәк соң?
Тәмлетамак. Ә мин каян белим. Кызык түгел – бетте-китте, вәссәлам!
Дүрткүз. Ә син гашыйк булып кара, Тәмлетамак.
Тәмлетамак. Нәрсә-ә-ә?
Дүрткүз. Гашыйк бул. Берәр матур гына песигә гашыйк бул. Аның турында уйла. Вәт шунда кызык була.
Тәмлетамак. Ни сөйлисең син, тиле. (*Көлә башлый. Эчен тотып та көлә, тәгәри-тәгәри дә көлә.*) Уф, үләм. Нәрсә сөйлисең син, Дүрткүз бәгырькәем? Нәрсә лыгырдыйсың син, көчек?
Дүрткүз. Дөньяның кызыгы, Тәмлетамак, мәхәббәттә, ярата белүдә. Менә син миңа кара. Мин бит гашыйк булырга җыенам, Тәмлетамак! (*Җырга күчә.*)

Миңа рәхәт яшәүләре бу дөньяда,
Күңелемә һәр мизгелдә гөлләр ява,
Күзем йомып ачкан саен, дөнья яңа,
Минем өчен күктә яңа йолдыз яна.

Җырлар җырлап, челтер-челтер чишмә ага,
Җир өстенә төн патшасы ак ай калка.
Минем өчен таң сылу –
Таң каршылап, сайрар кошлар моң тарата,
Куанычлар, сөенечләр, шатлык арта.
Әнә елга дулкыннарын ярга кага,
Тулган ай да, нурын чәчеп, миңа бага,
Рәхмәт яусын, рәхмәт яусын бу дөньяга.

Тәмлетамак. Ходаем! Беткәнсең бит син. Тилергәнсең бит син. Шулай инде, бәрәңге чәчәк атканда, этләр котырып ала.

Дүрткүз. Син дә гашыйк бул, Тәмлетамак!

Тәмлетамак. Надан баш. Мәчеләр бит март аенда гашыйк була. Йа Алла, кемгә гашыйк булдың инде?

Дүрткүз. Кемгә икәне әле билгеле түгел. Минем әле гашыйк буласым гына килә. Яратасым килә.

Тәмлетамак. И-и-и! Ычкынгансың син. Кемне яратасың килә соң?

Дүрткүз. Белмим әле. Күңелемдә менә гыйшык уты кабынды. Менә дөрли-дөрли яна.

Тәмлетамак (*янә тәгәри-тәгәри көлә*). Уф, үләм! Койрыгыңа ут капмасын. Кемне яратырга да белмәгәч, гашыйк булып буламы? Менә мине ярат, миңа гашыйк бул. (*Көлә.*)

Дүрткүз. Юк, Тәмлетамак. Сиңа гашыйк булырга ярамый миңа. Син бит мәче, мин бит эт.

Тәмлетамак. Этле-мәчеле йөрербез.

Дүрткүз. Үзем кебек этне яратасым килә.

Тәмлетамак. Әнә Акбайны ярат, аңа гашыйк бул.

Дүрткүз. Ярамый, Тәмлетамак. Ул бит ата эт, мин дә ата эт.

Тәмлетамак. Аңладым, аңладым. Сиңа кызлар кирәкмени?

Дүрткүз. Әйе, кызларга гашыйк буласым килә.

Тәмлетамак. Алай икән. Рәхмәт, Дүрткүз, кәефемне күтәрдең. Рәхәтләнеп көлдем. Табып биримме соң үзеңә этләр кызын.

Дүрткүз. Безнең авылда юк.

Тәмлетамак. Каян килсен авылга рәтле эт. Эт кызларының матурлары Казанда. Телевизорда карап яттым, мин сиңа әйтим, йөриләр килештереп. Синең өчен генә тәрбияләп үстергәннәр диярсең. Барыйк, Дүрткүз, Казанга.

Дүрткүз. Акбай абый ни дияр бит.

Тәмлетамак. Әйт аңарга. Үләм, Акбай абый, Казандагы эт кызларын яратасым килә, диген. Тәмлетамак та барсын безнең белән, диген. Син кода булып барырсың, Тәмлетамак кияү егете булып барсын, диген.

Дүрткүз. Эт туенда мәче кияү егете була алмый.

Тәмлетамак. Ярый, ярый. Болай гына барырмын. Мин дә мәче егетләре күреп кайтырмын. Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итәрбез. (*Чарлины күреп алып.*) Туктале, Дүрткүз, тукта. Әнә кара әле. Үзе монда килә. Гашыйк бул шуңа.

Дүрткүз. Кем соң ул?

Тәмлетамак. Казаннан килгән эт кызы. Аның хуҗасы безнең авылныкы икән, моны да ияртеп кайткан. Кара син аның кыяфәтләрен. Кара башын боргалап атлауларын. Әгәр дә мин синең сыман эт булсам, аңа үлеп гашыйк булыр идем. Гашыйк бул син аңа. (*Мәгълүм бер җырны җырлап.*)

Гашыйк бул син аңа,
Вакытлыча гына булса да.

Кара, чибәр бит.

Дүрткүз. Чибәр. Каршына барыйм микән?

Тәмлетамак. Ашыкма. Башта без синнән герой ясыйбыз. Кызлар алар мәче булсалар да, эт булсалар да, кеше булсалар да батыр егетләрне яраталар. Синнән дә батыр ясыйбыз.

Дүрткүз. Ничек итеп?

Тәмлетамак. Тыңла. Мин хәзер аны монда куып китерәм. Кысрыклыйм. Син качып тор. Мин аңа «күзләреңне тырнап чыгарам» диюгә, син атылып чык та миңа ташлан. «Үтерәм, чәйнәп ташлыйм» диген. Мин курыккан булып китәрмен. Син батыр булып калырсың, кыз синеке булыр. (*Чыгып китә.*)

Тәмлетамакның әллә нинди тавышлар чыгарып мияулаганын, Чарлиның өргәнен ишетеп кача. Тәмлетамак белән Чарли куышып
керәләр. Чарли, чигенеп, рәшәткәгә сыена.

Чарли. Ләң, ләң, ләң... Килмә якын. Кем син?

Тәмлетамак. Син үзең кем? Безнең авылда нишләп йөрисең?
Чарли. Нишләп йөрүемдә синең эшең булмасын. Хулиган!
Тәмлетамак. Мин хулиган гына түгел, мин – бандит, мин – боевик. Әйт яхшы чакта, ник безнең авылга килдең!
Чарли. Хуҗам алып кайтты, беләсең килсә. Ул шушы авылныкы!
Тәмлетамак. Мин шушы авылның атказанган песие. Миннән бөтен авыл этләре куркып тора. Мин егерме этнең койрыгын өздем, утызының колагын чәйнәдем, кырыгының күзен тырнап чыгардым. Ә безнең авыл этләре синең ише генә түгел. Безнең авыл этләре беләсеңме кемнәр?! (*Такмаклап.*)

Безнең авыл этләре –
Этләрнең егетләре,
Казаннарның этләре –
Авыл эте бетләре.

Чарли. Ләң, ләң, ләң, ләң, ләң, ләң, ләң.
Авылыгызны беләм.
Авылыгыз этләреннән
Койрыгым болгап көләм.

Тәмлетамак. Безнең авыл этләре –
Биек тау бөркетләре.
Элеп алып селкеп сала
Синдәй эт кебекләрне.

Чарли. Ә син, кошка поршивая,
Мактанма этләр белән.
Мактансаң этләр белән,
Ләң, ләң, ләң, ләң, ләң, ләң, ләң.

Тәмлетамак. Туктале, тукта... Нәрсә диден син? Күрсәтәм хәзер паршиваеңны! Мияу-у-у...
Чарли. Килмә якын. Хәзер хуҗама шылтыратып әйтәм. Ул килеп җитәр дә кирәгеңне бирер.
Тәмлетамак. Нәрсә? Нәрсәңне шылтыратырсың...
Чарли. Менә күрәсеңме бу сотовый телефонны. (*Муенына аскан кесә телефонын күрсәтә.*) Бер кнопкасына басуым була, хуҗам килеп җитә.

Тәмлетамак Чарлидан кесә телефонын тартып ала.

Бир, бир телефонымны?!
Тәмлетамак. Тукта, карыйм әле. Кайсы җиренә басасы? Күрсәт.
Чарли. Бир, бир!..
Тәмлетамак. Кычкырма. Шушы җиренәме?
Чарли. Шунда.

Тәмлетамак Чарли күрсәткән төймәгә баса. Телефоннан «Чарли! Син кайда?» дигән калын тавыш ишетелә.

Тәмлетамак (*телефонны муенына асып куя*). Шәп әйбер икән бу.
Чарли. Бир, бир!..
Тәмлетамак. Казан этләренә генә телефон асып йөрергә димәгән, авыл мәчеләренә дә телефон килешә.
Чарли (*өреп, Тәмлетамакка ташлана*). Ләң, ләң, ләң, ләң!
Тәмлетамак. Өргән була тагын мескен. Хәзер мин синең күзләреңне тырнап чыгарам.
Дүрткүз (*атылып чыга*). Чыгарып кына кара. Үтерәм, чәйнәп ташлыйм.
Тәмлетамак (*курыккан булып чигенә*). Зинһар, зинһар, тимә! Китәм, китәм...
Дүрткүз. Бир алган әйбереңне хуҗасына.
Тәмлетамак. Бирәм, бирәм... (*Телефонны бирә.*)
Дүрткүз. Күземнән югал!
Тәмлетамак. Югалам, югалам... (*Чыгып китә.*)
Чарли. Рәхмәт сезгә. Мин шундый курыктым.
Дүрткүз. Син безнең авылга кунакка кайттыңмыни?
Чарли. Әйе.
Дүрткүз. Чибәр икәнсең син.
Чарли. Мин бит авыл эте түгел, тәрбиядә генә яшим. Воспитанная.
Дүрткүз. Мин Дүрткүз исемле, синең исемең ничек?
Чарли. Чарли.

Дүрткүз. Синең гашыйк буласың киләме, Чарли?
Чарли. Что-о?
Дүрткүз. Минем яратасым килә, гашыйк буласым килә.
Чарли. Чудной...

Кесә телефоны шылтырый. Чарли тыңлый да «вәү, вәү, вәү» дип җавап бирә.

Мине хуҗам чакыра. Сау булыгыз!
Дүрткүз. Сөйләшеп торыйк инде бераз.
Чарли. Мине хуҗам чакыра. (*Китеп бара.*)
Тәмлетамак (*чыгып*). Их син, пешмәгән. Мин сиңа эт тотып бирдем. Яратасым килә, дидең, яратырга идең.
Дүрткүз. Бер күрүдәме?
Тәмлетамак. Бер күрүдә булмаса, булмый инде ул, Дүрткүз. Яшь шул әле син, бала гына. Эт тә түгел, көчек кенә әле син.
Дүрткүз. Көчек түгел, эт.
Тәмлетамак. Ярый, ярый, синеңчә булсын. Телефонын бирмәскә иде. Кыланалар Казандагылар. Этләре дә телефонлы.

Акбай керә.

Акбай. Нишләп торасыз монда?
Тәмлетамак. Менә күршебез Дүрткүзнең гашыйк буласы килә. Үләм, ди, яратасым килә, ди.
Акбай. Кемне?
Тәмлетамак. Үзе дә белми шул. Бер чибәр генә Казан этен куып китергән идем дә, ошатмады.
Дүрткүз. Мин ошамады димәдем.
Тәмлетамак. Алайса, нигә җибәрдең соң?
Акбай. Туктагыз әле. Кайсы эт, теге йоны кыркылган эт кисәгеме?
Дүрткүз. Эт кисәге түгел ул, Акбай абый.
Тәмлетамак. Беләсеңме, Акбай, шул эт хуҗасы белән телефоннан сөйләшә. Мин өйдә телевизор карыйм бит. Анда кеше белән кеше сөйләшә. Монда эт белән кеше сөйләшә. Нәрсә инде бу?
Акбай. Аптырама, Тәмлетамак. Цивилизация.
Тәмлетамак. Нәрсә-ә-ә?
Акбай. Цивилизация галәмәтләре. (*Дүрткүзгә.*) Әллә бик ошадымы, Дүрткүз?
Дүрткүз. Ошаганын белеп бетерә алмадым. Чибәр.
Акбай. Ул бит Казанда – өйдә яши торган эт, Дүрткүз. Сиңа карамас. Хәер, син үзең дә шәһәрдә туган. Урам көчеге идең. Ияртеп кайттым үзеңне. Менә гашыйк булыр яшькә дә җиттең.
Тәмлетамак. Казан дигәннән, Акбай, Казанга 1000 ел тула диме? Бик зурлап бәйрәм итәргә җыеналар, ди. Әллә без дә барыйкмы?
Акбай. Нәрсә калган анда безгә?
Тәмлетамак. Кешеләр арасында буталып йөрү рәхәт бит.
Акбай. Сиңа шул буталырга гына булсын.
Тәмлетамак. Барыйк, Акбай! Дүрткүз, әйт Акбайга, барыйк, диген.
Дүрткүз. Кая?
Тәмлетамак. Кара, бу бөтенләй саташкан. Безнең сөйләшкәнне дә ишетми. Казанга барасың киләме, дим? Казанга 1000 ел тулган, ди. Кызык булачак, ди. Менә анда кызлар күп инде сиңа. Юк, ишетми. Беткән бу, мескен. Әрәмәлекләрне урап кайтыйм.
Акбай. Кара аны, кошларга тия күрмә.
Тәмлетамак. Син бигрәк инде, Акбай. Рәзе мин кошларга тиям. (*Көйли-көйли боргаланып чыгып китә.*)
Акбай. Кыздыра башлады. Бар, Дүрткүз, үз ишегалдыңа кайтып, күләгәгә кереп ят. Юк-бар нәрсәләр белән башыңны катырма.
Дүрткүз. Яратасы килә бит, Акбай абый, гашыйк буласы килә.
Акбай. Булырсың. Эт бетмәгән дөньяда. Бар, кайт! (*Китә.*)
Дүрткүз. Кайт та кайт, дисең. Ә минем гашыйк буласым килә. Барыйк Казанга, анда эт кызлары күп, ди бит Тәмлетамак.
Акбай. Барыйк, дисеңмени?
Дүрткүз. Барыйк, Акбай абый. Гашыйк буласым килә.
Акбай. Син әйткәч бармый булмас инде, энекәш. Үземнең дә күптән булганым юк. Бәйрәм дә булгач, матурдыр Казан. Җыен, иртәгә иртүк китәрбез. (*Китеп бара.*)
Дүрткүз. Ур-ра! Казан тулы эттер инде, эт кызлары күптер инде! (*Җырга кучә.*)

Гашыйк буласым килә,
Яраттырасым килә.
Мин яратканны үземә
Караттырасым килә.
Яраттырасым килә,
Гашыйк буласым килә.
Мин яратканның күзенә
Карап торасым килә.

Дүрткүз җырлаганда, сәхнә әкренләп кенә караңгылана. Күктә түгәрәк ай калка. Дүрткүзнең җырлаганын Чарли күреп тыңлап тора.

Чарли. Браво! Браво!
Дүрткүз (*Чарлины күрүенә сөенеп*). Исәнмесез! Вау, вау!.. Хәерле төн!
Чарли. Исәнмесез! Ләң, ләң, ләң!
Дүрткүз. Рәхмәт мине эзләп килүеңә.
Чарли. Ә мин сезне эзләп килмәдем. Төнге прогулкага чыккан идек, җырлап утырганыңны күрдем дә туктадым. Сез нәрсә турында җырладыгыз?
Дүрткүз. Мәхәббәт турында.
Чарли. Ә нәрсә ул мәхәббәт?
Дүрткүз. Гашыйк булу.
Чарли. Ә нәрсә ул гашыйк булу?
Дүрткүз. Ярату.
Чарли. Ә нәрсә ул ярату?
Дүрткүз. Шуны да белмисезме? Менә берәүне күрәсең дә аны гел күрәсе килеп тора. Димәк, аны яратасың.
Чарли. Секс что ли?
Дүрткүз. Мин андый сүзне белмим. Яратуны гына беләм. Минем яратасым килә.
Чарли. Мине что ли яратасыгыз килә.
Дүрткүз. Анысын белмим әле.
Чарли. Мине көндез күрдегез, тагын күрәсегез килдеме?
Дүрткүз. Килде.
Чарли. Значит, мине яратасыз. (*Көлә.*)
Дүрткүз. Нигә син көләсең. Яраткан эттән көләргә ярамый.
Чарли. Мин бит сезгә «яратам» димәдем.
Дүрткүз. Яратмагач, нигә минем яныма туктадыгыз?
Чарли. Сез бит мине явыз мәчедән спасли.
Дүрткүз. Явыз түгел ул. Хәйләкәр генә ул. Шуңа күрә дә мәче ич инде ул.
Чарли. Безнең өйдә дә мәче бар. Ул ласковая.
Дүрткүз. Безнең авыл ошыймы соң сиңа?
Чарли. Юк. Койрыкка әллә нәрсәләр ябыша.
Дүрткүз. Тигәнәк инде ул. Ай сиңа ошыймы?
Чарли. Ай ай инде ул.
Дүрткүз. Ю-у-ук. Авылның ае матуррак, ди Акбай абый. Тулган айга карасам, минем җырлыйсым килә.
Чарли. Чудно...
Дүрткүз. Син бит Казан өендә ятып айны күрмисең.
Чарли. Миңа ул кирәкми дә. Аның каравы безнең Казанның 1000 еллыгы була.
Дүрткүз. Казан ул сезнеке генә түгел, безнеке дә. (*Телефон шылтырый.*)
Чарли (*телефонга*). Вәү, вәү!.. Ләң, ләң!.. Ярый, мин киттем, хуҗам чакыра. Хуш!.. (*Китеп бара.*)
Тәмлетамак (*килеп чыга*). Йә, ничек, Дүрткүз? Гашыйк булдыңмы?
Дүрткүз. Юк әле.
Тәмлетамак. Килгән бит. Чибәр бит.
Дүрткүз. Әллә нинди ул. Ул яратуның ни икәнен аңламый.
Тәмлетамак. Бигрәк нәзберек булып чыктың әле син.
Дүрткүз. Без бит мәчеләр түгел, Тәмлетамак, өй түбәләрендә мыраулап йөргәнне мәхәббәт дип атамыйбыз.
Тәмлетамак. Сөйләнүе, хәчтрүш. Бәрәңге бакчалары таптап чабышып йөрүегез мәхәббәт инде. Ишеттеңме Акбайның әйткәнен? Казанга барабыз, диде. Бар, ятып йокла. Булмаган мәхәббәтне көтеп утырма.

Ут сүнә. Ут янганда, Акбай, Тәмлетамак, Дүрткүз Казанга таба чабалар. Урман аланына җиткәч, каршыларына Бүре чыга.

Бүре. Стоп!

Акбай. Исәнме, Бүре!

Бүре. Исәнен исән дә. Бик еш йөри башладың әле урман аркылы.

Акбай. Казанга моннан туры бит.

Бүре. Туры дип... Синең бар авылың, минем бар урманым. Бутамыйк инде территорияләрне. Кешеләр бит шул территория өчен сугыша. Без акыллырак булыйк инде.

Акбай. Без бит синең урманыңны алырга килмәдек. Үтеп кенә китәбез. Син дә үтеп кит авыл аркылы, зыян гына салма.

Бүре. Кереп кара авылга, тотынасыз һауларга. Ярый инде үзегез генә булсагыз. Нигә инде бу мәчене ияртеп йөрергә.

Тәмлетамак. Син безгә баш булма, ярыймы. Бүре дигәч тә.

Акбай. Тик тор, Тәмлетамак!

Тәмлетамак. Тик тор дип... Нәрсә ул? Документың бармы урман синеке дигән?..

Бүре (*тешләрен күрсәтеп*). Менә минем документым, йолкыш.

Тәмлетамак. Синдә теш булса, миндә тырнак бар.

Акбай. Тәмлетамак, җитте! Юкса кайтарып җибәрәм. Бүре, син аның сүзенә карама инде. Мәче мәче инде ул. Казанга барырга кирәк безгә. Иртәгә Казанның бәйрәме бит, күрәсебез килә. Аннары менә энекәш тә, гашыйк буласым килә, ди. Авылда ул яратырлык этләр юк. Казанга барып эзләп карыйк.

Бүре. Бик тиз гашыйк буласыз сез этләр. Урманга килеп тә бүре кызларын аздырып йөрисез. Ни эт, ни бүре түгел балалар туа.

Акбай. Нишләтәсең инде, Бүре. Дөньясы тарайды, дөньясы кысанланды шул. Җибәр инде татулык белән син безне?! Ачуланышмыйк.

Бүре. Нинди бәйрәм соң ул Казан дигәнегездә?

Акбай. 1000 ел тула бит иртәгә. Казан салына башлауга 1000 ел.

Бүре. Нигә мин белмим? Менә сез этләр кешеләргә сатылдыгыз, әйеме?

Акбай. Сатылмадык инде, Бүре. Бергә яшәргә өйрәндек.

Бүре. Өйрәндегез шул. Ә бит сез бүре нәселеннән. Кешеләрнең дә татар, башкорт дигәннәре бүре токымыннан. Ак бүре булган аларның башлыгы. Оныттылар. Урманга безне атарга мылтык күтәреп киләләр. Нәрсә, сезне чакырдылармы?

Акбай. Без чакырганны көтеп тормадык инде.

Бүре. Оныттылар. Аңа китсә, кеше дигән җан иясе Казан шәһәренең нигезенә беренче ташны салганда, янында эт торгандыр.

Тәмлетамак. Мәче дә булган.

Сарбай, Актүш керәләр.

Бүре. Монысы тагын нәрсә? Стоп! Кая барасыз?

Акбай. Казан этләре алар. Мин аларны таныдым. Мин алар белән Казанда күрешкән идем. Исәнме, Сарбай туган! Кая чабасыз?

Сарбай (*Акбайны читкә алып китеп*). Эшләр начар, Акбай! Казанны чистарталар.

Акбай. Чистартса ни? Бәйрәм бит.

Сарбай. Бездән чистарталар. Урам этләрен җыялар.

Акбай. Кит аннан!.. Ни өчен?

Сарбай. Беләсең ич инде, Акбай. Үзләре безне башта урамга чыгарып ыргыталар, аннары безне гаеплиләр. Имеш, без кешеләрне тешлибез.

Бүре. Сез нәрсә, монда миңа каршы план корасызмы?

Акбай. Синең кайгы юк әле монда, Бүре туган. Казанда этләрне аулыйлар, ди.

Бүре. Ауламаска... Күбәйдегез.

Акбай. Алай димә инде, Бүре. Без дә бит җан ияләре. Нишләргә инде?!

Бүре. Нишләргә?! Авылга кайтып китәсез инде.

Сарбай. Авылга гына сыймабыз шул без.

Бүре. Урманда сезгә урын юк. Куяннар үзебезгә дә санаулы гына.

Акбай. Нишләргә соң... Без бит бәйрәмгә дип чыккан идек. Сезнең белән бергәләп бәйрәм итәрбез дигән идек... 1000 елга бер килгән бәйрәмне бәйрәм итмәсәк, нинди этләр инде без. Ярый, кайгырудан файда юк, гамәл кылырга кирәк. Болай итәбез. Кичкә хәтле монда торабыз, караңгы төшкәч, карарбыз. Бүре, рөхсәт ит кичкә хәтле торырга урманыңда.

Бүре. Бер сарык бирәсеңме?

Акбай. Әй Бүре, Бүре... Шундый чакта...

Бүре. Ярый, шаярдым гына. Тик шушы аланнан читкә тайпылмыйсыз. Ишетсен колагыгыз. Мин киттем, мине өердә көтәләр. Әгәр дә мәгәр мәчегез бер кошка тисә, сугыш чыгачак. (*Китә.*)

Тәмлетамак. Миннән качып ни сөйләшәсез сез?

Акбай. Казанда этләрне аулыйлар, ди.

Тәмлетамак. Шул кирәк. Йөрмәсеннәр хулиганланып.

Сарбай. Мәчеләрне дә аулыйлар.

Тәмлетамак. Монысы дөрес түгел! Мәчеләргә тиярге ярамый. Мәче ул мәче, эт кенә түгел.

Акбай. Бар, кайтып кит хәзер үк. Иярткәнгә рәхмәт юк.

Тәмлетамак. Әгәр дә мәче рәхмәт әйтә башласа, ул мәче булудан туктый, Акбай. Мәче горур һәм мөстәкыйль булырга тиеш.

Сарбай. Алайса, горур бул. Йөрмә безнең тирәдә. Мин сиңа Акбай түгел, ботарлап та ташлармын.

Тәмлетамак. Син безнең арага кермә. Без авыл этләре, авыл мәчеләре – тату яши беләбез. Әйеме, Акбай?

Акбай. Бар әле, ычкын әле моннан.

Тәмлетамак. Мине ташлап качып китмәгез. (*Китеп бара.*)

Акбай. Сөйләштек, Сарбай. Бәйрәмне барыбер бәйрәм итәчәкбез. Дүрткүз, кил әле монда, кайда син? Сарбай, син дә чакыр үзеңнекен.

Сарбай. Әй, Актүш, кил әле?! (*Актүш килгәч.*) Болай сөйләштек. Казанга төнлә кайтабыз, бәйрәм итәчәкбез. Ә хәзер күләгәдә ял итегез. Еракка китеп йөрмәгез.

Ут сүнә. Ут янганда, Дүрткүз ялгызы гына уйланып утыра.

Дүрткүз. Нигә җир өстендәге җан ияләре гашыйк булып кына яшәмиләр икән? Гашыйк буласың килүдән дә рәхәт нәрсә юк бит дөньяда. Гашыйк буласы килгәннәрнең күңелендә усаллык булмый.

Тәмлетамак керә.

Тәмлетамак. Нәрсә, Дүрткүз, һаман да гашыйк буласың киләме?

Дүрткүз. Кит әле, Тәмлетамак, уйларга комачаулама.

Тәмлетамак. Эт тә уйлый беләмени?

Дүрткүз. Нинди җан иясе син, Тәмлетамак. Үзең безнең белән йөрисең, үзең гел безгә каршы сөйлисең.

Тәмлетамак. Гадәтем шундый инде. Нишлим. Этләргә этлек эшлисем килә. Аңгыра, томана бит сез, нишләтим. Яныңда искиткеч чибәр эт кызы йөри, шуны күрмисең, гашыйк буласым килә дип елап торасың. Әнә кара теге эт кызына, синеке бит инде ул.

Дүрткүз. Килми бит минем янга.

Тәмлетамак. Егет булсаң, килерлек ит.

Дүрткүз. Ничек?

Тәмлетамак. Аның исеме – Актүш. Исемен кушып җыр җырла. Түшләрең ак, фәлән-төгән, диген. Яле, яле, син бит җыр чыгарырга оста.

Дүрткүз. Ак түшеңә башкаемны
Куясым килә.
Исемеңне күңелемә
Уясым килә.

Шулай җырласам ярар микән?

Тәмлетамак. Ишетүгә яныңа чабып киләчәк. Әйдә, мин качтым, син башла.

Дүрткүз (*җырлый*).

Ак түшеңә башкаемны
Куясым килә.
Исемеңне күңелемә
Уясым килә.

Актүш кереп тыңлап тора. Дүрткүз җырын дәвам итә.

Ак түшеңә карап-карап
Торасым килә.
Яратасым һәм дә гашыйк
Буласым килә.

Актүш. Матур җырлыйсыз икән.

Дүрткүз. Исәнмесез!

Актүш. Минем исемемне кайдан беләсез?
Дүрткүз. Түшегезгә карадым да Актүштер дип уйладым.
Актүш. Сез Дүрткүзме? Күз өстегездә ике сары төртке бар.
Дүрткүз. Дөрес. Дүрткүз мин. Ә минем абыем – Акбай. Ул мине көчек чагымда Казаннан ияртеп кайткан. Урам эте булмасын дип кызгандым, ди. Хәзер авылда яшим.
Актүш. Авылда әйбәттер инде. Туйганчы ашаталардыр.
Дүрткүз. Ашавын ашаталар да, гашыйк булырлык эт кызлары юк. Ә минем гашыйк буласым килә.
Актүш. Нәрсә соң ул гашыйк булу?
Дүрткүз. Гашыйк булу ул – ярату.
Актүш. Ә ярату нәрсә?
Дүрткүз. Ярату ул – мәхәббәт.
Актүш. Мәхәббәт нәрсә?
Дүрткүз. Казанда торып шуны белмисеңме?
Актүш. Белмәгәч белмим инде. Өйрәтегез.
Дүрткүз. Мәхәббәтне өйрәтеп булмый.
Актүш. Кызык икән сез. Өйрәтмәгәч, каян белим?
Дүрткүз. Мәхәббәт ул яраткан этеңне олылау, аны гел күрәсе килеп тору. Әйтегез әле, мин сезгә ошыйммы?
Актүш. Мин нәрсә дип әйтергә тиеш?
Дүрткүз. Менә сез мине күрдегез, әйеме? Ошасам, «ошый» диегез, ошамасам...
Актүш. Ә мин сезгә ошыйммы соң?
Дүрткүз (*Актүш тирәсендә әйләнеп йөргәннән соң*). Ошыйсыз да кебек, ошамыйсыз да кебек.
Актүш. Ничек инде ул «кебек тә кебек»?
Дүрткүз. Сезгә гашыйк буласым килә. Тик нигәдер гашыйк була алмыйм шикелле.
Актүш. Ә мин сезгә гашыйк була алам шикелле.
Дүрткүз. Әгәр дә без икебез дә шикелле булмыйча гына чынлап гашыйк булсак, мәхәббәт булыр иде.
Актүш. Мәхәббәт – матур сүз.
Дүрткүз. Сезгә тагын да якынрак килеп утырырга ярыймы, Актүш?
Актүш. Мәхәббәт булгач ярыйдыр инде. (*Якынаеп утыралар.*)
Дүрткүз. Юк. Бу әле мәхәббәт түгел. Бу әле мәхәббәт бар микән дип сынап кына карау. Бәлки, гашыйк булышырбыз, бәлки, якын дуслар гына булып калырбыз. Дөнья матур, әйеме? Дөнья тагын да матураеп китте.
Актүш. Дөнья матур түгел шул, Дүрткүз. Казанда безне тоталар, ди Сарбай абый. Көчкә качып котылдык. Урам этләренә дөнья матур түгел шул.
Дүрткүз. Син урам этемени?
Актүш. Шулай инде. Хуҗабыз юк бит безнең. Хуҗалы этләр өйдә яши. Хәзер мине яратмый да башлыйсыңмы инде?
Дүрткүз. Нигә?
Актүш. Урам эте бит мин.
Дүрткүз. Шулай булып чыга икән шул.
Актүш. Гашыйк буласың килми башладымы?
Дүрткүз. Тукта, уйлап алыйм әле мин бераз. (*Уйланып торганнан соң.*) Син бит үзең теләп урам эте булмаган.
Актүш. Шулай шул.
Дүрткүз. Шулай булгач, синең яратылырга хакың бар.
Актүш. Тагын да якын килеп утырыйммы янына?
Дүрткүз. Утыр. Ләкин гашыйк булмыйча гына утырыйк. Гафу ит, минем күңелем эзләгән эт кызы син түгел, ахрысы.
Актүш. Каян беләсең?
Дүрткүз. Шулай тоелган сыман кебек шикелле. Әйдә, без якын дуслар гына булыйк.
Актүш. Мәхәббәт турында сөйләдең дә, минем дә гашыйк буласым килә башлады. Гашыйк булмагач, нигә сөйләргә иде мәхәббәт турында. (*Җырга күчә.*)

Җәйге төн, айлы төн –
Җир нурга коенган:
Тулган ай янына
Йолдызлар җыелган.

Дүрткүз. Җәйге төн, айлы төн –
Тулган ай елмая.
Елмаеп карыйсы

Килә бу дөньяга.
Икәү бергә. У-у-у, у-у-у,
У-у-у, у-у-у.

Дүрткүз. Син мине ачуланма инде, Актүш!
Актүш. Сине ачуланырга минем хакым юк.
Тәмлетамак (*пәйда булып*). Гашыйк булыштыгызмы?
Дүрткүз. Юк әле, Тәмлетамак.
Тәмлетамак. Пешмәгән син, Дүрткүз!

Акбай белән Сарбай керәләр.

Акбай. Юлга чыгарга вакыт, балалар!
Дүрткүз. Казангамы, Акбай абый?
Акбай. Казанга. Әй, Бүре!
Бүре. Нәрсә җитмәде инде тагын?
Акбай. Рәхмәт сиңа, туган. Яхшылыгыңны онытмабыз.
Бүре. Без бүреләр исән булганда этләр дә яшәячәк. Тик шулай да урманга еш килеп йөрмәгез. Хушыгыз!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Казан шәһәрендәге бер паркның аулак урыны. Агачлык арасындагы кечкенә генә аланда Бурзай белән Бульдог. Шәһәр өстендә бәйрәм
шау-шуы. Фейерверклар яктысы.

Бульдог. Тормыш бер дә кызык түгел, Бурзай абый. Кемнәрдер бәйрәм итә, кемнәрдер посып ята.
Бурзай. Түз. Кешеләрнең бәйрәме үтеп китсен, аннары без бәйрәм итәрбез.
Бульдог. Ә бит мин затлы нәселдән.
Бурзай. Урам барыбызны да тигезли инде ул, Бульдог туган.
Бульдог. Мин бала идем әле. Мине кеше таларга өйрәтмәкче булды берәү. Мин теләмәдем. Менә урам эте булып йөрим.
Бурзай. Син үкенмә, Бурзай. Кешеләр арасында да бомжлар бар.
Бульдог. Юк, үкенмим. Тик менә... Нигә безне аулыйлар кешеләр? Безнең ни гаебебез бар? Безнең дә бит, Бурзай агай-эне, урамда иркенләп бәйрәм итәргә хакыбыз бар. Без дә бит бу җирнең балалары.
Бурзай. Шулаен шулай инде дә. Арабызда усаллар бар бит. Тешләшәләр. Кешеләргә өрәләр.
Бульдог. Сарбай акыллы булып чыкты – авылга китте Актүшне ияртеп. Нишлим, авыл минем өчен түгел. Мин шәһәр эте, Казан эте мин.
Бурзай. Бар әле, Бульдог, күз-колак булып кайт әле. Берәрсе тәртип бозмасын. Кешеләр бәйрәменең ямен җибәрмәсен.
Бульдог. Борчылма, Бурзай, тәртип булыр. Син әйткән – миңа закон.

Чабышып, Акбай, Сарбай, Дүрткүз, Актүш керәләр.

Бурзай. Ни булды, Сарбай?
Бульдог. Авылга барып җитә алмадык. Менә Акбайлар очрады. Алар Казанга киләләр иде. Бәйрәм итәргә.
Бурзай. Бәйрәм... Әйттеңме соң мондагы хәлләрне?
Акбай. Беләбез. Ләкин бәйрәмне бәйрәм итмичә ярамый. 1000 ел бит ул!
Тәмлетамак. Сезгә генә бәйрәм итәргә димәгән.
Бурзай (*Тәмлетамакка күрсәтеп*). Ә ул кем?
Акбай. Ә ул безнең белән. Безнең авыл мәчесе. Бер ишегалдында яшибез. Бусы – Дүрткүз.
Тәмлетамак. Аның гашыйк буласы килә. Матур кызларыгыз булса, рәхим итегез!
Бульдог. Авыл дисәң авыл, мәче ияртеп йөриләр.
Тәмлетамак. Син тик тор, җәлпәк танау.
Бульдог (*Тәмлетамакка*). Нәрсә диден син, сәләмә? Бульдогка шундый сүз әйтергә ничек җөрьәт иттең? Авыл мәчесе башың белән мине мыскыл итәргә!..
Тәмлетамак. Җикеренмә.
Акбай. Тәмлетамак! Телеңне тый. Бар мәчеләрең янына. Озак йөрмә, бәйрәм итәбез дә кайтып китәбез. (*Тәмлетамак чыгып киткәч.*) Син ачуланма инде, Бульдог туган!
Бульдог. Гафу итегез, мин сезгә туган түгел. Мин затлы нәселдән, сез – авыл эте. (*Көйләп.*)

Без Бульдоглар –
Затлы токымнан без.
Без Бульдоглар –
Патша затыннан без.
Без Бульдоглар –
Аристократлар без.
Без Бульдоглар –
Технократлар без.

Бурзай. Нәсел тикшермик, Бульдог! Әйткәнне үтә. (*Бульдог чыгып киткәч.*) Син аңа үпкәләмә, Акбай! Мактанчыграк инде ул. Ярый, килгәнсең икән, бик яхшы, бергәләп бәйрәм итәрбез.

Акбай. Бәлки әле туй да ясарбыз. Менә энекәш бит, гашыйк буласым килә, ди. Казанда чибәр эт кызлары күптер.

Бурзай (*Актүшкә күрсәтеп*). Менә ич кызларның асылы.

Актүш. Без аңлаштык инде, Бурзай бабай. (*Бер читкә китеп ята.*)

Бурзай. Гашыйк буласы килү әйбәт нәрсә инде ул. (*Бульдогны чакыра.*) Бульдог!

Бульдог чабып кереп.

Бульдог. Тыңлыйм, Бурзай абый!

Бурзай (*Дүрткүзгә күрсәтеп*). Менә бу егетнең гашыйк буласы килә, ди. Чибәррәк эт кызлары күрсәң, монда алып кайт.

Бульдог. Миннән яучы ясамагыз инде, Бурзай абый.

Бурзай. Бу – минем үтенечем, Бульдог.

Бульдог. Сезнең үтенечегезне үтәргә һәрвакыт әзер. (*Чыгып чаба.*)

Бурзай. Нишләтәсең, этнең күңеле бер сөяк.

Акбай. Сөяк дигәннән, күчтәнәчебез бар. Авылыбызга шәһәр байлары кайткан. Яланда, ике сарык суеп, шашлык пешергәннәр. Өелеп сөяк калган.

Бурзай. Рәхмәт, Акбай туган.

Шул вакыт, арты белән чигенеп өрә-өрә, Муйнак керә. Аны Тәмлетамак куып алып килгән.

Тәмлетамак. Акбай, Дүрткүзгә кәләш таптым. Алыгыз. Юып чистартсаң, чибәр күренә. (*Чыгып югала.*)

Бурзай (*Муйнакка*). Кем син?

Муйнак. Муйнак мин.

Сарбай. Күргәнебез юк. Безнең тирәдән түгел, ахрысы?

Муйнак. Азинодан мин. Монда чүп савыты тапкан идем дә... Теге мәче... Минем ашыйсым килә.

Акбай. Кайда болай пычрандың?

Муйнак. Чүп савытына әллә нәрсә ташлаганнар.

Бурзай. Яле, кил әле. Чибәр генә күренәсең үзең.

Муйнак. Минем ашыйсым килә.

Акбай. Дүрткүз, кил әле бирегә.

Дүрткүз. Минем аңа гашыйк буласым килми.

Акбай. Сөяк бир үзенә. Аның ашыйсы килә.

Сарбай (*Муйнакка*). Сөягеңне кимергәч, Казансуда юынып кил. Карап йөр, тотып алмасыннар.

Дүрткүз белән Муйнак читкә китәләр. Дүрткүз Муйнакка сөяк бирә, Муйнак сөяк кимергәнне карап тора.

Дүрткүз. Синең гашыйк буласың киләме?

Муйнак. Минем ашыйсым килә.

Дүрткүз. Аша, аша. Безнең сөяк күп. Бүген Казанның 1000 еллыгын бәйрәм итәләр, беләсеңме?

Муйнак. Минем ашыйсым килә.

Дүрткүз. Аша, аша. (*Акбай янына килә.*) Акбай абый, ә без бәйрәм карарга барабызмы?

Сарбай. Ашыкма. Кешеләр бәйрәм итеп йоклап бетсен, аннары безнең бәйрәм башланыр.

Дүрткүз. Кешеләрнең бәйрәме кызык инде ул. Авыл сабан туенда быел рәхәтләнеп йөрдем. Анда барасың, монда киләсең. Җыр тыңлап торасың.

Бурзай. Җырны аны тыңлап та була, җырлап та була. Җырлап ачыла күңел. (*Җырга күчә.*)

Их, дусларым, сезгә әйтәм,
Таш бит Казан каласы;
Уйнап-көлеп күңел ачыйк –

Без табигать баласы.

Сарбай. Казан каласы – таш кала –
Калаларга башкала;
Яшәсен Казан каласы
Үрнәк булып башкага.

Бурзай. Әйдә, Акбай, кушыл безнең җырга.
Бергәләп (*җырлыйлар*).

Казан каласы таш кала,
Мең яшьтә дә яшь кала.
Кешеләргә генә түгел,
Этләргә дә башкала.
Башкала, баш кала, башкала!

Аларның сүзен хуплагандай, күктә салют утлары кабына. Шул вакыт
Бульдог Барбосны сөйрәп керә.

Барбос (*дулап*). Җибәр, җибәр!..
Бульдог. Кычкырма. Ычкына алмассың.
Бурзай. Ни булды?
Бульдог. Менә күрегез, шушындый хулиганнар аркасында безгә бәйләнәләр кешеләр.
Сарбай. Нишләгән?
Бульдог. Мин карап торам, әйеме, агач артына посып. Күрәм, әйеме, урамнан узып баручы малайларга өрә бу.
Барбос. Алар үзләре башлады. Мин тик кенә ята идем карап. Алар миңа таш ыргыттылар.
Бульдог. Бер малайның ботыннан тешләргә маташа.
Барбос. Мин нәрсә... Нигә ул минем авызга типмәкче була.
Бульдог. Менә шушындыйлар безне хур итә. Безне «котырган» диләр.
Бурзай (*Барбоска*). Нигә урамга чыгып яттың?
Барбос. Мин чыгып ятмадым, койма ярыгыннан гына караган идем.
Бурзай. Эт аулаучылардан көчкә саклап калдык үзеңне. Ә син...
Барбос. Таш ыргытмасыннар миңа.
Сарбай. Син кеше белән кешене аера белмисеңмени?
Барбос. Мин әйбәтләренә өрмим.
Бурзай. Өрәсез. Шул өрүегез аркасында бәйләнәләр безгә. Кешеләрне генә гаепләмәгез, гаеп үзебездә дә бар. Тешләшмичә генә яшәргә буладыр бит дөньяда.
Барбос. Кешеләр үзләре дә тешләшеп яши әле.
Сарбай. Дәшмә. Кешеләрдә эшең булмасын. Әйбәт этләрне алар өйләрендә тоталар.
Барбос. Сине ник тотмыйлар соң?
Бульдог. Дәшмә, диләр сиңа. Без урам этләре.
Акбай. Сезнең хәлләр җиңел түгел шул, егетләр.
Бульдог. Ә син кысылма. Шәһәр этләре сөйләшкәндә, тыңлап кына тор.
Акбай. Синең шәһәрлегең инде, Бульдог дус.
Бульдог. Дус түгел мин сиңа. Кабатлап әйтәм, дус түгел. Мин нәселле эт.
Акбай. Әллә без нәселсезме? Минем бабамның бабасының бабасы Мәрәтхуҗа авылында яшәгән.
Бульдог. Синең авылыңа ничә яшь? Минем Казаныма 1000 яшь!
Сарбай. Этләшмәгез, җәмәгать! Без барыбыз да этләр токымыннан. Бүленеп-бүлгәләнеп йөрер заман түгел. Бульдог, бар, караштырып кайт, тәртип бозучы этләр кешеләргә зыян салмасын.
Бульдог. Мин булганда барысы да о’кей булыр. (*Китеп бара.*)
Бурзай (*чыгып баручы Барбоска*). Ә син кая, Барбос!
Барбос. Койма ярыгыннан карап торырга. Анда кызык.
Бурзай. Беркая да бармыйсың. Кызык күрәсең килсә, кызыкны үзең яса. Кешеләр нишли урамда?
Барбос. Җырлыйлар.
Бурзай. Ә без җырлый белмибезме? Тагын нишлиләр?
Барбос. Бииләр.
Бурзай. Ә без бии белмибезме? Яле, Актүш, күрсәт әле осталыгыңны!
Актүш. Җырлыйммы? Биимме?
Бурзай. Башта җырла.
Актүш (*җырлый*).

Җырла, дисез, җырла, дисез,

Сезгә нинди җыр кирәк?
Сезнең алда җыр җырларга,
Бурзай бабай,
Сарбай абый,
Акбай абзый,
Сандугач теле кирәк.
Җырлыйк әле, җырлыйк әле
Барыбыз бергә чакта;
Вакыт җиткәч таралырбыз,
Бурзай бабай,
Сарбай абый,
Акбай абзый,
Төрлебез төрле якка.

Акбай. Яле, Дүрткүз, син дә күрсәт осталыгыңны.

Дүрткүз бии.

Сарбай. Нәрсә, без әллә яшьләрдән кимме?!

Дүрткүзгә кушылып, бөтен этләр дә биергә керешә. Чарлины куып,
Бульдог керә. Биючеләр туктап калалар.

Чарли. Нишлисең син, идиот?!
Бульдог. Минме?! Минме идиот?! Хәзер күрсәтәм мин сиңа идиотны.

Чарлига ташлана, ләкин аны Бурзай тотып кала.

Бурзай. Ни булды?
Бульдог. Менә бу эт кисәге – келтеринкә...
Чарли. Мин келтеринкә түгел, Чарли...
Бульдог. Менә шул эт кисәге Чарли урамда кешеләр арасында рәхәтләнеп түшен киереп йөри. Җитмәсә, муенына телефон аскан.
Чарли. Йөрергә минем хакым бар. Бәйрәм бүген. Мине хуҗам бәйрәм күрсәтергә алып чыкты. (*Елап.*) Ә ул миңа килеп бәйләнде.
Бульдог. Мин сиңа бәйләнмәдем. Гашыйк буласың киләме, дип сорадым. Ә син «идиот» дидең. Бурзай абый, «чибәр эт кызы алып кайт» дидең. Менә алып кайттым. Гашыйк булыгыз. Ләкин мин шуны әйтәм – мин бу келтеринкәгә гашыйк булмас идем.
Чарли. Ни сөйлисең син, идиот. Илтеп куй мине хуҗам янына һәм телефонымны бир.
Бульдог. Әгәр дә тагын бер идиот дисәң... Мин усал эт түгел, Бурзай абый, әгәр дә тагын бер идиот дисә, мин аны...
Чарли. Идиот, идиот, идиот...
Бульдог (*еларга җитешеп*). Бурзай абый!
Бурзай. Син, сеңлем, арттырып җибәрмә. Мин күрәм, син өй эте. Син кадер-хөрмәттә яшисең. Ләкин безнең дә горурлыгыбыз бар.
Чарли. Ә нигә ул мине куып китерде?
Бурзай. Аңа мин куштым. Әгәр дә чибәр эт кызы күрсәң, монда китер, дидем. Чөнки дә безнең чибәр егетебез бар. Дүрткүз, кил әле якынрак.

Дүрткүз килә.

Менә аның гашыйк буласы килә.
Чарли. Бумы? Фу, беләм ич мин аны. Авыл эте ич ул. Авылларында ул миңа әллә нәрсәләр сөйләп торды. Мәхәббәт, ди, фәлән, ди. Ярату, ди.
Дүрткүз. Ул яратуның ни икәнен белми, Бурзай абый.
Чарли. Ә? Минме белмим?! Минем менә дигән пуделем бар, беләсеңме? Ул да коттеджда яши. Үзенә аерым бүлмәсе бар.
Акбай. Безнең ишегалды сезнең каттижларыгыздан мең тапкыр артык.
Чарли. Артык булса, шунда яшәгез. Се-ля-ви! Бирегез телефонымны, озатып куегыз.
Бурзай (*Бульдогка*). Кайда аның телефоны?
Бульдог. Мин аны ыргыттым. Нигә кирәк ул миңа?
Чарли. Илтеп куегыз мине! Әгәр дә минем хуҗам сезне күрсә, беләсезме нишләтә?
Сарбай. Син хуҗаң белән мактанма.
Барбос. Без үзебез хуҗалар.

Бурзай. Ягез, бәйләнмәгез анда, ул бит чын эткә охшамаган да.
Чарли. Минме?! Минме охшамаган?! Мин – эт! Мин – чын эт! Мин – пудель токымыннан!
Бурзай. Булды, булды. Эт син. Чын эт, сеңелкәш!
Чарли. Минем урам этләренә сеңелкәш буласым килми.
Бульдог. Чәйнәп ташлыйммы үзен?
Сарбай. Чәйнәрлеге дә юк бит аның.
Чарли. Бар! Чәйнәрлегем бар минем.
Бурзай. Ярый, ярый. Әгәр чын эт булсаң, өреп күрсәт.
Чарли. Әллә өрмәмме. Ләң, ләң, ләң! Вәү, вәү, вәү!

Этләр тәгәрәшеп көлә.

Бурзай. Шулай өрәләрме. Әй, җаным-җанкисәгем. Этләр менә болай өрә ул. Ягез әле.

Этләр җырлый-җырлый өрәләр!

Вау-вау-вау, вау-вау-вау,
Безгә кирәк вауларга,
Вауларга да вауларга –
Хакыбызны дауларга!
Вау-вау-вау, вау-вау-вау,
Без бит әле исән-сау.
Вау-вау-вау, вау-вау-вау,
Без туганбыз вауларга,
Вауларга да шауларга,
Эт нәселен данларга,
Вау-вау-вау, вау-вау-вау,
Безнең башлар исән-сау.

Бурзай (*Чарлиның чәңгелдәп көлгәнен күреп-ишетеп*). Нигә көләсең?
Чарли. Үзегез шундый сәләмәләр, үзегез җырлыйсыз.
Сарбай. Шундый инде без. Менә син сәләмә түгел, берни эшли белмисең.
Чарли. Мин бии беләм.
Бурзай. Шулаймыни? Яле, яле, күрсәт биеп.
Чарли. Мин сезнеңчә белмим. Мин балетча гына биим.
Сарбай. Йә, йә...
Чарли. Раз-и, два-и, три-и. (*Биеп китә.*)

Аның биюе урам этләренә ошый, кул чабалар.

Чарли (*биеп туктагач*). Илтеп куясызмы инде хәзер?

Шул вакыт Чарлиның телефоны шылтырый.

Бурзай. Нәрсә ул анда?
Чарли. Минем телефон. Минем хуҗам мине эзли.
Бурзай. Кайда ул телефон?
Чарли (*Бульдогка күрсәтеп*). Менә бу алды, дип әйттем ич инде.
Бурзай (*Бульдогка*). Ыргыттым дигән идең.
Бульдог. Мин аны монда гына ыргыткан идем. (*Телефонны алып килә.*)
Чарли. Бирегез, бир. (*Телефонны Бульдогтан тартып алып.*) Вәү, вәү, вәү.

Телефоннан «Чарли! Чарли!.. Син кайда?» дигән тавыш ишетелә. Этләр, Чарли тирәсенә җыелып, кызыксынып тыңлыйлар. Аннары барысы да телефонга «вау, вау!» дияләр. Көлешәләр. Чарли чыгып качмакчы була, аны тотып алалар.

Чарли. Җибәрегез, җибәрегез!
Бурзай. Ашыкма. Башта әйбәт кенә саубуллаш. Сау булыгыз, абыйлар, апалар, туганнар, диген.
Чарли. Сау булыгыз! (*Китәргә җыена.*)
Бурзай. Абыйлар, апалар, туганнар, димәдең.

Якында гына Чарли хуҗасының «Чарли, Чарли!» дигәне ишетелә.

Чарли. Җибәрегез! Хуҗам монда килеп җитте.
Бурзай. Исән-сау яшәгез! Бәхетле булыгыз, диген.

Чарли. Исән-сау яшәгез, бәхетле булыгыз!
Бурзай. Мин сезне сагынырмын, диген.
Чарли. Мин сезне сагынырмын. Бу сүземне мин чынлап әйтәм. Чыннан да мин сезне сагынырмын. Без бит барыбыз да этләр. Рәхмәт сезгә. Минем кебек бәхетле булыгыз!
Бурзай. Инде бар. Рәхмәтеңне әйт тә ычкын.
Чарли. Рәхмәт. (*Чыгып чаба.*)
Сарбай (*моңсу паузадан соң*). Шундый инде безнең хәлләр, туганнар!
Бурзай. Кызык булып китте үзе.
Сарбай. Уйлап-уйлап йөрим дә кайвакыт уйлап куям: эт язмышын бүтәннәргә күрсәтмәсен иде. Берәүләребезне кешеләр, үз балалары кебек кочакларына алып, күтәреп йөриләр, берәүләребезне, чылбыр белән бәйгә куеп, рәхәтләнеп чабып йөрүдән дә мәхрүм итәләр, берәүләребезне кешеләр үз ишләрен таларга өйрәтәләр, кайсыларыбыз менә безнең кебек ташландык җан ияләре булып яшәгән булабыз.
Акбай. Этләр генә түгел, кешеләр дә шулай инде анысы.
Сарбай. Кешеләрдә минем эшем юк, Акбай. Мине этләр язмышы борчый. Сиңа рәхәт, Акбай. Син авыл эте. Син анда ишегалдына булса да хуҗа. Теләгән җиреңә барып ятасың. Син анда кирәкле җан иясе. Без кемгә кирәк? Артык җан иясе булудан да артык бәхетсезлек булмыйдыр ул. Ятасың кайвакыт кояш төшкән җирдә җылынып, үтеп йөриләр яныңнан. Ник берсе шунда җылы күз карашы ташласын, ник берсе шунда бер сынык ипи ыргытсын.
Бурзай. Булды, Сарбай, тирәнгә керәсең. Шуны бел: тирәнгәрәк төшкән саен, чыгуы авыррак була.

Бульдог белән ызгышып, Тәмлетамак керә.

Тәмлетамак (*чигенә-чигенә*). Туктыйсыңмы син миңа бәйләнүдән, шапай авыз. Акбай, тый әле шул чучка танауны.
Акбай. Ни булды инде тагын?
Бульдог. Йөрмәсен бәйрәмнең ямен җибәреп Казан урамында.
Тәмлетамак. Мин үземә дуслар эзлим бәйрәм итәргә. Этләр белән бәйрәм итә алмыйм бит инде мин.
Бульдог. Мәчеләрнең эше тычкан тоту, бәйрәм итү түгел.
Тәмлетамак. Өйрәтмә, җәлпәк авыз. Казаныгызга әйтер идем инде, ырлашырга этләр күп, мыраулашырга мәчеләрегез дә юк.
Дүрткүз (*Муйнак килгәнне күреп*). Туктагыз! Минем гашыйк буласым килә, ә сез талашасыз. Әнә ул мин гашыйк булырга тиешле гүзәл.
Этләр. Кайда? Кем ул? (*Дүрткүз караган якка карыйлар.*)
Дүрткүз. Әнә! Күрегез, нинди чибәр. Муены ап-ак, тәпиләре ап-ак.
Сарбай. Безнең Муйнак ич инде ул. (*Чакыра.*) Муйнак, Муйнак!

Юынган, чистарынган, матурланган Муйнак керә.

Муйнак. Бурзай бабай, мин юындым. Казансуга төштем дә юындым.
Дүрткүз. Минем аңа гашыйк буласым килә.
Бурзай. Бул соң, кем сиңа комачаулый?
Дүрткүз (*Муйнак каршына килеп*). Минем сиңа гашыйк буласым килә.
Муйнак. Минем сиңа гашыйк буласым килми.
Дүрткүз. Ник? Нигә?
Муйнак. Башта миңа гашыйк буласың килмәде.
Дүрткүз. Анда син бүтән төрле идең.
Муйнак. Шул ук Муйнак идем.
Дүрткүз. Ялгышканмын. Гафу ит! Минем аңа бик тә гашыйк буласым килә. Бурзай бабай, Сарбай абый, Акбай абый, әйтегез Муйнакка, минем аңа гашыйк буласым килә.
Сарбай. Муйнак сеңлем, гашыйк бул син Дүрткүзгә! Менә дигән егет ул.
Акбай. Безнең Дүрткүз кебек эт егете тирә-якта юк.
Тәмлетамак. Нәрсә инде ялындырган буласың.
Муйнак. Ә син мәче башың белән безнең арага кысылма. (*Дүрткүзгә.*) Әгәр дә мине киләчәктә дә үпкәләтмәскә сүз бирсәң, миңа гашыйк булырга рөхсәт итәм.

Этләр куанышалар.

Дүрткүз. Үзең дә гашыйк бул миңа, Муйнак.
Этләр. Гашыйк бул, Муйнак, гашыйк бул!
Муйнак. Бабайлар, абыйлар! Сез мине үз арагызга сыендырдыгыз. Мин сезнең сүздән чыкмыйм.

Этләр шатланышып сикерешәләр.

Бурзай. Димәк, туй! Ике бәйрәм бергә бүген, күңел ачыгыз!
Тәмлетамак. Туй булгач, аның бүләге дә була инде. Бүләк итәргә нәрсәгез бар?
Бурзай. Бүләкме? Бар ул бүләк. Без урам этләре Дүрткүз белән Муйнакка Казанның олуг бәйрәме көнендә Казанның ике урамын бүләк итәбез. Берсе Дүрткүз урамы булыр, икенчесе – Муйнак урамы. Ә хәзер җырлагыз, биегез!

Әлбәттә инде, бәйрәм көнне, туй көнне кайсы эт биемичә түзсен.
Бииләр, җырлыйлар.

Пәрдә.

# «Интернет Акбай»

*Балалар өчен ике пәрдәле тамаша*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Акбай – авыл эте.
Тәмлетамак – авыл песие.
Бозау.
Бәти.
Бәрән.
Мияумистер – Кышландия мәчесе.
Һаумистер – Кышландия эте.
Дүрткүз.
Кар кызы.
Кыш бабай.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәхнәгә, җырлап, Тәмлетамак керә. Муенына кесә телефоны аскан.

Тәмлетамак.

Тәмлетамак кем дисәгез,
Ул мин буламын.
Төрле хәйлә-мәйләләрне
Мин ул кыламын.
Минем нәсел – мәче нәселе –
Дөнья иркәсе.
Безнең кулда бу дөньяның
Киче, иртәсе.

Исәнмесез, кадерле тамашачылар! Таныш булыгыз, мин бу йортта дөнья күрүче мәче – Тәмлетамак. Сез уйлыйсыз инде бу авыл мәчесе икән дип. Ашыкмагыз, хөрмәтлеләрем! Бу ишегалдында яшәүче эт – Акбай да, Бозау, Бәти, Бәрән дә миңа гади мәчегә караган кебек кенә карыйлар. Ә минем нинди көчкә ия икәнлегемне белмиләр. Алар менә сезнең кебек үк чыршы бәйрәме була дип йөриләр. Акбай урманга чыршыга китте. Ләкин әгәр дә мин теләмәсәм, бернинди бәйрәм дә булмый.

Бозау керә.

Бозау. Әй, Тәмлетамак, Акбай абый кайтмадымы әле?
Тәмлетамак. Мин сиңа әй түгел. Бозау башың белән олыларны олылый белмисең.
Бозау. Тәмлетамак булгач ничек дип әйтим соң?
Тәмлетамак. Хөрмәтле, кадерле, гыйззәтле Тәмлетамак, диген, аңгыра.
Бозау. Син үзең аңгыра. (*Китеп бара.*)
Тәмлетамак. Менә шулар белән яшәп кара инде.
Бәти (*керә*). Акбай абый күренмиме?
Тәмлетамак. Синең өчен кем исәнләшә, хулиган?
Бәти. Син кем соң ул хәтле? Мәче генә бит син.
Тәмлетамак. Мәче генәме?
Бәти. Мәченең дә әле начары. Тычкан тотмый торганы.

Тәмлетамак. Әй син, Кәҗә бәтие, сүзеңне үлчәп сөйлә. Ачуымны китерсәгез, чыршы бәйрәмегез булмаячак. Бәйрәмегезгә Кыш бабай белән Кар кызы килмәячәк.

Бәти. Сөйләгән була, хәчтерүш.

Тәмлетамак. Сөйләнгән була, диме? (*Тамаша залына карап.*) Ишеттегезме мине мыскыл иткәнен. Барысы да шундый алар. Акбай барысыннан да яманрак. Күрсәтәм әле мин аларга. Ә сез барыгыз да өйләрегезгә кайтып китегез. Быел чыршы бәйрәме булмаячак. Булмаячак быел чыршы бәйрәме. Нигә, дип сорагыз... Чөнки дә Кыш бабай да, Кар кызы да килмәячәк. Нигә, дип сорагыз... Чөнки дә Кыш бабай белән Кар кызын мин китертмәячәкмен. Нигә, дип сорагыз... Хәзер, күреп торыгыз. (*Кесә телефоныннан номерлар җыеп.*) Аллю! Кышландияме бу? Мияумистер, сезме бу?

Экранда Кышландия мәчесе Мияумистер пәйда була. Ул компьютер каршында утыра.

Мияумистер. Мин!

Тәмлетамак. Мин Татарстаннан. Тәмлетамак! Таныдыгызмы?

Мияумистер. О-о-о, Тәмлетамак! Хелло, Тәмлетамак!

Тәмлетамак. Хелло, Мияумистер! Яшәсен Бөтендөнья мәчеләренең какшамас дуслыгы! Ничек анда сездә?

Мияумистер. О'кей! Файн. Суык. Сездә ничек?

Тәмлетамак. Бездә дә о'кей! Менә чыршы бәйрәме үткәрергә җыенып йөриләр.

Мияумистер. О'кей! Бездән бөтен дөньяга Кыш бабайлар, Кар кызлары миллионлап китеп тора. Сезгә килеп җитмәделәрме әле?

Тәмлетамак. Юк һәм кирәкми дә.

Мияумистер. Ничек кирәкми?

Тәмлетамак. Татарстанның бөтен җиренә килсеннәр. Безнең ишегалдына килмәсеннәр.

Мияумистер. Ни өчен?

Тәмлетамак. Мине монда мыскыл итәләр. Мәче халкыннан көләләр. Син дә мәче, мин дә мәче, көлдермик үзебездән. Безнең кем икәнне белсеннәр Бозау, Бәти, Бәрәннәр. Акбай дигән авыл эте дә белсен.

Мияумистер. О'кей! Миңа нишләргә?

Тәмлетамак. Мин монда әйтәм: Кыш бабайлар, Кар кызлары яши торган илдә – Кышландиядә – быел бик каты кызу булган, Кыш бабайлар, Кар кызлары эреп үлеп беткәннәр, дим...

Мияумистер. Ләкин бу бит ялган, алар үлмәгән.

Тәмлетамак. Хәйлә корганда ялганларга да кирәк. Без бит мәчеләр, песиләр. Дөресме?

Мияумистер. О'кей!..

Тәмлетамак. О'кей булса, шул, сезгә шылтыратып сорасалар, мин әйткәнне әйт, үлделәр, диген.

Мияумистер. О'кей!

Тәмлетамак. О'кей! Яшәсен Бөтендөнья мәчеләренең какшамас дуслыгы! Бөтендөнья мәчеләре, берләшегез!

Бәрән. Тәмлетамак, Акбай абый кайтмадымы?

Тәмлетамак. Нәрсә сез бөтенегез дә миннән Акбайны сорыйсыз?

Бәрән. Чыршыга китте бит.

Тәмлетамак. Китсә кайтыр. Чыршы бәйрәме барыбер булмый.

Бәрән. Ничек булмый?

Тәмлетамак. Син Кыш бабайларның кайда яшәгәнлеген беләсеңме?

Бәрән. Беләм, Кышландиядә.

Тәмлетамак. Менә шул Кышландиядә быел бик кызу булган, Кыш бабайлар, Кар кызлары эреп үлеп беткән. Аңладыңмы? Ферштейн, томана сарык бәрәне?

Бәрән. Син үзең томана сарык бәрәне. Кыш бабайлар үлми.

Тәмлетамак. И аңгыра? Син беләсеңме, минме? (*Кесә телефоныннан номерлар җыеп.*) Мә, сөйләш?

Бәрән. Кем белән?

Тәмлетамак. Кышландия президенты белән. Исәнмесез, Мияумистер президент, диген. Безгә Кыш бабай җибәрмәссез микән, диген.

Бәрән (*телефонны алып сөйләшә.*) Исәнмесез, мияумистер президент! Безгә Кыш бабай җибәрмәссез микән.. Ә?

Тәмлетамак. «Ә» шул менә. (*Елап.*) Нишләрбез инде Кыш бабайсыз?! Син дә ела, Бәрән, чыршы бәйрәме булмый бит.

Тәмлетамак тагын да ныграк кычкырып елый, аңа Бәрән кушыла. Елый-елый чыгып китә.

*(Көлеп.)* Елашыр көннәрегез алда әле, җанкисәкләрем! (*Телефоннан.*) Мияумистер! Син анда Кыш бабайларга әйт әле, Мәрәтхуҗа авылының ишегалдында чыршы бәйрәме булмый, диген. Андагы Бозау, Бәти, Бәрәннәр, Кыш бабайны яратмыйбыз, килеп йөрмәсен, дип әйтәләр, диген. Акбай дигән этләре, Кыш бабайны талап үтерәм, дип әйтә икән, диген.

Бозау, Бәти, Бәрән керәләр.

Бозау. Син монда нәрсә сөйләдең, Тәмлетамак?
Тәмлетамак. Нәрсә ишеттегез, шуны сөйләдем. Бәрәнегез үзе сөйләште Кышландия президенты белән.
Бәрән. Әйе, сөйләштем.
Бәти (*Тәмлетамакка*). Бир әле телефоныңны?
Тәмлетамак. Бир әле түгел, бирегез әле. Телефоныңны түгел, телефоныгызны.
Бәти. Йә инде...
Тәмлетамак. Йә инде түгел.
Бәти. Казаннан урлап кайткан да телефон, мактанган була. Бездә дә булыр әле.
Тәмлетамак. Булгач сөйләшербез. Мә, сөйләш.
Бәти. Алле, кем әле бу? Миңа Кышландия президенты кирәк!
Мияумистер. Ә сез кем?
Бәти. Мин Кәҗә бәтие.
Мияумистер. О'кей! Нинди кәҗә бәтие?
Бәти. Ала Кәҗә бәтие. Сез чыннан да президентмы?
Мияумистер. Ә сез чыннан да Кәҗә бәтиеме?
Бәти. Мин бит мәче түгел алдашырга. Безнең Тәмлетамак кына ул гел алдаша.
Мияумистер. О'кей! Сезгә ни кирәк?
Бәти. Монда әйтәләр, Кыш бабайлар үлгән, диләр.
Мияумистер. Әйе, үлеп беттеләр. Сезгә дә Кыш бабай җибәрә алмыйбыз. (*Экраннан югала.*)
Бозау. Нәрсә ди?
Бәти. Бәрән әйткәнне әйтә.
Бәрән. Нишлибез инде хәзер? (*Елый.*)

Бозау кушыла. Елый-елый җырлыйлар.

Яңа елны көткән идек без,
Бәйрәм өмет иткән идек без.
Чыршы алып кайтырга диеп,
Бик тиз генә кайтырмын диеп,
Акбай киткән иде урманга.
Бар да әзер диеп торганда,
Нинди яман хәбәр ишеттек.
Менә хәзер нишлибез инде,
Көтмәгәндә зур кайгы килде.

Елашып-җырлашып чыгып китәләр.

Тәмлетамак. Ха, ха-ха! Менә шулай була ул мәчеләрне санга сукмасагыз. Югыйсә Акбай да Акбай! Күрик, нишли алыр икән Акбаегыз. *(Бии-бии җырлый.)*

Күрдегезме сез Тәмлетамакны,
Нинди шәп хәйлә ул уйлап тапты.
Бәйрәмнәре булмаячак,
Тәмлетамак үч алачак
Акбайдан. Хәзер өйгә кереп китәм,
Шатлыгымнан авыз итәм
Акмайдан.
Аңладыгызмы Тәмлетамакны –
Аның хәйләсе гел катлы-катлы.
Бозау, Бәти, Бәрәннәргә
Күңел ачу бәйрәмнәрдә
Килешми.
Акбайлар шуны белсеннәр,
Миңа ялынып килсеннәр –

Хи-хи-хи!

Акбай (*чыршы күтәреп керә*). Нәрсә сикеренәсең, Тәмлетамак?
Тәмлетамак. Ишетсәң син дә сикерерсең әле, Акбай.
Акбай. Тагын ни кыландырдың?
Тәмлетамак. Анысын бәтиләр әйтерләр. Ха-ха-ха! Хи-хи-хи! (*Китеп бара.*)
Акбай. Нәрсәдер кыландыра бу кәнтәй (*бозаулар киткән якка карап*), сез кайда, малайлар?

Бозау, Бәрән, Бәти елашып керәләр.

Ни булды сезгә?
Бәрән. Тәмлетамак әйтә... (*Сүзен әйтә алмыйча елый.*)
Акбай. Нәрсә ди?
Бәти. Кышландиядә Кыш бабайлар үлеп беткән, ди. Чыршы бәйрәме Кыш бабайларсыз булмый, ди.
Акбай. Ни сөйли ул юньсез мәче? Тәмлетамак! Тәмлетамак!
Тәмлетамак. Ни сүзегез бар, Акбай әфәнде?
Акбай. Нәрсә сөйләп йөрисең син, ә?
Тәмлетамак. Минем белән сез дип сөйләшүегезне үтенәм.
Акбай. Үтенермен мин сиңа. Малайларны елатып йөрсәң... Кем үлгән? Нинди сүз ул?
Тәмлетамак (*кесә телефоныннан номерлар җыеп, телефонны Акбайга суза*). Рәхим итегез!..
Акбай. Нәрсә анда?
Тәмлетамак. Сөйләшегез, Акбай әфәнде.
Акбай (*телефонны алып*). Аллю! Кем бу?
Мияумистер (*экранда күренеп*). Хелло!
Акбай. Нинди Хиллу? Кем син?
Мияумистер. Кышландия гражданины Мияумистер.
Акбай. Нинди министр?
Мияумистер. Ноу министр, Мияумистер.
Акбай. Кышландияме соң бу?
Мияумистер. Ес, Кышландия...
Акбай. Кыш бабайга бир әле телефонны.
Мияумистер. Ноу Кыш бабайлар. Юк. Үлеп беттеләр!
Акбай. Нәрсә сөйлисең син? Кыш бабайлар үлми.
Мияумистер. Ә сез кем?
Акбай. Акбай. Авыл эте.
Мияумистер. Ду шпик инглиш?
Акбай (*Тәмлетамакка*). Нәрсә ди ул? Дуешник инглиш, ди.
Тәмлетамак. Инглизчә сөйләшә беләсеңме дидер.
Акбай (*телефонга*). Белмим мин дуешнигыгызны.
Мияумистер. Белмәсәгез, татарча әйтәм: Кыш бабайлар юк бездә. Ноу. Үлеп беттеләр. (*Югала.*)
Акбай (*Тәмлетамакка*). Кем соң ул?
Тәмлетамак. Кыш бабайларның хуҗасы. Кыш бабайларны Яңа елда ул тарата. Президент.
Акбай. Әкият сөйләмә. Мияумистер, ди. Мияу булгач, мәчедер әле.
Тәмлетамак. Әлбәттә, мәче. Дөньяга мәчеләр хуҗа.
Акбай. Кит моннан, йолкыш!
Тәмлетамак. Йолкышмы, түгелме, чыршы бәйрәме булмаячак. Кыш бабаегыз юк. Чыршы бар, Кыш бабай юк. Кыш бабай юк – бәйрәм юк. О’кей! (*Китеп бара.*)
Бозау. Нишлибез инде, Акбай абый?
Акбай. Ашыкмагыз. Чыршыны утыртыйк. Чыршы булмаган җиргә Кыш бабай килми.

Чыршыны утырталар.

Дүрткүз кайда соң әле?
Бозау. Казанга барам дигән иде.
Акбай. Көчек чагында Казаннан ияртеп кайткан идек, тәки онытмый Казанын.
Бәти. Казанныкы Казанга карый инде.
Акбай. Ярый. Туган җирләре этләргә дә кадерле. Ничек чыршы?
Бозау.
Бәти.
Бәрән.        Мату-у-ур!
Бәрән. Чыршы утырткач та юк Кыш бабай.

Акбай. Әйләнегез чыршы тирәли, җырлагыз, чакырыгыз Кыш бабай белән Кар кызын, килеп җитәрләр.

Чыршы тирәли әйләнәләр, җырлыйлар. Тәмлетамак бер читтә көлеп күзәтә.

Иске ел китте, Яңа ел килде,
Кыш бабаебыз, син дә кил инде.
Кил, кил, Кыш бабай,
Күңелләргә хуш бабай!
Син булмагач бәйрәмдә,
Бәйрәмебез буш, бабай!
Кил, кил, бабакай,
Кар кызын да алып кил,
Бүләк тулы капчыгың
Иңбашыңа салып кил.
Килче, Кыш бабай, зинһар, кил инде,
Монда бергәләп көтәбез сине.
Кил, кил, Кыш бабай,
Күңелләргә хуш бабай!
Син булмагач бәйрәмдә,
Бәйрәмебез буш, бабай!
Кил, кил, бабакай,
Әйлән-бәйлән уйнарбыз,
Яшел чыршы янына
Дусларны да җыйнарбыз.

Туктап Кыш бабайны көтәләр. Күренмәгәч, моңаеп чыршы төбенә утыралар.

Тәмлетамак (*уртага чыгып*). Әйттем бит мин сезгә. Булмый чыршы бәйрәме. Кереп ятыгыз абзарыгызга. Акбай, син дә кереп ят ояңа. Әгәр дә бик ялынсагыз, үзем булам Кыш бабай. Киям хуҗабызның тунын, киям аның бүреген, ябыштырам сакал. (*Иңенә сумка аскан Чарли кергәнне күреп.*) Ә син монда нишләп йөрисең, эт аламасы?

Чарли. Кит юлдан. Мин – Чарли. Мин шәһәр пуделе. Исәнме, Акбай абый! Сез нигә күңелсез? Сезгә ни булды?

Акбай. Менә утырабыз моңаеп. Бәйрәмгә дип чыршы куйдык. Кыш бабай юк. Син ничек килеп чыктың авылга?

Чарли. Хуҗам кайтты авылга. Яңа елны монда каршылыйм, ди. Мин сезне эзләргә чыктым. Ә сез мин килгәнгә сөенмисез.

Акбай. Сөенәбез дә бит. Кыш бабай юк. Кар кызы юк.

Чарли. Чакырдыгызмы соң?

Акбай. Чакырдык та... әнә Тәмлетамак әйтә, Кыш бабайлар үлеп беткән, ди. Кышландиядә бер Кыш бабай да калмаган, ди.

Чарли. Чепуха. Хәзер... (*Кесә телефонын алып, номерлар җыя.*)

Тәмлетамак аңардан телефонны тартып ала.

Тәмлетамак. Син нәрсә монда килеп баш булып йөрисең, шәһәр эте. Казаныгызга кайтып командовать ит, яме.

Чарли. Бир телефонны!

Тәмлетамак. Бирде ди, көтеп тор.

Акбай. Бир телефонны, Тәмлетамак!

Тәмлетамак. Син дә миңа баш булма. Бәрәннәреңә баш бул, яме.

Акбай. Бир диләр.

Акбай, качып китәргә җыенган Тәмлетамакны эләктереп, телефонны алырга тели. Тарткалашалар. Акбайга Бозау, Бәти, Бәрән булыша.
Телефонны алалар.

Тәмлетамак (*егылган җиреннән торып*). Ярар, ярый, ярар... Күрсәтермен әле мин сезгә Кышландиянең кайда икәнен. (*Чыгып китә.*)

Чарли. Нинди тәрбиясез мәче. Безнең өйдәге мәче минем янда койрык болгап кына йөри.

Акбай. Телефоның менә, Чарли. Нишләмәкче идең?

Чарли. Минуточку, Акбай абый! (*Телефоннан номер җыеп.*) Але! Бу Кышландияме? Але, Һаумистер, сезме?

Һаумистер (*экранда күренеп*). Але, Чарли! Хелло! Исәнмесез, Чарли! Хәлләр ничек?

Чарли. Файн.供 Сездә ничек?

Һаумистер. О’кей, Чарли!

Чарли. Кадерлем, Һаумистер, мин сезне сагындым.

Һаумистер. Мин дә сезне сагындым, Чарли. Нигәдер соңгы вакытта Интернетта күренмисез.

Чарли. Юлда хуҗам белән озак йөрдек. Кадерлем, Һаумистер, сезнең Кышландиядә ни булды? Безгә нигәдер Кыш бабай белән Кар кызы килми. Монда әйтәләр, Кыш бабайлар үлгән, диләр.

Һаумистер. Нәрсә-ә-ә?

Чарли. Кыш бабайлар үлеп беткән, диләр. Без көтәбез – килмиләр.

Һаумистер (*көлә*). Һау-һау-һау!.. Ялган, Чарли. Миллион Кыш бабай дөнья буйлап таралды. Чакырмыйсыздыр.

Чарли. Чакырганнар, килмәгән. Кадерлем! Һаумистер! Будь другом, җибәр әле безгә Кыш бабай белән Кар кызын.

Һаумистер. О’кей! Адрес.

Чарли. Татарстан, Кама Тамагы районы, Мәрәтхуҗа авылы.

Һаумистер. О’кей, Чарли! Көтегез. Гуд бай!

Чарли. Гуд бай, Һаумистер!

Экранда Һаумистер югала.

Акбай. Ничек, Чарли, була дидеме?

Чарли. Көтәбез, Акбай абый.

Акбай. Һай, рәхмәт! Шәһәр этләре Кышландия этләренең дә телен белә шул.

Чарли. Без беләбез. Шәһәр малайлары гына үз телләрен белми.

Акбай. Ягез, егетләр, Чарлига ни дип әйтәбез?

Бозау.

Бәрән.

Бәти. Рәхмәт дибез. (*Җырга күчеп.*)

Рәхмәт сиңа, Чарли,  
Чап син армый-талмый,  
Йөриячәк юлларыңда  
Дуслар барлый-барлый.  
Рәхмәт яусын, Чарли,  
Бәхтең артсын, Чарли.  
Рәхмәт сиңа, Чарли,  
Яшә, артка калмый.  
Яхшы эшләр эшләүченең  
Юлына кар яумый.  
Рәхмәт яусын, Чарли,  
Бәхтең артсын, Чарли.

Акбай. Инде, әйдәгез, Кыш бабайны авыл читендә каршы алыйк, адашмасын.

Чыгып китәләр. Тәмлетамак керә.

Тәмлетамак. Иртәрәк куанасыз, әфәнделәр. (*Кесә телефоныннан шылтырата.*) Алло! Мияумистер, синме?

Экранда Мияумистер күренә.

Мияумистер. Хелло! Ни булды, Тәмлетамак?

Тәмлетамак. Монда ЧП. Көтелмәгән хәл. Эшләр җайлы гына барганда, авылга шәһәр эте Чарли килеп төште. Ул Акбайның күптәнге танышы. Ул Кышландия эте Һаумистер белән элемтәгә керде. Һаумистер авылга Кыш бабай җибәрергә сүз бирде. Ферштейн?

Мияумистер. Андэстэнд!

Тәмлетамак. Аңласаң шул. Бөтендөнья этләре берләшә. Без нишлибез?

Мияумистер. Нинди тәкъдимегез бар?

Тәмлетамак. Тәкъдим – бер, Кыш бабайны безгә җибәрмәскә.

Мияумистер. Ничек?

Тәмлетамак. Башыңны эшләт, Мияумистер!
Мияумистер. Без бит хәзер баш белән эшләмибез, Тәмлетамак. Безнең өчен компьютер уйлый, компьютер эшли.
Тәмлетамак. Уйлат компьютерыңны. Этләр Кыш бабайны ниндидер Интернет аша китерергә уйлыйлар. Җибәрттермә.
Мияумистер. О'кей.
Тәмлетамак. Кайда хәзер Кыш бабай?
Мияумистер (*компьютердан эзләнеп*). Ул Интернет кибетендә балаларга бүләк сайлый.
Тәмлетамак. Чыгар ул кибеттән. Җибәрмә Кыш бабайны безгә. Үлсәң үл, минем сүзне аста калдырма. Мәчеләрнең әйткәне өстен чыгарга тиеш. Яшәсен Бөтендөнья мәчеләренең какшамас дуслыгы! Бөтендөнья песиләре, берләшегез!

Берләшегез, мәчеләр, берләшегез!
Этләр кебек өрмәгез, мияулагыз.
Безнең максат – этләргә этлек эшләү,
Беркемнән дә беркайчан оялмагыз.
Берләшегез, песиләр, берләшегез!
Мияулагыз, песиләр, мырлашыгыз,
Безнең башлар хәйләкәр, уйлашыгыз,
Кирәк икән тырнагыз, тырмашыгыз!

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Телефоннан сөйләшә-сөйләшә, Тәмлетамак керә.

Тәмлетамак. Аллю, Мияумистер! Ничек анда эшләр?

Экранда Мияумистер.

Мияумистер. О'кей, уйлыйм.
Тәмлетамак. Син уйлама, кешеләр уйласын. Аларның бүтән эшләре юк. Безгә хәрәкәт итәргә кирәк.
Мияумистер. Хәзер мин вирус программасы җибәрәм. Ул Кыш бабайны Интернет эченә суырып алачак. Аннан ул чыга алмаячак. Нигәдер Кар кызын таба алмыйм.
Тәмлетамак. Тап. Кар кызы да килмәсен.
Мияумистер. О'кей... Ләкин монда да бит этләр бар. Алар да компьютерны беләләр.
Тәмлетамак. Син нәрсә, этләргә бирешеп торасыңмы? Алар бит надан. Ә без акыллылар, хәйләкәрләр. Боз шуларның кампитрын.
Мияумистер. О'кей!
Тәмлетамак. Кыш бабайны эләктереп алмасыннар.
Мияумистер. О'кей!
Тәмлетамак. Их, үземдә кампитр булса, күрсәтер идем этләргә күрмәгәннәрен. (*Бозау, Бәти, Бәрән, Акбай, Чарлиның кергәнен күреп.*) Кайда Кыш бабаегыз, әфәнделәр?
Акбай. Ә син нәрсә авызыңны ерасың?
Тәмлетамак. Ерырлык авызым булганга ерам. Чыршы бәйрәмегез үтүт. Ялыныгыз миңа, үзем Кыш бабаегыз булам.
Акбай. Потың бер тиен.
Тәмлетамак. Хәзер бер тиен, бара тора мең сум булачак.
Без песиләр бөекләр бөеге,
Чөнки без юлбарыс затыннан.
(*Көйләп чыгып китә.*)
Акбай. Бу нәрсәдер кыландырган, ахрысы. Кыш бабайның килмәвендә моның да катнашы юк микән. Шылтырат әле, Чарли, Һаумистерга, нәрсә икән анда?
Чарли. Алмый бит телефонны.
Акбай. Тагын шылтыратып кара.
Чарли (*телефон номерларын җыеп*). Але, Һаумистер, кадерлем, каядыр югалдыгыз.
Һаумистер (*экранда*). Кемдер монда миңа комачаулый.
Чарли. Кыш бабай һаман да юк.
Һаумистер. Мин аны югалттым.

Чарли. Ничек?

Һаумистер. Кыш бабай Интернет кибетендә бүләкләр сайлый иде, кинәт юкка чыкты. Таба алмыйм. Кая китте икән дип баш ватам.

Акбай. Нәрсә ди?

Чарли. Югалттым, ди.

Акбай. Сора әле, Кышландиядә мәчеләр бар микән?

Чарли. Һаумистер, сездә анда мәчеләр бармы?

Һаумистер. Аларның булмаган җире бармыни?

Чарли. Кыш бабайның югалуы, бәлки, алар эшедер. Монда Тәмлетамак атлы бер мәче авызын ерып йөри. Бәйрәмегез булмаячак, ди.

Һаумистер. Хәзер беләбез. Тәк... Тәк... Тәк... Мияумистер серверы ябык, бәлки, шундадыр. Хәзер хакер программасы җибәрәм. Тәк... Тәк... Тәк... Әйе... Шулай... Бирелә! Мияумистер сайтында бикләнгән Кыш бабай.

Чарли. Чыгара аласызмы?

Һаумистер. Белмим әлегә. Саклану чаралары бик көчле.

Чарли. Тырыша күрегез, хөрмәтле Һаумистер! Уңышлар телим.

Акбай. Йә, ничек, Чарли?

Чарли. Монда эшләр бик катлаулы, Акбай абый. Кышландия мәчесе Мияумистер Кыш бабайны үз сайтына бикләп куйган.

Бәрән. Нәрсә соң ул сайт?

Бәти. Тик кенә тор, Бәрән. Син түгел, мин дә белмим.

Акбай. Артта калдык шул, артта калдык. Шәһәрнең һәр эте дә белә кампитрны. Без шул сөяк кимерүдән башканы белмибез.

Бәрән (*елап*). Нишлибез инде хәзер, Акбай абый?

Акбай. Туктале син, Бәрән...

Чарли. Их, белмәдем. Үземнең ноутбугымны алып килгән булыр идем.

Акбай. Нәрсә бугымны дисең, Чарли?

Чарли. Ноутбук. Кулга тотып йөри торган компьютер. Ул булса, Интернетка үзем чыгар идем дә... (*Телефоны шылтырый.*) Әйе, әйе, Һаумистер! Ярый, тырышыгыз инде, кадерле Һаумистер!

Акбай. Нәрсә ди?

Чарли. Кыш бабайны табып карыйм, ди. Минем нишләргә җыенганымны Мияумистер сизеп алды. Көрәшәбез, ди.

Акбай. Җиңә генә күрсен инде. Әйдәгез, без аңа теләк телик. (*Җырлыйлар.*)

Һаумистер, Һаумистер,
Сиңа бездән ярдәм тиештер.
Шул безнең ярдәмебез,
Ирешсен теләгебез.
Авыр эшең җиңел булсын,
Безнең дә күңел булсын.
Җиң, җиң, Һаумистер,
Җиң, җиң, Һаумистер.

Экраннар аша Кышландиягә күчәбез. Бер экранда Һаумистер, икенче экранда Мияумистер. Компьютерда эшлиләр.

Мияумистер. Әй, Һаумистер, эттән туган нәрсә, нигә минем сайтка тыгыласың? Минем супер антивирус программасын җиңәргә маташасыңмы?

Һаумистер. Гафу итегез, сез нигә Кыш бабайны үзләштердегез? Минем хакер программасы дөреслекне табачак. Ул көчле.

Мияумистер. Башта син Кыш бабайны үзләштердең.

Һаумистер. Мин аны үзләштермәдем. Мин аны Татарстанга җибәрергә җыенган идем. Мәрәтхуҗа дигән авылда аны көтәләр.

Мияумистер. Эт башыңнан нигә әле Кыш бабайларга баш булдың?

Һаумистер. Кыш бабайлар чакырган җиргә барырга тиешләр.

Мияумистер. Ә менә мин җибәрмәсәм, нишләрсең?

Һаумистер. Гафу итегез, сезнең аңа хакыгыз юк.

Мияумистер. Кем әйтте?

Һаумистер. Кыш бабайлар ирекле булырга тиеш!

Мияумистер. Туктале, Этмистер...

Һаумистер. Гафу итегез, Этмистер түгел, Һаумистер. Мин бит сезгә Песимистер дип әйтмим.

Мияумистер. Әйтеп кара... Туктале, син үзең нигә дип Кар кызын сайтыңа бикләп куйдың? Ул да бит ирекле.

Һаумистер. Мин аны бикләмәдем. Мин аны ашыгыч рәвештә Татарстанга җибәрдем. Сез дә Кыш бабайны җибәрегез.

Мияумистер. Юк, мин беркемне бер кая җибәрмим. Кыш бабай безнеке.

Һаумистер. Безнеке дә.

Мияумистер. Юк, безнеке генә. Кышландиягә мәчеләр хуҗа.

Һаумистер. Гафу итегез, ни дидегез?

Мияумистер. Кышландиянең хуҗалары – песиләр.

Һаумистер. Һау-һау-һау!

Мияумистер. Көлмә песидән, авызың өшегән.

Һаумистер. Авызым өшегән булса да, көләм сезнең ишедән. Җибәрегез Кыш бабайны.

Мияумистер. Ноу!

Һаумистер. Алайса, мин аны сездән тартып алам.

Мияумистер. Алып кара. Тыгылма, дим сайтка. (*Кесә телефоны шылтырый.*) Тыңлыйм, Тәмлетамак!

Тәмлетамак тавышы. Бирмә Кыш бабайны.

Мияумистер. Мәчеләр кулыннан әйбер алып булмый.

Тәмлетамак тавышы. Яшәсен мәчеләрнең какшамас дуслыгы!

Мияумистер. Бөтендөнья песиләре, берләшегез!

Һаумистерның кесә телефоны шылтырый.

Чарли тавышы. Хөрмәтле Һаумистер, ничек анда эшләр?

Һаумистер. Кар кызы китте, каршы алыгыз. Кыш бабай өчен көрәшәм.

Чарли тавышы. Афәрин. Бу көрәш тарихка кереп калачак, Һаумистер. Һәм ул «Интернет Акбай» исемендәге көрәш дип аталачак. Бу безнең иң бөек акциябез.

Тәмлетамак тавышы. Ишетәсеңме, Мияумистер? Бирмә Кыш бабайны. Монда этләр сездәге этләр белән берләшеп, сиңа каршы көрәшергә җыеналар. Көрәшләренең символын «Интернет Акбай» дип атадылар. Ә без көрәшебезне «Интексен Акбай» дип атыйбыз.

Мияумистер тавышы. Нигә Акбай? «Тәмлетамак» дип атыйк.

Тәмлетамак тавышы. Юк. Ноу. Этләрнең башын бутар өчен шулай кирәк.

Чарли тавышы. Хөрмәтлем Һаумистер, ишетәсезме мине? Ишетәсезме мине?

Һаумистер. Ишетәм, кадерле Чарли.

Чарли тавышы. Кыш бабайны көтәбез.

Һаумистер. Көтегез, җиңү безнең якта булачак.

Мияумистер. Син кем белән сөйләшәсең анда?

Һаумистер. Ә сез кем белән сөйләштегез?

Мияумистер. Интернет Акбай беләнме? Беләбез планнарыгызны. Нишлисең син, хайван, нигә минем сайтка керәсең? Хәзер күрсәтәм мин сиңа.

Ярыша-ярыша, компьютерда көрәшәләр. Клавиатура такылдаталар.
Үз-үзләренә сөйләнәләр.

Мияумистер. Кара, нишли... Мин бу этне бу хәтле акыллы дип уйламаган идем.

Һаумистер. Кара, ничек хәйләләп бикләп куйган.

Ишегалдында Кыш бабайны көтәләр.

Акбай. Нинди хәбәрләр бар, Чарли?

Чарли. Көрәшәләр! Кар кызы хәзер килеп җитә. Кыш бабай өчен кызу көрәш бара.

Бәти. Безгә көрәш кирәкми, безгә бәйрәм кирәк.

Акбай. Көрәшсез бәйрәм булмый, Бәти.

Бозау. Карагыз әле, кем килә...

Чарли. Кар кызы ул, иптәшләр. Каршы алыйк.

Җырлап, Кар кызын каршылыйлар.

Гүзәлләрдән гүзәл, нәфис Кар кызы,
Ераклардан ерак, озын юл узып,
Чыршыбызның бәйрәменә киләсең,
Безнең сагынып көткәнне син беләсең.
Хуш киләсең, хуш киләсең, Кар кызы,

Ераклардан ерак, озын юл узып.

Кар кызы керә.

Кар кызы. Исәнмесез, дусларым! Чыршы бәйрәме котлы булсын!

Акбай. Хуш киләсең, Кар кызы! Тик менә бәйрәмебезнең яме китеп тора бит әле.

Кар кызы. Әйе шул. Бабам тоткынлыкта. Мин хәтта аның белән сөйләшә дә алмыйм. Ләкин мин беләм: дөреслек җиңәчәк. Кыш бабай белән Кар кызы аларны көткән җирдә булырга тиеш. Дөрес бит, дусларым?

Тавышлар. Дөрес, дөрес!

Кар кызы (*бер читтә торган Тәмлетамакка*). Ә сез нигә читтә торасыз?

Кар кызы. Ул – мәче. Ул безнең бәйрәмебезне бозарга тели.

Тәмлетамак. Син тик тор, ярыймы.

Бозау. Ул безнең белән бәйрәм итәргә теләми.

Тәмлетамак. Син дәшмә, ярыймы.

Бәрән. Ул үзен әллә кемгә куя.

Тәмлетамак. Син кысылма, ярыймы.

Кар кызы. Туктагыз, туктагыз, дусларым, ямьсезләнмәгез. Дөньяның матурлыгын бозмагыз.

Бәти. Без түгел – ул.

Акбай. Йә, йә булды, әрепләшмәгез... Нишләтик, Кар кызы, Тәмлетамак ишегалдына хуҗа булырга тели. Безне санга сукмый. Алай ярамый бит инде. Менә мин дә эт, ләкин үземне президент дип әйтмим. Без ишегалдында барыбыз да тигезләр. Менә Чарли да... Ул Казанда тәрбиядә, өйдә яши. Урам эте дә түгел. Менә безнең янга кайткан. Кил, Тәмлетамак, безнең янга, этле-мәчеле яшәмик, бәйрәмнең ямен бозмыйк.

Тәмлетамак. Бөтенегез дә минем каршыга килегез, аягыма егылып, баш орып ялынсагыз, килермен.

Кар кызы. Алай ярамый, дустым.

Тәмлетамак. Мин синең дустың түгел.

Кар кызы. Һай, нинди тупас сез. Ялгыз яшәп булмый.

Тәмлетамак. Мин ялгыз түгел, без Җир шарында әллә ничә миллион.

Акбай. Ярый, игътибар итмәгез аңа, йөрсен берүзе мәчеләнеп.

Тәмлетамак. Мәчеләнәме, мәчеләнмиме, Кыш бабай килмәячәк. Кар кызы белән генә чыршы бәйрәме булмый. (*Кесә телефонынннан шылтыратып.*) Мияумистер, нык тор, җибәрмә безгә Кыш бабайны.

Мияумистер (*экранда*). Ес, Тәмлетамак!

Тәмлетамак. «Интексен Акбай» операциясе дәвам итә. Алар «Интернет Акбай» дип саташсыннар. Ә без «Интексен Акбай» белән үз эшебезне эшләрбез.

Мияумистер. Мин тырышам Кыш бабайны җибәрмәскә, ләкин Һаумистер дигән эт тә бик тырыша.

Тәмлетамак. Акбайның кампитрында тычкан дип атала торган нәрсә булырга тиеш, ягъни мәсәлән, мышь. Сезнеңчә, моус.

Мияумистер. Әйе, ес, бар. Безнекендә дә бар.

Тәмлетамак. Үзеңнекенә тимә. Һаумистер кампитрының тычканын аша.

Мияумистер. Ничек «аша»?

Тәмлетамак. Мәчеләр тычканны ничек ашый?

Мияумистер. Ләкин кампитр тычканы башка тычкан, ашарга ярамый торган тычкан.

Тәмлетамак. Кирәк булганда ярагaн-ярамаганны тикшермиләр, Мияумистер.

Мияумистер. О’кей!

Экран югала. Дүрткүз керә.

Дүрткүз. Исәнмесез-саумысыз, иптәшләр-товарищлар!

Кар кызы һәм Тәмлетамактан башкалар, шау-шу килеп, аны каршылыйлар, сорашалар.

Акбай. Ничек кайтасы иттегез, Дүрткүз?

Дүрткүз. Ничек инде авылдагы чыршы бәйрәменә кайтмыйсың?

Акбай. Шәһәр этләре ничек яши анда?

Дүрткүз. Өйдәгеләре әйбәт, урамдагылары элеккечә. Менә Акбай абый, урам этләре сиңа бүләк җибәрделәр. Кемнеңдер машинасыннан төшеп калган. Эчен ачып карасалар, ашарга яраклы бернәрсә дә юк, ди. Нәрсә икәнен белмиләр. Акбайның башы түгәрәк, нәрсә икәнен ул белер, диделәр.

Чарли. Бу бит ноутбук. Бу бит кампитр. Минем дә мондый кампитрым бар. Булды бу, хәзер эшкә тотынабыз. Кыш бабайны азат итәбез.

Барысы да Чарли тирәсенә җыелалар.

Чарли. Антенна кирәк. Антенна табыгыз.
Бәти (*бер тимер таяк алып килеп*). Тимер таяк ярыймы?
Чарли. Када җиргә.
Бәрән (*бер кәстрүл тотып килеп*). Бу ярыймы?
Чарли. Кигер таяк башына.

Экраннарда Мияумистер белән Һаумистер.

Мияумистер. Әй син! Кагылма диләр минем сайтка. Компьютерыңның тычканын барып ашыйм.
Һаумистер. Килеп карагыз.
Мияумистер. Нишлисең, кая китте Кыш бабай?
Һаумистер. Җикеренмәгез, миндә юк ул.
Мияумистер. Кая китте?

Сәхнә уртасындагы экранда Кыш бабай пәйда була. Ул, иңбашына капчыгын асып, кая барырга белмичә басып тора. Менә ул бәргәләнә башлый. Аны Һаумистер белән Мияумистер үз якларына тарткалыйлар.

Һаумистер (*Мияумистерга*). Нишлисез сез? Өзәбез бит Кыш бабайны.
Мияумистер. Ә син нигә тартасың?
Һаумистер. Аны ишегалдында көтәләр.
Мияумистер. Көтми генә торсыннар. (*Тарткалый торгач, Кыш бабайны урталайга яралар.*)
Һаумистер. Харап иттек.
Мияумистер. Беркемгә дә тәтемәсен. Бу ни? Кем тагын минем серверга бәреп керде.
Һаумистер. Ур-ра! Бу – Чарли. Чарли, афәрин!
Чарли. Безнең хакерлар мондый антивирусларны узарга күптән өйрәнде. (*Мияумистер компьютерыннан Кыш бабайның яртысын тартып чыгара.*) Һаумистер! Бир миңа Кыш бабайның икенче яртысын. (*Кыш бабайны тоташтыра.*) Исәнмесез, Кыш бабай!
Кыш бабай. Кем ул миңа эндәшә?
Чарли. Бу без Мәрәтхуҗа авылының ишегалдында. Кар кызы килеп җитте, сез – юк. Нигә килмисез?
Кыш бабай. Ничек барырга белмим. Кемнәрдер мине юлдан яздырдылар. Йә бер якка тартып алалар, йә икенче якка. Өзгәләделәр.
Чарли. Хәзер сезне саташтыручы булмас. Мин күрсәткән юлдан килегез.

Мияумистерның телефоны шылтырый. Тәмлетамакның тавышы ишетелә.

Тәмлетамак. Әй син, Мияумистер, аңгыра баш, нишләп Кыш бабайны ычкындырдың?
Мияумистер. Нишләп мине аңгырабаш дип мыскыл итәсең?
Тәмлетамак. Кем соң син Кыш бабайны тота алмагач?..
Мияумистер. Кышландия мәчесен мыскыл итәргә хакың юк. Бөтендөнья мәчеләре, берләшегез, дип кенә булмый ул. Берләшкәч, дус булырга кирәк.
Тәмлетамак. Төкерәм мин синең дуслыгыңа. Мин кушканны эшләмәгәч.
Мияумистер. Ә мин сезнең белән бу тонда сөйләшергә теләмим. (*Телефонын сүндерә.*)

Һаумистерның телефоны шылтырый.

Һаумистер. Тыңлыйм, Чарли.
Акбай. Чарли түгел әле бу, Акбай.
Һаумистер. Исәнмесез, мистер Акбай! Чыршы бәйрәме белән котлыйм! «Интернет Акбай» операциясенең уңышлы тәмамлануы белән дә котлыйм!
Акбай. Анысы өчен Чарлига рәхмәт. Хәзер телефонны аның үзенә бирәм.
Чарли. Хелло, Һаумистер! Сезгә зур рәхмәт.
Һаумистер. Үзегезгә рәхмәт.
Чарли. Безнең чыршы бәйрәменә рәхим итегез, Һаумистер!
Һаумистер. Без бит һәрвакыт бергә, Чарли. Кышландия ул әкиятләр иле. Аны карталардан эзләп табып булмый. Ул һәрберебезнең күңелендә. Димәк, мин инде сезнең янда. Дөньяда әкиятләр барын онытмыйк. Хушыгыз, Чарли!

Һаумистер экранда югала. Кыш бабай пәйда була.

Кыш бабай. Котлы булсын чыршы бәйрәме, балалар!

Ишегалды халкы. Котлы булсын! Хуш киләсең, Кыш бабай!

Кар кызы. Мин монда, бабакай!

Кыш бабай. Рәхмәт төшсен, кызым! Миннән алда килеп җиткәнсең. Миңа озын юллар үтәргә туры килде шул. (*Читтә басып торган Тәмлетамакка.*) Ә син нигә безнең янга килмисең?

Бәти. Ул сине китермәскә тырышты. Үзе мәче булса да, этлек эшләргә ярата.

Кыш бабай. Алай икән. Димәк, ялгышкан. Ялгышканнарны гафу итәргә кирәк. (*Тәмлетамакка.*) Кил бирегә.

Тәмлетамак. Мин оялам.

Кыш бабай. Ояла белү күркәм гадәт. Димәк, син әле бигүк начар түгел. Төзәлерсең. Кил якынрак. Инде Яңа елны, чыршы бәйрәмен котлап җыр җырлыйк.

Җырлыйлар, Чарли бии.

Еллар китә, ел артыннан
Туа тора яңа еллар.
Алда безне көтеп тора
Өмет тулы яңа юллар.
Кыш бабайлы һәм Кар кызлы Яңа ел!
Син һәрвакыт безнең өчен яңа бул,
Яңа шатлык, яңа бәхет алып кил,
Яңа елга яңа юллар салып кил!
Еллар кыска, юллар озын,
Дуслар белән бергә узыйк.
Һәм яңадан бергә-бергә
Киләчәккә юллар сузыйк.
Кыш бабайлы һәм Кар кызлы Яңа ел!
Син һәрвакыт безнең өчен яңа бул,
Яңа шатлык, яңа бәхет алып кил.
Яңа елга яңа юллар салып кил!

Пәрдә.

# Әйт әле, Күбәләк

*Ике пәрдәле пьеса*

КАТНАШУЧЫЛАР:

Тукай.
Апуш.
Акбай.
Шүрәле.
Сандугач.
Күбәләк.
Карлыгач.
Каракош.
Күбәләкләр, карлыгачлар.

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

Сәхнәдә караңгылык һәм тынлык. Менә шул тынлыкны бозып, моңлы музыка ишетелә һәм бер нур сәхнә түрендәге Тукайның йөзен яктырта. Тукай әкрен генә сәхнә алдына килә, нур да киңәя, Тукайны бөтен гәүдәсе белән яктырта. «Мин кемнәрнең күңелендә яшим икән» дигән сыман, залдагы тамашачыларны күзләре белән барлап чыга.
Аның күз карашын зал буйлап йөргән нур күрсәтеп бара.

Тукай (*барлап бетергәч*). Минем гомерем шактый күңелсез, шактый караңгы, шуның белән бергә кызык кына үтте. Атам илә анам бер ел ярым кадәр бергә торгач, беренче бала буларак, мин дөньяга килгәнмен. Минем туганыма 5 ай заман үткәч, атам аз гына авырып дөнья куйган. Тол калган анам янында берничә вакыт торгач, анам, мине Шәрифә исемле бер фәкыйрь карчыкка вакытлыча асрарга биреп калдырып, Сасна авылы имамына кияүгә чыкмыштыр. Соңра анам мине үз янына алдырган. Ләкин бу рәхәт бик озакка бармаган, анам нindидер авырудан вафат булган. Әнкәмнең җеназасын

күтәреп алып барганда, кышның үтә дә салкын көнендә яланаяк, яланбаш килеш «әнкәйне кайтарыгыз, әнкәйне бирегез!» дип шактый гына җир мәет күтәрүчеләрдән калмый барганмын. Бу вакыт миңа нибары өч яшь тә сигез айлар чамасы була. Шул көннән соң мин кулдан-кулга йөреп, хәсрәтнең иң ачы җимешләрен татып, яңадан туган авылым Кушлавычка кайттым. Миңа ул вакыт инде сигез яшь ярымнар тирәсе булгандыр.

Әкрен генә сәхнә яктыра. Күктәге йолдызлар берәм-берәм сүнә. Ай бата. Тукай шигыренә язылган җыр ишетелә:

Галибанә яктырып, әкрен генә ал таң ата,
Моңланып, хәсрәтләнеп, ялкау гына ак ай бата.
Бер-бер артлы юк булып, күкләрдә йолдызлар сүнә,
Таң җиле куйды исеп, яфраклар аз-аз селкенә.

Кояш чишмә янында үлән-чәчәкләр арасында тезләрен кочаклап утырган бәләкәй Тукай – Апушны яктырта. Тукай берара Апушка карап тора да ботаклы-чатаклы бер агачка барып сөялеп Апушны күзәтә. Апуш селкенмичә дә утыруын дәвам итә. Шулчак күбәләкнең «Хәерле иртә!» дигән тавышы ишетелә. Апуш, башын күтәреп, тавыш иясен эзли. Тавыш яңадан кабатлана.

Апуш. Кем син?
Күбәләк (*көлеп*). Ә син эзлә. Уңга карап, сулга карап.
Апуш. Карадым, күренмисең.
Күбәләк. Алга кара.

Кояш нуры Апуш каршындагы чәчәккә кунган Күбәләкне яктырта.

Күбәләк. Күрдеңме инде?
Апуш. Син Күбәләкме?
Күбәләк. Әйе, мин – күбәләк. Кояш җылысыннан уянучы табигать бизәге. Ә син монда нишләп утырасың?
Апуш. Ә мин чишмә җырын тыңлыйм. Иртән-иртүк киләм дә чишмә җырын тыңлап юанам.
Күбәләк. Мин күрдем, син моңланып утырасың.
Апуш. Моңлы бала моңлана инде ул.
Күбәләк. Ә син моңланма. Уйна.
Апуш. Берүземме? Ничек итеп?
Күбәләк. Менә миңа кара. (*Очына-очына уйный. Аңа кояш нуры ияреп йөри. Күбәләк әкренләп ифрат та гүзәл кыз балага әверелә. Канатларын җилпи-җилпи бии. Җыр суза.*)

Мин Күбәләк, Күбәләк,
Әйдә биик бергәләп.
Кояш безне сәламли,
Биегез, биегез, ди.
Шатлана белегез, ди,
Боега күрмәгез, ди,
Кайгырып йөрмәгез, ди.

(*Апуш каршысына чүгәләп.*) Ә син нигә биемисең?
Апуш. Биисем килми минем.
Күбәләк. Нигә?
Апуш. Биисем дә, уйныйсым да килми. Күңелемдә шатлык юк.
Күбәләк. Шатлык ул биегәндә килә.
Апуш. Рәхмәт сиңа яныма килгән өчен. Минем бит сөйләшер кешем дә юк, Күбәләк. Мин ятим. Кулдан-кулга йөрим.
Күбәләк. Ә син әйт, синең күңелеңне ачар өчен мин нишлим?
Апуш. Сөйләшеп утырыйк.
Күбәләк. Утырыйк. Синең исемең ничек?
Апуш. Габдулла булачакмын. Хәзергә мин әле Апуш кына.
Күбәләк. Сөйләшик, Апуш!
Апуш. Әйт әле, Күбәләк, сөйләшик бергәләп,
Бу кадәр күп очып, армыйсың син ничек?
Ничек соң тормышың? Ничек көн күрмешең?
Сөйләп бирче тезеп: табаламсың ризык?

Күбәләк. Мин торам кырларда, болында, урманда,

Уйныймын, очамын якты көн булганда.
Иркәли һәм сөя кояшның яктысы,
Аш буладыр миңа чәчәкләр хуш исе.

(*Апушны кулыннан тотып.*) Син, әйдә, тор. Тирә-ягыңа кара. Күр, ничаклы матурлык!

Апуш. Мин аларны күрмим шул, Күбәләк. Күзләрем күрсә дә, күңелем күрми. Әтием юк, әнием юк. Син ятимлекне аңламыйсың, син бары кайгы-хәсрәтсез генә очып уйныйсың.

Күбәләк. Ә син беләмсең, Апуш, күбәләкнең гомере бер көнлек. Шуңа күрә дөньяның матурлыгын җаныңа сеңдереп өлгерергә кирәк. Кеше гомере – озак. Кайгырып-моңаеп кына яшәсәң, ул гомерне ничек яшәп бетерерсең? Көл син, юат үз күңелеңне. Кил әйдә, биибез.

Апуш. Юк, Күбәләк. (*Җиргә утырып.*) Күңелем үсми минем. Менә син әйт әле, Күбәләк, нигә мин бәхетсез булып тудым икән?

Күбәләк. Алай димә, Апуш. Бәхетнең ни икәнен үсә-үсә аңларсың. Әйдә, биибез!

Апуш. Синең уеңда бию генә.

Күбәләк. Сине юатасым килә, Апуш. Синең күңелеңне ачу өчен нишлим икән? Тукта... Син беркая да китмә. Мин хәзер киләм.

Апуш Күбәләкне көткәндә, аның янына Акбай чабып килә.

Акбай. Һау-һау, син монда икәнсең, Апуш. Ә мин сине эзләп йөрим.

Апуш. Син беләсең бит, мин кояшны чишмә янында каршылыйм.

Акбай. Беләм дә, онытканмын. Әйдә кайтабыз, сине хуҗалар эзли.

Апуш. Нигә?

Акбай. Сине каядыр алып китәргә җыеналар бугай.

Апуш. Әйе. Килеп тә җиткәннәрмени?

Акбай. Шулайдыр. Мин кешеләрнең телен аңлап та бетермим бит әле. Мин бит әле бик кечкенә. Мин сине генә аңлыйм, синең белән генә сөйләшә беләм. Син китмә, Апуш, Кушлавычтан. Ул синең туган авылың.

Апуш. Минем бүген уйныйсым килми, Акбай. Минем бүген кәефем юк.

Акбай. Син боекма, Апуш. Әнә Күбәләк килә. Әйдә аны бергә куабыз.

Күбәләк. Куышлы уйнарга вакытым юк, Акбай. Апушның күңелен ачарга кирәк. Мин аның күңелен ачар өчен Сандугачны алып килдем. Сандугач, кил монда!

Сандугач. Куркам мин. Анда Акбай. Ул кошларны куркыта.

Акбай. Син нәрсә, куркытмыйм мин, уйныйм гына. Әнә бит Күбәләк курыкмый. Ул әле минем колагыма кунып та уйный. Кил.

Сандугач. Барыбер, читкәрәк кит.

Акбай. Ярый, ярый, синеңчә булсын. (*Читкәрәк китеп утыра.*)

Сандугач. Сиңа ни булды, Апуш? Нигә шулай моңаясың?

Акбай. Ә син сорашма, сайра гына.

Күбәләк. Сайра, Сандугач, Апушның күңеле ачылсын.

Сандугач. Минем җырым таң турында шул. Хәзер инде, күрәсең, кояш чыкты.

Күбәләк. Син барыбер җырла, Апушка җырла.

Сандугач. Бәлки, минем җырым аңа ошамыйдыр.

Апуш. Сандугач сайравын, Сандугач җырын ошатмаган җан иясе юктыр.

Сандугач. Алайса, тыңла.

Чут-чут, чут-чут,
Минем җырым таң турында,
Җырым туа таң нурында.
Чут-чут, чут-чут, трил-трил, чут-чут.
Җырым белән төн озатам,
Җырым белән таң уятам.
Чут-чут, чут-чут.
Һәр җырымда җәйләр яме,
Һәр җырымда яшәү тәме.
Трил-трил, чут-чут, трил-трил, чут-чут.
Моңлы җырым – моңсуларга,
Дәртле җырым – ярсуларга.
Чут-чут, чут-чут.
Басып сайрар гөлләрем бар,
Мактап җырлар илләрем бар.
Чут-чут, чут-чут, трил-трил, чут-чут.

Апуш. Рәхмәт сиңа, Сандугач!
Акбай. Мактап җырлар илләрем бар, дисең, кайда соң синең илләрең?

Күбәләк белән Сандугач көлешәләр.

Сандугач. Бала шул әле син, Акбай. Шушында бит инде минем илем. Әнә теге әрәмәлектә.
Акбай. Алайса, «илем» диген. Нигә «илләрем» дисең? Менә минем илем берәү генә.
Апуш. Акбай, бәхәсләшмә. Сандугач, өйрәт миңа җырыңны. Кая гына барсам да, синең җырыңны җырлармын. Ничә яшьтә булсам да, синең җырыңнан аерылмам.

Туган үскән җирләрем бар,
Мактап җырлар илләрем бар.

Сандугач. Трил-трил, чут-чут, чут-чут.

Сандугачның сайравына Күбәләк кушыла. Акбай да чут-чут дип сикеренгәли. Апуш килә. Күбәләк белән Сандугач биергә тотыналар. Аларга Апуш та, Акбай да кушыла. Шул вакыт читтәрәк үсеп утырган Тукай сөялгән ботаклы-чатаклы агач та хәрәкәткә килә. Бактың исә ул
Шүрәле икән.

Шүрәле. Нигә мине оныттыгыз, нигә мине биергә чакырмыйсыз? (*Тукайга.*) Ә син, Тукай, китеп тор, син зур инде. Син үзеңнең бала чагыңны гына күзәт.
Күбәләк. Син монда идеңмени, Шүрәле? Исәнме, Шүрәле!
Шүрәле. Монда булмый, кайда булыйм?! Менә ич мин, монда ич мин, шуңа гына тордым ич, сине тыңлап тордым ич мин. (*Каршына өреп килгән Акбайга.*) Син нигә өрәсең миңа, көчек?
Акбай. Көчек түгел мин, Акбай мин.
Шүрәле. Акбай булсаң, Шүрәле абзаң белән исәнләшеп сөйләш. Әнә Күбәләктән үрнәк ал. (*Апуш каршысына килеп.*)

Борным кәп-кәкре – бөгелгәндер
Тәмам кармак кеби;
Төз түгел куллар, аяклар да –
Ботак-тармак кеби...
Яп-ялангач, нәп-нәзек,
Ләкин кеше төсле үзем.
Урта бармак буйлыгы бар
Маңгаемда мөгезем.
Кәкре түгелдер минем бармакларым –
Бик төз төзен.
Тик килешсез – һәрбере дә
Ярты аршыннан озын.

Апуш. Ә мин сине беләм.
Шүрәле. Беләсең? Минеме? Безнең күрешкәнебез юк.
Апуш. Миңа Былтыр бабай сөйләде.
Шүрәле. Ә-ә-ә, Былтыр. Беләбез без аны. Ул минем бармагымны бүрәнә ярыгына кыстырган иде. Ләкин мин үч сакламыйм. Шүрәлеләр үч саклый белмиләр. Ә син миннән куркасыңмы, Апуш?
Апуш. Юк, курыкмыйм.
Шүрәле. Ничек курыкмыйсың? Куркыныч ич мин.
Апуш. Юк, куркыныч түгел. Сине күргәч, минем көләсем килә.
Шүрәле. Көләсең килә? Бу – яхшы. Мин сиңа рөхсәт итәм, көл син миннән, Апуш, рәхәтләнеп көл, күңелең күтәрелсен.
Күбәләк. Көл, Апуш.
Сандугач. Көл, елмай, Апуш.
Акбай. Көл, Апуш. (*Үзе кычкырып көлә.*)
Шүрәле. Ә син көлмә, көчек. Үземнән көләргә мин кешеләргә генә рөхсәт итәм. Чөнки алар мине уйлап чыгарган.
Апуш. Мин кеше түгел шул әле, малай гына.
Шүрәле. Юк, Апуш, син – кеше. Моннан сигез ел элек, Кырлай урманында көн итүче бабам әйтте: «Кушлавыч авылында бер бала туды. Аңа Габдуллаҗан исеме куштылар. Ул әлегә Апуш кына. Үскәч зур кеше булачак», – диде. Ә без шүрәлеләр ялган сүз сөйләмибез.

Күбәләк белән Сандугач сөенешәләр.

Күбәләк. Чынлап та шулай дидеме бабаң?
Шүрәле. Мөгезем белән ант итәм.

Сандугач. Шундый шатлыклы хәбәрне ишеткәч, сайрыйсы килә, җырлыйсы килә. Әйдә, Шүрәле, мин җырлыйм, син бие.

Шүрәле. Гүзәлләрдән гүзәл Сандугач! Синең сайравыңны мин тын да алмый тыңлыйм. Бии-бии тыңлыйм. Әмма бу юлы мин Апуш янына килдем. Мин Апуш такмак әйтсә генә биим.

Апуш. Мин бит такмак әйтә белмим.

Шүрәле. Ә син өйрән, Апуш. Сиңа өйрәнергә кирәк. Синең бит киләчәктә зуп-зур Тукай буласың бар.

Күбәләк. Афәрин, Шүрәле!

Акбай. Маладис, Шүрәле!

Шүрәле. Үз телеңдә сөйләш, көчек!

Акбай. Мин көчек түгел, Акбай мин.

Шүрәле. Үз телендә сөйләшмәгәннәр Акбай була алмый, көчек кенә була ала.

Сандугач. Бәхәсләшмәгез! Бие, Шүрәле! Апуш, такмак әйт!

Апуш. Бие, бие, Шүрәле,
Әрле-бирле йөр әле.
Бии-бии йөреп кенә
Күңелебезне күр әле.

Шүрәле (*биеп китеп*). Әйт шуны!

Апуш. Әй, Шүрәле, Шүр генә,
Син дөньяда бер генә.
Безнең урман синең өчен,
Рәхәтләнеп йөр генә.

Шүрәле. Әйт шуны. (*Тагын да дәртләнебрәк бии.*) Кил, Апуш, бие минем белән.
Кил, Апуш, яннарыма,
Ял булыр җаннарыма.
Әйдә син дә, Күбәләк,
Биик бергә-бергәләп.
Бие әйдә, Сандугач,
Күңелсез син булмагач.
Әйдә, Акбай, син дә бие,
Биер өчен бию көе.

Бию көен бүлдереп, шомлы көй яңгырый. Сәхнәгә Каракош күләгәсе төшә. Биючеләр туктап калалар.

Каракош (*көлә*). Биегән буласызмы, мескеннәр? Ләкин белми биисез. Хәзер мин сезне үзем биергә өйрәтәм.

Шүрәле. Син кем?

Каракош. Син нәрсә, Сәләмә, мине танымыйсыңмы? Мине күргәнең юкмы, Сәләмә йолкыш?

Шүрәле. Мыскыл итмәвеңне үтенәм.

Каракош. Әле син үтенә дә беләсеңмени, йолкыш? (*Шүрәле өстенә килә.*) Хәзер мин сиңа үтенәм, Сәләмә.

Апуш (*Каракош алдына баса*). Тимәгез аңа.

Каракош. Бу нинди имгәк?

Апуш. Мин имгәк түгел, мин – кеше.

Каракош. Кеше? Ха-ха-ха!.. Кеше шундый була микәнни? Яле, яле, күреп карыйк әле кешене. Нинди була икән ул кеше?! Күрешик әле кеше белән. Танышыйк. Мин Каракош булам, кеше әфәнде. (*Җырга күчеп.*)

Минем исем шәрифләрем – Каракош,
Миннән көчле бер зат та юк дөньяда.
Тырнакларымны батырсам, кан ага,
Канатларымны җилпесәм, җир яна.
Миңа каршы чыгучылар җан бирә,
Минем сүздән чыгучылар кыйнала.
Миннән качып биючеләр яшь түгә,
Миннән башка көчлеләр юк дөньяда.

Белдегезме инде минем кемлегемне, кеше кисәге.

Апуш. Белмим. Белергә дә теләмим.

Каракош. Шулаймыни? Шулай ук көчлемени син, имгәк. Ха-ха-ха...

Апуш. Көлмә кешедән, томшыгың өшегән.

Каракош. Ай-яй-яй, ай-яй-яй, курыктым. Котым ботыма төште, канатларым калтырый башлады. Син беләсеңме, кеше кисәге, мин күкләр белән кыялар патшасы. Ачуым килсә, җәй белән кышны үземнеке итәм, зәһәрем чыкса, күләгәм белән кояшны томалыйм.

Апуш. Күләгә белән кояшны томалап булмый. Кояш булганда гына күләгә була.

Каракош. Кара, син ниләр беләсең икән!

Апуш. Беләм. Син дә өйрән.

Каракош. Кил әле, өйрәт әле!

Апуш. Кит син безнең авылдан. Күләгәң белән безнең авылны каплама. Кит безнең җиребездән.

Каракош. Синең җирең юк, барысы да минем җирем.

Апуш. Юк, бу – безнең җир.

Каракош (*Апуш өстенә килә*). Синең җирең минем канат астында.

Шүрәле (*Каракоштан Апушны каплап*). Килмә якын Апушка.

Каракош. Син, йолкыш, кемгә каршы төшкәнеңне беләсеңме?

Шүрәле. Бик беләм, куркытма.

Каракошка ташлана. Каракош аны селтәп ыргыта. Акбай өреп Кара-
кошка ыргыла. Каракош аны да селтәп ыргыта.

Каракош. Йә, тагын кайсыгыз бар? Мескеннәр! Каракошка каршы чыгарга уйлаганнар. (*Апуш өстенә килә.*) Хәзер сине дә дусларың янына олактырам.

Сандугач. Каракош, зинһар, тимә Апушка. Ул бит әле бәләкәй.

Каракош. Бәләкәй булса, телен тыйсын. Миңа «җирем» дип лыгырдамасын. Ә син нигә аның өчен сайрыйсың? Кем сиңа сайрарга рөхсәт итте. Минем рөхсәтемнән башка бу җирдә бер кош та сайрарга тиеш түгел.

Күбәләк. Каракош, тимә Апушка. Ул мине ярата.

Каракош. Ә син кем? Син миңа сүз әйтәсеңме, өтек?! Күбәләк булсаң, бүтән җирдә бие. Югалыгыз күз алдымнан!

Карлыгач. Кычкырма, Каракош – кара корсак, балаларымны куркытасың.

Каракош. Кем ул анда тагын әле?

Карлыгач. Мин ул.

Каракош. Син кем?

Карлыгач. Без Карлыгач булырбыз, Каракош – кара йөрәк.

Кара уйлы Каракош,
Килеп безнең авылга,
Кара канатың белән
Син Апушка кагылма.

Кара эчле Каракош,
Килмә безнең якларга,
Кара канатың белән
Җиребезне капларга.

Кара җанлы Каракош,
Курыкмыйбыз без синнән.
Ал кара канатыңны
Апушыбыз өстеннән.

Каракош. Ах, син!.. Мин сине!.. (*Карлыгач өстенә килә.*)

Карлыгач. Ә син мине тагын куып кара, кара уйлы Каракош!

Карлыгач үзенә ташланган Каракоштан тайпылып өлгерә. Каракош тагын ташлана, Карлыгач тагын тайпылып өлгерә. Куышып чишмә
буйлап китәләр.

Күбәләк. Рәхмәт Карлыгачка! Куркудан үләм дип торам. Син бик курыктыңмы, Апуш?

Апуш. Без курка торган халык түгел.

Сандугач. Каракоштан курыкмаган җан иясе юк.

Апуш. Үскәч, минем янга килеп карап карарсың. Ул үзен мәңгелеккә килгән дип уйлый. Рәхмәт сезгә, дусларым, мине якладыгыз.

Сандугач. Без яклап нишли алабыз инде? Без бит сайрый гына беләбез. Рәхмәт Карлыгачка!

Күбәләк. Каракош куып тота алмаса ярар иде. (*Елап.*) Шүрәле кызганыч, Акбай кызганыч.

Карлыгач керә.

Карлыгач. Нәрсә җебеп төштегез?

Сандугач. Син исән икәнсең, Карлыгач!

Күбәләк. Без сине кызгандык.

Карлыгач. Нигә кызганырга? Каракошта көч булса, бездә җитезлек бар. Мине куып тотам дигәндә, мин тиз генә тайпылдым да, ул, үз кыясына үзе бәрелеп, җиргә мәтәлеп төште.

Күбәләк

Сандугач (*сөенешеп*). Рәхмәт сиңа, Карлыгач!

Апуш. Рәхмәт, Карлыгач!

Карлыгач. Без бит бер ишегалдында яшибез, Апуш. Син миңа карап сокланасың. Балаларыма тимисең. (*Җирдә яткан Шүрәле белән Акбайны күреп.*) Ә алар нишләп яталар?

Күбәләк. Каракош шулай итте аларны.

Карлыгач. Барыгыз әле, чишмәдән су алып килеп өсләренә бөркегез.

Сандугач белән Күбәләк чишмәдән су ташып Шүрәле белән Акбай өстенә бөркиләр.

Шүрәле (*күзләрен ачып*). Мин кайда?

Карлыгач. Син Кушлавычта, Шүрәле. Рәхмәт, Апушыбызны якладың.

Шүрәле. Якладым да, көчем җитмәде шул, көчем.

Карлыгач. Көчегез җитмәсә дә, көрәштегез. Кара көчләргә каршы көрәшергә кирәк. Дөрес әйтәмме, Апуш?

Апуш. Мин көрәшәчәкмен!

Карлыгач. Ярый, мин балаларым янына очтым. Ә сез җырлагыз, биегез.

«Апуш! Габдуллаҗан!» дигән тавыш ишетелә.

Акбай. Өйдә сине көтәләр, Апуш. Син ишегалдында җигелгән ат күрмәдеңме, Карлыгач?

Карлыгач. Күрдем, кая ияреп барырга җыенасың?

Акбай. Апушны алып китәләр бит бүген.

Карлыгач. Кая?

Акбай. Белмим кая икәнлеген. Алып китәләр.

Сандугач. Апуш, китмә!

Күбәләк. Китмә, Апуш!

Апуш. Мин үз ихтыярымда түгел шул, дусларым. Мине дөнья буйлап йөртәләр. Менә үсеп җитәрмен дә кайтырмын яныгызга. Бер дә аерылмам.

Күбәләк. Ул чакта мин булмам шул инде, Апуш. Зарар юк, мин үземнән соң туачак күбәләкләргә әйтеп калдырырмын, Апуш кайтканда, аны каршы алыгыз, диярмен.

Сандугач. Мин дә әйтеп калдырырмын. Алар сиңа, Апуш, минем сиңа җырлаган җырымны җырларлар.

Акбай. Ул чакта бәләкәй булмый инде Апуш. Зур була.

Апуш. Юк, күңелем минем Апуш булып калыр.

Шүрәле. Ә мин Апушны үзем каршылаячакмын. Апуш ничә яшьтә булса, мин дә шул яшьтә булачакмын. Шүрәлеләр картаймый. Син кайтканда, Апуш, менә шул урында ботаклы агач булып басып торырмын.

Күбәләк. Синең күбәләкләргә күңелсез булыр, Апуш.

Карлыгач. Елашмагыз. Кешене елап озатырга ярамый. Җырла җырыңны, Сандугач!

Сандугач. Сау, исән бул, Апушыбыз,
Сердәшебез һәм дустыбыз.
Сикәлтәсез булсын юлың,
Исән булсын аяк-кулың.

Кайт яңадан зур дан алып.
Исемеңне данга манып.
Апуш булып киттең бездән,
Зуп-зур булып кайт син безгә.

Апуш. Рәхмәт, Сандугач, рәхмәт, дусларым!

Күбәләк. Мин инде синең белән мәңгелеккә хушлашамдыр, Апуш. Биеп озатам үзеңне. Моңсу чакларыңда минем биюемне искә төшер. (*Бии.*)

Апуш. Рәхмәт, Күбәләк! Кая гына булсам да, кем генә булсам да, сине онытмаячакмын.

Шүрәле. Мин дә бии беләм бит, Апуш дус. Әйдәгез әле, сиптерик әле бер. Дөньясы селкенсен. (*Бииләр.*)

Пәрдә.

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

Беренче пәрдәдәге чишмә буе. Кояш күтәрелеп килә.

Карлыгач (*очып керә*). Һә-һә-һәй! Белмәгәннәр, белегез, ишетмәгәннәр, ишетегез, күрмәгәннәр, күрегез! Кайтып килә! Кайтып килә!

Акбай керә. Ул инде картайган.

Акбай. Кем кайтып килә?
Карлыгач. Шагыйрь кайтып килә, шагыйрь кайтып килә!
Акбай. Нинди шагыйрь? Кайсы шагыйрь?
Карлыгач. Тукай дигән шагыйрь, ди. Дусларым хәбәр иттеләр. Казаннан чыгып китә, диделәр. Кушлавыч аның туган авылы, диделәр.
Акбай. Үзебезнең Апуш түгел микән? Беләм бит мин аны, үзем озатып калган идем. Исеме Габдуллаҗан түгел микән?
Карлыгач. Исемен әйтмәделәр, Тукай гына, диделәр. Кушлавычка кайта, диделәр.
Акбай. Бар, оч каршысына, исемен белеп безгә хәбәр бир.

Карлыгач очып чыгып китә. Шүрәле керә.

Шүрәле. Ни булды монда? Нинди тавыш?
Акбай. Тукай кайтып килә, ди. Безнең Апуш түгел микән, дибез. Син дә беләсең бит Апушны?
Шүрәле. Ничек инде белмәскә? Нәрсә, ул хәзер Тукай булды микәнни? Шагыйрь булам, дигән иде.
Акбай. Шагыйрь, ди, Тукай, ди.
Шүрәле. Алайса, ул үзебезнеке! Үзебезнең Апуш! Үзебезнең Тукай! Сандугачларга, күбәләкләргә хәбәр итик. Апуш аларны ярата иде.
Акбай. Ул яраткан сандугачлар, күбәләкләр юк бит инде. Апушны синең белән мин генә күреп беләбез. Без дә картайдык.
Шүрәле. Шүрәлеләр картаймый. Алар һәрвакыт 18 яшьтә. Һә-һә-һәй, сандугачлар! Күбәләкләр!

Каракош керә.

Каракош. Нәрсә үкерәсез монда? Тавышыгыз әллә кая ишетелә. Син кемнәрне чакырасың, Шүрәле?
Шүрәле. Сине түгел! Каракошны чакырмыйлар, ул чакырмыйча килә.
Каракош. Ха-ха-ха! Чөнки дөньяга мин хуҗа.
Шүрәле. Син бик кабарынма, Каракош. Син инде элеккеге Каракош түгел. Картайдың, безне җиңә алмассың.
Каракош. Минме картайдым? Мин әле... Мин сине... Мин сине беләсеңме нәрсә эшләтәм, Сәләмә?
Шүрәле. Нишләтә дә алмыйсың, Каракош. Яхшы чакта кит моннан. Без монда үзебезнең Апушны карый алабыз. (*Кергән сандугачларга, күбәләкләргә.*) Килегез, сандугачлар, килегез, күбәләкләр! Курыкмагыз Каракоштан, ул инде хәлсез.
Каракош. Ах, сәләмә Шүрәле! Мин сине!.. (*Шүрәле өстенә килә.*)

Алышалар, Шүрәле Каракошның канатларын каерып тота. Акбай шатланып өреп тора.

Шүрәле. Каурыйларыңны йолкып бетерәм. Югал күз алдымнан.
Каракош. Күрсәтермен мин әле сиңа. (*Китеп бара.*)
Акбай. Афәрин, Шүрәле, афәрин.

Карлыгач керә.

Карлыгач. Шул үзе. Мин кечкенә Апуш үзем, зуп-зур Тукай булдым, ди. «Тау башына салынгандыр безнең авыл, бер чишмә бар, якын безнең авылга ул» дип җырлый. Сез аны каршыларга әзерләнә торыгыз, мин балаларымны алып килеп җитәм.
Сандугач. Безне нигә чакырдың, Шүрәле?
Күбәләк. Ә безне нигә чакырдың?
Шүрәле. Безнең Апушыбыз кайта.
Акбай. Тукаебыз кайта.
Сандугач. Ә кем ул?
Күбәләк. Кем ул Апуш? Кем ул Тукай? Без аны белмибез.

Шүрәле. Белмәсәгез белерсез. Ә сезнең бабаларыгыз, әбиләрегез аны белә иде. Алар шушы чишмә буена Апуш белән уйнарга килә иде.

Күбәләк. Нинди уен уйнарга?

Акбай. Минем белән нинди уен уйныйсың соң? Кояшта кызынып ятарга да ирек бирмисең.

Күбәләк. Син бит Акбай, ул – Тукай, ди.

Шүрәле. Син аны куандырыр өчен биерсең. Ә син, Сандугач, сайрарсың да җырларсың.

Сандугач. Ә кайсы җырны җырларга?

Шүрәле. Сандугачның кайсы җыры да Тукайга ошар.

Сандугач. Мин таңны каршылау җырын җырлыймын.

Карлыгач керә.

Карлыгач. Килә. Әнә килә. Чишмә янына килә.

Шүрәле. Әйтегез, тезелешеп басыгыз. Сандугач, башла.

Сандугач. Чут-чут, чут-чут,

Минем җырым таң турында.
Җырым туа таң нурында,
Чут-чут, чут-чут, трил-трил, чут-чут.

Тукай керә. Каршылаучыларга сокланып карап тора. Сандугач җырын дәвам итә. Күбәләк бии.

Һәр җырымда җәйләр яме,
Һәр җырымда яшәү тәме.
Чут-чут, чут-чут.
Моңлы җырым – моңсуларга,
Дәртле җырым – ярсуларга.
Чут-чут, чут-чут.

Шүрәле. Хөрмәтле вә гыйззәтле Тукай! Без сине туган авылыңа исән-сау кайтуың белән чын күңелдән котлыйбыз. Төкле аягың белән!

Карлыгач. Чын күңелдән куанып каршылыйбыз сине.

Тукай. Рәхмәт сезгә! Мин сезне сагынып кайттым. (*Акбайны күреп.*) Акбай!.. Мин сине таныйм бит, Акбай! Исәнме, дустым, Акбай! Картайсаң да, таныдым.

Акбай. Син дә бәләкәй Апуш түгел инде. Әнә Шүрәле генә үзгәрми.

Тукай. Исәнме, Шүрәле! Сине дә сагындым. Кушлавыч белән Кырлай шүрәлеләре кебек Шүрәле беркайда да юк. Син миңа ачуланма инде, Шүрәле. Бармакларыңны Былтырдан кыстырып шигырь яздым.

Шүрәле. Шүрәлеләр үч сакламый.

Тукай. Карлыгач, мин сине дә таныдым. Синең очып уйнауларың һәрчак күз алдында булды.

Акбай. Бу Карлыгач инде, Тукай, син белгән Карлыгач түгел.

Тукай. Мин белгән Карлыгач, әнә Сандугач та мин белгән Сандугач. Күбәләк тә мин белгән Күбәләк. Минем күңелемдә алар барысы да исән. Рәхмәт сезгә үз итеп каршылавыгыз өчен! Сагындым, бик сагындым туган ягымны. Туган якларын сагына белмәгәннәр иң бәхетсез кешеләрдән алар.

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.

Күбәләк. Тукай абый, сине шагыйрь, диләр. Ә кем ул шагыйрь?

Сандугач. Әйе, әйе, кем ул шагыйрь?

Тукай. Менә син, Сандугач, «моңлы җырым» дип җырладың. Ә нәрсә ул моң?

Сандугач. Моңмы? Моң ул моң инде.

Тукай. Моң ул күңелнең уйлануыдыр. Әгәр дә баш белән уйлыйсың икән, монысы акыл буладыр, күңел белән уйласаң, моң туадыр.

Шүрәле. Аңладыңмы инде? Шигырь дә шул була инде, әйеме, Тукай? Күбәләк, дисәң, ул күбәләк кенә була, ә менә Күбәләгем-түгәрәгем, дисәң, шигырь була. Дөрес әйтәмме, Тукай? Әгәр дә мәгәр шуны көйгә салсаң, җыр туа. (*Җырлап.*)

Күбәләк гөлләргә кунса,
Гөлләр тибрәнә микән?!
Ул да мине сагынганда,
Күбәләгем-түгәрәгем,

Асыл кошым-сандугачым,
Җырлап җибәрә микән.

Ишеттеңме, Сандугач, синең исемең дә җырга кергән. Белдегезме инде шигырьнең ни икәнен? Дөрес әйттемме, Тукай?

Тукай. Шүрәлеләр ялгыша белмиләр. Шүрәле дөрес әйтә. Дусларым, күңел сөенгәндә, шатлыклы шигырьләр, күңел хәсрәтләнгәндә, моңсу шигырьләр туа. Менә сезне күрдем дә, күңел куана. Һәм, әлбәттә инде, сезнең хакта бер генә дә начар шигырь язып булмый. Әйе бит, Акбай?

Акбай. Дөрес әйттең, Тукай. Әйдә хәзер туган җиреңә кайтыйк. Карлыгач, бар, син кайта тор, балаларың белән Тукайны үз нигезеңдә каршы алырга әзерлән.

Тукай. Акбай, дусларым! Әгәр дә рөхсәт итсәгез, мин ялгызым гына шушы чишмәнең челтерәвен тыңлап бераз гына утырыр идем.

Шүрәле. Дөрес, шагыйрь уйланырга тиеш, ләкин, Сандугач, Күбәләк, ерак китмәгез. Синең җырың, Сандугач, әкрен генә ишетелеп торырга тиеш. Син дә, Күбәләк, шушы тирәдәрәк уйна. Кил, Тукай, утыр шунда. Ә мин сиңа комачауламыйм. Әнә шунда тавыш-тынсыз басып торырмын. Әгәр уйларың ераккарак китәргә теләсә, кил дә сөял миңа. Мин бит кешеләр уйлап чыгарган зат, безгә таянсаң, халык мәхәббәтен яуларсың. (*Бер читкә барып, агач булып баса.*)

Башкалар да чыгып китәләр. Тукай чишмә янына утыра, чишмә җырын тыңлый, Сандугачның чутылдавы ишетелә, Күбәләкнең уйнавы да рәшә аша күренә. Кинәт барысы да тынып кала. Үз күләгәсе белән кояшны
каплап, Каракош керә.

Каракош. Исәнме! Танийсыңмы мине? Син Апуш чагыңда, мин бу урынга килгән идем. Син миннән курыкмаган булып маташтың. Таныдыңмы? Каракош мин!

Тукай. Нигә килдең?

Каракош. Минем киткәнем дә юк. Китәргә җыенмыйм да.

Тукай. Сиңа миннән ни кирәк?

Каракош. Миңа синнән берни дә кирәкми. Синең куркуың гына кирәк миңа. Мин бөтен җан ияләренең дә куркуыннан үземә көч алам. Син җыен Сандугач-Күбәләкләрне, Карлыгач-Акбайларны яратасың, туган ягыңны сагынып-яратып кайттың. Мине ярат димим. Синең яратуың миңа кирәкми. Син миннән курык кына. Сөйләгән сүзләрең, язган шигырьләреңнең төбенә курку ятсын, бу бәндәләрне дә миннән куркырга өйрәт.

Тукай. Курыкмасам нишләтерсең?

Каракош. Өегездә кара күләгә булып торырмын. Йөрәгеңдә шом булыр. Әгәр курка белсәң, ара-тирә өстеңә кояш чыгарып алырмын.

Тукай. Син, Каракош, минем кеше икәнлегемне онытасың.

Каракош. Онытмыйм. Әйе, син бәләкәй чагыңда ук «мин – кеше» дигән идең. Ул вакытта сине саклап калдылар. Хәзер инде мин синең белән алышырга теләмим. Ләкин өстеңә кояш чыгармаячакмын.

Тукай. Юк инде, Каракош, кояшка ук хуҗа була алмассың.

Каракош. Күләгәм өстеңдә торыр.

Тукай. Минем җанымдагы кояшны күләгәң каплый алмас.

Каракош. Алайса, әйдә болай килешик. Мине мактап шигырь яз.

Тукай. Сине мактап, Каракош, кара йөрәклеләр язсын.

Каракош. Аңламыйм, нәрсәгә буталасың шул Сандугач, Карлыгач, Күбәләкләр белән. Алардан ни чыккан?

Тукай. Аны аңлар өчен Каракош булып тумаска кирәк. Ә бит, Каракош, алар синнән көчлерәк.

Карлыгач (*очып кереп*). Көчлерәк. Кит, Каракош, шагыйрь яныннан.

Каракош. Тагын килдеңме?

Карлыгач. Килдем, куып тотып кара.

Карлыгач Каракошка һөҗүм итә дә читкә китеп өлгерә. Ачуы чыккан Каракош тагын аны куып китә. Тукай өстенә кояш нуры сибелә. Тукай, күккә карашын төбәп, чалкан ята. Янә Сандугач сайравы ишетелә. «Исәнме, Тукай!» дигән тавышка торып, Тукай карана. Апуш
пәйда була.

Апуш. Исәнме, Тукай!

Тукай. Исәнме!.. Син кем? Тукта, тукта, таныйм бит мин сине.

Апуш. Танийсың, билгеле. Апуш ич мин. Синең балачагың. Син егет булып кайткансың. Мине сагындыңмы соң, Тукай? Нигә эндәшмисең?

Тукай. Ни дип дәшим икән, Апуш. Бик сагындым, дисәм, алдашу булыр. Ятимлектә үскән балачакны кем сагыныр икән?

Апуш. Шулайдыр. Син бу чишмә яныннан киткәндә, мин бик моңсу идем. Язмышым кайда мине илтеп ташлавы билгесез иде. Ләкин балачак барыбер балачак инде. Аның үз матурлыгы бар. Син бит шуны сагынып кайттың.

Тукай. Әйе, сагынмасам, ашкынып кайтмас идем.

Апуш. Рәхмәт сиңа, Тукай!

Тукай. Ни өчен миңа рәхмәт?

Апуш. Мин ятимне кеше иттең.

Тукай. Аның өчен бер Ходайга һәм кешеләргә рәхмәт әйтергә кирәк.

Апуш. Шулай анысы, ләкин үзең тырышмасаң, бүтәннәр кул селтәр иде. Ходай да, тырышканны яратырмын, дигән.

Тукай. Син өлкәннәр кебек сөйләшәсең.

Апуш. Бала булсам да, мин бит синең балачагың, Тукайның балачагы. Укы әле миңа берәр шигыреңне, Тукай!

Тукай.

Айрылып китсәм дә синнән гомремнең таңында мин,
И Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин.
Ул таныш кырлар, болыннар тартты әүвәл хиссеми;
Тарта торгач, куймады, кайтарды ахыр җисмеми.
Кысса да синдә фәкыйрьлекләр, ятимлекләр мине,
Изсә дә үз ишләремнән хур вә кимлекләр мине, –
Үтте инде ул заманнар, очтылар шул кош кеби;
Уйласам, ул көннәрем тик кичтә күргән төш кеби.

Апуш. Син инде китмәскә кайттыңмы?

Тукай. Юк, Апуш, мин инде авылны яратсам да, аңа гына сыймамын, ахры. Казаныбыз үзенә тарта. Минем тавышым Казан мөнбәреннән яңгырарга тиеш. Ә авылга мин кайтып йөрермен. Кайткан саен, шушы чишмә янында синең белән очрашырбыз.

Апуш. Әйе, оныта күрмә мине.

Тукай. Минем сиңа бер үтенечем бар, Апуш. Син хәзер дусларыңны җый да уйна, күңел ач. Ә мин читкәрәк китим дә сезне күзәтим.

Апуш. Нинди уен уйнарга?

Тукай. Бала чагымда мин уйный алмый калган уеннар күп. Һәрберсе аларның миңа кадерле.

Апуш. Акбайны чакырыйм алайса.

Тукай. Чакыр, барысын да чакыр. (*Агач-Шүрәлегә барып сөялә.*)

Апуш. Акбай! Акбай!

Акбай (*чабып керә*). Кем мине чакырды?

Апуш. Әллә күрмисеңме, әллә танымыйсыңмы? Мин ич бу – Апуш!

Акбай. Ә Тукай кайда?

Апуш. Мин бит инде ул Тукай.

Акбай. Юк, син Апуш, Тукайның бәләкәй чагы гына.

Апуш. Ә син Тукайның бәләкәй чагы белән уйнарга теләмисеңме?

Акбай. Телим. Ә нинди уен уйныйбыз?

Апуш. Әйдә, мәтәлчек атабыз. Калма миннән. Әйдә.

Мәтәлчек атып уйныйлар.

Бер аякта сикерәбез, баш кадала йөрибез.

Уйныйлар.

Акбай. Күбәләк белән Сандугачны чакырыйк.

Апуш. Әйдә.

Акбай.

Апуш. *(Күбәләк белән Сандугачны чакыралар.)*

Сандугач, Күбәләк,
Килегез бергәләп.
Уеннар уйнарга,
Биергә, җырларга.
Без чишмә буенда,
Килегез уенга!

Сандугач керә.

Сандугач. Сандугач дигән сүз ишеттем, сез чакырдыгызмы?
Акбай
Апуш Без, Сандугач, без. Безгә синең җырың җитми.
Сандугач. Рәхим итегез! Минем җырым туган ил турында.

Чут-чут, чут-чут,
Җырым илем турында.
Туган җирем турында,
Чут-чут, чут-чут.
Туып үскән илемдә
Сайрыйм мин үз телемдә,
Чут-чут, чут-чут.
Әрәмәлек, болыннар
Җанга якын урыннар,
Чут-чут, чут-чут.
Сайрыйм шулар турында,
Яшәү яме җырымда.

Күбәләк керә.

Күбәләк. Мин сезнең чакыруыгызны ишеттем. Соңгарак калганыма гафу үтенәм. Болында дусларым белән уйный идем.
Апуш. Ә син дусларыңны да чакыр монда, Күбәләк. Бергәләшеп уйныйк.
Күбәләк. Һә-һә-һәй! Күбәләкләр! Монда килегез.

Чыркылдашып күбәләкләр керә.

Таныш булыгыз, минем дусларым! Дусларым хакына күбәләкләр биюен бүләк итик.

Күбәләкләр биюе.

Шүрәле. Нигә тагын мине онытгыгыз? (*Тукайга.*) Гафу итегез, Тукай әфәнде, бөтенесе күңел ачканда, мин агач булып басып тора алмыйм. Рәхим итеп бирегә утырыгыз. (*Апуш янына килеп.*) Акбай сикерә, Сандугач җырлый, Күбәләкләр бии, мине чакырмыйлар да. Миннән башка бәйрәм була алмый. Кушлавыч, Кырлай урманнарының атказанган Шүрәлесе «Шүрәле» балетыннан па-де-де бии. Кул чабыгыз. (*Бии.*)

Бию бетеп, алкышлар туктагач, балаларын ияртеп, Карлыгач керә.
Алар барысы да фрактан.

Карлыгач. Котлы булсын бәйрәмегез! Бәйрәмгә бүләк – Карлыгачлар хоры. Җыр! «Туган авыл». Габдулла Тукай сүзләре. Башладык!

Карлыгач дирижерлык итә, балалары җырлый.

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.

Апуш, Акбай, Шүрәле, Сандугач, Күбәләкләр җырлаучылар тирәли
түгәрәк әйләнәләр. Тукай сәхнә алдына килә. Ут аны гына яктырта.

Тукай (*Күбәләкне чакыра*). Күбәләк! Мөмкин булса, кил әле яныма.
Күбәләк. Килдем.
Тукай. Син нинди гүзәл, Күбәләк! Табигать сине шундый да матур итеп бизәгән. Ә үзеңнең гомерең бик кыска. Әйт әле, Күбәләк, нигә ул шулай икән? Нигә матурлыкның, гүзәллекнең, нәфислекнең гомере кыска була икән?
Күбәләк. Мин белмим. Мин канатларымны җилпеп оча гына беләм, чәчәктән чәчәккә куна гына беләм. Син үзең әйт.
Тукай. Мин дә белмимдер. Кешенең дә бит гомере озын түгел, Күбәләк. Әллә кеше дә матур, гүзәл микән? Үзенә Ходай тарафыннан бирелгән кыска гына гомере эчендә кеше бөек эшләр эшләп өлгерергә тиештер. Әнә бит, әле кайчан гына сезнең белән уйнап йөргән Апуш идем, бүген зуп-зур Тукай булдым. Мин инде уйный алмыйм, мин уйлый гына алам. Уйларым җирем, илем, милләтем турында. Сау булыгыз, күбәләкләр, сандугачлар, карлыгачлар, шүрәлеләр, Акбай! Сау бул, авылым! Мин инде китәм. Әүвәл Казанга. Аннан... Аннан киләчәккә. Киләчәктә дә мине көтәләр дип өметләнәм.

Әкрен генә артка чигенеп, яктылыкка кереп китә. Җыр аны озатып бара.

Пәрдә.

# Эчтәлек

Иҗатында – ил гаме...*А.Габәши-Салихова* ..........

Шулай булды шул .........................
Галиябану, сылуым иркәм ....................
Алты кызга бер кияү .......................
Саташу ...............................
Риваять ...............................
Мулла ...............................
Дивана ...............................
Син мине күрәсеңме? .......................
Ак тәүбә, кара тәүбә ........................
Читлек ...............................
Гашыйк буласым килә ......................
«Интернет Акбай» .........................
Әйт әле, Күбәләк .........................

Литературно-художественное издание

**Миннуллин** Туфан Абдуллович

## Пьесы

Казань. Татарское книжное издательство. 2010

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

**Миңнуллин** Туфан Габдулла улы

## Пьесалар

Мөхәррире *Р.Ә.Заһидуллина*
Рәссамы һәм бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Н.Н.Мусина*
Корректорлары *Л.Р.Галимова, С.Н.Галимуллина, Г.Г.Зиннәтуллина*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 15.07.2010.
Форматы 84г108 1/32. Шартлы басма табагы 21,84.
Тиражы 2000 д. Заказ О-973.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.